# КАЗАН УТЛАРЫ

11. 1986



# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**1986**

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

Г. МӨХӘММӘДОВА. **Сикәлтәле туры юл.** *Документаль повесть* . . . . . . . . . . . 3
Ф. САФИН. **Мәхәббәтнең бәхет кичендә.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 51
Ә. БАЯНОВ. **Мәңгелек бәхәс.** *Повесть* . . . . 54
Г. ЛАТЫЙП. **Зәңгәр ялкын.** *Шигырьләр* . . . 83
Н. МАДЪЯРОВ. **Кырлар тулып.** *Шигырьләр* . 86
Р. НИЗАМИЕВ. **Иҗаттагы егет чак.** *Р. Кутуйга 50 яшь* . . . . . . . . . . . . . . . 88
Р. КУТУЙ. **Чатнаган көзге.** *Хикәя* . . . . . 89
С. МУЛЛАГАЛИЕВ. **Бер яктылык.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 93
Н. ЗАРИПОВ. **Киттек.** *Шигырьләр* . . . . . . 96
Р. ВӘЛИУЛЛИН. **Безнең язмыш.** *Шигырьләр* . . 97
Р. ХӘМИД. **Майның унбишләрендә.** *Ике бүлектә драма* . . . . . . . . . . . . . . 99

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА

В. ШӘРИПОВ. **Яңа гасыр тракторы** . . . . . . 118
**Иңнәрендә ил гаме** . . . . . . . . . . . . 122

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

М. ӘХМӘТОВ. **Үсеш, яңарыш еллары** *(Балтач районы)* . . . . . . . . . . . . . . . 127

М. ВӘЛИЕВ **Тәнкыйтьчеләр** . . . . . . . . 130
**Тәрҗемә турында сөйләшәбез.** *(М. Мәһдиев, Г. Сафарова, Н. Нәбиуллина, К. Хәмзин)* . 139

БИБЛИОГРАФИЯ

В. БАЖАНОВА. **Театрлар дуслыгы** . . . . . 143

ИЛЕБЕЗ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘРЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

В. ДЕМЕНТЬЕВ. **Хәсән Туфан гөлләре** . . . . 146

СӘНГАТЬ

Б. ГЫЙЗЗӘТ. **Нигез ташларын салганда** . . . 151

САРА САДЫЙКОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Г. БӘШИРОВ. **Аның тылсымлы көче** . . . . 157

ЯЗУЧЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Н. АРСЛАНОВ. **Якын дуслар идек** 162

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09.
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

Г. ЧОКРЫЙНЫҢ ТУУЫНА 160 ЕЛ

Р. ӘХМӘТОВ. **Шәмдәлләрдә якты утлар...** . . 16
Г. ЧОКРЫЙ. **Мәдхе Болгар.** ***Шигырьләр*** . . . 169

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Я. АБДУЛЛИН, М. ГОСМАНОВ, И. ТАҺИРОВ. **Һади Атласи турында** . . . . . . . . . 172
А. КОЧКИНА. **Идел буе болгарларында рун язуы** . . . . . . . . . . . . . 176
Х. КУРБАТОВ. **Археолог А. Кочкинаның «Идел буе болгарларында рун язуы» исемле мәкаләсенә карата** . . . . . . . . . . 179
Х. ФӘРХЕТДИНОВА. **Моңлы гомер** . . . . . 180
Җ. ЗӘЙНУЛЛИН. **Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе һәм «Кәлилә вә Димнә» турында** . . . . 183

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

К. ЛАТЫЙПОВ. **Көндезге яктылык** . . . . . 186

С. ШАКИР. **Демьян Фәтхи** . . . . . . . . . 189

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . 192

## *В нашем номере*

Документальная повесть Г. МУХАММЕДОВОЙ о Галимзяне Ибрагимове. Повесть А. БАЯНОВА «Вечный спор». Рассказ Р. КУТУЯ «Зеркало с трещиной».
Стихи Ф. САФИНА, Г. ЛАТЫЙПА, Н. МАДЪЯРОВА, С. МУЛЛАГАЛИЕВА, Н. ЗАРИПОВА, Р. ВАЛИУЛЛИНА.
Драма Р. ХАМИДА «В разгаре мая».
Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь. Статья В. ШАРИПОВА «Трактор нового столетия» о Елабужском тракторном заводе. Статья Р. КАРАМИ, А. РАШИДОВА, Р. АХМЕТЗЯНОВА о земляках-нефтяниках Сибири.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» выступление первого секретаря Балтасинского райкома КПСС М. АХМЕТОВА.
В рубрике «Литературная критика» статья М. ВАЛИЕВА о проблемах современной литературной критики. Статья В. ДЕМЕНТЬЕВА (Москва) «Цветы Хасана Туфана».
В дискуссии о проблемах литературного перевода участвуют М. МАГДЕЕВ и читатели.
В номере рецензируется книга «Межнациональные связи татарского театра».
В рубрике «Искусство» статья Б. ГИЗЗАТА об истории татарского театра.
Материалы к юбилеям Г. Чокрый, С. Садыковой, Д. Фатхи, Р. Кутуя.
К истории культуры: статья Я. АБДУЛЛИНА, М. УСМАНОВА, И. ТАГИРОВА о жизни и деятельности Хади Атласи.
Статья А. КОЧКИНОЙ «Руническое письмо у Волжских булгар» и комментарий Х. КУРБАТОВА. Статьи Н. Арсланова, Х. Фархетдиновой и Дж. Зайнуллина.
В рубрике «Творчество молодых» статья К. ЛАТЫПОВА о творчестве художника Ф. Якупова.
На наших обложках — творчество художника И. Халиуллова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова. А. Минһаҗева.*

Производствога бирелде 1.09.1986 ел. Басарга кул куелды 17.10.1986 ел. ПФ12469. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 62449. Заказ В-329. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

## Гөлсем Мөхәммәдова

# СИКӘЛТӘЛЕ ТУРЫ ЮЛ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

*Журнал варианты*

## Саубуллашу

Мәдрәсәне ташлап чыгарга мәҗбүр булгач, Галимҗан Ибраһимов туган авылына — Солтанморатка кайтып китте.Ләкин анда этисе белән килешә алмады. Нәкъ Вәли мулла мәдрәсәсеннән куылган чагындагы кебек, Гыйрфан мулла бу юлы да нык ачуланды:

— Синең күңелең укуда, адәм булуда түгел икән! Аңлашылды! Вәли мулла мәдрәсәсеннән куылган чагында: «Ул бик артта, торгынлыкта катып калган мәдрәсә, анда шәкертләргә белем бирмиләр, киресенчә, бар кадәр акылыңны төрле хорафатлар белән томалыйлар, надан калдыралар!» — дип аклanган идең! Ә хәзер нәрсә?

Галимҗан этисенә:

— Ул мәдрәсә чыннан да шундый иде бит. Сез үзегез дә шул фикергә килгән идегез... — дип әйтә башлаган иде, Гыйрфан мулла йодрыгы белән өстәлгә сукты:

— Әхлаксыз! Сүземне бүлмә!

Көтелмәгән тупас мөгамәләдән кашларын җыерып, башын чайкаса да, Галимҗан сүз әйтүдән үзен тыйды. Улы эндәшми калгач, этисе бераз тынычланган сыман булды. Тавышын баса төшеп:

— Әйдә, анысы шулай булсын! «Менә бу мәдрәсәдән шәкертләр мәдәниятле, мәгърифәтле булып тәрбияләнеп чыгалар! Монда кешене кимсетмиләр, түбәнсетмиләр! Монда дөнья таләп иткән тарих, җәгърафия, рус теле, хифезсиххәт[1], һәндәсә[2] кебек фәннәрне укыталар!» — дип, авыз суын корыганчы «Галия» мәдрәсәсен мактаучы син идең бит! Инде тагы ни кирәк? — дия-дия, Гыйрфан мулла үтәли тишәрдәй итеп улының күзләренә текәлде, йодрыгы белән тагын өстәлгә сугып алды.

Этисенең ярсуын көчәйтмәс өчен, башын түбән иеп, эндәшми генә утырган Галимҗан сискәнеп китте. Улы нәрсәдер әйтергә тели дип уйлаган Гыйрфан мулла имән бармагын янады:

---

ГӨЛСЕМ МӨХӘММӘДОВА *(1903) — Әстерханда туган. Укучыларга «Яшьлек көннәре» дигән китап авторы һәм тәрҗемәче буларак таныш. СССР Язучылар союзы члены. Казанда яши.*

— Теленне тыеп тор! Кемгә каршы киләсең?! Инде минем белән карулашырга җыенасыңмы, оятсыз! — дип кычкырды.

Улының:

«Мин бит бер сүз дә әйтмәдем»,— дигәнен ишетмәгән сыман, үзенекен дәвам итте:

— Тормыш көтә башлаганымнан алып бүгенгәчә: «Балаларыгызны укытыгыз, мәгърифәтле, халкыбызга файдалы кешеләр булып үссеннәр!» — дип, агай-энеләрне үгетләп, ничәмә-ничә авыл балаларын үз кулым белән остазларына тапшырдым. Алар бүгенгәчә мин урнаштырган мәдрәсәләрдә укыйлар. Берсен дә кумадылар! Берсе дә укуын ташлап китмәде. Ә минем үз балаларымны — абыеңны да, сине дә,— мәдрәсәдән куып чыгаралар! Бу — мәсхәрә, хурлык бит! Халык күзенә күренерлегемне калдырмадыгыз! Мондый балаларның булганыннан булмаганы яхшы! — дип, кулын селтәп, читкә борылды. Шул араны күзе тәрәзәгә төште: капкадан хатыны Хәсәнә остабикә кереп килә иде.

Улына карата әйтелгән каты сүзләрнең остабикә йөрәгенә агулы чәнечке булып кадалачагын Гыйрфан мулла белә. «Шундый йомшаклыгың белән балаларны бозып бетерәсең!» — дип, хатынын шелтәләгән вакытлары да булгалады. Йөрәгендә кара кан булып оешкан ачуларын, җәрәхәтле уйларын улына иркенләп әйтү, күңеленә сеңдерү өчен, ялгыз калырга теләп, остабикәсен күршеләргә, бәби туена барырга күндергән иде. Менә хәзер ул кайтып та килә. Күрәсең, йөрәге сизгәндер. Туйның таралганын да көтмичә өйгә ашыккан. Әнкәсе өйгә кереп килгәнче, сүзне тизрәк йомгакларга кирәк дип, Гыйрфан мулла аякка басты, Галимҗанга таба борылып, аңа күзен дә күтәрмичә, йодрыгы белән өстәлгә суга-суга:

— Сүзем шул: синең кебек баланың миңа кирәге юк! Күземә күренәсе булма! Кая теләсәң, шунда кит! — дип кулын селтәде дә, авыр басып, ишеккә таба атлады.

* * *

Әтисе чыгып киткәч, Галимҗан терсәкләре белән өстәлгә таянган хәлдә, йодрыклары белән ике яктан чигәләрен кысып, уйланып калды. Әтисенең катылыгына үпкәләүдән бигрәк, аның хәленә керергә тырыша, хәтта аны бераз кызгана да кебек иде. «Бәлки әткәйгә, мине «Галия»дән кудылар дип әйтәсе булмагандыр? Бу кадәр сүз дә чыкмас иде. Ләкин ялганларга, алдашырга теләмәдем, турысын әйттем. Ә чынлыкта мине бит рәсми рәвештә кумадылар! Фәкать киләсе уку елы башлаганда, нинди дә булса бер сылтау табып, мәдрәсәгә кабул итмәячәкләрен Зыя Камали миңа аңлату белән генә чикләнде. Ләкин ничек булса да барыбер: куылу — куылу була инде ул! Моңа төрле аңлатмалар биреп маташу мәгънәсез эш. Шулай да куылуның сәбәбе, әткәй уйлаганча, бозыклык, юлсызлык түгел!» Утыра торгач, егетнең башына тагын бер яңа уй килде: «Бәлки куылуымның сәбәпләрен әткәйгә яхшылап аңлата алмаганмындыр»,— дип, Галимҗан үзе белән мәдрәсә җитәкчеләре арасындагы низагның сәбәпләрен күңеленнән кичерде: укыту программасын тагын да яңарту, реформалаштыру һәм кайсыбер фәннәрдән иске фикерле мөгаллимнәр урынына чын мәгънәсендә белемле укытучыларны чакырту кирәклеге турында эчке идарәгә биргән таләпләребез, бу — бер! — дип, сул кулының чәнчә бармагын бөкте. Үзебезнең «Белем» җәмгыятебездә Коръәннең аерым аятьләрен тәрҗемә итеп, шул турыда фикер алышуыбызның хәбәре тышкы идарәгә барып җитүе. Бу — ике! Егетнең атсыз бармагы бөгелде. Ниһаять, кулъязма газетабызда язган мәкаләләребез эчке һәм тышкы идарә әгъзаларының күңелләренә ошамау. Бу — өч! — дип, урта бармагын бөкте дә имән бармагына карап көлемсерәп

[1] Хифезсиххәт — гигиена
[2] Һәндәсә — геометрия

куйды. Башын чайкап: «Әйе, «Коръән алладанмы, түгелме?» исемле китабымның эчке идарәдә дә, тышкы идарәдә дә тудырган шау-шуы турында әткәйгә бер сүз дә әйтмәдем шул! Ләкин бу куркудан түгел, фәкать аның дини карашларын кимсетәсем килмәгәнлектән генә иде. Әткәй куса-кумаса да, барыбер миңа моннан тизрәк китәргә кирәк. Күз алдында тормасам, ул да тынычланыр, мин дә үз юлымны табармын. Тик менә әнкәйне ничек күндерергә? Китүемнең сәбәбе әткәйнең холыксызлануы түгел, бәлки тормыш юлымны билгеләр өчен кирәк булганлыгын аңа ничек аңлатырга?» — дип уйланып, бүлмә буйлап йөрдейөрде дә тәрәзә янына килеп тукталды.

Икенче бүлмәдә Гыйрфан мулла остабикәсенең кереп килгәнен көтеп алды һәм гадәттә булмаганча кабаланып:

— Ә-ә, кайттыңмы, анасы! Иртәрәк кайтканың яхшы булды әле. Чәй эчәсем килгән иде. Самавыр куеп җибәрсәң, яхшы булыр! — дигән сүзләр белән каршылады.

Мәсьәлә чәй эчәсе килүдә түгел иде, әлбәттә. Остабикә туйга баргандагы өс-башын алмаштырыр өчен залга керсә, улының кәефсезләнүен күреп борчылыр дип сагаюдан иде.

Иренең урынсыз кабалануына шикләнгән остабикә аңа күз кырые белән генә карап:

— Алайса аз гына сабыр ит әле, өс-башымны алмаштырыйм,— дип, зал ишегенә таба атлады.

— Күзлегемне күрмәдеңме? Улыңның Уфадан алып кайткан гәзитләрен укыйм дип алган идем, кая куйганымны хәтерләмим,— дигән булып, Гыйрфан мулла хатынын тагын туктатты.

Хәсәнә остабикә сәке өстендә яткан газетаны күрсәтеп, аның астындагы күзлекне иренең кулына китереп тоттырды һәм: «Моның шулай хәйләләп маташуы юкка түгел. Мине залга кертмәскә тырыша бу!» — дип уйлап алды, ире тагын берәр сәбәп тапкалаганчы, тиз генә залга кереп китте.

Тәрәзә аша ишегалдына карап торган улын күргәч үк Хәсәнә иренең ни өчен монда кертергә теләмәвен аңлады: «Атасы тагын бик каты орышып рәнҗеткән булса кирәк. Бүлмәгә кергәнемне дә сизмәде! Шулай кешенең аңын алгандай рәхимсез бәрелмәсә булмас идеме икән?!» — дип уйлап, аңа йомшак тавыш белән эндәште:

— Нәрсә шулай бик уйланып калдың, улым?

Җиңел атлаган аяк тавышларыннан бүлмәгә әнисе кергәнен Галимҗан сизгән иде. Тик борчулы йөзен күрсәтмәс өчен тәрәзәдән күзен алмыйча басып тора бирде. Ләкин анасы үзе эндәшкәч, җавапсыз калу да мөмкин түгел иде. Ул, елмаерга тырышып, әнкәсенә таба борылды.

— Чыннан да, әнкәй, уйланып калганмын икән.

— Әллә әткәң берәр авыр сүз әйттеме?

— Әткәйнең миннән ризасызлыгын үзең дә беләсең бит! Мәдрәсәдән ни өчен китүемнең сәбәбен һаман аңларга теләми. Бозыклыктан, юлсызлыктан дип уйлый...

Галимҗан кергәннән бирле әнисенең аягүрә басып торуын абайлап:

— Син утыр, әнкәй, синең белән киңәшәсем бар. Сүз бәлки озакка сузылыр! — дип, аны өстәл янындагы урындыкка утыртты. Үзе каршыга килеп басты:

— Минем озакламый моннан китәргә тиешлегемне аңлыйсыңдыр?

— Мин юкта әткәң сине тагын өйдән куа башладымы әллә? — дип, Хәсәнә остабикә улының сүзен бүлде.— Син аңа рәнҗемә, улым! Күңелеңә авыр алма! Ул һәрвакыт башка балаларына караганда сине иң зирәге, иң акыллысы дип исәпли. Мәдрәсәне тәмамлагач, бу бала халкыбызга мәгърифәт нуры чәчәр, аларны алга әйдәр! — дип хыяллана иде. Шуның өчен мәдрәсәне ташлап китүең аңа бик авыр булды! Син инде аның да хәленә кер, үпкәләмә! Биш-алты көн дә үтмәс — барысы да онытылыр!..

— Әткәйнең миңа шулай каты бәрелүе күңелсез, әлбәттә. Ләкин мин аңа үпкәләмим. Хыялның җимерелүе һәркемгә дә авыр ул. Ләкин әткәй бер нәрсәне аңламый: хәзерге көндә хәтта «Галия» кебек алдынгы саналган мәдрәсәләр дә кара сөрем астында яшәгән халкыны мәгърифәт, ягъни белем бирә алмыйлар!

— Алай булгач нишләргә соң? Әллә бөтенләй укымаска кирәкме? дип, Хәсәнә остабикә аптырап калды.

— Укырга кирәк, әлбәттә. Тик бүгенге көндә яраклы белемнәрне бирә торган башка урыннарны эзләү хәерлерәк,— дип, Галимҗан анасын тынычландырырга тырышты.

Остабикә һаман шикләнгән сыман:

— Ул тагын нинди урыннар икән? — дип сорады.

Улы әнисе янына килеп утырды, аның борчулы йөзенә карап:

— Кызганычка каршы, безнең үзебездә, үз телебездә укыткан, заманабызча тиешле белемнәрне биргән гимназияләр, дәрелфөнүннәр-университетлар юк әле,— диде.

— Анда урысча укыта торганнардыр бит? Шунда кереп укырга телисеңме?

Галимҗан ихтыярсыз көлеп җибәрде.

— Бик керер идем дә шул, мондый фән сарайларының ишекләре хәзергә безнең кебекләргә ябык әле! Бу хәл русларның: җәннәткә бик керер идем дә, гөнаһларым җибәрми,— дигән мәкаленә туры килә, әнкәй.

— Нишләп алай?

— Русларда безнең «Галия» кебек мәдрәсәләргә караганда күп дәрәҗә югарырак белем бирә торган гимназияләр бар. Укуны уңышлы рәвештә тәмамлаган гимназистларга «Өлгергәнлек аттестаты» дигән кәгазь бирәләр.

Улының аңлатмасын дикъкать белән тыңлап утырган Хәсәнә остабикә, зур күзләрен кыса төшеп, керфекләре арасыннан гына читкә карап уйланып торганнан соң:

— Урыс гимназиясендә укымагач, андый кәгазьне каян аласың? — дип сорады.

— Аның билгеле бер юлы бар, әнкәй...

Ана, улына сүзен тәмамларга да бирмичә, сискәнгән төсле булды:

—Туры юлмы ул?!

Галимҗан тагын елмайды. Әнисенең җилкәсенә кулын салды, аны тынычландырыр өчен тәфсилләп аңлата башлады:

— Әлбәттә туры юл. Университетта укучы берәр студентны яллап, өлгергәнлек аттестатын алыр өчен кирәк булган белемнәрне аңардан өйрәнәсең. Аннан соң: «Сезнең кул астындагы уку йортында өлгергәнлек аттестатына имтиханнар тапшырырга рөхсәт итегез»,— дип гимназия башлыгына гариза бирәсең. Рөхсәт итсә, тиешле хакын түләп, имтиханнар тапшыра башлыйсың. Тырышлыгың уңышлы нәтиҗә бирсә, кулыңа аттестатыңны алып, университет ишегенең тоткасына ябышасың. Мин белгән юл — менә шул.

Хәсәнә остабикә тынычланган кебек булса да, йөзендә борчылу эсәре сизелә иде әле.

— Фикерең дөрес, юлың туры икән,— диде ул уйчан гына.— Ләкин студентка түләргә дә, теге кәгазьне алыр өчен дә акча кирәк икән бит. Ул кадәр акчаны каян алырга соң? Сатып, акчага әйләндерерлек алтын-көмешем дә юк бит минем! — дип, ул тагын уфтанып куйды.

— Борчылма, әнкәй! Синең акчаң да, алтын-көмешең дә кирәкми! Акчасын да, алтын-көмешен дә үз хезмәтем белән табып, мин үзем синең кулыңа китереп тоттырырлык егет инде. Аттестатлы булыр өчен кирәк акчаны үзем табармын. Менә шуның өчен дә миңа мөмкин кадәр тизрәк моннан китәргә кирәк. Кыр эшләрен тәгәлләдек дип әйтергә мөмкин. Калган ягын Әхми бабай белән Габделхәким дә башкарыр...

Әнисе аптырап, күзләрен зур ачып улына карады.

— Шулай ук тиз китәргә уйлыйсыңмы?

— Тизрәк китсәм, максадыма якынрак булырмын.

Галимҗан, әнисе бераз тынычлана төшсен дип, эндәшми утырды. Ниһаять Хәсәнә остабикә:

— Кая китмәкче буласың? — дип сорады.

— Казах даласына китәргә уйлыйм. Анда минем кебек шәкертләргә һәрвакыт эш табыла. Балалар укытып, казах халкына кулымнан килгәнчә хезмәт күрсәтермен. Беләсеңме, минем үземә дә ничаклы файда булачак! Кыш буе түләп укырлык табышымны әйтеп тә тормыйм! Җәен, киң далада саф һава сулап, бөтен вөҗүдеңне тазартуың үзе ни тора!

Әнисенең елмайганын күреп, Галимҗанның да күңеле күтәрелде.

— Менә күрдеңме, куркырлык та, шикләнерлек тә, ачуланырлык та һичбер сәбәп юк. Барысы да үз вакытында җайланыр, борчылма! — дип аякка басты. Читкәрәк китеп анасына карап торды һәм: — Синә өстеңне алмаштырырга кирәктер, мин чыгып торыйм,— дип ишеккә борылды.

* * *

Галимҗан: «Кешеләр йокыдан торганчы юлда булырмын»,— дип уйласа да, әйберләрен күтәреп ишегалдына чыккач, әнисе белән Габделхәкимнең җигүле тарантаска нәрсәләрнедер иплән урнаштырып маташканнарын күрде. Бер әнисенә, бер Габделхәкимгә карап алгач, башы белән энесенә ишарәләп:

— Бу кая барырга җыена? — дип сорады.

Хәсәнә остабикә улының тавышын ишетүгә күтәрелеп карады да күз яшьләрен башындагы яулыгының очы белән сөртә-сөртә аңлатып бирде:

— Габделхәким кая да бармый. Ул сине озата. Әткәң таң атканчы торып, Әхмигә ат җигәргә кушты. Уфагамы, Оренбургамы — кая дисә, шунда илтеп куй үзен дип әйтте...

Әнисенең сөйләп бетергәнен көтәргә сабыры җитмәгән Габделхәким:

— Ә мин сине олы юлга чаклы озата барам! — дип кычкырды.

Галимҗан әтисеннән мондый яхшылыкны көтмәгән иде. Кичә кич саубуллашырга дип янына кергәч тә сөйләшергә теләмәде ул. Егет шул турыда әйткәч, Хәсәнә авыр сулап: «Ата кеше ата була инде ул,— диде.— Әнә хәзер дә тәрәзә янына килеп, ишегалдына күз салгалап йөри».

Әнисенең сүзләре Галимҗанның күңелен йомшартып җибәрде: «Ата кеше ата булганы кебек, бала кеше дә бала була белергә тиеш!» — дигән уй белән, кулындагы әйберләрен тиз генә тарантас өстенә ташлады да йөгереп өйгә кереп китте.

Әтисе, чыннан да, залда икән. Галимҗан ашыгыч адымнар белән аның янына килеп басты һәм кулын алды.

— Әгәр яшьлегем сәбәпле ялгышлык эшләгән булсам, кичер мине, әткәй. Ләкин мин һичбертөрле яманлык эшләмәдем. Хәзер китәмен. Кайчан кайтачагымны әйтә алмыйм. Ләкин юлым туры, изге максатка алып бара торган юл булачагына ышануыгызны телим. Авырма, сызланма, исән-сау бул, әткәй!

Улының шулай олылап саубуллашуына дулкынланудан Гыйрфан мулланың тамагына төер тыгылгандай булды, тавышы ничектер үзгәреп, калтырап чыкты. Кулын Галимҗанның җилкәсенә куеп:

— Яхшы юлга бар! — диде һәм ишеккә кадәр озатып куйды.

Өйдән атылып чыккан Галимҗанның ачылып киткән йөзен күреп, улының әтисе белән килешкәнен остабикә аңлап алды. Хәзер инде аның күзләре шатлыктан яшьләнде.

Әнисенең бәхетле балкыган йөзе буйлап тамган яшьләрне күргәч: «Әнкәйнең күңеле бик нечкә шул, бик сизгер! Әткәйнең йомшарганын

шунда ук сизде. Шуның куанычыннан жылый да ул хәзер»,— диган уйдан Галимҗан үзенең дә күңеле нечкәргәнен сизде.

— Исән-сау бул, әнкәй. Борчылма! Әткәй дә фатихасын бирде. Барып урнашкач ук мин хат язармын! — дип әнисен кочаклады ул.

Капканы киң ачып, атның кузгалуын сабырсызлык белән көтеп торган Габделхәким:

— Я, абый, утыр инде! — дип кычкырды.

Галимҗан, әтисе белән тагын бер кат саубуллашкандай итеп, зал тәрәзәләренә таба борылып карады. Әнисе, улыннан аерылырга теләмичә, аның күкрәгенә башын куеп:

— Яхшы юлга бар, балам! Аллаһе тәгалә үзеңне изге теләкләреңә ирештерсен! — диде һәм, үрелеп, Галимҗанның маңгаеннан үпте. Галимҗан исә, хәттыйн тыш дулкынлануын сиздермәскә тырышып, эндәшми генә тарантас янына килде.

Атлар кузгалды.

Хәсәнә остабикә, ихтыярсыз аккан күз яшьләрен тыя алмыйча, капка баганасына сөялеп, тарантас артыннан карап калды.

## Казахстан даласында

Галимҗан Ибраһимов Казахстанның киң җәйләвенә килеп җиткәндә язның соңгы матур көннәре иде. Ефәк кебек нәфис яшел үлән әле корымаган. Һава — күкрәкне киереп суларлык саф, хуш исле, бөтен җаныңны яңартып, җиңеләйтеп җибәрерлек җиләс һәм ачык. Ләкин киез тирмәләр арасында төркем-төркем йөреп торган халыкның табигать хозурлыгына шатлануы сизелми.

Күзәнәктән ал яулык
Тартышаек, яр-яр!
Кил, кил, кодам,
Кил, кодам,
Айтышаек, яр-яр! —

дип, шаян казах кызларының матур, көчле тавыш белән егетләрне айтышуларга чакырулары, тапкырлыкта ярышулар ишетелә. Казах туйларында, җыеннарында һәрвакыт була торган думбра чалулар күренми. Киресенчә, халыкның күплегенә карамастан, кычкырып сөйләү, тавышлану, көлешүләр юк. Ак чалмалы, сирәк сакаллы, олы яшьтәге кешеләрнең күплеге дә бу халыкны монда ниндидер бер үкенечле вакыйга китергәнен сөйли иде.

Найман ыругының өлкәне Баембәт байның зур улы Якупның вафат булганын һәм бүген аның җеназасы чыгачагын Галимҗан юлда ук ишеткән иде. Шунлыктан ул мондагы кешеләрнең күңелсезлегенә гаҗәпләнмәде. Ләкин, халык арасында катнашып йөри торгач, кайберәүләрнең кайгылы йөзләре астында яшеренгән башка тойгылары барлыгын да аңлады...

Җеназа уку, мәетне җирләү вакытындагы гореф-гадәтләрне Галимҗан, әлбәттә, белә. Монда аны бигрәк тә хәйран калдырган нәрсә — күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек тирән тойгы тулы сыктау әйтемнәре булды.

Ирләр табутны күтәреп, җеназа укыр өчен киң җәйләүгә чыгып киттеләр. Алар артыннан карап калган хатын-кызлар төркеменең алдында басып торган чал чәчле кәмпер:

Биек тауның басыннан күч киләде,
Сулкылдап кара юргам бус киләде.
Аерылган кузы җандан җаман икән,
Мөлдерәп кара күздән яшь киләде! —

дип такмаклый башлауга, аның янәшәсендәге хатын:

Тау басында каласы,
Каласыннан биек калгасы.
Калгасына менеп карасам да,
Күренмәйде ак егетнең карасы! —

дип дәвам итте. Боларның барысы да, хатыннарның ачы күз яшьләре белән кушылып, яшь Галимҗанны бик нык дулкынландырды. Ана йөрәген шундый тирән хәсрәткә салган үлем хәленең казах ыруглары арасында мәкерле планнар тудыруга сәбәп булуы хәтта аның ачуын китерде. Казахлар арасында алты-җиде ай яшәгәннән соң гына Галимҗан, җаппаслар гына түгел, ыруг башында торган Баембәт кебек башка байларның да, өстенлек алып, бүтәннәр өстеннән хөкем итәр өчен казах илен ваклап та, бөтен көе дә патша чиновникларына сатарга әзер торганлыкларын үзенең күзәтүчәнлеге аркасында күреп һәм төшенеп өлгерде.

Мәрхүм Якупның өче, җидесе үткәнгә кадәр балаларны җыеп укыта башлау турында сүз дә булу мөмкин түгел иде. Бушка үткән көннәр Галимҗанга тирә-якка күз салырга, казахларның үзенчәлекле көнкүрешләре, гореф-гадәтләре белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирде. Аның казах даласына беренче килүе иде. Шуның өчен аңа күп нәрсә кызыклы да, гаҗәп тә булып күренә иде.

Авыл уртасындагы зур булмаган мәйдан тирәсендәге ун ак тирмә Баембәт байның һәм аның якыннарыныкы икән. Мәйданнан читкә таба ераклаша барган саен, карасу төстәге киезләре искерә, тетелә барган тирмәләр күренә. Ә инде иң читтә иске, ертык киез кисәкләреннән корылган бөтенләй шыксыз, җиргә сеңеп баргандай тәбәнәк алачыклар утыра.

Баембәт байның бер башына өч-дүрт хатыны булу Галимҗанның исен китәрмәде. Татар байлары, бигрәк тә муллалар арасында өч хатын белән тору еш очрый торган, хәтта әдәбиятка да кергән бер хәл икәнен ул белә иде. Татар баеның иң яраткан хатыны өченчесе — иң яше булганы да аңа мәгълүм. Монда исә Баембәт байның башка ике хатыныннан күп яшь һәм сөйкемлерәк булган, тукал дип йөртелә торган өченче хатыны шул дәрәҗә түбәнсетелгән, кыерсытылган ки, хәтта хокуксыз асрау хәленә төшерелгән иде. Галимҗанны аеруча гаҗәпләндергәне — тукалның сукранмыйча, карышмыйча, үз хәленә риза булып торуы иде.

Чит кешеләргә битен ачып күренергә, сүз әйтергә, ялгыз башы урамга атлап чыгарга хокукы булмый үскән татар кызына караганда уйнап-көлеп, җырлап-әйтешеп, егетләрдән калышмыйча ат уйнатып иркен үскән казах кызлары иргә чыккач нишләп үзләрен шулай хурларга, кыерсытырга рөхсәт итәләр икән? — дип аптырый иде ул.

Ниһаять, мәрхүм Якупны яд итүнең җиденче көне үткәннән соң, Баембәт бай Галимҗанны чакыртып алды һәм балаларны укыту турында сүз ачты. Укырга тиешле балалар арасында Таңатар дигән малайның исеме аталмады. Авыл читендә иң шыксыз алачыкларның берсендә яшәгән Майташ кәмпернең оныгы булган бу бала беренче көннәрдән үк Галимҗанның дикъкатен үзенә җәлеп иткән иде. Бу малай кем нинди йомыш кушса, шуны үтәп йөри. Я кулыннан килгәнчә кул буенда байларның керләрен уучы хезмәтче хатыннарга булыша, я көче җиткәнчә бияләрне саву алдыннан колыннарны аналарыннан аерып бәйләүчеләргә ярдәмләшә, я тукалның кайнап торган казаны астына куй тизәген китереп аудара яки башка шуның кебек эшләргә булышкалап йөри. Әбисе Майташ кәмпернең имчелек итүе һәм малайның шундый тырышлыгы аркасында алар ачлы-туклы булса да көн күреп яталар иде.

Таңатар пычак белән юнып ясаган думбрага охшаш такта кисәген һәрвакыт үзе белән бергә алып йөри. Әгәр өлешенә төшкән мәшәкатьләр арасында аз гына буш вакыт килеп чыкса, ул үзенең «думбра»сын

чирткән булып, туйларда, җыеннарда ишеткән җырларны, үләңнәрне җырлый башлый. Нинди генә озын үләң булмасын, ул аны бер ишетүдә отып ала. Хәтта «Баян-сылу», «Кыз-җебәк» кебек казах халкы тудырган поэмаларның өзекләрен Галимҗан беренче тапкыр шул бала авызыннан ишетте. Шул гаҗәеп сәләте өчен аны хәтта бай балалары да кимсетмиләр, киресенчә, бик бирелеп аның үләң әйткәнен тыңлыйлар иде. Бәлки бай Таңатар турында оныткандыр, дип уйлады Галимҗан Ибраһимов һәм:

— Тагын Таңатар исемле бер бала бар бит...— дип сүз башлады.

Байның чырае кинәт караңгыланып китте.

— Аны укыткан өчен акчаны кем түләйде? Авылдагы барлык балаларны укытырга миндә җирдән тапкан акчалар юк! — дип мөгаллимнең сүзен кырт кисте.

Ләкин Галимҗан бирешмәскә тырышты:

— Таңатар бик сәләтле бала ул! Сез аның әйткән үләңнәрен ишеткәнсездер. Әгәр аны укытсагыз, вакыты белән анардан ыругыгызның данын күтәргән икенче Абай Кунанбаев үсеп җитешүе ихтимал!

— Абай кем дә, бу — кем?! Абай ул иң зур ыругның башында торган Кунанбай Үскәнбаевның улы булады! Аксакалларның әйткән бер сүзе бар: ятим бала асрасаң — авызың, борының кан булыр, ятим колын асрасаң — авызың, борының май булыр,— дигәннәр.

Шундый җавап ишеткәч, Баембәтов белән бәхәсләшеп утыруның файдасы булмаячагы аңлашылды.

Ләкин сәләтле баланы надан калдыру табигатьнең юмартлыгына хыянәт итү булып тоелды Галимҗанга һәм ул Таңатарның әбие Майташ кәмпер белән сөйләшеп карарга булды. Шул ук көнне кичкырын Майташ кәмпернең алачасына барып керде. Көтелмәгән кунакны кая утыртырга, нәрсә белән сыйларга белми аптыраган кәмперне тынычландырыр өчен Галимҗан Ибраһимов:

— Борчылмагыз, мамай, утырыгыз! Миңа бернәрсә дә кирәк имәс. Мин сезнең Таңатар турында сөйләшергә килдем,— диде. Моны ишеткәч, әби әүвәлгедән дә артыграк тынычсызланды:

— Вай! Опырмай! Ни булды?! Таңатар яманлык кылгандай бала имәс иде гуй! — диде.

— Ни өчен тик яманлык турында гына уйлыйсыз? — дип гаҗәпләнде егет.— Таңатар һичбер төрле яманлык эшләмәде!

Кәмпер дога кылгандай ике кулын югары күтәреп:

— Шөкер, я кадыр фәннам?! Байның балалары бер яманлык кылып, минем оныгыма япмадылармы икән, дип уйлаган идем гуй! — диде, тынычланып киткәндәй булды.

«Тормыш бу карчыкны шул дәрәҗә изгән ки, хәзерге көндә ул язмыштан фәкать золым гына көтә икән!» — дигән уй Галимҗанның йөрәген тетрәтте.

— Таңатарны укыта башласам, сез каршы булмассызмы, дип сорарга килгән идем мин,— дигән сүзләр кәмперне хәйран калдырдылар.

— Вайбай! Ике канаты бердән сынган ата-анасыз баланың кемгә кирәге бар, кырагым?! Аны укыткан өчен сиңа кем акча түләячәк?!

— Таңатарны укыткан өчен миңа сездән дә, башкалардан да бер тиен кирәкми. Әгәр сез риза булсагыз, мин аны тиген укытырмын.— Галимҗанның сүзләрен ишеткән Майташ кәмпер ышанырга да, ышанмаска да белми катып калгандай булды. Ниһаять, исен туплап, Галимҗанга карап арык муенын сузды:

— Таңатарны укытканың өчен йорт башы Баембәт бай ачуланмасмы? Таңатарга җәбер кылмасмы? — дип пышылдады.

— Оныгыгызны көндезге эшләреннән аерып, көнкүрешегезгә зарар китерәсем килми. Шуның өчен мин Таңатарны кичкырын, эшләреннән соң укытыр идем. Аны бай балаларына кушып укытмасам, укытканым өчен байдан акча сорамасам, кемнең ни эше бар?!

Кәмпер тынычлана төшкән сыман булды:

— Әгәр чыннан да шулай булса, ходаем сине морадына ирештерсен! Ятим балага иткән игелегенә каршы игелек күр! — дип береннән-бере яхшы теләкләр теләп дога кылды.

* * *



Башлаган эшен озакка сузарга яратмаган Галимҗан, икенче көнне үк тиешле кешеләрне табып, авыл читенә тирмә кордырып, байдан язып алган исемлек буенча Таңатар аркылы балаларны җыйдыртты.

Болар арасында дүрт баланың инде укый-яза белгәнлеге аңлашылды. Калганнары исә, моңарчы кулларына әлифба, каләм тотмаган балалар булып чыкты.

Каршысында тезелеп утырган укучыларына карагач, Ибраһимовның электә Ногай далаларында укытып йөргән чактагы уйлары хәтеренә килде. «Бу балаларның кулларына каләм тоттырып язарга өйрәткәнче «Мөгаллимәүәл»[1] китабы белән файдаланып торырга мөмкин булыр. Әгәр әлифба китабы балаларның үз ана телендә язылган булса, балалар өчен дә, мөгаллим өчен дә җиңел булыр иде, билгеле. Ә инде хәреф танып, язарга өйрәнгәч, нишләргә? Тагын шул «Шәрех Габдулла», «Бәдәвам», «Сөбателгаҗизин», «Гарәп сарфы», «Гарәп нәхүе»ме? Татар, казах, үзбәк кебек халыкларга, үзләренең ана телләренең кануннарын өйрәнеп, дәреслекләр язарга мөмкиндер бит? Сөбателгаҗизиннәр урынына менә бу балаларның үз халкының күңелен дулкынландырган, йөрәгеннән кайнап чыккан, тормышларына ямь биргән үләңнәреннән, «Баян-сылу», «Кыз-Җебәк», «Кузы-күрпәч» кебек поэмаларыннан файдаланырга мөмкин түгелмени? Шулай булырга тиешлегенә ышана торып, башкалардан ярдәм көтеп кул кушырып утырыргамы, әллә җиң сызганып эшкә керешергәме? Бу фикер үзенең көтелмәгән кинәтлеге белән Галимҗанны аптырашта калдырган-дай булды, ләкин тора-бара ул аңа иялэште, фикере ныгыды һәм мөмкин кадәр казах теленнән алынган мисаллар белән шәкертләрен теленең үзенчәлекләрен күрергә өйрәтә башлады.

Дәресләрдән буш араларда, укыту методлары турында уйланулар белән бергә, иҗат эшен дә артка куймады. «Галия» мәдрәсәсендә үк күңелендә туган һәм зиһенендә билгеле бер калыпка салынып өлгергән «Гыйшык корбаннары» дигән хикәясен язды.

Тирә-як тынып, җәйләүдәге халык йокыга талганнан соң, Галимҗан авылдан читкә китеп күл буена барып утыра иде. Су өстенә якты ай сукмагы салынган, караңгы күк йөзенә сибелгән йолдызлар бик якында җемелдиләр, аларны кул белән чүпләп алырга мөмкиндер кебек. Үләннәрнең хуш исе белән төнәтелгән һава күңелне сихерли, хыялга көч бирә, канат куя, аларны башта туган уйлар белән бәйләп, бер җепкә тезәсе килә башлый. Менә шулай хыялында туган күренешләрне кәгазьгә төшерү дәрте Галимҗанны торган саен ныграк сабырсызлый. Инде октябрь ае якынлашып килә. Күп тә үтмәс, казахлар җәйләүдән кышлакка күчә башлар. Кечкенә өй эчендә, дүрт-биш кеше тыгызланып яшәгән җирдә иркенләп утырып яза алмаячагын ул белә иде. Галимҗан бирейдән китеп, берәр тынычрак урын табарга да, шунда яза башларга уйлады. Ләкин кая китәргә? Андый тыныч урынны каян табарга? Бу мәсьәләне чишәргә көтелмәгән бер очрак ярдәм итте.

Көннәрнең берендә Галимҗан Ибраһимов җәйләүгә еш килеп йөри торган кырыктартмачы Гайфи агайның ак тирмәдән чыкканын күрде.

— Гайфи абзый, минем әнигә бүләк итәрдәй берәр яхшырак әйберең юкмы? — дип сорады.

— Ник булмасын?! Җаның ни тели, һәммәсе бар,— диде кырыктартмачы.— Теләсәң — яулык, теләсәң — күлмәклек, теләсәң — күкрәк-

[1] «Мөгаллимәүәл» — «Әлифба» китабы.

чә балдак дисеңме, алка, санжакмы[1], — дип сөйләнә-сөйләнә алдына аскан тартмасын, аркасындагы төенен ипләп җиргә куйды да товарларын ачып җибәрде.

Чыннан да, нәрсә генә юк иде монда! Тартмада иннек, кершән, исле сабын, сагыз, энә, җеп, уймак, мәрҗән кебек вак-төякләрдән башлап, көмеш һәм алтынга манган балдаклар, беләзекләр, санҗаклар, алкалар... Төендә исә кар кебек ап-ак тукымалардан башлап төрле төстәге ефәкләр, күз чагылдыргыч аллы-гөлле бизәкле ситсылар, читләренә алсу, кызыл гөлчәчәкләр тукыган озын чуклы шәлләр, дала хатын-кызларының күңелләрен station аздырырлык тагын байтак маллар бар иде.

Галимҗанның күзе төшкән нәрсә — өстенә бик матур бизәк чигелгән күкрәкчә белән кызыл ташлы, алтынга манган көмеш алка булды.

— Алка янына кушып санҗак белән балдакны да алсаң, бик килешеп торыр иде,— диде Гайфи абзый.— Күрмисеңме, ташлары да бер төстә, бизәкләре дә бер төрле!

— Юк, Гайфи абзый, юрганыңа карап аяк suz...— дип җавап кайтарды Галимҗан.

Сәүдәгәр товарларын җыя башлап:

— Авылга, әти-әниләр янына кайтам дисең алайса? — дип ярым сорап, ярым раслап Галимҗанга карады.

— Юк,— диде Галимҗан.— Берәр җирдә табышлырак эш алып, башта берничә ай эшләргә кирәк. Шуннан соң гына кайтырмын ахрысы.

— Әллә монда табыш аз булдымы?

— Аз түгелен түгел дә, тик менә хуҗалар якын арада кышлакларына кайтырга җыеналар, ә анда мондагы кебек уңайлы иркенлектә балаларны укытырлык шартлар булмас кебек.

— Шулай дисеңме? Ә кая барырга уйлыйсың соң?

Бу турыда Галимҗан үзе дә уйлап бетермәгән иде әле.

— Анысы үзем дә белмим әле. Бәлки, берәр кечерәк шәһәрдә яки зуррак урыс авылында туктармын. Анысын киләчәк күрсәтер,— диде ул.

Үзен чын мөселман дип санаган Гайфи агайның ачуы килеп, кырыс кына:

— Урыс арасында сиңа ни бар?! Дин кардәшләрең арасында сиңа эш табылмас дип уйлыйсыңмы әллә?! — дип куйды.

— Хәзерге заманда, Гайфи абзый, кеше арасында кеше булам дисәң, урыс телен өйрәнмичә ярамый. Урыслар арасында яшәп карасам, телләрен яхшырак өйрәнмәмме икән дим...

Бу сүзләр кырыктартмачының күңеленә ятты бугай, тавышы йомшара төште:

— Шулай дисеңме? Син, егет, алайса Миасс каласына бар. Үзе моннан бик ерак та түгел, аннары акча эшләү ягыннан да эшең пешәр. Анда алтын да, җиз дә казыйлар икән. Җиз эретә торган заводлары да бар, диләр. Шунда үзеңә эш тә тиз табылыр, урыс телен дә өйрәнерсең, эшчеләр арасында мөселман кардәшләрең дә аз булмас,— дип киңәш бирде.

Кырыктартмачының киңәшен онытмыйча, туры килгән чакларда Галимҗан Миасс шәһәре турында башка кешеләрдән дә сораштыра башлады. «Шәһәр зур түгел. Җиз эретә торган заводыннан башка күзгә күренерлек, телгә алырлык бер нәрсәсе дә юк»,— диделәр аңа. «Чыннан да шулай булса, фикеремне үзгәртерлек хәлләргә юлыкмам. Әгәр инде заводында миңа көн күрерлек табышлы эш тә очраса, бигрәк тә яхшы булыр»,— дигән өмет белән Галимҗан Миасска китте.

Шәһәргә килеп төшкән көнне үк ул үзенә заводка якын гына тар бер тыкрыкта чоланга охшаш кечкенә фатир тапты. Ләкин завод тиз-

[1] Санҗак — кыйммәтле брошь.

дән ябылачак, шунлыктан кешеләрне кара эшкә генә алалар икән. Галимҗан башка эш эзләп вакыт үткәрмәде, заводка кара эшче булып ялланды. Эше бик авыр икән. Иртәнге сәгать җидедән кичке караңгылык куерганчы җизле мәгъдәнне[1] бер-бер артлы килеп туктаган атлы вагонеткалардан завод амбарларына ташу, җизе эретеп алынганнан соң калган шлакны кире төяү кебек авыр эшләр бөтен көчне ала, шулай ун-унбер сәгать эшләп яшь әдип һәр көн кич хәлдән таеп фатирына кайтып егыла иде. Казах даласындагы планнарын тормышка ашыру түгел, хәтта «Галия»дә укыганда туган һәм күңелендә өлгереп житкән бер-ике хикәясен дә язарлык хәле калмый иде. «Күнеккәнгә кадәр шулай булыр инде ул. Һавалар җылынгач, көннәр озайгач бәлки җиңеләер әле»,— дип, язга чаклы түзде. Ләкин язга таба да үзгәреш сизелмәде. Шундый газап белән кулына тигән эш хакы тартып-сузып җан асрарга гына житә иде. Заводта каравылчы булып торган Мортаза абзый турында ниндидер татар байларының прискаларында күп елларны алтын юган, дип ишеткән иде Галимҗан. «Андагы эш җиңелрәк булмаса да, бәлки килере башкачарак, эш көне кыскарактыр»,— дип уйлап, Галимҗан аның белән киңәшергә булды һәм якшәмбе көнне картны кунакка чакырды. Хәрчәүнәдән казылык, ак күмәч, алты пешкән йомырка, бер шешә эчемлек, бер чәйнек кайнар чәй алып кунагын каршылады.

Мортаза абзый, ишектән кереп килүе белән ике куллап күрешкәннән соң, тирә-ягына каранды.

— Фатирың мактанырлык түгел икән. Шулай да барак түгел инде... Ни дисәң дә ялгыз башың, сүгенеп, кыйнашып тынычсызлаган кеше юк,— диде.

Шул араны тәрәзә кырындагы тар ятак өстенә таралган кәгазь һәм китапларга күзе төште. Кунак шул дәрәҗәдә гаҗәпләнде ки, хәтта Галимҗанның:

— Утырыгыз, Мортаза абзый! — дип өстәл янына чакырганын да ишетмәде.

— Ай-һай, егет, син укымышлы кеше икәнсең! Нишләп соң бу җәһәннәм төбенә килеп төштең? — дип әйтеп куйды.

— Бу турыда соңыннанрак сөйләшербез. Хәзергә өстәлгә якынрак килеп утырыгыз әле, абзый,— дип Галимҗан кунагының беләгеннән тотып, өстәл янына китереп утыртты.

— Бу заводка килгәнче сез кайдадыр алтын казый торган прискаларда эшләгәнсез дип ишеткән идем. Анда ничек? Эше бик авыр түгел идеме? — дип сорады.

Мортаза абый гаҗәпләнде:

— Ул сиңа нигә кирәк булды?

— Прискага китеп эшләсәм, эше дә җиңелрәк, килере дә күбрәк булмасмы дип уйлыйм...

Абзыйның йөзе караңгыланып китте:

— Синең кебек укымышлы булсам, мин шулай заводларда, прискаларда эт көнендә сөйрәлеп йөрмәс идем. Берәр авылда мулламы, мәзинме булып, симез каз ите белән пешкән бәлеш төбен ашап, яисә мөгаллим булып балалар укытып көн күрер идем. Бөтен белгәнеңне онытып, эчкечелеккә сабышып, башыңны югалтканчы, моннан кит син, егет! Прискада яхшырак булмасы, имеш!..

— Мин бит, Мортаза абзый, монда мәңге калырга димим. Кыш буе укырлык акча табарга да, аннары укуымны дәвам итәргә уйлыйм.

Абзыйның йөзе ачылып китте.

— Болай дисәң, эш башкачарак шул! Прискада җиңелрәк тә, төшемлерәк тә булмасмы дисәң инде. Мин, егет, алтмышка якынлашам, ә дөньяда җиңел эш тапканым юк. Безнең кебек гидайларга, җырда әйтелгәндәй, кайда барсаң да бер кояш, күбәләктәй җанга көч! Бу бармакларны күрәсеңме? — Буыннары төенләнеп-төенләнеп

[1] Мәгъдән — руда.

шешкән бармакларын күрсәтер өчен кулларын Галимҗанга таба суз-ды.— Аяк бармаклары да шундый! Илле сигез яшемә җитәр-җитмәс ни өчен шулай билемне турайта алмыйм? Беләсең килсә, моңа рима-тис диләр! Монда хет җир өстендә якты көнне күреп яшисең, ә анда, шахтада, җир астына төшеп билдән пычрак суда атна буена җәһәннәм газабы чигәсең!..

Галимҗанның рус телен яхшырак өйрәнермен дигән өмете аклан-мады. Үз тирәсендәге рус егетләре сезонлы эштә эшләп, авыл белән завод арасында йөргән кешеләр булганлыктан, сөйләшүләре дә әдәби рус теленнән яхшы ук ерак иде. Галимҗанның моны гына аңларлык белеме бар иде инде.

Шулай да ул заводтагы эшен җәйгә кадәр ташламады. Якшәмбе көннәрендә генә булса да, өстәл башына утырып, Казахстан даласында кичергәннәрен, шул вакытта хыялында туган күренешләрне, күңелендә уянган хисләрне кәгазьгә төшерә башлады. Ләкин эш бик әкрен бара иде. «Болай дәвам итсә, бер нәрсә дә килеп чыкмас»,— дип, Галимҗан көннәрдән бер көнне заводтагы эшен ташлады.

Бу яктан килере киселгәч, казах даласында эшләп тапкан акчасын бик кысып тотарга мәҗбүр булды, ләкин бу да аны куркытмады. Мәд-рәсәләрдә үткәргән еллар ачлы-туклы яшәргә күнектергәннәр иде инде. Көнкүреш авырлыкларына һич тә илтифат итмичә, Галимҗан бөтен күңелен салып җәй буенча «Казах кызы» дип аталган романы өстендә эшләде. Әмма җәйнең озын якты көннәре үтеп, яңгырлы, үзәккә үтә торган кискен җилле көз килеп җиткәч, яшь әдипнең башында: «Мон-дагы кебек юеш, караңгы фатир Казанда да табылыр әле. Һәрхәлдә, үз халкыбызның әдәбияты, мәдәнияте үзәгендә булырмын! Татар әдибе булырга, татар мәдәниятенә хезмәт итәргә теләгән кеше Казанның үзен-дә кайнарга тиеш! Казанга китәргә кирәк!» — дигән уйлар туа баш-лады.

Ниһаять, октябрь аеның җилле, яңгырлы бер көнендә Галимҗан, Миасс белән саубуллашып, Казанга юл тотты.

## Казан

Миасска караганда Казанның һавасы Галимҗанга бөтенләй башка булып күренде. Инде октябрь уртасы булса да, күк йөзе ачык, һава саф, җиләс. Агачлар, яшел киемнәрен салмыйча, һаман купшыланып утыралар. Ара-тирә яңгырлар яугаласа да, шәһәрне юындырып, яңар-тып, матурлатып кына китә иде.

Миасста үткәргән соңгы ике-өч ай эчендә кесәсе шактый такы-райганлыктан, Ибраһимов фатирны зур урамнардан карамыйча, «Бол-гар» мөсафирханәсенә якынрак җирдән эзләде һәм Захарьевская белән Екатеринская урамнарын тоташтырган Суконный тыкрыгындагы иске агач өйнең ярым подвалында кечкенә генә бер бүлмә тапты. Бүлмә караңгы, хәтта көндез дә кояш нуры төшми. Биек итеп уелган кеч-кенә тәрәзәдән үткән-сүткән кешеләрнең аяклары гына күренеп кала. Фатирның бу якларына Галимҗан әһәмият бирмәде, киресенчә, көт-кәненнән дә арзанрак булганына куанды гына.

Галимҗан Ибраһимовның Казан туфрагына аяк басуы беренче генә түгел иде. 1907 елның җәендә, бер ногай авылында балалар укыткан чагында, «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле хикәя язган иде. Шул әсәрен, Уфага кайтышлый юл уңаеннан, яңа чыга башлаган «Әльислах» газетасына тапшыру өчен октябрьнең соңгы бер көнендә пароходтан төшеп, пристаньнан җиде чакрым ераклыктагы Казан шә-һәренә юл тотты. Газета идарәсендә Галимҗанны кара кашлы, очлары аз гына бөдрәләнеп торган куе кара чәчле, кара мыеклы егерме ике-егерме өч яшьләр тирәсендәге егет каршы алды. Бу — газета чыгару эшләренә булышлык итеп йөрүче Хәбир Бәкер булып чыкты. Аның

әйтүе буенча, газетаның хәкыйкый редакторы Фатих Әмирхан авыруы сәбәпле соңгы көннәрдә идарәдә күренми икән, ә нәшир һәм рәсми редактор Вафа Бәхтияров бер-ике сәгатьтән соң гына киләчәк ди.

Галимҗанның нәширны көтеп утырырлык вакыты юк иде. Ул болай да «Галия»дә дәресләр башлану вакытына кичеккән иде инде. Ике сәгатьтән Казаннан Уфага пароход китәчәк, шуңа ашыкканлыктан кулъязмасын яңа танышы Хәбиргә калдырып, үзе пристаньга кире китте. Ул вакытта Галимҗан Казанның атаклы урыннарын карап йөри алмаган иде. Хәтта Сөембикә манарасын да юл өстеннән генә күреп үтте...

Хәзер аның бөтен теләге — тизрәк урнашырга да татарның мәдәни үзәге булып танылган шәһәрнең әлегә тышкы ягы белән генә булса да танышу иде. Шул ният белән ул Казанга килүенең икенче көнендә иртән үк урамга чыкты.

Воскресенский[1] урамының икенче очында бөтен Русияга мәшһүр университет бинасы барлыгын ул ишетеп белә иде. Шунда бару нияте белән урамга чыкты.

Бөтен кварталны биләп алган, кашына зур алтын хәрефләр белән «Императорский университет» дип язылган, унике колонналы мәһабәт бинаның порталы Галимҗан Ибраһимовны нык дулкынландырды. Университет ишегеннән керәп-чыгып йөргән студентларны күргәч, аның йөрәге дәртләнеп, көчлерәк тибә башлады. «Шушы шәүкәтле фән сараенда студент булу шәрәфенә кайчан-да булса ирешерменме? Әллә минем бу омтылышым буш хыял булып кына калырмы икән?» — дип уйлады. Ләкин шунда ук үз-үзен рухландырга теләмәгән сыман: «Шикләнмә, дустым! Булыр бер көн, син дә башыңны югары күтәреп, тулы хокуклы студент сыйфатында бу бинаның бусагасын атлап үтәрсең!» — дигән фикер белән соңгы елларда тормышын яктырткан өметне куәтләргә тырышты.

Йөрәгенең ашкынуын тыя алмыйча, берсеннән-берсе матур хыялларга бирелеп, университет тирәли әйләнеп чыкты.

Иртә белән урамга чыкканда, Кабан күлен, мәшһүр Печән базарын, Әҗем, Апанай мәчетләрен һәм башка шундый атаклы урыннарны карап йөрергә исәбе бар иде. Ләкин университет биналарын күргәннән соң, күңелен биләп алган дәртле хисләрен сүндермәс өчен, артык беркая да бармаска булып, турыдан-туры фатирына юнәлде.

* * *

«Йолдыз» газетасы редакциясенә керер өчен Печән базары аркылы үтәргә кирәк иде. Татарлар яшәгән күп шәһәрләргә даны таралган бу базар яшь әдиптә чыннан да гаҗәп тойгы калдырды. Халыкның ыгы-зыгысы, кайнап, мыжгып, шаулап торуы һәрбер базар өчен табигый, әлбәттә. Ләкин Печән базарын башка базарлардан аерып торган нәрсә — төрле галантерея, комганнар, читек-кәвешләр, түбәтәй тулы эрелеваклы, шкафларга охшаган, тар, озын лареклар иде. Базар эчендә башка урын табылмаган төсле, болар чаттагы мәчетнең ике ягына да тыгызланып тезелгәннәр. Сатучылар исә, күбесенчә прилавкалары өстенә менеп, аякларын бөкләп, яки салындырып утырганнар. Лареклар алдында җиргә капчык җәеп тезелешеп утырган агай-эне дә аз түгел. Болар төрле тимер-томыр әйберләр, энә, җеп, тасма кисәкләре кебек вак-төякләр белән сәүдә итүчеләр икән.

Ике катлы мәчетнең түбәсен ярып күккә омтылган манараны яхшырак күрер өчен, Галимҗан лареклар каршына басты һәм, башын артка ташлап, югары карады.

Җирдә утырганнарның берсе, аның тарафына бармагын сузып:

— Әй, знакум, чаво смотришь наш мәчет? — дип кычкырды.

---

[1] Воскресенский — хәзерге Ленин урамы.

Үзенә таба юнәлгән бармакка күз ташлап, Галимҗан гаҗәпләнде һәм:

— Сез миңа әйтәсезме, абзый? — дип сорады.

Татарча җавапны ишеткәч, абзый утырган урыныннан сикереп торды да шап итеп ике кулы белән ботларына сукты һәм нәкъ мәчет ишеге янындагы ларекның прилавкасы өстендә аякларын бөкләп утырган кәҗә сакаллы сатучыга карап:

— Мөхәмматҗан хафиз! Кара әле син бу мөртәткә. Йөзендә иман нурының әсәре дә калмаган, үзе мөселманча сөйләгән була бит! — дип кычкырды.

Тегесе, артына без белән чәнечкәндәге кебек, кинәттән прилавкасы өстеннән сикереп төште һәм, соң дәрәҗәдә кызулыгын күрсәтеп, баскан урынында да бер сикереп алды.

— Монда, хак мөселманнар арасында ни дип йөрисең син, урыска дүнгән, динеңне саткан мөртәд! Кяфер! Кит, югал моннан! Кит дим синә! — дип җикеренә башлады.

Башка сатучылар да Мөхәммәтҗан хафизның сүгенүенә кушылдылар:

— Шулай кирәк!

— Дөрес әйтәсең, Мәхәмматҗан хафиз!

— Китсен, юк булсын моннан!

Хафиз тагын да ярсыбрак китте, хәтта авызыннан төкрекләре чәчри башлады:

— Синең урының монда түгел, җәһәннәмдә, кяфер! Чәчләренә карагыз, пуп чәчемени! Кит! Кит! Хәзер үк юк бул!

Галимҗан Ибраһимов: «Көфер почмагының нәкъ үзенә эләккәнмен икән. Казанның бу атаклы урынын да күрергә насыйп булды, тик болар өстемә генә атыла күрмәсеннәр»! — дип уйлап, башын чайкап куйды да, Евангелистлар урамына[1] борылып, «Йолдыз» редакциясенә юнәлде. Галиәсгар Камалның анда эшләгәнен Галимҗаң белә иде һәм аның «Бәхетсез егет», «Беренче театр» исемле комедияләрен, «Сабир хәзрәт» исемле хикәясен укыганы да бар иде.

Идарәнең ишеген ачып бусагадан атлау белән Галимҗан туктап калды. Ике тәрәзәле зур бүлмә эчендә барлыгы ике генә өстәл булу сәбәпле, ул аңа бөтенләй буш булып күренде. Өстәлләрнең зуррагы өстенә хәттыйн тыш күп газеталар, язулы кәгазьләр өелгән. Икенче өстәл тегесенә караганда кечерәк. Аның каравы бу өстәл янында утыз яшьләр тирәсендә берәү башын күтәрмичә, ниндидер кульязма укып утыра иде. Аның озын куе мыекларына, эре сөякле калын гәүдәсенә карагач, Галимҗан: «Галиәсгар ага шулдыр инде»,— дип уйлады һәм аңа таба атлады. Алдына Галимҗан килеп баскач кына бу кеше күтәрелеп карады һәм егетнең биргән сәламен кабул итеп алгач:

— Сез кем буласыз? Моңарчы күргән, таныган кешеләремнән түгел шикелле? — диде.

— Шулайдыр. Минем Казанга килгәнемә бары ике-өч көн генә. Исемем Галимҗан Ибраһимов була...

Егетнең исемен ишетү белән, Галиәсгар Камал, елмаеп, аякка басты һәм кулын сузып:

— Әсәрләрегез, мәкаләләрегез буенча исемегезне беләм, инде үзегезне дә күреп танышуыма бик мәмнүнмен. Мин Галиәсгар Камал дигән кеше булам. «Йолдыз» газетасының мәсьүльсәр катибы»,— дип, үзен дә таныттты.

— Сезне күргәч үк бу кеше Галиәсгар ага булырга тиеш дип уйлаган идем, шулай булып чыкты да,— диде, Галимҗан елмаеп.

— Утырыгыз! — дип Галиәсгар ага, урындык күрсәтте дә үзе кунагын баштанаяк карап алды һәм: «Буе-төсе егетнең күркәм күркәмен дә, өс-башын азрак төзәтәсе бар икән»,— дип уйлады.

[1]Евангелистлар урамы — хәзерге Татарстан урамының Болак аръягындагы өлеше.

Галимҗанның киемнәре, чыннан да, өтегрәк иде. Төймәләрен чишеп, чабуларын ачып җибәргән пальтосының җиң очлары, кесә тирәләре байтак кыршылган. Киң каеш белән буган кыек якалы кызыл сатин күлмәге дә уңа төшкән. Тезләре өрелеп торган чалбар балаклары төсе агара башлаган һәм борыннары югары күтәрелеп торган итек кунычларына тыккан. Башында искерәк фуражка...

Сүз башлап җибәрер өчен Галиәсгар ага:

— Казанга бөтенләйгә күчеп килдегезме? — дип сорады.

Галимҗан:

— Татар мәдәнияте, әдәбияты өлкәсендә эшләргә теләгән һәрбер кеше татар мәдәниятенең үзәге булган Казанда яшәргә тиеш дип уйлап, бөтенләй торып калырга дигән ният белән килдем,— диде.

— Фикерегез дөрес, Галимҗан әфәнде. Монда күчеп килүегез бик тә дөрес. «Әльислах»та басылган мәкаләләрегез дә, Зәки шәкерт турындагы хикәягез дә замана таләп иткән кирәкле, мәгънәле нәрсәләр иде. Казанга, әлбәттә, буш кул белән килмәгәнсездер? Кызганычка каршы, хәзер «Әльислах» туктатылды. Бәлки инде «Йолдыз»га язышa башларсыз?

— Язылып беткән һәм бүгенгә кадәр дөнья күрмәгән ике-өч әсәрем бар кулымда. Берсенең исеме «Татар хатыны ниләр күрми», икенчесенең — «Гыйшык корбаннары», өченчесе — «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә». Моннан башка, хәзер казахлар тормышыннан зур гына хикәя димме, роман димме, бер нәрсә язып утырам. Якын арада тәмамлармын шикелле.

Галиәсгар җанланып китте:

— Әгәр «Йолдыз» күңелегезгә ошаса, хикәяләрегезнең берсен бәлки безгә бирерсез? Без дә, «Әльислах» шикелле, хикәягезне ике яки өч кисәккә бүлеп, берничә санда басарбыз.

— Казанда һәм башка шәһәрләрдә чыккан газеталар арасында «Йолдыз», әлбәттә, алдынгы урынны тота дип әйтергә мөмкин. Тарихи мәсьәләләр буенча да кызыклы һәм кирәкле мәкаләләрне еш басасыз. Газетагызның теле дә җиңел һәм укырга күңелле... Шулай булгач, Сезнең тәкъдимегезне мәмнүният белән кабул итәм!

Галимҗан Ибраһимовның газетаны шулай мактавы Галиәсгарның күңеленә ятты, ләкин моны сиздермәскә, тыйнаклык күрсәтергә тырышты:

— Газетабызның яхшы тарафлары, һичшиксез, бар, ләкин килмәгән яклары да юк түгел...

Дөрес дип ышанган фикерен шәкерт чагыннан ук турыдан-туры әйтергә өйрәнгән Галимҗан Ибраһимов:

— Мин дә шуны әйтәсем килгән иде: кайвакыт газетагызның бер үк битендә бер-беренә капма-каршы ике фикер әйтелгән чаклары бик еш очрый. Бу ике фикернең кайсына уңай мөнәсәбәттә булганын газета укучыга аңлатмый. Шул сәбәптән газетаның үзе нәкъ ышанган билгеле бер карашы юк шикелле тоела...

«Кара син аны! Газетаның иң зур кимчелеген сизеп алган. Яшь булса да, акыллы егет икән!» — дип уйлады Галиәсгар, ләкин үзе эшләгән газетаны якларга тырышты.

— Үзегезгә мәгълүм, Галимҗан әфәнде, заманалар авыр. Бишенче-алтынчы еллар үтеп китте. Мәсләкләр чуалды. Администрация яңадан көч алды. Шундый шараит эчендә «Йолдыз»ны саклап калыйм, яшәтим дисәң, төрле хәйләләргә, үзеңә якын булмаган мәсьәләләргә дә юл куярга, урын бирергә туры килә. Нишлисең? Замана бик буталчык шул! Менә, «Яшен»не дә, үз юлында нык барганы өчен туктаттылар... «Урал»ны да яшәтмәделәр. Шулай барса, татар дөньясында, «Нур», «Бәянелхак», «Борһан тәрәккый» кебек карагруһ, буталчык, консерватив газеталардан башка, кулга алырлык бер газета яки журнал калмаячак.

Газета үз битләрендә идеясенә каршы булган мәкаләләргә урын

бирә икән, аларга үзенең мөнәсәбәтен аңлатырга тиеш дигән фикердә калганлыктан, Галимҗан сүзне икенчегә борды:

— Бәлки, сез белә торгансыздыр, Фатих Әмирхан әфәнденең фикере ничек икән? «Әльислах» туктатылгач, башка исем белән булса да, шул ук юлны тоткан берәр газета чыгарырга уйламыймы икән?

— Ул турыда бернәрсә дә әйтә алмыйм. Аны инде сез Фатих әфәнденең үзеннән сорарсыз.— Галиәсгар Камалның шул җавабын ишеткәч, «Килешмәгәнрәк сорау бирдем ахрысы»,— дип, Галимҗан бераз уңайсызланды. Моны Галиәсгар да сизде һәм: «Җавабым корырак булды күрәсең»,— дип, йомшартыбрак әйтергә кирәк тапты:

— Сез, Галимҗан әфәнде, аның үзе белән очрашыгыз. Ул соңгы вакытта шушы «Болгар» номерларында өченче катта яши, Габдулла әфәнде Тукаев та шунда. Аның белән дә танышырсыз. Казанның алдынгы яшьләре арасында Фатих әфәнденең таныш-белешләре күп. Бу яктан да аның белән күрешү сезгә зарар итмәс.

Киңәшләре өчен рәхмәтен белдереп, Галимҗан башын иде, ләкин сүз әйтеп өлгермәде, чөнки Галиәсгар сөйләвен дәвам итте:

— «Шәрык» клубына барыгыз. Клубта ара-тирә булса да театр куябыз. Уйнаучылар һәвәскәрләр түгел, чын артистлар, «Сәйяр» труппасы артистлары. Профессионал артистлар труппасы оештырылганын ишеткәнсездер...

Театр, артистлар турында сөйләсә дә, бу труппаны оештыруда аны татар клубына рәсми рәвештә беркетүдә үзенең зур роль уйнавы турында Галиәсгар Камал бер сүз дә әйтмәде. Габдулла Тукаев белән икесенең «Яшен» урынына башка берәр һөҗү журналы чыгару турындагы хыялларын әйтергәме, әллә бу турыда сөйләргә иртәрәкме дип уйланып кына бераз тукталып торды. Шул араны, ничектер ихтыярсыз, алдындагы кулъязманы үзенә якынрак китерде. Аның бу хәрәкәтен күргән Галимҗан: «Кешене эшеннән аерып, әдәпсезләнеп, вакытын күбрәк алдым ахрысы»,— дип уйлады.

— Киңәшләрегез өчен зур рәхмәт! Әлбәттә, Фатих әфәнде белән мөмкин кадәр тизрәк очрашырга тырышырмын. Татарның профессионал артистлары уенын күрү дә, һичшиксез, бик кызыклы һәм шатлыклы вакыйга! Вакытыгызны күбрәк алганым өчен гафу итегез,— дип аякка басты.

— Вакытыгыз булганда, яки газетабызда бирердәй мәкаләгезме, хикәягезме булганда, юлыбызны онытмагыз, килегез! — дип, Галиәсгар ага Ибраһимовны ишеккә кадәр озатып куйды.

* * *

Ике-өч атна эчендә Галимҗан «Шәрык» клубы, «Йолдыз» идарәсе, «Гасыр» нәшрияты кебек урыннарга күп булса биш-алты тапкыр гына барып килгәләде. Кая барса да, ул тизрәк фатирына кайтырга ашыга. Бу көннәрдә аның язу-сызу эшләре зур уңыш белән бара, әдип аруталуны белми, көнне төннән аермый утыра иде. Шулай да ул, өйдән чыккан араларында, Гафур Коләхметов, Галимҗан Сәйфетдинов, Хәнәфи Кайбышев, Ибраһим Кули, Заһит Нуркин кебек яшьләр белән танышып өлгерде, хәтта кайберләре белән берникадәр якынлашты да.

Көннәрнең берендә, байтак вакыт башын күтәрми эшләгәннән соң, әллә ничек бармаклары туңган кебек булып китте. Каләмен куеп, кулларын угалый башлады. Чыннан да, бармаклары гына түгел, аяклары да, бөтен гәүдәсе дә бик нык өшегән икән. «Ник болай булды соң?» — дип уйланып тирә-ягына каранса, күзе тәрәзәгә төште. Ни күрсен! Урам ярты аршин калынлыгында ап-ак кар белән капланган. Бу кадәр кар кайчан явып өлгергән икән? Иртә белән ипи алырга чыкканда, аның әсәре дә юк иде ич, дип гаҗәпләнде Ибраһимов. Җылыныр өчен бүлмәсе буйлап арылы-бирele йөренә башлады. Шул вакыт стенага кулы тиеп китте. Ул да боз кебек суык икән! «Хуҗа хатынга әйтергә

кирәк, мичкә яксын. Инде ноябрь ае ич. Саранланмасын. Өй җылынмаса, бу суыкта барыбер эшләп булмас»,— дип уйлады һәм пальтосын, бүреген киеп чыгып китте.

Кая бару, кемнәр белән очрашу-танышу турында аның билгеле бер планы юк иде. Мамык түшәккә охшап җәелеп яткан ап-ак кар өстендә йөрисе, бу вакытның — беренче кар вакытының — үзенә генә хас салкынча саф һавасын сулыйсы килгән иде аның. Ләкин аяклары ихтыярсыз Евангелистлары урамына алып китте. «Болгар»ның икенче катына менеп кенә җиткәндә, редакциянең ишеге ачылып, каршына Галиәсгар Камал килеп чыкты.

Галимҗанга аның өс-башы бик пөхтә, үзенә бик килешеп торган кебек күренде. Чыннан да, Галиәсгар аганың кыяфәте бик ягымлы һәм мәһабәт, киемнәре өстенә коеп куйгандай ятышлы иде. Яшь әдипкә ачык йөз белән карап, кулын суызды да:

— Редакциягә килә идегезме? — дип сорады.

— Кереп чыгарга исәбем бар иде, ләкин күрәм, сез үзегез каядыр ашыгасыз. Соңгы атналарда фатирымнан бик сирәк чыгуым сәбәпле, дөньядагы яңалыклардан хәбәрем юк, шуны беләсем килгән иде.

— Башка эшегез булмаса, бәлки, Габдулла Тукаев янына барырбыз? Мин шул ният белән чыккан идем. Яңалыклар турында да анда сөйләшер идек.

Галимҗан Ибраһимовның Тукаев иҗаты турында кайбер фикерләре бар иде инде. Хәтта ул бу турыда мәкалә язарга да ниятләнә. Галиәсгар аганың тәкъдименнән соң бераз икеләнеп торгач: «Тукай белән очрашып, иҗаты турындагы фикерләремне башта аның үзенә сөйләсәм, зарар итмәс!» — дигән карарга килде һәм:

— Форсаттан истифадә[1] булсын! Әгәр Сезне уңайсызламасам, мин каршы түгел,— диде.

Габдулла Тукаевның бүлмәсе шунда ук, «Болгар» мөсафирханәсенең өченче катында икән. Ашханә янындагы ишекне шакып кергәндә, бүлмәдә ике кеше утыра иде. Боларның кара тутлы, ягымлы йөзле, зур кара күзле һәм калын иренлесе Фатих Әмирхан икәнлеген Галимҗан белә иде. Ике тәгәрмәчле креслосы да моны раслый.

Бүлмә мактарлык түгел: Евангелистлар урамына караган бердәнбер тәрәзә алдында шыр ялангач өстәл, ике-өч иске урындык, «солдат караваты» дип йөртелә торган тар тимер карават. Ишекнең уң ягында элгеч. Анда төймә тишегеннән эленгән пальто, таушалганрак фуражка... Ләкин Галимҗанның моңа исе китмәде, чөнки моңарчы үзе яшәгән фатирлар Тукаев бүлмәсеннән бик күп тапкыр килешсез дә, шыксыз да була иде...

Кунаклар кереп килүгә, бүлмә хуҗасы утырган урыныннан торып:

— Ә, сез икәнсез, Галиәсгар ага! Рәхим итегез! — диде дә Галимҗанга карады. Әмирхан да кызыксынып аңа текәлде.

Тукаев яңа кешеләр белән танышырга атлыгучан түгел иде. Бигрәк тә якын күргән кешеләре белән тәмләп әңгәмә корып утырганда, ашка төшкән таракандай, уртага килеп кергән чит кешеләрне өнәми иде. Шулай да ул коры гына:

— Сез дә, әфәндем, өстегезне салыгыз,— дип әйтергә үзен мәҗбүр итте.

Кунакчыл өйдә үскән Галимҗанга Тукайның шулай коры каршы алуы никтер ят тоелды. Башкалар да моны сизделәр, ләкин Галиәсгар ага бер нәрсә дә күрмәгән, аңламаган төсле булып:

— Танышыгыз, әфәнделәрем! Бу — яшь әдибебез Галимҗан Ибраһимов була,— диде, егетнең терсәгеннән тотып, номер хуҗасы алдына китереп бастырды. Аннан соң Галимҗанга карап: — Бу кешенең кем икәнен мин сезгә баскычтан менгән чакта ук әйткән идем,— дип, ша-

[1] Форсаттан истифадә — очрактан файдалану.

гыйрьнең исемен атап әлгермәде, Тукай кунакка кулын сузды. Якын күргән, хөрмәт иткән кешеләре белән очрашкандагы кебек үзен «Апуш» дип таныштмады, «Габдулла Тукаев» дип тулы исемен әйтте. Аның кечкенә генә кулы Ибраһимовның кара җир эшләре белән кытыршыланып, яргаланып беткән крестьянча зур учында югалып калды.

Уңайсызлыкны таратыр өчен, Әмирхан да мөмкин кадәр самимирәк елмаерга тырышып әйтеп куйды:

— Сезне «Әльислах»та басылган әсәрегез белән мәкаләләрегез аша гына таный идем, инде үзегезне дә күрүгә ирештем.

Килеп кергәч тә гореф-гадәт буенча исәнлек-саулык сорашудан, беренче карның сафлыгы, матурлыгы турында һәм шуның кебек башка сүзләрдән соң Галиәсгар ага, бик кирәкле нәрсәне кинәт исенә төшергән кебек:

— Әле кичә генә мин Әхмәт Урманчиев белән сөйләштем,— диде.— Бу сүзләрне ишетү белән Тукаев, кызыксынып, Галиәсгар ага тарафына борылды.— Көлке-һәҗү журналы чыгаруга һәм аңа нәшир булырга ул каршы түгел. Фәкать бергә җыелып, журналның айга ничә тапкыр чыгарылачагын, мөндәриҗәсен [1], кыскасы, рөхсәт алыр өчен кирәк булган мәгълүматларны билгеләргә кирәк дип әйтә.

Тукаев, бу мәсьәләләр турында уйлап, билгеле бер карарга килгән икән инде.

— Монда сөйләшеп-киңәшеп утырырлык бернәрсә дә юк. Журналга исем кирәкме? Рәхим итегез! Ялкынлы ук күк йөзен ялт-йолт ярып үтмичә, яшен булмый бит ул! Яшенне яңадан җанландырыр өчен аның «Ялт-Йолт» итеп күкне ярып киткән ялкынлы угын уятырга кирәк! Журналның юлы дисәң, шул ук «Яшен» юлы һәм шулай ук унбиш көнгә бер тапкыр чыга торырга тиеш!

Елмаеп, бер Ибраһимовка, бер Тукайга карап утырган Әмирхан шагыйрьнең сүзләрен ишеткәч көлеп җибәрде:

— Яшә, Габдулла! Синең белән кайчан гына очрашмыйм, үзеңдә һаман яңадан-яңа сыйфатлар таба торам! Менә хәзер дә син талантлы, зур шагыйрь булып кына түгел, сәләтле нәшир сыйфаты белән дә күз алдыма килеп бастың!

Әмирханның Тукайны талантлы зур шагыйрь дип әйтүе Галимҗан Ибраһимовка Габдулла Тукаевның иҗаты турындагы фикерләрен белдерергә уңайлы очрак булды. Сүзне башлап җибәрер өчен ул:

— Габдулла әфәнденең шигырьләре турындагы мәкаләгезне укыган идем,— дип, Әмирханга карады.

Фатыйх әфәндене болай да зур күзләре тагын да зуррак ачылды. Танышыр-танышмастан әлек Галимҗан Ибраһимовның бу мәкалә турында сүз башлавы аңа урынсыз кебек тоелды. Гаҗәпләнгәнен сиздермәс өчен елмаеп:

— Әллә сез минем фикерләремә кушылмыйсызмы? — дип сорады.

Әмирханның елмаюында да, тавышында да ирония бар кебек сизелде Ибраһимовка. «Әллә пенснесенең пыялалары елтырау сәбәпле шулай тоелдымы икән?» — дип уйлап алды, хәтта бераз тукталып торды. Ниһаять, ул:

— Ник кушылмаска? Фәкать иң әүвәл шуны әйтәсем килә: Пушкин, Лермонтов, Некрасов кебек рус шагыйрьләре, Гете, Байрон кебек европалы шагыйрьләр үз әсәрләрендә халык әдәбиятыннан бик оста файдаланганнар, һәм бу хәл аларның иҗади көчләрен арттырган, халыкның моңына, шатлыкларына, уйларына, кыскасы, халыкның рухына якынлаштырган,— диде.— Габдулла әфәндене «Шүрәле», «Су анасы», «Яңа кисекбаш» кебек халык әдәбиятыннан яки фольклор дәрәҗәсенә ирешкән борынгы поэмалардан файдаланып язган әсәрләре Тукаев әфәндене иҗатын халкыбызның рухына якынлаштыралар. Бу әсәрләр-

[1] Мөндәриҗә — эчтәлек.

нең теле дә халкыбызның теле — татар теле. Шул сәбәптән, Габдулла Тукаев әфәнденең шундый шигырьләрен халкыбыз якын күреп, яратып укый.

Тукай үзе дә, башкалар да Галимҗан Ибраһимовның сүзләрен канәгатьлек белән тыңладылар. Шулай да Фатих Әмирханның башына: «Бу сүзләрне башкачарак та аңларга мөмкин бит»,— дигән уй килде. Һәм ул:

— Габдулла әфәнде Тукаевның халык әдәбияты белән аһәңдәш әсәрләре аның талантына уңай тәэсир итәләр, баеталар, дидегез. Мин бу фикерегезгә һич каршы түгел. Ләкин аның фольклорга нигезләнмәгән әсәрләре ул дәрәҗәдә үк яхшы түгел дип әйтергә теләдегез кебек тоелды. Әллә мин ялгышаммы? — диде.

— Габдулла әфәнденең халык әдәбиятына нигезләнгән әсәрләренең теле саф татарча һәм бу — бик яхшы. Әгәр әсәрләрегез халкыбызның күңел түренә кереп утырсын дисәк, ана телебезнең бөтен байлыгыннан, бөтен нечкәлекләреннән файдаланырга тиешбез. Габдулла әфәнденең соңгы шигырьләрендә бу омтылыш сизелә. Аның соңгы әсәрләренең теле әүвәлге кебек чуар, корама түгел. Тукаев әфәнденең шигырь теле турындагы фикеремне ачыграк аңлатыр өчен бер-ике мисал китерергә рөхсәт итегез,— дип, Галимҗан Ибраһимов «Гыйшык бу я» исемле шигырьдән түбәндәге юлларны укый башлады:

> Ач никабыңны йөзеңнән, парласын рүе заман,
> Бән дә энварың илә парланаем, парланаем!

Галиәсгар Камал бер Тукайга, бер Әмирханга карап алды. Тукайның чыраенда ачу катыш гаҗәпләнү сизелде. Галимҗан Ибраһимов та, гәптәшләренәң чырайлары үзгәреп киткәнен күреп, сүзеннән туктады: «Мин бит Тукаевның шигырьләрендә булган кимчелек турында әйттем. Күп вакыт кеше үз кимчелекләрен башкалар күрсәткәч кенә ачыграк күрә башлый. Шуның өчен мәдхия укудан бигрәк, күңелсез һәм ачы булса да, тәнкыйть итү кирәгрәк. Фәкать ул яхшы ният белән әйтелгән булсын»,— дип уйлады. Галимҗан фикерен яңадан дәвам итә башлаганчы, Галиәсгар Камал:

— Бу турыда Фатих әфәнде «Әльислах» газетасында язган иде инде. Шул ук фикерне кабатлап утыруда ни файда? — дип әйтергә ашыкты.

Фикеренең хаклыгына ышанган Галимҗан Ибраһимов исә өстенлек алырга тырышты:

— Хакыйкатьне кабатлаудан һичкемгә зарар булмый дип беләм. Бу — бер. Икенчедән, Габдулла әфәнденең бүгенге шигырьләрендә дә шундый ук кимчелекләр очрамаса, бу турыда сөйләп утыру кирәк булмас иде! — дип кискен җавап бирде.

Тукаевның чырае тагын да караңгылана төште. Беренче шигырьләренең теле корама булганын ул үзе дә бик яхшы белә иде. Бигрәк тә Фатих Әмирханның мәкаләсеннән соң бу шигырьләреннән хәтта күңеле кайткан иде. Шуның белән бергә, йөрәгенең ерак бер почмагында ул шигырьләргә җылылык, самимият тә саклый, чөнки аларның барлыкка килүендә Тукаевның Уральск мәдрәсәсендә укыган чагындагы беренче һәм иң якын дусты — яшь төрек егете Габделвәлинең тәэсире зур булган иде. Бу егет Тукаевны төрек әдәбиятының бөтен нәфислеге, нечкәлеге белән таныштыручы, аның күңелендә нәфис әдәбиятка мәхәббәт уятучы, шагыйрьлек дәрте тудыручы кеше булды. Табигате белән дә галиҗәнап, хакыйкать эзләүче, җәберләнгән, изелгәннәрне яклаучы гыйсъянчы егет иде ул. Габделвәли, үзе укыган Стамбул университетының студентлары белән бергә, төрек солтанына каршы күзгалган хәрәкәткә кушыла һәм шуннан соң, зинданга ябылу ихтималыннан качып, Уральск шәһәренә килеп чыга.

Монда да күп яшәми. Иран халкының шаһ хакимиятенә каршы

баш күтәрүе турында ишеткәч, егетнең гаделлеккә, иркенлеккә омтылган йөрәге түзми. Бернәрсәгә карамастан, Иран көрәшчеләре сафына кушылырга ашыга һәм шунда хат-хәбәрсез юк була. Әгәр аның дөньяда барлыгын ишетсә, Тукаев бүген үк очрашырга, әүвәлге дуслыгын яңартырга тырышыр иде. Шуның өчен кунагының: «Беренче шигырьләрегезнең теле — төрле телләрдән алып ясалган корама»,— дигән мәгънәдәге сүзләре Тукаевның иң кадерле хатирәләренә тупас кагылу кебек булды. Әгәр Галимҗан Ибраһимов бу нечкә хисләрдән, кадерле хатирәләрдән хәбәрдар булса, бәлки сүзне шулай кинаттән, әзерлексез башламаган булыр иде.

Әйтергә кирәк тапкан сүзен Галимҗан Ибраһимов кебек үк турыдан-туры, кискен рәвештә әйтә белгән Габдулла Тукаев үзе җавап биргәнче Фатих Әмирхан бәхәскә катнашуны кирәк тапты.

— Хәзерге көндә безнең әдипләребез, шагыйрьләребез, барысы да мәдрәсә җимешләре дип әйтсәк, хакыйкатьтән бик ераклашмабыз. Мәдрәсәләрдә исә, үзегез беләсез, татар теле, татар әдәбияты урынына күбесенчә, я гарәп, я төрек телен һәм әдәбиятын укытып килделәр. Шуның өчен дә әдипләребезнең, шагыйрьләребезнең әсәрләрендә гарәп, фарсы, төрек сүзләре кирәгеннән артык булуы гаҗәп түгел. Без барыбыз да бу кимчелегебездән котылырга тырышабыз. Ләкин Габдулла әфәнде бүгенге көндә дә шундый корама телдә яза дип әйтү — бөтенләй ялгыш! Тукай кебек ана телебезнең кадерен белеп, аңа мәдхия укыган кемне күрсәтә аласыз? Бүгенге көндә татар баласы сөйләргә өйрәнүе белән Габдулла әфәнденең шигырен:

> Әй, туган тел, әй, матур тел! Әткәм, әнкәмнең теле!
> Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы!

дип җырлый башламыймы?! — диде ул һәм, ике яшь әдип арасында салкынлык тумаса ярар иде дигән фикер белән:

— Сәнгатьнең бурычы, хөсусиятләре кебек мөһим мәсьәлә турында сүз арасында гына сөйләшү дөрес булмастыр. Моның өчен махсус җыелыш ясап фикер алышсак яхшырак булыр иде,— дип өстәде.

Галиәсгар ага да:

— Бик дөрес әйтәсез, Фатих әфәнде! Хак сүзгә җавап юк! — дип, Әмирханның фикерен куәтләде, һәм кинәт исенә төшереп: — сәнгать, шигърият турында сүз киткәч, бөтен дөньямны онытканмын! Бүген бит «Купеческое собрание» бинасында театр уйныйбыз! Спектакльгә кирәкле кием-салымнарны табыштырып, хәзерләп куйган идем. Шуларны алып барып, уйнаучыларга тапшырырга, декорацияләрне, реквизитны күздән кичерергә кирәк,— дип, урыныннан кузгалды.

Сүзне әдәбият турындагы әңгәмәдән тагын да читкәрәк борып җибәрер өчен, Әмирхан, нинди җавап алачагын яхшы белсә дә:

— Театр бүген буламыни? Нинди пьеса куясыз? — дип сорады.

Галиәсгар ага:

— Бүген була, бүген! «Беренче театр» белән «Бүләк өчен» пьесаларын куябыз! — дип җавап бирергә ашыкты. Һәм: — Шулай булгач, сез инде миңа рөхсәт итегез, мин китием! — диде дә Ибраһимовка карады: — Сез, Галимҗан әфәнде, ничек? Монда каласызмы, әллә минем белән китеп, артистларыбыз белән танышасызмы? — дип сорады.

Галимҗан Ибраһимов җавап биргәнче, Фатих Әмирхан сүз кушты:

— Мондый уңайлы очрактан файдаланып калыгыз! Татар дөньясында беренче рәсми труппа бит бу! Оешуларына ике ел да юк, ә осталыклары югары дәрәҗәгә менде дип әйтергә мөмкин. Арада бик талантлылары да бар. Мисал өчен Габдулла Кариевне генә алырга мөмкин. Артистлыгыннан башка ул сәләтле администратор да әле. Труппада хәтта ике туташыбыз да бар! Хатын-кыз рольләрен бик матур итеп уйныйлар!

— «Сәйяр» труппасы турында ишеткән идем. Инде үзләре белән дә якыннан танышсам, әлбәттә, бик яхшы булыр! — дип Галимҗан

ризалыгын белдергәч, Фатих Әмирхан да, Галиәсгар Камал да эчләреннән куандылар. Алар икесе дә Галимҗан Ибраһимовның тәнкыйтен урынсыз һәм ялгыш дип саныйлар һәм мондый тәкыйтьнең шагыйрь күңеленә тиешсез рәвештә тупас кагылуын теләмиләр иде.

— Алайса киттек, Галимҗан әфәнде. Сәнгать һәм әдәбият турындагы фикерләрегез белән якын арада, пошкырып кайнап утырган самавыр янында ничек тә булса иркенләп сөйләшербез, уртаклашырбыз әле,— дип, Галиәсгар ага Галимҗанны ашыктырды.

* * *

«Купеческое собрание» бинасына килеп кергәндә фойеда халык байтак җыелган иде инде. Энҗе калфаклы туташлар сердәшләре белән, яшь ханымнар көяз ирләре һәм шаян күзле буйдак егетләр дуслары белән парлашып, фойеда ашыкмый гына әйләнеп йөриләр. Кызлар башкаларның киемнәрен, бизәнү осталыкларын тикшереп, үзара фикер алышалар, көлешәләр. Шунда йөргән егетләргә аларның сүзләре кагылмый, күзләре төшми дип әйтеп булмый, әлбәттә. Ләкин егетләр кыюланып туташларга күз төшерсәләр, кызлар аны күрмәгәнгә салыналар, карашлар очрашканда да ялгышлык белән, очраклы гына булган кебек кыланалар.

Галимҗан читтәрәк баскан олырак кешеләр янында туктап, әйләнбәйләи булып йөргән бу яшьләргә кызыгып карап торды. Аның да менә шуларга кушылып йөрисе, туташларның ачык матур йөзләренә сокланып, күз алмыйча карыйсы килә. Ләкин ялгыз башы агым эченә кереп китәргә уңайсызлана да иде. Шулай икеләнеп торган арада кемдер аның беләгеннән тотып:

— Сез дә монда икәнсез, Галимҗан әфәнде,— диде.

Борылып караса — Хәбир булып чыкты. Үз вакытында «Әльислах» газетасында эшләгән егетне Галимҗан Ибраһимов «Йолдыз» редакциясендә яңадан очраткан һәм шуннан соң берничә тапкыр урамда да күрешкән иде. Бүген Хәбир гадәттәгедән артык көяз күренде: атлас кебек ялтырап торган катыргы ак манишка белән манжетлар, нигилист рус яшьләре арасында «собачья радость» дип, үзләрен тәрәккый пәрвәр дип санаган татар егетләре арасында «күбәләк» дип йөртелә торган кара галстук, өстендә өр-яңа кара костюм, чәчләр дә, брильянтин ягып ялтыратып, маңгай өстенә кабартып тарап куелган...

Галимҗан көлемсерәп Хәбирне баштанаяк карап чыкты да:

— Ай-һай, егет, сез монда бик ерактан, Франциянең нәкъ үзеннән килгәнсез ахрысы! — диде.

— Франциядән бигрәк, бәлки, Англиядән килгәнмендер. Мәсьәлә анда түгел. Шундый ерактан килгәч, мескенләнеп, дивар терәтеп торудан, халык арасына кереп, кешеләрне дә сәер итеп, үзебезне дә аларга күрсәтеп йөрү артык булмасмы? Әйдәгез, бергәләп без дә бу каруселькә кушылып әйләник! — дип, Галимҗанны үзе белән чакырды, ләкин анысы джентльмен егетнең өс-башына тагы бер тапкыр күз йөртеп алганнан соң, үзенең киемнәрен дә күздән кичереп, башын чайкады.

— Юк, Хәбир әфәнде, минем төсен югалта башлаган бу кызыл сатин күлмәгем, җиң очлары кырылган пиджагым синең ак манишкаң белән, аягымдагы иске итекләрем көзге кебек ялтыраган штиблетларың белән ярыша алмыйлар. Синең янында мин теге матур туташларга бигрәк тә бичара булып күренермен. Шулай булгач, баскан урынымнан кузгалмый торсам, хәерлерәк булыр!

Ләкин Хәбир, кыстый-кыстый, ниһаять аны күндерде һәм алар яшьләр арасына кереп кушылдылар.

Мондагы кебек чит-ят ирләр күп булган җирдә татар хатын-кызларының шулай битләрен капламыйча, хәтта калфаклары өстеннән шәл дә ябынмыйча яланбаш көе иркенләп, көлешеп, сөйләшеп йөрүләрен Галим-

җан Ибраһимов беренче тапкыр күрде һәм үзенең гаҗәпләнүен яшермәде:

— Казан җәмгыяте көфер почмагының кануннары буенча гына яшәми икән: театр кебек халык күп була торган урында мондагыдай чәчәкләр бәйләме күрермен дип уйламаган идем,— дип Галимҗан каршы яктагы кызларга саклык белән генә ишарә итте.

— Әллә күзегез бик кызамы? — дип Хәбир көлеп җибәрде, ләкин шунда ук бөтен кыяфәтен үзгәртеп, икенче яктан үтеп барган кызларга карады, төчеләнеп кулын күкрәгенә куйды һәм түбәнчелек белән башын иде.

— Бик матур белешләрегез бар икән. Бу туташлар белән мине дә таныштырмассызмы?

Ибраһимовның шулай кызыксынып соравына каршы Хәбир бик җитди итеп җавап кайтарды:

— Болар икесе дә минем туганнан туган сеңелләрем: Гафифә белән Гарифә туташлар. Сезнең әдип икәнегезне белсәләр, алар үзләре дә бик теләп танышыр иделәр дә, тик әнә тегендә әтиләре белән әниләре алардан күзләрен алмыйча күзәтеп торалар. Әгәр дә мин сезне сеңелләрем янына алып барып таныштырсам, апаларым да, җизниләрем дә рәхмәт әйтмәсләр...

Ул тагын нидер әйтмәкче булган иде, кыңгырау шалтырап, кешеләрне тамаша залына чакырды. Егетләр дә халык артыннан ишеккә таба юнәлделәр.

Спектакль ике бүлектән гыйбарәт икән. Башта артистлар «Беренче театр» исемле комедияне уйнадылар. Антракттан соң шулай ук бер пәрдәлек «Бүләк өчен» исемле комедия уйналачак. Ике комедиянең дә Галиәсгар Камал тарафыннан язылган әсәрләр булганын Галимҗан Ибраһимов яхшы белә, аларны укыганы да бар, ләкин сәхнәдә әле беренче күрүе иде. Аларны артистлар башкаруында күрү Галимҗанга укыган чагындагыдан да ныграк тәэсир итте. Фойега чыккач, шул турыдагы фикере белән уртаклашырга уйлап, халык арасыннан күзе белән Хәбирне эзли башлады. Ләкин аны туганнан туган сеңелләре үз яннарына чакырып алганнар икән. Әнә Галимҗан тарафына вакыт-вакыт башы белән җиңелчә ишарә итеп, кызларга нидер сөйли, алар да кызыксынып тыңлыйлар, ара-тирә абыйлары ишарә иткән якка күз кырыйлары белән карап алалар. «Мин аның белән артистларның уеннары, комедия турында сөйләшермен дисәм, ул кызларга минем турыда әйтә ахрысы,» — дип уйлап өлгермәде Галимҗан, читтәрәк басып торган Гафур Коләхметовны күрде. Аның белән дә «Йолдыз» редакциясендә танышкан иде ул. Соңыннан берничә тапкыр «Шәрык» клубында да, башка урыннарда да очрашып сөйләшергә, фикер алышырга туры килгәләде. Икесенең дә иҗтимагый-сәяси хәлләр белән кызыксынулары, әдәбият-сәнгать мәсьәләләрендә карашлары туры килү сәбәпле, арада җылылык урнашкан иде. Шуның өчен Ибраһимов: «Менә бу кеше белән теләгәнеңчә иркенләп сөйләшергә мөмкин»,— дип уйлап, Коләхметов янына килде.

Чыннан да, кул биреп исәнләшкәннән соң, Коләхметовның беренче сүзләре театр турында, артистларның уеннары турында булды:

— Я, Галимҗан әфәнде, безнең Казан театры, артистларыбызның уены сезгә ошадымы?

Ибраһимов җавабын көттермәде:

— Галиәсгар ага тормышыбызның бөтен ямьсез чирләрен бик яхшы белә һәм үзенең әсәрләрендә аларны гаять осталык белән күрсәтә,— дип тиз генә әйтеп ташлады да бераз тукталып торды: — мин аның пьесаларын комедия дип түгел, ә сатира дип әйтер идем.

Коләхметов яшь әдипнең Галиәсгар Камалның комедияләренә биргән бәясе белән килеште:

— Мин дә нәкъ шул фикердә. Ә артистлар сезнеңчә ничек уйныйлар?

— Бу турыда мин үземне мөтәхәссәс[1] дип әйтә алмыйм. Шулай да

[1] Мөтәхәссәс — белгеч

артистлар бик килештереп, ышандырырлык итеп уйныйлар кебек. Тик менә асрау Биби генә, кыз кешедән бигрәк егерме-егерме биш яшьлек егеткә охшый...

Колахметов ихтыярсыз көлеп җибәрде:

— Аны кем уйнаганын беләсезме?

Галимҗан «белмим» дигән мәгънәдә башын чайкагач, Гафур тагын да рәхәтләнебрәк көлде:

— Күзегез үткен икән, Галимҗан әфәнде. Асрау кызны уйнаган артист, чыннан да, яше егермедән байтак ашкан шагыйрь Сәгыйть Рәмиев ул! Аның сәхнә фамилиясе Сәбактөгин.

Бу сүзләрдән соң Галимҗан, күңелле хәбәр ишеткән кеше сыман, бик кәефләнгән кыяфәт белән:

— Мин аны көчле талант иясе булган шагыйрь дип белә идем, артистлык сәләте дә бар икән. Ходай тәгалә аңардан юмартлыгын кызганмаган! — дип елмайды.

Рәмиев шигырьләрендәге аллаларга, шаһларга, кануннарга буйсынырга теләмәгән, аларның күктәге һәм җир йөзендәге тәхетләрен җимерергә, көл итәргә әзер торган тыелгысыз гайрәтле хисләр Галимҗан Ибраһимовны сокландыра иде. Әгәр шагыйрь әйтәчәк фикерен, күңелендәге теләкләрен, омтылышларын коры үгет-нәсихәт белән генә түгел, бәлки шундый ялкынлы хисләр аркылы гәүдәләндереп бирә алса, шул вакытта гына шагыйрь чын мәгънәсендә шагыйрь була, дип уйлый иде ул һәм Сәгыйть Рәмиевне шундый шагыйранә хисләрнең колы, димәк, чын шагыйрь дип таный иде.

— Бездә күпкырлы талантлар юк түгел. Бишенче ел аларга күз ачып, баш күтәрергә мөмкинлек бирде. Мисалны ерактан эзләмичә, яныбыздан гына да табарга мөмкин. Менә Галиәсгарны гына алыйк: ул — драматург, ул — публицист-тәнкыйтьче, ул рәссам-график, ул — артист, режиссер, ул — бик яхшы оештыручы! Менә бу «Сәйяр» труппасын оештыруда аның роле бик зур булды. Инде «Шәрык» клубы үзенең яңа бинасына күчү белән, ул артистларны, көнкүрешләренә җитәрлек айлык хезмәт хакы бирдереп, шул клубка беркетергә тырыша.

Бу эштә үзенең дә катнашы барлыгын Колахметов Ибраһимовка әйтмәде билгеле.

Кинәт кыңгырау шалтыравы Галимҗанның ачуын китерде: шундый мөһим һәм кызыклы әңгәмәне өзәргә туры килә иде.

* * *

Казанның үзе, аның тормышындагы ямьле-ямьсез яклары белән танышу, әдәби-мәдәни мохите эчендә кайнау, үзенең әсәрләре өстендә уйлану, эзләнү... Шулай 1910 ел да үтеп китте.

Галимҗан Ибраһимовның Казанга килүенә инде ел ярым. «Казах кызы» исемле әсәренең соңгы ноктасы әле куелмаган булса да, ахыргы битләре язылып бетүгә якынлашкан һәм аны Оренбургтагы «Вакыт» нәшриятында бастыру өчен Фатих Кәрими белән сөйләшенгән иде.

Әле әсәр язылып бетмәгән, ә тормыш яңадан-яңа мәсьәләләр, яңадан-яңа бурычлар куя бара. Ничә еллар буена «Гомуми әдәби лисан» тудырырга тырышып йөргән пантюркистларның тавышлары барган саен зәгыйфьләнә башлады инде. Аның каравы әсәрләребезне халкыбыз аңлый торган саф, сада чын татар телендә язарга тиешбез, дигән тавышлар өстенлек алдылар.

Ана теленең кануннары, аны укыту ысуллары турында Галимҗан Ибраһимов кавказлы нугайлар арасында балалар укыткан чагында ук уйланган иде.

Ул вакытта яшь Галимҗан: «Ни өчен безнең мәдрәсәләрдә гарәп теленең сарыф, нәхүен укыталар да, соңгы сулышыбызга чаклы тормышы-

бызга ямь, мәгънә биргән ана телебезнең кануннарын өйрәтмиләр икән?» — дип фикер йөртә иде. Хәзер инде ул җиң сызганып эшләргә, ана телебезнең кануннарын эзләп табарга, тикшерергә, аларны билгеле бер тәртипкә салырга, кыскасы, татар теленең сарыфын, нәхүен тикшереп язарга тиешмен, дигән фикергә килде.

Бу эшне башлап җибәрер өчен романны язып бетерергә, нәшриятка тапшырып гонорарын алырга кирәк иде. Юкса, аның Казанга килгәндәге акчасы, инде күп булса, бер ай чамасы ачлы-туклы яшәргә генә җитәчәк.

Бер көнне шулай, тормышның күңелсез якларын уйлап утырган вакытта, көтелмәгәндә Шәһит Әхмәдиев килеп чыкты. Ул байтак акча белән кайткан икән.

Галимҗан белән Шәһит унбер-унике яшьләрендә Вәли мулла мәдрәсәсендә бергә укый башлаганнар иде. Шул очрашуларыннан бирле бүгенге көнгәчә якын дуслыкларын бозмадылар, ни тапсалар, шуны уртаклаштылар. Бу юлы да Шәһит алып килгән акчаларын уртак итте. Галимҗанның акчасы бурычларын түләргә дә җитмәячәк иде. Шуның өчен исәп-хисапны бурычлардан башладылар.

Якыннары, дуслары арасында вакланып тиеннәр санап утырырга яратмаган Галимҗан Ибраһимов, кемгә күпме бурычлы булганын онытмас өчен, махсус бер дәфтәргә язып бара иде.

Иптәшенең шул гадәтен белгән Шәһит Әхмәдиев:

— Бурыч дәфтәреңне бир әле! — дип сорап алды да андагы саннарның бер тиенен дә калдырмыйча дикъкать белән санап чыкты.

— Әгәр кибетче арттырып язмаса, кибетче дә булмас иде ул! Аның дәфтәрендәге бурычларның суммасы башкачарак булыр. Шуның өчен без ун-унбиш тиен чамасы арттырып язсак, ялгышмабыздыр,— дигәннән соң гына акчаларны бүлә башлады.

Галимҗан, шул көнгә кадәр бик саклап тотканыннан калган дүрт сум егерме җиде тиен акчасын чыгарып өстәлгә, иптәше алып килгән акчалар янына куйды. Шуннан соң: «Бу эшнең калган якларын син миннән остарак башкарырсың әле»,— дигән кебек, читкәрәк китеп утырды һәм кулына каләмен алды.

— Бусы — фатир бурычы, ә бусы — кибетчегә бирәсең булсын,— дип, Шәһит Әхмәдиев акчаның беркадәрен читкәрәк алып куйгач, көндәлек хәрәҗәтләргә, кәгазь сатып алырга, итек табанын яматырга һәм шуның кебек башка нәрсәләргә кирәген хисаплый башлады. Шәһитнең яз һәм җәй буе эшләп тапкан акчасын бик саклап тотсалар, көз буена җитәчәк кебек күренде.

— Ул вакытта инде «Казакъ кызы»ның гонорары да кулга керер,— дип, Шәһит бик канәгать кыяфәт белән кулларын уып куйды.

— «Яшьләр хаятеннән бер ләүхә», «Яз башы» исемле хикәяләрне дә, бер кат күздән кичереп, нәшриятка тапшырсак, бу да бик кирәкле һәм урынлы өстәмә булыр! — диде Галимҗан.

Исәп-хисапны бетереп, акчаларны өстәл өстеннән җыештыра башлаганда, исенә бик кирәкле бер нәрсә төшкәндәй булып, Шәһит:

— Их, дус! Без бит синең учительгә түләргә тиешле акчаны исәпкә алмаганбыз! Син аңа аена күпме түлисең? — дип сорады.

— Мин хәзер учительләр яллап русча укудан ваз кичтем, Шәһит дус. Мин инде рус телендәге дәреслекләрне генә түгел, рус телендәге фәнни әсәрләрне дә үзалдыма укып моталага кылырлык дәрәҗәгә килдем...

Шәһит, бик кызыксынып, дустының сүзен бүлде:

— Димәк, якын киләчәктә өлгергәнлек аттестаты алу ихтималың бар?

Шәһитнең болай да матур йөзе шатлыгыннан тагын да нурланып, җанланып китте. Ләкин Галимҗан «юк» дигәнне аңлатып башын чайкагач, ни әйтергә дә белмичә, аптырап калды. Галимҗан исә әрнүле тавыш белән иптәшенә аңлата башлады:

— Ничә еллар буена ачлы-туклы яшәп, тапкан барлы-юклы акчамны учительләргә түләп, җаен-кышын укыдым, саулыгымны каушаттым. Ә нәтиҗәдә ни күрдем? Кайсы гына гимназиянең, кайсы гына рус уку йортының алдына барма, шап итеп ишегеп ябалар, бусагасы аркылы атларга ирек бирмиләр. Инде кеше булам дисәң, үзеңә генә ышанырга, үз көчеңә генә таянырга кирәк! — диде.

«Галия» мәдрәсәсендә укыган чагында ук яшь Галимҗанның ипигә дигән соңгы акчасына Блохин кибетеннән китаплар алып укыганын Шәһит белә иде. «Чыннан да, Галимҗанның белеме хәзерге көндә гимназияләр тәмамлаган яшьләрнекеннән күбрәк»,— дип уйлады Шәһит, сүзне озынга сузмыйча: — Шулай шул! — дип кенә әйтеп куйды.

Шәһит килгәч, Галимҗанның көндәлек тормышы да җайланды. Ашык-пошык, коры-сары ашаулар бетте. Кибеткә, базарга йөрү, бүлмәне җыештыру кебек вак-төяк мәшәкатьләрне дә егет үз өстенә алды. Әдәбият, матбугат дөньясындагы яңалыкларны тәнкыйди күз белән тикшереп барырга һәм бу турыда «Йолдыз»га мәкаләләр язарга, әсәрләре өстендә эшләргә, уйланырга Галимҗан Ибраһимовның вакыты күбрәк калды.

* * *

Ниһаять, «Казакъ кызы» язылып бетте һәм, Фатих Кәримнең үз исеменә атап, Оренбургтагы «Вакыт» нәшриятына җибәрелде. Инде иркенләп утырып татар теленең кануннарын да тикшерергә, ялкынлы хисләрнең сәнгатькә, шигърияткә ни дәрәҗәдә көч биргәнен күрсәтергә дә вакыт җитте. Галимҗан Ибраһимов җиң сызганып эшкә кереште.

Тыныч кына эшләп утырган бер вакытта, 1911 елның башында, Галимҗанны гына түгел, Россия татарларының бөтен мәдәни катлавын сагайткан кара хәбәр таралды. Вятка губернасының Сарапул өязендәге Бубый авылында Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйлылар тарафыннан ачылган мәдрәсәдә охранка тентү ясаган. Төн буена сузылган бу тентү вакытында бик күп тыелган китаплар, язмалар, прокламацияләр табылган, шул сәбәптән Бубыйлар үзләре дә, мәдрәсәнең башка мөгаллимнәре дә кулга алынып, зинданга ябылганнар. Башта бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр. Чөнки газеталарда тәфсилләп язылган мәкаләләр басылмады. Шулай да күңелсез хәбәр куерганнан-куера барды. Охранканың зур отряд җибәреп, мәдрәсәдә тентү ясатуы бушка булмаган икән. Татар халкын агартучы, аңа туры юл күрсәтүче, аның рухи ихтыяҗларын үтәү юлында көрәшүче саф йөрәкле, ачык фикерле яшьләр тәрбияләү нияте белән мәдрәсә җитәкчеләре Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйлар, бигрәк тә бишенче-алтынчы еллардан соң, атнакич саен мәдрәсәдә җыелыш җыйганнар, патша хөкүмәтенең татар халкын ничек изүе, кысуы турында ялкынлы нотыклар сөйләгәннәр, дөньядагы халләргә шәкертләрнең күзләрен ачарга, аларның күңелләрендә самодержавиегә каршы дошманлык тудырырга тырышканнар. Бу җыелышларда шәкертләрдән докладлар ясатып, фикерләрен халык алдында ачык итеп сөйләргә өйрәткәннәр. Нәтиҗәдә, шәкертләрнең кайберләре русларның сәяси оешма әгъзалары белән бәйләнешкә кереп, халык арасында прокламацияләр дә тарата башлаганнар, имеш. Ишми ишан, Хөсәен мулла Әбүбәкеров, Шаһи-Морат Гадылов кебек мәшһүр карагруһлар, мәдрәсәнең үзендә эшләүче Фәез Даутов, Юнусов кебек провокаторлар бирел торган донослар охранканың дикъкатен күптән инде Бубый мәдрәсәсенә юнәлткән була. Ләкин Гобәйдулла Бубыйлының «Хакыйкать» исемле китабы басылып чыккач, аның тугызынчы бүлегендә самодержавиене хурлап язган фикерен шул ук доносчылар түкми-чәчми генә түгел, хәтта яхшы ук кабартып охранкага җиткезгәч, жандармерия погром башлый. Мәдрәсәләрдә, мөгаллимнәрнең өйләрендә тентүләр, төрмәгә ябулар, штрафлар китә. Төрле шәһәрләрдә яшәүче яңа фикерле татарларны өйләрендә,

нәшриятларда, кибетләрдә, китап складларында, матбагаларда көн саен тентүләр булганы, юк-бар сылтаулар белән күп кешеләрнең кулга алынулары ишетелә. Бубый вакыйгасыннан файдаланып, охранканың зур бер сәяси процесс тудырырга, татарлар арасындагы самодержавиегә зарарлы булган хәрәкәтне төбе-тамыры белән юк итәргә тырышканы күренә.

Оренбургтагы «Вакыт» нәшрияты да бу афәттән котылып кала алмады. Монда гаҗәпләнерлек бер нәрсә дә юк иде, чөнки нәшриятның рәсми хуҗасы Фатих Кәрими, Оренбург губернаторының фикеренчә, зарарлы мәкаләләр язучы буларак, охранкага электән үк мәгълүм кеше иде. Хәтта ул берничә тапкыр төрмәгә ябылырга хөкем ителгән һәм штраф түләү аркасында гына котылып кала алган иде. Шул сәбәпле, аның типографиясендә тентү аеруча җентекле үткәрелә һәм жандармнар, уч төбе кадәр генә язулы кәгазьне дә калдырмыйча, җыеп алып киталәр. Шул вакытта «Казакъ кызы» да охранка кулына төшә.

Фатих Кәриминең бу турыда язган хәбәре романның авторын куандырмады, әлбәттә, шулай да Галимҗан китапның кайчан да булса дөнья күрәчәгеннән өметен өзми иде. «Китапта охранка бәйләнерлек бер сүз дә юк. Димәк, аны бүгенме, иртәгәме нәшриятка кайтарып бирерләр. Тик шунысы бар: тентү вакытында алынган китапларны, кулъязмаларны карап, тикшереп чыкканчы байтак вакыт үтәчәк. Шулай булгач, роман охранка кулыннан ычкынып, дөнья күргәнче бәлки бер елга якын гомер узар. Аның тизрәк басылып чыгуы миңа рухи яктан да, матди яктан да бик кирәк, дип охранканы ашыктырып та, аңа әмер биреп тә булмый шул! Безне һәр яктан кыскан, изгән, канатыбызны шулай каерган тормыштан кайчан, ничек котылырбыз икән?! Шуны белгән кешеләрне кайдан эзләп табарга?» Галимҗан Ибраһимов бишенче-алтынчы елларда көрәштә фидакарьләрчә катнашкан кайбер кешеләргә мөрәҗәгать итеп карады. Ләкин аларның, билгеле бер сәбәпләр аркасында, бу хәрәкәттән читләшкәннәрен белде. Кайберләре баштагы элемтәләрнең өзелүен, аны яңартырга теләп тә уңышка ирешә алмауларын әйттеләр. «Әллә алар миңа ышанмыйлар, әллә инде самодержавие революцион көчләрне чыннан да шулай хәлсезләтеп, подпольега китәргә мәҗбүр иткәнме?»— дип уйлады Галимҗан. Бу фикерләрен ул Шәһиткә дә әйтте. Дусты аны тынычландырырга тырышты:

— Син юкка болай борчыласың! Минемчә, мәсьәлә сиңа ышанмауда түгел. Соңгы елларда патша хакимиятенең сәяси хәрәкәтләрне генә түгел, хәтта аз гына яктырак омтылышларны, арзуларны да ничек каты бастырырга тырышканын үзең дә күрәсең бит. Бубыйлылар мәсьәләсенә бәйләп охранканың ничек котырганы һәркемгә мәгълүм! Шушындый бер заманда, бәлки, чыннан да, сакланып хәрәкәт итәргә, яңадан-яңа кешеләргә охранканың дикъкатен җәлеп иттермәскә кирәктер?

— Ә идән астында посып кына утырудан ни файда?

— Посып утыралармы, әллә юкмы, без бит аны белмибез. Бәлки ачыктан-ачык хәрәкәт итәргә вакыт җитмәгәндер.

— Вакыт җиткәнне көтеп, шулай кул кушырып утырырга кирәк дип әйтмәкче буласыңмы?!

Ибраһимовның җан әрнүе белән биргән соравына каршы Шәһит иңбашларын сикертеп куйды:

— Гаҗәп кеше син! Менә хәзер ана телебезнең кануннарын тикшереп, аның сарыфын язып утырасың. Бу хезмәтең татар мәдәнияте үстерү юлында кирәкле зур бер эш түгелме? Ә язган һәм бүгенге көндә язып утырган хикәяләрең, романнарың шулай ук халкыбызның тормыш офыгын киңәйтүгә, мәдәниятен күтәрүгә хезмәт итмиләрме?

— Мин бит татар халкы өчен әдәбият-мәдәният кирәкми дип әйтмим! Ләкин заманыбыз хәзерге көндә бездән тагын да көчлерәк, кискенрәк, хәлиткеч чаралар, эшләр таләп итә. Шунсыз охранка татарның әдәбиятын да, мәдәниятен дә, хәтта татарның үзен дә тар-мар итәчәк! Инде мәгърифәтчелек белән генә канәгатьләнеп: «Ачылмасмы татарның

ике күзе? Җәһаләттән һәлак була милләт үзе! Моннан соң күренмәсме икән безгә, мәгъшукабыз мәгарифәтнең якты йөзе?» — дип кенә аһ-зар чигеп утыра торган вакытлар үтте, дустым! Халкыбызның мәгърифәтен үстерер өчен дә тормышыбызны төбе-тамыры белән үзгәртергә кирәк. Шунсыз безгә мәгърифәтнең якты йөзен күрсәтмәсләр! Кара сөрем эчендә яшәтерләр!

Шәһит дустының сүзләре белән килешә, тик аның күңелен күтәрергә, ничек тә булса уйларын язып утырган әсәрләренә кайтарырга тырыша иде. Ләкин Галимҗан Ибраһимов та башлаган эшен ярты юлда калдыра торган кеше түгел. Сәяси көрәшкә катнаша алмавына никадәр борчылса да, иҗади эшләрен ташламады. Хәтта Фатих Кәрими әфәндедән, «Казакъ кызы» романы охранкада югалу сәбәпле, нәшриятка кайтарылмады, дигән хаты да аның рухын төшермәде, иҗади эшләреннән аермады, чөнки ул бу эшләреннән халыкка кирәклеген аңлый иде. Киресенчә, халыкның рухи байлыгын таптарга, юк итәргә омтылган золымга каршы ачуы тагын да көчлерәк кабынды...

## Кеше эзлим

Яланаякка чолгау белән генә кигән иске игектән кыш чыккан Галимҗан Ибраһимовка 1911 елның суыклары бик озакка сузылган кебек тоелды. Шуңа күрәдер, Гафур Колахметовтан укырга алган китапларын кайтарыр өчен урамга чыгуы белән, аңа апрель кояшы бигрәк тә назлы, йомшак булып, тротуарлар кырыена кыш буе өелә килгән, хәзер инде ап-ак тазалыкларын югалтып керләнгән, иңә төшкән көртләр, алар астыннан челтерәп аккан гөрләвекләр һаваны сафландыра, җиләсләндерә, күңелне күтәрәләр төсле тоелды. Бу тойгы: «Бүгенге көн уңышлы булырга тиеш. Мондый көндә теләгеңә ирешмәү мөмкин түгел»,— дигән өметне дә уятты.

«Бишенче-алтынчы елларда, Хөсәен Ямашев белән беррәттән революция юлында көрәшүче татарлар арасында Галимҗан Сәйфетдинов исемле кеше дә бар, дип Вәли мулла мәдрәсәсендә укыган чакта ук ишетә идем. Колахметов исә Сәйфетдиновның иң якын дусларыннан берсе. Фикердәш кешең белән генә шулай дус буласың бит. Димәк, болар икесе дә бер фикердәге, бер юлдагы кешеләр. Бүген Гафур әфәндедән үтенеп сорарга кирәк. Ни өчен алар мине үз араларына алырга теләмиләр? Мин бит җаным-тәнем белән халыкка хезмәт итәргә телим! Алар минем теләгемне, омтылышларымны аңларга тиешләр һәм аңларлар да!» — дип уйланып барганда, кемдер арттан килеп аның беләгеннән тотты.

Галимҗан Ибраһимов сискәнеп, башын күтәреп караса, Гафур Колахметов үзе икән.

— Руслар, на ловца и зверь бежит,— дип юкка әйтмиләр икән. Мин бит сезгә бара идем, Гафур әфәнде, ә сез үзегез килеп чыктыгыз,— диде Ибраһимов, күрешергә кулын сузып.

— Очрашуыбыз яхшы булды, чөнки мин өйгә тиз кайтмам. Әллә бик ашыгыч йомышыгыз бар идеме? — дип сорады Колахметов.

— Алай ашыгырлык бернәрсә дә юк. Тик сездән алган китапларны кайтарып, тагын шундый ук бер-ике китап алмаммы дип уйлаган идем. Хәер, үзем турында әйтәсе сүзләрем дә бар иде...

Ибраһимовның җавабын ишеткәч, Колахметов сызылып торган коңгырт кашларын күтәреп, киң маңгаен җыерып, уйланып барганнан соң:

— Мин үзем дә ул китапларны студент Габдрахман Мостафиннан алган идем. Хәзер дә юлым шул якка таба. Теләсәгез, бергә барыйк. Китапларны да шунда хуҗасына тапшырырбыз,— диде.

Галимҗан бу тәкъдимне кире какмады.

Алар килеп кергәндә студентның кечкенә бүлмәсендә өч-дүрт кеше җыелган һәм алларына лото карталары, фишкалар куеп, уртадагы өстәл тирәсенә утырганнар иде.

Сүз Карл Маркс тәгълиматы турында барганы аңлашылды, чөнки яңа кунаклар көрешеп, тыгызланып булса да өстәл янында урын алганнан соң, егетләрнең берсе:

— Марксның әсәрләрен каян табарга мөмкин? — дип сорады.

Җавапны лото мичкәләре тулы кечкенә капчык тотып утырган Галимҗан Сәйфетдинов бирде:

— Әлбәттә, алар Русиядәге басмаханәләрдә басылмыйлар, китап кибетләрендә ачыктан-ачык сатылмыйлар...— Аның кысыграк күзләрендә елмаю чаткылары уйнап алды. Кулындагы капчыкны селкеп, мичкәләрне шалтыратып алганнан соң сүзен дәвам итте: — Әгәр Маркс тәгълиматы белән танышырга теләсәгез, миңа кунакка килегез. Квартирам Карл Маркс рухы белән тулы!

Сәйфетдиновның бу сүзләре Ибраһимовка көнелендәге омтылышлары турында сөйли башлар өчен бик уңай сәбәп булды.

— Без барыбыз да Карл Маркс җәнапларының тәгълиматы белән якыннан танышырга тиешбез дисәм, хата булмастыр. Назариятне [1] белү, әлбәттә, бик кирәк,— диде ул.— Ләкин, назарияттән башка хәрәкәт тә кирәк дип уйлыйм. Миңа моңарчы революцион назарияләр белән танышырга туры килмәде дип, кул кушырып утырырга безнең хакыбыз юк! Халкыбызның бүгенге көндәге әхвале бездән эш, көрәш таләп итә. Сез безгә менә шул көрәш юллары турында сөйләгез, безләрне шул юлга алып барыгыз!

Яшь әдипнең дулкынланып, кызып әйткән сүзләрен ишеткәч, башкалар да: «Җавап нинди булыр икән?» — дигән сыман кызыксынып, бер Галимҗанга, бер Сәйфетдиновка карап алдылар. Сәйфетдинов исә, сул терсәгенә таянып, коңгырт чәчләрен берничә тапкыр бармаклары белән артка тарап, уйланып торганнан соң, ниһаять, башын күтәреп, яшь адашына елмаеп карады.

— Хәзергә мин үзем дә андый хәрәкәттән ераграк торам,— дип башлады ул һәм бу сүзләрен кабатларлык нинди дә булса берәр мөһим сәбәп эзләп, бераз тукталып торганнан соң кинәт йөзе ачылып китте: — Минем хатыным Ольга Войдинова Казанда хатын-кызлар өчен ачылган гали курсларда укый. Ике елдан тәмамлаячак. Шуннан соң мин үз ихтыярымда булачакмын, югыйсә жандармерия кулына төшү ихтималым бик мөмкин. Хәзергә хәл күз алдыгызда. Аз гына шикләндеме, охранка шунда ук кулга ала, зинданга яба, сөргенгә җибәрә, аса, кисә... Ә бу хәлдә Ольга, укуын тәмамлый алмастан, юл уртасында калачак...

Шундый сылтау тапканына бик канәгать булып, ул күбәләк галстугын төзәтеп куйды.

Ләкин Галимҗан Ибраһимов аның сүзләренә һич ышанмады. «Сәяси хәрәкәттән бөтенләй ераклашкан булса, күпне белергә теләгән городовойларны, дворникларны алдар өчен менә шулай лото уйнаган булып, Маркс тәгълиматы турында сөйләп утырмас иде»,— дип уйлады һәм тагын да кызуланып адашына ябышты:

— Тормыш көннән-көн авырлаша бара. Сулыш алырлык та чара калмады. Бик дөрес әйтәсез: авызыңны ачып, хак сүз әйтүче булдымы, аны шунда ук зинданга ябалар, сөргенгә куалар... Бу әхвәлдә эндәшмичә, көрәшмичә, читкә чигенеп, посып утыру үзе бер җинаять түгелме?

Сәйфетдинов яшь әдипнең бу сүзләренә бөтен күңеле белән кушыла һәм аның шундый кызулык белән көрәшкә омтылганын күреп сөенә иде. Ләкин шуның белән бергә, әле күптән түгел Хөсәен Ямашевның Галимҗан Ибраһимов турында әйткән сүзләре дә исенә төшә. «Мин аны Оренбургтагы мәдрәсәдә укучы шәкерт чагыннан беләм. Шул вакытта ук ул миңа уйлана торган, эзләнә торган егет булып күренгән иде. Аның соңгы хикәяләре әдип буларак үсә барганын күрсәтәләр. Шул юл белән барса, халыкның мәдәниятен, аңын үстерүче кирәкле кеше булып

---

[1] Назарият — теория.

житешәчәк. Талантлар адым саен очрамыйлар. Шуның өчен Галимҗан кебек егетләргә туры юл күрсәтеп, ярдәмләшергә, ләкин үзләрен замананың хәвеф-хәтәреннән сакларга кирәк»,— диган иде ул.

Ниһаять, Сәйфетдинов башын артка ташлап, сул кашын күтәребрәк, җитди кыяфәт белән Галимҗанга карады:

— Бик дөрес әйтәсез, адаш! Төрле кысулар, изүләр көннән-көн арта бара. Менә шуның өчен дә бик сак булырга кирәк. Революция көчләрен, көрәшчеләрне жандармерия кулына төшермәс өчен, партия үзенең эшен конспирация юлы белән алып барырга мәҗбүр...

Сәйфетдиновның бераз тукталып торуыннан файдаланып, моңарчы эндәшми утырган Колахметов, бер Сәйфетдиновка, бер Ибраһимовка карап алды да:

— Чыннан да, бер җирдә өчтән артык кеше җыелдымы, городовой килә дә житә. «Ни өчен җыелдыгыз?» — дип тикшерә, «Таралыгыз!» — дип куа башлый. Әгәр инде берәр нәрсә сизенсә, һичшиксез, шунда ук охранкага хәбәр бирә. Әле монда берәү дә кереп тикшеренеп йөрмәвенә гаҗәпсенеп утырам мин,— диде ул.

Квартир хуҗасы студент Мостафин көлеп җибәрде:

— Гаҗәп түгел! Сез килгәнче мин городовойга чынаяк тутырып акны эчерттем дә иптәшләрем килеп лото уйнаячагыбызны сөйләдем. Шул сәбәптән, ул килгәнегезне дә күрмәмешкә салынды, ничә кеше килгәнен дә санап маташмады.

Галимҗан Ибраһимов, сүзнең төп темадан читкә китүенә канәгатьсезлеген күрсәтеп, кашларын җыерды. Сәйфетдиновның конспирация турындагы сүзләрен ул: «Партия бүгенге көндә синең кебек сыналмаган, тикшерелмәгән һәрбер кешене үз сафына ала алмый».— диган мәгънәдә аңлаган иде. Ләкин, тотнаксызлык күрсәтергә теләмәгәнлектән, сабыр тавыш белән:

— Замананың җиңеләя төшкәнен көтеп, безнең кебек типсә тимер өзәрдәй егетләр читтә тик утырырга тиешме сезнеңчә? — дип сорады.

Алдындагы лото мичкәләре идәнгә чәчелеп киткәненә илтифат итмичә, Сәйфетдинов кулындагы капчыгын өстәлгә куйды, һәм һәрбер сүзенә басым ясап:

— Нигә тик утырырга кирәк булсын? — дип сорауга каршы сорау бирде дә, җавап та көтмичә сүзен дәвам итте: — Менә сез, адаш, татар әдибе булып үсеп киләсез. Бик яхшы, мәгънәле хикәяләрегез бар. Хәзер татар тормышыннан зур роман, татар теленең сарыф, нәхүен [1] язып утырасыз дип ишеттем. Сезнең бу эшләрегез — халкыбызның мәдәниятен үстерүгә, дөньядагы хәлләрне күрерлек итеп күзләрен ачарга, аңнарын киңәйтергә зур ярдәм итә торган эшләр... Кыскасы, әгәр сез хәзерге эшегезне намуслы рәвештә алып барсагыз, халык каршындагы бурычыгызны тулысынча үтим дип хисаплый аласыз. Менә сез, назариятне белү кирәк дип бик дөрес әйттегез, әлбәттә. Назарият белән коралланмыйча, көрәшүнең мәгънәсе юк, чөнки сәяси көрәш иске тормышны җимерү өчен генә түгел, яңа тормыш корыр өчен дә кирәк ул. Димәк, сәяси көрәшченең яңа тормыш нинди булырга тиешлеген һәм бу тормышны ничек корырга кирәклеген яхшы белүе мәҗбүри. Тик шунда гына без кирәкле нәтиҗәгә ирешәчәкбез...

Сәйфетдиновның фикерләре бик дөрес икәнен һәм үзенең сәясәттә хәзерлеге зәгыйфь булганын Галимҗан Ибраһимов яхшы аңлады. Шулай да мондый сүзләр аны канәгатьләндермәде генә түгел, хәтта хәтерен калдырды. Үз араларына кертмәс өчен Сәйфетдинов аны күкрәгенә тибәреп, артка чигендерергә тырышкан кебек тоелды. Ләкин ул бу турыда бәхәсләшеп утырудан файда чыкмаячагын белде. Күңелендә кайнаган үпкәсен сиздермәс өчен китәргә булды. Алып килгән китапларын Колахметовка сузды. Башта Гафурның озынчарак нәфис йөзендә гаҗәпсенү

[1] Сарыф — морфология, нәху — синтаксис.

әсәре күренде, ләкин Галимҗанның китапларны ни өчен аның кулына тапшырырга теләвен шунда ук аңлап, сызылып торган нечкә мыегы астыннан көлемсерәп куйды. «Бу китапларны аңа мин биргән идем бит»,— дип уйлады, кабул итеп алгач, кулдан-кулга биреп, Мостафинга тапшырды. Анысы, тиз генә икенче бүлмәгә чыгып, тагын ниндидер ике китап тотып керде.

— Укырга теләсәгез, менә, бик кызыклы ике брошюра: берсе — «Принципы труда в современном обществе» исемле, икенчесе — «Пролетарская борьба в России»,— дип, аларны Галимҗанга сузды.

Галимҗан Ибраһимовның кәефе шул дәрәҗә кырылган иде ки, ул рәхмәтен дә әйтә алмады. Башын гына иеп, китапларны алды да саубуллашып чыгып китте.

* * *

«Яшь йөрәкләр» язылып бетте. Хәтта басыла да башлады. Ләкин романны тудырган уйлар, хисләр һаман суынмыйлар, борчыйлар. Ниндидер ачыкланып җитмәгән протест әдипнең йөрәген кимерә, газаплый. Әллә Зыя белән Мәрьямнең фаҗигасе һаман шулай күңелен сызлатамы? Дөньядагы иң матур, иң гали омтылышларга киртә булып, аларны изгән, агулаган, шул фаҗигане тудырган тормыш шартлары аның күз алларын караңгылаталармы? «Өстебезне каплап алган бу сөремнән ничек котылырга?! Инсанның иң мөкатдәс тойгыларын, омтылышларын таптаган кара көчләрне ничек җиңәргә?! Бишенче-алтынчы елларда яшьнәп-күкрәп, күкрәк киереп, җиң сызганып, якты киләчәк юлында җәлладларга каршы көрәшкә чыккан егетләр бүген кайларда? Шулай ук алар зинданнарда, сөргеннәрдә һәлак булып беттеләрме? Аларның намуслы, якты йөзләре хәтеребездә дә бит, ә безгә ни эшләргә кала? Бу бәлаләрдән котылганнар шул дәрәҗә конспирациягә бирелгәннәр ки, аларны эзләп табу мөмкин түгел. Хәзерге вакытта бәлки шулай кирәктер дә, ләкин... ләкин... Революция җиңелде, бөтен өметләр өзелде, алда тик караңгы төн, дип төшенкелеккә бирелгән, эчкечелеккә, карта уенына, хатын-кызлар белән уйнаш итүгә сабышкан егетләр азмы? Нишләргә? Кая барырга? Бу сазлык минем үземне дә бөтенләй тартып алып йотканчы, аякны нык басардай урынны каян табарга?» — дигән күңелсез уйларга бирелеп утырган бер көндә, Казатинда яшәгән иптәше Каюм Мостакаевтан хат килде. Ул җәй көннәрендә казах арасына кымызга барачагы һәм, аннан кайтышлый юл уңаенда, берничә көнгә Казанда тукталачагы турында язган иде.

Каюм белән очрашу ихтималы Галимҗанны бик шатландырды. Уртача буйлы, алсуланып торган яңаклы, куе кара кашлы, һичбер төрле таракка буйсынмаган куе кара чәчле, ябык кына, сөйкемле бу егет белән танышканына бер ел гына булса да, Галимҗан аны саф күңелле, вәгъдәсендә нык тора торган кеше дип белә иде. Былтыр Казанда очрашкан чакта сүз ара сүз чыгып, Галимҗан Ибраһимов аңа: «Әгәр тамак туйдырырлык һәм өлгергәнлек аттестатына хәзерләнер өчен учительгә түләрлек акча килердәй хезмәт табылса, бернәрсәгә карамастан, теләсә кая барып, синең кебек җиң сызганып эшләргә риза!» — дигән иде. Шуны онытмаган икән. «Киевнең үзендә татарча укытучылык урыны булырга тора. Әгәр әүвәлге фикереңнән кайтмаган булсаң, кичектерми җавап бир!» — дигән.

Киев студенты Хәлиулла Еникеевның Казан университетының медицина факультетында укучы якташы Хәнәфи Кайбышевка язган хатына караганда, андагы мөселман студентлары арасында ниндидер иҗтимагый хәрәкәт башланганга охшый. Әгәр чыннан да шулай булса, анда үз идеалларыннан өметләрен өзмәгән намуслы кешеләр табылырга тиеш. Бәлки шулар белән танышырга мөмкин булыр... «Аннары, кемнәрне укытырга? Зурларнымы, балаларнымы? Хезмәт хакы күпме булачак?

Шуларны да ачыкларга кирәк»,— дип уйлады Галимҗан Ибраһимов, шунда ук Каюмга җавап язарга булды. «Киевкә барудан, әлбәттә, баш тартмыйм. Эшнең матди тарафларын да тәфсиллерәк белеш. Кымыздан кайтышлый берничә көнгә Казанда тукталачакмын дигәнсең. Ул вакытта мин дә Казанда булачакмын. Шунда очрашып, билгеле бер карарга килербез»,— дигән сүзләр белән хатны тәмамлады.

Җәйнең соңгы көннәрендә бу ике дус Казанда, «Болгар» гостиницасының бер бүлмәсендә күрештеләр. Кыскача гына хәл-әхвәл сорашканнан соң, өстәл тирәсендәге урындыкларга утырырга ашыкмыйча, кызыксынып, аяк өсте торган хәлдә бер-берләренә карашып алдылар. Галимҗанга Каюм узган елга караганда да ябыграк, йончыганрак булып күренде. «Сәламәтлегә мактанырлык булмаса кирәк. Кымыз да үзенә ярдәм итмәгәнгә охшый»,— дигән уй килде аның башына. Каюмга исә Галимҗан да чиктән тыш арыган, хәлсезләнгән, күзләре, яңаклары эчкә баткан кебек күренде. «Өс-башы да һаман шул, искечә икән»,— дип уйлады. Чыннан да, Ибраһимовның өстендә былтыргыга караганда да уңа төшкән кыек якалы кызыл сатин күлмәк, билендә зур пряжкалы киң кара каеш, кулында яңа дип әйтергә мөмкин булмаган киң кырпулы кара эшләпә, аякларында күп юлларны таптаган иске итекләр... Ләкин егетләр күңелләрендә калган шыксыз тәэсирләрне бер-беренә белдермәделәр. Дустының тышкы кыяфәтеннән туган күңелсезлеген сиздермәс өчен Каюм:

— Мин хәзер килермен. Половойга самавыр китерсен дип кенә әйтим әле! — диде дә, номердан ашыгып чыгып китте.

Ялгыз калгач, Галимҗан Ибраһимов уртадагы өстәл тирәли йөреп чыкты, ләкин бүлмәдә дикъкатьне җәлеп итәрлек бер нәрсә дә күрмәде: өстенә соргылт сары одеял япкан тар тимер кровать, иске комод, ишек янында көзгесе чатнаган юынгыч, ике урындык...

Каюм озак көттермәде.

— Ашханәдә кайнар пәрәмәчләр бар икән. Самавыр да кайнап утыра, хәзер кертерләр! — дип, ишектән үк сөйләнә-сөйләнә килеп керде.

Дөрестән дә, Каюм артыннан ук дип әйтерлек кара кәләпүшле, алъяпкычлы половой килеп керде. Шаулап, пошкырып торган ярты чиләклек самавырны өстәлгә утыртканнан соң ул, ашханәдән чынаяклар, пәрәмәчләр, казылык кебек нәрсәләр ташый башлады. Бу нигъмәтләрне күреп, Галимҗан Ибраһимов хәтта аптырап калды. Кулларын ике якка җәеп ихтыярсыз:

— Бу кадәр сый нигә кирәк? Син болай да кыш буе җыйган акчаларыңны юл чыгымнарына туздырып бетергәнсеңдер,— дип әйтмичә булдыра алмады.

— Хафа булма, дустым! Ял вакытында да сыйлашмасак, кайчан сыйлашырбыз? Әйдә, утыр, пәрәмәчләр кайнар чакта ашап алыйк! — дип, иптәшен табынга чакырды.

Галимҗанның да, Каюмның да карыннары ачыккан иде. Башта алар, күп сөйләшмичә, бик тәмләп тәлинкәдәге бер өем пәрәмәчләрне ашап бетерделәр. Каюм гөрләп пошкырып утырудан һаман туктамаган самавырдан иптәшенә чәй ясап сузды да:

— Беренче каттагы «Юл» көтепханәсенә кергән идем. Синең «Яз башы» исемле хикәяң белән «Шура» журналында басылган «Йөз ел элек» дигән хикәяләреңне генә таптым. Башка әсәрләрең сатылып беткән. «Тукай белән Ибраһимовның әсәрләре көтепханәдә озак кунаклашмыйлар, дәррәү сатылып бетәләр. Әле боларның да моңарчы сакланып калулары гаҗәп»,— ди сатучы малай. Мин бигрәк тә синең «Татар сарыфы» дигән әсәреңне алырга теләгән идем,— диде. «Бәлки үзеңдә артык берәр нөсхә табылмасмы?» дигән өмет белән иптәшенең күзләренә карап алды.

— Таптың китап саткан җир! — диде Галимҗан.— Андагы киштәләрдә бер вакытта да китаплар күрмәссең! Элегрәк хат язып сораган

булсаң, мин ул китапны сиңа почта белән дә җибәргән булыр идем. Ләкин хәзер кулымда артык бер нөсхә дә юк.— Каюмның күңелсезләнеп, башын кагып алганын күргәч, өстәп куйды: — Сиңа ул китап бик кирәк булса, мин аны табарга тырышырмын.

Каюмның чырае ачылып китте:

— Менә бу вәгъдәң өчен зур рәхмәт сиңа! — дип, шатлыгыннан кулы белән тезенә сугып куйды.

Ниһаять Каюм төп мәсьәләгә күчте:

— Киевта татарлар аз түгел. Байлар, сәүдәгәрләр, вокзалда ресторан тотучылар да бар. Менә шуларның балаларына татарча укытучы кирәк.

— Балалар зурлармы?

— Икесеме-өчесеме Киев университетында укучы студентлар, тагын бер-икесе гимназисткалар. Боларга татар телен һәм әдәбиятын укытырга, тагын берничә яшь балага хәреф танытып, укырга-язарга өйрәтергә кирәк булачак.

— Димәк, шәкертләр үнләп булачак...— дип, Галимҗан Ибраһимов уйланып торды да: — Аларның барын оергә кушып укытып булмас шул,— диде.

— Әлбәттә, шулай! — дип, Каюм да аның сүзен раслады.— Көн саен җиде-сигез сәгатеңне шәкертләр укытып үткәрергә туры киләчәк. Аның каравы, калган уналты-унҗиде сәгатеңне, теләсәң, өлгергәнлек аттестатына хәзерләнеп, теләсәң, романнар, хикәяләр язып, теләсәң, болай гына ял итеп, хәл-көч җыеп үткәрерсең! — дип өстәде.

— Яшь балаларга хәреф танытырлык кеше табылмыймы соң анда?

— Мулла яки мөәзин кебек берәрсе табылыр иде бәлки. Үзең беләсең, татар булган җирдә, әлбәттә, мулла-мөәзинсез булмый. Ләкин хуҗалар: «Безгә хәзерге заманның таләпләренә муафыйк, мәдәни халык арасында үз-үзен тота белерлек, шәкертләренә үрнәк булырлык кеше кирәк»,— диләр. Шуның өчен мин синнән дә лаек кеше тапмадым.

Иптәшенең сүзләре Галимҗанны бераз уңайсызландырды. Ярарга тырышу нияте белән Каюм аны тиешеннән артык мактаган сыман тоелды. Сүзне икенчегә борырга тырышты:

— Хезмәт хакы ничек булачак? Белешмәдеңме?

— Ник белешмәскә? Белештем! Ашау-эчү алар исәбеннән вокзалның беренче классы ресторанында. Квартир нәкъ шәһәр уртасында диярлек. Шулай ук хуҗалар хисабына. Аена утыз биш тәңкә акчалата! Әгәр шул шартларга риза булсаң, юл расходларын да үз өсләренә алачаклар. Тик юл хакы утыз биш тәңкәдән артмаса икән, диләр.

Иң якты хыялында да Галимҗан Ибраһимовның мондый яхшы шартлар тәкъдим итәрләр дип өметләнгәне булмады. Ышанырга да, ышанмаска да белми, күзләрен зур ачып, иптәшенә карады:

— Син, дус, чынлап әйтәсеңме, әллә шаяртасың гынамы?

— Шаяртырга син бала түгел ич! — Каюмның шулай дип әйтүе булды, Галимҗан урыныннан сикереп торды да, иптәшен кочаклап алып, уң яңагыннан да, сул яңагыннан да үпте. Шулай балаларча ашкынудан икесе дә уңайсызландылар. Галимҗан сүзне үзен аеруча кызыксындырган якка күчерергә ашыкты:

— Киев университетында минем якташлардан Хәллә Еникеев исемле егет укый. Аны беләсеңме?

— Киевкә барган араларда очрашам мин аның белән. Анда мөселман студентлары бик күп. «Якташлык җәмгыяте» оештырганнар. Хәлиулла да анда әгъза икән. Җәмгыятьләрнең эшләре турында бик мавыгып сөйли ул.

— Эшләренең, чыннан да, мәгънәсе бармы икән соң?

— Болай, алар арасында булганым юк. Мин студентлардан бер читтәрәк тора торган кеше бит. Шулай да Хәлләне күргәлим. Аның сүзенә караганда, җәмгыятьчеләр, гомумән, мәгърифәтчелек эшләре

белән шөгыльләнәләр икән. Җыелышларында иҗтимагый, тарихи һәм башка мәүзуглар буенча докладлар, рефератлар укыйлар ди...

Мостакаевның сүзләре студент-медик Хәнәфи Кайбышевның Хәллә турында әйткәннәрен раслый иде. Димәк, Еникеев чыннан да студентлар арасында сәясиме, иҗтимагыймы хәрәкәткә катнаша икән.

— Адресын беләсеңме син аның?

Каюм гаепле кеше сыман, аптырап:

— Менә бит! Мин аның үзе белән берничә тапкыр фатирына бардым, ә урамының исемен дә, йорт хуҗасының фамилиясен дә белмим,— дип җавап кайтарды.

— Белмәсәң дә, әллә ни зыян юк. Хәлләнең адресын Кайбышевтан алырга мөмкин. Алар бик якын дуслар, даими хат алышып торалар,— дип, Галимҗан иптәшен тынычландырды.

Иптәшләрнең сүзләре күп булды, вакытның узганын да сизмәделәр. Өстәлдәге самавыр да, егетләрнең үзен онытуларына кәефсезләнгән, үпкәләгән сыман сүнгәннән-сүнә барып, ара-тирә моңлы итеп сызгыргалап ала иде.

* * *

Озакламый, юл чыгымнарына дигән утыз биш тәңкә белән, Каюмның үзеннән бурычка алынган кырык сум да килеп җитте.

Русларның «киеменә карап каршы алырлар, акылына карап озатырлар» дигән әйтемнәрен хәтердә тоткан Галимҗан Ибраһимовның Киев байларына иске киемнәрдән күренәсе килмәде, өс-башын яңарта төште. Бурычларын да түләде.

Иртәгә китәм дигән көнне ул, Еникеевның адресын алыр өчен, Хәнәфи Кайбышев белән очрашырга булды.

Хәнәфинең яңа күчкән фатирына Галимҗанның әле барганы юк иде. Ишектән кереп килүе белән тукталып, бүлмәдәге җиһазларны күздән кичерде. «Моның әүвәлге фатиры андый бай, зиннәтле түгел иде бит. Бу фатирга әллә ни хәтле акча түли торгандыр. Бу кадәр акчаны каян ала икән? Ни дисәң дә, алпавыт малае шул!» — дип уйлады.

Бүлмәнең җиһазы Галимҗан Ибраһимов кебек үз көчләре белән көн күргән яшьләр өчен, чыннан да, ис китәрлек иде. Караватны киртәләп торган ширманың кара ефәгә өстенә елга буендагы күренешләр, агачлар арасында балык каптырып утырган кытайлар чигелгән. Тәрәзә алдында язу өстәле. Аның өстендә арыслан сыны рәвешендә ясалган соры мәрмәр кара савыты. Идәндә зур йомшак келәм. Уртада җете кызыл төстәге хәтфә эскәтер ябылган түгәрәк өстәл. Аның тирәсендә шундый ук хәтфә белән тышланган дүрт йомшак урындык. Сул стена буенда диван. Язу өстәле алдында һәм аның сул ягында ике кресло. Стенада кара атлас өстенә соры ефәкнең төрле төсмерләре белән чигелгән сәмруг кош сыны...

Бу зиннәтле бүлмәнең хуҗасы, Казан университетының студенты Хәнәфи Кайбышев, ишек янында кузгалмыйча басып торган Галимҗан Ибраһимовка карап:

— Нәрсә катып калдың? Әйдә, үт, утыр! — дип, кулы белән креслоны күрсәтте.

Галимҗан язу өстәле янындагы креслога килеп утырды да инде Хәнәфинең үзен баштанаяк күздән кичерде.

Студент өстендәге җылы халатның якасына, җиң очларына, кесә кырыйларына әллә нинди матур үрнәкләр типчелгән, аягында башы югарыга кәкрәеп торган йомшак өй башмаклары. Егетнең зифа буена, кысынкырак кара күзләренә, дулкынланып торган кара чәчләренә бу затлы киемнәр килешеп тора иде. Ләкин өй хуҗасының кыяфәте Галимҗанга ничектер ясалма булып күренде.

— Әллә авызыңа май каптыңмы, эндәшми торасың?

— Синең шулай байларча яшәвеңә хәйран калып торам. Үзең ал-

дыңгы фикер кешесе булсаң да, мирзалык гадәтләре каныңа сеңгән. Ләкин шул кадәр акча каян табасың?

Кайбышев көлемсерәде:

— Сәнгатькә табынган кеше үзенең көндәлек тормышын да матур итеп оештырырга тиеш дип уйлыйм мин. Монда гаҗәпсенерлек бернәрсә дә юк! — дип җавап бирде дә, акча мәсьәләсенә кагылмыйча гына, сүзне икенчегә борды: — Киевка китәргә җыенасың дип ишеттем. Анда синә ни калды?

Галимҗан Хәнәфинең күзләренә төбәлеп карады:

— Аңламаган булып кыланма әле! Мондагы әхвәлне мин сөйләмәсәм дә, бик яхшы беләсең. Киевтә ниндидер бер җанлы хәрәкәт барлыгы турында миңа үзең әйткән идең бит!..

— Ә-ә! Хәлиулла Еникеевның хаты турында әйтәсеңме? Ул бит мавыгучан кеше. Аның сүзләренә бик үк ышанып та булмый. Яңа иптәшләре белән бер сафта торып халыкны җәберләүче, изүче залимнәргә каршы көрәшәчәк, имеш! Әйтерсең лә, тирә-юньдәге әхвәлдән хәбәре юк! Шулай урынлы-урынсыз такылдап йөрсә, Столыпин бабаң үзен үлем элмәге белән кавыштырганны сизми дә калыр. Хәлиулла кебек «көрәшчеләр» (бу соңгы сүзне Хәнәфи аеруча мыскыл белән әйтте) тик Киевтә генә табылыр, Казанда андыйлар юк дип уйлыйсыңмы?

Кайбышев аякларын алга сузып, креслога аркасын терәп, ипләбрәк утырды. Сул кашын күтәрә төшеп, ирония белән әңгәмәдәшенә кырын күз ташлады. Аның кунакны юри ярсытасы, күңелендә ни барын, ни югын әйттерәсе килә иде.

Галимҗан Ибраһимов, чыннан да, ярсып китте. Утырган урыныннан торды да бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлады.

— Хөсәен Ямашев кебек саф йөрәкле аерым шәхесләр юк түгел иде. Я, алар кайда хәзер?! Ямашев кинәт үлеп китте. Халык арасында, ул кара көчләр, хаиннар кулыннан һәлак булды, дигән сүзләр йөри. Ибраһим Моратов кебекләр зинданнарда, сөргеннәрдә чахоткадан үлеп калдылар. Ишеткән хәбәрем дөрес булса, Гомәр Терегулов әүвәлге идеалларыннан кире кайтканга охшый... Бу кеше Уфа губернаторына гариза биргән, моннан ары сәясәткә дә, иҗтимагый хәрәкәтләргә дә катнашмам, дип тәүбә иткән, сәяси ышанычлылык алып, земствога эшләргә кергән, диләр...

Хәнәфи Галимҗанның сүзен бүлде:

— Урысларда бер мәкаль бар: «Рыба ищет где глубже, а человек — где лучше»,— диләр. Бик дөрес мәкаль! Революция җиңелде! Шуны аңларга кирәк, дус! Дон Кихот Ламанчский булып, җил тегермәннәре белән сугышып йөрүләрдән ваз кичәргә вакыт! Бишенче елны түгелгән каннар да җитәрлек! Акыллы кешеләр бүген легаль юллар белән йөрергә тырышалар!

Галимҗан Ибраһимов Кайбышевның алдына килеп басты:

— Безнең атаклы философыбыз, теоретигыбыз, әдибебез, кыскасы, бөтен Казанга мәшһүр булган син үзең дә соңгы вакытта тынып калдың. Димәк, син тирә-ягыңда ышанычлы терәк булырлык иптәшләр тапмыйсың!

— Син дә тапмыйсың, юкка йөрисең,— диде Кайбышев. Бераз уйланып торгач, дулкынланган чагындагы гадәте буенча рус сүзләрен куша-куша, дәвам итте: — Адәмне бер савытка охшатыйк. Тормыштан, природадан, наукадан алган благолары белән бу савыт башта үзен камил тутырсын. Әгәр тулып ташыса, әнә шул артыкны ул башкаларга бирергә хаклы. Кешеләргә, җәмгыятькә, халыкка, инсаниятькә хезмәт әнә шул тулып ташкан тамчылар рәвешендә булганда гына табигый. Менә шул хакыйкатьне аңлау гына революциядән соң миңа тынычлык бирә алды,— дип, сүзен бетерде.

Иптәшеннән бу сүзләрне ишеткәч, Галимҗан ни әйтергә дә белми катып калды. «Бу бит тар индивидуализмның төп нигез ташы! Бу —

Хәнәфинең үз фикере түгел. Әллә чыннан да ул «гыйльми, фәлсәфи индивидуализм» сазлыгына шуып төштеме икән?» — дип уйлады. Ниһаять, акылын туплап, кырыс тавыш белән сорап куйды:

— Авыл мужигы Степан Кривоногов хәтле дә була алмыйм дисеңме инде?

Кривоноговның кем икәнен бердән исенә төшерә алмыйча, аптыраган кыяфәт белән кунагына карап торганнан соң Хәнәфи:

— Ул тагын нинди авыл мужигы? — дип сорарга мәҗбүр булды.

Галимҗан шелтә белән башын чайкады:

— Сиңа ни булды? Бөтен татар галәменә кагылган Бубыйлар вакыйгасын да оныттыңмы әллә?

— Онытмадым, әлбәттә. Ләкин ул Кривошеинның...

— Кривошеин түгел, Кривоногов, Степан Кривоногов! — дип, Галимҗан Ибраһимов Кайбышевның сүзен бүлде.

— Әйдә, Кривоногов булсын! Ләкин аның Бубыйларга нинди мөнәсәбәте бар? — дип, анысы авызының бер кырые белән көлемсерәде. Кабара барган ачуын басарга тырышып, Хәнәфинең күзләренә бераз карап торганнан соң Галимҗан басынкы тавыш белән:

— Кривоногов, авылларының старостасы өендә чәй эчәргә дип тукталган жандармнарның кая, ни өчен барганлыкларын белешә дә, тиз генә атын җигеп, Бубыйларның авылына чаба һәм аларга: «Жандармнар сезнең мәдрәсәне тентергә киләләр!» — дип хәбәр бирә. Шуның өчен бит ул күптән түгел бер елга төрмәгә ябылды,— дип аңлатты.

Әгәр Степан Кривоногов жандармнарның тентү ясаячакларын алдан килеп хәбәр итмәгән булса, охранка кулына әллә ни хәтле брошюралар, кульязмалар, русча-татарча прокламацияләр, хатлар, протоколлар эләккән булыр иде. Хәбәрне алу белән Бубыйлар мәдрәсәдәге мөгаллимнәр һәм барча шәкертләр, бөтен эшләрен ташлап, шик уятырлык китап-кәгазьләрнең күбесен яндырып өлгерәләр. Ләкин, вакыт тарлыктан, материалларның бер өлеше юкка чыкмый кала һәм охранка кулына эләгә. Охранкага Бубыйларны патша хөкүмәтенә зарарлы фикерләр таратуда һәм башка шундый «гөнаһларда» гаепләргә шул кадәресе дә җитеп кала.

Татар дөньясында бик зур яңгыраш тапкан вакыйгада катнашучы кешенең исемен оныту гафу итмәслек хәл, дип уйлый иде Галимҗан Ибраһимов.

Кайбышев исә Бубый мәсьәләсен бик яхшы белә, ләкин аңа башкачарак карый. Шуның өчен ул:

— Кривоноговмы, Криволаповмы, аның исемен тәгъбир әйткән кебек тәкрарлап утырырга ул кадәр зур сәбәп юк дип уйлыйм мин. Просто дусты Габдулла Бубинский берәр бәла-казага очрамасын дип чапкан ул Бубыйга. Ниндидер сәяси идея аркасында дип уйлыйсыңмы әллә? — Бубинскийларның үзләре дә, в конце концов, берәр файдалы нәтиҗә чыгара алмадылар. Ничә елга крепостька утырттылар. Татар халкына әллә ни хәтле яңадан-яңа изү-кысулар тудырдылар. Тентүләр, төрмәләр...

Кайбышевка фикерен әйтеп бетерергә ирек бирмичә, Галимҗан Ибраһимов кулын селекте. Аның кәефе нык кырылган иде. «Бүген бу кеше белән сөйләшерлек түгел. Моңа нидер булган. Әллә, чыннан да, фикере шундый кискен рәвештә үзгәрдеме икән?» — дигән уйлар белән саубуллашты да, Хәлләненең адресын алырга да онытып, ишеккә таба атлады.

## Киев белән танышу

Поезд Киевка килеп җиткәндә, көзге моңсу кояш баерга әле иртә булса да, һава салкынча иде. Мәскәү поезды килгән чакларда вок-

залга чыгып, юлчыларны сәер итеп, перрон буйлап арлы-бирле йөрү гадәте монда да бар икән.

Халык арасында европача киенгән, калфаклы татар хатын-кызлары да күренгәлиләр. Алар белән янәшә, шулай ук нәкъ «а ля франс» киенгән, мыекларын фабрылап, борып куйган, кулларында трость уйнаткан ирләре горурланып атлыйлар. Йөрешен акрынайта барган поездның тәрәзәләреннән күзен алмыйча перронда Каюм да басып тора. Алтынчы вагон тәрәзәсеннән карап барган Галимҗанны күрде бугай, шуннан калышмаска тырышып, ашыга-ашыга атлады.

Поезд туктау белән, кулына зур чемодан тоткан Галимҗан Ибраһимов вагон баскычыннан сикереп төште дә Каюмга таба юнәлде. Ә дусты исәнләшергә дә онытып:

— Сине танырлык түгел бит, Галимҗан! Бер карасаң, Шаляпинга охшыйсың, тагын бер карасаң — Горькийның нәкъ үз генәсе! — дип каршылады.

Галимҗанның Казандагы кыек якалы кызыл сатин күлмәге белән күпне күргән пиджагы, кара төсен югалтып, җирәнгә әйләнә башлаган итекләре белән искелектән читләре салынып торган эшләпәсе урынына хәзер аның өстендә арыслан сыны итеп ясалган төймә белән каптырылган яңа плащ-накидка, аягында яңа штиблетлар, башында әле генә магазиннан чыккан эшләпә!

Каюмның чиктән тыш гаҗәпләнүен күргән Галимҗан сул кулы белән иптәшен кочаклап алды:

— Бик исең китмәсен, дус! Плащ белән эшләпәне Кәрим Тинчуриннан әҗәткә алып тордым. Пиджак — Садрый Җәләлнеке. Калганнарын синнән бурычка алган акчага үзем ипләдем!

Дуслар, юл әйберләрен күтәреп, баскан урыннарыннан кузгалдылар. Ләкин алар ашыкмый иде. Каршыларына ара-тирә очраган яшь матур ханымнарның артыннан карап калалар да әкрен генә тагын алга атлыйлар.

Галимҗан Ибраһимов кызыксынуын яшермәде:

— Киевтә менә шулай европалылар кебек качмыйча, иркенләп йөри торган татар хатын-кызлары бардыр дип уйламый идем!

— Күрәсең бит, бар икән шул,— дип кенә җавап бирде Каюм,— син юл кешесе, ачыккансыңдыр. Ресторанга кереп, хуҗаларның ашсуларын татып карарга уйламыйсыңмы? — дип сорады.

Киевкә якынлашкан саен яшеллеге арта барган матур юл күренешләрен күзәтә-күзәтә, Галимҗан ашау-эчүне оныткан иде. Иптәшенең тәкъдимен ишеткәч кенә ачыкканын тойды.

Вокзалның беренче класслы ресторанына кереп утырулары белән ак тастымалны беләгенә элгән официант болар янына килеп басты, егетләрнең заказларын кабул итеп алгач, башын иеп, татарча:

— Каюм абзый, аш янына акнымы, кызылнымы китерием? — дип сорады.

— Һәрвакыттагыча,— дип Каюм кыска гына җавап биргәч, официант тагын башын иде һәм тиз генә әйләнеп килеп, алларына лимонад шешәсе белән ике фужер китереп утыртты.

— Рюмкалар китермәдем, лимонадны фужерлардан эчәләр бит! — диде ул, хәйләле елмаеп.

— Бик яхшы иткәнсез! — дип, Каюм шешәне кулына алды. Шул арада яннарына студент тужуркасы кигән бер яшь егет килеп туктады. Аны күрү белән Каюм шешәне өстәлгә кире куйды һәм, урыныннан торып, иптәше тарафына борылды:

— Танышыгыз! Бу — студент Ибраһим Максудов. Сездән татар теле белән әдәбияттан дәрес алачак шәкертләрегезнең берсе.

Тәкъдим иткән урындыкка утыргач, егет Галимҗан Ибраһимовка карап:

— Поезд килгән вакытта вокзалга төшеп, сезне каршы алмавым өчен гафу итүегезне үтенәм. Көтелмәгәндә бик ашыгыч бер эш чыгып

калды,— дип, тагын бер тапкыр башын иеп алды. Студент озак утырмады.

— Әнкәй белән әткәй Галимҗан әфәнде белән сезне, Каюм абый, бүген кич сәгать җидегә кунакка чакырдылар,— дип, өстенә алган йомышын үтәгәч, үзеннән олы кешеләрнең сөхбәтенә[1] комачау булмас өчен:

— Миңа рөхсәт итегез! — дип, урыныннан кузгалды.

Максудов китү белән Каюм янадан шешә белән фужерларга тотынды. Иптәшенең бу хәрәкәтен күргәч, Галимҗанның студент егет килер алдыннан әйтергә теләгән сүзләре исенә төште.

— Бу агай-эне аракыны нишләп шулай яшереп китерде? Бераз төшергәләп алу әллә монда зур гаеп саналамы?

Каюм, аның фикерен раслап, башын селекте:

— Әйе, шулайрак,— диде ул.— Әле үткән кышны гына бер укытучыны шул «ак» һәм «кызыл» белән мавыкканы өчен кудылар. Мондагы агай-энеләр, тыштан караганда нәкъ джентельмен кебек күренсәләр дә, кешене шул «төшереп алу» кебек эшләрне ярату-яратмауларына карап бәялиләр. Әгәр монда ныклап урнашырга, тамыр җибәрергә теләсәң, бу тарафтан бик сак булырга туры килер.

Ашап-эчеп алгач, яңа мөгаллим өчен алдан әзерләнеп куелган фатирга киттеләр.

Бүлмә зур, өч тәрәзәле, якты икән. Җиһазы да әйбәт кенә. Бөтен кирәк нәрсәләр бар: урын-җире белән кровать, язу өстәле, йомшак урындыклар, диван, этажерка... «Галия»дә укыган чагыннан башлап Киевкә килгәнче Галимҗан Ибраһимовка төрле фатирларда торырга туры килде. Ләкин ул һәрвакыт арзанлысын табарга тырыша иде. Шуның өчен моңа кадәр яшәгән фатирлары бик ярлы, шыксыз булалар иде. Хәзер шундый иркен, якты, җиһазлы бүлмәне күргәч, аның йөзе ачылып китте.

— Монда рәхәтләнеп укырга да, язарга да мөмкин! Үзе вокзалга да якын икән, ресторанга ашарга йөрү дә вакытны күп алмас,— дип, ул үзенең бик канәгать булуын белдереп куйды.

— Кара әле, монда кием шкафы да бар икән,— дип, ишек янындагы гардеробны ачып җибәрде. Өстендәге плащ белән башындагы эшләпәсен шкафка элеп куйды. Каюмга карап: «Син дә өстеңне сал»,— диде. Үзе чемоданын күтәреп, бүлмә уртасындагы өстәл өстенә куйды. Моның эченнән нәрсә чыгар икән, дигән кебек, Каюм иптәше янына килеп басты. Галимҗан исә бүлмәне тагын бер мәртәбә күздән кичерде дә:

— Ни дисәң дә, хуҗалар игътибарлы кешеләргә охшыйлар. Әнә махсус язу өстәле генә түгел, этажерка куйдырырга да онытмаганнар,— дип, чемоданын ачты.

Галимҗан, иң өстәге әйберләрен читкә алып куйгач, чемодандагы китапларын этажеркага тезә башлады.

— Моның авырлыгына карап, эченә таш тутырдыңмы әллә, дип уйлаган идем!

— Син дус, көлмә! Монда үзеңә дә кирәк нәрсә табылуы ихтимал, мисал өчен менә бу! — дип, Ибраһимов иптәшенең кулына бер китап тоттырды.

Каюм куанычыннан:

«Татар сарыфы»! — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.— Әллә чыннан да миңа бирәсеңме?

— Махсус синең өчен алып килдем,— дигән җавапны ишеткәч, Каюм китапны күкрәгенә кысты.

— Татар арасыннан бик еракта яшәвем сәбәпле, бу китапны кулыма төшерә алмаган идем. Бик тиз сатылып беткән. Зурдан да зур рәхмәт сиңа! Биргәнең өчен генә түгел, шундый кирәкле китапны язганың өчен дә, дус! — диде.

---

[1] Сөхбәт — әңгәмә.

— Син башта китапның эчтәлеге белән таныш, соңыннан кирәк тапсаң мәдхия укырсың,— дип, Галимҗан Каюмның мактауларын туктатырга уйлады, ләкин иптәше аның сүзләренә колак та салмады.

— Синең бер мәкаләңдә әйткән сүзләрең күңелемә сеңеп калган. «Без — татарлар,ана телебез — татар теле, әдәбиятыбыз — татар әдәбияты, мәдәниятебез дә — татар мәдәнияте булачак» — дип язган идең. Шуның өчен дә без, ана телебезнең нигезендә яткан хосусиятләрен яхшы белергә тиешбез. Ансыз әдәбиятыбызны да, мәдәниятебезне дә үстерә алмаячакбыз. Китабыңны моңа кадәр кулыма төшерә алмасам да, аның турында үзем кебек мөгаллимнәрдән бик күп ишеткәнем бар. Мактап бетерә алмыйлар. Татар теленең рухын, аның табигый хосусиятләрен соңына кадәр аңлый, төзелешләре бөтенләй башка булган гарәп, урыс яки башка телләрнең грамматика кагыйдәләрен икътибас[1] итәргә тырышмый, диләр.

Иптәшенең сүзен бүлеп, Галимҗан Ибраһимов:

— Ана теле укытучылары авызыннан шундый сүзләр ишетү, әлбәттә, бик күңелле. Әгәр бу хезмәтем аларның мөкатдәс эшләренә ярдәм итә, файда бирә торган булса, бик шатмын,— диде һәм, күңелле бер нәрсә исенә төшкән кебек булып көлеп җибәрде дә, сүзен дәвам итте: — Минем үземнең шәхси тормышым өчен дә бу китапның көтелмәгән бер әһәмияте булды. Мәдрәсәне ташлап, хикәяләр яза башлавыма әткәй бик каршы иде. «Мин сезне юк-бар әкиятләр язып, шамакайланып йөрсеннәр дип укытмадым, халкыбызга мәгърифәт нурын чәчеп, укымышлы кешеләр тәрбия итәрсез дип хыяллана идем»,— дип рәнҗи торган иде. «Татар сарыфы» чыккач, аның миңа булган мөнәсәбәте бөтенләй үзгәрде. Фән, гыйлем, белем алдында әткәй һәрвакыт сәҗдә кыла иде.

Каюм нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан иде, иптәше кулын күтәреп аны туктатты. Үзе, каяндыр, башка бер бүлмәдән ишетелгән сәгать сугуын тыңлап торды.

— Ишетәсеңме, сәгать бишне сукты. Тизрәк бит-кулны юып, өсбашны тазартып чыгып китәргә дә вакыт җитә. Юлда парикмахерга кереп, чәчне-мыекны төзәткәләгәнче, вакыт җидегә якынлашыр. Беренче көннән үк әдәпсезлек күрсәтеп, үзебезне көттермик,— диде. Бушаган чемоданын гардероб башына күтәреп куйганнан соң, язу өстәле янына килеп утырды. Каюмга таба борылып:

— Әйдә, иртәгәге көннең планы турында уйлашыйк әле. Син Казатингә кайчан китәргә җыенасың? — дип сорады.

— Якшәмбе көн кичен. Бүген җомга. Син дүшәмбе көннән укыта башларга тиеш. Димәк, икебезнең дә буш көнебез бар. Чыгып, шәһәрнең атаклы урыннарын карап йөрергә мөмкин булыр.

— Менә бу шәп фикер!

Алар иртәгә кая барачаклары, шәһәрнең кайсы урамнарын, нинди урыннарын карап йөриселәре турында сөйләшкәч, җыенып чыгып киттеләр.

* * *

Киев тимер юлларындагы поездларда һәм вокзалның үзендә рестораннар тотучы Габдулла Максудов шәһәрнең иң бай татарларыннан санала иде.

Максудов, еллар буе рус һәм украин байлары белән аралашып яшәгәнлектән, тормыш-көнкүреш хәлләре дә аларныкына охшап тора. Өй җиһазлары, гаиләдәге гореф-гадәтләр карап торганда тәмам европача, хәтта аристократларча дип әйтергә дә мөмкин иде.

Ишектән килеп керүгә, Галимҗан белән Каюмны кара фрак кигән лакей каршылады. Егетләрнең киемнәрен салдыргач, кунак бүлмәсенең ишеген ачып җибәрде дә:

— Галимҗан әфәнде Ибраһимов һәм Каюм әфәнде Мостакаев! —

---

[1] Икътибас — отып алу, күчереп алу.

дип игълан иткәннән соң, читкә тайпылып, кунакларга юл бирде.

Өй хуҗасы Габдулла әфәнде Максудов мәһабәт озын буйлы, юантык гәүдәле, алтмышлар тирәсендәге кеше икән. Ул ачык чырай белән егетләргә каршы атлады. Аның түгәрәк йөзендә ягымлы елмаю уйнаса да, кысыграк күзләре Галимҗанны, сынап, баштанаяк дикъкать белән карап чыктылар. Яшь язучының кыяфәте аңа ошаганы сизелде. Күз карашы йомшарган, чырае тагы да ачыла төшкән кебек булды.

Ибраһимовның килеш-килбәте кешене ихтыярсыз үзенә җәлеп итәрлек иде: ул вакыттагы шагыйрьләр, рәссамнар, гомумән, эстетлар арасында кабул ителгән мода буенча артка таралган озын, куе кара-коңгырт чәч, калын кашлар астыннан кызыксынулы дикъкать белән карап торган якты коңгырт күзләр, өстендә килешле кара костюм, кар кебек ак, крахмалланган манишка һәм манжетлар... Галимҗан гадәттә шулай киенеп өйрәнмәгән булса да, үзен иркен тота, өй хуҗаларының зәвыгына ошаганын сизгәч, Тинчурин дусның өс-баш турында биргән киңәшләре ярады әле, дип эченнән көлемсерәп тә куйды.

— Сезнең Киевкә килергә риза булуыгыздан мин бик мәмнүн,— диде Габдулла Максудов, Галимҗан Ибраһимовның кулын кысып.— Без Казаннан, татарлар арасыннан еракта яшәсәк тә, татар икәнебезне онытмыйбыз. Халкыбызның уңышларын, тәрәккыятен ишеткән саен чын күңелдән куанабыз!

— Атказанган галим һәм әдипне безнең балаларыбызны укытырга ризалатканыгыз өчен сезгә, Каюм әфәнде, бик зур рәхмәт! — дип, хуҗа Каюмның да кулын кысып өлгерде.

Бу мактауларга каршы Галимҗан Ибраһимов:

— Ана телебезгә һәм әдәбиятыбызга булган мәхәббәтемне шәкертләрнең дә күңелләренә сала алсам, бик шат булырмын,— дип җавап бирергә кирәк тапты.

Кунагын култыклап алган Габдулла әфәнде:

— Хәләле җефтем Галия ханым белән таныштырырга рөхсәт итегез! — дип, аны камин янында басып торган ачык йөзле, симез гәүдәле хатын янына алып килде. Илле яшьләр тирәсендәге ханым, бармак саен алтын йөзекләр кигән йомшак кулын Галимҗанга сузды. Галимҗан, башын иеп, ханымның кулын кысты да бер адым артка чигенде. Хуҗа хатынның йөзендә аптырау галәмәте чагылып киткән сыман булды, чөнки ул, кунак кеше джентельменнарча аның кулын үбәр, дип уйлаган иде. Аптыравын сиздермәс өчен алтын чылбырга таккан пенснесын, озын ефәк күлмәгенең якасын төзәтеп алды. Габдулла әфәнде, хатынының уңайсызлануын күрмәгәнгә салышып, Каюмга таба борылды:

— Сез Галия ханым белән дә, башкалар белән дә таныш. Шуның өчен Галимҗан әфәндене таныштырырга рөхсәт итегез.

Өй хуҗасы Галимҗан Ибраһимовны иң элек игезәкләр кебек берберсенә охшаган ике туташ янына алып барды.

— Болар минем кызларым. Бусы — Асия туташ, ә бусы — Суфия туташ.

Әтиләре исемнәрен әйтү белән, кызлар утырган урыннарыннан торып, бик нәзәкатьле итеп реверанс ясадылар. Галимҗан, гөл чәчәкләре кебек сөйкемле бу яшь кызларга туры карарга уңайсызланып, күзләрен түбән төшерде һәм башын ию белән чикләнде. Аның шулай тотнаклылык күрсәтүе Габдулла әфәндегә бик ошады. Кәефе шәп чакларындагы гадәте буенча, чал керә башлаган мыегын борып куйды.

— Инде шәкертләрегез белән танышырга вакыт житте,— дип, Галимҗанны ломбер өстәле тирәсендә утырган яшьләр янына алып китте. «Чәчәкләр флирты» дигән уенны уйнап утырган яшьләр, мөгаллимнәре якынлашканын күреп, кулларындагы катыргы кәгазьләрен ломбер өстәле өстенә куйдылар да, аякка бастылар. Габдулла әфәнде берәмберәм кызларның исемнәрен атый башлады:

— Менә бу — Гадилә туташ, гимназиянең алтынчы сыйныфында

укый, ә бусы — Зөһрә туташ, Гадилә туташның сыйныфдашы. Бусы исә — минем кызым Нәгыймә туташ, бишенче класс гимназисткасы.

Исемнәре әйтелгән бере, яңа укытучылары алдында түбәнчелек белән реверанс ясадылар, ә Галимҗан Ибраһимов аларны башын иеп сәламләде.

Кунак бүлмәсендәге студент һәм гимназистларның барысы белән дә таныштырганнан соң, Габдулла әфәнде Ибраһимовны янадан камин янына алып килде.

— Рәхим итегез! — дип, Галия ханым янындагы креслоны күрсәтте. Үзе хатынының икенче ягындагы, Каюм белән янәшә креслога утырды. Галия ханым, пенснесын киеп, Галимҗанга карады һәм әңгәмәне башлап җибәрү нияте белән:

— Сезнең электә Киевкә килгәнегез бармы? — дип сорады.

— Минем бирегә беренче килүем,— диде Галимҗан Ибраһимов.

— О! Алай булгач, сез башта Киевнең атаклы урыннары белән танышырга тиешсез! Сезгә, һичшиксез, Киевнең театрын да зиярәт итәргә кирәк. Монда бик талантлы артистлар бар,— дип, үз тәкъдимен кертте.

Галия ханым үзен бик алдынгы, европача тәрбия алган хатын дип саный иде. Ул, гимназиянең сигезенче сыйныфына күчкән җаендә, коммерческое училищене тәмамлап, әтисе кул астында өч-дүрт ел буе ресторан тоту эшенә өйрәнеп йөргән матур егет Габдулла Максудовка гашыйк булган һәм, укуын ташлап, аңа кияүгә чыккан иде. Гимназиядә алган тәрбиясе, рус гимназисткаларының өйләрендә күргәннәре һәм Чарскаяның институткалар турында язган романнарын кыз чагында йотылып укулары тәэсирендә ул үзенең өендәге низам-интизамны, өс-башны да нәкъ шулай итәргә тырыша иде. Габдулла әфәнде дә үзен дөнья күргән, тәраккый пәрвәр кеше дип саный, чөнки аңа чит илләрдә ресторан эшләренең куелышы белән танышыр өчен Париж, Лондон кебек шәһәрләргә баргаларга туры килгәли. Рус байлары алдында да артта калган мәдәниятсез татар булып күренәсе килми.

— Бүген вокзалда мин берничә татар ханымнарын күрдем. Башларында калфаклары булмаса, аларны рус, ханымнарыннан аерырлык түгел иде,— дип Галимҗан сүз башлаган иде, Габдулла әфәнде тотнаксызланып кунагының сүзен бүлдерде:

— Алар бит тышкы, ясалма кыяфәт белән генә күзгә күренергә тырышалар, ә үзләренең аякларыннан тотып селексәң, авызларыннан әлиф хәрефе дә төшмәс!

Галия ханым иренең сүзләрен эләктереп алды:

— Хәер, укый белгән кешеләргә дә монда корьән, әфтияктән башка укырлык китаплар юк. Казанда төрле кызыклы, гыйбрәтле китаплар, хикәяләр басыла дигән хәбәрне алу белән хат язып соратабыз, ләкин сатылып бетте дигән җавабтан башка бер нәрсә дә килми. Тик «Тәрҗеман», «Вакыт», «Йолдыз» газеталарын укып кына мөселман дөньясында нинди яңалыклар барлыгын белеп торабыз. Менә шул газеталар аркылы гына Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов дигән әдипләребез барлыгын беләбез...

— Соңгы бер-ике ел эчендә генә дә Галимҗан әфәнде Ибраһимов әдәби яктан да, мәгънә ягыннан да бик матур һәм әһәмиятле булган «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Уты сүнгән җәһәннәм» әсәрләрен язып бастырды, әле күптән түгел генә «Яшь йөрәкләр» дигән зур роман тәмамлады. Бу әсәр күләме белән дә, мөндәриҗәсе белән дә рус романнарыннан һич калышырлык түгел! — дип, Каюм да сүзгә кушылды.

Галия ханым соң дәрәҗәдә кызыксынуын күрсәтеп; Галимҗанга карады:

— О-о-о! — дип сузды ул.— Шулай ук бездә дә романнар бармы икәнни? Сезнең китапларны табып укыйсы иде! — диде дә, анна ры иренә

мөрәҗәгать итте.— Бу китапны Казаннан тизрәк соратып алдырырга кирәк, югыйсә сатылып бетәр дә тагын коры калырбыз!

Галимҗан Ибраһимов Галия ханымга карап:

— Казаннан соратырга бераз иртәрәк. Китап хәзергә типографиядә әле. Басылып чыгуы белән кулыма төшкән беренче нөсхәсен мин үзем сезгә бүләк итәрмен,— диде.

Галия ханым рәхмәтен белдереп өлгермәде, эчке ишекләрнең берсе ачылды. Өстенә кара фрак, ак манишка, башына кара хәтфә түбәтәен кигән лакей күренде.

— Аш табында! — дип белдерде ул.

Хуҗа ханым урыныннан кузгалды, кунакларына мөрәҗәгать итеп:

— Табынга рәхим итүегезне үтенәм! — дигәннән соң, иренең кулына тотынып, аш бүлмәсенә юнәлде. Башкалар да, аксөякләр җәмгыятендә кабул ителгән гадәткә ияреп, пар-пар булып аларның артыннан киттеләр.

Галимҗан Ибраһимовның күзләрендә елмаю чаткылары уйнап алды. Аның башына: «Габдулла әфәнде чын-чынлап күз буарга исәпли, ахры»,— дигән уй килде.

* * *

Икенче көнне дуслар шәһәр белән танышыр өчен иртән үк урамга чыктылар. Йөри торгач, бөтен квартал буена сузылган шыксыз бер бина алдына килеп туктадылар.

— Шәһәр уртасында нинди килбәтсез казарма бу тагын?

— Бу әфәндем хәзрәтләре, казарма түгел, университет була!

Галимҗан хәйран калды:

— Я жандармерия, я казарма дип уйлаган идем мин аны. Фән сараена охшаган бер җире дә юк бит моның! — дигәннән соң кыюсыз гына: — Әллә эчкә кереп карыйбызмы? — диде.

Каюм да икеләнгән сыман күренде. Галимҗанга баштанаяк күз йөртеп чыкты да:

— Өстеңдәге накидкаң, башыңдагы эшләпәң белән университет мөхитенә якын кешеләргә охшыйсың. Я рәссам, я мәшһүр шагыйрь дип әйтергә була. Ә минем иске, уңган пальтом белән башымдагы бүрегем...

Фән сараеның бусагасыннан гына булса да атлап керәсе килә иде Галимҗанның. Шуның өчен дустына сүзен төгәлләргә дә ирек бирмәде:

— Кием-салымның ул кадәр әһәмияте булмастыр. Эшлекле кыяфәт белән, уңга-сулга карамастан атласаң, минемчә, берәү дә туктатмас. Әйдә, шулай итеп карыйк!

Бәхеткә күрә, аларны берәү дә туктатмады. Укалы тасма белән бизәлгән кара мундир киеп ишек янында утырган көрәк сакаллы карт швейцар аларга хәтта күтәрелеп тә карамады. Коридор да буш дип әйтерлек. Ара-тирә генә кулларына язулы кәгазьләр тоткан кешеләр бер ишектән чыгып, икенчесенә кереп югала торалар.

— Лекцияләр вакытына туры килгәнебез ахры. Әнә теге ике студенттан башка кеше күренми,— диде Галимҗан үс киемнәрен сала торган җирдәге барьерга таянган килеш һәм сөйләшеп торган студентларның берсенә игътибар белән карады. Ул Галимҗанның танышы булып чыкты.

— Университет бусагасыннан атлап кергә сине очратырмын дип өмет итмәгән идем, Андрей! — дип, Галимҗан, елмаеп, студентка кулын сузды.

— Мин бит сине танымый торам. Бөтенләй купшыланып киткәнсең! — дип, студент та Галимҗанның кулын кысты.— Син нишләп бу якларга килеп чыктың? Уфада ни хәлләр бар?

— Соңгы вакытларда мин Казанда идем, ә Киевкә килгәнемә әле икенче генә көн. Менә бу иптәшем Каюм Мостакаев миңа монда бик яхшы эш табып бирде. Таныш булыгыз!

Студент Каюмга кулын сузып:

— Николай Андреев,— диде.

Галимҗан гаҗәпләнеп аңа карады, ләкин бер сүз дә әйтмәде. Аның ни уйлаганын Николай сүзсез дә аңлады. Көлемсерәп:

— Уфада үз исемем белән йөрү ярамый иде, фамилияне кушамат итеп алырга туры килде. Ул вакытта шулай кирәк иде,— диде.

— Аңлашылды! — дип, Галимҗан яннарында эндәшми басып торган коңгырт-сары чәчле, түгәрәк сакаллы студентка карап алды. Күзләрен тагын Николайга күчерде. Бу карашы белән ул, иптәшең белән нигә таныштырмыйсың, дип әйтергә теләгән кебек булды. Николай бу юлы да Галимҗанның теләген сүзсез аңлады.

— Университетларда очрый торган һәм студентлар арасында бик ихтирам казанган «мәңгелек студент»ларның берсе — Агаш була бу. Ә болар Уфалы якташым Галимҗан Ибраһимов белән аның дусты Мостакаев,— дип таныштырды да Галимҗаннан:

— Университетка нинди йомыш белән килеп чыктың? — дип сорады.

— Университетның бинасын күргәч, эченә керми түзә алмадым. Безнең кебекләргә монда белем алу насыйп булмас, ичмасам үткәндә булса да кереп карап чыгыйк, дидем.

— Якташыма аудиторияләрне күрсәтикме әллә? Син кая да булса ашыкмыйсыңмы? — дип, Андреев Агашка таба борылды.

— Сәгать җиделәргә кадәр ашыгырлык бер эшем дә юк,— диде Агаш.

— Алай булса, вакытны бушка үткәрмик. Башта бер-ике аудиторияне күрсәтик тә, аннары китапханәгә керербез. Иң ахырда актлар залын карап чыгарбыз.

Егетләр икесе бер авыздан:

— Бик яхшы! — дип әйтеп өлгермәделәр, кыңгырау шалтырады.

Бүлмәләрдән шаулап, гөрләп, көлешеп, шаярып студентлар чыга башладылар.

— Тәнәфес вакытыннан файдаланып, бер-ике аудиторияне карап чыгыйк. Тизрәк өсләрегезне салыгыз да, киттек! — дип ашыктыра башлады Николай.

Университетның тышкы күренеше Галимҗанга ошамаса да, аудиторияләрнең зурлыгы, яктылыгы, профессорлар өчен махсус эшләнгән кафедралар, бөтен стенаны биләп алган кара тактадагы саннар, сызымнар, күңелдә тантаналы хис уята торган бик зур һәм мәһабәт актлар залы Галимҗанга да, Каюмга да тирән тәэсир иттеләр.

— Мин хәзер лекциягә керәм. Бүгенгә җитеп торыр. Вакыт табып тагын бер килерсез әле. Шунда геология факультетының да, табигать фәннәренең дә музейларын карарбыз,— диде Николай.

Студентлар белән тагын кайчан, кайда күрешәчәкләре турында килешеп саубуллашканнан соң, урамга чыктылар да тротуарга басып, университетка карап тордылар. Ниһаять, Галимҗан:

— Каюм, син ничек уйлыйсың, бу гыйлем-фән михрабына үрмәләп булырмы, юкмы безгә? Бу бәхеткә ирешә алырбызмы икән, әллә явыз язмыш безне аяктан егып чигендерерме? — диде.

— Белмим, Галимҗан, белмим шул, дус! Әмма бу йортка тулы хокуклы студент булып керү — гаҗәп зур бәхет булыр иде!

Күңелсез уйларыннан котылырга теләгәндәй, Галимҗан башын селкеп алды:

— Хәтереңдәме: «Чуден Днепр при тихой погоде» дип башланган мәдхияне? Бүген нәкъ шундый тыныч һава. Гоголь үзенең көчле каләме белән шагыйранә тасвир иткән шул Днепрны барып карыйк әле!

— Алай булгач, безнең юл бу якка,— дип, Каюм Галимҗанны Владимирский паркка алып китте.

Дуслар текә яр читенә үк басып, түбәндә җәелеп яткан Днепрга карап тордылар. Галимҗан үкенечле тавыш белән:

— Бу елганың бусагалары бик күп булырга тиеш. Кызганычка каршы, монда берсе генә дә күренми,— диде.

— Ул бусагалар Киевтән түбәнрәк урында,— диде Каюм.— Күпме еллар шушы якларда хезмәт итеп, минем үземнең дә аларны күргәнем юк әле.

— Ул якларга якын араларда барып булмастыр. Әмма киләсе җәйдә аларны, әлбәттә, барып карарга кирәк! — дигәннән соң Галимҗан янадан алга атлады. Паркның икенче очына барып җиткәннәр икән. Каюм уң яктагы урамны күрсәтеп:

— Монысын Лавровский тыкрык диләр. Шушы юл белән китсәк, Киевнең мәшһүр Печора лаврасының капкасы алдына килеп чыгарбыз,— диде.

Капканы ачып керүгә, аларны типсә тимер өзәрдәй зур, таза гәүдәле, кып-кызыл чырайлы, урта яшьләрдәге монах каршы алды. Ут кабызып, егетләрнең кулына шәм тоттырды да, тар коридор буйлап җир астына алып китте. Ләкин дуслар Лавраның бөтен хикмәтләрен күреп бетерә алмадылар. Тар, караңгы коридорның ике ягындагы кечкенә хөҗрәләрнең берсе янына килеп туктау белән, монах сөйли башлады:

— Бу, әфәндем хәзрәтләре, изге Иннокентий атаның мәете. Сукырларны күзле итү, бала тапмаган хатыннарны бала таптыру кебек могҗизалары белән аллаһе тәгалә каршында бик зур савап казанган. Шуның өчен хода рәхмәте белән череми, бозылмый, бу көнгәчә таза булып ята. Ләкин табутларга кулларыгыз белән орына күрмәгез! Зур гөнаһлы булырсыз!

Монах симез иреннәрен бүлтәйтеп сөйләп торган арада Галимҗан Ибраһимов табут эченә кулын тыгып, капшанып та өлгергән икән:

— Здесь ведь одна труха и кости! — дип, әле генә ишеткәннәрен ялганга чыгарды.

Башта монах аптыравыннан телсез калды. Соңыннан исен җыеп:

— Басурманнар!! Мин боларны адәм дип уйласам, болар динсез, мәлгунь басурманнар икән! Аллаһ тәгалә җәзагызны бирер әле! Этләр! Иблис калдыклары, иблис ярченнәре! — дип, сүгенә-сүгенә, егетләрнең аркаларына төрткәләп чыгарды да артларыннан капканы шап итеп ябып куйды. Җир өстенә чыккач, Каюм җилкәсеннән авыр йөк төшкән сыман авыр сулап дустына карады.

— Әмма үзең тәвәккәл кеше дә соң, Галимҗан! Монда сөяк белән кибәктән башка бер нәрсә дә юк, дип әйттең дә куйдың! Ярый әле җинел котылдык. Мондый хәлләрдә монахлар кешеләрне ераграк берәр почмакка алып китеп, аннарын югалтканчы кыйныйлар, дип ишеткәнем бар. Бәхетебез бар икән, бу монах бик көчле күренсә дә, кулларына ирек бирмәде.

Галимҗан иңбашларын җыерды:

— Кул күтәреп карасын иде! Шулай ук без, ике яшь егет, аның арт сабагын укытмас идекме әллә? Юк! Син шуны әйт, мәдәният чыганагы булган зур бер шәһәрнең уртасында шундый мәҗүсилек, шундый торгынлык, шундый вәхшилек булсын инде! Хурлык бит бу! Без татарларда шул ук хәл. Мондый фанатизм учакларының эзен дә калдырмыйча җимереп, кырып ташлыйсы иде.

Изгеләрне, әүлияләрне зиярат иткәч, тәүфыйкка утырырсыңмы дип уйлаган идем, ә син һаман әүвәлге мөртәтлегеңә барасың,— дип, иптәшенең күңелсезләнеп торуын күргән Каюм шаяртып карады, ләкин Галимҗанның чырае ачылмады.

Аның күңел төшенкелеге Каюмга да күчте, ахры, ул да сүрән генә:

— Инде кая барабыз? — дип сорады.

— Бүгенгә шул җитеп торыр. Шушы җир асты караңгылыгыннан күңелем болганды! — диде Галимҗан.

Икенче көнне Каюм:

— Җир асты шәһәрчегендәге әүлияләрнең черегән сөякләрен кичә күрдек. Инде җир өстендәге тере мәетләрне барып карыйк, — дип, Галимҗанны Киев читендәге Подол дигән геттога алып китте.

— Патша законы буенча шәһәрләрдә яшәргә хокукы булмаган яһүдиләр генә түгел, монда вак-төяк белән сату итүче безнең агай-энеләр дә яши, — дип, юлда ук аңлата барды.

Шәһәрнең киң урамнарын, Крещатик[1] буендагы маһабәт таш пулатларны үтеп, Подолга кергәч күренгән кәкре-бөкре пычрак тыкрыклар җанны өшетеп җибәрде.

— Закон буенча яһүдиләргә зур калаларда яшәргә рөхсәт булмавын үзең дә беләсең бит? — дип сүз башлаган иде Каюм, Галимҗан аны бүлдерде:

— Беләм, бик яхшы беләм! Петербургта да, Мәскәүдә дә, эчке Русиянең башка зур шәһәрләрендә дә яһүдиләргә торырга рөхсәт юк. Аларга тик Белоруссия, Малоруссия, Польша шәһәрләре читендәге бистәләрдә генә яшәргә мөмкин. Ләкин бу бистәләр шундый әшәке, шундый пычрак дип башыма да китерми идем, — диде дә, бераз уйланып торгач: — Әмма, рөхсәт булмаса да, Русиянең һәр шәһәрендә, шулай ук безнең Казанда да, таш пулатларда яшәгән бай яһүдләр аз түгеллеген дә яхшы беләм. Ә монда мин байлар яшәгән бер генә таш пулатны да, менә бу хәлле кеше дип әйтерлек бер генә яһүдне дә күрмәдем.

Тагын бер-ике тыкрыкны йөреп чыкканнан соң Галимҗан Ибраһимов туктап калды.

— Җитәр, Каюм! Бу шыксыз тыкрыклар буйлап ике сәгатьтән артык йөрибез инде, ләкин кеше кыяфәтендәге нурсыз шәүләләрдән башка нәрсә дә күрмәдек. Мондый күңелсез күренешләрдән бөтенләй эчем поша башлады. Социал-демократлар бик дөрес әйтәләр: самодержавие үзенә менә шулай кабер казый икән! Әйдә, киттек моннан, дус! — дип, кайту юлына борылды.

## Яңа танышлар

Галимҗан Ибраһимовның Киевкә килгәненә бер айдан артык вакыт үткән иде. Һава инде байтак бозылган. Бүген дә көн бик боек, болытлы. Иртәдән ява башлаган көзге вак яңгыр кичкә таба туктаган сыман булды. Ләкин үзәккә үтә торган салкын җил күтәрелеп, агач ботакларындагы соңгы яфракларны өзә һәм ачу белән ярсып, җылаган тавышлар чыгарып, үткән-барганнарның битенә ыргыта.

Тышта караңгы һәм суык булса да, Ибраһимовның бүлмәсендә җылы, якты, уңайлы. Бүген аның янына күптәнге танышы — студент Хәлиулла килгән иде. Тезен тез өстенә куеп диванда утырган Галимҗан иң мөкатдәс серләрен, теләкләрен кунагына сөйли:

— Якташлык оешмасындагы студентларның үз белемнәрен арттырырга теләүләре, халык арасында аң-белем таратырга тырышулары бик яхшы, кирәкле эш. Ләкин безгә моның белән генә чикләнергә ярамый. Без революция назариясе белән коралланырга тиешбез. Шулай ук яшьләр арасында патша хөкүмәтенә каршы революцион көрәш ачу фикерен уята башларга да бурычлыбыз!

Хәлиулла гадәттән тыш дулкынланган иде. Кисәктән, урындыгы-ние белән бергә кубып, иптәшенең каршына килеп утырды да, аның тезенә сугып куйды һәм тавышын күтәрә төшеп:

— Менә бу эштә безнең якташлык оешмасыннан да уңайлы оешма юк инде! — диде. — Әгъзаларыбыз барысы да кызу канлы, яшьнәп торган егетләр. Барысы да революцион көрәшкә җаннары-тәннәре белән кушылачаклар. Монда минем шик-шөбһәм юк!

[1] Крещатик — Киевнең иң үзәк урамы.

— Белмим, белмим, — диде Галимҗан Ибраһимов башын чайкап. — Беренчедән, оешмадагы барлык егетләрнең дә революцион көрәшкә әзер булуларына шикләнәм мин. Арагызда ханнар, бәкләр, финансистлар кебек өстен катлау балалары барлыгын да онытма. Икенчедән, мин бит яшьләр арасында самодержавиегә каршы революцион көрәш фикерен уяту турында гына әйтәм. Чын мәгънәсендә революционер булыр өчен безнең үзебезнең дә әле белем һәм тәҗрибәбез җитәрлек түгел.

Хәллә дә үз фикерендә нык торганын белдереп:

— Иң әһәмиятлесе — эшне башлап җибәрү! Аннан соң ул үзе юл алып китәчәк, — дип әйтә башлаган иде, Галимҗан аңар фикерен тәмамларга бирмәде:

— Юк, дус, мондый эшне алай сабырсызланып үз агымына куярга ярамый! Бу тарафтан безгә Николай белән Агаш ярдәм итәргә булдылар... Безне якын көннәрдә бер социал-демократ белән таныштырырга тиешләр. Бу кеше үзе җитәкчелек иткән түгәрәккә безне кабул итүитмәү мәсьәләсен үзебез белән танышып сөйләшкәннән соң хәл итәчәк икән. Менә шул вакытта синең якташлык җәмгыятең турында да киңәшербез.

Хәллә тузынып китте, кызуланып, утырган урыныннан сикереп торды. Бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлады.

— Син танымаган-белмәгән, бер тапкыр да күрмәгән кешегә ышанасың, ә безнең якташлык оешмабыздан шикләнәсең, — дип кычкырды.

— Кычкырма әле! Мин чукрак түгел бит, — диде Галимҗан кырыс тавыш белән. — Хәзергә ул кеше сиңа, миңа таныш булмаса да, аны Николай белән Агаш бик яхшы беләләр. Ә Николай — күптәнге белешем һәм, аңа ышанам. Ул безгә ышанычсыз кешене тәкъдим итмәс!

Галимҗанның сүзләрен Хәллә колагына да элмәде, аның үз туксаны туксан иде.

— Оешмада һәммәсе дә алпавыт, бай балалары, имеш! Мин үзем дә мирзалар нәселеннән бит. Шуңа карап мин монархист булырга тиешме? Үткән тарихка да, бүгенге көнгә дә, күз сал әле, иң белемле, алдынгы кешеләребез шул алпавытлар, дворяннар арасыннан чыкмаганнармы?! Декабристларны гына исеңә төшер. Моннан башка Бакунин, Кропоткин, хәтта Карл Маркс үзе...

Хәлиуллага фикерен тәмамларга туры килмәде, кемдер ишекне шакылдатты.

— Рәхим итегез! — дип кычкырды Галимҗан Ибраһимов урыныннан торып.

— Менә без килеп тә җиттек! — дигән сүзләр белән Агаш күренде, ләкин бусагадан атламыйча, артыннан килгән кешегә юл бирде.

Кунаклар, студент шинельләрен салып элгечкә элгәннән соң, түргә табарак уздылар.

— Сезне таныштырырга вәгъдә иткән егет менә шул була инде. Күңелегездә ни барын, ни югын тартынмыйча сөйли аласыз, — дип, Агаш үзе белән килгән кешене күрсәтте.

Галимҗан, егеткә кул сузып, үзе белән таныштырды.

— Бик мәмнүнмен! Сезнең турыда Агаш белән Николай байтак сөйләде. Бигрәк тә Николай сезне бик күптән белә икән, — дигәннән соң гына кунак егет үзенең исемен әйтте: — Мин Зураб булам.

— Студент медик Хәлиулла Еникеев. Киевтәге мөселман студентларының якташлык җәмгыяте әгъзасы, — дип, Хәллә дә сүзгә кушылды.

— Хәзер самавыр кайный, утырышыгыз! — дип, Галимҗан Ибраһимов язу өстәле тартмасыннан колбаса, атланмай, күмәч кебек ашамлыклар чыгара башлады.

— Су тегермәнне җимерә диләр. Җылытырлык башка нәрсәң юкмы әллә?! Син ни дисең, Зураб? — дип, Агаш үзе белән килгән егеткә карады. Ләкин егет Агашның тәкъдимен кире какты:

— Син, Агаш, җитди мәсьәләләр турында сөйләшергә килүебезне онытма!

Шул арада Галимҗан кайнап торган самавырны кертеп, өстәлгә утыртты. Агаш та, Хәллә дә кыстатып тормадылар, шунда ук табынга килделәр. Зураб исә ашыкмады, язу өстәлендәге дәфтәр битенә кызыксынып карап торды.

— Агаш сезне татар язучысы дип әйткән иде. Әллә бу яза башлаган әсәрегезме?

Галимҗан Ибраһимов «әйе» дигән сүз белән генә чикләнергә теләгән иде, ләкин Зураб болай гына канәгатьләнмәде:

— Әсәрегезнең эчтәлеген кыскача гына булса да сөйләп бирә алмассызмы? — дип үтенде.

— Бу әсәрдә мин татар интеллигентының дөньяга карашы ничек үзгәрә барганын күрсәтергә телим, — дигән җавапны ишеткәч, грузин егет тагын да кызыксына төште. Шунда ук әсәрне укып чыгарга теләгән төсле, дәфтәрне кулына алып, гарәп хәрефләре белән чуарланган битләрен актара башлады.

— Язуга караганда бу — стенографиягә күбрәк ошый, — дип көлемсерәп, язманы кире куйды. — Каһарманыгызның фикерләрендәге үзгәрешләр белән мине дә таныштыра алмассызмы? — дип сорады.

Зурабның шулай җентекләп сораштырулары гади кызыксынудан гына түгеллеген Галимҗан Ибраһимов бик яхшы аңлый иде. Шуңа күрә мөмкин кадәр тулырак җавап бирергә тырышты.

— «Дустыма» дигән бу хикәянең каһарманы — татар шәкерте. Мәдрәсәдә чагында ул ислам диненең һәм дини фәлсәфәнең өстенлеген яклый. Заманның үзгәрә баруы нәтиҗәсендә, шәкертебезнең дә карашлары үзгәрә башлый. Инде ул татарлар арасында аң-белем таратучы, мәгърифәтче булырга ашкына. Бишенче елның кузгалышлары, аннары, мәдрәсәдән куылганнан соң, тормыш биргән сабаклар аны тагын да тирәнрәк уйланырга мәҗбүр итәләр. Инде ул тормышның нигезен төбетамырыннан үзгәртергә дигән фикергә килә...

— Сез кайчан сүз боткасы пешереп бетерәсез инде? Ашап туйганнан соң да иркенләп сөйләшергә мөмкин бит! — дип, Агаш Галимҗанның сүзен бүлде.

— Ник сүз боткасы булсын! Бик кызыклы хикәя икән,— дип, Зураб аш өстәле янына килеп утырды. Шулай да тагын сорау бирмичә түзә алмады:

— Каһарманыгыз тормышны ничек үзгәртергә уйлый?

Галимҗан Ибраһимов күңелсез генә елмайды. Вакытны сузар өчен, озаклап самавырдан чәй агызды. Чынаягын Зурабның алдына куйгач кына күтәрелеп карап, җавабын бирде:

— Мәсьәлә дә менә шунда шул. Әсәрнең каһарманы да, авторның үзе дә бу турыда ачык кына бернәрсә әйтә алмый. Тормышны үзгәртергә, башкача төзергә кирәклеген аңлыйлар, ләкин ничек үзгәртергә кирәклеген белмиләр.

Зураб белән Галимҗан өстәл янына килеп утыргач, Агашның теле ачылып китте:

— Күптән шулай кирәк иде! — диде ул, канәгать булып, — туңган кешегә кайнар чәй белән атланмай да бик әйбәт була икән...

Галимҗан Ибраһимов сүзне кирәк юнәлешкә борып җибәрергә теләде:

— Сәяси түгәрәк төзү өмете белән хыялланууыбыз турында Агаш та, Николай да сезгә сөйләгәннәрдер. Әгәр безне революцион көрәш назариясе белән таныштырырлык җитәкче табылса...

Хәлиулла, Галимҗанның әйтеп бетергәнен дә көтмичә, кайнарланып сүзгә кушылды:

— Сәяси түгәрәк дип кенә әйтү дөрес булмастыр. Мәсьәләне киңрәк куярга кирәк, чөнки түгәрәккә йөрүче халык күп булачак. Безнең

якташлык җәмгыятендәге мөселман студентларының гына да саны житмештән артык. Боларның күпчелеге, һичшиксез, бөтен күңелләре белән иң алдынгы революцион идеягә кушылачак! Мин аларны бик яхшы беләм! — дип, кызып, күкрәгенә дә сугып куйды.

Зураб, гаҗәпләнеп, Хәлләгә карады. Галимҗан исә иптәшенең тотнаксызлыгыннан уңайсызланып:

— Безнең Хәлиулла бик мавыгучан кеше, — диде. — Шуның өчен якташларын да артыграк мактый. Араларында ышанычлы егетләр булмас дип әйтмим, тик аларны хәрәкәткә җәлеп итү мәсьәләсендә бик ашыкмаска да кирәк дип уйлыйм.

Хәллә утырган урыныннан сикереп торды. Күз өстенә таралып төшкән озын, бөдрә чәчләрен бармаклары белән ике якка тарап җибәрде дә кунаклар килгәнче сөйләгән сүзләрен кызуланып-кызуланып кабатлады:

— Шуны да онытмаска кирәк. Оешмабызның кассасында ун меңгә якын акча бар. Моннан башка оешма әгъзаларының типография, нәшрият белән элемтәләре зур. Төрле фәнни брошюраларны русчадан тәрҗемә итеп бастырырга һәм халык арасында таратырга мөмкинлекләре бар. Мондый уңайлы очрактан файдаланып, революцион көрәш юлында әллә нихәтле эшләр эшләргә мөмкин булачак бит! Шуны уйлыйсызмы?

Хәлләнең, кулларын болгый-болгый, оратор кебек тавышын күтәреп сөйләвенә кызыксынып та, гаҗәпләнеп тә карап торган Зураб:

— Оешмагызның расланган уставы бармы? — дип сорады.

— Устав, әлбәттә, бар. Ләкин Киев губернаторы аны расламады. Шуннан соң якташлык казначее Ордубатский аны Петербургка алып китеп, раслатыр өчен Мәгариф министрлыгына тапшырды.

— Анда раcладылармы?!

— Әле җавап алганыбыз юк, ләкин расланыр дип ышанабыз!

Хәлләнең соңгы җавабын ишеткәч, Зураб уйланып торды да:

— Житмеш кеше барысы да бер фикергә килер дә, аларны тикшерми-сынамый гына сәяси көрәшчеләр арасына кабул итәргә мөмкин булыр дип ышанасызмы? Бу — бер. Икенчедән, уставыгызны Мәгариф министрлыгы раслармы, юкмы — билгесез. Димәк, оешмагыз үзе дә легаль хәлдә түгел. Шулай булгач, Галимҗан Гирфанович бик дөрес әйтә: ашыкмаска, бик сак булырга кирәк. Заманыбызның ни дәрәҗәдә авыр булганын яхшы беләсездер. Һәркөн диярлек тентүләр, зинданга ябулар. Кая карама — шунда жандарм, городовой, шымчы... Өч-дүрт кеше бер җирдә җыелганны күрделәрме, шунда ук эзәрлекләү башлыйлар. Шул сәбәптән, саклык, конспирация дигән нәрсәләрне...

Кеше сөйләгәнне тыңлый белмәгән Хәллә Зурабның да сүзен бүлде:

— Безнең төрек-татар халкы нихәтле артта калганын, никадәр кыерсытылганын, ничек изелгәнен үзегез дә яхшы беләсездер дип уйлыйм. Шуңа да карамастан, халкыбызны азатлыкка алып бару юлында файда китерерлек очрактан тыярга телисез!

Еникеевнең сүзләре Галимҗанның кәефен җибәрде. Ул ихтыярсыз татарчага күчеп:

— Син, Хәллә, уйлабрак сөйлә, авызың әйткәнне колагың ишетми, — диде һәм гафу үтенгән кыяфәт белән Зураб белән Агашка мөрәҗәгать итте:

— Хәлиулла, гадәтенчә, кызып китте. Минемчә, ул үзе дә якташлык оешмасындагы студентлардан бер селтәнүдә революционер ясарга җыенмый. Тик аларның ун мең тәңкәләреннән файдаланып, халык арасында революцион идеяне мөмкин кадәр тизрәк таратасы килә аның.

Сүзгә Агаш та кушылды:

— Син, Еникеев, конспирация кагыйдәләре белән исәпләшмичә, революцион эшләр алып барам дисең, бер ай да үтмәс, үзең дә, иптәшләрең дә Лукьяновкага[1] барып утырырсыз. Синең ваемсызлыгың

[1] Лукьяновка — Киевтәге зindан исеме.

аркасында үзең белән иптәшләрең генә түгел, сезгә беркетелгән партия әгъзасының да, аның белән элемтәдә торган башкаларның да жандармерия кулына төшү ихтималы бар.

Зураб Агашның фикерен куәтләде:

— Фәнни-популяр китапларны оешмагыз үзе дә бастырып тарата дидегез. Бу бик яхшы. Мондый эшләрне легаль юллар белән дә башкарырга мөмкин һәм ул шулай кирәк тә. Ләкин без сәяси ан-белем тарату турында сөйләшәбез, ә бу эш конспирация кагыйдәләрен бик катгый үтәүне таләп итә. Шуның өчен оешмагыздагы кешеләрнең барысын бердән сәяси түгәрәккә тарту да, аларны революцион эшкә катнаштырырга теләвегез дә ялгыш! Бу житмеш кеше арасыннан иң ышанычлы күренгәннәрен, башка вак йомышлар кушып, сынап карарга кирәк. Шундый сынаулардан соң гына сәяси түгәрәкләргә якынрак тартырга мөмкин булыр.

Иптәшләренең шулай беравыздан үгетләгәннәренә каршы әйтерлек сүз таба алмаганлыктан, Хәллә озын чәчләрен бармаклары белән тараштыргалап эндәшмичә утырды да:

— Барыгыз да миңа каршы булгач, нишлим? Әлбәттә, буйсынырга туры килә. Ярар алайса, сезнеңчә булсын, — дип, кинәт сүлпәнәйде.

— Димәк, якташлык оешмасы әгъзалары турында билгеле бер карарга килдек, — дип, Зураб икенче мәсьәләгә күчте. Бер Галимжанга, бер Хәлләгә карап алганнан соң ул: — Инде түгәрәк мәсьәләсенә килсәк, болай булыр: кайчан, кая жыелачагыбызны да, парольне дә сезгә Агаш хәбәр итәр. Беренче утырышта «Үткән йөзнең алтмышынчы елларында Грузиядә булган азатлык хәрәкәте» дигән темага докладны мин ясармын, — диде, шуннан соң Хәлләгә мөрәжәгать итеп: — Лекцияне тыңлаганнан соң самодержавиенең татар халкын гына түгел, башка милләтләрне дә изүен ачык күрерсез, — дип өстәде.

«Галия» мәдрәсәсендә укыган чагында, Дәүләт Думасына сайланган татар вәкилләрен озатырга дип, Галимжан шәкертләр белән вокзалга барган иде, шул исенә төшеп, үзенең тәкъдимен әйтергә кирәк тапты:

— Әгәр, Дәүләт Думасы кемнәргә хезмәт итәргә тиеш, ә ул чынлыкта кемнәргә хезмәт итә? дигән маузугда доклад ясалса, тагын да яхшырак булмасмы? — Шунда ук соңгы бер-ике ел буена үзен нык борчыган мәсьәләне дә әйтергә кирәк тапты: — Инородец дигәннәре кемнәр алар? Һәм бу халык кемнәр белән кушылып, кемнәргә каршы һәм ничек көрәшергә тиеш? Шул турыда сөйләшү безнең өчен кызыклы булыр иде.

— Әлбәттә, болар бик кирәкле һәм әһәмиятле темалар. Вакыты белән бу мәсьәләләр буенча да докладлар булыр, — дип жавап кайтарды Зураб.

*Ахыры бар*

## Фәннур Сафин

### Мәхәббәтнең бәхет кичендә

Бер хат булып килдем мин сиңа,
Алалмадым ләкин җавабын.
Сагыш кына идең әле син,
Хәзер — мәңгелек җан газабым...
Мин килгәндә, өйдә юк идең,
Өстәлендә — бары бер сурәт.
Анда — синең, минем яшьлегем
Карап тора иде күз төбәп.
Сагыш кына идең әле син,
Сөю көтми иде ташлама.
Мин килгәндә, өйдә юк идең,
Җан газабы шулай башлана.

❁

Син яшьлегем минем, нарасый кыз,
Без хыялда бүген күрештек.
Элеккечә — соңгы тапкыр гүя —
Күз карашлар белән үбештек.
Гаҗәпләндем: син бит һаман шул ук,—
Китмәгәнсең яшьлек ягыннан...
Ичмасам гел тигез гомер теләп
Нигә шаулый икән каеннар?!
Ә йолдызлар бишек җырын көйли,
Ала да күз кысып тын гына.
Авыл халкы моңлы җырын суза
Элеккечә сабан туенда.
Нигә шулай бар да кабатлана
Элеккечә, бәгырь яндырып?!
Киткән идем юкса, ул елларны
Үкенечле утта калдырып.
Сине искә төшерү күңелемнең
Чатырларын каерып ыргытты.
Чигәләрне утлы кыршау кысты,
Үз-үзеннән йөрәк курыкты...
...Авыл буйлап киткән идек, ярым,
Күз нурлары итеп түгеп бары
Чиксез кайнар йөрәк хисләрен.
Шундый якты, матур иде дөнья!
Ә кичләрен инде, кичләрен?!

---

*ФӘННУР САФИН (1948) — шагыйрь, «Кеше юлга чыкса», «Сез кемнәр», «Тынлык» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Яңгыравык көлү, пышылдаулар
Маныладыр шәфәкъ нурына...
Төн, менгән дә күкнең гөмбәзенә,
Зөһрә йолдызны алган кулына...
Ә тупылның озын бармаклары
Шул йолдызга таба үрелә.—
Аның белән тиңләшергә мөмкин
Әкияттәге шүрәле генә!
Көлдермәкче микән ул галәмне,
Аз-маз гына шулай кытыклап?
Бу дөньяны шатлык итәр өчен,
Юк, син, дидек, башка юлын тап!
Юк, бер генә йолдыз җитмәс диеп,
Бәхет йолдызлыгын эзләдек.
Йолдызларга нинди генә сүзләр
Пышылдамый иде күзләрең!
Ә көнләшү? Ә көнләшү синдә!
Хәтерлимсең? Минем исемдә!
Уйнап кына күрше кызыбызның
Кулып сыйпап куйган өчен дә
Киреләнеп беттең, үпкәләдең,
Читкә киттең — авыл кырына
(Шуңадырмы, инде әверелдең
Мәңгелек бер Сөю җырыма....).
Ә аннары кинәт, шаяртыпмы:
— Яле,куып тот!— дип кычкырдың.
Йөгердең син ындыр ягына таба,
Караңгыга таба, кичкырын.
Кавышкандай ике планета,
Кулларыңны кулга алганда,
«Өзеләбез!..» диеп тирбәлделәр
Йолдыз кебек кыргый алмалар...
Сүзләр генә түгел, күзләр иде
Керсез аңлашуның чарасы.
Яшералмый иде күзләр серен
Хәтта айсыз төннең карасы...
Пар аккошлар чиккән кулъяулыгың
Күкрәгемдә — җылы урында.
Без уйлап та ул чак карамадык
Ялгыз аккош булу турында.
Җанлы абагадай үрмә гөлләр
Аккошларның тирә-ягында.
Мәхәббәт тә шулай серле була
Сафтан да саф булган чагында.
Кайда соң ул гөлләр, пар аккошлар?—
Мин сагынам сезне, сагынам!
— Кайтарыгыз Бәхет йолдызымны!—
Диеп болытларга кагылам.
Йолдызларга таба кулым сузып
Сине эзләп узып барамын.
Табышмактай серле күз карашың,—
Таба алдыммы соң җавабын?
Истәлекләр белән сөйләшәм мин,
Тыңлаусызлар алар, үҗәтләр.
Мин аларның телен беләм дә бит,
Ләкин акцент миндә бик хәтәр!..
Һәм аңладым, бәгырь, соңлап белдем:
Чын мәхәббәт бездә булган ул!

...Япа-ялгыз барам...
Сагышымнан
Уянмасын берук дип авыл.
Ә бәхеттән үзебез качтык бугай,
Һәм без шуңа тиле төсседер.
Мәхәббәтнең йолдызлыгын кичкән
Адәм исә изге кешедер...

Таңда инде бары хат булып,
Бер хат булып килдем мин сиңа.—
Кулъяулыгымдагы аккошлар,
Абагадай гөлләр юксына...
Гөлләр көтә, ә син юк һаман,
Өстәлендә — бары бер сурәт.
Анда — синең, минем яшьлегем,
Йөрәк кебек яна ул дөрләп.
Йолдызларга үрләп яна ут,
Талбасмалар суга ташлана.
Житәкләшеп кайтыр юллар юк,
Жан газабы шулай башлана.
Башлана да олы юлларга,
Диңгезләргә килеп тоташа.
Сөю исән кала, бары тик
Сикереп чыга алсаң ут аша.
Үзәннәрдән йөгерә ул яшьлек
Зур калага таба, бер генәм.
Кала инде, кала уфтанып,
Кызарыплар пешкән бөрлегән.
Сагындырыр юкса барыбер
Житәкләшеп барган тар сукмак.
Бөрлегәндәй кызыл җөй булып
Жанда калыр хәтер-ярчыклар.
Нигә соң без вакыт тапмадык
Бөрлегәнне иелеп алырга?
Ник ашыктык, кая ашкындык?—
Имеш, дөнья күреп калырга!
Дөнья күрдек менә!..
Үзең юк,
Өстәлендә — бары бер сурәт.
Күзләремә карап тора ул,
Бәгыремә тула мөлдерәп.

Сагыш кына түгел инде син,
Син, бәхетем, хәзер — газабым!..
...Бер хат булып килдем мин сиңа,
Алалмадым ләкин җавабың.

Ә бәхеттән үзебез качканбыз,
Һәм без шуңа тиле төсседер...
Йолдызларын күрдек Сөюнең,
Ә андыйлар изге кешедер,—
Бәлки менә безнең ишедер?!

## Әхсән Баянов

# МӘҢГЕЛЕК БӘХӘС

ПОВЕСТЬ



Фәнүзәнең югары бәя алган күзәтүләре кешенең яшьлеген хәзерге белән чагыштырганда бермә-бер озынайту мөмкинлеген расласа да, шуның организмдагы төгәл механизмы тәҗрибәдә тәгаен ачылмаган әле. Шулай икән, эшләргә дә эшләргә, бөтен гомер буе эшләргә кирәк булачак. Бәлки бер-ике буын кеше гомере генә җитмәс тә. Әйе, җитмәү ихтималы бүгеннән соң тагы да артты. Бүгеннән соң Фәнүзә бу эштән читләшәчәк. Чөнки аның адәм балаларыннан гайрәте кайтты... Адәм баласы иң әүвәл кеше булсын икән. Шуңа ирешкәч, шул исемгә лаек икәнлеген раслагач кына, аңа яшьлек кебек гүзәл халәтне кабат бүләк итәргә мөмкин булачак. Нәҗар бу фикерне үзгәртергә һич тә мәҗбүр итә алмаячак.

Кайдандыр чишмә чылтыравы ишетелә. Яшьлек чишмәсе. Якында гына: берничә генә ел аша кулыңны сузсаң, кул җитәр кебек. Аның кайдалыгын Фәнүзә белә. Аның кайдалыгын Нәҗар белә. Кешеләргә шул чишмәнең кайда икәнлеген күрсәтмәкче иде алар. Инде ул чишмә чылтыравы бүтәннәргә тиз генә ишетелмәс. Ник дигәндә, аның чылтыравы әнә тиз генә үзгәрде дә куйды — ул нибарысы ванна бүлмәсендәге су агышына әверелде. Аңа да әле, бәлки, барча адәмнәр лаеклы дип әйтү кыендыр. Торбалардан аккан су шулай ук саф һәм изге. Ләкин ул барыбер яшьлек чишмәсе үк түгел шул, андый ук кодрәткә гади су ия түгел әле.

Гади су белән коенган гади кешегә — Нәҗарга эчке кием кертергә кирәк. Сурәткә төшереп куймасыннар. Әйеме? Башына шундый гади фикер килеп, Фәнүзәне урыныннан кузгатты. Үз тезләреңне, үз гарьлегеңне үзең кочаклап, күпме утырырга мөмкин?!

Фәнүзә, шкафтан майка һәм трусик табып, ванна бүлмәсендәге батареяларга элеп куйды. Нәҗарның үзенә борылып карамады. Чөнки аны бу кыяфәттә хатыны гына түгел, башка адәмнәр дә күргәндер сыман тоела һәм шул тойгы Фәнүзәнең йөрәген әле дә агулый бирә...

Нәҗар хаклы: агуның рәвешләре чынлап та төрле, бик күп төрле икән. Нәҗарны терелтеп кайтардылар, ә менә Фәнүзәне кем дәвалар һәм ничек итеп?

---

Дәвамы. Башы 10 санда.

Савыкты дигәч тә, Нажар әле эшкә чыгарлык хәлдә үк түгел. Ике-өч көнгә бер кабат поликлиникага барып күренергә кирәк. Авырудан гына түгел, ялгызлыктан гына да түгел, ә эшли дә, укый да алмаганнан интегергә туры килә. Шулай да аның хәле Фәнүзәнекеннән җинелрәктер.

Фәнүзә җайсызлыкны эшкә килә-килешли үк аерымачык күреп тора: кемнәрдер «күрмичә» узып китсә, кемнәрнеңдер күзләрендә кызгану — нәрсәдер беләләр, әйтмиләр генә. Ә бит шундый чак: аларның һәркайсы Фәнүзәне котларга тиеш кебек. Ни дисәң дә инкарь ителмәстәй эш башкарылган — кёше гомерендә бер генә кабат була торган нәрсә. Әмма, очрашмый карашлар, күрмиләр, танымыйлар...

Фәнүзә бүген турыдан-туры лабораториягә барып керде. Анда да шул ук хәл — унөч баш берьюлы микроскопларга иелә. Светлана белән Вәкил генә торып бастылар. Исәнләшкәндә боларның да бөтен нәрсәдән хәбәрдар икәнлеге күзгә ташланды. Урыннарыннан кубып, каршыга ук килүләренә карамастан, барыбер сизелде — ярыйсы ук төче, ясалма кыланышлар.

— Бик исән, Фәнүзә, котлыйм сине,— дип пайпылдаган булса да, Вәкил тавышында — ялган пафос.

— Әллә кайчан ук котладыгыз түгелме соң?

— Майны ботка бозмый,— дигән булып шаяртты тагын Вәкил.— Котлыйк әле, мондый җай гел генә чыгып тормас. Шулай бит, Света?

— Шулай. Котлыйм Сезне, Фәнүзә Кадыйровна, чын күңелдән.

Светаның күзләрендә — шулай ук уңайсызлану галәмәте. Шуны үзе дә сизгәнлектән, оялган кеше төсле башын ия ул.

Тиз арада тынлык урнаша. Һәр икесе пробиркалар белән булашкан-да, яки бүтән шөгыль табып, арлы-бирле йөренгән вакытта да эштән бигрәк Фәнүзә хакында уй йөртә.

Фәнүзә дә гел үзе турында уйлана. Нәрсәдер караган, күзәткән булып утырса да, колак төбендә һаман бер үк алама сүзләр...

Света бүтән көннәрдә мондый тынлыкка үзенең, сәеррәк булса да, матур һәм яңа көй шыңшуы белән ямь кертә белсә, бүген авызына су капкан диярсең. Ул да кайгыга калган.

Уйлар, уйлар, сүзләр, сүзләр...

Искеләренә бүтәннәре, яңалары өстәлә...

Башын иеп, Вәкил каядыр чыккан гына иде, Света тиз генә Фәнүзәне арттан килеп кочаклады да, шул ук җәһәтлек белән аның янына утыргач, искитмәле мөһим хәбәр җиткергәндәй тезеп китте:

— Белмәссең инде, ышаныргамы, ышанмаскамы. Нажарның романы хакында бөтен кала шаулый. Имеш, ул ниндидер кызга өйләнә икән, минем ирем шәһәрнең бөтенләй икенче читендәге заводта эшли. Шуннан ишетеп кайткан. Ә без монда янәшәдә генә берни белмичә утырабыз. Хәер, син белгәнсеңдер инде. Күптәннән башланган тарих диләр бит. Хәзер генә ишетелгәч тә...

Ишетмәгәнгә сабышырга җыенса да, Фәнүзә:

— Нәрсә ишетелде?— дип сораганын сизмичә калды.

— Ну, разводтыр инде, аннан соң...

— Кызый, син нәрсә әйткәнеңне беләсеңме?

— Нәрсә дип... Ишеткәнемне генә — тамчы да өстәмичә.

— Уфф!

— Нәрсә, ялган хәбәрме әллә?

— Ялган, ялган, ялган!

Бүтән вакыт булса, болай турыдан-туры ярып салмас, хисап бирмәс, чак кына башкачарак әйтер иде дә, тик бугазга ук килеп тыгылган агу һәм нәфрәт уйларга ирек бирми шул. Үрталүне сиздермәскә дә көч җитми кала. Кызны утырган җирендә калдырып, кечкенә савытлар алырга дигән булып, Фәнүзә салкын шкаф капкачына тотына.

Үзе генә белгән өзек-төтек көй көйләп һәм сөенечле кыяфәт белән Вәкил хәбәр китерә:

— Фәнүзә Кадыйровнаны Садир Хәкимович сагынган икән...

Бу көннәрдә Садир Хәкимович директор кабинетында утыра иде. Фәнүзә шунда керде. Ишеккә якынрак урындыкларның берсенә утырырга җыенгач, Садир Хәкимович:

— Узыгыз мондарак, курыкмагыз, мин кешегә тимим,— дип көлгән булды.— Менә шулай. Чырайдан язгансыз... Кәефегез шәптән түгел ахры димме?

— Шәптән түгел, Садир Хәкимович, киресенчә, бик начар.

— Менә монысына ышанмыйм. Юк, теләсә генә нәрсә әйтегез, ләкин монысына ышана алмыйм. Шулкадәр олы уңыштан соң, башкала кешеләре үзләре үк соклангыч эшләргә йомгак ясаганнан соң, кәеф начар була димени? Моннан да олырак шатлык була диме?

— Моннан да мөһимрәк нәрсә бар икән бит.

— Шаяртмагыз, Фәнүзә Кадыйровна. Мин ул хәтле үк беркатлы бәндә түгел.

— Беләм.

— Шуннан? Нәҗарның хәле ничек?

— Больницадан чыкты.

— Менә шәп — кайчан эшкә?

— Әле больничныйда. Операциядән соң...

— Ничек? Операция дә булдымыни? Нинди?

Фәнүзә бик тәфсилле рәвештә ире кичергән хәлләрне сөйләгәч, Садир Хәкимович чын күңеленнән кайгырган кыяфәткә керде.

— Менә инде, без бернәрсә белмибез. Янына да тәки барып булмады. Ике вазифаны берьюлы өстерәгәч, шулай була икән — кичерер инде Нәҗар.

— Садир Хәкимович, мин Нәҗарның кайсы больницада икәнен фәкать сезгә генә әйткән идем бит.

— Я, я, шуннан?

— Сез ул адресны кемгәдер биргәнсез.

— Ничек, ничек?

— Ә ул кеше күчтәнәчкә агу китергән.

— Фәнүзә Кадыйровна! Моны ничек аңларга? Чак кына вөҗдан кирәк ләбаса!

— Кирәк шул, Садир Хәкимович, бик тә кирәк.

— Мин сезне шундый да түбән уйлы кеше дип белмидер идем.

— Өйрәттеләр, Садир Хәкимович, шактый өйрәндек.

Шушы урында сүз арасына телефон чылтыравы кереп бик дөрес эшләде. Икесенә дә хәерле тоелмаган бәхәсне туктатып, башка темага күчәргә җай туды. Диссертация якланса да, бу юнәлештә тикшеренүнең чынлыкта хәзер генә башлануын һәм моннан соң тагын да ныклабрак эшкә керешергә туры киләчәге искә кабат төшерелде. Фәнүзә үзе дә шуны раслагач, гәп озакка сузылмады. Ләкин кузгалырга дигәндә, Садир Хәкимович киная белән генә елмаеп куйды да:

— Инде бер кечкенә мәсьәлә,— дип, Фәнүзәгә кабат утырырга ишарә ясады.— Нәҗар хакында. Гаиләгез турында. Сез, нәрсә, аерылышасызмыни? Дөресме шушы хәл? — Кәефе кинәт кырылган Фәнүзә, аптырап, ни әйтергә белми торган арада, тагын да катырагын өстәде.— Бөтен бүлекләр шаулый анда...

— Җитте сезгә!

Фәнүзәнең күнегелмәгәнчә җикереп эндәшүеннән Садир Хәкимович үзе курыккандай кинәт читкә тайпылып куйды. Нәкъ шушы вакытта ишек ачылды. Аннан Алсуның бик вакытлы күренгән гүзәл башы һәм ягымлы чырае Садир Хәкимовичны үгет-нәсихәт бирүдән коткарып калды.

— Нәрсә, Алсу Гаффаровна? — Беренче тапкыр Садир абзасы аңа атасы исеме белән ихтирамлы сүз кушты бугай.

— Рим Сәлихович исеменнән шалтыраттылар. Бүген сәгать биштән соң кереп чыксын әле, диделәр.

Рим Сәлихович — хәзерге вакытта барча институтлар өстеннән җитәкчелек иткән йогынтылы кеше. Аның дөньяда барлыгын бигрәк тә

бу институтта бер көнгә дә онытып тормыйлар. Чөнки Садир Хәкимович үзенең иң ихтирам иткән кешесе сыйфатында аның исемен көнгә бер генә кабат атамый торгандыр. Менә хәзер дә Алсудан шул исемне ишетүгә, кәефе күз ачып йомган арада күтәрелеп китте.

— Ярый, Фәнүзә Кадыйровна, дәвам итәрбез әле,— диде дә киенергә кереште һәм тиз арада китеп тә барды.

Зур бүлмәдә бер-берсенә охшаш ике хатын-кыз үзләре генә калды. Алсу Фәнүзәгә шул кадәр текәлеп бакты ки, әйтерсең, гомерендә беренче тапкыр күрә. Әйтерсең, Фәнүзәнең бите алама чир-махау белән капланган. Ныклап карасаң, бәлки чынлап шулайдыр әле. Фәнүзә бит үзе дә шулайрак сизә. Ә кешеләргә кызык. Кешеләргә кешене мыскыллы кызгану белән кызганырга җай чыккан икән, файдаланып калсын ул, үзенең өстенлеген тоеп рәхәтләнсен.

Аргос кешеләре үзләрен коткарган каһарманны кулларына таш, сәнәк, имән күсәкләр тотып каршылаган кебек, рәхмәтләрен шулай белдергән кебек, Фәнүзәгә каршы да аягүрә бастылар. Күсәкләр, сәнәкләр белән килләләр. Ә Фәнүзә ялгыз, бу минутта аның беркеме дә юк — әтисе дә, әнисе дә, сөйгән яры да!

«Нажар! Син! Син китердең миңа бу хурлыкны. Хыянәтең ясаган җәрәхәтләр канап тора! — дип уйлады Фәнүзә.— Синең хыянәтең мине шушы хәлгә төшерде. Шашкан күселәр көтүе кебек, бөтен каланы кимерә синең хактагы гайбәт. Алар минем җәрәхәттән тамган канны эчә, симерә бирәләр. Мин, үзем дә сизмичә, кинәт картайдым — ничә генә көн эчендә! Бер генә теләк тә калмады!»

— Син миңа әйтәсеңме бу сүзләрне, Фәнүзә Кадыйровна?

Фәнүзә кычкырып уйлаганын төшенсә дә, һич кыенсынмыйча җавап бирде.

— Әйе, мин дә ишеттем, тиздән Нажарның туе буласы, диләр. Шул туйда сезнең лабораторияләрдәге барлык бөҗәкләр, барча микроблар, җыйналып, танцага чыгачаклар икән.

Колакларын учлап, Фәнүзә ишеккә ташланды. Әмма котылырга җай юк иде. Кайсы бүлмәгә кермә, менә шушылай шуыша-шуыша, чыш-пыш йөри. Аларны таптап кына үтереп тә, бетереп тә булмый һәм булачак та түгел, агу да җиңә алмый — менә ичмасам адаптация! Кай арада җайлашканнар алар! Җитмәсә, тагын, тагын исемсез кыз! Кабердән казып алынган скелет кебек, шуның өрәге йөри — институтның бер ишегеннән икенчесенә, аннан өченчесенә, дүртенчесенә уза. Әнә ул авызын кыйшайткан да Фәнүзәнең колакларын авырттырып кычкыра:«Менә мин, менә — күрегез! Мин — Нажарның сөяркәсе! Күреп калыгыз!»

Янында гына әллә Алсу, әллә шул өрәкнең үзе. Кабат борылып, өрәккә булган нәфрәтен Фәнүзә гайбәтчеләрнең берсенә — Алсуга кайтара:

— Хуҗасына өргән эт — сафлыкка хыянәт. Мин синең күзләреңне чокып чыгарам, мин синең авызыңны, бөерләреңне алып, үзеңнән дә хәтәррәк ерткычларга ыргытам. Саклан! Сакланыгыз!

— Әләй, әләй, котырган! Фәнүзә котырган!

Арты белән акрын-акрын чигенә барып, нәрсәгәдер абынган Алсу әнә шулай дип кычкырып җибәрде.

Ары китә алмаганлыктан күзләрен коточкыч зур ачкан хәлдә диварга аркасы белән ябышып каткан кызга күз дә салмыйча, кая барганын үзе дә белештермәстән, Фәнүзә урамга ук чыгып китте: «Тиз, тизрәк, тынычрак җиргә!»

Каядыр ашыгып атлавын белде. Соңыннан ачыкланганча, аны аяклары өйгә алып кайткан икән. Өйдә беркем дә булмаганга, ишекне үзе ачып кергәч, шулай ук ашыгып чишенгәч, тиз арада тагын кушеткага менеп кунаклады һәм поликлиникадан кайткан Нажарны таныш кыяфәттә каршылады.

Ире тагын шаккатып тик тора. Беркөнгечә үк тезләрен кочаклап бөкшәйгән Фәнүзә, зур зәңгәр күзләре белән томыраеп, билгесезлеккә текәлгән. Үзе матур, үзе үлгән кеше төсле — йөзе куырылып калган.

— Нигә бөрештен, тагын нәрсә бар? — дип, хатынының чәчләреннән сыйпый-сыйпый сорарга мәҗбүр булды Нәҗар.
— Кала тулган... кимерүчеләр белән! Өр-яңа вируслар белән!
— Фәнүзә, акылыңа кил!
— Шулар, шулар эчте канымны. Йөриләр, кимерәләр, йөгерешәләр — институтның барча бүлмәләрендә, өстәлләрдә, кәгазьләр арасында, шкафларда, тәрәзә төпләрендә. Шулар аркасында мин бер көн эчендә картайдым. Алар әле дә сиздермичә генә канымны эчә. Син анда барма, син алар белән сөйләшмә. Югыйсә, сине дә харап итәчәкләр! Нәҗар! Саклап кал мине, коткар!
— Тынычлан, Фәнүзә, аңладым. Якларга, коткарырга сүз бирәм.
— Җитәр микән көчең? Сине дә бит шулар авыруга сабыштырды.
— Мин инде тереләдем.
— Ай, юк шул әле, терелеп җитмәдең шул. Ә аларны җиңәр көч тә юк. Алар инде бар дөньяны баскан.
— Ләкин көрәшергә мөмкин. Бөҗәкләргә каршы бөҗәкләр көрәшә ала.
— Ә син кеше — көчсез.
— Кеше бөҗәкләрне ашый торган бөҗәкләр чыгара ала.
— Аңладым. Басуларда корткычларга каршы микроблар көрәшә. Агуны алмаштырган микроблар. Тик бит, ул микроблар ашап бетергәч, икенче төрле бөҗәкләр барлыкка киләчәк тә, кеше тагын яңа микроблар үрчетергә мәҗбүр булачак.
— Корткычлык, күпме җайлашмасын, бездән барыбер котыла алмаячак.
— Онытма сүзләреңне.
Фәнүзә, Нәҗар күкрәгенә сыенып, тын калды.
Нәҗар аны бала йоклаткандай тирбәткәч, ул, нәкъ сабыйдай, йокыга да китте.

* * *

Нәфрәтнең әче төсе, вөҗдан газабы дип исемләнергә тиешле авыр тойгы белән берлектә, җиргә караңгы кич булып тарала. Дөньяны караңгылык баса...
Поликлиникада врач Нәҗарга рецидивтан сакланырга кирәклеген кисәтте: абсцесс яңармасын өчен, салкын тидермәскә, бүлмә җылысыннан салкынрак сыекча эчмәскә туры киләчәк. Алга-артка каранып йөрү һәм яшәү ирекне кысачак. Шулай да түзәргә мөмкин, ә түзә алмасаң, беркемне гаепләү үе тумас, вөҗдан таныч калыр. Әмма Фәнүзәнең рецидивлары Фәнүзәнең күптән түгел генә тынычлангандай тоелган күңел чирe бәйләнчек уйга әйләнә түгелме? Дингез төсле — бер дулкын юкка чыккач, икенчесе калкамыни! Шушы чир, ничек кенә гаепсез дисәк тә, Нәҗарны үз авыруыннан да яманрак газаплый, җанын сызлата, агулый лабаса — менә бусын нинди шеш дип атарга? Һәм аннан ничек котылырга мөмкин икән?
Кайдадыр ерак юлда автомобиль чаба. Каршысына... Әйе, каршысына кабан кыяфәтле Тилебаш чыга. Ул каршыга килеп басуга, автомобиль чыелдап юлдан кырыйга мәтәлә. Аның эчендә — кешеләр... Коткарырга кирәк, мөмкин кадәр тизрәк!
Тилебаш исә, дүрт аягының кайда икәнен дә онытып, урман чытырманлыгына томырыла. Еракка — җинаятеннән мөмкин кадәр ерагракка! Әмән абзый кулыннан ычкынган, кешеләр күзеннән һәм зиһененнән ычкынган Тилебаш! Һаман йөри!
Больница түрендә гипсланган аягы күккә сузылган директор ята... Теге чакта җәнлекләр бакчасын су басмаса, Садир үз дәрәҗәсендә утырса, Вәкил институт бусагасын уза алмаса, директор әүвәлгечә сәламәт аягы белән матур гына йөрер, һәм бу көннәрне төрле афәт чуарламаган булыр иде.
Әмма, төптәнрәк уйласаң, барысы өчен Нәҗар үзе дә гаепле булып чыга. Җиде-сигез ел чамасы элек ул Садирны үз канаты астына сыендырмаса, бөҗәкләр болай ук үрчи дә алмаган булырлар иде.

Вөждан газабы дигән исем алырга тиешле авыр хис шул гаепне аңлаудан ук яралды булса кирәк. Ничек аны йолкып атарга? Теш врачы гына ярдәм итә алмастыр. Йолкып ташлаганнан соң да, аның тамырлары калырдыр. Бәлки черетә торган тутык күптәнрәк барлыкка килгән булгандыр?..

* * *

Нажар яңадан атна чамасы вакыттан соң гына эшкә чыга алды. Көн саен Фәнүзә алып кайта торган хәбәрләр аркасында, институт бусагасына аяк басасы килмәс дәрәҗәгә җителгән икән. Шул сәбәпле, институт каршындагы кечкенә бакчаны узып, урамга чыккач, ул кинәт икенче якка борылды.

Иренең кая барырга җыенуы белән дә кызыксынмыйча, Фәнүзә институтка кереп китсә, Нажар үзе күптәннән бирле күрәсе килгән дусты янына музейга юл тотты. Сагындырган дусты — кайчандыр үзе ясаган һәм музейга бүләк иткән аю карачкысы да чирләгәндер, хәлен белергә кирәктер сыман тоелды.

Мәгәр аю әйбәт кенә басып тора иде. Нәкъ тере хәлендәгечә елтыр күзләре белән кешеләргә карап, гүя ки елмая. Аю шат, чөнки аның янында кешеләр өзелеп тормый, бигрәк тә бала-чага җыйнала икән. Бала-чаганың кочаклыйсы, сыйпыйсы килгәне күзгә күренеп тора. Көлешә-көлешә әйләнә, тулганалар. Әмма елтыр күзле дусны ераграк яшергәннәр шул — пыяла читлек эченә бастырып куйганнар — кул җитмәле түгел. Димәк, ул мәңгелек әсирлеккә эләккән булып чыга. Аның өчен бу тормыш — мәңгелек сагыш.

Озак яшәү, үлемсезлек — вакытны җиңү дигән сүз. Әмма болай мәңгелек эч пошу хәлендә яшәүдән ни мәгънә?

Аю чынлап та тере булса, мөгаен, Нажарга үзенең үпкәсен әйтер иде. Әйе, Нажар аңа бик үк сокланырлык тормыш бүләк итә алмаган икән. Әмма... әмма хата инде төзәтелгән түгелме соң?

Теге көнне бит Әмән абый шундый хәбәр алып килгән иде. Ул геннар хәзинәсеннән нәкъ менә шушы аюның исән калган күзәнәген алып, аңа икенче гомер биргән ләбаса. Менә бит ничек: монда торган аюның төп-төгәл күчермәсе инде яшәп ята — ашый, йоклый, тугайда сикергәли, агач башларына үрмәләп менә. Әйе, бу аю үлеменең очраклы хата икәнен белгән һәм аны авыр кичергән Нажар сөеклесенең тере күзәнәген алып калырга өлгергән иде. Күзәнәкне кайчан үстерергә икәнен генә хәл итмәгән иде. Әмән абый аны хәл иткән. Ана аюны шуның белән аталандырып, ихтимал, рәхмәт әйтеп бетерә алмаслык изгелек эшләгән ул.

Шулай, кайчандыр очраклы ядрәдән үлем тапкан аю икенче тормышын башлады булып чыга. Димәк ки, вакыт чигенеп, кирегә китеп алды да атылган ядрә яңадан үз патронына кереп утырды? Тикшереп карасаң, нәкъ шулайдыр да ул. Бер үк аюның ике кабат яралуыннан һәм дөньяга килүеннән соң, нинди генә могҗизага ышанмаска мөмкин икән? Могҗизаны инде кул белән тотып карау мөмкин түгелме соң? Каравылчы абый ярдәме белән үзе тудырган могҗизаны үз күзе белән күреп, үз куллары белән сыйпар өчен, Нажар карачкы аю белән хушлашты да автобус тукталышына китте. Ике-өч сәгатьтән соң исә тәҗрибә хуҗалыгына яңадан тергезелгән лаборатория бинасына барып та җитте.

Ярдәмче хуҗалык дигәне бик каты үзгәргән икән — Нажар, «Кая килеп чыктым соң мин?» — дигәндәй, аптырабрак калды хәтта. Бернича ел элек тугайны су баскач һәм, күп нәрсә җимерелеп, барча җәнлек-хайван һәлак булгач, финанс ягыннан аксаган институт, тиешле оешмалар белән килешү нигезендә, хуҗалыкны шушындагы совхоз карамагына күчергән иде. Совхоз шактый куәтле икән: санаулы ел эчендә менә дигән кирпеч бина — зоологик база калкытып куйган һәм аны кышын да, җәен дә көтүлексез эшли торган фермага әйләндергән. Институтның ярдәмче дигән хуҗалыгы шул рәвешле зур селекция үзәгенә әверелгән.

Дөрес, совхоз бу эшләрне әле дә институт кешеләре белән берлектә башкара. Әмма галимнәр инде бу җирдә кунак кына икәнлекләрен яхшы тоялар. Александр Иванович, хәтта үзе дә хәзерге шартларда совхоз директорына бәйле булып яшәде. Нажар исә, совхоз зоотехнигы вазифасына катнашып, селекция эшенә нигез салышты. Бүгенге көндә рәсми зоотехник булып эшләгән Әмән абый Нажардан калган аю күзәнәген башкалардан сер итеп кенә саклаган һәм, мөмкинлек тугач, аңа икенче тормыш бүләк иткән...

Уртак иҗат уртак бәхет тә булсачы!

Баскыч төбендә Нажар шундый теләк белән уйланыбрак торган арада, ишек үзе ачылмасынмы.

— Югалган мал, кайттыңмы? Әйдә, уз.

— Ә! Әмән абый! Узганчы... әллә башта карыйкмы?

Сүз мәгънәсен тиз төшенгән Әмән абый хәйләкәр елмаеп куйды:

— Шулаймы? Шулай дисеңме? Шулай була ул.— Күтәрмәдән төшеп, Нажарның кулын кысты.— Киттек соң.

Бозаулар өчен салынган абзарда... аю яшидер дип күз алдына китерү кыен, әлбәттә. Җәй көне, мөгаен, һавага чыгарырлар, җәнлекләргә аерым читлекләр куелыр. Әмән абзый үзе дә шулай эшләргә җыена икән.

— Искә төшермә, зинһар.

— Үз хаталарыбыздан гыйбрәт алабыз. Шулай, башкаларныкыннан түгел.

— Абзарда тәҗрибә алып бару өчен бозаулар да урнаштырылган икән. Киләчәктә, бәлки, ишәерләр. Ни дисәң дә, селекция киләчәктә аларга нигезләнә.

Аргы почмакта — аерым бүлем. Ачык ишек артында гына... аю көтә. Нажарның йөрәге кинәт сулкылдап куйды. Очрашу! Нинди очрашу! Һәм... әнә ул — таныш аю! Шулай бит? Әмма, юктыр, солы арасыннан баш калкыткан бу хайван аю түгелдер. Ничек шулай була алсын икән?

Шайтан алгыры, гап-гади нәрсә башына тиз генә килмәгән — бу аю теге яшенә җитмәгән бит... Аның әле яшьрәк чагы. Шуның аркасында Нажар ятсынса, аю үз үтерүчесен тану түгел, аңа хәтта күтәрелеп тә карамады. Шуңа күрә Нажар читлеккә якын ук килде. Таныш чалымнар эзләде. Тапты. Күзгә иң нык ташланганы — елтыр күзләр, колаклар, борын. Бүтән кешегә бәлки охшашлык та, аерма да күренми торгандыр. Ә Нажарга алай түгел. Нажар исә бөтенесен хәтерли — йонның ничегрәк үскәненә хәтле. Музейдагы аюның чынлап та төп-төгәл күчермәсе бу. Тик әлегә яшьрәк кенә, гәүдәгә дә бәләкәйрәк.

— Моңа ничә яшь инде, Әмән абый?

— Яңадан бер ел кирәк әле.

— Атып үтерергәме?

— Кырда очрашырга. Бу юлы — мылтыксыз.

— Тотып ашаса?

— Җәй көне бит... кагылмас.

Нажар читлеккә кулын орындыргач, аю шомлана калды. Шул хәрәкәт берничә мәртәбә кабатлануга, каты гына ырлап куйды.

— Яле, син дә шулай эшләп кара әле.

Әмән абый читлеккә ничә генә тапкыр кагылса һәм хәтта кулын эчкәрәк сузса да, аю тынычсызланмады. Шуннан нәтиҗә ясарга мөмкиндер. Димәк, ул сизенә. Әле танымый, әлбәттә. Ләкин бер елдан соң таныячак.

— Әмән абый... Аның хәтере дә терелсен дисәк, яз җитүгә, үз урманына илтеп куярга кирәк. Шуннан ул монда килеп чыгачак...

— Хатынын, балаларын эзләп. Тик тапмаячак. Нинди фаҗига!

— Ә теге юлы... теге юлы фаҗига тагын да зуррак булды бит.

— Белмим шул, зурракмы икән?

— Кызык әйттең, Әмән абый. Ә чынын без бер елдан соң белербез. Тик син аны илтеп куярсың инде, ә?

— Икәүләп илтсәк, яхшырак булмасмы?

— Икәүләп? Әйе, алай да була.

Нажар, саубуллашырга теләгәндәй, читлек аша кулын сузган иде, аю тагын сагаеп калды. Бераздан янә ырлады.

— Танырга җыена. Таныячак. Хуш, исән булып тор, аю иптәш!

Шулай саубуллашып, абзардан чыктылар. Аннары совхоз директорына барып, хәл-әхвәл һәм киләчәк планнар турында күңел өчен генә бераз сөйләшкәннән соң, Нажар кире калага кайтып китте. Юл буе аюны ничегрәк үзенең туган урманына илтеп куюю хакында башы катканчы уйласа да, төгәл фикергә килә алмады. Кайчандыр дөньяга килгән һәм үскән урманы аның өчен хәзер үз була алырмы? Ни генә әйтсәң дә, аю бит бу юлы үз урманында тумады. Киресенчә, үзенең һәлак булган төшендә, бөтенләй чит җирдә һәм чит анадан туды. Ул үз урманын, кайчандыр югалткан гаиләсен эзләп, бу якларга кабат сәяхәткә чыгармы? Ә чыга калса, хатынын һәм балаларын таба алмагач, шулай ук бөтенләй башка язмышка дучар булмасмы? Әйе, ул монда беркемне һәм бернәрсәне дә тапмаячак бит — хәтта теге юлы тапкан үлемен дә. Шулай булгач, аны үз урманы, үз гаиләсе, үз тормышы, үз язмышы булган чын җан иясе дип әйтеп булырмы? Әйтеп булачакмы?

Күпме генә уйланса да, гади генә тоелган бу сорауларга җавап табылмады. Һәм табылмавы ихтимал кебек. Чөнки ике ай чамасы вакыттан соң Әмән абзыйдан: «Аюны үз урманына илтеп куйдым»,— дигән хәбәр килеп төшсә дә, Нажар шатлана алмаячак. Кешенең очраклы рәвештә ясалган хатасын да төзәтү мөмкинлеге юк сыман һәм ул мәңгелек вөҗдан газабына тартыла сыман тоела башлады. Ә шундый газап белән мәңге яшәргә хөкем ителсәң? Үлем хыялый максатка әйләнмәс идемени?

Бу хакта Нажарга тагын-тагын да күбрәк уйларга һәм тагын да зуррак газаплар кичерергә туры киләчәктер. Ә иртәгә исә, кичәге гадилектән дә гадирәк тоелган, әмма чынлыкта четереклерәк, катырак чәбәләнгән җавапсыз сораулар, төеннәр әзерләп, институт каршы алачак. Чәбәләнгән төенне кисеп ташлау мәслихәт булса да, Нажарга андый мөмкинлек калмаган, ахрысы.

* * *

Юанырлык бер генә яңалык көтә иде Нажарны: ул да булса, өч ай тәнәфестән соң, директор, ниһаять, эшкә чыккан иде.

Битләрне әчеттергән җил Нажарның савыгып бетмәвен искә төшерсә һәм шундый ук ачы сизену галәмәте күңелне чәнчи торса, авыруны җиңәргә мөмкинлек биргән уй да шул тирәдә әйләнә иде: директор эшкә чыккач, тиз арада тәртип урнашачак. Тамак кымырҗавын һәм лимфатик төеннәр чәнчешеп сагайтуын да шул уй җиңеләйтә иде.

Уй матур да, әмма чынбарлык... Анысы ничек булыр?

Нажар ишекне ачып:

— Исәнме, Алсу! — дип өлгергәннән соң, баскан җирендә баганадай катты калды.

Бу ни? Бу кем?

Алсу урынында... Әйе, Алсу урынында, елмаеп, бөтенләй ят кыз утыра!..

Гаҗәпләнүе аркасында исәнләшергә дә онытып, Нажар директор ишеген шакыды.

— Сезнең янга керергә ярыймы соң?

Ярый, дигәнне аңлатып, директор баш каккач, җайсызлыктан тиз котылу өчен, ашыгып исәнлек-саулык сорашса да, кешене гадәттә аягүрә каршыларга күнеккән әдәпле директор бу юлы креслосында утырган килеш кенә кул сузды һәм анда да ике ай күрешмәгән кешеләрчә түгел, тырышып кына елмая алды.

— Әйдәгез. Хәлләр ничек?

— Сездән калышмаска тырыштым, Александр Иванович. Мин дә ай ярым чирләп яттым.

— Шулаймы? Да, монысы әйбәт үк булмаган икән.— Директор, нидер исенә төшеп, кулы белән кемгәдер изәгәндәй итте дә исәнлек-саулык белешүне дә булә куйды.— Син бераз гына көтеп тор инде — мин хәзер керермен,— дип, ишекне ачык калдырып, чыгып китте.

Директорның уң аягы әле дә бераз аксый икән.

Чыгып китүен шулай ук хәерлегә юрау кыен булса да, бераз уйларга форсат бирүе җәһәтеннән бәлки әле шулай файдалырактыр да. Шуны уйлап, салмак адымнар белән ишекле-түрле йөренергә керешә Нажар. Әүвәл озак кына башына юньле фикер килми аптыратты. Аннары еракта ишетелгән кыюсыз көй кебек, зәгыйфь бер аваз зеңләгәндәй итте. Фикер туды: «Алсу максатына ирешкән — фәнни хезмәткәр мәртәбәсе алган! Мөгаен!»

Директор керде. Сүзсез генә үз урынына утырды. «Нык утыр, иптәш директор, хәзер бөтен нәрсә сезнең ныклыкка бәйләнгән». Әмма бүлмәдә шом куера гына төште. Шуны сыегайту теләге белән Нажар үзе сүз башларга мәҗбүр булды.

— Алсу... нәрсә... әллә ул да чирләгәнме?

— Юк бугай. Аны күчергәннәр — лабораториягә.

— Ә! Менә ничек! Ә сез аннан бик зур ачышлар көтәсезме?

— Мин килүгә — сюрприз. Шулай да... шулай да зыян китерә алмас. Күптән сорап йөри иде.

— Бераз сәеррәк, Александр Иванович. Алсу бит артык сабый җанлы, бөҗәкләрдән курка, шикләнә торган кеше.

— Карап карыйк, бәлки алай ук түгелдер. Бәлки без кешеләрне күрә, күтәрә белмибездер. Ә Садир Хәкимович...

— Институтны фәнгә бернинди катнашы булмаган Вәкилләр, Алсулар чолгап ала түгелме? Алар белән нинди уңышлар яуларбыз?

— Алда күз күрер, карарбыз. Төшендек.

Директорның бернәрсәгә исе китмичә сөйләшүе тагын җайсыз булып китте. Каян килгән шундый салкын битарафлык? Һаман терелеп җитмәгәнме әллә?

— Ничек соң, Александр Иванович, аяк-кул сызлыймы?

— Түзмәслек түгел. Аның каравы, баеп кайттым әнә.— Директор түр почмактагы таягын ым белән күрсәтте.— Аяклар хәзер өчәү. Алай-болай тәртип бозсагыз, шул каты аяк тиз күтәреләр. Ә? Төшендекме?

— Сез моңарчы таяксыз да төшендерә белә идегез. Хәзер исә...

— Хәзер аңлатып торырга көч җитмәс кебек.

— Бәлки, кыюлык?.. Гафу итегез...

— Ихтимал.

Сагаймыйча нишлисең. Директор бит үз көчсезлегенә үзе кул куйды. Димәк, ул күбрәкне белә. Димәк, аңа нидер сөйләгәннәр. Димәк...

— Ярый, Нажар Зәбирович, уйны дәвам итәрбез, әле вакыт бар бугай. Ә хәзер... хәзер онытыла язган эшләрне карыйк.

— Сүзегез хак, Александр Иванович,— дигән булды Нажар берни аңламаган хәлдә.

Бүлмәсендә аның урынында Вәкил утыра иде. «Әллә мине дә алмаштырып куйганнармы?» дигән уй күз ачып йомганчы: «Шулай булуы хәерлерәк!» — дигән икенче фикергә әверелде.

Тыныч кына газеталар караштырып утырган Вәкил, Нажарны күрүгә, сикереп үк торды. Менә ичмасам бер кеше шатланды институтта Нажар күренүгә. Кышкы кояшның барча нурларын сагыну хисләренә әверелдереп, бөтенесен Нажар тарафына бөрки белде:

— О! О! Менә ичмасам! Язган мал! Ниһаять! Ай-яй сагындырдың! Шушы хәтле озак чирләргә ярыймыни шушы тынычсыз дәвердә. Дөнья язмышы кыл өстендә торганда. Әйдә, үз урыныңа утыргандай

утыр.— Бер колагыннан икенчесенә кадәр елмайган хәлдә, газеталарны өстәлнең икенче ягына чыгып рәтләргә кереште ягымлы иптәш.— Ярый, соң булса да уң булсын. Терелеп дөрес эшләгәнсең. Янына берничә мәртәбә талпынсак та, Фәнүзә Кадыйровна адрес бирмәде. Үз уйлары булгандыр инде.

— Булгандыр, булмыйча калмагандыр.

— Әйе, әйбәт, ярый. Шулай, дөрес.

Гадәттә әйтелә торган өзек-өзек сүзләр, әлбәттә, күңелдәге хәерсез хисләрне үзгәртерлек түгел иде. Бу минутларда нәрсәнедер ачыкларга, азагынача аңлап бетерергә кирәк иде.

Нажар шунда ук бүлмәдәге яңалыкка күзләре төшеп, Вәкилгә сүз кушты:

— Әллә селектор үткәргәнсез инде?

— Садир Хәкимович зирәклеге. Кешеләр белән арасын якынайтты. Нәрсәгә тотынса, кулыннан шул килә. Александр Иванович ничәмә ел эшләмәгәнне, ике айда башкарды да куйды. Инде бөтен кешенең күзләре ачылды — безгә нәкъ шундый директор кирәк икән. Гомер буе телефонсыз яшәгәнне телефонлы итеп бетерде. Квартиралы итте. Сезне дә. Ә? Аның яхшылыгын сизмәгән кеше бездә инде калмагандыр, бил-ләһи.

— Ялганның җиңүе вакытлыча гына була. Әмма бөтенләйгә булуы да ихтимал.

— Ничек, ничек дидегез Нажар Зәбирович?

— Болай, үз уйларым гына. Яле, бас әле селекторга. Лабораториягә чык.

Вәкил, шатланып, селектор сәдәфенә баскалады.

— Лаборатория? Светлана Владимировна, Сезме?

— Әйе, тыңлыйбыз.

— Алсу Гаффаровна, Сез ничек?

— Мин дә тыңлыйм.

— Монда менегез әле, Сезне Нажар Зәбирович күрергә тели.

— Ай, ай! Кайттымыни Нажар Зәбирович? Хәзер менәбез, хәзер.

Иң аскы каттан түгел, әйтерсең күрше бүлмәдән генә килә тавыш. Шуны гүяки үз уңышы итеп тойган Вәкил:

— Шушына бассаң, иптәш директорның да, Садир Хәкимовичнең дә ни сөйләгәне ишетелеп тора,— дип, тагын сәдәфләргә баскалады.— Безнең кебек гади халыктан сер яшерү бетте.

— Ишетү җайлары күбәйгән саен, аралашу мөмкинлеге артамы соң?

— Артамы дип... Анысы бездәндер инде. Дус булсак, фикердәшләр булсак...

— Ә селектор булгач, фикернең кирәге дә калмыйдыр әле.— Нажар шулай авыр тойгылардан арынып өчен шаяртмакчы иде дә, бик үк барып чыкмады бугай.

Шаянлыкка тумас борын дигәндәй чик куелды. Югары оешмалардан Садир Хәкимович кайтып кергәч, хәл янә мөшкелгә әйләнде.

— Нинди куәтле тавыш дисәм, чирле дигән тамак авазы икән әле,— дип, хәл белергә үзе керде директор урынбасары.

— Шул хәтле дәвалауга, куәтләнсә дә гаҗәп түгелдер,— дип, Нажар аңа утырган килеш кул сузды.

Күрешкәч, креслодан тәрәзә янындагы урындыкка күчте һәм, бераз гына хәл белешүләрдән соң, сүзне кирәгрәк җыпкыга кайтарырга тырышып, мөмкин кадәр ачык чырай белән гәпне дәвам итте Нажар:

— Шактый үзгәрешләр әзерләп куйгансыз, байтак сюрприз.

— Сиңа күңеллерәк булсын дидек.

— Алай гынамы? Әллә тагын да зуррак идея бар идеме?

— Төшенмәдек.

— Төшендегез.

— Ягъни?

— Ягъни дисәк... интригаларга яшьләрне катнаштырып, аларның вөҗданын, әхлагын пычратмаска, бозмаска иде. Кешелеклелекләрен югалтмаска... Минемчә, бу — авыр җинаять.

— Менә хәзер кызык булып китте. Ары киттек, тәгаенрәк...

— Кыз балалар ярдәме белән кешеләрнең яманатларын сатып... Әдәпсез сурәтләр булдырырга тырышып... Ә барып чыкмагач, уйлап чыгарып...

— Ягъни? Тагын да тәгаенрәк мөмкиндер кебек. Ә?

— Дөрес сизәсез — сезнең хакта бара сүз. Рухландыручы — сез. Максатыгыз — кемнәрнедер моннан җибәрү, котылу. Миңа калса, тиз арада сезгә үзем ярдәм итәчәкмен.

— Кызык. Ә кем каршы килер дип уйлыйсыз? Ашыга төшсәгез дә ярыйдыр, ә?

Гамәлдә ашыга төшелгәнен Нажар чамалап алды алуын да, соңгарак калынды бугай тик. Бу вакытта бүлмәдәгеләргә генә түгел, көчле тавыш белән бөтен институтка кычкыруын, барча бүлмәләрдә селекторга дистәләрчә кеше колак салуын шәйләми, белми иде шул. Хәтта директорның да тоташканын башына китерми һәм бу элемтәне бая Вәкилнең үз күз алдында урнаштырганын аңышмый ук калган иде. Их, нервалар, нервалар! Их, янында Фәнүзә булса! Ул ничек тә ярдәм иткән булыр иде.

Ерактан ишеткәч ук Фәнүзә тыны-көне бетеп килеп кергәндә, инде соң иде, артык соң иде. Җитмәсә, аның артыннан ук бастырып, Светлана Владимировна белән Алсу кереп җиттеләр. Ничәмә кеше, нишләргә икәнен белмичә, каттылар да калдылар. Нажар тәрәзә янындагы урындыкларның берсендә, ә Садир аңа каршы як дивар буенда — икесе бүлмәнең ике башында киерелеп утырганнар да берсен-берсе хәйләсез нәфрәт белән чәнчи бирәләр — карашларыннан ут чәчри. Вәкил генә эчендәге тирән шатлыгын көчкә тыеп, әле Нажарга, әле Садир ахирәтенә, әле яңа гына кергән кызларга карап елмая һәм, әрле-бирле йөренеп, селектор микрофоны тирәсендә бутала.

Светлана Владимировна, сүзсез бәрелешне күрмәгәнгә сабышып, Нажар абыйсы каршына килеп басты.

— Нажар Зәбирович, Сезне туелүегез белән котлыйбыз.

— Рәхмәт.— Зур тырышлык белән елмайган Нажар, үзе дә хәл сорашырлык көч тапты.— Үзегездә ничек соң?

— Бездә менә шушылай инде... Түзәбез.

— Ә сезнең хәл? — дип, Нажар Алсуга ихлас кызгану хисе белән күз ташлады.

— И-и, Нажар абый, Сез миннән сорамагыз инде минем хәлне, аннан сорагыз.— Шулай дип, кыз Вәкилгә ымлады.

— Ни булды соң?

— Ул белә. Алар!..

— Кемнәр?

— Кем дип... Шулар инде, бөҗәкләр. Бая микроскоптан караган идем... Анда да... мыжгып тора. Мин аны башта сез үрчеткән бөҗәкләр дип уйлаган идем. Ә аларны болар тараткан икән. Менә шушылар тараткан микроблар.— Алсу Садир белән Вәкил абыйсына баш изәде.— Шушылар. Безне ашап бетерсен өчен... Әнә, адәм канына ук үрмәләгәннәр бит инде. Үзем, үзем күрдем, микроб рәвешле корткычлар, чик-чамадан аштылар инде.

Бу сүзләрне гаҗәеп тынлык саклап, күләргәме, еларгамы икәнен белмичә тыңладылар, чөнки хәлне аңлап бетермиләр иде. Ә Вәкил белә. Алсуны үз төркеменә алгач, атна-ун көн уздымы, кызның сәеррәк хәрәкәтләре күзгә бәрелә башлады. Хәерсезлек сизгән Вәкил Алсуга әйбәт киңәшләр бирсә дә, төркем башкарган күзәтү-тәҗрибәләрнең җитдилеге, лабораториядә иҗат ителгән бөҗәкләрнең иген басуларында корткыч бөҗәкләргә каршы көрәшүчеләр икәнен, химикатлар белән эш итүгә

караганда күп мәртәбә куркынычсызрак, җайлырак булачагын, гомумән, бу эшнең һәм фәндә, һәм тормышта әйбәт ачыш икәнлеген аңлатырга тырышса да — кая ул! Микроскоп янында утырганда, колбалар белән булашканда яки көпшәдән көпшәгә сыекча күчергәндә, кыз кинәт сикереп тора да каты итеп, кабат-кабат кулларын юарга керешә. Ике көн элек исә: «Әләй!» — дип кычкырып җибәрде дә нәрсәләрнедер себереп төшерергә тырышкандай, түшләрен, беләкләрен, кулларын сыпыра башлады. Якындагы иптәшләре гаҗәпләнеп карасалар да, моңа әллә ни җитди игътибар итмәделәр шикелле. Хәзер исә шул хәрәкәтләре тагын кабатлангач, Вәкил, катырак булу фарызлыгын чамалап, үзенә дә, кызга да һәм, аннан бигрәк, җитәкчегә ярдәм кулы сузу нияте белән акылсызлыкка отпор бирергә ашыкты:

— Син, кызый, иплән. Нинди бөҗәк, нинди микроб?.. Шыр надан башың белән нинди эшкә үрләдең... Микроб — син үзең ул!

Чырае көл төсенә кергән Садир Хәкимович, Фәнүзә Кадыйровна янына килеп, ярым пышылдап әйтте:

— Сез... хәзер сез сүз әйтергә тиеш. Ирегез аткан пычрактан безнең йөзне акларга тиеш. Сез бурычлы. Хәзер үк! Ишетәсезме? — Фәнүзә кырыс кыяфәт белән сүзсез торганга күрә, боерган рәвештә искәртте: — Хәзер, яки — һичкайчан. Югыйсә юлларыбыз аерыла. Тыңлыйбыз. Я?!

Әмма Фәнүзә кискен адымнар белән икенче почмакка күчте. Ерактан күзләре очрашкач та Садир карашы белән: «юллар аерылды!» дигәнне аңлатып, баш какты.

Алсу, хәерсезгә каршы, тынычланырга һич чамаламый иде әле:

— Эпидемия. Света дөрес әйтә. Сез китергән афәт, сез үрчеткән бөҗәкләр. Сез йоктырган!

— Беренче чиратта сиңа йоккан — әнә тәнеңә үрмәли!

Вәкил бу вакытта үзенең тәкъдир ялгышы белән генә чагыштыру мөмкин хата ычкындырганын абайлап өлгергәнче, кыз кычкырып та җибәрде:

— Әләй, тәнемдә йөриләр, үрмәлиләр — ашыйлар! — Һәм кыз шулай әле билләрен, әле аркаларын, әле күкрәкләрен-башларын уа-уа сикергәләргә, сыпырынырга керешмәсенме. — Бөҗәкләр — тәнем буйлап йөри, ашыйлар, бетерәләр мине ашап. Ай, үләм бит, үләм, коткарыгыз, коткарыгыз!

Башта нишләргә белми торсалар да, эшнең уеннан узып, истерикага тоташканын барысы берьюлы сизеп, урыннарыннан сикереп тордылар.

— Ашыгыч ярдәмгә шалтыратыгыз! Тизрәк! Күреп торасыз бит, кеше акылдан язды! — дип белдерде Садир Хәкимович, кискен рәвештә.

Ләкин аның кайгыртуы Алсуның янган йөрәгенә керосин сипкәндәй генә тәэсир итте шул.

— Тизрәк! Ярдәм! Сезгә кирәк ярдәм, сезгә! — дип, кыз үз хәлен Вәкилгә күчерә бирде. — Бөтен чирнең башы синдә. Иптәш кызларымны, белгән егетләремне яллап, күпме мин синең агулы сүзләреңне шәһәр буйлата таратыштым? Имеш, шуның өчен мине үстерә, үрләтәләр! Ә чынлыкта адәм көлкесенә калдым. Нинди галим ди мин? Нинди лаборант? Вәкил үзе үк, мыскыллап, бик дөрес әшли. Менә ничек кайтарды ул минем тырышлыкларымны. Оят! Җирдә яшәмәслек итте. Уфф!

Бу сүзләр селектор аша шулай ук барча бүлмәләргә яңгырап таралды. Аларны тыңлап, барча халык аһ итте. Тегеяки бу сәбәп белән тыңламый ишетми калганнарга тыңлаган-ишеткәннәрне фаҗига төсләрен һәркайсы үз сәләтенчә куерта төшеп, бүлмәдән-бүлмәгә җиткерә, ташый торды. Институт тирәсендә генә тукталмыйча, Алсуның бар көченә үрсәләнеп кычкыруы бөтен калага ук яңгырамады микән әле. Һәрхәлдә тиешле иптәшләргә ул ишетелмичә калмады дияргә туры килә. Тавышсыз кычкыруларны да ишетә белгән иптәшләр, мөгаен, монысын гына ишетми калмаганнардыр.

— Сез, сез мине шушы хәлгә төшерүче. Менә күрегез үз эшегезне.

менә мин ул — хуҗасын югалткан эт. Мин сезнең күзләрегезне чокып чыгарам. Мин сезнең бавырларыгызны, бөерләрегезне ашап бетерәм. Сезгә генә димәгән бавыр-бөер ашарга. Җәнлекләрнекен генә түгел, бер-берегезнекен! Әкертен генә, сиздермичә генә! Сез хәзер барчагыз йөрәксез, бавырсыз, башсыз яшәп ятучы карачкылар! Үзегез дә беләсез, тик бүтәннәргә сиздермәскә генә тырышасыз. Микробларны да сез үрчеттегез — бер-берегезне кимереп бетерсен өчен. Ә алар сезнең ихтыярга буйсынмый башладылар. Үзләрен тудырган, үстергән бәндәләрнең дә җаннарына, үзәкләренә үткәнче мыжгылдый, үрчиләр. Бөтен институтны басты сез үрчеткән бөҗәкләр! Әнә, әнә бит! Ай!

Шушы сүзләрне ишеткәч, күрше бүлмәдә утырган яңа секретарь кыз, үзенең әлгәре булган Алсудан һич ким булмаганча, алама төш күреп уянгандай чарылдап, директор бүлмәсенә керде. Директор шулай ук бөтенесен ишетеп торган икән. Башын ике кулы белән учлаган да өстәл тактасына текәлеп каткан. Үзенең чираттагы бөек ачышы хакында уйлана диярсең.

— Александр Иванович, Александр Иванович, нишләп болай тыныч кына утырасыз, нишләп чик куймыйсыз?!

Кызның үрсәләнүенә каршы директор:

— Инде без дә көчсез... Йөгәннән ычкынды,— дип кенә куйды.

— Нәрсә ычкынды, кем ул?

— Үзегез дә күреп торасыз.

— Әйе, Александр Иванович, күрәм, ә сез кемнедер гаепләргә, кемгәдер җәза бирергә тиеш түгелме?

— Гаепле кешене, җәза алырга тиешле кешене дә күреп торасыз.

— Ул Сезме? — дип, сабыйларча ялгыш кычкырып җибәрүен тәҗрибәсез кыз тиз сизсә дә, соң иде инде. Директор аңа хәзер күрмәгәнен күрсәтәчәк.

Ләкин монысы да ул уйлаганча булып чыкмады. Һич ачуланмыйча гына, директор:

— Бар, кызым, үз эшеңне эшлә,— дип кенә боерды.

## Кабатлау сабагы

*Ә тормыш агачы яшьнәп яфрак яра.*

И. В. Гете.

Нәҗар директор янына бер атна чамасы вакыт узгач кына керә алды. Ташудан соң дәрья үз җыпкысына кайткандай, хәлләр тынычлана язды шикелле. Алсуны больницага озаткач, һәрхәлдә шау-шу тынды. Гәрчә бу, ихтимал, тышкы яктан караганда гына шулай күренгәндер. Кайбер кешеләрнең ярсу тойгылары басылырга һич җыенмыйдыр әле. Акыл шул хакта сөйли.

Директор ямансу каршылады. Кызганычка каршы, бүтәнчә көтелми иде.

Нәҗар ике ел рәттән отпускасын бухгалтерия аша уздырса да, гамәлдә ялга чыкмаган һәм, эш күп булгач, директор да шулай дөресрәк дип тапкан иде. Үлгәннән соң да өч көнлек эш кала дигәндәй, хәзер дә кул кушырып утыра торган вакыт түгел, билгеле. Әйе, эшнең бетәсе юк, әмма көч һәм теләк дигәндә...

Көч чамалы, ә теләк каядыр очты. Аягын сындырганнан соң, директор үзе дә шундыйрак хәлдә кебек. Нәҗар моны сизеп, күреп тора.

— Кәефләрегез ничек, Александр Иванович?

— Минеке зыянсыз, ә сезнеке — мөһимрәк...

— Мин бик терелеп бетә алмыйм бугай әле, Александр Иванович. Ике ел рәттән ял итмәү дә үзен сиздерә. Хәзер вакыт житте шикелле.

— Ике ай рәттән ял... түзә алырсызмы?

— Киресенчә, монда түзү кыенлашты.
— Төшендек. Кайчаннан?
— Иртәгәдән.
— Каршы килмим.
— Рәхмәт.

Шуннан соң, алар тагын бер биш минут чамасы утырдылар. Әмма гәп дөрләп китә алмады. Бөтен нәрсә кирәгеннән артык аңлаешлы иде.

Нажар, шул рәвешле, институтны бөтенләйгә дип ташлап китте. Бер үк вакытта, көтелмәгән хәлләр килеп чыгу ихтималын күздә тотып, китү хакында гариза калдырмады. Дөресрәге, кыюлыгы җитмәде бугай. Алда күз күрер...

* * *

Нишлисең бит, бөтен Союз күләмендә әһәмияте булган фәнни-тикшеренү институтының гыйльми советы члены һәм лаборатория башлыгы дигән исем көчле яңгырый, әлбәттә. Һичшиксез шулай. Әмма кеше исем алу өчен генә туммый, ә нәрсәнедер күбрәк күрү, һаман күбрәк белү өчен туа һәм шуның хакына яши. Нажар исем өчен туган кеше түгелдер, ул күбрәк белү өчен тугандыр, мөгаен. Һәрхәлдә, ул үзенә аң кергәннән бирле шушы хис, шушы омтылыш белән яшәде. Калганы — вакытлы мәшәкать.

Кемдер кешенең төп бурычын һәм функциясен биологик программага кайтарып калдыра: мәхәббәт һәм женси яшәү — тормышның өзлексезлеген хәл итә. Дөрес тә ул. Ләкин тулы түгел. Мәхәббәт — зур нәрсә, ләкин мәңгелек түгел. Мәхәббәт ул бетеп тә куя белә. Үлгән мәхәббәтне терелтү өчен дару, ай-һай, бармы икән. Булса, кирәге дә юктыр. Менә хәзер шундый дәвер бугай. Әмма Нажар, сөюнең ни икәнен сизми башласа да, тормыштан кул селтәргә җыенмый. Киресенчә, моңарчы белгәннәренә караганда киләчәктә өйрәнергә, табарга тиешле яңалыклары чагыштыргысыз күбәйде төсле. Шулай тоела, һәм чынлыкта да шулай ул. Нажар тукталган жирдән бүтәннәр башлап китәчәк...

Тик директор гына — бу юлы совхоз директоры гына — каршы килә күрмәсен.

Отпуск бетәр алдыннан, шундый теләк һәм өмет белән, Нажар үзе такырайткан таныш юллардан үз кыйбласына таба китте. Шул теләк белән совхоз директорына килде. Дөресрәге, башта Әмән абыйсын эзләп тапты.

Әмән өчен Нажарның килеп чыгуы — гадәти хәл. Һич тә гаҗәпләнмәде.

— Күрергә килгәнсездер инде, ә? — дип куйды.

Сүзнең нәрсә хакында икәнлеге күптән билгеле, янәсе.

Карт ялгышмый иде. Аю шулай ук алгы планда... Әмма...

— Менә... вакыт бар. Илтеп куярбыз бергәләп. Әйдә, карыйк та.
— Нәрсәне карарга?
— Аю дусны.
— Аю дус инде юк.
— Я, шаяртмасана.
— Чынлап.
— Үлдеме?

Нажар куркып өлгергәнче, карт аны тынычландырырга ашыкты:

— Илтеп куйдым. Үз урманына. Өч көн элек кенә.
— Ки-и-т! Нишләп ашыктың ул хәтле?
— Үзең кушкан идең ләбаса. Юл уңае туры килде дә... Совхоз машинасы. Көннәр инде җылына, аюлар болай да уяна. Исән булырга тиеш.

Ышанырга мәҗбүр иде Нажар. Әмма гаҗәпләнүе барыбер тиз генә үтмәде.

— Торган урыныбыздан купмыйча күтәбез, алайса?

— Авылда төпләнергә туры килмәгәе.

— Әгәр совхоз директоры каршы килмәсә... Син, Әмән абый, мине тәкъдим ит әле аңа.

Шул рәвешле, икәүләп дирекциягә килделәр.

Директор кәнсә янында кемнәр беләндер сөйләшеп тора иде.

Нажар тыңлап-тыңлап караса да, берни төшенә алмады. Сүз сирәгәйгән арада исә Әмән абзый директорга Нажарның нинди ният белән килгәнен әйтте дә:

— Әгәр дә мәгәр бик тә чибәр кәләш тапсагыз, төпләнеп үк калырга исәбе,— дип шаяртткан булды.

— Чынлапмы? — дип, Нажарның кулын кысты директор.

Анатолий Степанович Киселев. Каладагы директорның нәкъ киресе: артык озын булмаса да, шактый калын гәүдә, тулы йөз. Кул кысуына караганда, үгезне мөгезеннән, бүрене бугазыннан эләктерерлек гайрәт иясе. Үзе кебек үк куәтле адәмнәр белән эш иткән житәкче нәкъ менә шушындый булырга тиештер дә. Нажар каладагы директорның гына түгел, үзенең дә капма-каршысы булган бу кешене житәкче сыйфатында кабул итә алачак бугай. Шуңа күрә ул, чынын шаяруга әйләндереп булса да, көттермичә:

— Чынлап! — дип катгый җавап бирде.— Исәп шулайрак.

— Хәзер, гафу итегез.

Сүзнең дәвам итәчәген ым белән аңлатып, машина әһелләренә директор үзенең соңгы күрсәтмәләрен бирергә кереште. Тәгаен нәрсә, кем турында сүз барганын аңламаса да, шул кадәресен Нажар колагына сала алды: каядыр баралар, кемнедер күрәләр дә Киселев исеменнән нәрсәдер әйтәләр икән. Процедура төгәлләнгәч тә Нажарга борылды:

— Киттек, Нажар Зәбирович.— Директор аның исемен интегүсез әйткәннән соң, баягы тәкъдимен кабатлады.— Кереп сөйләшик.

Шулай дисә дә, мәгәр сүзен ул чынлыкта кергәндә үк башлады. Дөресрәге, дәвам итте.

— Ә нәрсә? Бер дә шаяртасы юк. Безнең монда теләсә нинди галим, кирәксә, дөньякүләм танылган академик өчен дә эш табылачак. Шулай бит, Әмән Зарипович? Бер дә ялмаясы юк. Кайсы институтка тигән безнең база? Ә? Сезнең кулда чакта карап торган шул өч аюыгыз бар иде, бала-чага ысулы белән тота торган күгәрчен-каргагыз, әрләнтычканыгыз... Тагын ни өсти аласыз?

— Хәзер аю да юк,— дип көлгән булды Нажар.

— Аю — ул уенчык кына. Әллә ни зур фәнни ачышка ярдәм итмәде бугай.

— Бәлки итәр, әле эш бетмәгән.

— Көтәбез әле, кайтканын,— диде Әмән абзый.

Кабинетка керделәр. Монда да игътибар итәрлек нәрсәләр байтак җыйналган икән. Нажарның түрдәге байракларга, стеналарга ябыштырылган мактау кәгазьләренә күз төшерүен күргәч, шуларның сәбәпләрен санап китте директор:

— Терлекчелек буенча, аллага шөкер, сынатканыбыз юк. Әлбәттә, сезнең хезмәт, сезнең киңәшләр белән. Әмма без сездән башка да шактый үсә белдек. Уйлап карыйк: нәрсә ул бүгенге көндә безнең зообаза? Чын фәнни үзәк. Тыюлык дисәң дә хәтере калырлык түгел. Шулай бит, Әмән Зарипович? Шулай. Бая санаганнардан тыш әкертен-әкертен яңа җан ияләре җыйнала: урман кәҗәләре, аслар, якут атлары, Себер сарыклары... байбак, улар, кеклик... тагын... дингез аръягыннан килгән кунаклар — Шотландия сыерлары... Тагын... Я, Әмән Зарипович, ярдәм ит.

— Болай да ышандырырлык булды, Анатолий Степанович. Кунак аларны үзе дә белә. Ул бит чынлыкта күптән безнең кеше.

— Бик әйбәт. Монда, әйтәм бит, өч институт берьюлы эшләсә

дә тарлык сиздермәбез. Күңелебез жиребездән киң, эш кенә эшләгез — нәсел яхшыртырга, мал арттырырга ярдәмегез тисен. Шул гына шарт. Әйе. Әгәр дә шаярмыйча әйтсәк, сезнең монда төпләнүегез үзегез өчен дә кызыклырак. Мин сезгә чынлап тәкъдим ясыйм. Хезмәт хакы дигәндә... Сез анда күпме аласыз әле?

— Ике йөз житмеш.

— Монда да шуны ук бирә алабыз. Шулай бит, Әмән Зарипович?

Директор сәдәпкә басты да селектор аша тиешле кешене дәшеп кертте:

— Владимир Алексеевич — баш бухгалтер. Безнең баш зоотехникның хезмәт хакы ничек каралган әле? Ике йөз алтмышмы?

— Шулай, ике йөз алтмыш.

— Ишеттегезме, Нажар Зәбирович? Аерма юк диярлек. Аның каравы — башка яклары. Сезнең анда шәхси машинагыз бармы?

— Хәзергә юк.

— Ә монда булачак.— Инде утырып өлгергән баш бухгалтерның нәрсәдер әйтергә жыенганын сизеп, директор аны бармак очы белән туктарга мәжбүр итте.— Ягъни... совхоз машинасы. Сезнең карамакта булачак. Теләсәгез, шәһәрдә торыгыз. Кырык-илле чакрым — каян килеп кая китмәгән — эшкә машина белән килеп йөрерсез. Булдымы? Баш зоотехник булып бүгеннән эшкә тотына аласыз.

— Мин риза.

— Ничек? Ничек дидегез?

Үзенең әле генә тырышып-тырышып үгетләвенә карамастан, ул тәкъдименең кабул ителүенә бик үк ышанмаган икән. Гажәпләнүе чамасыз иде. Бот чаба куйды:

— Менә бит, ә! Менә ничек! Житте, шаярудан уздык.

— Мин шаяртмыйм, Анатолий Степанович.

— Ниче-ек?

— Сез куйган шартларга мин риза. Әгәр үзегез кире кайтмасагыз.

— Менә инде. Нишләп үз сүземнән баш тартыйм. Тик... тик... сезнең анда... институтта барысы да тәртиптәме соң? Персональ эшегез алда тормыймы диюем.

— Юк, юк, бөтенесе — ажур.

— Булды алайса — по рукам!

Директор һич авырсынмыйча торып басты да кулын сузды. Нажар рәхәтләнеп:

— По рукам! — дип жавап бирде.

* * *

Александр Иванович житәкчелегендәге фәнни-тикшеренү институты башка институтның бер секторыннан үсеп чыкты. Микробиологиянең кешелеккә могжизалы казанышлар бүләк итәчәген аңлаудан бигрәк, аның күп тармаклыга әйләнә баруын һәм асылда үз эчендә хәзер үк төрле юнәлешләр хасил булганлыкны директив оешмалар бик тиз чамалаганлыктан, бөтен кварталга сузылган менә дигән сары йорт салып бирделәр. Моңарчы да аның һәр башлаган эшен шулай яклап килгәнлектән, житәкче оешмаларга карата булган ышаныч, акрын-акрын тынычлануга, директорның галим булу белән бергә хужалык кешесе һәм администратор да икәнен онытa башлауга барып тоташты бугай. Шул тойгы аркасында ул: «Галимнәргә бары тик галимнәр житәкчелек итәргә тиеш»,— дигән карашын нигездә онытты һәм үзе кайгыртырга тиешле күп нәрсәләрнең югарыда хәл ителүен көтеп торырга гадәтләнде. Югары урынның иң беренчесенә институтның элекке гыйльми секретаре куелгач һәм монда аны Садир Хәкимович алыштыргач исә, директорның кешегә салынуы хәтта арта төште дисәк тә ялгыш булмастыр. Күп кенә принципиаль мәсьәләләрне Садир Хәкимовичның яхшырак хәл итә белүе, кешеләрнең тормыш-көнкүрешен яхшыртуны да әйбәт кайгыртуы исә Александр

Ивановичка илаһи дигәндәй тынычлык китерде. Ике-өч ел эчендә өйсезләр өйле булса, ә зуррак галимнәр үз эшләренә муафыйк мактаулы исемнәр алса, каядыр сайланса, барча бу казанышлар Садир Хәкимовичның кешелеклегенә бәйләп аңлатыла башлады. Хезмәткәрләргә стенка-шкафлар, башка җиһазлар, төрле келәмнәр табу, теләгән барча иптәшләргә табигатьнең гүзәл төшеннән бакча участоклары юллау да Садир Хәкимовичның олы кайгыртучанлыгын исбатлап яфрак ярды һәм чәчкә атты гына түгел, ачымы, татлымы, җимешләрен дә бирә торды. Аның кайгыртучанлыгы җыелышларда, утырышларда киң җәмәгатьчелеккә бәйнәбәйнә сүз ителә иде. Садир Хәкимович шәхесен, шул рәвешле, салават күперенең барча төсләрен җыйган балкыш чолгап алды. Гыйльми совет утырышыннан кала барлык җыелышларны оештыру, ачу һәм ябуны Александр Иванович үзенең ышанычлы һәм һәрвакыт тере урынбасарына тапшыра торган булды.

Александр Иванович бу җыелышларда ниндидер ясалмалык сизсә дә: «Яхшылыктан яманлык эзләмиләр» дигән тыйнак фикер белән үзен тынычландыра килде. Ясалма пафос дигәнне ул мөнә нәрсәдә күрә иде: гуманизм хакында, тормыш шартларын яхшырту хакында артык күп сөйләшү дәрәҗәгә һәм комфортка омтылу кебек аламарак хисләрне дә кузгата түгелме? Урын һәм бүләкләр бүлешүгә дә шулар этәрмиме?

Синең житәкчелегеңдә кемдер акылдан яза икән, син моны кыз баланың нервлары йомшаклыгына, яки генетик кодына бәйләп — тәкъдир тарафыннан алдан ук билгеләнгән нәтиҗә дип карый алмыйсың.

Алсу атлы кызның бөтен институтка иләмсез кычкыруы тиешле оешмаларга көне-сәгате белән барып ишетелде. Селектор аларга да тоташкан диярсең. Шулайдыр да ул — күзгә күренми торган селектор уздыручылар һәм сәдәпкә вакытында баса белүчеләр бездә юк түгел бит. Бернинчә ел инде шундый шартларда яшәлде һәм директор бу җәһәттән дә үзеннән башка беркемне дә гаепле дия алмады.

Югарыга дәштеләр — больницада булган әңгәмә хакында, пенсия яше хакында сак кына искә төшерделәр.

— Төшендек,— дип, елмаерга тырышты Александр Иванович.— Сез хаклы.

Аны гыйльми секретарьлыктан күтәрелгән әлекке үз шәкерте чакырткан иде. Яшь житәкче, әдәп-тәүфикъ иясенең нәкъ үзе сыйфатында, сөйләшүне олы ихтирам белән башлады һәм шулай тәгәлләде дә:

— Без сине ашыктырмыйбыз, Александр Иванович. Үз көегез белән генә карарсыз.

Директор кешелекле сүзләр өчен ихлас күңелдән рәхмәт белдерде. Яшь житәкче, актык сүзен шуннан соң гына бик гади нәрсә хакында әйткән кебек әйтеп куйды. Директор колагында үз шәкертенең кайгыртып әйткән сүзләре мөнә хәзер дә яңгырап тора:

— Сезнең институт контрольдән ычкынган булып чыкты. Лабораторияләрегезнең берсендә Тилебаш туды...

— Тилебаш... Анысы... Садир Хәкимович хезмәте.

— Нажар Зәбирович пробиркасыннан килеп чыккан җен Аю кыяфәтендә! Анысы тагы ниләр кылмас!

— Аю... гади аю. Аннан курку урынсыз. Анда бернинди мутация, табигать хатасы юк.

Контрольсезлек — куркыныч нәрсә. Үзешчәнлек. Ниндидер очраклы кешеләр җеннәр оясын ача, хәзергечә әйтсәк, геннар хәзинәсенә керә ала. Аңа бит исемне дә дөрес биргәннәр — хәзинә! Үзегез уйлап карагыз: әгәр дәүләт хәзинәсенә теләсә кемнең кулы житсә, кая барып чыгар иде безнең бу җәмгыять?

— Төшендек, рәхмәт.

— Аюдан кешегә күчү — бер адым. Шул рәвешле без мутантлар — гарип албастылар иҗат итеп, дөнья кинлегенә чыгарып җибәрсәк? Әлеге

аюны, кабанны чыгарып жибәргән кебек? Ә? Ә ул кешедән өстен көчкә әверелсә, әпригә? Нажар Габбасов әйткәнчә, Тилебашка? Ә? Менә бит, Александр Иванович... дөнья каршында, кешелек каршында җаваплылык безне шәфкатьсез дә булырга мәҗбүр итә.

— Житәр, төшендек. Гаепне үз өстемә алдым.

— Артык рыцарьлык файдалы булмас. Бераз өлешен гаепле кешеләрнең үзләренә калдырсак, гаделрәк булыр, Александр Иванович. Мин беренче нәүбәттә иптәш Габбасовны күздә тотам.

— Габбасов — кристаллдай саф кеше, ходай үзе яраткан галим. Больницада сөйләшкәнчә, минем урынга лаеклы бердәнбер кеше ул. Тыйнаксызлыгымны гафу итегез.

— Шулай укмы икән? Ну, анысын да карарбыз, уйларбыз...

— Карагыз соң... уйлагыз. Ләкин чынлап уйлагыз.

— Рәхмәт, рәхмәт. Вәгъдә — иман.

Бу хәлләрне Нажар, әлбәттә, белми, читтә йөри... Асылда аңа урында — совхозда эшли, гәрчә әле институт кешесе булып калса һәм чираттагы ялда гына булып исәпләнсә дә. Ялны кем ничек файдалана, анысы — һәркемнең үз эше. Нажар сизә ки, ул инде китте... Аны институттан читләштерделәр. Ничек оста эшләделәр! Аларга Нажар үзе бик шәп ярдәм итте!

Гомернең иң матур бер өлешенә нокта кую өчен ике ай вакыт һәм бер утырыш житте.

Совет утырышын Садир Хәкимович үзе алып барды. Александр Ивановичның пенсиягә китәргә ризалык сорап язган гаризасын кычкырып укыганнан соң тирән кичерешкә бирелеп:

— Хөрмәтле остазыбыз ял сорый. Ул моңа, әлбәттә, лаеклы. Сездә нинди фикерләр булыр? — дип сүз башлады.

Яшь һәм талантлы галимнәрнең берсе:

— Үзен тыңлыйсы иде,— дип аваз бирде.

Александр Иванович үзе дә теләмәстән һәм сизмәстән кызарып куйды һәм сүз куәсенең кинәт кимеп куйганлыгын тойды. Шулай да, иптәшләр сорый икән, сүз әйтми калу аңлашылмас дип, гадәттә утырып кына сөйләргә күнеккән булса да, бу юлы торып басты.

— Садир Хәкимович дөрес әйтә. Чынлап та шактый арылган икән. Кайбер хаталар да булды...

— Нинди хаталар, Александр Иванович?

Шулай кискен дәшүче кем дисә, Габбасов икән. «Менә сиңа шыпырт егет! Менә тиле!» Әмма егетнең нияте начарлыкта түгеллеген белгән Александр Иванович уртәлүсез җавап бирде:

— Әхлакый тәрбия хакында уйлап житкермәгәнбез, Нажар Зәбирович. Шуның аркасында кайбер кыенлыклар барлыкка килде. Кеше хакына, бөтен кешелекне сәламәтләндерүгә, камилләштерүгә багышланган тырышлыклар, иң гуманистик ачышлар да, явыз затлар кулына эләксә, һәлакәтле кодрәткә әйләнә ала. Кайчандыр бик гади булган күкерт мылтык һәм туп эчендәге дарыга әйләнгән кебек. Атом төшенең таркалуы тормышны юкка чыгарырлык көчкә әверелгән кебек. Безнең саксызлык аркасында пәйда булган кара кабан — әнә шундый куркыныч хакында кисәткән карачкы ул. Әйе. Төшендекме? Шулай. Кешенең баш миенә, геннарына үтеп кергән фәнни оешмага намуслы кешеләр генә җитәкчелек итәргә тиеш. Мин үземне шул ышанычны аклый алдым дип әйтә алмыйм.

— Минемчә, бу гаять житди мәсьәлә хакында махсус сөйләшү булыр әле. Шулай бит, Александр Иванович? — дип, Садир Хәкимович директорны якларга ашыкты.— Александр Иванович һәрвакыттагыча зирәк фикер әйтә. Кушылам.

— Инде шул,— диде директор,— миңа ял чынлап та зарур. Ә соңыннан карарбыз.

— Дөрес, Александр Иванович, галим пенсиягә чыкмый. Директор

гына чыга. Сезнең акыллы киңәшләрегезгә без һәрвакыт мохтаҗ булачакбыз.

— Рәхмәт, бүтән сүзем юк,— дип директор бөтенләйгә тынды һәм шуннан соң тавышка куярга нәүбәт җитте.

«Александр Ивановичка сезнең исемнән, Гыйльми совет исеменнән яхшы эшләгәне өчен рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез», дигән сүзләрне кул чабып хупладылар. Аннары көн тәртибенә яңа директор сайлау куелды. Беренче сүзне иң өлкән галим — Александр Ивановичның якын дусларыннан берсе, үзе теләп, хәтта ашыга һәм каушый төшеп, тәкъдим кертте:

— Соңгы вакытта, барыгыз да, беләсез, үзенең күренекле гуманист булуы белән дә, гаять актив җитәкче буларак та безнең хөрмәтле якташыбыз Садир Хәкимович Шаһгалиев җәмәгатьчелек ихтирамын казанды. Дөресен генә әйткәндә, мин бүгенгесе көндә аннан да кулайрак кандидатура күрмим.

Аннары, директив оешма вәкиле — моңарчы тыйнак кына утырган Рим Салихович калкып корыч баритон тавышы белән үзенең һәм башка иптәшләрнең уртак фикерен хәбәр итте. Ахырда шуны өстәде:

— Дөрес әйтәсез, иптәшләр. Иптәш Шаһгалиев Садир Хәкимович гаять кешелекле, саф намуслы кеше. Зур оештыру талантлы барлыгын да раслады. Безгә бит галим генә түгел, каты куллы администратор да кирәк. Садир Хәкимович безнең уртак ышанычыбызны аклар дип уйлыйбыз.

Башкалар исә, аның тукталуын гына көткәндәй, ярыша-ярыша ул әйткән матур сүзләрне җөпләп, яңадан-яңа уңай сыйфатлар таба тордылар. Нажар белми йөргән икән... нотыкларны гаҗәпләнеп тыңлады: «Менә кем белән эшләгәнбез, үз бәхетебезне үзебез белми яшәгәнбез! — дип уйлады ул.— Оят, валлаһи!»

Күз алдында — чират. Этеш, төртеш, кычкырыш. Берәү, икәү, өчәү тәртип боза, ә калганнар... калганнар берни эшләми — сукранып тын тора. Алда — кассамы, мәңгелек хәзинә тишегеме? Шуннан алалар — кем сугышып, кем чират белән. Чиратсызлар алданрак өлгерә, элгрәк эләктерә: акчаны, мактау кәгазьләрен, данны, дәрәҗәне, эш урынын, директорлыкны... тагын, тагын нәрсәләрне? Хәтта мәхәббәтне?

Калганнар тын тора — Александр Иванович та, Нажар Зәбирович та, башкалар да... Ник? Ник?

Инде менә тагын тавыш бирергә вакыт җитте. Бер каршы тавыш барлыгын белеп, Нажарга тагын мәгънәле карап алганнан соң, яңа директор тиз арада бүлмәдәге һәр кешегә ихлас елмаю бүләк итеп чыкты. Ул үзенә ышаныч күрсәткән хөрмәтле хезмәттәшләренә рәхмәтләр яудырган мәлдә, Нажар икенче төрлерәк уйларга җөрьәт итте: «Менә бит ничек күңелле — ялган акча ясаучы максатына ирешә — баеды. Ялган җиңүче — ялган батыр, ләкин ул барыбер — җиңүче. Рыцарь җиңелде — аңа хәзер ышанмыйлар, ышанмаячаклар».

Котлаулар, яңа директорга уңыш теләүләр. Бәйрәм, шау-шу.

«Менә бит ничек күңелле: Һабил үзенең туганын үтерде. Кабилне. Аңа гынамы? Тагын кемне? Александр Ивановичны? Аны гынамы? Ә Нажарны ничек? Ул исәнме әле?»

Дустын котларга үзен мәҗбүр итә алмыйча, Нажар бүлмәдән ялгыз чыгып китте. Юлында беразга тукталып, күзләрен сыпырып куйса да, көн-барыбер яктырмады — ямьсез, шыксыз килеш калды.

Исерек кешедәй чайкала-чайкала, Фәнүзә бүлмәсенә таба китте. Ул анда керде, Фәнүзәне күрде дә бугай, ләкин таныды дип әйтү җайсызрактыр, Фәнүзә нәрсәдер әйтеп ирен култыклап урамга ук алып чыкса да, ул һаман мәгънәсез тәкрарлавын белде:

«Инде кем, кем генә ярдәм итә алыр?»

Аның исеме — Фәнүзә. Кайда ул? Кайда?

Фәнүзәң янында гына — синең белән бергә атлый.

Урам. Салкын жил. Зиһенне жилләтергә нәкъ шул кирәк тә. Ир белән хатын салкын жилле урамда йөри — бүтән беркайда да урын тапмаганнар гүя ки.

— Ялган вакытлыча гына жиңә...— дип, ир үзен ышандырырга тырыша.

— Ләкин бит без дә вакытлыча гына яшибез, Нажар. Ә алар яшәп кала... Эшебезгә житәкче булып Садир Хәкимович калды. Ул үзе, әшнәләре, дуслары... ни генә кыланмаслар? Без шул кешеләргә тагын бер кабат яшьлек бүләк итәргә тиешме? Мәңге тантана итсеннәр өчен? Ул жәмгыять әшәке жаннар жәмгыятенә әверелү мөмкин, ә житәкчесе — диктаторга. Шуңа үлемсезлек бүләк итәргәме? Бу инде сугыштан да начаррак булачак.

— Артык каушарга да ярамый. Ни генә әйтсәң дә, болар бит сугышның кан коелмый торганын сайладылар. Бәхәсне хәл иткәндә, кулларына күсәк тә, хәнжәр дә, мылтык та, пистолет та алмадылар. Хәтта тавыш күтәреп трибунага да чыкмадылар. Бөтенесе әдәпле хәл ителде. Бәхәсләрнең бу рәвеше жәмгыятьнең, цивилизациянең югары үсеш дәрәжәсен күрсәтә торган мисалдыр.

— Ә күңелгә барыбер алама юшкын утырды.

— Алар уйлаганча ук түгел. Алар сине акылдан яздыра алмадылар, буталдылар. Бөтенләй тиешсез кешеләре шашты.

— Минем дә нәрсәдәндер арынасым, чистарынасым килә. Совхозда хайваннарга хезмәт итү чистарак эш булыр сыман. Мина да шунда көчү хәерле.

— Рәхмәт.

Ир белән хатын шул вакыт урам уртасында кул кысыштылар.

* * *

Ләкин аларга жиңүче булып китәргә туры килмәде. Отпуск беткәннән соң икенче көнне гариза бирергә дип калага кайткач, телефоннан яңа директор үзе эндәште:

— Исәнме, Нажар. Кәефләрең ничек?

— Кәеф? Искиткеч.

— Ярап тора дигән сүзме инде бу?

— Кайберәүләр теләмәгәнчәрәк дигән...

— Ярый. Син минем янга иртәгә сәгать уникегә кил әле.

— Нишләп алай бик тәгаен?

— Би-ик мөһим бер эш турында сөйләшәсе бар.

Чак кына нервланып әйтте Садир бу җөмләсен. Димәк, хәерлегә түгел.

— Соң... би-ик мөһим булгач, нишлисең, барырмын.

Сүз шуның белән бетте. «Мөһим эш»нең нәрсә икәнен Нажар сорамады, тегесе әйтмәде.

«Башланды! Башланды кызыклар! Башланачак!» — дип уйлады Нажар һәм ялгышмады.

Сәгать төгәл уникедә директор кабинетына килде. Кабул итү бүлмәсендә ук күрештеләр. Кул биргәндә, Садир күзләрен яшерде. Үз аламалыгыннан ояламы? Юк, мөмкин түгел, сүзнең кискен төс алуыннан курка. Әнә бит, кабул итү бүлмәсенең нәкъ ишек төбендә аның хатыны утыра. Кулында мылтыгы гына юк — нәкъ сакчы... Юккамыни?

Юкка гынамы дисең, үз хатынына һәм шул ук бүлмәдә утырган тагын бер-ике хатын-кызга Садир бөтен торышы һәм тавыш төсмерләре белән ялварып:

— Без хәзер сөйләшәбез,— дип, үзенчә серле итеп карап куйды.

Бу өч сүздән: «Алай-болай хәл кискенләшә калса, уяу торыгыз»,— дигән мәгънәне аңлау ансат иде. Билгесезлек бераз эчен тырнаса да,

иптәшенең каушый төшүе кызык тоелып, Нажар сизелерлек үк ачык елмаеп куйды. «Директор икәнлегенә әле дә ышанып бетми, димәк».

Үз урынына утырды яңа директор. Карашын тагын яшерергә һәм чәчсез башын да, өстәлне дә, фикерен шомартырга тырышып ышкыса да, җайсызлыкны җиңә алмыйча, сүзен шактый интегеп башлады:

— Мин әлбәттә... бу очракта... кушканны гына үтәүче, ыһы...— Нажар аңа ярдәм итмәс өчен юри сүз кушмаганны сизеп булса кирәк, ниһаять, кыюлана төште.— Сүз синең мөдирлектән китүең турында бара. Син безгә шул теләгеңне әйткән идең. Рим Салиховичка да барып җиткән шул фикер. Синең китүеңә алар да каршы түгел.

— Аларга кайсыгыз барып әйтте?

— Анысы инде...

Нажар ни әйтергә белмичәрәк, аптырабрак торды. «Минем андый сүзне әйткәнем юк, нишләп алай гайбәт белән эш йөртәсез?» — дип куярга мөмкин иде. Ләкин моны яңа директорның үз файдасына боруы ихтимал. Болай да шактый файдалана белгән бит — Нажардан алдарак өлгергән әнә: Нажар үзе китми, аңа без тәкъдим ясадык,— дияргә җайны тәки оештырды дус кеше. Җитмәсә, урамга чыгарып ташларга һич җыенмый:

— Җитәкче иптәшләр әйтә — төп эшенә бөтен көчен бирә алырлык шартлар тудырырга, ярдәм итәргә кирәк ди.

— Рәхмәт сезгә, иптәшләр.

— Менә ичмасам, егетләрчә,— дип эләктереп тә алды Садир.— Иптәшләр әйтә: бөтен кешелек турында кайгыртучы андый егетләргә ярдәм итәргә кирәк ди.

— Нинди олуг кайгырту!

— Син шул ук лабораториядә каласың, өлкән хезмәткәр булып. Тиздән анда конкурс игълан итәчәкбез. Кайберәүләр белән хушлашырга туры килүе бар. Ләкин сиңа кагылырга җыенмыйбыз.

— Кайберәүләргә Фәнүзә Кадыйровна керәме? Сезнең бит юлларыгыз аерылды.

— Ихтимал.

— Димәк, мин дә китәм.

Бу сүзнең чын булуын теләсә дә, Садир Нажарның чыраена карап аптырабрак калды: «Шаяртамы, чынлап әйтәме?» янәсе. Шунлыктан Нажар кабатларга тиеш булды:

— Чынлап әйтәм, иптәш директор.

«Директор» сүзенә артыграк басым ясалуын сизгән Садирның үпкәләмәскә көче җитте:

— Алайса сүз бетте!

Садир сөйләшүнең җиңел тәгәлләнүенә гаҗәпләнү белән бергә, ансат котылу шатлыгын да яшерә алмыйча, «егет икәнсең» дип, ишеккә хәтле озата барды. Шунда гына Нажар:

— Сиңа да егет булу мөмкинлеге бар иде,— дип кәефне боза язды.

— Ничек?

— Хатын-кыздан болай ук үч алуны, гафу итегез, затлылык галәмәте дия алмыйм.

— Нажар Зәбирович, что син! Нинди үч! Дөрес, ул бөтен коллектив алдында минем битемә төкерүчеләрнең берсе булды. Синең сүзләрне дөресләргә маташып, Александр Ивановичка да кереп әләкләгән. Ә мин аның өчен, җанымны гына кисеп бирмәгән кеше. Ләкин... ләкин...

— Гаризалар иртәгә сәгать икедә синең өстәлдә булыр.

— Гаризалар! Хатын хакына гомер бәрабәре торырлык эштән баш тарталармыни? Чын галим эшеме инде шушы?

— Син юкка курыктың — мин беркайчан да директорлык вазифасына кызыкмадым бит.

— Нажар Зәбирович!

— Миңа каршы көрәшүеннең сере ап-ачык күренеп торды — суга төшкән кара таракан кебек.

Кул бирмичә генә чыгып китте Нажар. Ишек төбендә тамаша кылырга жыелган хатыннар төркеме тагын да куера төшкән иде. Ләкин алар өчен кызык бөтенләй була алмады. Жәнжалга, яңа кычкырышны күрергә, ишетергә әзерләнеп килгән мескеннәрнең кәефләре кырылды төште.

Шушылар гына житмәгәндәй, өйгә кайтышлый, больницада яткан иптәш очрап, янә бер начар хәбәр әйтеп салды:

— Яков Моисеевичка, безне үлемнән коткарган кешегә, инфаркт булган. Ниндидер командировкадан кайткач ди.

Юл буе изге кешенең сурәтен күз алдына китерергә тырышып атлаган Нажар: «Андый кеше үзе китсә дә, дөньяда төсен калдырырга тиеш», — дип уйлады.

* * *

Инде нәрсә?

Калганы — вакытка.

Совхозда эшләү Нажар өчен яңа дөнья ачу белән бер. Ни генә әйтсәң дә, дипломатия дигән нәрсәне аның жене сөйми бит.

Хәерлесе шул: Нажарга директор бөтен кеше алдында бер генә бурыч куйды:

— Без нәселле сыерлар һәм бүтән төр маллар сатып алуга күп акча түгәбез. Максатыбыз — ул чыгымнарны киметү. Сез аны үз өстегезгә ала аласызмы, иптәш Габбасов? Ягъни, нәселләрне без үзебез яхшырта алачакбызмы?

— Алачакбыз.

— Ул очракта без сезне башка эшләрдән азат итәбез. Ягъни, ирекле художникка әйләндерәбез. Шулай диләрме әле?

— Төшендек, иптәш директор.

Шул көннән соң Нажар лабораториягә тулы хужа булып калды. Гадәти эш, гадәти шөгыль, гадәти күзәнәкләр, аксым агышы, геннар, ходай хикмәтенә якынлашу, табигать белән бәхәскә керү — йокысыз төннәр... Ижаттан аерган афәтләр артта калгач, күңел үз жыпкысына кайтырга тиеш иде кебек. Ләкин тормышның көен бозган яңа хәбәр күңелен сискәндереп жибәрде.

Совхоз авылларының берсендә яшәгән бер әби күрше авылдан күчтәнәчләр күтәреп кайтып килә икән. Аяклары ул уйлаганнан акрынрак атлаганга, кичкәрәк калган. Әңгер төшкән бер мәлне авыл кешеләре бик каты кычкырган хатын-кыз тавышын ишеткән. Коточкыч тавыш, якын-тирә кешеләрнең үзәкләрен өзеп, жаннарын калтыраткан. Фажигага ышанмыйча ике-өч көн азаплансалар да, ачы тавыш һич онытыла алырлык түгел: әби чынлап та юкка чыккан бит. Исән кеше атна-ун көн буе нишләп күзгә күренмәсен, ди. Кемнеңдер күреп калуына караганда, әбине кешегә охшаш кабан ашаган...

— Галиәкбәр абзый, сез ничек уйлыйсыз, кеше ашаучы ерткыч яшәргә тиешме, әллә юкмы? — диде Нажар авыл агайларының берсенә.

Абзый, бу нинди тиле сүз дигәндәй, авыз-борынын жыерып, учекләгән ымлыклар чыгарса да, авылдагы яңа кешегә каты бәреләсе итмәде — сакал-мыегын сыйпап шомартты да тыныч кына жавап кайтарды:

— Без, ни, шулай уйлыйбыз, энем. Сугышта йөргәндә, телебездән: «Үтерүчегә — үлем!» — дигән сүз төшми иде. Тешли башладымы, этне дә юк итәргә туры килә. Бүтән ни чара?! Без шулай уйлыйбыз, знамы дискет. Шулай кем, энем.

Гәп жанлана төште.

— Кабан — жинаятьче. Кылган явызлыклары өчен жавап бирергә тиеш. Һәркем тормыштан үзенә лаекны ала,— диде Галиәкбәр янында утырган кыска муенлы карт.

Каптырылмаган кара пиджак эченнән ак майкасы һәм ындыр табагы чаклы, йонлач күкрәге күренеп торган яшь механизатор:

— Аның исәбендә — урманда сөякләре генә табылган Хөснибикә әби,— дип җинаятьнең иң зурысын искә төшерде.

Нажар үз белгәнен өстәде:

— Аның исәбендә — безнең Александр Иванович.

— Аның исәбендә...

— Котырса, хәләл малны да тотмыйлар, әйе. Хайван да, адәм дә үз башына котыра.

Тәмәке суыра-суыра әйтелгән фикерләр шул рәвешле кабанның табигатен дә, язмышын да ачыкладылар. Аның явызлыгы кан белән үк килгән — үз ишләрен, бала дуңгызларны бәләкәй чагында ук тешләп чинаткан, шуннан кызык тапкан икән. Үсә төшкәч, ата дуңгызларга гына үчләшә башлаган һәм сугыша-сугыша, үз җенесеннән булган барча чучкаларны калтыратып тоткан, һәм, шул рәвешле, көтү башлыгы булып үрләгән. Бәлки матур гына яшәп тә яткан булыр, үзе кебек дуңгызларны сөяркәләре-хатыннары ярдәмендә тагын-тагын, тагын да ишәйтә алган булыр иде дә бит, әмма, әлеге дә баягы, характеры харап итә — хәтта дуңгызны да. Усал булу белән бергә, ул артык горур да икән. Уңышлардан тиз масаеп өлгергән.

— Менә шулай,— дип тәмләп сөйләргә керешге Галиәкбәр абзый.— Әйе. Көтү башлыгы булган кабан олы юл аркылы чыгышлый, автомобиль килгәнен күрсә дә, башта курыкмады, көтүен саклап, горурана атлавын белде. Машина үзе курыксын, янәсе. Ә машина шулай ук куркырга теләмәде. Чатырдап-чатырдап юл читенә тәгәрәүне артыграк күрде. Бу вакытта инде кабан үзенең нишләгәнен, нишләргә тиешлеген абайламыйча, олы юлдан үзе дә баштүбән мәтәлеп китте. Мәтәлсә дә, «ә» дигән арада янә торып, бар көченә урман эченә,куаклыкка томырылды. Җилләр генә исте кабан артыннан. Күзләре дөньяны яңадан күрә башлаганда, ул инде бозлы су уртасында иде. Күл өстен кар күмсә дә, астан язгы су йомшартканга күрә, боз кабанны күтәрә алмыйча харап иткән... Көзге боз көзге калынлыгы булса да ышан, язгы боз ястык калынлыгы булса да ышанма, дигән акыллы китап. Ә дуңгызга нәрсә? Китап укыймыни ул дуңгыз? Укымагач, кайдан гыйбрәт алсын? Бәкедә аңа салкын суның һәм ләмле күл төбенең нәрсә икәнен озак кына өйрәнергә туры килә килүен. Әмма бу гыйлем озакка җитәрлекме икән?

Яшь механизатор аны җөпләп:

— Ярый әле без, басудан салам ташыганда күреп, ярдәмгә килдек,— диде.— Сәнәкләр, колгалар белән бозны ваткалап, дуңгызны ничек булса шулай коткардык тәки. Бу мәлдә чучканың тәкәббер кыллары күздән югалган, соп-соры һәм кап-кара бозлар белән капланган иде.

— Кабанның монда ничек килеп эләккәнен без, Нажар энекәш, ул чакта белми идек шул. Белсәк ки, коткарырга бик үк ашыкмаган булыр идек. Әйе, кем, туган. Кабан бу юлы хәтсез җиңел котылды. Әмма шуннан соңгы тормышы барыбер бозылды, көйсезләнде. Әлеге җинаятьтән соң ул ялгызлыкка дучар ителде. Ничекме? Анысы болай. Үзенең элеккеге көтүен усал дуңгыз артык озакламыйча, интекмичә генә янә таба алды. Бик пычранып беткәнгәме, әллә яңа «юлбашчы» ул якта яулап алган дәрәҗәсен бушлай гына кире кайтарырга теләмәгәнме, һәрхәлдә, бу кабан көтүгә инде кабат кушыла алмады. Килә башласа, яңа «юлбашчы» аны куа. Сугышып карарга рөхсәт, әмма хәл мөшкел. Салкын һәм пычрак су, комсыз ләм аның куәтен шактый какшаткан, знамы дискет.

Галиәкбәр абзый нотыгын механизатор егет очлап куйды:

— Трактор белән печән ташыганда болында без икенче юлы да гаҗәп хәлгә юлыктык. Урман кырыенда — бүреләр көтүе. Бүреләр, ни хикмәттер, печән кибәненә сикерәләр дә кире чигенәләр, чигенәләр дә кабат шунда ыргылалар. Бүреләрнең әле моңарчы печән ашаганнары юк бугай. Алар печән куышына кергән берәр кешегә һөҗүм итә торганнардыр, дибез.

Бәлагә таручыны коткару өчен, трактор белән туп-туры шул кибәнгә таба элдерттек: килдек тә бүреләр өстенә шатыр-шотыр ташландык. Ерткычлар качкач, куыштан кеше килеп чыгар дип көтәбез... Әмма... Әмма ләкин кеше түгел — дуңгыз! Дуңгыз чыкты печән эченнән, кабан дуңгызы. Килеп чыгуы булды, үзен коткарган тракторга ташлануы булды. Тешләрен ямьсез ыржайтып, тимерне кимерә, тракторны талый... Ярый әле тимер дуңгыз тешләреннән катырак, ярый әле дөньяда дуңгызларның, бүреләрнең, тагын башка төр ерткычларның тешләре үтми торган нәрсәләр була. Югыйсә... Шулай бит? Шулай. Тракторны җимерә алмаячагына ышангач, тагын аяклары атлаган якка юл тотты кабан. Тик озакламый куркуны янә оныткан булып чыкты. Аның исәбендә — якынтирә белгән ике кеше. Әби һәм директор... Шулай бит?

Тәмәке пыскыта-пыскыта кыйсса сөйләүчеләр дуңгызның котырган булуын шиксез танадылар һәм җыйнаулашып ауга чыгарга дәрт белдерделәр. Нажар:

— Мин сезнең хисләрне аңлыйм, әлбәттә,— диде.— Ләкин, иптәшләр, бу дуңгызны минем карамакка калдыруыгызны үтенәм. Чөнки минем аның белән шәхси исәп-хисабым бар. Шул исәпне икәүдән-икәү генә өзәргә тиешбез.

— Әгәр берүзеңә генә биреш мәсә... бергәләп тотынырбыз. Тере туган һәр зат яшәргә тиеш. Шулай. Әнә Локман бабай мең яшәгән. Ә Тилебашның мең көнгә дә хакы юк. Чөнки ул — табигать белән адәм хатасы. Хатаны төзәтү фарыз.

Агайлар хөкемнең шундыен расладылар.

...Әмән карт белән Нажар икәүләп күл буена килделәр.

Бирге як — дуңгызларның су эчә торган урыннары. Монда аяк басмау, адәм исе калдырмау дөресрәк булыр, дип, күлнең икенче ягына шактый урап чыктылар. Көтәр өчен ышык урын сайладылар. Тал арасы... Кыштырдавы мөмкин булган коры талларны йолкып, кисеп читкәрәк аттылар. Инде көтәргә кала. Көтә белү шулай ук ихтыяр таләп итә. Каравылчы ашыга белми, кирәк булса, бер урында мәңге карап утыра алачак. Нажар исә тормыш агышын, аксым хәрәкәтен күзәтеп күнеккән... Шулай итеп, тыныч кына көттеләр. Әмән абзый озынча күлнең бер башында, Нажар — икенче очында. Хаҗәте чыкса, карт яшеренгән җиреннән торып, кабанга күренәчәк һәм тегесе куркып, Нажарга таба китәчәк. Әгәр дә килгән юлыннан кире тауга элдермәсә. Монысы — бәхәсле, чөнки Тилебашның эчәсе бик килә бит...

Асылда ялгышмадылар. Өч сәгать чамасы үткәч... ерактан кыштырдау ишетелде. Нажарның колаклары — радио аппаратыннан һич ким булмаганча, шылт иткән авазны да элэктерергә ашыкты. Әйе, аваз бар, кемдер килә. Кешеме, ерткычмы, дуңгызмы? Әйе, дуңгыз. Чөнки ерактан булса да, борын тарту барыбер бүтән тавышлардан нык аерыла:

— Мырык... мырык...

Нажар — тораташ. Әмән абзый да шундый хәлдә булырга тиеш.

— Мырык, мырык!

Дуңгыз! Дуңгыз... тик... берәү генә түгел икән. Икәү, өчәү, дүртәү, биш, алты, җиде, сигез... тугыз дуңгыз! Тугызы берьюлы килеп, этешә-төртешә су чөмерергә керештеләр — берниндн тартыну, кыстату юк. Ә кешеләр, аларны куркытмабызмы дип икеләнгән иде. Хафаланасы түгел икән. Әмма саклану ярый, куркытмау ярый — рәхәтләнеп эчсеннәр. Боларның кешелек каршында җинаять кылганнары сизелми бит әле. Һич тә җәл түгел — эчегез, чучкалар, тик суны гына пычратмагыз. Ашыкмагыз, без түзә беләбез, көтәрбез. Сезне шушылай якыннан күреп тору үзе бер кызык, үзе бер тамаша.

Дуңгызлар күл буенда ким дигәндә ярты сәгать әйләнделәр. Эчтеләр, читкәрәк китеп йөренделәр — мыркылдап-мыркылдап килделәр дә тагын олпат кыяфәт белән генә тереклек суын чөмерделәр. Һиһаять, байтак рәхәт чиккәннән соң, арада иң зур дуңгыз моңарчы ишетелгәннән

катырак итеп чинады да килгәндәгечә үк салмак адымнар белән өскә таба атлап китте. «Юлбашчы!» — дип уйлап алды Нажар. Башкалары да бернинди бәхәссез-нисез житәкче чучка артыннан иярделәр. Менә, ичмасам, тәртип! Директорлар күрсә, мөгаен, көнләшмичә калмаслар иде.

Киттеләр. Ә көтелгәне? Әгәр дә ерак күлгә иярләшмәгән булса, озак зарыктырмас, анысы да килер. Субординация дигән кагыйдә... Тукта, чү! Әнә бит, көтү күздән югалганны көтмичә, килеп тә чыкты. Кайда гына яшеренеп торган диген!? Әһә! Тилебаш!

Килеп тә чыкты, ашыга-ашыга, су эченә кереп, чөмерергә дә керешге. Әллә, тегеләр кире килмәгәе дип шүрли, әллә артык сусаган, әллә чамасыз комсызлана. Мавыккан мәлендә эләктереп калырга кирәк.

Нажар белән дуңгыз арасы күп дисәң — ике йөз метр. Бу арадан ядрә барып житмәскә дә мөмкин. Ким дигәндә илле метр ара узарга кирәк. Ә күрешү бөтен эшне бозачак. Шул сәбәпле, Нажар шуышып барырга мәжбүр. Нишләмәк кирәк. Илле метр араны шулай узды аучы. Һәм кинәт Нажарның колагына кызы Энженең өзгәләнеп кычкырган тавышы ишетелгәндәй булды: «Әти, атма, атма!»

Шул тавышка алданып икеләнеп торганда, кабан ике аягына басты да туп-туры аның өстенә килә башлады. Нәкъ кеше! Ап-ачык дошман! Хужасына шулхәтле охшаган! Охшамаган да бугай: качып-посып түгел, дипломатия чапанына төренмичә, мылтыкка каршы күкрәген киереп килә.

«Әти, атма, атма!»

Әгәр атмасаң?

Тилебаш кинәт дүрт аякланды да... аннары... күз ачып йомган арада дошманы өстенә ыргылды. Нажарның мылтыгы шул чакта гына шартлады. Сикергән дуңгыз Әмән абзыйга алты метрлы хәшәрәт тасма-аждаһа булып күренде. Күзләренә ышанмас дәрәжәдәге могжиза абайлап, үзен дә шашкан кешегә исәпләп, кабан белән Нажар артыннан чатыр-чотыр чаба китте. Әйе, ни күрсен: Нажар кабанның сыртында утыра! Жайдакмыни — жилдерә күл буйлата. Дуңгыз урманны, тауны калтыратып, күлне чайкалдырып акыруын белә — биш аждаһа тавышын үзенә жыйган чинау белән чыелдый. Үзе чаба!

Шулай — өстенә дуңгыз ташланган мәлдә куркудан катырак сикерү аркасында булырга тиеш — Нажар кабанның сыртында булып чыкты. Атланырга чынлап тырышса, мондый ук талантлы уңышка ирешә алмаган булыр иде, әлбәттә. Әйе.

Кабанның да башы ике түгел. Барча сәбәпләр аркасында коты очканлыктан, инде ул тау сукмагы буйлап, астан өскә томырылды. Текә тауның яртысына житкәч, шунда жайдак шуа төшеп... Ялт! Бөтерчек кебек, бер нәрсәгә яраксыз таш шикелле, аска тәгәрәде. Әмән абыйсы килеп туктатмаса күлгә хәтле олагасы иде. Сулышлары тигезләнә язгач, алар шаркылдап көләргә керештеләр. Әмән абзый эчен тотып жиргә утырды.

— Жайдак! Цирк остасы! Тагын бер һөнәрең артты, валлаһи! Ай! Үтерден! Кабанны түгел, мине үтердең — көлдереп. Үләм! Ай! Уфф!

Әмән абзый хәтле булдыра алмаса да, Нажар да хәл кадәренчә хахылдарга тырышты.

— Кайда кабан?

— Тү-тү кабан! Очты тау башына.

Шулай да, ныклабрак карасалар, үләндә карасу-кызгылт таплар күзгә чалынды. Менә ничек икән хәлләр! Болай булгач, ерак китә алмас.

Фикер дөрес иде. Югала язган эзләрне барлап атлый-атлый, берзаман Тилебашның нәкъ өстенә барып чыктылар. Муенын, борынын, дулкынга ташланган дельфин шикелле сузган. Һәм шул рәвештә катып калган.

— Тилебаш!

Күзләре боз төсле — салкын, төссез. Дөньяга бу күзләр белән караган жан иясенең котыруы бер дә гажәп түгелдер. Менә ул ята — табигать хатасы... Адәм балаларының кара ижаты...

Нажар аның бер генә тере күзәнәген дә хәзинәгә салмаячак. Яман адәмнәрнең барча дуңгызлыгын җыйнап туган һәм яшәгән Тилебаш — кеше ашаучы ерткыч — яшәү белән мәңгелеккә хушлашты. Ул бары тик шуңа лаек иде.

Нажар минутлар эчендә шуны ачыкларга тырышты: күзгә күренеп торган ерткыч хаклы җәзасын татыгач, кешеләр тәмам тынычлана алырмы? Юк, тынычланырга иртәрәктер әле. Дуңгызның котыру чире кайсыдыр яшь дуңгызлар канында һаман яшәп ята бит. Димәк, ерткычлыкның ниндидер җәнлек кыяфәтендә тагы дөнья буйлата чабып китүе ихтимал. Кайчан? Бары тик шунысы гына ачык түгел. Әллә кеше шул «кайчан»ны көтәргә тиешме? Хәзер үк, яңа Тилебаш туганчы ук, аңа каршы көрәш башларга тиеш түгелмени? Әйе, корбаннар булмасын өчен, шулай тиеш. Ләкин моның өчен бөтен көтүне юк итәргәме? Алама нәселле җанвар белән бергә асыл хайваннарны да юк итәргәме? Күзәнәк яки яралгы хәлендә, бәлки, гөнаһсыз яшь дуңгыз хәлендә, урманда йөгереп йөргән, хәзергә тамыр-томыр белән ризыкланып канәгатьләнгән чагында укмы? Ә соңынтын кан исенә сусаячак яшь ерткычны ничек табарга, ничек танырга һәм ничек зарарсызландырырга?

Бурычы катлаулы адәм баласының. Катлаулы һәм тиз генә хәл ителүе мөмкин дә түгел. Һәрхәлдә — якын араларда.

Уйла, адәм баласы, шуның өчен табигать сиңа акыл бүләк иткән. Кирәк булса, башкалардан ярдәм сора. Ярдәм сорап аваз сал дөньяга, галәмнәргә.

* * *

Ниһаять, вакыты җитте: Нажар институтка килде. Кулында — төргәк...

Директор ишегендәге ачкыч Садирның үз урынында икәнлегеп күрсәткәнлектән, Нажар сорап-нитеп тормыйча гына керергә җыенгач, секретарь кыз ымсынгандай кузгалып куйды. Башта кем керәсен хәбәр итмичә генә узарга ярамый димәкче иде ахры. Тик шунда ук тынды, чөнки бу вакытта Нажар ишекне киереп ачкан иде инде. Ике катлы ишекнең икенчесе эчкә таба шулай ук киң ачылмыш. Нажар үзе исә ишекләрдән дә киңрәк булырга тырышкан ачык чырай белән, начальникка төкселәнергә һичнинди җай калдырмыйча, сәламнең иң кайнарын тондырмыш:

— О, Садир Хәкимович?! Кабинет сиңа бик килешә! Шә-әп! Молодец!

Олы төргәкне сул кулына күчереп, Нажар чын дусларча кул сузды. Ә күпме генә вакыт элек беркайчан да бу кешегә кул бирмәс кебек иде.

Тәкъдим ителгән пафосны Садир да кабул күреп торып басты:

— О, иске дуслар ташламыйлар! Менә ичмасам молодцы! Әйдә, утырып җибәр.

— Озак утыра алмам. Мин әле сиңа шундый эш белән,— дип, Нажар төргәкне чишәргә кереште.

— Нәрсә соң ул?

— Кызык әйбер бу, шәп нәрсә. Хәзер. Күрерсең дә аһ итәрсең.— Төргәкне чишеп, җәеп тә җибәрде.— Менә — кабан тиресе. Миннән бүләк.

Шул сүз белән тирене яңа директорның аяк астына ыргытты Нажир. Садир, нишләргә белмичә, ике кулы белән урындык артын кочаклады. «А» да, «бе» дә диярга базмыйча торган арада Нажар тагын ачыклык өстәргә тиеш булды:

— Ришвәт дип уйлама тагы. Бу — табигать бүләге, бушлай бирелә торган нәрсә. Үзем аттым.

— Теге... легендар кабан... Шул үзе түгелдер бит? Александр Ивановичның дошманы?

— Нәкъ үзе, нәкъ шул! — дип кычкырып көләргә ашыкты Нажар. Чөнки форсатны ычкындырмау мөһим иде.— Әйе. Һәм ул — синең аяк астында!..

Шунда гына җан керде яңа директорга. Өстәл кырыенарак чыкты. Шкаф тирәсенәрәк китеп, тирене шуннан карап бәяләргә тырышты.

— Шәп мал... Шәп... Ким дигәндә, утыз тәңкә тора инде ул.

— Иң мөһиме — ул җиңелде.

— Урманда тынычлык урнашты.

— Иң мөһиме — юл хәвефсез хәзер. Урманга теләсә кайчан кил — кабул итәрбез.

— Рәхмәт.

Гәп тәгәлләнсә дә, Нажар әле төп фикеренең әйтелмәгәнен чамалап, сүзнең кирәк юнәлешкә күчүенә җай чыгарыр өчен, үзалдына уйланган, дога укыган сыман:

Бүреләр дә түк, сарыклар да исән, инде. — Моннан ары сарыклар, бүреләр, дуңгызлар су эчәргә күл буена бергә төшәчәкләр һәм бер-берсенә матур итеп елмаячаклар.

— Монысы ни була инде? — Директор сагаеп дөрес эшләде.

— Бу шаян кыйсса гына, безгә катнашы юк.

— Ай-һай, син адәмчә генә сөйләшерсең микән? Ә азагы? Кыйссаның дим.

— Азагы шул: йодрыклар белән тәпәләшү, кылычлар белән кисешү, кара-каршы басып пистолетлардан атышу чорлары артта калды. Хәзер инде яшертен чәнчеш, агымлы ерткычлык кына яши ала — тарихи үсеш, прогресс. Шулай түгелме?

— Ихтимал, шулайдыр да,— дип, ниһаять, Садир Хәкимович килешкән төсле кылангач, Нажар урындыктан кинәт кубып аягы белән тирене шудырды да җаны өнәмәгән нәрсәне тибеп очыргандай иткәч, тагын пафослы сөйләмгә күчте:

— Иң мөһиме — Тилебаш җиңелде. Аның кемнәр өрәге икәнен үзең беләсең. Менә шул. Җәмгыять контроленнән ычкынган Тилебаш үзенең куркыныч икәнлеген, җае чыкса, үзен иҗат иткән хуҗасын да кызганмаячагын, тамагы туйгач, ялманып куячагын сиздереп ятачак. Минем йомыш тәмам. Хуш.

— Рәхмәт, зурладың, онытмам...

Садир Хәкимовичның әйтер сүзләре тагын да бар иде, әлбәттә. Ләкин ул тыйлыкты. Моның сәбәбен Нажар шулай ук белә. Матбугат аша таралган яңалык.

Фәнүзә үзенең күпьеллык тәҗрибәләрен, күзәтүләрен, язмаларын өйгә алып кайтып киткәч, биоген этәргечләр бүтәннәр өчен башланмаган өр-яңа тема булып калган. Аны дәвам итүче юк. Шундый ук сәбәп аркасында, Александр Иванович төркемендәге ми эшчәнлеге, Нажарның генетик юнәлеше дә бу институт карамагыннан алынып, башкаладагы тагын да махсусрак булган институтларга күчерелгән. Шулай итеп, чынында өч иптәш кенә түгел, өч фәнни юнәлеш эштән чыгарылган булып чыкты. Садир дус моны фаҗига төсендә кабул иттеме, әллә бик гадәти хәл дип карадымы — шуны белмәкче иде Нажар. Әмма андый аңлашуны Садир артык санады. Чөнки бу вакыйга аның җиңүенә аз булса да күләгә төшерә иде. Ләкин ул тыныч: гомерне озынайту проблемасы, әйдә, тагын бер ярты гасырга кичектерелә торсын — адәм баласы хәзергә андый ук озын гомергә лаек түгел әле. Аны әле ким дигәндә тагын ярты гасыр тәрбияләргә кирәк булачак. Шул җөмләдән, шәхси эгоизмнан арына алмаган, гомер бәһасенә тиң эшләрен җиңел генә ташлап киткән Нажарны һәм аның сөекле хатынын да. Бәлки әле Александр Ивановичның үзен үк. Бәхеткә, институт исән, директор вазифасын бетерү җае беркемгә дә бирелмәгән, эш хакы элекке микъдарында кала. Шулай булгач, тагын ни кирәк адәм баласына?!

Гәрчә, югары урын белән бергә, тикшеренү өчен дәрәҗәле темаларны

да ул үз кулына алмакчы иде дә... Аңа Нажар Зәбирович Габбасов ярдәм итәргә тиеш иде. Нишлисең — күңел теләгән һәр хыял тормышка тулысы белән ашмый бит. Табигый хәл. Булганына канәгатьлек кылыйк. Әйе, нык борчылырлык сәбәп юк: чыгышлар, җыелышлар, утырышлар калсын, бүләкләр, квартир, башка төр нәрсәләр бүлешү аның ихтыярында. Тагын ни кирәк адәм баласына?

Бер тел остасы әнә: «Тәрәзәдән башыңны сузма»,— ди. Чөнки тирәякка күренеп торган динозаврларның җирдә исеме генә калса, кандала әле дә булса иркенләп яшәп ята. Ничек кенә яши әле! Ә бөҗәк — микроблар, вируслар?! Тормыш тормыш инде ул — аның мәгънәсе хакындагы бәхәстә күп буыннар тарафыннан расланган Садир позициясе чын материалистик караш булып кала. Идеалистлар, әйдә, үзләренчә яши бирсеннәр... Алар да кирәк.

Садир боларны күңелендә генә калдырды, билгеле. «Болар тел белән әйтелми торган хакыйкатьләр. Аларның көче дә әнә шунда»,— дип уйлый Садир Хәкимович Шаһгалиев.

Нажар да әнә, ишек эргәсендә тукталып, соңгы сүзе белән чынлыкта үзенең көчсезлеген таныды:

— Без сиңа лаеклы булып чыктык. Мин сине җиңүең белән котлыйм. Молодец! — диде.

Шулай дигәч, кычкырып озак кына көлде. Гәрчә дус өчен сөенүгә, аның бәхетен уртаклашуга охшамаган иде бу көлү. Киресенчә, истерика галәмәте кебегрәк иде. Ихтимал, тәгаен шулай булгандыр да.

Кабан дуңгызы тиресен яңа директор бүлмәсендә калдырып, Нажар кабинетка бүтән кермәс өчен, хушлашмыйча чыгып китте.

Бер ай чамасы вакыттан соң аны башкалага чакыртып алдылар. Соңыннан белүенчә, Александр Иванович тәкъдиме белән эшләнгән икән монысы.

Александр Ивановичның пенсиягә китүенә башкаладагы зур белгечләр ризалашмыйча, аны шунда эшкә чакырып алганнар. Садир дус монысын да әйтми калдыруны хәерлерәк санаган булып чыкты.

Зур абруйлы киңәшмәдә Нажарның доклады әйбәт бәя алды һәм, шул рәвешле, хәер-хак дусларның соңгы янавы да сабын куыгы шикелле юкка чыкты. Җитәкчеләр гаять әһәмиятле фәнни эзләнүләргә мул өлеш кертүен әйткәч, яңа бурычлар куйганнан һәм, күп кенә киңәшләр биргәннән соң, Нажар Габбасовның академия карамагында калуын хәтеренә төшереп, боерык төсендә:

— Дәвам итегез! — диделәр.

...Кала белән табигать арасында тыныч юл ята.

Ике төрле яшәү: шәһәрдә — ял көннәре, елга буенда — эш көннәре.

Фәнүзә — гел диярлек аның янында. Ни әйтсәң дә, максат бер бит — кешелеккә хезмәт итү.

Кеше гомере...

Шулай да күңелгә һаман нидер җитми кебек. Җитәчәк тә түгелдер кебек. Моның сәбәбе — билгесезлек. Билгесезлек идеясе кайчандыр кара урманга каравылчы абзый илтеп ташлаган аю мисалында, мәңге каңгырып йөрер кебек.

Көз якынлашкач, Нажар, күп саен төнге сәгать икедә торып, кайчандыр күкрәп солы уңган җиргә бара торган булды. Ләкин инде бу төштә, беренчедән, нишләптер, солы чәчмәгәннәр, икенчедән, шуңа күрә бугай, басу үзе дә элекке түгелдер кебек һәм ул да булган хәлләрне яңадан кабатлый алмаячак сыман.

Әйе, хатаны төзәтү, аюны тормышка кире кайтару өмете матур хыял гына булып чыкты. Бер генә җан иясе дә ике кабат яши алмый. Яңадан тергезелгән аюны бәхетсезлеккә очраган элгәресенең үзеннән дә бәхетсезрәк игезәк туганы дияргә генә кала. Терелтү сабак бирде. Терелтү сабагы табигатьтә һәм тормышта кабатлануның мөмкин түгеллеген кабат раслады.

Яшәү шунда гына үз җыпкысына кайтты.
Шәһәр — авыл, авыл — шәһәр. Юл — эш.
Нажар бүген шоферга аю кыйссасын сөйләде. Юлдашы, уйлап та тормастан:

— Җаны ике булса да, безнең якка килеп чыгарга курка инде ул хәзер,— дигән хөкемен чыгарды.— Бу дөбер-шатыр дөньяга.

Ник алай әйтүенең сәбәбен Нажар, әлбәттә, сорашмады. Үзенең бүгенге томанлы көн төслерәк булган уйларына талды. Ләкин күпмедер баргач...

— Тукта әле! — дип, көйле генә барган шоферның кулларына ябышты.

Иләмсез, таныш чыелдау. Шоферның күзләрендә — гаҗәпләнү һәм каушау.

— Сез нәрсә?

— Күрәсең ич...— Ерак та түгел, кара пальтолы хатын-кыз юлны аркылы чыгып бара иде.— Мин аны кабан дип торам... Гафу итегез.

— Һы! — дип кенә куйды шофер, тиле белән бәхәсләшмим дигәндәй ымлык чыгарып.

Узышлый билгесез хатын белән Нажарның күзләре очрашты. Таңгы табигатьнең чиксез-төпсез серләре тулган күзләр моңаеп карап калды. Иртә таңда нишләп ялгыз йөри икән бу хатын-кыз? Сәбәп бер генә булу мөмкин — мәхәббәт. Сөеклесен көнгә күрсәтә алмавына караганда, гөнаһлы, яшьле, үкенечле мәхәббәт. Шулай да ул түзәр. Котырган дип кенә хәбәр таратмасыннар...

Балачакта ишетелгән җыр хәтергә килә:

Кызарып таңнар аткан чакта,
Менеп килә чокырдан.
Аска карый, өскә карый —
Гулять иткән чукынган.

Шуннан? Әгәр ул язмыш сукмагы булса? Ул чакта мәхәббәт гөнаһлы була ала димени?

Кеше үз уйларына үзе елмая.

*1984-1985.*

## Галимҗан Латыйп

### Зәңгәр ялкын

Дан калкулыгында зәңгәр ялкын,
Яктырта ул җирне, һаваны —
Дошманнарын тукмап тезләндергән,
Җиңеп чыккан утның дәвамы...

Тәүлек буе,
айлар,
еллар буе,
Ул гасырлар буе янәчак.
Алышына гомер белән гомер,
Яктылык гел алга барачак.

Олы-кече, башын ия-ия,
Ут янында антын кабатлар:
Ята монда — без яшәсен өчен
Утка әверелгән солдатлар...

Зәңгәр утлар, тыныч утлар яна,
Хәтерләрне безнең яңарта.
Көн арты — көн,
Төн арты — төн китә... —
Яктылыкны дөнья ярата.

*

Бер җырым бар минем җырланмаган,
Сиңа гына җырланырга тиеш.
Куркам ләкин, куркак булмасам да:
Калмагай дип җырланмаган килеш...

Бер сүзем бар минем әйтелмәгән,
Сиңа гына әйтелергә тиеш.
Куркам ләкин, куркак булмасам да:
Калмагай дип әйтелмәгән килеш.

Бер серем бар минем ачылмаган,
Сиңа гына ачылырга тиеш.

---

*ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙП (1912) — өлкән шагыйрь. «Адымнар», «Көчле яңгыр», «Җир җыры» һ. б. татар һәм рус телләрендә басылган утызга якын шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Куркам ләкин, куркак булмасам да:
Калмагай дип ачылмаган килеш.

Суларга да, янган утларга да
Минем белән бергә керерсеңме?..
Бер ут яна миндә көне-төне,
Син шул утта янып эрерсеңме!?

Бар булганым, җаным, тәнем белән
Әйтәм аны бары сиңа гына,
Хыялларым, өметләрем белән —
Сиңа гына — җаным сөйгәнемә!

## Сагынылган җыр кебек

Күкләрең болытсыз, зәп-зәңгәр,
Алдыңда офыклар ачыла.
Сизгер ул, өркетмә, җыр булып
Мәхәббәт киләдер каршыңа.

Ул синең бәхетең, тәхетең,
Йөрми ул чаң сугып, кычкырып.
Хаклыкны, сафлыкны ярата,
Җибәрмә син аны очырып.

Беләмсең, йөрми ул, мәхәббәт
Шомарган, тапталган юллардан.
Нәфис ул, өркә ул, курка ул
Тупас һәм боз чәчкән куллардан.

Ул сине ал итә, гөл итә,
Ул — синең гел янар чәчәгең...
Сагнылган җыр кебек матур ла
Мәхәббәт бар җирдә яшәве.

## Гитара

Гитара, гитара
Бер зыңлый.
Бер тына.
Ник болай моңлана,
Әйтәсе сүземе
Бар аның дөньяга?

Тирә-як шундый тын,
Һавалар зәңгәрсу.
Гитара кыллары
Кайчакта ярсулы,
Кайчакта ямансу.

Җыр оча, талпына,
Әйләнә ялкынга.
Егетнең бар моңы,
Кайгысы, шатлыгы
Мәхәббәт хакында.

Яшьлегең үзе дә
Бер тоташ ут бит ул.
Яшьлектә янмаган,
Өзелеп сөймәгән
Йөрәкләр юк бит ул.

Гашыйклар хыялы
Тота бу дөньяны:
Уйнасын гитара,
Зыңласын гитара, —
Өзелә күрмәсен
Тылсымлы кыллары!

## Җилфер-җилфер җилләрдә

Җәйге эссе көннәрдә
Бик рәхәттер керләргә.
Җилфер-җилфер җилләрдә
Бии-бии кибәргә.

Җилфер-җилфер керләрне
Кем чайкаган, кем элгән?
Шул керләргә карый-карый
Рәхәтләнә күңелләр.

Агармаса керләрең,
Күңел ак буламыни?
Күңелләр ак булмаганда
Дөнья яктырамыни!

Керләреннән таныйм мин
Уңган куллы кызларны.
Андый куллар салкыннарда
Эретәләр бозларны.

## Әткәм сүзе

Кеше җирен кереп сөрә күрмә,
Ызаннарга, балам, кагылма.
Көчек өрә диеп, өрә күрмә,
Ялган аллаларга табынма.

Фәрештә дип ышанып йөргәнең
Иблис булып чыкса — аяма.

Дөнья бит ул бары көчлеләргә,
Гаделләргә генә таяна.

Ата-баба гаме — дөнья яме,
Тап төшерә күрмә син аңа.
Халык бәхете өчен, илең өчен
Яныргa да кирәк, яныргa...

## Соңгы көннәренәчә

Берсен-берсе хуп күреп,
Ике карчык йон яза.
Ашамыйлар, эчмиләр —
Көн үтә дә төн уза...

Аннан алар җеп эрли,
Озын кичләр утырып.
Эшкә тисә куллары,
Почеты юк йокының.

Оныкларга оекбаш,
Бияләйләр бәйлиләр.
Озакламый кыш килер,
Менә үтәр җәй диләр.

Сабыйларның куллары
Туңмасын, аяклары...
Бала чакка ни житә, —
Уйнап үсәр чаклары!

Кайгырталар әбиләр
Кечесен һәм олысын.
Соңгы көннәренәчә
Биреп йөрәк җылысын.

# Нәҗип Мадъяров

❁

Кырлар тулып, кайнар дулкын булып
Офыкларда эссе йөгерә.
Җәй мичендә игеннәрем минем
Шул ялкыннар белән өлгерә.

Сөенеч бит күреп йөрүләре
Башакларның «йөзе килүен»!
Ул башаклар иелә төшкән саен,
Күтәрелә минем күңелем.

## Чакма чагып

Ут эчендә калды чал Европа,
Янды шәһәр, янды авыллар.
Ул елларда безнең йөрәкләрне
Өтеп үтте утлы давыллар.

Шул чакларда туган утлы уйлар
Әле дә китми безнең башлардан...
Ут эчендә тордык, үзебез утны
Чакма чагып алдык ташлардан.

❁

Гаҗәп түгел, гади бер нәрсәдән
Калкып чыкса әгәр зурлык, дан.
Гигант нарат! Ул да үскән әнә
Энә күзе кадәр орлыктан.

❁

Акыллы баш игән
Җүләргә;
Афәт килер инде
Кемнәргә?!

---

НӘҖИП МАДЪЯРОВ *(1928) — шагыйрь, «Чык бөртекләре», «Утлы кыя», «Рәшәле офыкларым» һ. б. шигырь китаплары авторы. Брежнев шәһәрендә яши.*

## Чәчәкле тугай

Җаннарыңны әсир итәрлек
Биредәге хуш ис, гүзәллек.
Һәрбер чәчәк балкый үзенчә,
Менә кайда икән бердәмлек!

## Еллар үткәч...

Төштә, урам буйлап, икәү
Каяндыр кайтып килеш...
Сөюемне белдерергә
Кыенсынамын имеш.

Төш кенә икәнен сизсәм,
Оялыр идеммени?!
Юкка чыгасыңны белсәм,
Уяныр идеммени?!

*

Дөрли ялкын күңел учагында,
Дөрләсен ул, берүк сүнмәсен.
Көйдерсен ут, юк-бар моң-зарларга
Күчәергә ирек бирмәсен.

Дөрли ялкын күңел учагында,
Дөрләсен ул, әйдә, дөрләсен.
Яна бирсен кайгыларым. Тик ут
Шатлыкларга үрли күрмәсен.

## Яши торгач беләсең

Туган җирендә дә
Туган җиреннән
Ерак яшәүчеләр
Бар икән...

# ИҖАТТАГЫ ЕГЕТ ЧАК

## РӨСТӘМ КУТУЙГА — 50 ЯШЬ



Сугыш алды елларында туган буын...

Аларның әтиләре Бөек Октябрь революциясе казанышларын ныгытуда, яңа тормыш төзү, Магнитка һәм ДнепроГЭС торгызу кебек тарихи вакыйгаларда катнашты. Илебезгә фашизм явы ябырылгач, шушы әтиләр изге көрәшкә — Ватанын, гаилә учагын һәм балаларын үлемнән коткару өчен дошманга каршы күтәрелде. Әтиләре фронтта, ут эчендә. Тылдагыларның да хәле җиңелдән түгел, йөрәк һәм беләк көчен Җиңү сәгатенә багышлыйлар. Сугыш чынбарлыгын, аның кырыс көннәрен үз җилкәсендә татыган балачак иде бу. Сугыштан соң аларның күбесенә әтисез үсәргә туры килде...

1936 елда Казанда туган Рөстәм Кутуй — әнә шул буын вәкиле. Аның әтисе — күренекле татар совет язучысы Гадел Кутуй — илнең кыен көннәрендә үзе теләп фронтка китә, Сталинградны һәм Польшаны азат итү сугышларында катнаша... Улына гомер генә түгел, язучылык очкыны да бүләк итә. Уйчан, сагышлы, артык чәчрәп тормаучан Рөстәм яшьтән үк иҗат белән шөгыльләнә башлый. Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң ул байтак еллар Татарстан китап нәшриятында һәм республикабыз телевидениесендә редактор булып эшли.

Бүгенге көндә Рөстәм Кутуй — Бөтенсоюз укучысына билгеле язучы, Казанда һәм Мәскәүдә чыккан дистәләгән китаплар авторы. Аның әсәрләре чех, румын, венгр, испан, инглиз, немец һәм башка телләргә тәрҗемә ителде. Р. Кутуй рус телендә иҗат итүче татар язучысы. Күп санлы шигырь һәм поэмалар, хикәя һәм повестьлар авторы. Шагыйрьлеге прозасында да сизелә. Ике жанр бер-берсен баета, тулыландыра. Авторның «Тамырлар» («Корни»), «Сөюнең беренче күз яшьләре» («И слезы первые любви»), «Нибары бер көз» («Одна осень»), «Уч төбендә кояш» («Солнце на ладони»), «Тормыш шундый ул» («Такая жизнь») кебек китаплары белән танышканнан соң моңа ышану кыен түгел.

Тәүге китапларының берсе «Җир буйлап барам» («Я иду по земле») дип атала. Әйе, үз иленең гражданины һәм язучысы буларак, иҗатында Рөстәм Кутуй нәкъ менә җир буйлап бара. Шигырьләрендә — лирика, романтика, тормыш җыры. Автор каядыр күккә ташланмый, җирнең үзендә тулып яткан төсләр-балкышлар белән эш итә. Шаккаттырырга тырышмый, язганнары тормышның үзендәгечә табигый. Шуңа күрә без инде ничә кабат күреп сокланган чык тамчыларына аның күзләре белән янә, сокланып, гаҗәпләнеп карыйбыз. Прозасында да табигый, салмак агыш, шатлык һәм сагыш дөньясында яшәүче реаль геройлар, тормышчан фәлсәфә. Әйтергә кирәк, сугыш чоры һәм сугыштан соңгы яшүсмер язмышы Рөстәм Кутуй иҗатында аерым бер урын алып тора. Үзе белгән, кичергән вакыйгалар. Мохит һәм тирә-яктагы кешеләр йогынтысында шәхеснең формалашкан, дөньяны үзләштергән чоры бу. Мондый әсәрләрдә моңсулык та бар, вакыты-вакыты белән кискен хәлләр дә куерып киткәли. Язучы яхшылык, рухи сафлык тантанасын зурлый, кыен хәлләрдә җебеп калмаска, тормышны яратырга өнди. Болар исә әдәбиятның гуманистик юнәлеше, тәрбияви йогынтысы турында сөйләүче күрсәткечләр.

«Гөлҗамал әби» исемле бер хикәядә баш герой үзенең оныгына: «Тормыш юлларында инсафлы бул, каршы очраганнарның аякларына басма»,— дип теләк әйтә. Әйбәт һәм кешелекле киңәш. Рөстәм Кутуйның геройлары шушы киңәшкә тугрылык саклыйлар, тормышка ямь өстәргә омтылып яшиләр.

Рөстәм Кутуй татар әдәбияты үрнәкләрен рус укучысына җиткерүдә дә актив эшли. Аерым алганда, ул Х. Туфан, С. Хәким, Р. Фәйзуллин шигырьләрен, Ә. Еникинең повесть һәм хикәяләрен русчага тәрҗемә итте.

Илле яшь — әдәби иҗат эшендә чын мәгънәсендә егетлек чоры. Тормышның ачыласы серләре әле дөнья кадәр мул. Алда — яңа эзләнүләр, яңа язмышлар, заман сурәтләре.

Рашат **НИЗАМИЕВ.**

## Рөстәм Кутуй

# ЧАТНАГАН КӨЗГЕ

хикәя



Театрга билетларны юан Гөләндәм апа тикшереп кертә иде. Аның авырлыгына агач басмалар ничек чыдагандыр.

Аның йөзен көмеш кунган, сөлектәй боргаланган кара бөдрәләр әйләндереп алган. Янып торган кысыграк күзләре, елмайганда җыерчыклар арасында калучы очлы борыны һәм кызыл бантка охшаган иреннәре әллә кайдан сәлам бирә.

Гөләндәм апаны чегән хатыны дип йөртсәләр дә, ул татарча сиптерә, чәчләрен катык белән юа, озын борынлы комганы белән мактанырга ярата һәм хатын-кызлардан көлә иде.

— Теләсәмме... әгәр теләсәм, ирләр минем артымнан түш белән шуышып йөрерләр, баскан эзләремне үбәрләр иде. Ә мин аларны үкчә белән, үкчә белән! Аннан сөлге кебек кибәргә эләр идем. Бот чабып көләрлек булсын! Алар белән баш катырып торырга...

Шул сүзләрдән соң үзе көләргә тотына. Ә куллары шәл почмагы белән уйный.

Алсу шәле Гөләндәм апаның иңеннән беркайчан да төшми. Бәлки ул төннәрен дә юрган өстеннән шул шәлен ябынып ята торгандыр. Ялгызы матур шәлне ябынып ятып, матур төшләр күрер өчен...

Көндезләрен уйнап-көлеп үткәрсә дә, кич житте исә аны сагыш баса һәм ул шәм яндырып көзге каршына барып утыра иде. Тәрәзәсенә кайчан гына күз салма, мәче башлы ябалак сыман, гел бер почмакта посып утыра. Аллы-гөлле шәле канатлар кебек салынып төшкән. Шәм яктысы көзгенең ике ягындагы кара бушлыкны ялый...

Аның йөргән кешесе Җабраил абый ишегалдында самавыр, примус, сәгать кебек нәрсәләр төзәтә иде. Җабраил абый эшли, ә Гөләндәм апа аның артына килеп басып, шәл чуклары белән уйный. Шул гына истә калган.

— Әнә кара фәрештәң капка төбендә таптанып тора. Бар, йөгер янына!— дип аптекада эшләүче Клава аңарга төрттереп ала. Ачуы килүдән түгел, болай гына. Кем янынадыр йөгереп чыгасы, гармун көенә бөтерелеп туфли туздырасы килүдән генә.

— Телеңне тый, фетнә! Юкса янтайган өеңә аяк та басмам. Башка эшең булмаса, әнә зиратка бар да попка сәдака бир!

Менә ничек оста җавап бирә, аннары авызын ерып көлә иде Гөләндәм апа.

— Үземнеке итәм бит Җабраилыңны, әй!— дип. Клава да талпынып куя.

— Кая инде сиңа, буш куыкка!— ди Гөләндәм апа, үтергеч итеп.— Синең аша бит коймадагы белдерүләрне укып була... Тавыкларны санарга да уңай...

— Ә син... син... Чегәннәрдән шәл чәлдереп!

— Җабраил бүләк итте!— дип масая Гөләндәм апа. Аннары үзен көтеп торучы Җабраил абыйга кычкыра:— Әй, самавыр остасы! Бүләк иттен бит, әйеме!

Кызыл күлмәк кигән Җабраил абый кояшта басып тора. Алтын тешен ялтыратып ала.

Бераздан ул күренми башлады, юкка чыкты. Сугыш аны да, аптекада эшләүче Клаваны да үзенә йотты.

Бервакыт мин Гөләндәм апаның:

— Харап кына булды башкайлары,— дип сәер пышылдавын ишетеп калдым.

Тәрәзәләр күптән инде электр утында коена, ә Гөләндәм апа һаман базардан шәм ташый.

— Исәнме, Шура! Нихәл, Катя! Ничек соң, яшәп буламы? Үрчисезме?

— Үрчибез, ишәябез, Гөләндәм,— дип елмаешып җавап бирәләр хатыннар.— Син һаман шәм яндырасыңмы?

— Пробкаларны таракан кимергәнгәме, счетчигы начар эшли. Башлары беткере! Ә шәм ул сыкрап янса да, яктылыкны бирә. Миңа күпме кирәк инде...

Шәмнәре кәрзиндә базардан алган тавык түшкәсе белән бергә ята, икесе дә алтын сары. Майлы шәмнәр Гөләндәм апаның тырпайган бармакларын хәтерләтә. Ак фитильләре чучка койрыгы кебек бөгелешкән.

Кич җитеп, күктәге ай дага бөгә башлау белән, Гөләндәм апа театрга билет тикшерергә китә. Аяклары күзгә күренмәс тузанны туздыра, бизәкле оеклары ялт та йолт килә. Чәчәкле шәле белән туфлиләре дә күзнең явын алырлык. Үзе дә гөл кебек ул Гөләндәм апа. Гөл кебек!

Гөләндәм апа театр ишеге төбендәге биек аркалы урындыкта патша хатыны сыман утыра, аякләре күкрәгенә тия яза, иңендә зур-зур гөлҗимеш чәчәкләре төшкән шул ук шәл. Ара-тирә тулы беләкле куллары белән чәч бөдрәләрен төзәткәли, йөзендә елмаю йөзе. Артистларга да алыштыргысыз инде, билләһи!

Затлы костюм кигән бер абзыйның аны бу урындыктан сәхнәгә күчәргә үгетләвен үз колагым белән ишетүем хак.

— Син, Гөләндәм, пәрдәне генә ачарсың. Сүз әйтергә дә, җырларга да кирәкмәс... Чыгып бер күренсәң шул җитә — зал минуты белән сәҗдәгә китәчәк.

Аннан ул күктәге тулган айны, мичтән чыккан нindидер бәлешләрне телгә алырга кереште. Мин инде калганын тыңлап тормадым, малайлар янына йөгердем.

— Гөләндәм апаның артистка буласы килә икән. Бер абый аны үгетли, конфет белән сыйлый. Риза булсаң, яландай зур көзге алып бирәм, ди!

Без ул абыйның пинжәген каппан, тукымасының юл-юл сызыкларын карыйбыз. Чалбарларының балакларын тарткалыйбыз, кыскасы тигәнәк кебек сырышабыз.

— Болай узынсагыз, икенче операга да кертмәм, әрсез алабайлар,— дип Гөләндәм апа безне шелтәләп ала.

— Ул сине артистлыкка кодалый ич!

— Курыкмагыз, мин үзем теләсә кемнән бишбармак ясый алам,— дип кенә җибәрә Гөләндәм апа.

Без, бушлай кергән малайлар, театрның бөтен почмакларын айкап чыгабыз. Музыка безне, җәймә белән җилләткәндәй, иркәли, куллрыбызда белдерүләр кыштырдый. Иң яраткан кешебез — Иван Сусанин. Кар көртләренә батып, таң турындагы соңгы җырын сузганда бигрәк тә ошатабыз. Аны кызганудан күз яшьләребез сытылып чыга. Фронтта үлгән әтиләребез искә төшә иде.

Гөләндәм апа кайчакта галеркага менеп, безне барлап китә. Җылы зур кулларын баш түбәбезгә куя. Шундук җанга җылы иңә.

Акча дигән нәрсәне без белми идек. Шуңа күрә буфетка керү юк. Буфетта эшләүче Сания апа көмеш акчалар салынган тәлинкәсе янынн бер дә китми. Ара-тирә иренендәге иннекне генә яңарткалап ала.

Тәнәфес җитте исә паркетта шуа башлыйбыз. Безгә көшелдиләр, тыялар, ачуланалар, куалар, тик берсенә дә исебез китми.— гаделсезлеккә күнегеп, каешлана барабыз. Безне алай гына җиңәм димә. Өстебездә кырыкмаса-кырык ямаулы кием, күтәрелеп карарлык та түгел, бары телебез генә кычыткандай чага.

Иң кыены — стена буйлап сугылган көзге каршыннан үтү. Үтмичә дә булмый — әйләнеч юлы юк. Шулай узып барышлый үзеңә күз саласың да, оятыңнан җир тишегенә керердәй буласың.

Сугыштан соң да тормыш тиз генә җайга төшмәде. Дөрес, ачлык үтте, әмма туклык алай тиз килергә ашыкмады. Ә көнләшүне без белми идек. Шулай да, тәлинкәдә баллы пирожныйларны күреп, төкерекне йотып куйган чаклар булгалады.

Аның каравы зур көзгеләрнең ялтыравы, аларның боздай булып стенадан агып торуы, җемелдәве безгә чиксез бәхет китерә, кабырга астында нидер ашкынып тибә иде.

Тәнәфес бетеп, кыңгырау чылтыраса да, мин һаман аста йөрим. Йөрәк күкрәктән сикереп чыгардай булып тибә. Аяк очларына гына басып көзгегә якынлашам. Күзләремне шар ачып, үз-үземә төбәләм. Аннары, хәер сораган теләнче кебек, кулымны сузам да борын аша:

— Зинһар мәрхәмәтегездән ташламагыз!..— дип эндәшәм.

Көлмим. Өстемдәге кыршылып беткән куртканың терсәкләре ялыкйолык килә.

Тотрыксыз томан эчендәге көзге буйдан-буйга чатнап төшкән. Кара яшен булып сузылган эз мине урталай бүлә. Көзгедән миңа ниндидер бер ят малай карап тора, аның күз карашы бөтен барлыгымны көйдереп ала.

Мин кинәт кыланчык бер хәрәкәт ясыйм, чөнки, шөкер театрдан чыккан да юк — сәхнәдәге кылычлар аһ-зар, йөз төрле кием-салым көн дә күз алдында. Мин бәлки малайлар үлеп яраткан хәйләкәр Хуҗа Насретдин булып кыланганмындыр. Шулчак көтмәгәндә чатнаган көзге эченнән шәл ябынган Гөләндәм апа килеп чыгып, янәшәмә басмасынмы! Шәл канаты белән элэктереп алып, мине каядыр җитәкләп тә китте.

Бераздан буфет урындыгына китереп утыртты.

— Тавышың чыкмасын, кара аны,— диде ул.

Үзе сакланып кына буфет бүлеме артына керде дә тәлинкәдә яткан ике пирожныйга үрелде. Шунда чүт кенә пыяла челтерәп куйды, киеренкелектән Гөләндәм апаның йөзе гөлҗимеш чәчәгедәй алсуланды, шәлендәге чәчәкләр төсенә керде.

Мин дә тыным кысылган хәлдә аның хәрәкәтләрен, сузылган чакта мәченеке кебек бөгелеп килгән аркасын, итәгенең җилфердәп алуын күзәтеп торам.

Буфетчы хатын Сания исә стена артында кем беләндер серләшеп утыра, ара-тирә аннан фужер челтерәве ишетелеп куя. Бу тегә озын абый иде, ахрысы. Ул Сания апаны да артистка булырга үгетли, аның алдында алтын-көмеш, энҗе-мәрҗәннәр тулы сандыкларны ача. Минем башым әйләнә, бары шуны гына ишетеп калам.

— Аша, тыгыла күрмә,— дип, Гөләндәм апа уйларымны бүлдерә.

Пирожныйлар авыз суларымны китерә.

— Без вакытны алай әрәм итмәбез,— дип, Гөләндәм апа җиңел сулап куя. Аның нәрсә әйтергә теләгәнен мин аңлап бетермим.

Пирожныйларның тышы ката төшкән, ә кремы кырыеннан җәелеп аккан. Эчендә исә — татлы һава.

— Тешеңне сындыра күрмә,— ди Гөләндәм апа.

Киң шәлен бөркәнгән килеш миңа карап утыра. Аннары капылт кына:

— Синең кебек улым булсын иде,— дип әйтеп куя. Бу сүз ыңгырашу кебек ишетелә.

Шулчак ул башын артка ташлагач, муенында күренеп киткән ике тирән җыерчык мине гаҗәпкә калдыра. Гүя кемдер аларны мәңгегә сызып калдырган.

Гөләндәм апа башын төшергәндә мин инде белә идем: ул картайган, авырайган икән. Ашыгып-кабаланып эшләп йөргәндә генә ул яшь, йөзе дә шат күренә, ә шәл астындагы Гөләндәм апа сары төргә яфраклары коелган көзге салкын җир кебек. Җабраил абый кочагының җылысын шәм генә алыштыра аламыни?..

Пирожныйларны мин бик тиз кабып йотам. Валчыкларына хәтле чүпләп авызга озатам. Гөләндәм апа шәл чите белән йөзен җиләтеп ала. Йөзе ни өчендер агарынган шикелле тоела. Бәлки ут яктысында гына шулай күренгәндер...

Менә ул кыймылдап куя, кулларыннан ниндидер калтырау уза. Аннан тыгыз итеп шәленә урана. Кинәт яшәреп китә, кара чәч бөдрәләренә көмеш кунган, ару-талуны белмәстәй үткен бер хатын-кызга әверелә. Аның тирәсендәге һава да хәрәкәткә килә.

Өстә кемнеңдер ария сузуы ишетелә.

Гөләндәм апа мине, адашкан кешене коткаргандай, өскә алып менеп китә. Караңгы баскычтан күтәрелгәндә арыган тавыш белән:

— Көзге алдый ул, ышанма син көзгегә. Син суга кара,— дип көлеп куя.

— Ул чатнаган,— дидем мин.— Елан шуышкандай бер эз пәйда булган.

— Әле кичә генә исән иде бит. Ничек чатнаган? Кем төзәтер инде аны, я хода? Шул гына җитми иде...

Русчадан **Солтан ШӘМСИ** тәрҗемәсе.

# Сафуан Муллагалиев

## Бер яктылык

Белә-белгәнемнән бирле
Бер яктылык килә миңа —
Ап-ак дөнья, ап-ак язмыш
Булып, мине кинәндерә...

Күңелләремә тула ул
Аңга тула, җанга тула.
Йөрәк белән сөйләшә ул —
Тыңлап, гүя, дөнья тына...

Урамнар да тыңлый тынып,
Җил дә тора исми генә.
Йолдыздан килә ул балкып,
Әйтми миңа исемен генә...

Әйтмәсә дә, сизенәм мин:
Ул нур — җанга һәм аңыма
«Җир» дигән якты йолдыздан —
Кешеләрдән килә миңа.

## Гомер башы

Кем уйлаган, коп-коры җир, имеш,
Дымланыр да — күтәрелер томан...
Йолдызлар да күреп текәлделәр,
Тып-тын булып бөтен дөнья тынган...

Сентябрьнең айсыз аяз төне,
Тик йолдызлар җемелдәшә күктә.
Бер сүнеп, бер яктырып һаман
Сәерсенеп дөнья кемне көтә?

Таң атканда, тауны тишә чишмә,
Бораулаган тауның күпме ташын...
Чая сабый сыман йөгереп чыкты,
Колын сыман күккә чөйде башын.

Зеңләп куйды җиһан — кешнәдеме,
Эндәштеме барлык тавышына?
Ташлы сукмак буйлап китте чишмә,
Иделенә китте кавышырга.
Дөнья белән китте танышырга...

Колач җәеп каршы алды киңлек,
Тамырларын үбеп сөйде талны...
Гашыйкларның йөрәгенә кереп,
Керфегенә тамчы булып тамды...

---

*САФУАН МУЛЛАГАЛИЕВ (1927) — «Сәлам бирәм» исемле шигырь китабы (1985) авторы; озак еллар Үзбәкстанның Маргилан шәһәрендә эшли, хәзер Казанда яши.*

...Чылбырыннан ычкынганмы дию,
Көтмәгәндә котырынды давыл,
Сындырды ул яшь-яшь тал-тирәкне,
Ишеп китте сабый чишмә тавын...

Җимерелде чишмә өстенә яр,
Җир астында ятып калды сабый —
Кем соң аны килеп казып алыр?
Кем соң аны кирәкле дип саный?..

Бер хәбәрсез яуда калган улын
Эзләп йөргән ана казый аны —
Зәңгәр чәчәк сыман сулган сабый,
Аңын җуйган, ләкин исән җаны...

...Учак ягып, шунда кала ана,
Улын тапкан сыман ул шатлана...
Ана җылысын тоеп, чишмә хәзер
Яңа юллар яра — юллар яңа...

Сандугач су эчсә, моңы тама,
Таллар эчсә, тама бал-шикәре.
Кеше эчсә, тама мәхәббәте, —
Чишмә ага — белми ул чикләрне...

❀

Вакыт чыңлый юлларда да,
Вакыт чыңлый кылларда да...
Чыңлый-чыңлый үткәннәрне
Хәтерләрдән кубара да
Алларыма җәеп куя —
Ярты гомер бушка үткән...
Ишетелә җирдән-күктән:
«Бушка үткән, бушка үткән»...

Күз алдым караңгылана:
Үткән вакыт, үткән вакыт...
Кайтыр идем яшь чагыма,
Тау-кыяны җимереп-ватып,
Кызыл утларын кабызып,
Йолдызлар кычкыра күктән:
«Вакыт үткән, вакыт үткән —
Яшел ут кабынмый бүтән»...

## Ай-һай

Тормышта чәчәк тә кирәк,
Каен, тирәк тә кирәк.
Яхшы-яманны иләргә
Кылдан иләк тә кирәк...

Тормышта барсы да кирәк,
Берсе дә артык түгел.

Тик нигә ташлап барырга
Өйрәнеп бара күңел?..

Ыргылабыз-сикерәбез
Алга-артка карамый.
Чын ак, дибез, ап-ак дибез,
Дегеттән дә караны...

Ай-һай, иләк кенә житәр
Микән безне иләргә...
Башта ил гамен йөкләргә
Кирәктер шул иңнәргә.

## Өмет бетсә

Өмет белән килдем дөньяга,
Өмет белән бастым юлларга.
Өмет белән акты уйларым,
Өмет кушты миңа жырларга.

Өмет илтте мине көрәшкә,
Өмет тартып алды үлемнән.
Өмет мине күккә күтәрде...
Өметемне жуйсам бүгеннән,
Шыр ялангач дөнья калачак,
Моңсызларның берсе, утын дип,
Учагына мине салачак,
Салачак...

## Бәхет

Зәңгәр күзләр карый сыман,
Яфраклар арасыннан...
Сөю сихерләре шулай
Жыр булып ага сыман.

Ул зәңгәр күзләр, дигәнем
Чәчәкләр икән бары.
Шулай да сөю күтәрде,
Күтәрде жырлы жанымны
Йолдызлардан югары...

Яна-көя, яна-көя
Иңли торгач күгемне —
Мәхәббәтем күңелемнән
Туган жиргә түгелде, —
Бу соң бәхет түгелме?

*

Яфракка яфрак бәрелсә —
Жил туа.
Жилләргә жилләр кушылса —
Сил туа.
Силләргә силләр кушылса —
Ут туа.
Уттан ялкын, ялкыннардан
Жанда тетрәү була.

## Нәби Зарипов

### Киттек

Салкын чишмә җырын кат-кат тыңлап,
Үстек аунап яшел чирәмдә.
Кульяулыгы тигәч борыннарга,
Егет булдык мәллә дигәндә,
Үкчәбезгә басып үскән кызлар
Фасон сайлап кием кигәндә,
Оялчан күз белән аска карап,
Мәхәббәтем сиңа, дигәндә,
Килде төште илгә утлы дәһшәт.
Эх, сыгылды билләр, сыгылды.
Киттек яуга. Юллар үргә менде.
Ничә ана һушсыз егылды.
Сулышларын кыскан сагыш йотып,
Кызлар һаман озата бардылар.
Узган чакта моңсу урманнарны,
Төркем булып басып калдылар, —
Кочаклады алар каеннарны...
Яфраклар җил тоеп шаулады.
Күрик бер дип артка борылдык без,
Кучер абзый атын каулады.

### Безнең туйга атлар җигелмәде

Безнең туйга атлар җигелмәде,
Кыңгыраулар ятты чормада.
Кияү егет булып барыр дуслар
Авып калды утлы кырларда.

Чорнамадым кияү билбауларын,
Киҗе-мамык бирнә кимәдем.
Килен төшкән чакта өй алдында
Уч тутырып таңкә чөймәдем.

Пуля үткән тишекләрне ямап,
Кан тапларын юдым, сөрттем дә,
Окопларда бергә йөреп кайткан
Шинелемне кидем өстемә.

Безнең туйга атлар җигелмәде,
Камыт, дуга калды келәттә...
Гадәтләргә кергән туй бәйрәме
Булгандыр бит безнең теләктә.

### Мөгаен, танымыйсың

Моннан дошманны кудык без,
Купканда утлы давыл.
Килдем мин тагын, күрим дип,
И сугыш үткән авыл!

Азат итешкән җирләрне
Ничек ди сагынмыйсың!..
Син яшь, ә мин картайдым шул,
Мөгаен, танымыйсың...

# Разим Вәлиуллин

## Безнең язмыш

Ил турында безнең уйлар.
Гел кешеләр өчен җырлар.
Уйлар, җырлар — безнең язмыш! —
        Каршылыклы, хафалы...
Үр артыннан яңа үрләр...
Үзәннәрдә туа ирләр.
Юллар, үрләр — безнең язмыш —
        сикәлтәле, җәфалы.
Кыйммәткә төшә җиңүләр.
Тик юк җылап җиксенүләр.
Егылып калулар булса да,
        җиңелү безгә ят әле.
Чор сулышы — могҗизалар,
Чын батырлык сорый алар.
Кылган эшләр — безнең язмыш!
        Бәлки, аз-маз хаталы?!
Бардыр. Гигантлар янында
Алар бары тик вак таплар.
Мәңгелеккә дип корабыз
        без Ил-Йорт, ихатаны...
Планета һәм Ил язмышы,
Ир-егетләр, безнең язмыш!
        Каршылыклы, хафалы...
        Сөенечле, мактаулы!

## Табынга мәдхия

Әти-әни хәстәрләгән табыннар табындыра...
Туганнар белән түгәрәк мәҗлесләр сагындыра.

Гел күңелдә дус-иш белән гөрләшеп утырганнар.
Табын күрке — матур җырлар — җаннарны тутырганнар.

Ашъяулык җәю — ул муллык, хәзинәдән ризыклар.
Аш-су тәме, табын яме — уен-көлке, кызыклар...

Көлә белсәң, сөйли белсәң, табын-сәгадәтлелек.
Табыннарны табын иткән — илаһи әдәплелек.

Тантана узмый табынсыз: зур бәйрәмнәр, зур туйлар.
Булмасын анда шәраблар һәм чуалмасын уйлар.

Җаннар ачык, уйлар садә, мәкернең урыны түгел.
Җыештырылмаган табын сыман булмасын күңел.

---

**РАЗИМ ВӘЛИУЛЛИН** *(1942) — шигырьләре журналыбызда беренче тапкыр басыла. Лениногорск шәһәрендә яши.*

Табынга чакырган икән, ише дип таный кеше.
Шул табын дәрәҗәсендә кешегә саный кеше.

Табыннар мәңгелек булсын, табыннар тулып торсын.
Бөек табын хөрмәтенә җырлыйк әле монысын:
— Табыннар абындырмасын, табыннар табындырсын!

●

Язлар килә, язлар, язлар...
Еллар эри, гүя, карлар.
Җырлый йөрәк моңлы саздай.

Аккош кайта сагынып, казлар...
Кошлар көнләшерләр, язлар —
Шәлен-иңен ача кызлар.
Сагындырган нәфис сыннар,
Эрегәннәр кышкы бозлар...
Дулый йөрәк очар тайдай.

Тунын салган дөнья җырлый,
Ташкыннардай хисләр ургый.
Яз — йөрәктәй, йөрәк — яздай.

●

Кайда яшьлек — шунда сөю,
кайда сөю — шунда җыр.
Бу яшьлекнең канатлары
сөю белән җырлардыр.

Яшьлек — хыял, романтика,
балкып яну, нурлардыр.
Яшь күңелнең канатлары
яну белән хыялдыр.

Кайда яшьлек — анда хезмәт,
хезмәт булса, уйлар зур.
Җиңүләрнең канатлары
тәвәккәллек, уйлардыр.

Еллар җитез, узып китә,
әйтерсең, аргамаклар...
Гомерләр кичәргә җитәр
яшьлек биргән канатлар!

Ризван Хәмид

# МАЙНЫҢ УНБИШЛӘРЕНДӘ

ИКЕ БҮЛЕКТӘ ДРАМА

КАТНАШАЛАР

Варис — балта остасы, пенсионер.
Закуан — өлкән улы, Мәгариф министрлыгының җаваплы хезмәткәре.
Мәгави — кече улы, колхозчы.
Зәримә — Мәгавиның хатыны.
Гүзәл — аларның кызлары.
Айдар — Закуанның малае.
Кызылтау, Дүртмаңгай — авыл өстендәге таулар.

## Беренче бүлек

*Мәңгелектән бер мизгел*

**Ике тау астындагы елга буенда кечкенә авыл. Таулар, төсләренә һәм формаларына карап, «Кызылтау» һәм «Дүртмаңгай» дип атала. Май ае. Таң атып килә. Авылның бердәнбер урамыннан чыккан юлда яланаяклы 14—15 яшьлек үсмер басып тора. Бу — Айдар. Киеме шәһәрчәрәк. Кулында кармак колгасы һәм тал чыбыгына тезелгән вак балык. Ул сокланулы күз карашын тауларга төбәгән.**

Кызылтау (*тавышы шактый ягымлы һәм таләпчән*). Әй! Дүртмаңгай! Күрше! Уян! Күзләреңне йомганнан соң ничә ел үткәнне беләсеңме?!

Дүртмаңгай (*карлыкканрак тавышлы*). Кигәвен сыңары!.. Тауга сәгать кирәкми, Кызылтау! Нигә уяттың? Әллә тагын сәнәкчеләр шаулыймы аста? Кичә дә шул мәлгуньнар аркасында татлы йокым бүленгән иде!

Кызылтау (*көлә*). Кичә дә?! Сәнәкчеләр сугышы беткәнгә алтмыш ел узса ни диярсең, йокы чүлмәге?

Дүртмаңгай (*исе китмичә*). Барыбер түгелме... Бер көн, алтмыш ел, мең ел... Йоклавыңны бел. Вакыты җиткәч, үзем уятырмын... (*Хырлап йокыга чума.*)

Кызылтау. Хырларга тотынды! Нинди вакыты җиткәч?

Дүртмаңгай. Җир өстендә икебез генә калгач... Күз алдыңа китер: беркөнне уянып китәсең — җир өсте шәп-шәрә! Хозурлык! Итәкләребез чип-чиста. Бер җан иясе дә кыймылдамый. Сыртларыбызны бернинди агач, үлән тамыры тишкәләми! Рәхәт! Килер ул көн, күрше, килер!.. Әнә: түбәндәге авылга кара. Ике аяклыларның тормышы шуңа таба бара, минемчә...

Кызылтау. Юк инде! Дөньяда синең белән икәү генә калырга язмасын! Эч пошудан вулкан кочагына ташланырга риза булырсың! Күзләреңне киеребрәк ачып кара әле. Әнә теге, авызын ачып, безнең сөйләшкәнне тыңлап торучы ике аяклы җан

---

РИЗВАН ХӘМИД *(1941) — драматург. «Кайтыр идем» дигән пьесалар җыентыгы авторы. М. Җәлил премиясе лауреаты. Язучылар Союзы идарәсенең председатель урынбасары. Казанда яши.*

нясе бер дә серле булып тоелмыймыни сиңа? Күзләрендә акыл нуры уйный!

Д у р т м а ң г а й. Һәй! Тузанлы юл өстендә тузан бөртеге... Акыл нуры, имеш... Кайдан килсен аларга акыл дигән нәрсә! Туалар, ашыйлар-эчәләр, сугышалар-кыйнашалар, картаеп үләләр һәм итәкләребез астына сеңеп югалалар. Шуны «яшәү» дип атыйлар. Мәгънә күрмим! Ә син «акыл» дисең! Акыл кирәкми дә аларга! Безгә зыян гына китерә ич ул. Тау корткычлары ич алар... Иокла... (*Хырлап йокыга чума.*)

**Уйга калган Айдар авылга юнәлә.**

**Б е р е н ч е к ү р е н е ш**

**Май урталары. Бүрәнәләре каралып беткән иске йорт. Зур гына ишегалды. Ишегалды агач койма белән бер генә яктан уратып алынган. Икенче ягы елга ярына барып тоташа һәм, ары киңәеп, зур гына тугайга әйләнә.**

**Әнә шунда текә яр башында искиткеч матур яңа йорт тора. Тәрәзә-ишек йөзләре, кәрнизләр, болдыр рәшәткәләре зур осталык белән бизәкләп-челтәрләп эшләнгән. Йорт әзер диярлек. Бары тик тәрәзә рамнары һәм түбә башында морҗа торбасы гына җитешми.**

**Иске йортның кече ягында агач карават, урындык. Кечкенә өстәлдә төрле-төрле дару шешәләре тезелгән. Варис карт йокламый, уйланып ята. Ләкин Зәримә килеп керүгә шундук күзләрен йома. Зәримә, авыруга игътибар белән карап торганнан соң, мендәрен рәтләп, чыгып китә. Бераздан өйгә Мәгави керә. Карт күзләрен ача.**

В а р и с. Абыеңа шалтыраттыңмы?

М ә г а в и. Әйе. Кайтырга чыкты, диделәр.

В а р и с. Утыр, улым. Сүзем бар.

**Мәгави урындыкка утыра.**

М ә г а в и. Киленең кергән иде. Даруыңны каптыңмы?

В а р и с. Керүче күренмәде.

М ә г а в и. Ай-һай!.. Ярар, мә, эч. Им булмасмы... (*Дару бирә.*) Гел бала-чага инде... (*Карт, башын күтәрә төшеп, дару каба.*) Нәрсә сорамакчы идең?

В а р и с. Эш болай, Мәгави улым... Яңа йортны кем өчен салганны үзең дә аңлагансыңдыр инде.

М ә г а в и. Ничек инде — кем өчен?! Үзеңә түгелмени?

В а р и с (*көлемсерәп*). Үземә... Синең үз йортың әйбәт. Әллә соңыннан үзәккә күчәргә дип торасызмы? Анда таш пулатлар бирәләр.

М ә г а в и. Кайчан ул — соңыннан?

В а р и с (*бик гади*). Мин үлгәч.

М ә г а в и. Ташлале, эти!

В а р и с (*улының сүзләрен җавапсыз калдыра*). Я, нишләмәкче буласыз?

М ә г а в и. Кая китик без моннан!

В а р и с. Ярар. Үз теләгегез, кыстамыйм... Сиңа бер үтенечем бар, улым. Закуан абыеңны, кайткач, авылда бөтенләйгә калырга күндерергә тырыш. Яңа өй — аныкы. Ә бу искесен теләсәгез нишләтерсез.

М ә г а в и (*ышанычсыз белән*). Риза булмаячак.

В а р и с. Әйткәне бармы әллә?

М ә г а в и. Аны яхшы беләм. Башына тай типмәгән ич аның? Мәгариф министрлыгында җаваплы хезмәткәр. Менә-менә министр урынбасары итәргә торалар үзен. Өчесенә дүрт бүлмәле фатир!

В а р и с (*тыныч*). Ә син күндерергә тырыш.

М ә г а в и. Нигә кирәк аның кайтуы? Аңламыйм мин сине, эти.

В а р и с. Син министр булмаганга. Син министр булсаң — аңардан башка да түзәр идек.

М ә г а в и. Министрлыкның монда ни катнашы бар?

В а р и с. Син нәрсә — сукырмы әллә? Туган авылыңның нинди хәлгә төшүен күрмисеңмени? Ничә йорт утырып калды хәзер?

М ә г а в и. Хафап икән — биш йорт янына тагын берәү өстәлә! Берни дә эшләп булмый инде хәзер, эти. Тарих тәгәрмәче шул якка әйләнә.

В а р и с. Ә син мин әйткәнне тыңла. Закуан абыең монда кайтса, авылга беркем дә кагылмаячак. Закуан монда кайтырга тиеш. Аңардан битәр беркем дә авылыбызга ярдәм итә алмый.

М ә г а в и. Мин аны үгетләмәячәкмен, эти.

В а р и с. Аңла.

М ә г а в и. Калдыр, эти. Үзең — теләсәң нишлә. Сүземне әйттем.

В а р и с (*бәхәсләшергә урын калдырмаслык итеп*). Ул чагында... Сез колхоз үзәгенә күчәсез. Ә ул — монда кайта.

М ә г а в и. Чынлап сөйләвеңме бу?

В а р и с. Башка чара күрмим. Ни өчен аны авылга кайтарырга теләмәвеңне белмиммени мин.

М ә г а в и. Без авылдан беркая да китмибез.

В а р и с (*үгет белән*). Кызмый тор. Ми-

нем өчен икегез дә тигез. Син якынрактыр да, бәлки. Ләкин — шулай кирәк. Синең монда калуыңның чуртыма файдасы тияме. Ә ул... Авылыбызны ул гына саклап кала ала.

Мәгави. Мин монда тудым — шушында яшәячәкмен! Миңа димәгәе, авылда хет беркем дә калмасын...

Варис. Ә соңыннан? Син үлгәннән соң ни булыр?

Мәгави. Закуан абый да дөньяга мәңгегә килмәгән!

Варис. Ул — бөтенләй башка. Ул кайтса юл да төзәтеләчәк, күпер дә салыначак. Һәм гомумән...

Мәгави. Төзәтеләчәк, пычагым! Ул анда — Казанда фигура. Монда гына кайтсын — шундук базары төшәчәк...

Варис. Тормышны начар беләсең син, улым. Әнә — Абдулла авылына кара! Элек нинди хәлдә иде дә, хәзер, райком секретаре пенсиягә чыгып, авылына кайткач, ничек кабат күтәрелеп китте!

Мәгави (*катгый*). Юк, әти. Үгетләмә. Абыйны кайтырга кыстамаячакмын. Гомергә синең алда ул беренче булды! Әллә мин аның кебек укырга теләмәдемме? Кая ул — талант! Ач торсак, торырбыз — тик ул укысын! Ә миңа — аннан калган сәләмәләр дә ярап тора! Син бит миңа унынчы класска кадәр кием дә алып бирмәдең! Бөтен нәрсә гел Закуан абыйдан калгач кына миңа эләгә иде!

Варис (*усал киная белән*). Менә ничек? Ә өйләнүең?! Ул да абыеңнан калган...

Мәгави (*бүлдерә*). Анысы — минем эш! *(Пыр тузып чыгып китә.)*

**Айдар кайтып керә. Кулында балык тезмәсе. Балыкларын бабасына күрсәтә.**

Варис. Ә, кайттыңмы, Айдар улым? Һу! Күрсәт әле, күрсәт... Бик тә хәтәр шәп урынга юлыккансың, ахры... Чоңгыллы урындамы? Андый җирдә балык шәп каба торган була. Кыдашта балык калмады, дигән булалар тагын! Әтиең юкка кармак күтәреп йөрисең, дип ачуланып киткән иде. Молодец! Әйдә, үзе күреп шаккатсын әле. Какрас тиздән кайтып җитәргә тиеш. Ярар, бар, улым, Зәримә җиңгәңә кертеп бир — әтиең кайтуына кыздырып куйсын. (*Айдар аңладым дип баш кага.*) Я, ничек, бабаң янында әйбәтме? (*Айдар елмая.*) Ә авылда яшәргә теләр идеңме? (*Айдар риза дип баш кага.*) Яңа йорт ошыймы соң? (*Айдар баш бармагын күрсәтә. Кәлә.*) Телисеңме, шул йортны үзеңә бүләк итәм? Бер үзеңә генә түгел, кәнишне,— ата-анаң белән бергә... (*Айдар, шатланып бабасын кочаклый.*) Ярар, ярар... Бабаңны ялгыш буып үтермә. Чыкмаган җаны гына калды аның хәзер. Болай килешәбез без синең белән: әтиең кайтып төшкәч, аңлат үзенә — авылда яшәргә телим, диген... Булдырырсыңмы? (*Айдар «риза» дип баш кага.*) Бик әйбәт. Ә мин синә, аякка тора алсам, кайбер нәрсәләр өйрәтермен. Кулыңнан эш килергә охшаган синең. Бабаңның һәр эшен әләктереп алырга гына торасың. Әнә нинди матур йорт салып куйдык бит әле икәү бергә! Шундый матур сарайлар төзергә өйрәнәсең киләме? (*Айдар, белмим дигәндәй, җилкәсен җыерып куя.*) Ничава, өйрәнерсең. Теләгең генә булсын. Һөнәргә өйрәнү кыен түгел. Һөнәреңнең беркемгә дә кирәкмәвен күрү авыр... Бер кеше дә дөньяга мәңгегә килми, һөнәре үлмәскә тиеш. Синең бабаңнар гомер-гомергә балта остасы булып, дан тотканнар... Җиде буынга кадәр белергә тиеш тә бит син аларны. Нишлисең инде. Әтиең Закуан да белми хәтта. Ул да ярыйсы гына мастер була ала иде дә бит. Теләмәде. Башын шәһәргә алып качты... Син дә качмассыңмы? (*Айдар юк дип баш кага.*) Егет кешегә, күбәләк кебек, урыннан-урынга кунып йөрү килешмиме ул. Бер эш сайла — гомерлек булсын! Син, бәлки, бабаң бөтен нәрсәгә үзе өйрәнгәндер, дип уйлыйсыңдыр. Юк, улым. Карт бабаңнар мирас итеп калдырды миңа үз һөнәрләрен. Сакларга куштылар. Матур бизәкле бер иске такта кисәге күрдең ич? Яшел тартмада. Минем өчен алтын бәясе тора ул такта кисәге! Кимендә дүрт йөз илле ел элек ясалган әйбер ул. Ә мин һаман шул өлгедән файдаланам... Дөрес, хәзер йортларны авылларда да күбрәк таштан салырга тырышалар, ә синең бабаңнарының кулы агач белән эш итәргә күнеккән. Ничава, безнең кулларның да кирәге чыгар. Агачка отставка бирергә ашыкмый торсыннар әле!.. Утыр әле яныма — бабаң сиңа бер сер ачарга тели. (*Айдар урындыкка утыра.*) Кара аны — беркемгә дә ләм-мим! Беләсеңме, без синең белән, улым, нәрсә төзедек? Йорт салмадык без — җиһан кордык! Түбәгә игътибар иттеңме? Бөдрә түбә дип атала ул. Авылда башка андый түбә юк. Чөнки түбә түгел ул — күк гөмбәзе! Йолдызлар да, ай да, кояш та, Киек каз юлы да бар анда. Гади бизәкләр генә түгел алар. Ә тәрәзә капкачларындагы тамгалар — Чулпан йолдызы билгесе. Балаларга бәхет китерә ул. Ә хәзер уйлап кара: ни өчен без аны нәкъ яр башына, су якасына салдык? Язгы ташу башлануга җимерелеп төшәчәк бит, шулаймы? Кайберәүләр бабаңның баш шөрепләре туза башлаган дип уйлый. Минем хәйлә ул! Әтиең кайтсын да ныгытсын әле ярны, мин әйтәм! Үз йорты ич — нибуч ныгытыр... Юкса яр җимерелә торгач, алты хуҗалык утырып калдык. Ә монда ныгыту турында уйлап та караучы юк.

Чөнки кайгырасы юк: мондагы йорты җимерелсә, колхоз үзәгенә китә дә бара — анда менә дигән әзер таш пулат бирәләр ич!.. Я, ничек, шәпме бабаңның хәйләсе? (*Айдар елмая. Аннан уз алдына.*) Ә мин атаңа йортын башка җиргә күчерергә рөхсәт итмәячәкмен... Ярны ныгыттырсын! Кара аны, әтиең кайтса-нитсә, сүз ике арада калсын. Килештекме? (*Оныгына кул бирә.*) Ярый, бар инде, улым, арыдым. Балыкларыңны Зәримә җиңгәңә кертеп бирергә онытма.

**Айдар тора. Шул ук секундта Зәримә килеп керә. Айдар аңа балыгын бирмәкче була, ләкин Зәримә кул гына селти. Айдар балыкларын урындыкта калдырып чыгып китә.**

Зәримә. Чынмы ул, әткәй, безне авылдан куасың икән?

Варис (*тыныч*). Кумыйм, килен. Закуан кайткач, орыш-талашсыз яши аласыз икән, бер сүзем дә юк. Яши бирегез.

**Әтисенең исемен ишеткәч, Айдар алгы якта туктап кала.**

Зәримә. Менә нәрсәдә икән эш! Мәгаен, миннән нидер яшерә кебек тоелган иде аны! Димәк, миңа дөресен әйтергә курыккан!

Варис. Сине жәлләп әйтмәгән, күрәсең.

Зәримә (*горур*). Ә минем өчен барыбер! Гайбәттән курыкмыйм мин! Куркудан уздым.

Варис. Син курыкмыйсыңдыр да бит... Ирең бутәнчәрәк уйлый. Икесенең берсе: я, Закуан кайткач, үткәннәрне онытып, туганнарча яшисез, я — үзәккә күченәсез. Үземнең дә сезне моннан җибәрәсе килми дә бит, башкача чара юк. Кызың турында уйла. Ирең турында. Бер авылда булгач, Закуан белән очрашмый тора алмассыз. Җиңел булыр дисеңме Мәгавиеңә?!

Зәримә. Ә ул безнең очрашуны күрмәячәк!

Варис. Димәк, син күчәргә риза? Бик әйбәт. Йортыгызны калдырырга мөмкин — колхоз алмашка фатир бирер. Йортыгызга хуҗа табылыр. Әнә кызлар фермага эшкә үзәктән өч чакрымнан килеп йөриләр. Рәхәтләнеп монда яшәргә риза булырлар.

Зәримә. Риза булмый гына торсыннар әле! Беркая да аяк атламыйбыз без моннан!

Варис. Кайда яшәсәгез дә барыбер түгелме сезгә? Болай да җәяүләп көн дә үзәккә эшкә чабасыз ич. Мәгави керсен әле монда. Әйбәтләп сөйләшик. Үчләшмичә генә.

Зәримә (*дулкынланып*). Әйе, син хаклы! Мин чынлап та өлкән малаеңа үч итеп, Мәгавине үземә караттым! Шуны һаман гафу итә алмыйсың син... Белсәң иде, күпме кан-яшь койдым мин Закуанның аркасында! Я, хода, аны яраткан кебек дөньяда тагын берәрсе ярата беләме икән! Ә ул мине ташлап качты. Минут саен үлем эзләдем, акылдан шашар хәлләргә җиттем! Мәгавиең кайтып төшмәгән булса, белмим, нәрсә белән бетәр иде... Мәгавиеңне өнәп чыкмадым мин — йөрәгем тулы сезгә үч иде! Соңыннан гына аңладым: Мәгави Закуанныңнан мең өлеш яхшырак икән! Миңа хәзер Мәгавидән башка беркем дә кирәкми.

Варис (*Зәриманең ачыктан-ачык күңелен ачып салуы йомшарткан аны, ләкин уз сүзендә каты тора*). Шулайдыр, бәлки... Тик мин башка юл күрмим, килен.

Зәримә. Закуанның авылга кайтырга хакы юк.

Варис. Аңлагыз: авыл язмышы турында сүз бара монда!

Зәримә. Мәгави мине ташласа да китмим мин моннан! Туган-тумачаларыбыздан авылда бер мин генә калдым хәзер. Мин китсәм — нигезебез бетәчәк ич! Авылны сагынганда туганнарым кая кайтып керер?

Варис. Ә Закуан кайтмаса,йорт нигезегез тагын да тизрәк бетәчәк! Мин үлсәм — шундук бөтенегезне үзәккә күчерәчәкләр! Миңа ихтирам йөзеннән генә бәйләнми торалар. Колхоз монда пләмәлек фермасы төзергә планлаштыра!

Зәримә. Кагылып карасыннар! Ишек тупсама аркылы ятачакмын — трактор белән таптап үтсеннәр әйдә.

Варис. Тупсага аркылы ята, имеш... Трактор да кирәкмәячәк — ташу агызып алып китәчәк сезне.

Зәримә. Ярны ныгытырбыз! Агач утыртырбыз. Әмәле табылыр, кайгырма.

Варис. Кая инде! Моңынчы таптыгыз бит әмәлен... Бердәнбер чара — Кыдаш елгасын Тугайлык аша турыга ерып җибәрү.

Зәримә (*шатланып*). Дөрес! Тотабыз да шулай итәбез!

Варис. Ә нәрсә белән ермакчы буласыз инде аны? Кәрәк беләнме?

Зәримә. Нишләп көрәк белән? Вульдозер сорарбыз.

Варис. Колхозданмы? Бәлки туп-туры Казаннан яздыртып алырбыз?

Зәримә. Вульдозер да булдымы баш ватар нәрсә!

Варис. Тәк... Ә беләсеңме, күпмегә төшәчәк ул? Кара акыл белән генә исәпләгәндә дә җитмеш меңгә! Менә сиңа бульдозер.

Зәримә. Җитмеш меңгә?!

Варис. Ә каян аласыз ул акчаларны? Закуаннан башка? Аның өчен эшләсәләр генә эшләрләр моны. Бар, әйбәтләп аңлат

шуны ирения. Закуан кайтуга җавабыгыз әзер булсын!

З ә р и м ә. Нәрсә эшләргә үзем беләм мин! (*Чыгарга бара. Айдар куркып артка чигенә.*) Син нишлисең монда? Без сөйләшкәнне качып тыңлап тордыңмы?! (*Айдар эндәшми.*) Әһ!.. (*Кул селтәп чыгып китә.*)

Айдар бабасы янына ташлана.

В а р и с (*оныгының хәлен аңлап*). Син безнең сөйләшүне ишеттеңмени? (*Айдар дөресләп баш кага.*) Өлкәннәрнең һәр сүзенә колак салма алай. Иөрәк кызган чакта кеше ни генә әйтеп ташламас... Тормышта төрле хәлләр була. Кил әле монда, утыр яныма. (*Айдар утыра. Ул сизелерлек каушаган.*) Я, я, я... тынычлан... Әтиеңнең гаебе юк монда... Әниең белән өйләнешкәнче булган ул хәлләр. Зур кеше ул, синең әтиең. Горурланырга тиеш син аның белән!

Ишегалдында Зәримәне ире Мәгави көтеп ала.

М ә г а в и. Ну, нәрсә диде?

З ә р и м ә. Картың Закуаныгыз белән тилерә! Минем сүзне ишетәсе дә килмәде.

М ә г а в и. Нишлибез?

З ә р и м ә. Син — ир, син уйла.

М ә г а в и. Ир дип... Ирлекнең монда ни катнашы бар?

З ә р и м ә. Катнашы юк шул! Иргә дә санамыйлар ич сине монда.

М ә г а в и. Юкны сөйләмә!

З ә р и м ә. Бар алайса, атаң белән сөйләшеп кара! Я, алла, күпме телгәләргә мөмкин инде җанны шул үткән белән! Бер аягы каберде бит инде. Һаман да...

М ә г а в и. Җитте, дидем!

З ә р и м ә. Белеп тор, Мәгави, син үзең теләсәң нишләрсең, ә мин сүземне әйтеп чыктым! Китәсең килсә — берүзең кит!

М ә г а в и (*әрнүле*). Мена ничек сөйләшә башладың...

З ә р и м ә. Әйе! Шулай! Минем белән командовать итәргә беркемгә дә ирек куймам!

М ә г а в и. Тукта, кызмый тор...

З ә р и м ә. Тагын ни көтәргә? Нәрсә эшли аласың соң син? Закуаныгыз кайтса — телеңне аркылы тешләячәксең бит син! Шулай түгел диярсең?!

М ә г а в и. Кызма дидем! Уйлашырга кирәк.

З ә р и м ә. Уйла! Ә мин уйлап куйдым инде.

М ә г а в и. Нишләмәкче буласың? Бәлки, ирең белән уртаклашырсың?

З ә р и м ә. Нинди кеше син, Мәгави?! Туган авылыңнан куалар ич! Телсез хайванмы әллә син?! Ир кеше ләбаса! Әллә исемең генә калдымы? Хет бер мәртәбә үз сүзеңне өскә куя аласыңмы син?

М ә г а в и. Сиңа әйтүе җиңел! Әти бит ул...

З ә р и м ә. Вулса? Булса ни булган? Үз фикереңбелән яшәргә ярамыймыни сиңа?

М ә г а в и. Ә бәлки, әти хаклыдыр, Зәримә?

З ә р и м ә. Хаклы булса, яшә инде картайганчы әтиеңнең акылы белән! Кем белән бәхәсләшеп торам соң мин?! Син бит үз хатыныңны да бала табарга күндерә алмадың!

М ә г а в и. Зәримә! Узынма!

З ә р и м ә. Дөрес түгел диген!

М ә г а в и. Үзең бит... Үзең теләмәдең ич!

З ә р и м ә. Әйе! Мин теләмәдем! Ә син — ир кеше! Мин башта теләмәдем. Ә соңыннан кабат сүз кузгатуыңны көттем. Чөнки чынлап яшәп китәрбез, дип ышанмаган идем. Ә син!..

М ә г а в и (*хәтере кала*). Табарга иде. Кем сиңа тапма диде?

З ә р и м ә. Сиземи йөргән дисеңме әллә мине? Абыеңның кочагыннан төшеп калганны күтәреп алырга курыкмадың, ә баладан курыктың. Димәк, аерылышырга мөмкинлек калсын дигәнсең!

М ә г а в и (*кыза төшеп*). Тагын ни әйтерсең?

З ә р и м ә. Бер башлагач, әйтелмәгәне калмасын. Бала турында сүз катырсың дип, көтә-көтә көтек булып беттем инде! Бәлки, һаман да аерылышуга мөмкинлек саклыйсыңдыр? Шулай булса — газапланма, әйт турысын. Мин сиңа ябышып ятмыйм.

М ә г а в и (*кырыс*). Тагын ниләр уйлап чыгардың?

З ә р и м ә. Сез ул — уйлап чыгаручылар! Атаң абыеңны дөнья кендеге дип саный! Ә синең өчен атаңның сүзе — закон! Чөнки кеше кубызына биергә яшьтән күнеккәнсең! Шулай булмаса, абыең кочагыннан төшкәнне...

М ә г а в и (*әрну белән*). Тагын бер сүз әйтсәң, шушы минутны мәңге каргаячаксың!

З ә р и м ә. Ярар. Теләсәң нишлә. Син — гаилә башлыгы. (*Кузгала.*)

М ә г а в и. Тукта. Әйдә икәү керәбез әти янына.

З ә р и м ә. Файдасыз. Тетмәбезне тетеп чыгарыр, шул булыр. Тик шуны онытма: әгәр дә эшне хәл итәргә миңа калдырсаң... Ертыкка ямау булып йөрмәм мин синең кебек... Кисәтеп куям: бөтенегез дә үкенерлек булыр! (*Китә.*)

**Мәгави, берүзе калгач, катгый бер уйга килеп әтисе янына керә.**

Мәгави (*Айдарга игътибар итмичә*). Әти! Без монда калырга карар кылдык. Соңгы сүзебез шул.

Варис. Алай... Җиңел булмас сезгә Закуан кайткач. Ике тәкә башы бер казанга сыймый. Сүзем шул: үзем исән чакта гауга-фәлән чыгарырга ирек куймаячакмын. Авыл булсаң — кавем бул. Күңелегезгә беркетеп куегыз!

Мәгави. Яхшы. Без риза. Әгәр дә Закуан абыйның Зәримә тирәсендә...

Варис (*бүлдерә*). Онытылма — Айдар тора янында!

Мәгави. Әй! Нәрсә аңлый әле ул!

Варис. Бар, Айдар улым, урам әйләнеп кер, этиең кайтмыймы икән?.. Балыкларыңны һаман җиңгәңә илтеп бирмәдеңмени? Бар илт. (*Айдар кирелэнеп, баш селки.*) Ни булды?.. (*Мәгавигә.*) Күр әнә — бала җиңгәсе янына барырга курка башлаган!

**Гүзәл йөгереп килеп керә. Аңа уналты яшьләр.**

Гүзәл (*сулышы капкан*). Бабкай! Закуан абый кайтты!

**Айдар, балыкларын урындыкта калдырып, чыгып йөгерә.**

Варис. Үзе генәмени?

Гүзәл. Түгел. Шофер белән. Машинасы күпер янында суга батты. Кара «Волга». (*Әтисенә.*) Әти, әнкәйгә ни булды, баламыз сыгып утыра?..

Варис. Бар, каршы ал, Мәгави. Ярдәм кирәктер. (*Мәгави китә.*) Ә син, Гүзәл, нишләп үзең каршы алмыйсың?

Гүзәл (*әйтәсе сүзе бетмәгәндәй икеләнеп тора*). Болай... Мин күрдем инде аны... Бабкай, дөресме ул... син, имеш, Закуан абыйны авылга кайтарырга телисең, диләр?

Варис. Кем әйтә?

Гүзәл. Минем дә колагым бар ич.

Варис. Җитмәгән җирең юк үзеңнең.

Гүзәл (*дулкынланып*). Ә ул чынлап та кайтачакмы?

Варис. Шулай кирәк. Үскәч аңларсың әле.

Гүзәл. Мине һаман да сабыйга чутлыйсыңмы әллә? Бөтенесен дә беләм мин. Әнкәй турында да. Закуан абый турында да!

Варис (*бүлдерә*). Юләр сүзләр сөйләмә! Юк сүз ул! Миңа да ышанмыйсыңмы?

Гүзәл. Сиңа ышанам, бабкай...

Варис. Ышансаң — шул. Әниеңнең бер гаебе дә юк монда. Ишетсен колагың — әниең турында бер начар сүз дә ишетмим моннан соң! Әни бер генә була ул! Син үзең дә бердәнбер алар өчен. Барып җиттеме, кычыткан чыпчыгы?

Гүзәл (*бабасының сүзне шаяруга борыын кабул итми*). Шуңа күрә дә мин Закуан абыйның монда кайтуын теләмим! (*Көтмәгәндә елап җибәрә.*) Бабкай! Җаным! Кирәкми ул монда! Кайтмасын! Аңардан башка шундый әйбәт иде.

Варис (*гаҗәпләнгән*). Бәй, бәй...

Гүзәл. Синең янда без бар ич! Мин үзем яңа өйне җыештырып торачакмын! Яңа өйгә күчәрсең, бабкай! Әнкәй белән чиратлап ашарга пешереп торырбыз! Мин пешерә беләм. Кайтмасын монда! (*Бабасының куккрәгенә каплана.*)

Варис (*бераз югалып калган*). Туктале, кызым... Нигә алай дисең? Якын абыең бит ул синең. Әтиеңнең бертуган абыйсы! Куркырлык берни дә юк ич! Кайчандыр әниең белән очрашкан икән — күптән онытылган бит инде ул! Ватма башыңны юкбар нәрсәләр белән!

Гүзәл. Юк! Беркем дә онытмаган ул хәлләрне! Бөтенесен дә күрәм мин! Әнкәй үз-үзен кая куярга урын таба алмый интегә! Әтинең дә йокысы качты! Күңелем сизеп тора, фаҗига белән бетәчәк бу!

Варис. Юкны уйлап чыгарма!

Гүзәл. Әнкәйне беләсең бит, ул да күрәзәлек итә ала. Әнкәйнең әнисен — Хәдичә әбекәйне дә «сихерче» дип йөрткәннәр бит! Мин дә шундый. Телисеңме, бабкай, әйтеп бирәм: сиңа күпме... (*Телен тешли.*)

Варис (*тыныч*). Яшисе калганны әйтәсеңме? Мин үзем дә яхшы беләм аны, кызым... Җыясы ризыгым бетеп бара шул. Бик аз калды, бик аз... Менә шуңа күрә бөтенегезгә дә яхшы булсын, дип тырышам да. Ата-бабаларыбызның нигезе корымасын өчен.

Гүзәл (*кабаланып*). Юк, юк, бабкай! Мин ул турыда әйтергә уйламаган идем. Син үзең дә белмисең аны. Кеше үзе турында беркайчан да белә алмый! Андый көч беркемдә дә юк! Башкалар турында гына әйтергә мөмкин! Син рәхәтләнеп яшисең әле, бабкай! Башка нәрсә өчен котым алынып тора минем, бабкай! Закуан абый авылга кайтса, нәрсә буласын белмим мин, тик... Соңгы вакытта төн саен бер үк төш күрәм мин: бөтен тирә-ягымны ут чолгап ала, имеш! Бөтен дөньяны ут баса! Ә каршымда кемнеңдер ачык кабере тора!

Варис (*хәйран кала*). Нәрсә ул төш! Төкер! Чепуха бөтенесе дә! Мин менә әллә ниләр күрәм дә...

Гүзәл (*сикереп тора*). Син бөтенесен дә сизәсең, тик аңламаган булып кыланасың, бабкай! Беләм бит мин! Барысын да күреп-белеп торам! Айдар турында да мин үзем белдем! Миңа беркем дә әйтмәгән иде.

Варис. Айдар турында? Нәрсә белдең?

Гүзәл. Бер күрүдә үк әпә икәнлеген дә. Ничек телдән язганлыгын да... Иртәгә кайта дигән төнне төшемә керде ул минем: имеш, ул кечкенә малай икән, әтисе белән бергә машинада утырып бара. Шул чак каршыларына бер кыз бала йөгереп чыкты да чүт кенә таптап үтмәделәр. Айдар кычкырып җибәрде дә телдән язды. Иртән торгач, әнкәйдән сораган идем, дөрес, шулай булган, ди!

Варис. Бер дә гаҗәп түгел: әлегрәк берәрсе сөйләгәнен ишетеп калган булгансыңдыр!

Гүзәл. Алай түгел шул, бабкай! Мин әлек Айдарның дөньяда барлыгын да белми идем! Әнкәй дә шаккатты... Чөнки безнең өйдә Закуан абыйлар турында беркайчан да телгә алмыйлар. Шулай булгач — күрәәзлек түгелме, синеңчә? (*Инанып.*) Закуан абыйлар авылга кайтса — коточкыч бер хәл булачак! Мин әйтте диярсең, бабкай! (*Чыгып китә.*)

**Карт, кәефе кырылып, ялгызы уйланып кала.**

Варис (*Айдар онытып киткән балыкларны күрә*). Ә балыклар тәки монда аунап яталар... Мда...

**Ишегалдына кулына портфель тоткан Закуан, аның артыннан Мәгави белән Айдар килеп керәләр. Аларны күргәч, Гүзәл болдырда туктап кала.**

Закуан (*җитди, беркемгә дә карамыйча*). Кайда ул? Өйдә ятамы?

Мәгави. Әйе. (*Закуан өйгә юнәлә.*) Ашыкмый тор, Закуан абый... Хәле ярыйсы әлегә. Бераз тын ал. Иң әлек син әнә тегендә кара... (*Кулы белән яңа йорт ягына күрсәтә.*)

Закуан (*тирән гаҗәпкә калып*). Нәрсә ул?!

Мәгави. Яңа йорт. Әти салып куйды. Менә, малаең эшләште. Чын кавалер булган ул хәзер! Кул астына кереп бара.

Закуан (*шаккатуын яшереп тормыйча*). Кайчан җитештерген? Чудо бит бу! Ну-ка, барып карыйк! (*Яңа йорт янына атлый.*)

**Мәгави аның артыннан иярә. Айдар да аларга кушыла.**

Гүзәл. Айдар! Пст, пст!.. (*Кил, дип кул изи. Айдар туктый һәм аңа сорау белән карый.*) Башта сиңа ачмам да дигән идем... Хәзер әйтергә булдым... Чөнки... кызганам мин сине. Кардәш тиеш кеше шулай да! (*Башкалар ишетмәслек итеп.*) Бүген төнлә мин әнә тегендә — яңа йорт янында яр башында берүзем басып тордым. Ничек анда чыгып басканмындыр инде, караңгы төндә. (*Айдар тыңлап бетермичә китмәкче була.*) Ашыкма, сөйләгәнне тыңлап бетер. Әтиең белән сиңа кагыла ул! Басып торам шулай. Дөм-караңгы. Күзгә төртсәң күренмәслек. Күкне кап-кара болытлар каплаган — ертык сырма итәге кебек асылынып-асылынып торалар. Ә Кыдашта әллә бака бытырдый, әллә су анасы пышылдый. Менә болайрак: «Рриу-рриу-руш-ш!» Куркуымнан котым ботыма төште, ә үзем — кадаклап куйдылармыни! Селкенә дә алмыйм. Арка үзәкләремә кадәр бәреште! (*Айдар түзмичә әтиләре киткән якка карана.*) Ышанмыйсыңмы?! Алдашсам, менә баскан җиремдә җир упсын! Алда тагын да куркынычрак! Ни үле, ни тере басып торам шулай! Кинәт йөрәгем жу итеп китте: яшелле-күкле тавыш белән ыжылдап, кемдер пышылдый башламасынмы! Болай ди: «Син бу туфракны мин әйткән кабердән алдыңмы?» Икенчесе чыелдап: «Әйе, яшен суккан карама астындагы кабердән»,— дип җавап бирде. Тагын ниләрдер сөйләштеләр дә, беренчесе туфракны яңа йорт нигезенә сибеп чыгарга кушты. «Дүрт якка да сип»,— ди. Шулай дию булды — күзалларым караңгыланып китмәсенме! Нишлиләр бу кабахәтләр, дим эчемнән генә. Ә үзем каккан казык кебек катып торам. Телне селкетеп карарга телим — булмый! Шулвакыт болыт астыннан ай килеп чыкты. Йорт ягына карыйм — беркем юк! Шундук тынлык урнашты, ә колаклар чыңлап тора... Куркуымнан кычкырып җибәрүем булды — уянып киттем! Хәтта әнкәй сикереп торды. Ян ягыңа борылып ят, саташасың, ди. Әнкәйгә бер нәрсә дә әйтмәдем. Юкса әллә ниләр уйлап бетерүе бар, ырымга тиз ышана ул... Ә иртән торгач, юри барып карадым — чынлап та нигезгә кемдер туфрак сибеп чыккан! (*Тирә-ягына каранып.*) Беләсеңме, ни дигән сүз ул? (*Серле итеп.*) Имеш тә, андый йортка кем генә урнашмасын — куркыныч үлем белән үлә икән! (*Айдар курыккандай артка чигенә.*) Кара аны — беркемгә дә сөйләмә моны! (*Кәлеп җибәрә.*) Әй, онытып торам — теләсәң дә сөйли алмыйсың бит әле син!

**Айдар этисе янына йөгерә. Гүзәл артыннан кычкыра.**

Чынга алма — чепухадыр, бәлки!.. (*Үз үзеннән канәгать булып.*) Ну, хәзер сине ул йортка аркан белән дә сөйрәп кертеп булмаячак...

**Закуан белән Мәгави болдыр янына киләләр.**

З а к у а н. Шаккаттырдыгыз мине... Ә этигә ни булды? Өзлектеме әллә? Әйтүе генә җиңел — шушы яшендә патша сарае салып куйсын әле!

М ә г а в и. Әнә шул яңа йорт болдыры кырыеннан табып алдык без аны. Һушсыз ята иде. Өй түбәсеннән егылып төшкәнме әллә, дип курыккан идек башта. Имгәнгән җире күренми. Нәрсә булганын Айдарың да сизми калган. Өйгә күтәреп алып кереп, врач чакырттык...

З а к у а н. Врач нәрсә ди?

М ә г а в и. Эшләр, беләсеңме, тегеләйрәк бит әле. Врач әйтә... (*Кызына карап ала һәм Закуанның колагына пышылдый.*) Рак. Менә шулай эшләр, Закуан абый.

З а к у а н. Кит аннан?!

М ә г а в и. Шик юк, ди.

З а к у а н. Мда...

**Шулвакыт Айдар Гүзәл янына килә һәм бармагын бөтереп чигәсенә күрсәтә.**

Г ү з ә л. Нәрсә, берни дә тапмадыңмы? Соң бит көн озын каты җил исте — нинди туфрак калсын ди?!

М ә г а в и. Нәрсә булды?

Г ү з ә л. Без болай гына...

М ә г а в и. Бар әниеңә әйт, берәр нәрсә әзерләсен... (*Закуанга.*) Бәлки бездә генә ашарбыз?

З а к у а н. (*кинәт энесенә карап ала*). Миңа барыбер... Тик этинең безнең белән утырасы килер бит?.. Әйдә монда гына.

М ә г а в и (*кызына*). Бар, монда китерегез. (*Гүзәл урамга чыгып китә*). Керәбезме? Сине көтә-көтә зарыгып бетте ул.

З а к у а н. Куркып торам әле. Ничегрәк соң, бик бетерешмәдеме?

М ә г а в и. Ярыйсы әлегә. Ашавы гына... (*Өчесе дә өйгә керәләр.*) Ул — теге якта.

**Закуан портфелен урындыкка куя һәм әчке якка этисе янына үтә.**

З а к у а н. Нихәл, эти?

В а р и с. Хәл кадәренчә, Закуан улым.

З а к у а н. Син нишләп әле болай? Кинәт кенә...

В а р и с. Чирне көтеп алмыйлар аны, улым... Җан бар җирдә каза бар. (*Күрешергә кул суза.*) Нишләп берүзең?

З а к у а н (*күрешә*). Сояның сессиясе башлана. Шалтырат, дип калды.

В а р и с (*көлемсерәп*). Ул-бу була калса дипме? Ярар, шалтырат, иртәрәк әле, диген.

М ә г а в и. Бусагаңнан атлап керүгә үк кешене куркытма инде, эти!

В а р и с (*кече улының сүзләренә игътибар итмичә*). Син озаккамы?

З а к у а н. Күз күрер әле. Айдар улымны бик сагындым. Әнисе дә алып кайт, ди... (*Юк-бар турында сөйләнгәнгә гафу үтенгәндәй.*) Ә син озакка дип кереп яттыңмы монда? Урамда май ае, алмагачлар чәчкәдә утыра, ә син...

В а р и с. Айдарны алып китәргә ашыкмагыз. Кайчан кайта әле тагын шулай. Миңа да юаныч. Малаең молодец. Кулы кулга йокмый, кулалмаш эшләште.

З а к у а н. Белмим, белмим. Өйдә пылесосны да ике-өч атнага бер генә кулына ала иде. Монда аны укуыңны укы, дип мазалаучы юк. (*Малаена.*) Ну что, нравится тебе у дедушки? (*Айдар баш бармагын күрсәтеп елмая*). Ну ладно, потом потолкуем... Я, эткәй, хәлең ничек? Кай җирең авырта? Казанга больницага барып карыйсыңмы әллә?

В а р и с. Хәлләрем әйбәт, улым. Бу кадәр әйбәт булганы юк иде әле. (*Көлемсери.*) Туган авылыңа бик сирәк кайтуың сизелә.

З а к у а н. Ник болай дисең, эткәй?

В а р и с. Телең чуарланган.

З а к у а н (*көлә*). Ә, аны әйтәсең икән! Шәһәрдә яшибез ич!

В а р и с (*елмаеп*). Каладан кайткан кешедән өч көнгәчә акыл сорама, диләр иде аны. Урам эте кебегрәк була түгелме соң?

З а к у а н. Аңлап бетермәдем?

В а р и с. Казанда йортыгызның ишегалдында хуҗасыз эт күргән идем бер баргач. Нинди токымнан икән бу, дип баш ватып утырдым. Койрыгы бурзайга, колаклары овчаркага, аяклары бульдогка охшаган. Сөйләшүең шуны искә төшерде!

М ә г а в и (*көлә*). Кайтып кереп җитмәде — оборотка алдың малаеңны, эткәй! Утлы табага бастырып өчен чакыртып кайтарган, дип уйлап, тәртәсен кирегә бормасын тагын.

З а к у а н (*ул да кушылып көлә*). Ике кулымны да күтәрәм, эткәй! Син хаклы!.. Ә, истән чыгып тора: яр башына нинди патша сарае салып куйдың анда? Бу йортың да менә дигән ич. Ялгыз яшәп туй-

дырды, дип бирәр принцесса алып кайтырга уйлыйсыңмы әллә? (*Көлә*). Улларыңнан яшермә инде, әткәй. Хупларбыз гына. Мәгави нишләптер берни дә әйтми. Нинди дер зур ниятең бар, ахры! (*Мәгави сиздермичә генә абыйсының җиңеннән тарта — арттырып җибәрмә, янәсе*.)

Варис (*улының шаян тонын кабул итеп*). Ниятсез кәҗә дә бакчага керми, улым. Ә нигә чакырдым дисең соң мин сине? Өлкән улым белән киңәшеп карыйм әле, мин әйтәм! Халык әйтмешли, бер баш әйбәт, ике баш тагын да яхшырак. Дөрес, халык үзе нишләптер күбрәк бер башка ышана. Мәгави, синекеләр кайда — кунакны тиешенчә кабул итегез. Юлда ватылгандыр.

Мәгави. Әйттем. Хәзер өстәл әзерләрләр. Үзең безнең белән утырасыңмы?

Варис. Барыгыз, барыгыз, юыныгыз. Мин соңарак.

**Мәгави белән Закуан алгы якка чыгалар.**

Закуан (*җитди*). Да... Әтине танырлык түгел. Шәүләсе генә калган.

Мәгави (*ишекне ябa чыга*). Тс! Әкренрәк.

Варис (*Айдарга*). Я, улым, яңа өй ошадымы әтиеңә? (*Айдар елмаеп баш кага.*) Ярар, бар син дә алар белән. Әтиеңне сагынгансыңдыр. Ишекне ачык калдыр — бераз һава керсен.

**Айдар ишекне ачык калдырып, алгы якка чыга.**

Мәгави. Ишекне яп, Айдар.

Варис. Мин ачык калдырырга куштым аңа. (*Шаяруга борып.*) Атагыздан яшереп, серләшеп утырмагыз әле анда үзегез генә!

Закуан. Ә без серләшмибез, әткәй. Менә Мәгавигә сөйләп утырам. Күпер өсте чалшаеп беткән. Чүт кенә суга мәтәлми калдык. Тәки шуны төзәтмәгәннәр икән! Машинаны кайтарып җибәрергә туры килде.

Варис. Нишләп шоферны ашарга чакырмадыгыз, Мәгави?

Закуан. Ерак тормый ул — райүзәктән генә. Райком машинасы иде. Беренче секретарь урынында туры килде. Синең турыда сорашып утырды, әткәй. Сәлам тапшырырга кушты.

Варис. Рәхмәт. Зиримә килеп нишләп тора инде, Мәгави!

**Гүзәл килеп керә. Ул төрле ашамлыклар кертә.**

Мәгави. Озак. Суга баттыгызмы әллә?.. Әниең кайда?

Гүзәл (*беркемгә дә күтәрелеп карамый*). Өйдә.

Мәгави. Кереме?

Гүзәл. Белмим...

Закуан (*ул аларның сөйләшүләрен игътибар белән тыңлап тора*). Ярар... Әйдәле, улым, күрсәт миңа: кайда юынырга? (*Закуан белән малае ишегалдына чыгалар.*)

Мәгави (*әтисе ишетмәслек итеп*). Әниең безнең белән утырырга теләмимени?

Гүзәл. Белмим...

Мәгави. Әйт, керсен. (*Гүзәл сүзсез генә чыгып китә.*) Әткәй, сиңа шунда гына кертергәме?

Варис. Ашыйсы килми әлегә. Соңрак. Син берүзеңме анда?

Мәгави (*әтисе ягына керә*). Әйе.

Варис. Закуанга берни дә әйтмәдеңме?

Мәгави. Юк әлегә.

Варис. Дөрес эшләгәнсең. Ашыктырма. Ут чыкмаган, өлгерер. Мин үзем әйтәм аңа. Башта утырып ашагыз.

Мәгави. Безнең белән үзең дә утырып алыр идең, әти. Аппетитың яхшырмасмы.

Варис. Ризыгым калган булса, ашалыр, улым... Закуан абыеңа аны-моны әйтми тор әлегә. Барысын да берьюлы әйтеп бетермәсәк тә ярар.

Мәгави. Паникага бирелергә ашыкмале, әткәй! Врач карады ич, куркырлык берни дә тапмады...

Варис. Ул тапмагандыр да... Ә миңа эзләп торасы юк. (*Айдар онытып калдырган балыкларга карап.*) Айдар һаман да алып чыкмаган икән балыкларын...

**Алгы якта Гүзәл күренә. Ул өстәлгә ашамлыклар куя.**

Гүзәл. Өстәл әзер, әти...

Мәгави. Ә кунаклар кайда?

Гүзәл. Әнә керәләр.

**Алгы якка Закуан белән Айдар керә. Мәгави алар янына чыга.**

Закуан (*күтәренке күңел белән*). Онығыңны танырлык түгел, әткәй! Мускуллары зыңлап тора! Тиздән әтисен запросто сыртына салачак! (*Малаеның чәчләрен туздырып җибәрә.*) Авыл һавасы килешкән!

Варис. Аның кебек көн дә таң тишегеннән торып балта селтәп кара да — килешмәсен, имеш! Сиңа да җитәрлек әле анда эш!

Закуан. Кая инде безгә... Миңа хәзер өстәл артында гына рекордлар куярга калды. Оһо! Зиримәнең кухнясын таныйм:

дөньяда бер ул гына шушындый пилмәннәр ясый белә!

**Мәгави ялт итеп абыйсына карап ала — тегесе ялгыш ычкындыруын аңлап, сүзне икенчегә бора.**

Я, нәрсә — ташландыкмы?

Гүзәл. Мин ясадым аларны.

Закуан. Кара син аны... Молодец! Нишләп, брат, уйга калдың—утырт кунакларыңны, юкса авыз сулары килә башлады!

**Айдар сиздерми генә өлкәннәрне күзәтә.**

Гүзәл. Әнкәй соңрак керәм, диде. Коймак пешерә калды.

Мәгави. Яхшы. (*Өстәл артына утыра.*) Утырышыгыз, син шунда утыр, абый... (*Өстәлнең икенче башындагы урындыкка күрсәтә.*) Утыр, Айдар, кабат дәшкәнне көтмә. Ә син, кызым, безнең белән утырасыңмы?

Гүзәл (*нишләп сорыйсың дигәндәй этисенә гаҗәпләнеп карап ала*). Бабкай! Пилмән кертәм. Азлап кына булса да ашап карамыйсыңмы?

Варис. Рәхмәт, кызым, мин — соңарак.

Закуан (*пышылдап*). Урыннан бөтенләй тормыймыни?

Мәгави. Иомышы төшкәндә тора.

Варис. Борчылма, Закуан улым, мин әле генә дару каптым. Артыннан ук ашарга ярамый. Сез ашагыз-эчегез... Мин үз уңаем белән...

**Сүзсез генә капкалыйлар. Гүзәл киеренке дулкынлану белән бер этисенә, бер Закуанга карый.**

Гүзәл. Эти, телисезме, бүген күргән төшемне сөйлим?

**Айдар аңа башкаларга сиздерми генә йодрык күрсәтә.**

Закуан (*сүз табылганга шатлангандай*). Кызык, яле сөйләп кара?

Мәгави (*ул кызының халәтен яхшы аңлый*). Син ашап кына утыр, кызым.

Закуан. Нигә тыясың? Сөйләсен әйдә...

Мәгави. Аның әкияте бетмәс.

Гүзәл. Кемгә әкият, кемгә чын.

Мәгави (*абыйсына*). Казанда ничек яшәп ятасыз?

Закуан. Казанны макта, авылда тор, дип җавап бирәм мин андый сорауга. Яшибез. Ә чынлап кына әйткәндә, хәзер Казан ни дә, шушы кечкенә авылыбыз ни — бөтенебез дә бер атом бомбасы астында йөрибез, диярга була! Зәримә нишләп күренми?

Мәгави. Керер... Авылга тартмыймы соң?

Варис. Мәгави улым, кешегә ашарга ирек бир.

Закуан. Зыян юк, эти... Энекәшне күптән күргән юк. Туйганчы сөйләшеп калыйк, ичмасам. (*Мәгавига*). Ничек дип әйтергә...

**Барысы да ашауларыннан туктап, тынып калалар. Хәтта Варис карт та башын алар ягына бора.**

Мондый сорауга мин гадәттә киресенчә җавап бирәм: авылны макта, калада тор!

Мәгави (*тыныч булырга тырышып*). Нишләп? Авылда начармыни?

Закуан. Начар түгел. Тик мин авыл тормышына икенче төрлерәк карыйм шул...

Мәгави (*этисе ягына күз ташлап*). Я, ярар, пилмән суына инә. Юкса, Гүзәл тырышкан — ә без кагылып та карамадык!

Закуан. Ашыктырма, әйтеп бетермәдем...

Мәгави (*бүлдерә*). Авыл — авыл инде ул! Корылык булса — күккә кадәр тузан, яңгыр яуса — тездән пычрак. Күңел ачыйм дисәң, мөмкинлеге...

Закуан. Ә ник соң, алай булгач, монда ябышып ятасың?

Мәгави. Миндәмени эш. Мин — бөтенләй башка хәл.

Варис. Мәгави! Нишләп абыеңа сүз әйтергә ирек бирмисең?

Мәгави (*кирелэнеп*). Пилмән суына, эткәй.

Закуан. Бәләкәй чакларында аңа җиңелрәк булды, эткәй! Бөтен авырлыклар иң элек минем җилкәгә төшә иде... Һаман да оныта алмыйм. Ач-ялангач, тишек чабаталардан мәктәпкә барабыз...

**Ул сөйләгән чакта Зәримә керә һәм туктап кала. Аны беркем дә күрми. Ул кулына зур таба белән коймак тоткан.**

Мәгави. Һу! Ул заманнарны искә төшерә башласаң!..

Закуан. Ә мин бүгенгә кадәр аяк киемен ике размерга зурракны киям. Чөнки мәктәпкә барганда аякларымны туңдырдым. Һаман өшиләр. Укытучы безгә Ломоносов турында сөйли: имеш тә, аңа уку шулкадәр кыен булган — көненә кайчак бер кадак кына ит ашап кала икән! Корсакларыбыз, ачлыктан бөрешеп, аркабызга ябышкан, ә без, авызыбызны ачып, Ломоносовны җәллап утырабыз...

Г ү з ә л. Күпме була инде ул безнеңчә?

З а к у а н. Дүрт йөз грамм.

З ә р и м ә (*ирония белән*). Менә ни өчен авылдан качып киткәнсең икән, Закуан? (*Барысы да аның ягына борыла. Коймакларны өстәлгә куя.*) Аның урынына, хәзер бөтенләй башкача булачак... Йортың гына да ни тора! Я ничек, яңа өең ошадымы?

З а к у а н (*гаҗәпләнеп*). Яңа өем?!

М ә г а в и. Катышмый тор, хатын!

З ә р и м ә. Бәй... Ишетмәдеңмени әле? Эти синең өчен салды ич ул йортны.

**Тынлык урнаша, Закуанның җавабын көтәләр.**

З а к у а н (*көлеп җибәрә*). Тамакка утырта яздың бит, Зәримә! Эткәй, дөресме ул?

В а р и с. Соңыннан сөйләшербез.

З ә р и м ә (*тыныч*). Кемгә чәй ясыйм? Закуан, сиңа сөт беләнме, болай гынамы?

З а к у а н. Болай да ярый... (*Пышылдап*). Чынмы ул? (*Этисе ягына ымлый*).

З ә р и м ә. Эти, Закуан чынмы ул, дип сорый?

З а к у а н (*үпкәләп*). Нигә инде син?..

В а р и с. Соңыннан, дидем ич. Ашагыз тыныч кына.

**Тынлык.**

З ә р и м ә. Хатыныңны нигә алып кайтмадың, Закуан? Былтырдан бирле күзгә башка күренми.

З а к у а н. Шулай туры килде. Сессиясе башланып калды.

З ә р и м ә. Җәйгә кайтамы соң?

З а к у а н. Күз күрер әле...

М ә г а в и. Җылы якка-мазар барырга ниятләнмисездер?

З а к у а н. Якын-тирәдә генә уйлаганыбыз юк әлегә. Монда кайтсак та... Кыш быел ятимнәр кышыдай җылы килде — җәй салкын булырга охшый...

Г ү з ә л (*үрсәләнеп сикереп тора*). Мин утыра алмыйм монда. (*Ишеккә ташлана.*)

З ә р и м ә. Син кая? Кыланмышың кырга сыймый.

Г ү з ә л. Шах түткиләргә кунарга киттем! Алар киткәч, кайтырмын! (*Закуан белән Айдарга ымлый.*)

М ә г а в и. Адәм йөргесез саулык ашамы? Акылыңнан шашма.

Г ү з ә л. Әйе! Мин акылдан шашам! Ә сез — нормаль кешеләр! Шундый хәлләрдән соң да берни булмагандай авызга-авыз куеп рәхәтләнеп утыра аласыз!

М ә г а в и. Нинди хәлләрдән соң?!

Г ү з ә л. Ничек шулай итә аласың син, эти?! Горурлыгың кайда синең? Әнкәйгә кара! Свиданиега әзерләнгән кебек ясанып кергән! Сезгә карап минем күңелем болгана! Нинди принципсыз кешеләр сез, әнкәй?!

З а к у а н (*тирән гаҗәпләнеп*). Менә бу очрашу...

Г ү з ә л (*нәфрәт белән*). Ә мин сезнең белән сөйләшергә дә теләмим! Күрәлмим мин сезне!

З ә р и м ә (*тыныч*). Ул синең этиең, Гүзәл кызым.

М ә г а в и (*рәнҗеп*). Зәримә! Кем теленнән тарта?!

**Авыр тынлык урнаша. Гүзәл өйдән чыгып йөгерә. Айдар бабасы янына кереп китә.**

З а к у а н. Менә бу чынлап та минем өчен көтелмәгән яңалык!

З ә р и м ә. Дәлилләр кирәкме?

**Айдар бабасы ягына керә торган ишекне ныклап ябып куя һәм бабасына ташлана.**

В а р и с. Тыңлама син аларны, улым. Монда утырып тор. (*Торып, балалары янына чыга.*) Оят түгелме сезгә, балалар?

З ә р и м ә (*тыныч*). Мин сезне алдан кисәтеп куйдым, эти.

В а р и с. Ә балаларыгызның ни гаебе бар?!

З ә р и м ә. Кызым болай да сизенә иде инде. Кеше авызыннан ишеткәнче, үз анасы әйтү яхшырак.

З а к у а н. Ә нигә моңынчы әйтмәдең?

З ә р и м ә. Кирәк, дип тапмадым. Ә хәзер — вакыты килде!

**Әчке бүлмәдән Айдар чыга һәм этисен чыгып китәргә кыстый.**

З а к у а н. Нәрсә кирәк?! Туктап тор, монда ачыклыйсы нәрсәләр бар!

З ә р и м ә. Малаең алдында ачыкларга телэмисеңдер?

З а к у а н. Нәрсә аңлый ул!

В а р и с (*Айдарга*). Бар, улым, чыгып тор.

**Айдар чыкмыйм, дип баш селки, этисенең җиңен тарта.**

З а к у а н. Туктап тор, дим! Инде хәзер нишләмәкче буласың, Зәримә?

М ә г а в и. Монда Зәримә түгел, мин нидер эшләргә тиеш, минемчә...

З ә р и м ә (*ирөнә, ачу белән*). Син эндәшми генә утыруыңны бел инде! Элегрәк уйларга кирәк иде аны. Мин монда син эшлисе эшне хәл итеп утырам! Ганлә башлыгы эшлисе эшне! Шулай, эти, бер малаеңның кызын үстерәм, икенчесе белән торам. Үзе мине ташлап китмәсә — аерылырга теләгем юк! Тик син бездән, эти, булмастайны таләп итәсең! Минем ата-бабаларым яшәгән монда, аларның йорт нигезләре миңа калды. Ул нигезне мин генә саклый алам. Синең тырышуың да, эти, борынгы нигезегезне бирмәү. Тик син сайлый аласың: синең уллары икәү. Берсен куып

җибәрсәң дә нигезегез югалмый! Син шул турыда уйлап та карамадың! (*Закуанга.*) Син монда яшәргә кайтсаң, авторитетың белән авылны саклап кала аласың, дип уйлый әти. Ә син кайтсаң, үзең аңлыйсың — Мәгави белән без авылны ташлап китәргә мәҗбүр булачакбыз! Я, кайсысын сайлыйсың, Закуан?

З а к у а н. Берни аңламыйм! Кем кайтырга җыена?! Нәрсә турында сөйлисез сез?! Башта Гүзәл турында ачыклап бетерик!

М ә г а в и. Гүзәлгә кагылма!

З а к у а н. Ишеттең ич, хатының нәрсә диде!

В а р и с. Бәхәсне туктатыгыз! (*Зәримәгә.*) Син хаклы, Зәримә килен. Ирең хәл итәргә тиеш иде моны. Калганын иртәгә сөйләшербез. (*Үз ягына кереп китә һәм ишекне ябып куя.*)

**Өстәл артында дүртәү утырып калалар. Айдар һаман да этисенең җиңенә тотынган, ә анысы куркыныч көткәндәй Зәримәгә карап тора, Зәримә горур рәвештә аңа карый, Мәгави башын иеп уйга калган.**

## Икенче бүлек

*Мәңгелектән тагын бер мизгел*

**Кара болытлы иртә. Кызылтау белән Дүртмаңгайның түбәләре шадраланып, ямьсезләнеп беткән.**

**Тузанлы юл өстендә Айдар ялгызы басып тора.**

Д ү р т м а ң г а й (*уяна*). Ф-фу!.. Бүген төнлә тагын кемдер баш түбәмдә учак яккан, ахры! Бөтен борын тишекләремә сөрем тулды!

К ы з ы л т а у. Саташма, Дүртмаңгай... Күптән инде беркемнең дә менгәне юк. Уйлары синдә түгел. Иоклап ятмасаң, төнге хәлләрне үзең дә күргән булыр идең!

Д ү р т м а ң г а й. Мин кызыгырдай нәрсә юк бу дөньяда!

К ы з ы л т а у. Түбәнгә кара.

Д ү р т м а ң г а й. Карадым. Шуннан?

К ы з ы л т а у. Үзгәреш сизмисеңме?

Д ү р т м а ң г а й. Нинди үзгәреш? Кичә дә биш-алты йорт бөрешеп утыра иде — бүген дә шулар гына.

К ы з ы л т а у. Дүрт маңгаеңа бер рәтле күзең юк икән! Күрмәсәң — тыңла. Бүген төнлә бу авылда шаккаткыч хәл булды. Иң матур яңа йортны ут төртеп яндырдылар. Борыныңа шуның сөреме кергәндер!

Д ү р т м а ң г а й. Ут төртеп бик дөрес эшләгәннәр! Барыбер язмышлары хәл ителгән инде.

К ы з ы л т а у. Юкны лыгырдамачы!

Д ү р т м а ң г а й. Тиздән бөтенесен дә дүртаяклылар ыруы куып җибәрәчәк!

К ы з ы л т а у. Кем әйтә аны?

Д ү р т м а ң г а й. Хәтерендәме, элек монда ике аяклы кыргый кабиләләр яши иде? Син вулкан белән чуала идең әле ул вакытларда. Сәер нәмәрсәләр иде алар! Җир өстендә нәрсә йөгерә — шуны тотып ашыйлар иде. (*Көлә.*) Соңгысын тотып ашадылар да — ачтан тәгәрәшеп дөмектеләр! Ә бу ике аяклылар борынгы бабалары хәленә калудан куркып, күрәсең, үзләре дүртаяклылар ыруы үрчетәләр. Бу авылда хәзер дүртаяклылар ыруы арткан саен, ике аяклылар кими бара! Шулай булгач, нәтиҗә ясарга да күп акыл кирәкми. Киләчәктә дөнья дүртаяклыларга калачак! Ха-ха-ха!

К ы з ы л т а у. Сиңа шул шатлыкмы?! Фикереңне чебеш көйгә ачып салырга ашыкма, дип ничә әйттем! Таш маңгайларыңа кара, ичмасам: шул дүртаяклылар тишкәләп бетерде ич инде!

Д ү р т м а ң г а й. Ә үзеңнең маңгаеңны кем актарды?!

К ы з ы л т а у. Шул мырк-мыркләр булмый, кем булсын! Бу авыл кешеләре гомергомергә минем Бала Чишмәдән су алалар иде, хәзер борылып караучы да юк. Дүртаяклылар пычратып бетерде!

Д ү р т м а ң г а й. Синең өчен барыбер түгелме? Яши белмиләр, димәк! Үзләренә үпкәләсеннәр!

**Айдар йодрык күрсәтә. Кызылтау белән Дүртмаңгай тынып кала.**

### И к е н ч е   к ү р е н е ш

**Икенче көн иртән. Яңа йорт урынында бары тик янып күмерләнгән бүрәнә кисәкләре, кисәүләр генә өелеп ята.**

**Варис картның өендә киеренке тынлык. Варис карт үзе эчке якта ята. Ул саташа булса кирәк. Сирәк-сирәк кенә бәйләнешсез берничә сүз әйтеп куя һәм тагын онытыла. Алгы якта Закуан белән Мәгави кайгы эчендә утыра. Закуан, вакыт-вакыт сикереп торып, арлы-бирле йөренә. Ул энесе алдында үзен бераз уңайсыз тота.**

В а р и с. Хәбиров малае Наил салдырды ул чучка фермасын. Элек умарталык иде ул урында. Наил, мәлгунь, туздырып ташлады... Чучка малай!

**Закуан** (*ишек янына килә*). Саташа, ахры?.. Әткәй! (*Варис карт эндәшми. Бераз көткәннән соң.*) Я, нишлибез, энекәш?

**Мәгави.** Нишлисең... Күтәбез.

**Закуан.** Нәрсә көтәбез? Тагын күпме көтәргә була? Үлгәненме?

**Мәгави.** Кычкырма. Ишетә-нитә калса...

**Закуан.** Ишетерлеге калмаган инде. Больницага илтеп карарга кирәк! Болай тик утырып булмый бит инде. Кул кушырып.

**Мәгави.** Врач әйтте бит — файдасыз, диде. Тәнен тишкәләп азаплау гына булыр. Әткәй үзе дә тегендә-монда кузгатып йөртергә кушмады.

**Закуан.** Ниндидер... идиотизм! (*Энесе янына килеп утыра.*) Ә пожарны нишләтәбез?

**Мәгави.** Зурга җибәрәсең килмидер ич?

**Закуан.** Болай да калдырып булмый бит инде! Йорт кадәр йорт янсын да! Әткәйдә дә Әндри казнасы юк. Тикшертергә кирәк. Случайно януы мөмкин түгел. Яшен сукты дияр идең — төн чалт аяз булды. Электр очкынына да сылтап булмый — тока тоташтырылмаган. Берәрсе ялгыш тәмәке төпчеге ташлагандыр дисәң — бу авылда тартучы юк кебек. Бу тирәдә чит кешеләр дә күренмәде, диләр. Димәк... кемдер үч итеп ут төрткән булуы мөмкин!

**Мәгави.** Кем?

**Закуан.** Белсәм, баш ватып утырыр идемме монда! Әткәйгә үчле кеше юк идеме авылда соңгы вакытта?

**Мәгави.** Кемнең үче булсын инде аңарда!.. Ярар. Янган — беткән. Узган эшкә салават. Кире кайтарып булмый. Гүзәл белән малаең Айдар турында кайгыртып утырам. Ул мескеннәр нишләп йөри икән...

**Закуан.** Пычагым булсынмы аларга!

**Мәгави.** Ә кичәге... скандал?

**Закуан.** Авыл психологиясе синдә! Егерменче гасыр азагы балалары алар. Синең белән минем кебек түгелләр. Башка камырдан. Хәзер алар тормышка вообще бүтәнчә карыйлар.

**Мәгави** (*ачуын тыеп*). Гүзәлне белмисең син!..

**Закуан** (*киная белән*). Үз кызым булса дамы?

**Мәгави** (*кискен*). Кагылма!

**Закуан.** Ярар, ярар — синеке булсын. Претендовать итмим ич.

**Мәгави.** Җитте бу турыда.

**Закуан.** Тыңлап торам да, энекәш, аптырыйм мин сиңа...

**Мәгави.** Әйтеп бетер?

**Закуан.** Яхшы. Бер минутка. Бертуган братлар икәнлегебезне онытып торыйк. Абстрактно фикер йөртеп карыйк. Әйтик, сиңа бер хатын очрый. Матур, яшь, акыллы, кыскасы — теләсә кем күзе төшәрлек хатын. Андый очрашулар була. Аның белән йокларга да мөмкин. Шуны белә торып аның белән тормыш кору... тем более — абыеңның сөяркәсе белән!

**Мәгави** (*тыныч*). Туган абыем булмасаң, пошляк син, дип йөзеңә бәреп әйтер идем, Закуан абый. Ничек тоталар икән сине министрлыкта?

**Закуан.** Авызыңны үлчәбрәк сөйлә!

**Варис.** Эх! Синең кебек чучкалар күбәебрәк китте дөньяда...

**Закуан белән Мәгави тынып калалар. Янына керәләр.**

**Закуан.** Әткәй, кем турында әйтәсең? (*Варис карт җавап бирми.*)

**Мәгави** (*бераздан*). Һаман саташа... Син кит булмаса, Закуан абый. Эшең көтә торгандыр. Әткәй белән ул-бу хәл килеп чыкса, хәбәр итәрбез... Син монда чакта Гүзәл дә үз-үзенә урын тапмаячак. Зәримә дә...

**Закуан** (*тирән гаҗәпләнеп*). Пожарны ачыкламыйчамы?! Урынымнан да кузгаласым юк! Сиңа барыбер. Синең өчен төзелгән өй түгел.

**Алгы якка чыгалар.**

**Мәгави.** Янмаса, торырга кайтыр идеңмени?

**Закуан.** Күз күрер иде әле. Гомумән... Беркемдә дә санаусыз мал ишелеп ятмый.

**Мәгави.** Тикшереп-нитеп маташасы юк! Мин төрттем!

**Закуан** (*хәйран кала*). Син?! Ни өчен?!

**Мәгави.** Сине кайтармас өчен.

**Закуан.** Тукта, чынлап сөйләвеңме бу?!

**Мәгави** (*сынау белән*). Ә син мине судка бирә аласың. Бирергә теләмәсәң — болай да түләрмен. Берьюлы түгел, әлбәттә. Өлешләп. Хакын килешербез. Күпме дип әйтәсең — шуңа риза.

**Закуан.** Туктале...

**Мәгави.** Туктап торасы юк, Закуан абый. Акчасын бүген үк түли башларга мөмкин.

**Закуан.** Нинди акча?! Башыма сыймый! Ничек кулың күтәрелде?! Атаң салган йортка!

**Мәгави.** Мин шундый кеше, күрәсең. (*Көлемсери.*) Авыл идиотизмы. (*Ул үзен өстеннән авыр йөк төшкәндәй тота.*) Килештек? (*Абыйсына кулын суза.*)

**Закуан** (*кул бирми*). Колхоз Герострать килгән!

Мәгави (*елмая*). Геростратмы, түгелме — ишеттең. Әткәй өчен кайгырма, караучы табылыр. Айдарың калып торыр. Малаең шәп егет. Үзеңә охшамаган! (*Чыгып китә.*)

**Закуан аптырап басып кала.**

Закуан. Чынлап та идиот! (*Айдар кайтып керә. Ул этисенә күтәрелеп карамый.*) Кайда йөрисең син?.. Миңа китәргә вакыт җитеп килә. Решать итәргә кирәк. Монда калып торасыңмы, юкмы? (*Айдар калам, дип баш кага һәм бабасы ягына юнәлә*). Тукта, аңлап бетермәдем: калырга телисеңме? (*Айдар дәреслап баш селки.*) Тик белмим әле, улым... Мондагы хәлләрдән соң... Әйдә, улым, ачыктан-ачык сөйләшик. Син инде сабый бала түгел. Кое-что понимаешь. Ирләрчә сөйләшергә була дип уйлыйм. Минем сиңа ничек относиться иткәнне үзең дә әйбәт беләсең. Мин әниеңне дә, сине дә бик яратам. Телдән язгач, мәктәптә иптәшләрең алдында үзеңне уңайсыз тотарсың, дип өйдә генә укыттык. Вакытыбызны, акчабызны жәлләмәдек. Һәм начар белем бирмәдек, дип уйлыйм. Мин боларны сиңа шуның өчен исеңә төшерәм, улым... Хәтереңдә тот — синең алда минем бер гаебем дә юк. Инде кичәге сөйләшүгә килсәк... Үсә төшкәч үзең дә яхшы аңларсың. Кичә син ишеткән нәрсәләр әниең белән өйләнешкәнче булган хәлләр. Гүзәлнең минем кыз икәнлеген мин үзем дә кичә генә беренче мәртәбә ишеттем. Без, чынлап та, Зәримә апаң белән бәлки, өйләнешкән дә булыр идек... Минем белән Казанга китәргә теләмәде. Әнисе чирле иде, атасы да күптән түгел генә үлгән чак. Ә миңа ашыгыч Казанга укырга китәргә кирәк иде... Теперь понял, почему мы с ней расстались? (*Айдар эндәшми.*) Шул елны Мәгави абыең армиядән кайтып төште. Мин киткәч ике айдан соң өйләнешкәннәр. Ә мин ишетми дә калдым. Вот и все. Надеюсь, папаң турында начар уйламассың? (*Айдар башын иеп тора*). Ярар, үскәч аңларсың... Ә син беләсеңме, кем ут төрткән? (*Айдар беләм, дип баш кага.*) Мәгави абыеңмы? (*Айдар ул түгел, дип кире кага.*) Ә кем ул чагында? Мәгави абыең үзе әле генә миңа шулай диде ич! (*Айдар җилкәсен кыса.*) Ә кем төрткән?!

**Айдар әйтмим, дип башын кага һәм бабасы ягына кереп китә. Урындыкка барып утыра. Тынлык.**

Что за чертовщина! (*Ишеккә юнәлә.*)

**Зәримә килеп керә. Аны күргәч, туктап кала.**

Ә, Зәримә... Мәгави кайда? Өйдәме?

Зәримә. Тагын ни булды? Әтинең хәле ничек? Даруын каптырырга вакыт.

Закуан. Йоклыймы, һушсыз ятамы — билгесез. Мәгави төнлә ничәләрдә кайтты?

Зәримә. Нигә кирәк булды әле ул сиңа?

Закуан. Кичә кич эзләткән идем — күренмәде. Күрше авылга китте, диделәр. Шуңа соравым.

Зәримә. Үзең күрдең ич, пожар бетәрәк кайтып керде. Шул гынамы соравың?

Закуан. Ә... кызың кайда?

Зәримә. Каян белим мин... Нинди допрос тагын? Бала болай да...

Закуан. Кызык... Күңелем ышанмаган иде аны!

Зәримә. Нәрсәгә ышанмаган иде?

Закуан (*канәгатьлек белән*). Җитди нәрсә түгел. Пожар турында ни уйлыйсың, Зәримә? Кем булыр икән?

Зәримә. Ничек — кем булыр икән?

Закуан. Ут төртүче.

Зәримә. Чынлап та төрткәннәрмени?

Закуан. Һичшиксез.

Зәримә. Менә ничек?..

Закуан. Тикшерүче чакыртырга кирәк булыр.

Зәримә. Шикләнгән кешең бармы соң?

Закуан (*серле*). Ачык кына әйтеп булмый әлегә... Ә син ничек уйлыйсың? Иң беренче пожарны син күргәнсең, диләр.

Зәримә. Допрос ясарга булдың?

Закуан (*шаяртуга борып*). Допрос?! Аллам сакласын!

Зәримә. Юкка тырышасың, Закуан. Тикшеренүләреңне ташларга киңәш итәр идем мин сиңа. Тынычлык китермәс ул сиңа.

Закуан. Күрәзәлек итүеңне ташламагансың, ахры! (*Көлә.*) Урамда егерменче гасыр азагы — ә син һаман күз бууучы!

Зәримә. Күз бууның катнашы юк монда. Авылда яшәсәң, син дә минем сүзне әйткән булыр идең. Безнең авылда сер юк.

Закуан. Әйтимме, сезнең тормышны мин нәрсәгә охшатам?

Зәримә. Әйтеп кара?

Закуан Исеңдәме икән, бервакыт Кызылтау өстендә урман янган иде. Мин дүртенче класста чак бугай.

Зәримә. Кыскарак әйтеп булмыймы?

Закуан. Аңлаешлырак булсын дим. Безне дә сүндерешергә кудылар. Шунда бер нәрсә күреп шаккатканым әле дә исемнән чыкмый. Шартлый-шартлый урман яна, төтен, ялкын — чыдар әмәл юк. Бер аланга йөгереп чыктык шулай. Уртада черек имән ята. Ул да яна башлаган. Ике башы да пыскып маташа иде. Якынрак килеп карыйбыз — имәннең уртасындарак зур кырмыска оясы. Нишлиләр дисең? По-

жарга исләре дә китми, үз эшләре белән мәж килләр!

Зәримә. Ә нишләргә тиеш соң алар, синеңчә? Сезнең белән бергә пожар сүндерешергәме?! *(елмая.)*

Закуан. Ни әйтергә теләгәнемне аңламадыңмы?

Зәримә. Аңладым. Ник аңламаска. Без дә шул кырмыскалар шикелле дип әйтмәкче буласың! Ялгышмыйсың микән, Закуан? Читтән карап кына нәтиҗә ясыйсың!

Закуан. Белмим, белмим... Кайчакта читтән карау да мешать итми!

Зәримә. Тикшерүче килеп, ут төртүчене тапса, нишлисең?

Закуан. Кызык сорау. Җавапка тартырлар!

Зәримә. Әгәр дә ул якын кешең булып чыкса?

Закуан. Закон алдында бар кеше дә тигез түгелмени? Алай булса — кызганыч, әлбәттә! Башында мие булган кеше моны эшләмәс. Нәселебездә андый кешенең табылуы беребез өчен де күңелле хәл түгел. Геннар белән что-то неладно дигән сүз ул!

**Әчке яктан Варис картның ыңгырашып куюы ишетелә. Айдар бабасының маңгаеннан тирен сөртә.**

Варис. Кем бу?.. Ә, синме, карчык?.. Эх, карчык, карчык... Миннән алда китәм дигән идең... Киресенчә килеп чыкты... Мин беренче булып китеп барам. Я, я, балавыз сыгарга ашыкма. Шулай язган, күрәсең... Яңа йортка күчәрсең... Закуаннар янына... *(Тына.)*

**Закуан белән Зәримә аның янына килеп, тыңлап торалар. Зәримә Варис картның маңгаена юешләп сөлге куя. Айдар өмет белән бер Зәримәгә, бер әтисенә карый.**

Зәримә. Улыңны алып чыгар идең моннан. Бала күзе өчен түгел.

Закуан. Озакка бармас, ахры... *(Сүзен әйтеп бетерми, тынып кала.)*

Зәримә *(кискен)*. Мин күрәзәче түгел!

Закуан *(югалып)*. Әйдә, улым, монда утырма. *(Айдар бабасына ябышып, баш тарта.)*

Зәримә. Йокыга китте... *(Чыга. Закуан аның артыннан иярә.)* Мәгави да кирәк чакта әллә кайларда йөри!

Закуан. Да... *(Катгый.)* Сез теләсә нәрсә әйтерсез, ләкин мин пожарны тикшертмичә калдыра алмыйм! Пожар булмаса, әткәйнең хәле болай ук кинәт начарланмас иде. Беләсеңме, Мәгави бая миңа нәрсә диде?

Зәримә *(бүлдерә)*. Мәгавины калдыр! Аңа кичәге хәлләр дә муеннан ашкан. Көне-төне ут йотып йөри!

Закуан. Мин калдырыр идем дә, ул үзе миңа...

Зәримә. Аның урынында башка берәү булмаганга сөен!

Закуан. Минемчә, син минем белән мондый тонда сөйләшергә...

Зәримә *(бүлдерә)*. Хакым булганга әйтәм! Ә кичәге хәлләрдән соң шиккә төшкән булсаң — оныт. Хафаланма. Синнән үч алу нияте белән дә әйтмәдем мин ул сүзне. Вәгъдәләшкән кызың булмадым. Гүзәлнең үз атасын белмәве дә синнән тормады. Аллага шөкер, ятим үсмәде. Мәгави да аны кызы урынына үз күрә, Гүзәл дә Мәгавины әти дип үлеп тора. Сине эзәрлекләргә теләсәм, әллә кайчан капкынга эләккән булыр идең инде! Икесен дә тынычлыкта калдыр.

Закуан. Кем сине эзәрлекли, ди? Пожар турында әйтәм мин!

Зәримә. Ут төртүчене табасың килсә, тынычлан — ул синең каршыңда.

Закуан. Син?!

Зәримә. Калганы — синең эш. *(Чыгып китә.)*

**Айдар бабасы ягыннан чыгып, Зәримә артыннан шаккатып карап кала.**

Закуан. Берни аңламыйм... *(Малаен күрә.)* Ишеттеңме?.. Дөресме? *(Айдар ул түгел, дип баш кага.)* Ул түгел?! Тагын нинди табышмак? Кем соң алай булгач?!

**Айдар бабасы янына кереп китә.**

*(Ныклы бер карарга килеп, әчке бүлмәгә керә.)* Бар әле, улым, Мәгави абыең белән Зәримә җиңгәңне чакырып алып кер. Тиз бул, икесе дә керсеннәр! Ул арада гына бабаңа шайтаным да булмас. Мин монда ич.

**Айдар тын гына ишеккә юнәлә, ләкин чыгып китәргә өлгерми, Мәгави үзе килеп керә.**

Мәгави *(пышылдап)*. Әткәй нихәлдә? Аңына килмәдеме?

Закуан *(алгы якка чыга)*. Йоклый, ахры. Хатының кайда калды? Керсен әле монда.

Мәгави. Кайда булсын — өйдәдер. Тиздән Турайдан врач килеп җитәчәк. Үзәккә барып, телефоннан шалтыраттым. Юньсез! Әткәйнең хәлен сөйләп биргәч, әҗәле җиткән кешене алып кала алмыйм инде, минем участокта аның кебек кабер көтүчеләр алтау, диде дә трубканы ташлады. Янында булсам, якасыннан ала идем. Кабахәт нәрсәне. Укол ясап китәрмен, дигән булды, судка тарттырам дип кабат шалтыраткач... Елдан-ел кешеләр юньсезләнә бара, әллә инде... Сезнең заслуга! Педагоглар заслугасы!

Закуан. Ташлале!

Мәгави. Мәгариф министрлыгында утырасың ич! Кеше тәрбиялибез, дип күкрәк кагасыз!

Закуан (*түземсезләнеп*). Калдырып тор! (*Айдарга.*) Бар, җиңгәң керсен. (*Айдар чыгып китә.*)

Мәгави. Зәримә нигә кирәк монда?

Закуан. Ашыкма. Ул кергәч аңларсың.

Тынлык.

Варис (*саташа*). Дөнья таулардан гына тормый, Айдар улым... Тауның да итәге булмаса — түбәсе дә булмас иде... (*Тына.*)

**Мәгави белән Закуан этиләре янына керәләр.**

Мәгави. Нык бетереште карт... Үзе һаман оныгына акыл биреп ята!

**Варис картның тигезрәк сулый башлавын күргәч, кире алгы якка чыгалар.**

Варис (*кинәт ачык тавыш белән*). Пыскып яткан учак тирәсенә кул җылытырга да килмиләр, Мәгави улым! Пыскып яшәмә! Ир бул! Дөрләп яшә!..

Мәгави (*атлыгып этисе янына керә*). Әткәй! Син мине ишетәсеңме?.. Бу мин — Мәгави... Кай җирең авырта, әткәй? Хәзер врач килә!

**Тынлык. Бары тик Варис картның авыр-авыр сулаганы күренә.**

Закуан. Азаплама картны. Күрәсең ич! Акылына зыян килгән, ахры... Зәримә нишләп тора инде?..

**Ишектә Зәримә белән Айдар күренә.**

Зәримә (*керә-керешли борчулы*). Әткәйме?!.

Закуан. Юк, мин чакырттым сине, Зәримә.

Зәримә (*ялт итеп иренә карап ала*). Теге мәсьәлә буенча булса — Мәгави белән хәл итегез!

**Айдар әчке якка бабасы янына кереп утыра. Ишек ачык кала — моңа игътибар итмиләр.**

Закуан. Аяк өсте генә сөйләшә торган нәрсә түгел. Утырыйк. (*Өстәл янына барып утыра, өстәлдә яткан балык тезмәсен идәнгә томыра.*)

**Зәримә белән Мәгави бер-берсенә карашып алалар һәм өстәл янына килеп утыралар.**

Зәримә. Утырдык. Тыңлыйбыз?

Закуан (*Мәгавига карап*). Кызык килеп чыга бит әле, килен-энекәш... Шактый кызык!

Мәгави (*сагаеп*). Нәрсәсе кызык?

Закуан. Моннан биш минут кына алда хатының Зәримә...

Зәримә. Тикшерүдән тәм табасың, ахры! Сузма инде! Мин төрттем утны, дидем. Һәм баш тартырга уйлаганым да юк!

Мәгави. Син?! Чынлап әйтәсеңме?!

Зәримә. Әйтеп торам ич!

Закуан (*ирония белән*). Я, инде хәзер нишлибез, энекәш?

Зәримә (*сүзенең төбен аңлап бетерми*). Судка бир! Сиңа дип салынган өй. Сыерыбызны сатып булса да түләрбез!

Мәгави (*ул хатынының сүзләрен чынга ала*). Ала-ай...

Зәримә. Алдан ук кисәттем мин сине. Гаилә башлыгы була бел дидем!

Закуан (*көлемсерәп*). Ул аны доказать итте, Зәримә. Бик шәп доказать итте!

Зәримә. Нәрсә эшләде?

Закуан. Үзеннән сора.

Зәримә. Нишләдең, Мәгави?

Мәгави (*сүзне читкә борырга тырышып*). Юк белән башымны катырмагыз әле. Турай врачын сүгеп ташладым. Шуны әйтмәкчедер. Эти янына чакырган идем, кирәләнеп маташа, юньсез!

Зәримә. Шулмы батырлык?!

Закуан (*түземсезләнеп әле берсенә, әле икенчесенә карап торганнан соң*). Калдырыгыз әле шул врачыгызны! Файдасы тияр дисезме! Монда җитди нәрсә турында сүз бара!

Зәримә. Кызык... Чирдән дә җитди тагын нәрсә бар икән дөньяда!

Закуан. Кызык шул! Бик кызык! Башта берегез: мин төрттем утны дип, гаепне үз өстенә алып чыгып китте, аннан соң — икенчегез!

Зәримә. Ничек, ничек?

Закуан. Иреңнән сора, дидем ич!

Зәримә (*гаҗәпләнүе чиктән ашкан*). Мин төрттем, дип әйттеңме?! (*Мәгави эндәшми.*) Мин чыгарган бәет түгел, үпкәләмә, Гайнетдин, диярсең!

Закуан (*түземлеге бетә*). Җитте! Мәче-күсе уены уйнап утырмагыз әле монда! Кемне якларга тырышуыгызны бик яхшы беләм мин!

Зәримә, Мәгави (*икесе бергә*). Кемне яклыйбыз?!

Закуан. Жертвагыз кирәкми миңа!

Зәримә (*горур*). Беркем дә жертва түгел! Ярар, чынын әйтәм. Барыбер ачыл-

мый калмас! Мәгави дөресен әйткән. Пожар — икебезнең эш. Тик Мәгави минем катнаш та барлыкны белми калды. Ике туган арасында гауга чыкмасын, дип үз өстемә генә алмакчы идем. Рас Мәгави үзе дөресен әйткән икән, бик әйбәт! (*Мәгавигә.*) Әйдә, картым!

Мәгави. Сабыр... Бер нәрсә башыма сыймый! Аңлый алмыйм мин сине, Закуан абый.

Закуан. Ә мин сезне аңларга тырышам — барып чыкмый! Кылмаган эшне үз өстегезгә алып, нишләмәкче буласыз сез?! Нәрсә доказать итәсез? Благородство күрсәтәсезме?!

Зәримә. Ничек инде кылмаган эш? Әнә бит кисәүләре яр башында ята!

Закуан (*аның сүзләрен игътибарсыз калдыра*). Наивный кешеләр сез!

Мәгави. Без наивный да булыйк ди... Ә син үзеңнең нәрсә эшләгәнеңне чамалыйсыңмы әзрәк булса да? Күрше бүлмәдә әткәй бер йотым су йота алмыйча үлем түшәгендә интегеп ята, ә син!.. Ниндидер йорт әткәйдән кадерлерәкмени сиңа?! Кешедән кадерлерәк! Оят түгелме!?

Закуан (*хәтере калып*). Син мине... демагогия белән оялтырга азапланма! Благородный кеше килгән! Йорт әткәйнең соңгы якты истәлеге булачак иде! Без гаепле кешене табарга тиешбез! Шул чак благородный булырсың! Әткәй алдында долг үтәвең шул булыр! Йорт үзе өчен салынганга тырыша бу, дип уйлыйсыздыр минем турыда! Төкерәм мин андый гына йортларга! Әткәйнең хәләл көче кергән аңа! Ул аңа бөтен осталыгын, рухи байлыгын биргән! Миңа шул кадерле! Ә сез монда качыш-посыш уйнап утырасыз! Миңа ярдәм итәсе урында!

Зәримә. Кая инде безгә, кара акыл белән андый югары материяларны аңларга!

Закуан. Бик кара акылга баеп киткәнсез әле барыгыз да!

Мәгави (*әрнеп*). Иң аянычы шунда — син бу сүзләреңә чын күңелдән ышанасың бугай, Закуан абый...

Закуан. Нәрсә, нәрсә?!

Зәримә (*үз итеп*). Ул барыбер сине аңлый алмый, Мәгави. Әйдә. Су язып май төшмәс барыбер. (*Кузгала.*)

Закуан (*хәтере калып*). Юк инде! Китми генә торыгыз! Так вот! Пожарга Мәгавинең дә, синең дә катнашың юк...

Зәримә. Кемнең катнашы бар соң алай булгач?

Гүзәл килеп керә. Ул бик нык дулкынланган.

Гүзәл (*Закуанга*). Допрос алмагыз алардан! Бөтен авыл шаулый. Закуан Мәгави белән Зәримәне пожар өчен судка бирергә уйлый, диләр. Алар гаепле түгел! Мин төрттем! Мин төрттем — мин җавап бирермен! (*Кыю рәвештә барысына карап чыга. Тынлык урнаша.*)

Зәримә (*сокланып.*) Карагызчы моны!

Закуан (*тыныч*). Ә мин шикләнмим. Ну что ж, преступление есть преступление, җавабын бирерсең, кызый. Безнең алда. Бабаң каршында, наконец! (*Житди.*) Тиздән үнҗидегә керәсең. Ялгышмасам.

Гүзәл. Ялгышмыйсыз! Җаваптан качарга уйласам, әйтмәс идем! Теләсәгез нишләтегез. Төрмәгә ябып куйсагыз да бер тамчы да курыкмыйм! Мин барыбер өйдә калмас идем...

Закуан. Анысы синең эш. Телисең икән җәһәннәмгә олак!

Гүзәл. Җәһәннәмгә?.. (*Үчәнлек белән.*) Ә нигә? Уйлап карарга кирәк. Озакламый авылыбызда барыбер зияраттан башка берни дә калмаячак! (*Ул ни сөйләгәнен үзе дә белештерми кебек.*) Ата-ана белән бала арасы пүчтәк кенә нәрсә икән ул! Мин генә ул, юләр, башка төрле уйлап йөргәнмен! Ана хакы — изге хак, имеш!

Зәримә (*әрнеп*). Гүзәл! Нервылар болай да какшаган чак...

Гүзәл. Ә сиңа барыбер түгелмени? Ялгыш кына, уйнаштан гына тапкансың ич син мине!

Зәримә. Югал күз алдымнан! (*Яңагына суга.*)

Гүзәл (*икенче яңагын куя*). Бу ягыма да сугарга мөмкин. Дөньяга килергә хакы булмаган кешегә ярый ул. Тормасын күз алдында әлекке гөнаһларны искә төшереп! Я, нигә тынып калдыгыз? Асыгыз-кисегез!

Мәгави. Тынычлан, кызым. (*Янына килә, кулыннан ала.*) Зәримә, син хаклы түгел!

Гүзәл. Тынычлан?! Мин тыныч, моңынчы әти дип саналган абзый! Ә шулай да кызганыч...

Мәгави. Нәрсә кызганыч?

Гүзәл. Синең чынлап та үз әтием булмавың. Мин барысын да беләм. Бүген төнлә мине эзләп йөрүеңне дә...

Мәгави. Тагын нәрсә беләсең?

Гүзәл (*әкрен*). Шах түткиләргә барып, мине көтеп утыруыңны да.

Мәгави. Артыгы кирәкми, кызым... Ә син кайда идең?

Г ү з ә л. Бер нәрсә сорыйсым килә... әти.

М ә г а в и. Сорап кара.

Г ү з ә л. Әгәр дә... әйдә, әти, китик моннан икәү бергә, онытыйк бу әшәкелекләрне, икәү бергә яшик дисәм, ни дияр идең?

З ә р и м ә. Гүзәл?! Адәм сыман кылан! Сүзеңнең ата-анасы юк. Тилердеңме әллә?!

Г ү з ә л. Элек тиле булганмын мин! Я, ни дияр идең, әти?

М ә г а в и. Әниең белән бергә булсак — риза, дияр идем, кызым.

Г ү з ә л (*бераз ни әйтергә белми карап тора*). Ә сез нәрсә дип җавап бирер идегез?

З а к у а н (*бераз югалып*). Кызык... Андый сорау ишетмәдем бит әлегә!

Г ү з ә л. Ә сез ишеттем, дип уйлагыз.

З ә р и м ә. Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә, дидем мин сиңа!

З а к у а н (*уз-үзен кулга ала*). Ә сиңа андый сорауны өлкәннәргә бирергә иртәрәк. Ә менә мин бирсәм ул сорауны — җавап бирер идең. (*Башкаларга таба борыла.*) Кызык ситуация килеп чыга! Борыны кипмәгән балага инициатива биреп утырабыз! (*Мәгавигә.*) Шоколад та каптыр син аңа! Подвиг эшләгән ич! Кыюлыгы җитеп, бабасының яңа йортына ут төрткән!

М ә г а в и. Туктатыйк, Закуан абый. Мин башка бу турыда сөйләшергә теләмим. Тикшердең, гаепле кешеләрне таптың. Өчебез бергә ут төрткән, дип сана.

Г ү з ә л. Өчебез бергә?

З а к у а н. Чөнки син кайтканчы әтиең белән әниең, берәм-берәм кереп, ут төртүләрен танып чыктылар! Син юньсезне каплап калырга тырышып!

Г ү з ә л. Ничек инде?

З а к у а н (*кызган*). Үзләреннән сора, каршыңда утыралар ич!

М ә г а в и. Гүзәлнең гаебе юк монда.

З а к у а н. Каян беләсең?!

Г ү з ә л. Син бер нәрсә дә белмисең, әти!

М ә г а в и. Бик яхшы беләм, кызым. Мин баргач, Шах түтиләрдән чыгып, күршеләрдә качып калуыңны да. Ә мин кайтып киткәч, кире түтиләргә кереп йоклавыңны да. Иртәнгә кадәр, кызым, син беркая да чыкмадың. Шах түтиләрдә йокладың. Ә шулай да... молодец, кызым!

З а к у а н (*чынлап та гаҗәпкә калган*). Ә кем төрткән соң алай булгач?!

М ә г а в и (*кискен*). Мин, дидем бит анде!

З ә р и м ә (*Гүзәл янына килә, күңеле йомшарып*). Әй, кызым, кызым... (*Кызының тузгыган чәчләрен рәтли*). Ә бит мин сине моңа кадәр сабый бала, дип йөри идем. Ә син буйга гына түгел, акылга да үскәнсең икән...

Г ү з ә л (*ярсып, әнисенең күкрәгенә каплана*). Нигә газаплый ул безне, әнкәй?! Безнең аңа ни яманлыгыбыз тиде?! Ни кирәк аңа монда?! Ничек теле бара шулай сөйләшергә!

З ә р и м ә. Я, я, кызым... Бабаң чакыртып кайтарды ич аны. Озак тормас, китәр...

М ә г а в и. Барыгыз өйгә кайтыгыз. Хәзер, артыгыздан мин дә чыгам.

З а к у а н (*уйчан*). Тукта... Бер нәрсә искә төште!

З ә р и м ә. Әйдә, кызым, ирләр үзләре аңлашырлар...

Г ү з ә л. Ни пычагым җитми аңа тагын?!.

Ишеккә таба юнәләләр.

З а к у а н. Зәримә! Син пожар янына барганда әткәй кайда иде?

Зәримә белән Гүзәл тукталып калалар.

З ә р и м ә (*икеләнеп*). Каян белим мин аны?.. Өйдә булмый кайда булсын ул? Урыннан тора алмаган кеше!

З а к у а н (*бусанып йөри*). Өйдә түгел иде шул... «Пожар!» — дип кычкырган тавышка йөгереп чыктым — каршыга чайкала-чайкала әти кереп килә. «Нишләп кешегә әйтмичә тордың, әти?» — дим...

В а р и с (*ачык тавыш белән*). Айдар улым, синме бу? Дөм караңгы... Ут кабыз, балам. (*Айдар бабасының кулын тота.*) Әтиең кайтмадымы?

Барысы да эчке бүлмәгә керәләр.

З а к у а н. Мин монда, әткәй! Китмәдем әлегә... Хәлең ничек?

М ә г а в и. Ишетми бугай ул сине...

В а р и с (*улының сүзен ул чынлап та ишетми*). Әтиең китмәгән булса, үзең тыңла, улым... (*Авыр сулый.*) Карт бабаң әйтә иде... бала — ата-ананың рухын саклый торган сандык ул... ди торган иде. Бала — үткән белән киләчәкне тоташтырып торучы бәҗра да, дип өстәр идем. Бала белән бала бертөрле булмый икән шул. Сыер да, елан да бер үк кырда йөриләр... Тик берсе сөт бирә, икенчесе — агу җыя...

Айдар бабасының күкрәгенә капланып елый. Онытының битен сыйпый, күз яшьләрен сөртә.

Елыйсың түгелме, улым?.. Ташла, егет кеше ич син... Күз яше күрсәтмә бабаңа... Күз яше, яшьлек — икесе бертуганнар алар... Күз яше ялгыз гына акмый ул. Үзе белән

бергә яшьлекне дә агызып алып китә... (*Тына.*)

М ә г а в и (*этисенең кукрәгенә иелеп тыңлый*). Тагын онытылды... Сулышы бик әкрен... Врачы да килеп җитмәде, ичмасам! Әйдәгез, моннан чыгыйк — этигә һава кирәк.

Чыгалар.

З а к у а н (*өзелгән сүзен дәрәҗә белән дәвам итә*). Так вот... Әллә мин әйтәм...

М ә г а в и (*бүлдерә*). Җитәр инде! Күпме чәйнәргә була?

З а к у а н. Ачыклап бетергәнче! Син пожар бетүгә генә кайтып кергәнсең. Зәримә — шулай ук отпадает! Гүзәл — үзең доказать иттең! Берегезнең дә версиягез очы-очка бәйләнми. Круговая порукага охшый! Ә кем кала?

З ә р и м ә (*җен ачуы белән*). Син каласың!

З а к у а н (*кул селти*). Ташлале... Җитди сүз барганда... Димәк... бер генә кеше төртүе мөмкин... (*Әтиләре яткан якка борыла.*)

М ә г а в и. Ничек телең әйләнә!

**Шулвакыт Варис картның кулы кинәт идәнгә салынып төшә. Әтисенең сүзләрен игътибар белән тыңлап торган Айдар, бабасының вафат булуын аңлап, тораташ кебек катып кала.**

З а к у а н (*эчке бүлмәгә ташлана*). Ашыкмагыз, үзеннән сорыйбыз без аны!

А й д а р (*коты алынып, этисенең юлына аркылы төшә һәм... үзе дә көтмәгәндә илереп кычкырып җибәрә*). Не надо, папа!!. Дедушка умер...

*КПССның XXVII съезды карарларын — тормышка!*

## Вахит Шәрипов

# ЯҢА ГАСЫР ТРАКТОРЫ

Кама буендагы мәшһүр автомобиль заводыбызның бар куәтенә эшли башлавына әллә ни күп вакыт үтмәде дә әле, төзүчеләребез исә яңа баһадирның каркасларын торгызырга тотындылар. Аларның бу максаты авыл хуҗалыгына ярдәм итүгә, игенчеләрнең хезмәтен җиңеләйтүгә юнәлдерелгән. Алабуга якларыннан яңа төр тракторлар колхоз-совхоз басуларына юл алса, Азык-төлек программасын тормышка ашыру шактый тизләнәчәк. Заводның эшчәнлеге табыннарыбыз муллыгында да сизелеп торачак.

Шулай да еш кына укучылардан: «Безнең илдә трактор заводлары күп иде бит инде, нигә яңасы?» кебек сорауларны ишетергә туры килгәли. Чыннан да, бар бездә андый заводлар, байтак алар: Минск, Липецк, Владимир, Харьков, Волгоград, Чиләбе, Чабаксар, Алтай кебек шәһәрләрдә авыл хуҗалыгына кирәкле машиналар чыгарыла. Хәзер яңадан да егермегә якын завод салынып ята. Артык күпкә китә түгелме соң? дигән сорау урынлы да кебек.

Безнең ил тракторлар ясау буенча дөнья күләм беренчелекне тота. Җитмәсә, үзебез соңгы вакытта экстенсив үсешне тәнкыйть итеп, интенсив ысулны хуплый башладык. Ягъни ни булган мөмкинлекләрдән нәтиҗәлерәк файдаланырга, киңлеккә түгел, тирәнлеккә омтылабыз. Бу яңалыклар берсенә берсе каршы килмиме соң? Кама буенда моңарчы күренмәгән киң колачлы трактор заводы, әле алай гына да түгел, заводлар комплексы торгызу шулкадәр хаҗәт идемени соң?! Чынбарлыкка күз салыйк! Басуларыбызның егерме процентлабы, ягъни 40 миллион гектардан артыграк өлеше, сабан культуралары ишелчә, бәрәңге, чөгендер, кукуруз, көнбагыш кебек рәт араларын эшкәртеп үстерелә торган культураларга бирелә. Соңгы елларда күп кенә хуҗалыклар ярма өчен өлгертелә торган бөртеклеләрне дә рәт-рәт утыртып, аларны шул ук ысул белән тәрбияли башладылар. Мондый алым уңышны күтәрүгә ярдәм итә. Табигый ки, рәт арасына кереп йөрердәй универсаль тракторлар кирәк. Хәзер бу төр машиналар әлеге эшнең яртысыннан артыграгын үз җилкәләрендә тоталар. Әмма механизаторларның техника белән тәэмин ителүе, ихтыяҗ белән чагыштырганда, ике тапкырга кимрәк. «Правда» газетасының хәбәр итүенә караганда (7 декабрь, 1985 ел), хәзер чыгарыла торган авыл хуҗалыгы машиналарының утыз процентлабы иске проектлар буенча ясала.

Азык-төлек программасын мөмкин кадәр тизрәк тормышка ашыру өчен, безгә басулардагы хезмәтне ашыгыч рәвештә индустриаль нигезгә көйләргә кирәк. Шунлыктан сабан тракторларын күпләп җитештерү сорала. СССРның трактор һәм авыл хуҗалыгы машиналары министрлыгы мәгълүматлары буенча безгә андый тракторлар 675 мең данә таләп ителә. Хәзергә аларны Минск һәм Липецк заводларында ясыйлар. Хәер, Липецкиныкын тракторчылар кабул итәргә теләми, Т-40 АМ, Т-40 М машиналары — кичәге көн техникасы. Минск тракторларын һич җиткерер хәл юк. Бик тырышканда да, аларны тагын 10-15 меңгә артыграк чыгара башларга мөмкин, тик бу гына мәсьәләне хәл итми.

Димәк, кичекмәстән киң колачлы чара күрү кирәк иде. КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы нәкъ менә шуңа күрә 1984 елның сентябрендә Татарстанның Алабуга шәһәрендә яңа трактор заводы салырга дигән карар кабул итте.

Моңарчы безнең ил трактор заводының мондый масштаблысын белмәде. Элеккеләрен салуга ун еллар вакыт китә иде, КамТЗ исә нигездә бер бишьеллык эчендә төзелеп бетәргә тиеш. Темп КамАЗ салгандагыдан да ике мәртәбә кызурак барачак. КамАЗ темпы исә моңарчы илдә иң кызулардан санала.

КамТЗ алты заводтан торачак: трактор, двигатель, ягулык аппаратуралары, торба компрессорлары, тимерчелек-кою һәм станок-инструментлар заводлары. Комплекс эштәге мөстәкыйльлекне тәэмин итәчәк. Ул трактор җыюда кирәкле кайбер детальләрне хәтта башка заводларга да җибәреп торачак.

Безнең КамАЗ автомобиль төзелешендәге иң соңгы яңалыклардан башланган иде. Соңгы 10-15 ел эчендә машиналар ясау техникасы һәм технологиясе шактый алга китте. КамТЗ бу юлдагы иң яңа ысулларга таяначак: роботлар, конвейерның яңа схемалары, системаларны еш үзгәртү мөмкинлекләре — барысы да күздә тотыла. Кыскасы, бу комплекс — XXI гасыр заводы, киләчәк заман корылмасы дип аңлатыла.

Инде тракторларның нинди)рәк булачагына тукталыйк. Конструкторлар фикеренчә, КамТЗдан чыккан тракторлар бик чыдам, ышанычлы, аз чыгымлы булачак. Механизатор өчен дә барлык уңайлыклар каралган. Машинаның моделен СССР халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә куйганнар иде. Авторы — Минск трактор заводы баш конструкторының урынбасары Игорь Иванович Кандрусев. Игорь Иванович КамТЗның баш конструкторы итеп билгеләнде. Ул безгә менә боларны хәбәр итте:

— 1983 елда ук КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы 150 ат көчле тракторлар һәм аларга кирәкле өстәмә машиналар ясаучы завод булдыру турында карар кабул иткән иде. Аның моделе турында уйлаганда илдәге һәм чит илләрдәге барлык яңалыклар күздән кичерелде. Гамәлдәге принциплар, бу юлдагы үсеш баскычлары ныклап өйрәнелде. МТЗ-142 моделенә тотынганчы бөтен тәҗрибә иләк аша үткәрелде. Аның тарту көче 2 тонна. «Беларусь» тонна ярым гына тарта. Яңа трактор, куәте зур булганга күрә, кукурузны, көнбагышны, сояны эшкәрткәндә, берьюлы унике рәт алдыра, бәрәңгене — сигез рәт, «Беларусь» 8-4 рәт кенә эшкәртә ала иде. Культиваторның алты рәтлесен, бәрәңге җыю җайланмасының дүрт рәтлесен тагарга мөмкин булачак. Элек ике рәттән арттырып булмый иде.

Яңа тракторның уникеләп үзгә төре ясалачак. Агрегатларның гомуми төрлелеген исәпләсәң, йөзгә якынлаша. КамТЗдан чыккан машинаның хезмәт җитештерүчәнлеге, элеккеләргә караганда, 1,3-2 мәртәбәгә артыграк. Яшелчәчелектә аңардан файдалану аеруча зур нәтиҗәләргә китерәчәк, монда кул хезмәтен киметергә мөмкинлек туачак һәм уңышны күтәрүгә юл ачылачак.

«КамТЗ» маркалы машина ягулыкны сизелерлек дәрәҗәдә янга калдыра ала. Моторы капиталь ремонтсыз 12 мең сәгать эшләүгә көйләнгән. Хәзергә бу сан 6-8 мең сәгатьтән артмый иде әле.

Механизаторларга уңайлы шартлар күздә тотыла. Герметик кабинага җил дә, тузан да керми. Аңа кондиционер куела. Тракторчы рульне үзе теләгән хәлгә көйли ала. Утыргыч та, тракторның нинди мәйданнан узуына карамастан, һәрчак тигез горизонталь рәвештә кала торган итеп җайланган.

Шушындый модель буенча ясалган яңа трактор Солнечногорскидагы басуда сынау үтте һәм дәүләт комиссиясе тарафыннан кабул да ителде инде. Тәҗрибә өчен ясалган берничә трактор Украина, Кубань, Себер, Белоруссия һәм Мәскәү янындагы кырларда эшләп йөри. Молдавиядәге бер трактор проектта каралган 12 мең сәгатьне эшләп тутырды да инде. Колхоз председателе безгә: «Ул әле һаман яңа тракторлардан да шәбрәк!» — дип белдерде.

Завод салынып яткан арада конструкторлар әлеге модельне тагын да камилләштерү буенча баш ватачаклар. Тракторның тышкы күренеше, мәсәлән, әле җитди эзләнүләрне сорый. МТЗ-142 моделен без тирәннән уйланулар өчен бер җирлек дип кенә таныйбыз...

Булачак тракторның ничек эшләгәнен күрү өчен без фәнни-тикшеренү институтының Мәскәү өлкәсе Раменский районындагы тәҗрибә басуына бардык. Бәрәңге алучылар звеносының җитәкчесе Николай Бабарыкин машинаның бөтен «осталыгын» күрсәтеп бирде:

— Мин «Беларусь»ның барлык төрләрендә эшләдем,— дип аңлата башлады.— Бу «МТЗ-142» тракторына утыруыма ел ярымлап кына әле. Ни таксаң шуны эшләтә. Язын гусеницалы тракторда эшләүче иптәш егет белән ярышып карадык. Берсендә юри унике сәгать тоташ эшләдек. Тукталгач, карасам,— иптәшем тәмам алҗыган. Тузан, өзлексез калтыранып утыру аны эштән чыгарган. Мин — яңа туган бала кебек. Шәп машина, сүз дә юк! Аңарда бер ел эшләгән хезмәт хакына «Жигули» алдым. Ватылып та интектерми. Тизрәк чыгарсыннар гына инде!

Укучыда тагын бер сорау туарга мөмкин: ни өчен заводны Татарстанда салырга кирәк тапканнар? Бу мәсьәлә төрле оешмаларда бик озак тикшерелә. Ниһаять, бурычны «Камгэсэнергострой» берләшмәсенә тапшырырга хәл кыла-

лар. Монда, әлбәттә, аның КамАЗ салудагы героик тырышлыгы роль уйнаган-дыр. Бары тик шундый батыр һәм тәвәккәл коллектив кына комплексны тиз арада сафка бастыра алачак.

«Камгэсэнергострой»ның начальнигы, Социалистик Хезмәт Герое Евгений Никонорович Батенчук бу хакта:

— Бу ике төзелешнең башланып китүен чагыштыруы да кыен,— дип сөйли.— КамАЗны салуда, әйтергә мөмкин, эш тап-такыр бушлыктан башланды. Төзүчеләребез Чаллыдан 50-60 чакрым радиустагы авылларга таралды. Ашханә, транспорт, мунча — берсе дә җитми иде. Төзелеш осталарының азлыгын әйтеп тә тормыйм. Трактор заводына тотынырга, шөкер, тәҗрибә дә, белгечләр дә бар. Яңа килүчеләрне Брежневтагы тулай торакларга урнаштырабыз. Эш урынына ярты сәгатьтә илтеп куялар. Тиздән Алабуганың үзендә дә торак йортлар, ашханәләр сизелерлек артачак...

Сүз дә юк, Алабуга төзелеше башка, чагыштырмача җиңелрәк шартларда җәелеп китте. КамАЗ өчен салынган киң юллар, һава, су маршрутлары, тимер юл — барысы да бүген КамТЗ төзелешенә дә хезмәт итә.

Алабуганың моңарчы нинди шәһәр булганлыгын Совет энциклопедик сүзлегеннән укып белергә мөмкин: район үзәге, елга пристане, җиңел һәм азык-төлек промышленносте бар. Нефть җитештерелә. Пединститут, И. И. Шишкинның музей-йорты урнашкан. Шәһәргә 16 гасырда нигез салынган.

Сүзлектә шәһәрнең табигате, гаҗәеп матурлыгы турында сүз юк. Шунлыктан өстәп әйтик, бу яклар элек-электән туган ил табигатенең барлык матурлыгын гәүдәләндерүче почмактан санала. Иван Иванович Шишкинның мәшһүр «Нарат урманы иртәсе», «Арыш», «Кама» кебек әсәрләре нәкъ менә монда — Тойма елгасының Камага кушылган урыннарында язылган.

Алабуга аша Себергә юл топкан Ермак дружинасы үткән, монда, Казанга барышлый, Емельян Пугачев тукталган. Фельдмаршал М. И. Кутузовның атаклы ординарецы Надежда Дурова Алабугада илле еллап яшәгән. Шәһәрдә күренекле шагыйрә Марина Цветаеваның кабере саклана. Шишкин, психиатр Бехтерев, маршал Говоров, Менделеев кебек данлы шәхесләр Алабуганы дөньяга мәгълүм итеп таныткан. Радищев, Салтыков-Щедрин, Короленко, Алексей Толстой, Пришвин кебек әдипләрнең иҗатында да Алабуга аерым урын били. Маршал Чуйковның исә хәрби чыныгу юлы шушыннан башланган. Бөек Ватан сугышы елларында Алабуга батырларының унберенә Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Яңа завод салырга ашкынып килүчеләрне дә бу якларның шушындый мактанычлы сыйфатлары үзенә тартып торадыр, мөгаен.

Аларга нindирәк бурычлар йөкләнә, төзелеш нинди масштабларда барачак соң? Татарстанның «Госстрой» председателе Р. С. Насыйров:

— Чаллы төзелеше безгә бу юлы шактый еракка карап эш итәргә сабак булды,— дип, әңгәмәне ерактан башлады.— Мин, Чаллыда миллион кеше яшәячәк, дигәч, күпләр көлгән иде. Әнә, анда хәзер үк ярты миллион чамасы кеше тупланды. Хәзерге планнарда Брежнев шәһәрендә яшәячәк 800 мең кеше күздә тотыла. КамАЗ заводларының шәһәрдән артык еракка китеп салынуы да урынсызрак булып чыкты. Кем белгән бит аны, ул чакта безнең кулда һава сафландыргыч фильтрларның хәзерге кебек куәтлеләре юк иде. Тулай тораклар, торак йортлар янында җәяү йөреп, кәеф-сафа корырлык мөмкинлекләр турында да уйлап җиткермәгәнбез.

Алабуга төзелешендә элекке кимчелекләрне кабатламаска тырышачакбыз. Кешеләр йөри торган ял итү мәйданнары тирәсендәге йортлар ике-дүрт катлы гына булачак. Дөрес, бу яңалык экономик яктан отышлы түгел, әмма без барыннан да элек кешеләргә рәхәтлек турында кайгыртырга тиешбез. Моннан тыш, биредә, ил күләмендә беренче тапкыр буларак, «шәһәр — якын тирәлек — табигать» комплексы күздә тотыла. Яңа системаның яңалыгы шунда ки, төзелеш табигатькә зарар салмаска тиеш. Алабугадагы яңа йортлар шәһәрнең элекке үзәгеннән үсеп чыккан кебек торгызыла да аны уратып ала. Завод каршысындагы мәйданда дирекция бинасы калкып чыкты, ул заводлар бинасын шәһәр белән тоташтырачак. Шәһәр 350 мең кешегә исәпләп салына. Аның үз театры, циркы, зоопаркы, ипподромы булачак.

Яңа шәһәрнең проекты Мәскәүдә КПССның XXVII съездына багышланган «Без коммунизм төзибез» дигән күргәзмәгә куелды. Проекттагы кыю яңалыклар тамашачыларда зур кызыксыну уяткан иде. Ул вакытта РСФСРның культура фәнни-тикшеренү институты сектор мөдире Вячеслав Леонидович Глазычев проект турында:

— Проект КамТЗ салучылар теләге буенча төзелде,— дип сөйләде.— Монда шәһәрдә яшәүчеләрнең культурасын, камиллеген үстерү мөмкинлекләре иң алгы планга куелды. Алабуга кешенең һәрьяклап үсүенә, аның

сәләт мөмкинлекләре ачылуга барлык шартларны тудырачак. Проект шәһәрнең элекке матурлыгын һәм башка кадерле сыйфатларын файдалануга йөз тота.

Вячеслав Леонидовичның сүзен СССР Художниклар Союзының Үзәк тәҗрибә студиясе җитәкчесе Евгений Розенблюм дәвам итте.

— Шәһәрнең элекке йөзенә зыян китермәү, киресенчә, аңардан отышлы файдалану өчен, без тарихны бик җентекләп өйрәндек. Алабугада Петр I чорында Полтава яны сугышларында әсир төшкән шведлар җиз кою һөнәрен башлап җибәргәннәр икән. Шәһәрдә җиз кыңгыраулар ясаганнар. Һөнәр әле дә дәвам итә. (Сүз уңаеннан әйтик: КамТЗның генераль директорының төп һөнәре дә — коючы.) Бу хакыйкать шәһәрне бизәгәндә дә файдаланылачак. Без фанер детальләрдән түгел, коелган чуен рәсемнәрдән бизәкләр ясаячакбыз. Иске урамнардан мөмкин кадәр отышлырак файдалану өчен буш аралыкларга, җимерек йортлар урынына коттеджлар салыначак. Бакчалар, куаклыклар һәм агачлар — барысы да шул килеш калачак. Хәзергә ташландык хәлдәге ерганаклар, ермаклар төзекләндерелеп, матурлатылачак. Аларның арада зуррагын зоопарк сыманрак тамаша урынына әйләндерүебез дә ихтимал.

Шәһәр тирәсендә дачалар, ял базалары төзеләчәк. Аларда спорт уеннары, төрле күңелле тамашалар оештырылыр дип уйлыйбыз. Боларның барын да шәһәр кешеләре үзләре башлап йөрергә тиеш булачаклар...

Бу әңгәмәдәге сүзләргә өстәп, тагын шуны әйтергә кирәк — КамТЗ дирекциясе эшчеләргә бакча итеп бүлү өчен һәм питомник ясауны күздә тотып, 2 200 гектар җирне алды да инде.

1985 ел башында Алабугада КамТЗның «Тракторозаводстрой» һәм «Жилстрой» трестлары барлыкка килде. Беренче торак йортлар салына башлады. ВЛКСМ Үзәк Комитетының штабы эшкә кереште. Төзелеш Бөтенсоюз удар төзелеше дип игълан ителде. 1985 елның июнендә станок-инструментлар заводының (СИЗ) беренче субае кагылды. Илнең башка трактор заводларына КамТЗның беренче белгечләре өйрәнергә киттеләр. Төрле шәһәрләрдә, кайбер чит ил фирмаларында заводка кирәкле әйберләрне җитештерү турында сөйләшүләр алып барыла. Коллективка яңадан-яңа кешеләр килеп кушыла торды. Гадәттә, мондый эш кайнаган җиргә кыюлар җыела. Мәсәлән, Никарагуа башкаласы Манагуада бинаһая зур госпиталь салу хаҗәте тугач, иң беренче булып анда нигезне өйрәнүчеләр китте. Арада Казан егете, бораулаучы Мәхмүт Хөсәенов та бар иде.

Манагуада эшләве җиңел түгел. 45 градуска җиткән эссе һавасы гына ни тора?! Әмма Мәхмүтне кешеләр гашыйк итә. Берсендә ул кулын җәрәхәтләгән эшченең көлә-көлә көй сызгыруына гаҗәпләнеп карап тора:

— Нәрсәгә шатланасың син, Карлос? Кулың авыртадыр бит?—дип сорый.

— Әй, амиго, ник шатланмыйм, бер кулым гына авырта бит,— ди тегесе.— Икесе дә җәрәхәтләнгән булса, нишләгән булыр идем?

Мәхмүт Никарагуада Мәскәү егете Николай Аниян белән дуслаша. Аерылышканда, берсен-берсе кунакка чакырышалар. Тик Мәхмүт, кайтып, бер атна да тормый, Алабугага китеп бара. Хәзер елмаеп сөйли:

— Бораулларга килеп кенә баскан идем, күрше скважина янында Николайга охшаш кеше күреп алдым. Янына барсам — ул! Тагын бергә эшлибез.

Алабуга төбәге бүген киләчәктә туачак матурлык белән рухланып яши. КамТЗның генераль директоры урынбасары Борис Иванович Лобода:

— Без монда яшәячәк кешеләрнең киләчәген формалаштырабыз шикелле,— ди.— Алабуга бик матур шәһәр, төзелеш аны тагын да гүзәлрәк итәчәк. Мин кешеләрнең дә матур хыяллар белән килүен телим. Җаваплылык тоеп һәм хыяллар белән килсеннәр!

Алабуга төзелешенең беренче кыенлыкларын җиңәргә ярдәмгә КамАЗ ветераннары җыелды: Таһир Нәфыйков, Иван Стороженко, Владимир Елизаров, Мингали Габбасов, Рафаил Баязитов...

Станок-инструментлар заводын салучылар төзелеш темпын, КамАЗ салучыларга караганда, ике-өч тапкырга кызулаттылар. Ул чакта куллануы мөмкин булмаган ысулларны эшкә җиктеләр. Завод корпусын җыйганда конвейерлы агым ысулы аеруча ярап куйды.

Төзелешнең беренче елында 32 миллион сумлык эш башкарылды, 46 мең квадрат метр торак файдалануга тапшырылды. КПССның XXVII съезды ачылышына СИЗның беренче чиратына каркас корылып бетте.

Хәзер еш кына «КамТЗ — XXI гасыр заводы» дигән сүзләрне очратырга була. Бу төшенчәне завод XXI гасырда эшләячәк дип кенә кабул итәргә ярамый. Әлеге сүзләр — бу төзелешнең техника дөньясына зур яңалыклар

алып килүенә дә ишарә. КамТЗның генераль директоры Николай Иванович Бех бу хакта:

— Кечкенә алачыкта мәһабәт машина ясап булмый,— дип, гади генә аңлата башлый.— Тездән сазга батып эшкә килгән слесарьдан да әллә ни көтәргә кирәкми. Бары да заманга лаек булырга тиеш. Хәзергә кадәр безгә эшкә алынган кешеләрнең 81 проценты югары һәм урта белемле. Югары дәрәҗәдәге техниканы бары тик сәләтле һәм укымышлы белгечләр генә эшкә җигә ала. Без яшьләргә зур өметләр баглыйбыз. Киләчәк — аларныкы. Алар көчле, белемле, хыялга бай...

Бу сүзләрдә киләчәк гасырга юл алган завод белән борынгы Алабуга шәһәрен берләштерә торган тирән мәгънә бар кебек.

# ИҢНӘРЕНДӘ — ИЛ ГАМЕ

**Язучы Рифкат Кәрами, шагыйрьләр Әхмәт Рәшитов һәм Рәшит Әхмәтҗанов Көнбатыш Себердә, нефть чыгаручы якташларыбыз янында булып, әдәби кичәләр, иҗади очрашулар уздырдылар, нефтьчеләрнең тормыш-көнкүрешләре белән таныштылар. Бу юлъязмада алар шул тәэсирләре белән уртаклашалар.**

Без ерак сәфәргә кузгалдык. «Ерак» сүзен җөмлә матур булсын өчен генә әйтәбез шикелле. Себер, ничектер, балачактан ук күңелгә урнашып калган як. Халык бәетләрендәге «Безнең Гали Себер китте, бунтарь дип тотып биргәч», «Габдрахман мулла Себер китте, патша сурәтен ертып», «Әсма мескен Себер китә, елга түгел — гомергә» дигән юлларны искә төшерү генә дә, күңелдә язылмаган поэмаларны, романнарны, шигырьләрне барлый сыман...

Ә «Көнбатыш Себер нефте», «Төмән нефте» кебек сүзләр безгә яхшы таныш. Шулай да алар безгә бик ерак, кайдадыр җир читендә итеп тоймадык. Чөнки урамда безнеңчә сөйләшүчеләр очрый, туган телдә игъланнар күзгә ташлана. Монда күптән түгел генә Әлмәт татар дәүләт театры булып киткән. Гастрольгә Р. Хәмиднең «...диде кардәш...», Р. Мингалимнең «Кунак кызы гел килмәс», Ф. Садриевның «Эһем, эһем, дигәчтен...» пьесалары буенча куелган спектакльләрне алып килгәннәр. Алар Лангепас, Сургут, Нижневартовск шәһәрләрендә булганнар.

Табигате дә әллә ни ят түгел Төмәннең: кояшы да бездәгечә кыздыра, агачлар да яфрак ярып утыра. Ләкин... бу әле сәфәребезнең яртысы гына булып чыкты.

Юлыбыз — Лангепас шәһәренә. Сургут, Нижневартовск, ни дисәң дә таныш иде, ишеткәләп торабыз. Лангепасы нәрсә тагын? Ни исеме таныш түгел, ни үзе. Урыны да Төмәннән Казан белән Мәскәү арасы ераклыгында. Шулай да мәһабәт ТУ-154 аны бер сәгать дигәндә очып үтә. Самолеттан елга, урманнар, сазлыклар күренә. Без һаман югарырак күтәреләбез. Самолет безгә: «Карагыз, күрегез Себер киңлекләрен!» — ди сыман.

Пассажирларның күбесе — эшче, инженер-техник работниклар. Алар бик тыныч, үз дәрәҗәләрен белеп-тоеп утыралар кебек. Бу очулар алар өчен гадәти хәлгә әйләнгән. 30-40 чакрымдагы буровойга эшкә баралар диярсең!

Безнең өчен бу гади рейс түгел. Күренешләре үк сәер. Әйтик, әгәр без Бөгелмәдән Казанга баручы самолетта булсак, аста берөзлексез авыллар, шәһәрләр күзгә чалынып иде. Ә монда... Өсте җыерылып торучы сазлык-күлләр, сирәк агачлы урманнар, боз белән капланган җансыз елгалар гына. Аста бөтенләй тормыш юк, кеше яшәми сыман. Бәлки алай да түгелдер, бу тирәнең Көнбатыш Себер түбәнлеге икәнен белгәнгә күрә генә шулай тоеладыр...

Самолет безне Сургут шәһәренә китереп төшерде.

Сургут. Аңа 1593 елда нигез салынган. Төмәннән җиде яшькә генә кече. (Быел Төмәннең 400 еллыгын бәйрәм итәләр) Сургут — хант сүзе, балыклы урын дигәнне аңлата. Элек кечкенә бер авыл, политик тоткыннарны сөрү урыны булган, халкы да 20 меңнән артмаган. Ә хәзер — 220 мең. Сургут — яшь кала. Анда яшәүчеләрнең уртача яше — егерме җиде генә. 63 милләт вәкиле яши биредә.

Шәһәрдә — нефть, газ, электр энергиясе, геология, балык һәм урман промышленносте предприятиеләре, ГРЭС...

Ике Бөтенсоюз удар төзелеше — энергетика объектларын һәм нефть-газ үткәргечләрен төзү — гомумхалык эшенә әверелгән. Кайбер социалистик илләр вәкилләре дә бу эштә катнаша.

Кая карама — төзелеш: актарылган җир, краннар, тракторлар, тырпаеп торучы субайлар (монда бөтен корылмалар да субай өстендә утыра), төзүче егет-кызлар... Бер урында тугыз катлы йортлар өчен нигез салынса, икенче җирдә кинотеатр, йөзү бассейны... Кирәк, барысы да кирәк. Чөнки халык төпләнеп, матур итеп яшәргә исәпли.

Сургут безнең Әлмәт шәһәренең күтәрелеп килгән чагын хәтерләтә. Әлмәтне төзүдә катнашкан кешеләр буларак, без шундыйрак хисләр кичердек. Кем белә, бәлки Әлмәтне төзүдә катнашкан кешеләр, бу шәһәрдә дә җиң сызганып эшлиләрдер?..

Безнең Лангепаска киткәнче, бераз вакытыбыз бар әле. Шәһәр белән бигрәк тә аның кешеләре белән танышабыз. «Геолог» исемле культура йорты бар. Анда татар фольклор группасы да оештырылган. Аның концертлары әледән-әле булып тора. Сәнгатькә гашыйк якташларыбыз — З. Гамилова, Г. Шакирова, Н. Сафәрова, Ф. Гыйззәтуллин, А. Галин, И. Шәйдуллин, Н. Җиһаншина, Д. Уртабаева кебек һәвәскәрләр үзләренең җырлары, нәфис сүзләре белән күпләрне сокландыралар. Шунысы кызыклы: кайберәүләр бирегә гаиләләре белән йөриләр. Ирле-хатынлы Закировлар, Зәйнуллиннар, Сафәровларның чыгышын халык көтеп ала икән. Бу матур эшләрне армас-талмас Г. Рангулова оештырып йөри.

Төмәндә кояш, чалт аяз иде, ә Сургутта яңгыр, салкынча. Лангепаска кадәр поездда тагын ике сәгатьләп барасы икән. Поезд сирәк агачлы, тәбәнәк нарат, каен урманы эченнән бара. Сазлык. Авыллар очрамый. Ике станция уздык: Ульт-Ягун, Чумпас. Урман эче. Вокзал бинасы. Бер-ике йорт. Салкын. Кар. Җил. Бездә яз иде, монда чын мәгънәсендә кыш икән әле. Ниһаять, безнең станция. Әле бу шәһәр үзе түгел. Берничә автобус тора, ләкин алар без күреп өйрәнгән гадәти автобусларга охшамаган, куәтле «Урал» машинасына көйләнгән вахта автобуслары.

Юлда шофер ике балыкчыны утыртты. Таза, эре сөякле, кызгылт йөзле, көрәктәй куллы. Аларга карап, бу якларда нindирәк баһадирлар эшләвен чамалап була. Болар шәһәр кешеләреннән бөтенләй аерылып торалар. Сабыр холыклы, аз сүзлеләр.

Унбиш минут чамасы урман эченнән баргач, ике катлы такта йортлар, будкалар, мастерской-гаражлар күренде. Бу — Баулыдан килеп эшләүчеләрнең базасы икән. Арырак, урман эчендә — минзәләлеләр. Тагын бераздан шәһәр үзе башлана. Анда да әле башта гаражлар. Бөгелмә бораулау идарәсе объектлары төзелеп киткән. Ә шәһәрнең үзәге — ике катлы агач йортлардан гыйбарәт. Яңа микрорайон исә бераз арырак, анда — тугыз катлы йортлар. Безне «Урьевнефть» идарәсенең кунакханәсенә урнаштырдылар. Бу идарә элек Төмәннеке булган, хәзер «Татнефть»кә карый. Бүлмәдәшебез дә якташ булып чыкты. Казан төзелеш институтын тәмамлаган. Проект институтында эшли. Туган ягы — Буа районы.

Билгеле, ике тәүлек диярлек юлда булганнан соң шактый арылган. Йокы тәмле булды. Шулай да иртәнге алтыда ук (безнеңчә әле дүрт кенә) тордык. Күзгә беренче ташланган күренешләр: саз итеге кигән, аркасына биштәр аскан бер ир бара, аугадыр, күрәсең; ике-өч кеше йөгерергә чыккан, тырык-тырык юырталар. Чү! Әнә каршыдагы йорт артыннан бер ир белән бер хатын чыктылар. Хатыны спорт костюмы кигән, ә ире... ак трусиктан гына, хәтта аягында да берни юк! Утыз яшьләр тирәсендә булыр, сакаллы, кып-кызыл тәнле таза ир. Ниһаять, чын себер, чын тайга кешеләрен күрәбез! Аяк асты карлы боз. Ә моңа?.. Алга китеп булса да әйтик, без ул адәмне көн саен күрдек. Шундый иртәнге күнегү — аның өчен гадәти хәл икән.

Лангепаска (бу сүз хант телендә «тиенлек» дигәнне аңлата) килүебезнең максаты — нефтьчеләр белән очрашу. Эш урыннарында, тулай торакларда булу, татар әдәбияты белән таныштыру. Беренче очрашу — «Урьевнефть» тулай торагында булды. Анда Азнакай егетләре дә, Белоруссиядән килгән механизаторлар да бар. Сорауларны яудырдылар гына. Ләкин безнең үзебезнең дә сораулар байтак иде.

Хакасиядә сәнгать училищесын тәмамлап килгән яшь кенә кыз монда тәрбияче икән.
— Эшләве бик авыр,— ди ул.— Тулай торак гадәти йортка урнашкан. Кызыл почмак өч бүлмәле фатирны били. Килүчеләр күбәйсә, тоталар да бер бүлмәсенә кеше кертәләр. Алар киткәч, буяп агартабыз. Бераздан тагы кеше кертәләр. Елына 2-3 тапкыр шулай була.
— Егетләр ничек ял итә?
— Төрлечә. Культура йорты берәү генә, кино буласы көнне — мәхшәр. Билет җитми...
Әйе, монда тормыш-көнкүреш әле җайга салынмаган. Чөнки шәһәр яңа формалашып килә. Тирә-якка төзелеш мәйданнары җәелгән. Яңа йортлар, социаль көнкүреш объектлары салына. Һәр квадрат метр җирне зур авырлык белән сазлыктан яулап алалар. Ни дә булса кору өчен башта мәйданга ком ташырга кирәк, аннары гына эшкә тотынырга мөмкин. Егетләр ял вакытларын ничек уздыра соң? Даими яшәүчеләр телевизор ала, ә вахта белән йөрүчеләр моны кирәксенми. Чөнки айның унбиш көне генә монда үтә, калганы — өендә. Кино билетына чират тору, әлбәттә, яхшы күренеш. Ләкин башка нәрсәгә дә чират шактый иде шул... Димәк, культуралы ялга мөмкинлек булмагач, башкасына тартылалар.
Нигездә монда халык эшләргә дип килә. Моның шулай икәненә без Баулы бораулау идарәсенә баргач та инандык. Партбюро секретаре Елена Әхмәтовна Мәҗитова бүлмәсендә баян да, телевизор да бар. Ләкин ул аның үзе өчен түгел.
— Әле генә кайтардык. Урнаштырып өлгермәдек,— ди элекке укытучы Елена Әхмәтовна.— Мәнә безнең идарә бригадаларының эше белән танышыгыз. И. Махленов һәм В. Филимонов бригадасы (монда бер бригадада ике мастер, вахта ысулы шуңа ихтыяҗ тудыра) ел башыннан 20 мең метрга якын бораулады инде. Планнарын, социалистик йөкләмәләрен үтәрләр алар.
Дөресен әйтик, бу бригаданың 1986 елга социалистик йөкләмәсе идарәдә иң югары — 70 мең метр. Идарә тулаем 187 скважина тапшырырга тиеш. Р. Галин — Н. Лазарев бригадасы ел башыннан — 7, Г. Головкин — Н. Коврин бригадасы 13 скважинаны сынаган.
— Экспедициянең иң яхшы вахталарымы? — дип сорый Е. Мәҗитова.— Менә алар: бораулаучылар М. Солтанов, Г. Шульгин, С. Гимаев, В. Журавлев. Ә иң әйбәт эшчеләребез бораулаучы ярдәмчесе Н. Любин, токарь А. Җамалетдинов, электр белән эретеп ябыштыручы А. Минаев.
Аннары без И. Д. Лагио бригадасына юл тоттык. Юл дигәннән, ул монда бик кыйммәткә төшә. Чөнки башта бүрәнә тезәргә, ком җәяргә, аннары тимер-бетон плитәләр түшәргә кирәк. Ә барысын да читтән, еракта ташыйлар. Шулай да юл әйбәт, әчкә кату төшерлек итеп дыркылдатуын исәпләмәсәк, түзәрлек. Ул — домино тезеп куйган кебек шакмак-шакмак, өч рәт буйлап салынган плитәләрдән гыйбарәт, плитәләр тоташкан урынга битум агызсаң, дыңгырдавы бетәр иде. Монысы — киләчәк эше.
Урман эчендә, сазлык өстендә маһабәт буровой манарасы. Өр-яңа техника, өч мең метрга хәтле бораулый ала. Ком өстендә тумбалар, алар өстендә, рельстагы локомотив кебек, насослары һәм корылмалары белән буровой манарасы үзе. Ни өчен рельста? Монда буровойлар төбәкләп-төбәкләп урнаша. Бер төбәктәге манара 5 әр метр читкә күчә-күчә, егермеләп скважина бораулый һәм туп-туры түгел, әлбәттә, ә 1400 метрга хәтле авышлык белән. Тирәнлеге дә шактый — 2400 метр (Татарстанда 1600—1800 метр). Төбәктә дистәгә якын будка бар. Кызыл почмагы, кочегаркасы, ашханәсе, мунчасы. Чөнки кешеләр шунда яши. Мунча көн саен диярлек ягыла икән. Ашау-эчү әйбәт, Татарстаннан вахта белән килеп йөрүче апалар өчпочмагын да, коймагын да пешерәләр. Эш авыр, көч күп түгел. Димәк, ризык та туклыклы булырга тиеш.
Бригаданың алдынгы эшчеләре бораулаучы Гыймаев, ярдәмчесе Н. Любин, электрик Н. Хөсәенов, слесарь В. Шумков — барысы да тәҗрибәле эшчеләр.
Безнең эш һәм яшәү шартлары белән кызыксынуны сизгәч, бер егет, көлеп, әйтә куйды.
— Монда кешеләр чирләми. Мин үзем өч елга бер чирләдем, анда да Баулыга кайткач, грипп эләктердем.
Ни өчен чирләми соң монда халык? Аларның шыңшып, иркәләнеп-назланып ятарга вакытлары юк. Һәркем эш белән мәшгуль. База ихатасында булсын, идарә бинасында булсын, без тик йөргән кешеләрне очратмадык. Һәркем үз эшен белә, шуңа күңелен биргән. Өлкәнрәкләр вакарь белән йөрсә, Абрек Нуришанов кебекләр чын мәгънәсендә чатыр чаба. А. Нуришанов — Бөгелмә бораулау идарәсенең Лангепастагы беренче экспедициясендә профком председателе. Үзе Әлмәт егете, Миңлебай авылында туган. Когалымда (ул Лангепастан төньяктарак) комсомолда эшләгән. Аңарчы нефть техникумын, читтән торып, Казан педагогия институтын

тәмамлаган. Хатыны әлегә Әлмәттә икән. Абрек Әнәсовичның бер генә минут та тик торганын күрмәдек без.

Монда акча мул төшә. Ләкин халык акчага гына ябышып ята дисәк, хата булыр. Партком секретаре В. Н. Мордвинов элек баш механик ярдәмчесе булып эшләгән. Хәзергә караганда акчаны ике мәртәбә күбрәк алган. Ләкин бу эшен бик ярата. Эш дигәндә, Василий Николаевич кырыс, таләпчән, шурләп сүз ашереп торучылардан түгел. Буровойдан кайтканда, безне бер машина узып китте. В. Мордвинов аны танып алды да куып җитәргә кушты. Шуннан ул теге пассажирны (ә ул начальник урынбасары икән) тетмәсен тетмәсенме?!

— Ни өчен сез йөк машинасына утырып йөрисез? Үз машинагыз кайда?

Теге ык-мык килә, фәлән җиргә фәлән нәрсә илттем, ди. Василий Николаевич әле безнең янга кереп утыргач та тиз генә тынычлана алмады.

— Кешедә оят юк! Белеп тора югыйсә, һәр йөк машинасы исәптә...

Буровойга баргач та, бәләкәй генә ЧП булып алды. Ипи китермәгәннәр икән. Василий Николаевич рациядән тиешле күрсәтмәләр бирергә керешге. Аның җыелыш үткәрүен дә күрергә туры килде безгә. Гади генә мисаллар белән, ләкин һәркемнең йөрәгенә үтеп керердәй сүзләр белән ул сыйфат, социалистик ярыш, сакчыллык, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү турында сөйләде, КПССның XXVII съезды куйган олы бурычларны телгә алды, конкрет саннар китерде, бик җентекләп эшчеләрнең гозер-үтенечләрен, киңәш-тәкъдимнәрен тыңлады, куен дәфтәренә язып куйды, кайберләрен шунда ук хәл итә дә барды.

Сораулар четерекле, дәгъвалар нигезле. Аэропорт эшендә дә четерекле нәрсәләр килеп чыга икән. Эшчеләрнең таләбе урынлы. Әгәр ул илгә нефть бирү өчен кечен кызганмый, унбиш көн буе, гаиләсеннән аерылып, бөтен уңайлыклары булган фатирын калдырып, буровойдагы будкада яши икән, димәк, аның транспорт, туклану кебек мәсьәләләрдә дә үзенә карата тиешле кайгыртучанлык күтәргә хакы бар. Эшче кеше — илнең тоткасы, таянычы, ышанычы. Партком секретаре М. Вафин бригадасындагы пешекчеләр Рәмзия Хөснетдинова һәм Миңниса Нуриәхмәтова, кочегарлар Люба Дмитриева һәм Миңнур Мусина, лаборант Нина Еремина, бораулаучы Владимир Мурин, слесарь Фәрхетдин Хисамов һәм электрик Әнәс Әхмәтвәлиев исемнәрен олылап телгә ала. Секретарь яхшы аңлый: коллектив — абстракт төшенчә түгел,— ул аерым шәхесләрдән тора. Бу бригадада үзара мөнәсәбәтләр яхшы, кешеләр тырышып эшлиләр, матур итеп яшиләр дә. Кайберләре кулларына каләм алып, шигырь дә язалар. Әнәс Әхмәтвәлиев безгә үзенең берничә шигырен укып күрсәтте. Әлбәттә, ул үзенең шагыйрь түгеллеген белә. Ләкин күңеле белән ул шагыйрь: соклана, борчыла, сөенә, ил-көн белән бергә, халыкның уй-фикерләрен тоеп яши.

Бөгелмә бораулау идарәсендә алдынгылар шактый. Ләкин бу тирәләрдә даны шаулаган В. Колесников бригадасына тиңләшергә шактый кирәк әле. Ул бригада узган ел 91 мең метр бораулаган. Ә Б. Старшов, М. Вафин һәм башка мастерларның бригадаларына нәрсә комачаулый соң?

Василий Николаевич Мордвинов:

— Технология хезмәте начар куелган,— дип аңлата.— Мин Иваново-Франковскида булдым, анда бөтенесе дә төгәл үтәлә, авариялар дә юк. Измә белән дә тәэмин ителгәннәр. Ә бездә әле... Авыш бораулауны да үзләштереп җиткереп булмый, тәзәтү эшләре шөгыльлебезнең унбиш процентлабын алып тора. Бу күп. Ярый әле, торбалар пресслауны җайга салдык, аерым цех төзедек. Цемент склады өлгерә. Торбаларны әрәм-шәрәм итмәү, монтаж вакытында тик торуларны киметү — менә безнең өстәмә резервларыбыз...

Партия һәм хөкүмәтебез нефтьчеләр турында туктаусыз кайгырта. Бу елларда техниканың аеруча куәтлеләре: сазлыкта да йөри ала торган тракторлар, экскаваторлар, куәтле краннар, «Ураган», Урал, КрАЗ, КамАЗ, ТАТРА машиналары. Боларны безнең беркайда да бу кадәр күләмдә күргәнебез юк иде. Ә менә алар ничек файдаланыла, ни дәрәҗәдә кадерләп тотыла, кемнәр аларны йөртә — монысы инде механизаторларга, җитәкчеләргә бәйле.

Лангепастагы яңача тормыш оешып, ныгып кына килә әле. Хәзергә җирле оешмалар «Татнефть» берләшмәсе коллективлары белән һәрвакытта да уртак тел табып бетерә алмыйлар. Төпләнеп эшләүче коммунистлар — шәһәр партия оешмасына, вахтачылар туган якларындагы оешмаларга карый. Бу хәл эштә шактый гына уңайсызлыклар да китереп чыгара. Ләкин проблемалар гауга-низагларсыз, шау-шуларсыз хәл ителә, психологик климат заман җилләре йогынтысында сафлана, яхшыра бара.

Март ахырында бу якларда КПССның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре Г. А. Быстров, «Татнефть» берләшмәсенең генеральный директоры КПССның XXVII

съезды делегаты Ә. К. Мөхәммәтҗанов, партиянең Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре Ф. Х. Мөхәммәтшин, нефть һәм газ промышленносте эшчеләре профсоюзының өлкә комитеты секретаре Г. Г. Гыйләҗев һәм башка җитәкче работниклар булып киткән. Хәл итәсе мәсьәләләрне уртага салып сөйләшкәннәр, яшәп килгән кыенлыкларны җиңү юлларын билгеләгәннәр. Бу хакта КПССның Лангепас шәһәр комитеты беренче секретаре Анатолий Игоревич Григорьев аеруча дулкынланып сөйләде.

— Себер нефтен күмәк көч белән генә күтәреп була,— диде ул.

Лангепас куәт туплый, Лангепас яулыйсы үрләрне билгели. Узган ел ул илгә 25 миллион тонна нефть, 1,2 миллиард кубометр газ бирде, быел тагын да куанычлырак нәтиҗә көтелә. Шәһәр үзе дә күзгә күренеп үсә. Былтыр монда 80 мең квадрат метр торак, 560 урынлы балалар бакчасы, 1176 урынлы мәктәп, универсам һәм башка объектлар файдалануга тапшырылган.

Ләкин «кирәк»ләр тагын да күбрәк: кибетләр, кинотеатрлар, спорт комплекслары, китапханәләр... Шунысы сөендерә: кешеләр алдагы көнгә ышанып яшиләр. КПССның XXVII съезды беркемне дә битараф калдырмаган, кеше рухының яңа катламнарын ачкан. Без ни турында гына сөйләшсәк тә, сүз шул яңалыкларга барып тоташты.

Бер җирдән — икенче җиргә, буровойдан буровойга йөри-йөри көннәр үтә торды. Язучы халкыннан без монда иң беренчеләр икәнбез — шуңа күрә әле анда, әле монда чакырып кына алалар. Кешеләр шигъри сүзгә, җырга, музыкага сусаган. Без дә ялындырып тормыйбыз. Иртә таңнан чыгып китәбез дә арып-талып төн уртасына гына кайтып җитәбез. Күңелдә яңа шигырьләр шыта:

Ерак юллар үтеп килдек монда,
Һәм торабыз менә хәйран калып:
Йокымсырап яткан тарафларга
Көчле ташкын булып агыла халык.

Йолдызлар да шул ук, шул ук Ай да,
Үзгә бары заман — уяу тайга;
Яңгырап тора туган яктан килгән
Таныш моңнар буровойда.

Һәр адымда таныш УБР лар —
Әлмәт, Баулы һәм Бөгелмә атлы;
Безнең кара алтын осталары
Килгән Себер якларына хәтле.

Көрәш мәйданнары һаман киңрәк;
Мөмкинлекләр башка, көчләр башка.
Безнең Татарстан егетләре
Мәйдан тота бүген Лангепаста.



**М. Г. Әхмәтов,**

КПССның Балтач райкомы беренче секретаре,
КПССның XXVII съезды делегаты.

# ҮСЕШ, ЯҢАРЫШ ЕЛЛАРЫ

Безнең район — республиканың иң төньягында. Ул Мари АССР, Киров өлкәсе, шулай ук ТАССРның Арча, Кукмара районнары белән чикләнә. Халыкның 83 проценты — татарлар, 14 е — удмуртлар, 1,9 ы — руслар, калганын чуваш, мари, үзбәк, әрмән милләте вәкилләре тәшкил итә. Эш кешеләренең 68 проценты — колхозчылар, башкасы — эшчеләр һәм хезмәткәрләр.

Район тарихы бай. Безнең якларга халыкның кайчан урнашканлыгы төгәл билгеле түгел. Тарихи мәгълүматлар халыкның гасырлар буе якты, азат, мул тормыш өчен көрәшеп яшәве хакында сөйли. Пугачев восстаниесе вакытында безнең як халкының актив катнашуы тарихта аерым урын алган. Район территориясеннән «Себер тракты» уза, ул юлдан ирек яулаучы күпме каһарманнар Себергә озатылган! Тоткыннарның качарга омтылып талпынганнарын җәзалау өчен махсус кара таганнар әзерләнгән. Хәзерге Карадуган авылының исеме шуның белән бәйле. Безнең як халкының газаплы тормышын, изелүен бөек рус шагыйре, язучы Радищев үзенең сәяхәтнамәләрендә бик төгәл чагылдыра. Үзе тукталыш ясаган Арбаш, Янгул авыллары турында ул зур мәгълүмат язып калдыра.

Социалистик революциядән соң да әле фаҗигале хәлләр шактый булган. 1918 елның көзендә Мортаза бай җитәкчелегендә сәнәкчеләр хәрәкәте күтәрелә. Балтач аша Малмыждан Арчага баручы хәрби комиссар алар тарафыннан үтерелә. Районнар төзелгәнгә кадәр җитәкче эшләрдә эшләгән Закир Хәертдинов, Сәгыйть Фәйзуллин, Риза Алкин, Фәләхи Шаляпин кебек партиягә тугрылыклы җитәкчеләр безнең яклардагы шул кискен көрәшләрдә чыныгу алган.

1930 елда бездә Түнтәр районы төзелә. Бу авыл район үзәгеннән исәпләнсә дә, анда эшләү өчен шартлар авыр була. Шунлыктан 1931 елда район үзәге Балтачка күчерелә, районның исеме дә Балтач дип үзгәртелә. Шушы ук елны 5-6 тракторы, унлап катлаулы сугу машинасы булган МТС төзелә. Балтачта «МТС» исемле район газетасы чыга башлый.

1930 елда Арбор волостенда 25 коммунистны берләштергән 5 партия ячейкасы оеша, ә шул ук вакытта чагыштырмача зурлардан саналган Көшкәтбаш, Субаш, Иске Көшкәт авылларында бер генә партия члены да булмый. Шушы ук елны күмәк хуҗалыклар төзелә. Колхозлар оештыруда аеруча зур активлык күрсәткән Кадыйр Гайнетдинов бу чорны тасвирлап, үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «1930 елда безгә (Түнтәр авылына) кантоннан бер трактор бүләк иттеләр. Аны бөтен авыл халкы җыелып карады. Бераздан ярым катлаулы сугу машинасы биргәннәр иде. Юлда ава күрмәсен дип, аны саклап кайтырга 30 кеше җибәрдек. Бар иде еллар, заманнар...» К. Гайнетдинов 1931 елның декабрь аенда Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты сессиясендә катнаша.

Колхозлашу төрле сыйныфларның көчле көрәше аша алып барыла. Борбаш авылы кулаклары активист Гадел Гомәровны үтерәләр. М. Лызи авылында да фаҗигале хәлләр була. Райондашыбыз күренекле прозаик Алексей Медведевның «Лызинское поле» трилогиясендә нәкъ шул фаҗига яктыртыла.

Районның бу чорда эшләгән җитәкчеләрен халык әле һаман олылап, хөрмәт белән искә ала. Партия райкомының тәүге җитәкчесе Гариф Усманов, райкомның оештыру бүлеге мөдире Гарифулла Хәйруллин, эшче-крестьян инспекциясе председателе Сабир Хәкимҗанов, Балтач волосте Башкарма Комитеты председателе Закир Мөхәммәтшин, партия активисты Фазыл Рәхмәтуллин, партия һәм финанс органнарында эшләгән Мәгъсүм Әхмәтҗанов кебек фидакарьләрне һич тә онытмыйбыз.

1930 елларда комсомол ячейкалары барлыкка килә. Беренче комсомоллардан да талантлы җитәкчеләр үсеп чыга: Риаз Алкин, Низам Зиатдинов, Галимҗан Шаһимәрданов, Мөхәммәтгали Закиров һәм башкалар.

Бөек Ватан сугышына кадәр үк Халык мәгарифен үстерүгә зур өлеш керткән Габделхәй Хәсәнов Н. К. Крупская чыгышын тыңлау бәхетенә ирешә, Мәгъмүрә Рамазанова ике чакырылыш рәттән — ТАССР Верховный Советы депутаты, Галия Гарифуллина РСФСР Верховный Советы депутаты булып сайлана.

Районда әкренләп культура революциясе киң колач ала, 1934 елда Балтачта беренче клуб ачыла. Юсупов Әмин кино күрсәтә башлый, төбәкнең яшь шагыйрьләре Хәбра Рәхман, Вәдүт Мифтахов яңа тормышны поэзиядә чагылдыралар.

Күмәк хуҗалыклар оешуның беренче елларында ук район халкы зур уңышларга ирешә. 1933 елда хәзерге «Правда» колхозы һәр гектардан 15 центнер уңыш ала, республиканың күчмә Кызыл байрагы белән бүләкләнә. 1934 елда хәзерге «ВЛКСМның 50 еллыгы» колхозы да шундый ук байракка лаек була. Район 1933 елда, колхозчы-ударникларның 2 съезды ачылу хөрмәтенә барган ярышта җиңеп, республика күчмә Кызыл байрагын ала. «Труд» колхозы нәселле атлар үрчетү буенча ирешкән уңышлары өчен, Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең Почет китабына кертелә.

Фин сугышы кампаниясендә районыбызның өч егете — Ибраһимов Хәбибулла, Хафиз Сабиров, Бакый Рәхимов — Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар. Бөек Ватан сугышы чорында районның 9000 нән артык кешесе Ватан иминлеген саклауда катнаша. Шулардан Гайфетдин Гыйльметдинов, Василий Булатов, Габдулла Гарифуллинга Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

«Совет сугышчысы» исемле фронт газетасы 1943 елның 3 декабрендә Г. Гыйльметдиновның авылдашларына язган хатын урнаштыра. Анда түбәндәге юллар бар: «Кадерле авылдашлар, туганнарым! Мин Днепрны кичүчеләрнең беренче сафында булдым. Аны кичкәндә, снаряд ватыгы тиеп, көймәбез су астына китте. Мин йөзеп чыктым, автоматым белән дошман траншеясына бәреп кердем, кулыма немец пулеметын төшереп алдым да үз пулеметлары белән үзләрен кырдым. Туган илем өчен мин җанымны-тәнемне кызганмыйча сугышам һәм киләчәктә дә сезнең ышанычыгызны акларммын. Мин үземнең пулеметым белән 400 немецны үтердем.

Сез, колхозчы туганнар, Кызыл Армиянең данлыклы җиңүләренә лаеклы рәвештә колхоз кырларында, терлекчелек фермаларында армый-талмый эшләгез! Ватан өчен, фронт өчен!»

Шул ук газета авылдашларының Гыйльметдиновка җавап хатын урнаштыра. «Сезгә Советлар Союзы Герое исеме бирелү хәбәрен ишеткәч, тагын шуны язарга булдык. Без фронтка ярдәм итү өчен тырышып эшлибез. Көз көне 470 гектар урынына, 578 гектар арыш чәчтек. Язгы чәчү уңышлы бара, атлар яхшы. Сез бит үзегез дә 5-6 ел ат караучы булып эшләгән идегез. Әниегезнең тормышы яхшы. Колхоз шушы көннәрдә гена аңа бер савым сыер бүләк итте. Дошманны тизрәк тар-мар итеп кайтыгыз, сезне 1 Май бәйрәме белән котлыйбыз».

Районыбызның каһарманына туган якларына әйләнеп кайтырга туры килми, ул кадерле пулеметы «Максим» янында батырларча һәлак була. Истәлеген мәңгеләштереп, Шаумян исемендәге колхозда аңа һәйкәл куелды. ВЛКСМ райкомы Г. Гыйльметдинов исемендәге вымпел булдырды, ул кыр эшләре батырларына тапшырыла, урта мәктәптә аңа багышланган күргәзмә бар, пионер дружинасы аның исемен йөртә.

Бөек Ватан сугышында районыбыз хатын-кызлары да егетләк күрсәттеләр. Нинди генә хәрби һөнәрләрне өйрәнергә туры килмәде аларга! Мөнәвәрә Гарифуллина — артиллерист, Фатыйма Җәләлова — авиатор, Нәсимә Сафиуллина — элемтәче... Такыялар үрәсе нәфис куллар сугышчан корал алды, иңбашларына ирләр күтәрә алмаслык йөкләр менде, әмма кызлар бирешмәделәр.

Тылда да хәлиткеч урыннарда хатын-кызлар эшләде. Җәвәһирә Шиһапова, Разия Нәбиева, Сәрвәр Зарипова, Фаизә Шәмсетдинова, Мөнәвәрә Ризванова оста җитәкче буларак танылдылар. Бер Субаш авыл халкы гына да танк колоннасы төзү өчен 200 мең сумнан артыграк акча җыйды. Фронттагы һәм тылдагы районташларыбызның олы хезмәтен бәяләп бетерү кыен, алар җиңү хакына мөмкин булмастай эшләр башкардылар.

Сугыш яраларын төзәтү, халык хуҗалыгын аякка бастыруга районыбыз хезмәт ияләре зур дәрт белән тотынды. Авыл хуҗалыгындагы аеруча зур үзгәрешләр, КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март Пленумыннан соң башланды. Ул чордан соң терлекләр саны — 2, машина-тракторлар — 2,5, хуҗалыкларның энергетика белән кораллануы 5 тапкырга артты. Бу елларда йөзләрчә кешеләр СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде, ә «Правда» колхозы тимерчесе Сәрвәр Нәфыйковага Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Без, Сәрвәребез бөтен дөньяда бердәнбердер, дип уйлыйбыз. 1971 елда К. Тимбикованың аңа багышланган «Синең өчен» исемле повесте басылып чыкты.

1972 елдан башлап безнең терлекчеләр, республикада беренче булып, ике сменалы эшкә күчте. Хәзер терлекчелектә эшләүчеләрнең 70 проценты урта белемле яшьләр. Егет-кызларны авылда калдыру өчен ике сменалы эш тә, заманча клублар төзү генә дә житми икән. Хәзер һәр хуҗалыкта диярлек ясле-бакчалар эшли, яңалары оештырыла. Соңгы елларда колхоз һәм совхозлар, предприятиеләр торак йортларны күпләп сала. Кайбер гаиләләр үзләрендә яңа өй булдыра. Андыйларның саны ел саен 200 дән артык була. Кул хезмәтен механикалаштыру да — яшьләрнең авылда калуына этәргеч. Хәзер сыер саву тулысынча, тирес чыгаруның 90 процентлабы машиналарга йөкләнде.

Оештыру һәм масса-политик эшләрне яхшырту нәтиҗәсендә район X бишьеллыкта терлекчелек продуктлары җитештерү һәм хәзерләү планнарын уңышлы үтәде. IX бишьеллык белән чагыштырганда бу чорда сөт җитештерү — 17, ит — 18, йон — 22 процентка артты, ә XI бишьеллыкта X белән чагыштырганда ашлык җитештерү — 33, сөт — 18, ит 9 процентка артты. Үсеш терлекләрнең баш санын түгел, ә продуктлылыгын арттыру исәбенә алынды. Район соңгы елларда, кышлату чорында, терлекчелек продуктлары җитештерү һәм хәзерләүне арттыра барганы өчен, 4 тапкыр КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамотасы белән бүләкләнде. Шундый ук грамоталар «Правда», «Алга», «Труд» колхозларына да бирелде.

1985 елда район буенча һәр сыердан 3565 килограмм сөт савып алынды, 10 савымчыбыз һәр сыердан — 5000, 70 савымчыбыз 4000 килограммнан артыграк сөт савалар. 3 хуҗалык 4000 килограмм чиген уздылар инде. Максат — райондагы һәр сыердан 3700 килограмм сөт алу. 1990 елда исә 4000 килограмм сөтне район буенча һәр сыердан савып алырга чамалыйбыз.

Җирне эшкәртүгә игътибар арту, органик ашламаларны ел саен һәр гектарга 10 ар тонна кертә бару, минераль ашламалардан дөрес файдалану, орлыкчылык эшенә игътибарны арттыру нәтиҗәсендә көлсу, ачы туфраклы җирләрдән дә узган ел 23,2 центнер уңыш алынды, ә Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге, «Якты юл» колхозлары һәр гектардан 31 әр центнердан артыграк уңыш үстерделәр. 1990 елда аны 30 центнерга җиткерү район игенчеләренең изге максаты булып тора.

Соңгы елларда «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз аеруча югары уңышлар яулап килә. Алар узган ел һәр гектардан 31,2 центнер уңыш алды. Һәр сыердан 4200 килограммнан күбрәк сөт савылды, унберенче бишьеллык планнарын 3 ел да 10 айда үтәде. Колхоз, ирешелгән уңышлары өчен, ике тапкыр КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагына лаек булды, унынчы бишьеллык йомгаклары буенча колхоз Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Колхоз председателе ТАССРның атказанган агрономы, СССР Верховный Советы депутаты X. Галимуллинга Ленин, Октябрь Революциясе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары бирелде.

Районның башка хуҗалыклары да якты омтылышлар белән рухланып эшлиләр.

Район үзенең атаклы кешеләре белән хаклы рәвештә горурлана. Алар арасында галимнәр Ишморатов Б. М., Вәлиев Г. Г., Фәләхов И. Ф., Гафаров А. Н., Әхмәдиев Ф. Г., Хәеретдинов Р. Г., Гарифҗанов Г. Г., Габделхәев Б. Г. кебек фән докторлары бар. Районыбыздан Хәбибрахманова Ш. X.— I чакырылыш, Кашапова Р. К., Гыйльметдинова Р. X., IX—X чакырылыш СССР Верховный Советы депутатлары булдылар. Фатихов Н. Ф., Гомәрова Л. П. КПССның XXV, XXVI съездына делегат итеп сайланды. Әдипләр белән булган тыгыз бәйләнешләр дә шатландыра безне. М. Фәйзи, безнең Шода авылында яшәп, «Галиябану»ны язган. Күренекле артистлар Ж. Сәләхова һәм Р. Ибраһимова Кенә авылында туып-үскән кешеләр. Үзешчән композитор И. Хисамовның күп әсәрләре шулай ук Балтачта язылды.

Район хезмәт ияләре зур эшләр башкарып, киләчәккә матур өметләр белән яши. Бөтен көч КПССның XXVII съезды карарларын үтәүгә юнәлдерелә.

Район партия оешмасы моңа кадәр ирешелгәннәрне тагын да ныгытырга, экономика, культура, мәгариф, медицина өлкәсендә һәм башка тармакларда зур уңышларга ирешергә омтыла.

Мансур Вәлиев

# ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР

## Әдәбият — күңел юлдашы

Авыр димим сине,
Җиңел димим.
Үлчәп булмый сине, замана.
Утыз яшькә җиткән егетләрнең
Икенче кат чәче агара,—

дип язган иде шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин үзенең бер шигырендә замандашыбыз күңеленең уй-кичерешләрен төгәл чагылдырып.

Әйе, чорыбыз катлаулы да, җаваплы да. Планетабыздагы хәзерге хәлнең четереклелеге һәрбер намуслы йөрәккә тәэсир итә. Һәрбер намуслы җан бүген илләр һәм халыклар язмышы өчен — Җиребез киләчәге өчен борчыла, «чәчен агарта».

Әнә шундый һәм әле тагын бик күп төрле гаять драматик кичерешләр белән яшәүче замандашыбызга бүген ышанычлы күңел юлдашы кирәк. Моңа кадәрге тормышта очрамаган өр-яңа юл чатларында килеп чыкканда да, авыр-авыр ситуацияләрдә калганда да замандашыбызга дөрес һәм кешелекле юнәлешне табышырдай булышчы кирәк. Күңелен төрле шик-шөбһәләр чолгый башлаганда да, рухны какшатмау, иманны сындырмау өчен кешегә сердәш кирәк...

Дөньяда беренче мәртәбә яңа тормыш төзергә алынган совет кешесенә күңел юлдашы һәм тугры сердәш булуны илебез халыклары әдәбияты үзенең иң изге вазыйфасы дип саный. Яратып укыган, озак вакытларга хәтергә сеңеп калган әдәби әсәрләрне яңадан күңелдән барлап чыксак, без тагын бер мәртәбә әнә шул хакыйкатькә төшенербез: алар безнең тормыш юлыбызда тугры дус сыман булганнар икән, без ул әсәрләр һәм андагы зур язмышлы геройлар белән даими рәвештә диярлек, гел киңәшеп, серләшеп яшибез икән!

Ә хәзер — партиябезнең XXVII съездында игълан ителгән социаль һәм экономик үсешне тизләтү программасын тормышка ашыру процессында, кеше факторын тагын да яхшырак өйрәнү һәм аның барлык мөмкинлекләрен халык файдасына эшкә җигү процессында — әдәбият алдында торган бурычлар тагын да зурая төшә. Хәзер күп миллионлы халкыбызның — һәркемнең, һәр кешенең — аңын, уйлау һәм фикерләү рәвешен партия съезды юнәлеш биргәнчә үзгәртү таләп ителә. Икенче төрле итеп әйткәндә, бу — кешенең һәрвакытта һәм һәр җирдә актив тормыш позициясендә торуы, эшнең торышы өчен үзендә зур шәхси җаваплылык тоюы дигән сүз.

Әдәбият менә шушы бурычны үзенә генә хас гаять нечкә чаралар аша — кеше күңеленә тәэсир итә торган хисләр һәм кичерешләр аркылы, образлы яшәү дөньясы белән әкрен-әкрен тормышка ашыра килә.

Үткәннәргә борылып карасак та иң җаваплы чорларда без әдәбиятның һәрчак кеше күңеленең юлдашы булып баруын күрербез. Ул аның белән бар авырлыкны уртаклаша, аның белән эчкерсез рәвештә серләшә-киңәшә, дусты да, остазы да була. Илебез әдәбиятында иҗат ителгән бик күп уңышлы әсәрләр әнә шуңа матур мисал. Алар безнең укучыга бик тә яхшы таныш. Андый китапларны укучы күтәп алып, чират тора-тора укый...

## «Тәнкыйть» дигән иҗат

Бик күпләр күтәп алып укыган, халык арасында зур җанлану тудырган әдәби әсәрләр булу анысы барыбызга да аңлашыла. Рухи тормышыбызның аерылгысыз бер өлеше сыман кабул ителә хәзер бу.

Ә менә шушындый бик кызыклы һәм тирән эчтәлекле әдәби әсәрләр янына тагын «әдәби тәнкыйть» дигән иҗат нигә кирәк соң? Әдәбият та, укучылар да аннан башка гына яши алмыймыни?

Бу сорауларга җавап биргәнче, башта һәркем үзенең китап уку процессын искә төшерсен. Менә син, гап-гади бер укучы, әдәби китап укып чыктың, ди. Ул сиңа бик тә ошады. Сиңа андагы геройлар ошады, әсәрдә күтәрелгән тормыш проблемалары сине дулкынландырды... һәм әле тагын — бу әсәрдә сурәтләнгән хәлләр син үзең күргән, үз башыңнан кичергән вакыйгаларга бик ошаган булырга мөмкин. Хәтта әле сезнең авылда яисә районда шушы темага караган тагын да кызыклырак, гыйбрәтлерәк вакыйгалар булуы да бик мөмкин. Тормыш бит ул! Еш кына аның күренешләре язучы фантазиясен дә узып китә.

Әнә шул вакытта инде син нишлисең?

Башта, әлеге әдәби әсәрне укып чыккач, әлбәттә нык дулкынланасың, әсәрләнәсең һәм үзеңдә туган ул хисләрне, кичерешләрне кемгә әйтергә, кая куярга, кем белән уртаклашырга белмисең... Шулай байтак йөрисең... Аннары инде — ирексездән диярлек, кулыңа каләм аласың һәм күңелеңдә, йөрәгеңдә ташыганны алдыңда яткан ап-ак кәгазьгә түгә башлыйсың... Бу вакытта инде син укыган әсәрдәге һәм реаль тормыштагы вакыйгалар, кешеләр бергә аралашып китә. Без инде аларны аера алмый башлыйбыз. Язган вакытта синең өчен иң кадерле булган, иң күңел түрендә яткан уйлар, кичерешләр кузгала һәм барысы-барысы, һәммәсе бер кайнар ташкын булып ага, кәгазьгә тулып ташый. Урыны-урыны белән бу язма шигырь юлларына да, вакыт-вакыт чын проза әсәренә дә ошап китә. Ә нигә, гаҗәпмени! Син — укучы — шулай ук кайнар хистән һәм дәртле йөрәктән мәхрүм түгел бит! Әгәр шулай икән, сәбәбе чыккач, нигә әле ул — күңел дигән дөнья — бер ярсып шауламаска, тулып ташымаска тиеш?!

Шулай итеп, әле генә үзен гап-гади укучы дип санаган кеше, үзе дә сизмичә, иҗат белән шөгыльләнә башлады. Иҗатның «әдәби тәнкыйть» дигән төре белән... Тәнкыйтьче дә, кайберәүләр уйлаганча, бик алай куркыныч кеше түгел — гел күсәк күтәреп кенә тормый. Ул иң кайнар йөрәкле һәм тәҗрибәле, югары зәвыклы укучы. Билгеле инде: дөнья булгач ул укучыга ошамаган һәм хәтта бөтенләй ошамаган, ачуын китергән әсәрләр дә очрый. Менә шул чагында инде әлеге югары зәвыклы, намуслы укучының йөрәге тыныч кына, дәшми генә кала алмый. Ул борчылып, әрнеп, бу хәлнең сәбәпләрен дә аңларга һәм ачарга теләп яза. Аның болай чыгыш ясавы һич тә «күсәк күтәрү» булмый, ә бәлки әдәби иҗат эшендәге түбән сыйфатка, «брак»ка каршы төшү була.

Теге яки бу әсәрне укыгач туган фикерләрен, тойгыларын белдереп чыгыш ясаган гап-гади укучыларны республикабызда басыла торган газета-журнал битләрендә еш күрәбез без. Мисал өчен, 1983-84 елларда «Казан утлары»нда бүгенге проза турында зур сөйләшү барганда аңа бик күп укучылар катнашты. Аларның байтагының фикер йөртү, әдәбиятны аңлау һәм тою дәрәҗәсе профессиональ тәнкыйтьчеләрнекенә тиң диярлек иде. «Татарстан яшьләре» битләрендә булып узган «Шигырьне кем укый?» дигән сөйләшү дә поэзия сөючеләребезнең әдәбият серләрен аңлауда шактый вәкаләтле булуларын раслады. «Социалистик Татарстан» газетасы үз укучыларының андый хатларын даими рәвештә диярлек бирөп бара.

Ә инде профессиональ тәнкыйтьчеләргә килсәк, безнең әдәбиятта югары хәзерлекле кадрларның зур гына отряды бар. Сан ягыннан гына алып карасак та, бүгенге көнгә 187 кешене берләштерүче Татарстан Язучылар союзының 24 е — тәнкыйтьчеләр. Күргәнебезчә бу аз түгел.

## Кемгә нәрсә җитми?

Ләкин яшерен-батырын түгел: бүген бездә бу жанрның торышыннан ризасызлык бик көчле. Бүген әдәби тәнкыйтьтән бездә һәркем дә канәгать түгел. Һәм тагын шунысы кызыклы — аннан һәркем үзенчә, үзе уйлаганча канәгать түгел.

Әлбәттә, күпләрне, иң беренче чиратта, бүгенге әдәби тәнкыйтьнең тешсезлеге, шактый еш күренгәләүче әдәби бракка каршы бөтенләй диярлек көрәшмәве, усал мәкаләләрнең бездә бөтенләй диярлек күренмәве борчый.

Икенче берәүләр хәзерге әдәбиятта бик мөһим мәсьәләләрнең тәмам өлгереп җитүен күреп торалар һәм ул хакта әдәби тәнкыйть үз сүзен әйтер дип көтәләр-көтәләр дә, моны күрү бәхетенә ирешә алмагач, шулай ук тәнкыйтькә үпкәлиләр.

Өченче төр укучылар исә басылып чыккан әдәби әсәрләрдә бик кызыклы образлар, уңышлы детальләр, истә кала торган, кыйммәтле метафоралар табалар. Тәнкыйтьче булган кешеләр аларны җыйнап, гомумиләштереп язар дигән өметтә яшиләр. Кызганычка каршы, аларның бу теләге дә еш кына тормышка ашмый кала.

Аннан соң, бүген безнең әдәбияттагы процессларны башка әдәбиятлар белән чагыштырып карау ихтыяҗы да бик көчле. Бу эшләнсә әдәбиятыбыз өчен бик файдалы нәтиҗә-

ләр килеп чыгар иде, үзебезнең үсешкә дә, тулаем алга китүгә дә этәргеч булыр иде...
Болардан тыш әле әдәби тәнкыйтькә икенчерәк төр максатлардан чыгып караучылар да юк түгел. Югарыда санап кителгән үсешкә хезмәт итүче ризасызлык янына аларныкы да килеп кушыла. Ә болары нинди төр канәгатьсезлек соң тагын?
Берәүләр үз иҗатына игътибар булмаганга күрә әдәби тәнкыйтькә үпкәли. Икенче берәүләргә исә күпмедер игътибар булса да, мактау, күтәрелү дәрәҗәсе җитми — ул шуңа күрә канәгать түгел. Өченче төр язучыларга карата тәнкыйть ниндидер уңайдан тәртмәле сүз әйткән — алар шуны кичерә алмыйлар. Дүртенчеләргә исә тәнкыйтьчеләр мактаган язучы иҗаты ошамый. Бишенчеләргә, киресенчә, тәнкыйтьчеләр тарафыннан «чеметелгән» автор иҗаты ошый — алар тәнкыйтьче фикере белән килешергә теләмиләр, бар уңайдан тулаем тәнкыйтьне дә бетереп, сүгеп ташлыйлар...
Шуның өстәвенә, әле тагын бит әдәбиятның төрле жанрлары арасында, һәр жанрның үз эчендәге төрле иҗади юнәлешләр арасында үзара ярышу сыман мөнәсәбәт яши. Теге яки бу стиль, иҗади юнәлеш турында үз фикерен кистереп әйткән тәнкыйтьчедән риза булмаска ул уңайдан да сәбәп чыгып кына тора.
Аннан соң, күп кенә язучылар басылып чыккан һәрбер китап яисә әсәр үзе турында матбугатта фикер ишетергә тиеш дип исәпли һәм чынлыкта моңа ирешелми икән — шулай ук тәнкыйтьчеләргә, гомумән, тәнкыйтькә үпкәли.
Күрүебезчә, укучыларның да, язучыларның да бүгенге әдәби тәнкыйтькә булган карашлары, аны күзаллаулары һәм таләпләре бик төрлечә. Әле җитмәсә, вакыт-вакыт тәнкыйтьчеләрнең үз араларында да бәхәсләр куерып китә. «Тәнкыйтьче кем өчен язарга тиеш?» — дигән шикелле уйланулар, кылыч уйнатулар була...
Югарыда санап үтелгән хәлләрнең күбесе, әлбәттә, безнең әдәби тәнкыйтебезнең иҗтимагый абруе үсүгә ярдәм итми. Киресенчә, башка сәбәпләр белән бергә кушылып, үсешне тоткарлаучы факторга әверелә.

## Төптәнрәк уйласак...

Әмма мәсьәләнең эченәрәк кереп, төптәнрәк уйлап карасак «бездә әдәби тәнкыйть юк!», «бездә әдәби тәнкыйть үсми!» дип йөрүнең безгә бернинди дә файда бирмәгәнен күрербез. Акыллы кешеләр алай итмиләр... Мисал өчен игенчене яисә бакчачыны алыйк. Берәр елны уңыш азрак чыкса, ул бит: «бездә уңыш юк, бездә ашлык үсми» дип кычкырып йөрми. Иң элек ул бу хәлнең сәбәпләре хакында уйлана. «Нишләп болай булды соң бу? — ди.— Орлык начар идеме? Кирәк вакытта сугармадыммы әллә? Җитәрлек ашладыммы? Ә һава хәле ничегрәк булды соң әле?..» Кыскасы, уңышка бәйле булган бөтен факторларны күңеленнән җентекләп тикшереп чыга чын игенче, чын бакчачы.
Безнең әдәби тәнкыйть белән дә нәкъ әнә шундый хәл бит. Тик ул социаль күренеш һәм шуңа күрә күбрәк социаль факторларга — безнең барыбызның уртак тырышлыгына бәйле.
Игенче иң элек туфрак һәм чәчүлек орлык турында уйлаган кебек, биредә без дә иң башта төп җирлек — әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләп килүче кадрлар турында сөйләшик.
Безнең әдәбият өлкәсендә җитди тикшеренүләр алып барып докторлык дәрәҗәсенә ирешкән хөрмәтле галимнәребез, күп еллык иҗади тәҗрибәгә ия тәнкыйтьчеләребез бар. Алар матбугатта басылган аерым мәкаләләре белән дә, китап булып дөнья күргән күләмле хезмәтләре аша да хәзерге әдәби тәнкыйтьне үстерүгә җитди өлеш кертәләр. Мисал өчен Ибраһим ага Нуруллинның 1983 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Тормыш һәм сәнгать чынлыгы» исемле җыентыгы тынгысыз рухи эзләнү алып баручы тәнкыйтьчебезнең укучы каршында үзенә бер төрле хисап бирүе кебек иде. «Киләчәккә карап» дигән мәкаләсендә ул әдәби тәнкыйтьне ничек итеп күзаллавын да яза, әдәбиятның шушы төре алдына үз таләпләрен дә куя: «Тәнкыйтьтә иң мөһиме — әсәрнең төп мәгънәсен, анда күтәрелгән проблемаларны ачу, тормыштагы нинди процесс, нинди тенденцияләр йогынтысында мәйданга килүен аңлатып бирү һәм әдәби процесста нинди урын тотуын билгеләү. Икенче төрле итеп әйткәндә, әдәби әсәр нигезендә тормышның үзендә бара торган катлаулы процессларны аңларга ярдәм итү». И. Нуруллин үз иҗатында бу принципка тугры калырга тырыша. Ләкин шунысы гына бар: соңгы елларда газета-журнал укучылар Ибраһим аганың ялкынлы мәкаләләрен сирәгрәк күрә башладылар...
Күренекле әдәбият галиме Гали ага Халитнең 1985 елда чыккан «Портретлар һәм проблемалар» дигән китабы да безнең әдәби тәнкыйтебез өчен истә калырдай күренеш иде. Бу җыентыктагы Г. Тукай, Дәрдмәнд һәм Әмирхан Еники турындагы бүлекләр үзгә бер илһам белән, бу әдипләр иҗатын яшәтүче төп көчләрне, тенденцияләрне нык белеп, тоеп язылган.
Ә ил күләмендә танылган тәнкыйтьчебез Рафаэль Мостафин иҗаты бүгенге тормыш һәм шул ук вакытта әдәби процесс белән бәйләнеш ягыннан бик күп яшьләргә үрнәк

булып тора. Аның мәкаләләрен үзәк журналлар һәм газеталар да, шулай ук республикабыз матбугаты да бик яратып баса. Шулай ук тәнкыйтьченең «Кем ул Алсу?» исемле мәкаләсе укучыларның аеруча исендә калды. Ни өчен шулай? Чөнки бередә, беренчедән, яшь язучы Фәүзия Бәйрәмованың зур җанлану тудырган «Болын» повесте игътибарга алынган булса, икенче бик мөһим момент: мәкаләнең төп агышы, сүз сөреше бүгенге реаль тормыш хәлләре, хәзерге чорда яшәүче яшь кыз язмышы хакында иде. Әнә шуңа күрә, чынбарлык проблемалары белән тыгыз үреп язылганга күрә, Р. Мостафинның бу һәм башка язмалары киң яңгыраш тапты.

Фәрваз Миңнуллинның соңгы елларда дөнья күргән «Прозаның гражданлык йөзе» һәм «Талантлар юлы» дигән китапларын укыган кеше сугыштан соңгы чор татар совет прозасы үсешенә караган байтак четерекле сорауларга җавап таба ала. Шулай ук яшьрәк буын тәнкыйтьчеләрдән Р. Мөхәммәдиевнең «Әгәр без янмасак...», «Якутлар табыладыр вакыт белән» С. Маннаповның «Сезгә ышанам» һәм Ф. Зөлкарнәевнең «Кешем, асылың кем?» китапларын да безнең укучы яратып кабул итте.

Ә соң газеталарыбызда даими рәвештә басылып торучы кызыклы мәкаләләр? Алардан башка бүгенге әдәби тәнкыйтьне тулы күзаллап буламы соң? Аксакал язучыбыз Гомәр ага Бәшировның 1985 елда «Социалистик Татарстан» газетасында дөнья күргән «Бай һәм халыкчан булсын» исемле зур мәкаләсе, мәсәлән, байтак тәнкыйтьчеләргә өлге хезмәтен үти. Гомәр аганың уйлануларында безнең чор өчен кыйммәтле актуальлек тә, еллар каршында искермәүче, тоныкланмаучы олы хакыйкатьләр дә бар. Әдәбият турында җиңел генә фикер йөртүче кайберәүләргә каршы төшеп, ул болай яза: «Әмма матур әдәбиятның меңнәрчә еллардан бирле үтәп килә торган изге һәм төп вазыйфасы барын истән чыгармыйк. Ул — кеше үзе, аның рухи байлыгы, ул хәзинәне тагын да баетырга ярдәм итү, күркәм сыйфатлы, инсафлы кешеләр тәрбияләү, замандашларыбызга төрле кимчелекләрдән азат булырга ярдәм итү...»

Вакытлы матбугатта еш чыга торган «Яңа әсәр укыгач ...» дигән рубрика материаллары да, Язучылар союзының иҗат секцияләре белән берлектә редакцияләр үткәргән төрле тематик сөйләшүләр дә әдәби тәнкыйть фикерен җанландыруда, үстерүдә мәгълүм роль уйный.

Сүзне бу якка борып җибәрсәк, шуның ише мисалларны байтак китереп булыр иде. Бар караганда, шактый канәгатьләнергә дә мөмкинлек бар сыман. Абруйлы гына тәнкыйтьчеләребез җитди генә хезмәтләр бастыргалап тора, укучыларыбыз сирәк-мирәк булса да ялкынлы һәм хәтта усал мәкалә дә күргәләп ала... Кайбер проблемалар буенча да, аерым авторлар иҗатына багышланып та кызыклы гына мәкаләләр туа тора...

Ләкин... Бер чагыштыру ясап алыйк әле.

## Менә дигән үрнәк

«Минем мәкаләмдә бары тик ачуы чыккан кешене күрсәтәз, Сез өлешчә генә хаклы буларсыз: Сезнең китабыгызны укып чыкканнан соң мине билән алган халәтне белгертү өчен ул сүзләр үтә дә көчсез һәм йомшак... Юк, бередә мөһимрәк сәбәп бар. Сезгә хөтерем калуны, кимсетелүне мин үткәреп тә җибәрә алган булыр идем һәм, әгәр дә эш анда гына булган булса, хәзер бу хакта дәшми калырга да акылым җитәр иде минем; ләкин кимсетелгән гаделлек тойгысын, кешелек дәрәҗәсенең кимсетелүен кичереп булмый...»

Әнә шундый ялкынлы юллар, кайнап торган хис белән башланып китә В. Г. Белинскийның «Гогольгә хат»ы. Русның зур язучысы Н. В. Гоголь иҗатындагы ялгышуны — тормыш дәреслегенә, гаделлеккә хыянәт итүне — шул рәвештә кискен гаепләп чыга тәнкыйтьче. Бу әсәр Россиядәге барлык революцион көчләрнең, ил азатлыгы өчен зур көрәш алып баручыларның — бөтен намуслы кешеләрнең йөрәк авазы булып яңгырый.

«Нәрсә ул обломовчылык?» — икенче бер зур тәнкыйтьче Н. А. Добролюбовның бүген мәктәп дәреслекләренә кертелгән мәкаләсе шулай дип исемләнгән. Сер нәрсәдә соң? Моннан бик күп еллар элек иҗат ителгән тәнкыйть мәкаләсе ни өчен хәзерге яшьләр тарафыннан да җентекләп өйрәнелә?

Иң төп сер шунда: В. Г. Белинский мәкаләсендәге сыман, бередә дә иҗтимагый тормышның бик мөһим мәсьәләләре күтәрелә. Аерым алганда кешеләрдәге рухи ялкаулыкның, рухи көчсезлекнең, мескенлекнең — икенче төрле итеп әйткәндә: обломовчылыкның социаль һәм әхлакый сәбәпләре, тамырлары тикшерелә, өйрәнелә. Тәнкыйтьче обломовчылыкның иң үзәк тамыры — татлы хыял, матур теләк һәм сүз белән генә канәгатьләнеп яшәү икәнен ача. Шул теләкне, уйны тормышка ашыру өчен аз гына да кыймылдамауны, бер адым да атламауны, селкенмәүне кискен гаепли. Тәнкыйтьче матур сүзләр белән практик эшләр арасында булуы мөмкин булган һәм еш кына очракларда килеп тә чыга торган зур аермаларны ачып сала, фаш итә.

Н. А. Добролюбовның социаль һәм рухи анализы шулкадәр тирән — мәкалә хәтта бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый. Бүген безнең алга бик тә үткен төстә килеп баскан тәрбия мәсьәләләре уңаеннан, мисал өчен, Захар образы үтә кызыклы. Баланы, яшь кешене бәләкәйдән үк диярлек хәрәкәттән, үз ихтыяҗларын үзе үтәүдән, физик һәм рухи хезмәттән азат итү, мәхрүм итү, хәрәкәтнең бәрәкәтле процессыннан читтә калдыру — ялкаулыкны, обломовчылыкны китереп чыгара торган җирлек менә кайда! Захар образы менә шуларны гәүдәләндерә. Яшь буынны тәрбияләгәндә Захар сыман булмаска кирәклек — бүген дә искерми торган бик җитди социаль, әхлакый сабак...

1986 ел югарыда без искә алып үткән ике бөек тәнкыйтьченең юбилей елы булды. Николай Александрович Добролюбовның тууына — 150, ә Виссарион Григорьевич Белинскийның тууына 175 ел тулды...

Юбилейлар... Без андый чакларда күренекле кешеләрнең исемнәрен бик еш кабатлыйбыз, эшләгән эшләрен санйыбыз. Ә менә әлеге бөек кешеләрнең тормышта нинди принциплар буенча яшәгән, нинди шәхесләр булуы хакында еш уйланабызмы без? Ул кешеләрнең кайсы принциплар буенча яшәп, ничек иҗат итүе хакында беләбезме, онытмыйбызмы?

1986 ел әдәбиятыбызда Габдулла Тукай, Муса Җәлил юбилейлары елы да булды. Шул уңайдан әле куелган сораулар тагын да актуальләшә төшә. Без баштарак телгә алган бөек тәнкыйтьче шәхесләр дә, үз әдәбиятыбызның бөек, олы шагыйрьләре дә бер хакыйкатьне бик ачык раслый: зур шәхесләрнең зур яшәвеннән генә зур иҗатлар туа!

Безнең хәзерге әдәби тәнкыйтьчеләр өчен бу хакыйкать аеруча күз уңында торырга тиеш. Алар бу хакта аеруча нык уйланырга тиеш.

В. Г. Белинский һәм Н. А. Добролюбов иҗатына беренче күз салу гына да безне бөтенләй бүтән төрле яшәү эченә алып керә. Менә алар язган ялкынлы әсәрләрнең исемнәре генә нинди: «Безнең заман герое», «Якты көн кайчан килер?» һ. б. Күргәнебезчә, бередә иҗтимагый тормышның иң үткен мәсьәләләре, бередә — әдәби геройларны конкрет яшәеш җимеше буларак тирәннән һәм киң масштаблы аңлау, бередә — перспектив һәм революцион фикерләү, бередә авторларның тынгысыз һәм намуслы йөрәкләре, актив көрәшче шәхесе! Юк, эстетик анализ да аксамый аларда. Тормышчан һәм зур идеяләрнең әдәби әсәрдә ничек яшәве, сәнгатьчә ни рәвешле бирелүе бу тәнкыйтьчеләрнең игътибар үзәгендә.

Әнә шуңа күрә безнең бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин тәнкыйтьче Добролюбовның ялкынлы мәкаләләрен укыгач: «Вот как нужно писать!» — дип әйтә торган булган. Белгәнебезчә, үзенең «Герцен истәлегенә» исемле мәкаләсендә В. И. Ленин аларның иҗатына үтә зур бәя бирә, Россиядәге революцион көрәш тарихында аларның үлемсез урынын, әһәмиятле ролен билгели.

Әйе, бу бөек тәнкыйтьчеләр яшәп иҗат иткән чордан соң байтак еллар үтте, илебездә Бөек Октябрь социалистик революциясе булды. Ләкин бит иҗтимагый идеаллар өчен, югары максатлар өчен көрәш туктамады! Ул көрәш бүген дә, хәзер дә дәвам итә! Ә бүген әдәбиятта әлеге бөек тәнкыйтьчеләр кебек шәхесләр нигә соң күренмиләр?

Яшьләр белән очрашу вакытында бер өлкән тәнкыйтьчебезгә биргән идек әнә шул сорауны. Хәзер, безнең көннәрдә, Добролюбов һәм Белинский сыман көчле тәнкыйтьчеләрнең күренмәвен ул болайрак аңлатты: «Алар чорында матбугат һәм әдәби тәнкыйть көрәшнең бердәнбер диярлек коралы булган. Халыкны борчыган уй-тойгыларның бик зур күпчелеге әдәби тәнкыйть әсәре аша дөнья күргән. Шуңа күрә Добролюбов һәм Белинский кебек тәнкыйтьчеләрнең язганыннан ялкын бөркеп тора һәм эчтәлеге белән дә гаять киң колачлы алар... Ә хәзер үзегез беләсез, халык бәхете өчен партия дә, хөкүмәт тә һәм күп санлы җәмәгать оешмалары да тырыша...»

Өлкән тәнкыйтьчебезнең менә шул фикеренә ошаган сүзләрне икенче бер вакытта яшьрәк буын иҗатчысы авызыннан да ишетергә туры килгән иде. Үзенең кайбер яшьтәшләрен тәнкыйтьләргә, төзәтергә теләп ул болай дигән иде: «Халык дип без артык күп сөйләмибезме икән соң? Хәзер бит, иптәшләр, халык турында партия һәм хөкүмәт кайгырта.»

Беренче карашка һәр ике фикер дөрес кебек. Бередә бәхәсләшергә һич тә урын юк сыман. Ләкин аз гына игътибарлырак булсак, без әлеге ике иптәшнең гап-гади бер нәрсәдә ялгышканын күрербез.

Эш шунда: партия ул — без үзебез, партияле каләмебез! Шулай булгач, бүген партия алып бара торган гаять мөһим һәм киң колачлы көрәш — ул беренинди шикләнүсез безнең, һәрбер коммунистның, һәрбер намуслы каләм иясенең шәхси көрәше булып тора! Бүген безнең йөрәкләребез, иҗатларыбыз берсүзсез әлеге олы көрәшкә мобилизацияләнгән булырга тиеш! Без: «Халык турында партия, хөкүмәт кайгырта бит»,— дип үзебезне бүгенге көрәшләрдән читтә санарга тиеш түгел.

Безнең әдәбиятның кайбер тармакларында, аерым алганда тәнкыйтьтә, хәлләрнең бик үк шәп тормавын да иң беренче чиратта тәнкыйтьче шәхесләрнең зур тормыштан читләшү позициясе белән аңлатырга кирәк. Зур тормыштан ераклашу белән!

«Яшь тәнкыйтьчеләр» дигәндә моннан берничә ел элек булган бер утырыш искә төшә. Анық көн тәртибенә яшь тәнкыйтьче иҗатын тикшерү куелган иде. Утырыш болай гадәттәгечә барды — яшь иптәшнең язганнарын мактаучылар да булды, аңа карата тәнкыйть сүзләре дә әйтелде. Ләкин иң кызыгы шунда: фикер аерымлыгы ул утырышта катнашучы язучылар белән тәнкыйтьчеләр арасында килеп чыкты. Язучылар, үзләре образлы тел белән, җанлы һәм кызыклы итеп тасвирлаучылар, тәнкыйть мәкаләсенең дә шундыен — йөрәк ялкыны кушып язылганын хупладылар. Ә тәнкыйтьчеләр исә әлеге яшь иптәшнең мондый язмаларын «тәнкыйть мәкаләсе булып җитмәгән» дип бәяләделәр.

Инде хәзер ул утырыштан соң байтак кына гомер узды. Әлбәттә, теге вакытта күренгән ике төрле караш әле бүген дә бар, әле һаман үзен сиздерә. Тик хәзер, гомер үткән саен шул һаман ачыграк аңлашыла бара: соңгы елларда әдәби тәнкыйтькә килгән күпчелек яшьләр үзләрен борчыган мәсьәләләр хакында кызыклы, җанлы итеп, образлы тел белән язарга омтылалар — укылышлы итеп язарга!

Шулай итеп, яшьләр әдәби тәнкыйтьнең яманаты чыккан «академик» стильдән — артык җитди һәм җансыз стильдән — җанлы, образлы язуга борылыш ясавы хәзер инде күз алдында. Ә киңрәк планда алып караганда бу күренеш тулаем әдәбияттагы һәм культура өлкәсендәге халыкчанлашу, демократлашу процессының бик ачык бер чагылышы иде. Әдәбиятыбыз үзе дә соңгы егерме елда җанлы тормышка, кешегә, халыкка бик якынайды бит! Анда халыкның үзе төсле фикерләү, уйлау һәм кузаллау, сөйләшү рәвеше көчәйде.

Соңгы елларда әдәби тәнкыйтькә килгән яшьләр үз иҗатлары аша иң элек тормыштагы, әдәбияттагы әнә шул матур тенденцияне гәүдәләндерделәр. Кемнәр хакында сүз бара соң?

Ринат Мөхәммәдиев, Салих Маннапов, Равил Кукушкин, һәм Фәиз Зөлкарнәев кебек яшьләр турында биредә әйтеп тору да кирәк түгел сыман. Чөнки алар язганны барыбыз да яхшы белә, укып бара. Биредә бары тик шунысын гына билгеләп үтәсе килә: җанлы итеп, хис белән язу омтылышы иң көчле булып әнә шул буын яшьләре иҗатында чагылды, тулы бер юнәлеш төсен алды. Салих Маннаповның 1984 елда дөнья күргән «Сезгә ышанам...» исемле китабы үзендәге әйбәт хикәя сыман укыла торган әдәби тәнкыйть әсәрләре белән әлеге тенденцияне аеруча калку чагылдырды.

Билгеле, бу буын яшь тәнкыйтьчеләр язганны «төче» дип бәяләргә теләүчеләр дә булды. Чөнки, алдарак әйткәнебезчә, әдәби тәнкыйтькә ике төрле караш әле һаман яши. Анысы — андый бәя, сүзләр ишетелгәләү гаҗәп түгел... Аннан соң яшь тәнкыйтьчеләрнең үзләренең дә кызыклы итеп язабыз дип артык төчеләнебрәк киткән очраклары булгалагандыр. Чыбыкны бер яктан иенчегә бөккәндә, гадәттә, артыграк та бөгелеп киткәли бит ул... Ләкин шунысы хак: нигездә бу дөрес юл, иҗаттан, әдәби тәнкыйтьтән халык көткән юнәлеш иде. Бу — безнең әдәби тәнкыйтьне җанлы һәм чын тормыш белән ныграк бәйләячәк юл иде, ышанычлы юл иде!

Инде хәзер, бүгенге көндә, яшьләр тәнкыйте ни хәлдә соң? Анда нинди исемнәр, нинди әсәрләр, нindирәк омтылышлар чалымлана?

Язганнары әдәби тәнкыйть белән генә чикләнмәсә дә (ә бу бит үзе матур сыйфат!) биредә яшь тәнкыйтьчеләр турында сүзне Фәүзия Бәйрәмовадан башламыйча булмый. Чөнки соңгы берничә елда «Татарстан яшьләре» газетасында әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышлап аның имзасы белән басылган язмалар, чын мәгънәсендә укучының, бигрәк тә яшьләрнең җан азыгына әверелделәр. Ф. Бәйрәмова яшь артистка янсә хөрмәтле аксакал әдип турында язамы, урта буын иҗат кешесе хакында уйланамы, яки халык сәнгате проблемасына кагыламы — һәрвакыт укучының да үзегенә үтәрдәй итеп яза, җаны-тәне белән бирелеп яза. Ышанып әйтергә мөмкин: аның бу юнәлештәге иҗаты республика яшьләр матбугаты аша бик күп укучыларны әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә якынайтты, газета битләрен җанландырып җибәрде.

Ләбиб Леронов белән Әхмәт Сәхәпов язмалары исә шактый югары эрудициягә ия булу һәм күтәрелгән проблеманы киң колачлау, тормыш агышы белән бәйләп карау, әдәбият язмышы өчен борчылу хисе белән аерылып торалар. Мәсәлән, беренче авторның тәрҗемә турындагы мәкаләләре, ә икенчесенең аерым авторлар иҗатына багышланган рецензияләре зур гына өметләр уята.

Шулай ук Газинур Моратов һәм Ркаил Зәйдуллинның яшьләр һәм балалар матбугатында еш басылып торучы язмалары да авторларның оригиналь иҗат юнәлеше хакында сөйли. Алар әдәби әсәрләр хакында югары таләпләрдән чыгып фикер йөртергә, мавыктыргыч итеп язарга омтылалар.

Тагын да яшьрәк буын тәнкыйтьчеләрне әзерләү буенча моннан берничә еллар элек «Татарстан яшьләре» газетасы битендә эшләгән «Яңавазы» студиясе зур роль уйный иде.

Анда укучылардан алып өлкән яшьтәгеләргә кадәр әдәбият серләрен өйрәнде, күренекле әдипләрнең иҗат лабораторияләре белән танышты. Укучылардан да студиягә бик күп хатлар килде. Шуның белән яшьләрдә әдәби тәнкыйть фикерен үстерү буенча мөһим эш эшләнә иде... Кыскасы, һәммә яктан алып караганда да изге ниятле, матур эш булды бу. Яшь тәнкыйтьче студиясенең яңадан ачылуын укучылар бик хуплап каршылар иде...

## Ниләр комачаулый?

Димәк, хәзер безнең әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүче тәҗрибәле өлкәннәребез дә, актив язучы урта буын кадрларыбыз да һәм, әле яңа гына күреп киткәнебезчә, өметле генә яшь каләмнәребез дә бар. Ләкин, барыбер, шушыңа карап кына әдәби тәнкыйть өлкәсендәге кадрлар мәсьәләсе тулысынча хәл ителгән дип әйтә алабызмы соң? Юк, алай дип әйтә алмыйбыз әле!

Ни өчен? Иң беренчедән, кадрларыбызның сан ягы байтак кына булса да, хәзер, бүгенге көнне безне аларның сыйфаты канәгатьләндерә алмый. Әйе, әйе — тәнкыйтьчеләребезнең абсолют күпчелеге фән докторы яки кандидаты булуга карамастан, без биредә әнә шулай итеп әйтергә җөрьәт итәбез. Чөнки алар барысы да — филологлар гына! Безнең матбугатта басылган әдәби тәнкыйть мәкаләләрен укыганда да авторларның филолог кына булулары бик тә нык сизелә. Алар, гадәттә, әдәби әсәрне аерым текст итеп кенә карыйлар, шул текстка югары уку йорты биргән нормалардан чыгып якын килеләр. Алар өчен әдәбият белеменең моннан әллә ничә дистә ел элек язылган кануннары бердәнбер һәм төп закон. Алар шуннан башканы бик үк белергә теләмиләр.

Ә бит әдәби әсәр ул — иң беренче чиратта җанлы тормыш җимеше. Тормышта барган күп төрле социаль һәм рухи процесслар продукты. Анда чорның иң алдынгы идеалларын, иң матур идеяләрен гәүдәләндергән геройлар тынгысыз көрәш алып баралар...

Игътибарга алынган әдәби әсәрне һәм андагы геройлар яшәешен тулы итеп, бар нечкәлегендә тою өчен тәнкыйтьче кешегә әлеге социаль һәм рухи көрәшләрнең үзләрен тирән аңлау һәм тою кирәк. Мәкалә язучы автор тормыштагы әлеге олы проблемалар яшәешен үз күңеле аша да үткәргән булырга тиеш!

Ә бу инде, күргәнебезчә, бүгенге филологның бик үк көченнән килми. Моның өчен бүген социолог һәм философ буларак та зур әзерлек кирәк. Ә андый әзерлек җитмәү сәбәпле күпчелек әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә «саф» әдәби проблемалар гына калку итеп куела, язучы күтәргән үтә мөһим социаль һәм рухи мәсьәләләр бер читтә торып кала. Әдәбият галимнәре телендә еш очрый торган кагыйдә — «итен иткә, сөяген сөяккә аеру» принцибы эшли башлый. Нәтиҗәдә менә дигән кызыклы әсәр турында язылган тәнкыйть мәкаләләреннән чиркангыч булып «ит һәм сөяк» кенә күренеп тора. Ә бит әдәби әсәр үзе җанлы һәм тере организм иде! Ул яши иде! Аны кайберәүләр кулындагы әдәби тәнкыйть «коралы» әнә шундый хәлгә китерде.

Үзеннән үзе сорау туа: менә шундый юл белән эш итү кемгә генә һәм ни өчен кирәк? Аннан кемгә нинди файда бар? Безнеңчә, моннан беркемгә дә бернинди файда юк! Бу — безнең әдәбиятның да һәм әдәби тәнкыйтьнең үзенең дә абруен төшерү генә!

Шуңа күрә социаль һәм фәлсәфи планда зурдан фикер йөртә алучы тәнкыйтьче шәхесләре җитмәү — бүген безнең иң авырткан урын. Аны ничек хәл итәргә соң? Бүген без еш кына филологларның тормыштан аерылган булуыннан, ә журналист кадрларның эстетик анализда йомшак булуыннан зарланабыз. Менә хәзер югары уку йортларында реформа бара. Бәлки шул вакыттан файдаланып, әдәбият-сәнгать һәм гомумән культура мәсьәләләре буенча шөгыльләнә торган, югары әзерлекле журналист кадрлар булдыру турында уйларгадыр?

Ни өчен журналист кадрлар дибез?

Чөнки әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен тормыш белән бәйләп һәм аларны бергә, табигый бербөтен итеп карауда журналистикадан да кулайрак жанр юк. Башта үзебез сүз алып барган Добролюбов һәм Белинскийларны да алып карагыз! Алар иң беренче чиратта — журналистлар! Кыю, намуслы, югары әзерлекле һәм талантлы журналистлар алар. Шушы урында юлбашчыбыз В. И. Ленинның үзен ни өчен «литератор» дип язуын да искә төшерик. Тормыш мәсьәләләре хакында тулаем кайгыртып язу дип аңлый моны юлбашчы. Бирегә, бу очракта, журналист кадрлар нигезендә мәсьәләне үзебез көткән дәрәҗәдә хәл итәргә теләү дә реаль уңышка китерергә мөмкин.

Аннан соң, безнең филологлар нигездә язучы өченрәк, аңа төбәп язалар. Ә журналист ул бөтен иҗатын киң катлау публикага багышлый. Шуңа күрә бу яктан да журналистлардан чын әдәби тәнкыйтьче әзерләргә тырышу максатка ярашлы тоела.

Шул уңайдан әдәби тәнкыйть мәкаләләренең теле яңадан да уйландыра. Ни өчен соң безнең байтак тәнкыйтьчеләр яхшы мәгънәдәге публицистлыктан качарга тырышалар? Монда аларны нәрсә куркыта? Ни өчен әле безнең кайбер әдәби тәнкыйтьчеләр өчен пафос белән, дәртләнеп, чын-чыннан илһамланып язу оят эш сыман санала?

Соңгы елларда тормышыбызга шактый тирән үтеп кергән бюрократизм чиренең әдәбиятка тәэсире ахыры бу. Без — салкын, җансыз поза белән җитди булып күренергә, акыллы булып күренергә телибез, ахрысы. Шулай итеп без иң бөек халәтне — хәрәкәтнетик торуга, катканлыкка һәм еш кына очракта догмага да алыштырып куябыз. Менә бит ул тере диалектика бозылуның нинди начар яклары бар! Әдәбият кебек иң кайнар хисләр дөньясына да тәэсир иткәли икән ул...

## Тагын «кайбер» мәсьәләләр

Әйе, әдәбиятыбыздагы тәнкыйтьнең үсеше тагын кайбер мәсьәләләргә дә бәйле әле. Алары нинди соң?

Мондыйлардан беренчесе һәм иң масштаблысы — әдәбиятта югары сыйфат өчен көрәшнең бер үк вакытта «бөтен фронт буенча» алып барылырга тиешлеге. Ул көрәшнең һәркайда һәм һәркайчан барырга тиешлеге. Бу фикерне ничек, ни рәвешле аңларга соң?

Төшенүе җиңелрәк булсын өчен башта мисаллар китерик.

Менә республикабыз язучыларының чираттагы җыелышы бара. Каләмдәшләр үзләре алдында торган мөһим бурычларны ачыклыйлар. Чираттагы сүзне тәнкыйтьче ала да: бүгенге көндә әдәбиятыбызның иң йомшак тармагы — проза жанры,— ди, хәзер безгә аны тернәкләндерү турында нык итеп уйларга кирәк,— ди... Залда утыручылар бу тәнкыйтьченең чын күңелдән һәм әдәбият өчен ихлас борчылып сөйләвен тоялар, аның сүзенә ышаналар. Чөнки бу — чынлыктагы хәлне дөрес чагылдыручы сүзләр, объектив бәя. Аның хәлне төзәтергә чакыруы да бик урынлы, вакытлы.

Аннан соң сөйләүчеләр бу хәлне аңлап, шул юнәлештә нинидер чаралар тәкъдим итәргә тиеш иде бит инде. Чыннан да, шундый ихтыяҗ зур иде җыелышта... Әмма сүз алган икенче оратор алай итмәде. Ул, үзе прозаик кеше, залны гаҗәпләндереп, тәнкыйтьче сүзенә каршы төште, үзе эшләгән тармакны теттереп мактый башлады һәм бүгенге ситуацияне дөрес итеп аңлау, шуннан чыгып конкрет нәтиҗәләр ясау эшен шактый катлауландырды.

Күргәнебезчә, биредә ике кеше ике төрле максаттан чыгып эш итте. Беренчесе, әдәбиятны үстерү турында кайгыртса, икенчесе турыдан-туры шәхси мәнфәгатен уйлады, үз чыгышы белән хакыйкатьне капларга тырышты...

Янсә тагын менә мондый очрак.

Бер авторның язган әсәрләрен әдәби җәмәгатьчелек тә, укучы да һәм тәнкыйть тә һич кабул итми. Ә матбугат шуларны ни өчендер һаман бастыра тора. Чөнки теге автор үзе бик әрсез — ишектән кусаң, тәрәзәдән керә! Аңа каршы торырга матбугат әһелләренең әллә кыюлыгы җитми, әллә зәвыгы... Шулай итеп, теге автор бөтен әдәбиятны бутап, әрлебирле йөри бирә... Ә баксаң, әдәби тәнкыйть инде күптән аның әсәрләре хакында фикер әйткән: бу әдәбият түгел, дигән.

Менә без ике мисал китердек. Алар ни хакында сөйли соң?

Безнеңчә, биредә бер зур нәтиҗә чыга: без һәркайда һәм һәркайчан уртак эш мәнфәгатен беренче урынга куймасак, гадел һәм объектив фикергә колак салмасак, ә ниндидер бүтән мотивлар һәм сәбәпләр табып, шулар белән аклана-аклана эш итә башласак, әдәбиятыбызны да һәм аның белән бик нык бәйләнгән тәнкыйтьне дә үстерә алмабыз. Бу мәсьәләдә безнең бөтен иҗат союзыбызда ныклы бердәмлек булырга тиеш!

«Бер нәрсә бәхәссез,— дип күрсәтелде КПССның XXVII съездында иптәш М. С. Горбачев сөйләгән Политик докладта,— акыллы һәм гадел сүз зур йогынты көченә ия. Әмма ул политик, экономик һәм социаль адымнар белән бергә кушылса, аның әһәмияте йөзләрчә тапкыр арта!»

Үзебездә әдәби тәнкыйтьне үстерү проблемалары хакында уйланганда да без әнә шул бик актуаль һәм тирән мәгънәле хакыйкатьне истән чыгармасак иде. Әдәби тәнкыйтьне дә чакыру, өндәү юлы белән генә үстереп, тернәкләндереп булмый! Югарыда әйтеп кителгәнчә, ул да иген уңышы кебек: аңа бик күп төрле факторлар тәэсир итә. Әдәби тәнкыйть ул әнә шул күп төрле факторларның нәтиҗәсе, җимеше булып яши.

Шушыңа бик тә тыгыз килеп тоташа торган икенче мөһим проблема мондый: әдәби процесста бары тик талантлы әсәрләргә һәм талантлы авторларга гына юл тоту. Бу җитештерү сферасындагы сүз белән әйтсәк — «уравниловка»ны бетерү була. Мәсьәләнең мөһимлеген барыбыз да аңлый торгандыр. Яхшы эш белән начарны тигез куюның, аларны бер төрле бәяләүнең уртак эшне никадәр таркатуын, имгәтүен бөтенебез дә төшенә. Материаль җитештерү өлкәсендә бу аеруча күзгә ташлана торган нәрсә.

Ә бит зур әһәмияткә ия рухи кыйммәт тудыручыга карата да һәммә яктан күбрәк игътибар булырга тиеш: мораль яктан да, башка тарафтан да. Без кулыбыздагы бөтен чаралар ярдәмендә андыйларны якларга һәм аларга киң юл ачарга тиешбез. Чөнки алар хезмәте халкыбызга, җәмгыятебезгә иң кирәкле, иң күп файда китерә торган хезмәт!

Чынлыкта алай килеп чыгамы соң? Еш кына очракта безнең иң яхшы әсәрләребез урта кул әсәрләр белән янәшә йөрмиме соң? Һәм бу әдәби тәнкыйть гаебе белән генә шулай килеп чыкмый. Мәсьәлә бик конкрет куелган урыннарда да без тигезләү ысулы белән котылырга тырышабыз. Без ситуациядән шулай чыгу юлына өйрәнгәнбез. Чөнки — алай җиңелрәк һәм үзең өчен дә хәвефсезрәк!

Уртак эшкә һәм шулай ук халык өчен әле күп талантлы әсәрләр тудыра алачак авторның күңеленә гаять зур зыян бу. Без барыбыз да һәм, әлбәттә тәнкыйть тә, халык көткән рухи кыйммәт тудыручыларны күтәрергә һәм лаеклы бәяләргә тиешбез!

Инде килеп өченче момент.

Сугышта һәм армиядә булган ир-атлар бик яхшы белә: аеруча җаваплы, аеруча хәлиткеч минутларда кешенең үз-үзен ялгыз итеп тоймавы, янында булмаса да якында дуслары, иптәшләре, теләктәшләре барлыгын белеп, тоеп, сизеп торуы — аңа искиткеч зур көч бирә, аның күңелен, рухын күтәрә. Җаваплы эшләр башкарырга бик нык ярдәм итә... Ә киресенчә булса — кеше үзен ялгыз итеп тойса — бу хис аның күңелен иләсмиләс китерә, аны икеләндерә, шикләндерә, башында кирәкмәгән, эшкә ярдәм итмәгән уйлар тудыра. Нәтиҗәдә уртак эшкә зыян килергә мөмкин.

Хәзерге вакытта — әдәби тәнкыйть офыгында сәләтле яшь көчләр күренеп торганда, без аларны намуслы сүзнең, фикернең һәрчак хуплануына һәм җиңәчәгенә ышандырырга тиешбез. Үзебезнең һәр адымыбыз, һәр кылган гамәлебез белән аларда шуны расларга, шул ышанычны үстерергә тиешбез! Гадел сүзне, намуслы яшь омтылышны әнә шулай гына уңышлы рәвештә үстереп була. Юк, бу алар алдыннан бөтен каршылыкларны алып кую, юлны җиңеләйтү дигән сүз түгел. Тормышта да, әдәбиятта да намуслы һәм туры сүзле кешегә юл җиңеләймәячәк анысы. Бусы мөмкин түгел. Әле без әйткән нәрсә ул — яшьләрне алар сайлаган төп юлда ныгыту, дигән сүз. Гадел фикер әйтү кирәклеген раслау дигән сүз!

«Кайбер» проблемаларның тагын берсе — әдәби тәнкыйть фикерен гел җанлы, гел тере итеп тота торганы: матбугатта әдәбият һәм тормыш мәсьәләләре буенча фикерләр хәрәкәте, аларның каршылыклар аша үсә торган, бәхәсләр аша үсә торган хәрәкәте бару.

Без барыбыз да марксистик-ленинчыл философияне өйрәнгән кешеләр. Аның өйрәтүе буенча да, тормыш үзе раслап торганча да: үсеш нигезендә һәрвакыт каршылыклар бәрелеше, шулар хәрәкәте ята. Ә рухи дөнья, әдәбият һәм әдәби тәнкыйть өчен бу халәт бигрәк тә мөһим. Бүген бездә әдәби тәнкыйть йомшак булуның тагын бер зур сәбәбе әнә шул — бәхәсләр һәм фикер көрәше, хәрәкәте җитәрлек дәрәҗәдә булмау. Без, гадәттә, иң кызыклы әсәр хакында да бер генә фикер әйтү белән чикләнәбез. Безнең газета-журналлар бу хакта ни өчендер «сүз озайтырга» теләмиләр. Ә бит иҗтимагый әһәмияткә ия олы фикерләр кузгаткан әсәрләр хакында зурдан кубып, җитди итеп сөйләшергә кирәк. Мондый сөйләшү бит ул — төрле фикерләр кайнау дигән сүз. Димәк, шуның аша халкыбызның эстетик һәм иҗтимагый фикере, аңы үсә дигән сүз! Бу — культурабыз үсешенең тагын да югарырак баскычы әзерләнә дигән сүз!

## Халык көтә!

Бүген илебез тормышының һәр тармагында, һәр өлкәсендә зур үзгәрешләр бара. Җәмгыятебезне алга таба хәрәкәтләндерүче төп двигатель — халык массаларының көче, энергиясе, энтузиазмы — тулы куәтенә эшли башлады хәзер. Совет халкы — дөньяда беренче булып социалистик революция ясаган, кешелекнең бик тә куркыныч дошманы немец фашизмын җиңгән, сугыштан соң кыска гына вакыт эчендә үз илен яңадан матур итеп торгызган халык, бетмәс-төкәнмәс көчкә һәм энергиягә ия булган халык — бүген өр-яңа биеклек яулау өчен гаять тә киң масштаблы көрәш җәелдерде.

Бүгенге әдәбият та әнә шул көрәшнең эчендә, үзәгендә бара. Реаль тормыш һәм чынбарлык проблемалары бүгенге әдәби геройларның язмышын һәм гомер мәгънәсен билгели. Заманыбызның чын, җитди әдәбияты бүгенге кешенең күңел юлдашы булып бара.

Халкыбызның әдәби тәнкыйтькә булган ышанычы да әле какшамаган. Халкыбыз әдәби тәнкыйтьнең дә чын һәм җитди иҗатка әверелүен көтә. Чорның олы көрәшләре белән тыгыз тоташкан булуын көтә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре дә укучыны чын әдәби әсәр кебек рухландырсыннар, уйландырсыннар, тәрбияләсеннәр! Алар тыныч һәм битараф яшәү чагылышы булмасыннар!

Күргәнебезчә, бу әдәбиятның эчке мәсьәләләрен генә түгел, ә бөтен социаль һәм рухи яшәешне колачлый торган бурыч. Димәк, бүгенге тәнкыйтьчеләрнең үзләренең шәхесләре һәм иҗатлары, аларның бөтен яшәү һәм фикерләү рәвешләре әнә шул югарылыкта булырга тиеш!

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

## Мөхәммәт Мәһдиев:

1. Эчтәлекне тулы килеш саклау-сакламау турында бөтенләй дә сүз алып барырга ярамый. Эчтәлекне сакламагач, тәрҗемә буламыни ул? Милли колорит турында да шуны әйтергә кирәк. Метафораларны төгәл тапшыру кыен нәрсә, монда тәрҗемә ителгән әсәр күпмедер югалтуларга дучар була, бу — котылгысыз.

2. Анкетада санап кителгән сыйфатларның барысы берьюлы уңышны хәл итә. Әле тагын тәрҗемәче халыкның көнкүрешен (быт) яхшы белергә тиеш. «Фронтовиклар» романын тәрҗемә иткәндә мин тәрҗемәчегә салам эскерте, кибән, көлтә, көлтәдән куелган чүмәлә, кышкы юл буена кадалган чыршы-нарат ботаклары (маяк) турында рәсемнәрен ясый-ясый аңлаттым. Авыл тормышын тасвирлаган әсәрләребез, гадәттә, русча яңгырамый. Чөнки тәрҗемәчеләр татар авылын күргән кешеләр түгел, күбесе зур шәһәрдә туып, шунда югары белем алып, төпләнеп калган кешеләр. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы ни өчен рус телендә популяр булып китте? Монда Г. Әпсәләмовның талантына тәрҗемәче осталыгы килеп кушылган. «Ак чәчәкләр» — шәһәр романы. Тәрҗемәче дә — шәһәр тәрбиясе алган кеше. Шәһәрдә яши. «Ак чәчәкләр» романының эчке закончалыкларында, аерым детальләрдә аның өчен аңлашылмаган берни дә юк. Ул аны җырлый-җырлый, рәхәтләнеп, аңлап, геройлар кичерешен үзе дә кичереп тәрҗемә итә. Аның өчен берninди милли, көнкүреш барьерлары юк бу романда.

3. Прозада тәрҗемәче оригиналны бирел бетерә ала дип уйлыйм. Тәрҗемә итүдән бик күп югалта торган поэзия әсәрләре, әлбәттә, була. Халык җырларыбыз, мәкальләр — әдәби әсәрләр бит. Әйтемнәр, чагыштырулар, идиомаларның бик күбесен тәрҗемә итеп булмый. Мисаллар:

Җыр

Иртә тордым — иртә икән;
Әтәч кунган киртә икән.
Бу күп исәп, бу күп хәсрәт
Башны дивана итә икән.

Тәрҗемәсе:

Встал утром — оказывается, рано;
Петух сидит на плетне.
Большое горе, большие думы
Дурманят голову.

Әйтемнәр, мәкальләр

а) Сукыр тавык юлга чыкса — буран булыр;

Если слепая курица выйдет на дорогу — к метели.

б) Хәзер кибеттә йөзле кадакны им өчен таба алмыйсың;

Теперь в магазинах гвоздей-соток для лекарства не найдешь.

Күргәнебезчә, мондый әсәрләрне тәрҗемәдә үз куәте белән саклап булмый. Югалтулар — котылгысыз.

4. Оригиналдан тәрҗемә итү әйбәтрәк инде. Разия Фәизова әнә шулай эшли иде. Мәҗит Рафиковның да отышлы ягы шунда иде дип уйлыйм.

5. Подстрочниклар белән мин бик күп нужа күрдем. Минем әсәрләремә «подстрочный» тәрҗемә ясауда бик күп кеше катнашты. Арадан берсе «мунча сыерчыгы»н үзенчә аңлап «банный скворец» дип тәрҗемә иткән иде. Подстрочник ясаучы бик тирән мәгълүматлы булырга тиеш. Берсе, мәсәлән, бик зур хезмәт куйды: чыршы үләне, билчән, буаз сарык, кысыр калган сыер, кырлык үләне исе, ат бәкәле һ. б. сүзләрнең русчасын озак эзләп, сүзлекләрдә казынып кына таба алды. «Каз канатлары» романының тәрҗемә процессында исә көтелмәгән нәтиҗә килеп чыкты. Мин аны бүлеп-бүлеп, берниnди тәҗрибәсе булмаган яшьләрдән эшләткән идем. Карыйм — подстрочник мине канәгатьләндерми. Шуннан яңабаштан үзем эшләп, оригиналга мөмкин кадәр якын китереп шомарттым, мөмкин кадәр әдәбиләштерергә тырыштым. Мондый ярым әзер подстрочникка тәрҗемәче бик шатланган: ара-тирә генә стилистик яктан төзәткәләгән дә, тәрҗемә иттем дип, китереп тә тапшырган. Кабат эшләтеп, яңадан тикшереп, нәшрият иза чикте. Шулай итеп, подстрочникның начары да начар, үтә яхшысы да начар булып чыкты. Әмма, рус нәшриятларында чират көтеп ята торган бер-ике әсәремнең подстрочнигы турында миндә нәшрият рецензентларының матур бәясе бар: «Должен отметить исключительно добросовестное отношение подстрочного переводчика к тексту...» «Нельзя не отметить высокое мастерство подстрочного переводчика»... Бу сүзләр моннан күп еллар элек Р. Сабиров эшләгән тәрҗемәләр турында.

6. Бу сорау белән кызыксынганым юк.

7. Анкетада санап чыгылган авторларның русчага тәрҗемәсе турында мин бик начар фикердә. Юк, берәүне дә яңгырата алмадык әле русчада. Осталык җитмәүдә түгел, тәрҗемәгә «эш» итеп карауда. Авторның эчке дөньясына кермичә генә тәрҗемә итәләр. Тукай тәрҗемәләре арасын-

да мин А. Ахматова һәм Павел Радимов тәрҗемәләрен генә уңышлы тәрҗемә дип саныйм. Болай дип сөйлиләр: Тукайның «Малая серия»дә җыентыгы әзерләнгәндә нәшрияттан Анна Ахматовага чылтыратканнар: «Берничә шигырен русчага тәрҗемә итә алмассызмы?» дигәннәр. А. Ахматова бу вакытта авыру икән, болай җавап биргән:

— В эти дни я плоха (ул бер вакытта да «авырыйм» дип әйтмәгән, «плоха» дип кенә әйтә торган булган — М. М.), однако для своего поэта постараюсь.

Ул Тукайны яратып, аңлап тәрҗемә иткән. 1922 елда Тукайның беренче русча җыентыгы Казанда басылып чыга. Юка гына китап. Начар кәгазьдә, ямьсез тышлыкта. Әмма тәрҗемәсе — сокланырлык. Барысы да Павел Радимовныкы.

8. Безнең шагыйрьләр русча яңгырамыйлар. Авторлар үзләрен-үзләре ышандырып, алданып йөрмәсеннәр, яңгырамыйлар.

9. Проза әсәрләренә килгәндә берсе турында да югары фикердә түгел. Шулай да Н. Дәүли прозасын, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәрен, Н. Фәттахның «Этил суын» әйбәт тәрҗемәгә кертер идем.

11. Тәрҗемә эшен оештыру — Татарстан Язучылар союзы идарәсе инициативасы белән булырга тиеш. Югыйсә, әсәреңне тәрҗемә иттерү өчен син, язучы, башкала урамнарында, кулуарларда кеше эзләп йөрергә тиешсең. Язучы — язарга гына тиеш. Кемнең маңгае нык — шул кеше күбрәк ишек ачып, башкала нәшриятларының идәнен таптап, әрсезләнеп йөри дә, тәрҗемә иттерә. Кемгә кем әләгә! Ә автор инициативасыз булса? Таланты бар, әмма маңгае каты булмаса? Тәрҗемә эшен оештырырга кирәк, үз агымына, аерым авторларның «пробивной» сәләтенә кайтарып калдырасы түгел. Ахыр исәптә, бу сөйләшүнең төп мәгънәсе әнә шул мәсьәләгә кайтып кала.

## Гөлнар Сафарова:

Бездә генә түгел, гомумән, тәрҗемә фәнендә әлегәчә өйрәнелмәгән, бөтенләй диярлек яктыртылмаган кайбер проблемалар бар. Аларның берсе — шәхси атамаларны — исем, фамилияләрне, кушаматларны икенче телдә ничек бирү мәсьәләсе. Бу турыда күптән яшәп килгән методика бар: алар үзгәртелмичә бирелергә тиеш: Иванов — Иванов дип, Петров Петров дип. Бу — гомуми кагыйдә. Тәрҗемәчеләр шулай эшлиләр дә.

Ләкин...

Бөтен дөнья әдәбиятында гасырлар буенча бер алым кулланылып килә: автор үзенең кайбер әсәрләрендә махсус әдәби максатта, әйтик, борычлы киная, ачы көлү, мәсхәрәләү, шаярту, сүз уйнату оста укмаштырылган каламбур, юмор, сатира сыйфатында нинди дә булса бер исем, кушамат яки үзе иң кирәкле дип хисаплаган фамилия куллана. Мәсәлән, Чеховның «Лошадиная фамилия» хикәясе бөтенләй шул нигездә корылган. Ат фамилияле кешене табу ярышында катнашучылар Лошадкин, Кобылин, Меринов, Рысаков һ. б. фамилияләрне китерәләр. Әмма бөтен хикәянең әкәмәтен, интригасын чишүче Овсов берәүнең дә башына килми. Әсәрнең татарчага тәрҗемәсендә бу фамилияләр үзгәрешсез, русча бирелгән. Нәтиҗәдә мәгънәсез, бөтенләй кирәкмәгән тәрҗемә килеп чыккан, аны русчаны бик яхшы белүчеләр генә аңларга мөмкин, ә татар укучысы әсәрнең хикмәтен аңласын өчен, бу фамилияләрне татар телендә дә ат тирәсендә уйнатырга кирәк иде. Мәсәлән, Айгырбеков, Юртаков, Атбаев, Алашауллин, Солыбаев шикеллерәк итеп.

Чеховның кайбер хикәяләрен бик әйбәт тәрҗемә иткән С. Ибраһимова да бу хатадан котыла алмаган: «Малайлар» хикәясендә өстәл артында утыручы кунак, гимназистның фамилиясе — Чечевицын. Ни өчен ул Чечевицын? Чөнки Чеховка бу фамилия бик кирәк булачак. Хикәядә бер гимназистка фамилиясеннән алып, иптәшен төрткәләп шаярта, үчекли башлый, юри чыгырыннан чыгармакчы була:

«— Ә кичә бездә ясмык боткасы пешерделәр.

— Уразада ясмык ашау файдалы».

Күренә ки, гимназистның фамилиясе дә югарыдагы текстка яраклаштырып, Чечевицын дип түгел, Ясмыков дип бирелергә тиеш. Ә биредә әдәби элементларда логик бәйләнеш югалган.

Менә минем кулда 1962 елның ахырында Татарстан китап нәшрияты русча чыгарган Тукайның проза әсәрләре. Аны тәрҗемә итүдә ун кеше катнашкан. Тәрҗемәләрдәге искитәрлек, шаккатырлык шаркылдап көләрлек, офтанып, ачуланып еларлык урыннарына тукталып тормастан, шәхси атамалар турында әйтми үтеп булмый.

Тукай күп кенә публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләрендә, аерым памфлетларында ачы сатирик алым, иң кирәкле чара максатында, икейөзле кабахәтләр өстеннән көлү өчен, аларның чын йөзен фаш итү өчен, конкрет шәхесләрнең исем-фамилияләрен, фонетик яктан аз гына үзгәртеп, оста сүз уйната, чәнечкеле каламбурлар төзи: Сапсата Сатаров, Ахмак Шәрик, Ахмакҗан Чәйдәшев (Чәйнәшев) Кишери, Аптрар Аптрарович, Бытбылдыкитдин һ. б. һ. б.

Русча тәрҗемәдә бу атамалар шул килеш бирелгән. Ләкин бу исем, фамилия,

кушаматлар рус укучысына нәрсә аңлата соң? Бернәрсә дә!

Бер уңайдан сөйләшүдә, тәрҗемәләрдә әсәр исемнәренең дә дөрес бирелү мәсьәләсенә кагылырга кирәк дип уйлыйм. Бу эштә дә бездә башбаштаклыклар күренә. Мәсәлән, В. Нуруллинның әсәре ни өчен «С ношей гору не обходят» дип тәрҗемә ителгән? Мондый исем әсәрнең идеясен дә ачмый, ә русларда тискәре ассоциация тудыра: «Наоборот, с ношей горы, подъемы следует обходить» — чөнки, йөк күтәреп, тауга менү логикага ябышмый. Л. Н. Толстойның «Воскресение», «Война и мир» әсәрләрен дә «Яңадан туу», «Сугыш һәм тынычлык» (элек «Сугыш һәм солых») дип тәрҗемәләү дә дөрес түгел. «Терелү», «Сугыш һәм халык» (яки «Сугыш һәм гавәм») булырга тиеш, чөнки эпопеяда сүз рус халкының сугышка карашы, илбасарларга каршы көрәштә катнашуы, күтәрелеп чыгуы, патриотизмы турында бара. Элекке иске славян орфографиясендә «мир» ике төрле язылган: міръ — халык, дөнья һәм миръ — тынычлык. Романның беренче басмасында да «Война и міръ».

Әдәби әсәргә автор бик күп уйлаганнан соң гына исем куша. Шуның өчен әсәр исеме игътибар белән тәрҗемә ителергә тиеш.

## Н. Нәбиуллина:

Бу рубрикада басылган язмаларны бик кызыксынып укып барам, андый сөйләшүләр бик кирәк. Редакция бу проблеманы вакытында күтәрә.

Ләбиб Леронов: «Моңны ачар ачкыч бармы?» — дип сорау биргән. Әзли башладым. Моңга тәңгәл сүзне русчада тапмадым. «Моң» итеп рус телендә калдырырга кирәк дип уйладым. Әнә бит рус телендә безнең (татарларның) «товарищ» сүзе дә ничек матур яңгырый. Моңны да шулай калдырырга кирәк дип таптым. Рус телендә ничек яңгырар соң ул сүз: «мон», «монг» (моргка охшап китә). Юк, калдырып булмый икән. Саф татар сүзе икән, үзебездә генә кала торган сүз икән. Шулай булгач — шигырьләрне, прозаны русчага бик шәп тәрҗемә итсәң дә, моңын югалта икән. Мин шуны һәркем белеп, бөтен нерв күзәнәкләре белән аңларга тиеш. Ана телен белмәү горурлык түгел. Ана телен өйрәнергә кирәк, һәр татарга татарча укырга кирәк.

Хәзерге яшьләрнең кайберләре бөтенләй диярлек укый белмиләр. Татарчадан русчага тәрҗемә ителгән китапларны укыйлар да, татарча укыган кебек булалар. Бу бик сай, өстән генә алган белем, моңсыз калган белем. Руслардан күбрәге бу китапларны алмыйлар да. Бу хәлне үзем күргәнем бар, бер генә мәртәбә түгел.

Л. Леронов кебек, Расул Гамзатовны миңа да рус шагыйрьләре якын итте, ә тәрҗемәчеләре генә димәс идем. Аларның эшләре миңа күренмичә узып китәр иде, әгәр телевидение кызыксыну уятмаса. Башта авар икәнен аңламадым, милләте кем икән дип кызыксындым. Безнең татарлардан түгел микән дидем. Исеме безнеңчә, матур, язган сүзләре дә йөрәккә сеңә. Анналарны радиодан ишеттем, тагы да кызыксыну уянды. Китабын эзли башладым, китабыннан алда пластинкасын таптым. Анналары гына китабы минем кульма килеп керде. Шуны әйтәсем килә, хәзерге заманда — шулхәтле күп информация, күп китаплар чорында—алар арасында кайсысына тукталырга белмисең. Нихәтле генә русчага тәрҗемә итмәсеннәр, әгәр телевидениедән Мәскәү тапшыруын күрмәсәк, Мәскәү радиосыннан ишетмәсәк, популярлык шагыйрьләргә, язучыларга, җырчыларга тиз генә килми. Мәскәү теле-радио тапшыруына керергә кирәк. Казан телевидениесе безгә килеп җитми.

Мин Шәүкәт Галиевне русчага тәрҗемә итәләр. Ә аны кешеләр беләме соң? Русчасы Әгерҗе кибетендә өелеп ята, ә минә Устиновта ул юк, «заграница» ул Шәүкәт Галиевка. Бездә аны белмиләр. Ә менә Мәскәүдән «Ш. Галиев Андерсен исемендәге премиягә лаек булды» дип күрсәтсәләр, радиодан сөйләсәләр, пластинкасы да чыкса, Гамзатов кебек популяр шагыйрь булыр иде ул. Әмма бу эшләнми.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар.

Мине русчага тәрҗемә итәләр дип мактанасы юк, мине атам-бабам телендә татарча укыйлар, тыңлыйлар дип горурланасы. Ә моның өчен ни кирәк? Яшьләрне татарча укырга өйрәтергә кирәк. Бу бер дә кыен түгел. Мин бүген телевидениедән «Софья Ковалевская» дигән фильм карыйбыз. Аны Стокгольмга эшкә чакыралар, лекцияләрне немец телендә сөйләрсең диләр. Швед телен өйрәнерсең дә, ике атнадан швед телендә сөйләрсең диләр. Һәм шулай була да — чит ил телен бик тиз өйрәнеп, шул телдә лекцияләр укый. Ә без үз туган телебездә укый белмибез.

Бездә, татарларда бер ялгышлык яши — кайберәүләр үзебезнең телдә укымый. Укыйсы килә килүен, аңламый торган сүзләр күп очрый, сүзлек юк, вакыт та юк диген булалар. Миндидер бер ялкаулык, уйлыйсы килмәү, җиңел тормыш эзләү тәннәребезне, башыбызны ялап алган. Мин шуны җимерергә кирәк — бу булыр моңның беренче ачкычы.

Тәрҗемә турында тирәнтен сүз алып бара алмыйм, бер китапның исеменә генә кагылыйм.

«Әтил суы ака торур» — «Итиль-река течет» (Нурихан Фәттах). Моңы беткән бит русча иткәч. Татарча әйткәндә әллә нинди сихри хисләр йөрәктә уяна, дулкынландыра, саф һава исләре килеп китә. Әтил суының ярлары, анда үскән агачлары, яшәгән кешеләре күренеп китә. Үзең дә көймәгә утырып шул судан гасырдан-гасырга йөзеп барасың сыман... Элек-электән Әтил суы аккан, ага һәм мәңге агачак ул! Ә русча әйткәндә «течет», ну и что, что течет, вода из крана течет, из дырявого ведра вода течет, непонятная река Итиль течет — пусть себе течет»,— кебек тоела.

Журнал битләрендә татарчадан русчага тәрҗемә итү турында гына сүз бара. Болай берьяклы гына сөйләшү дөрес булмас дип уйлыйм. «Взаимное обогащение языков» булырга тиеш дип уйлыйм. Шул чакта гына без алга китәрбез. Безнең гаиләләр дә бәхетлерәк булыр иде, аерылышу һәм бәхетсез балалар саны кимер иде.

Күп кенә яшьләр гаилә коралар да, татарча укымагач, татарча сөйләшә белмиләр, рус сүзләрен яртысыннан артыгын кушып сөйләшәләр. Шулай да татарча беләбез дигән булалар... Менә бер егет армиядан кайтты, татар кызын алды. Кыз гаиләсендә татарча сөйләшәләр, ә бу егет татарча белми, әнисе улы белән татарча сөйләшмәгән. Кызганып:

— Ты, Радик, так и не научился говорить на родном языке,— дидем моңа бервакыт.

— А я все понимаю. Я, как собака, все понимаю, а сказать не могу,— ди.

Рәхәтләнеп, татарчасын да, русчасын да белсә, сөйләшсә, балаларына «Шүрәле»не, «Су анасы»н укыса, бәхет үзе килер иде гаиләгә. Кыен бит шулай эт сыйфатында яшәргә. Сөйләшүне башлаган Л. Леронов үзенең шигырь-пародияләрен язсын иде менә шундый кешеләр турында. Матур-матур егетләр, кызлар ишетсеннәр иде, татарча сөйләшә башласыннар иде — аңлыйлар бит әле алар ана телен. Сөйләшә башлагач, укып та җибәрерләр иде, ярдәмлекләр, сүзлекләр булса.

Кыскасы шул: Тукай русча Тукай түгел, Пушкин татарча Пушкин түгел! Шулай булгач татарчаны да, русчаны да без белергә тиеш. Берьяклы гына сүз барырга тиеш түгел. Моңны ачар ачкыч — безнең илебездә яши торган бөтен телләрне белү, өйрәнү.

*Устинов шәһәре*

## Касыйм Хәмзин:

Шагыйрь Сибгат Хәкимнең «Фазыл чишмәсе» — халыкка кергән иң популяр җырларның берсе. Хикмәт телендә, халыкчан рухында. Чишмәнең үзе кебек челтерәп ага. Рус телендә аның берничә тәрҗемәсе бар. Шуларның бер вариантын билгеле тәрҗемәче Вил Ганиев эшләгән. Кайбер юлларын чагыштырып карыйк. Менә оригиналы:

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем;
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.

Менә рус теленә тәрҗемәсе:

Под горою, под крутою,
Серебрясь бежит родник.
Я спускаюсь за водою —
Возвращусь в единый миг.

Болай фикере дә дөрес шикелле. Мәгънәсен бозмаган. Ләкин оригиналдагы җылылык югалган, мамыгы беткән. «Суга дип килгән, кайтырмын дигән» сүзләр бу җырны күңелгә якын җыр иткән. Чишмәнең борылмалары булган кебек, җырның да борылмалары бар...

Менә икенче куплет:

Өздереп нигә карадың,
Ник тоттың чиләгемнән?
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән.

Менә рус телендә ничек яңгырый ул юллар:

Заглянул Фазыл в глаза мне,
Душу взгляд прожег насквозь!
Не вода лилась на камни,—
Пламя сердца полилось!

Монда да шул ук хәл. Тәрҗемә оригиналга якын. Тәрҗемәдә иң куркыныч нәрсә — якынчалык, русча әйтсәк приблизительность! Бер караганда бик кечкенә деталь: «ник тоттың чиләгемнән?» Авыл егетләре, чыннан да, чиләктән тота. Бу Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ында да шулай. Чишмә буенда Галиябану белән Исмәгыйлнең очрашуын исегезгә төшерегез. Шигъри, халыкчан деталь. Шигырь, җыр шул детальләрдән тора. Шулар коелса — су гына кала... Тукай шигырьләренең рухына керә алмауның да сере бәлки шундадыр: Тукай көй, моңнан тора. Моң тирәндә ята. Тәрҗемәче аңа төшеп җитә алмый... Билгеле, мин бөтен тәрҗемәләр дә начар дигән караштa тормыйм. Шулай да татар поэзиясенең иң яхшы шагыйрьләрен әле без зур дөньяга чыгара алмадык.

*Ленинград*

библиография

# ТЕАТРЛАР ДУСЛЫГЫ

Татар халкының күпкырлы таланты илебездәге халыкларның рухи кыйммәтләрен үзенә сеңдергән үзенчәлекле милли культура тудырды. Сәнгать белгече И. Илялова «Татар театрының милләтара элемтәләре» дигән китабын менә шушы милли культура казанышы булып саналучы театрның формалашуына һәм үсүенә, интернациональ асылына һәм башка халыкларның театр сәнгате белән интернациональ мөнәсәбәтләренә багышлаган. Әлеге монографик хезмәт зур фактик материал җирлегендә милли театрның үткән юлын, социалистик культура үсешенең гомуми процессына кушылуын күрсәтү максатын куйган теоретик эзләнүләр исәбенә керә. Илебез халыклары театр сәнгатенең бер-берсен баетышу «механизмын» өйрәнү исә социалистик культура үсешенең тирәндә яткан закончалыкларын, сәнгатьтә интернациональ һәм милли башлангычлар диалектикасын ача. Татар театры, китапта күрсәтелгәнчә, бу процесста тулы хокуклы һәм эшлекле катнашучы булды. Әлеге хезмәттә милләтара элемтәләр сәнгатьне интернациональләштерүнең зарур һәм закончалыклы элементы, интернациональ эчтәлегенең чагылыш формасы итеп күрсәтелә. Алдынгы социаль һәм эстетик идеалларны сеңдереп, «алучы» ролендә дә, күпмилләтле совет театрының барлыкка килүенә һәм үсүенә ярдәм итеп, «бирүче» ролендә дә чыгыш ясаган татар театрының милләтара элемтәләре күпьяклы һәм төрле юнәлештә булуы ачыла.

Шуның белән бергә, китапта культураның, шул исәптән театр культурасының үсешен үзара бәйләнеш һәм иҗади хезмәттәшлек тенденцияләре белән генә аңлатырга мөмкин түгел икәнлеге дәлилле итеп раслана. Театр, сәнгатьнең башка төрләре кебек үк, халыкның тормышын, тарихи язмышын чагылдыра. Үзара бәйләнеш тенденцияләре үсеше нәкъ менә шушы объектив нигездә күзәтелә. Тарихка мөрәҗәгать итеп, И. Илялова башка халыклар театрын баетучы бәйләнешләр системасында татар театр сәнгатенең үзенә аерым миссиясе булуын күрсәтә. Бу Татарстанның географик урынына, ягъни аның Европа белән Азия очрашкан төбәктә урнашкан булуына, профессиональ татар театрының алданрак тууына бәйле.

Татар театрының формалашуы шома гына бармый. Аның юлына мөселман руханилары, мөлкәтле сыйныфның реакцион вәкилләре, карагруһчылар каршы төшә. Карагруһчыларның беренче татар актрисасы С. Гыйззәтуллина-Волжскаяга һөҗүме татар милли театрының каты сыйнфый көрәш процессында тууы хакында сөйли. Ләкин халыкның сыйнфый аңы, демократик омтылышлары хаклык һәм азатлык сөрәнчесе булган театр сәнгатендә үзен һаман көчлерәк сиздерә.

Татар театрының тууын Мулланур Вахитов, Габдулла Тукай сәламләп каршылыйлар. Милли театрның идея һәм художество юнәлешен билгеләүдә Вахитов һәм Тукайның, татар мәгърифәтчеләренең, беренче татар драматургларының өлеше зур. Театр сөючеләр өчен кызыклы булган бай фактик материалда, бөтен революцион-демократик культура кебек үк, татар милли театрының да халыкның милли үзаңын уятырга омтылуы, аның әхлакый һәм гомумкультура үсешенә хезмәт итүе исбатлана. Шушы юлдан ул, дөнья театры, бигрәк тә рус театр сәнгате казанышларын иҗади үзләштереп, туктаусыз алга барды.

Рус театр мәктәбе татар сәхнә сәнгате эшлеклеләре өчен осталыкка, тормышны реалистик гәүдәләндерүгә өйрәнүдә бәһасез мәктәп, идеялелек һәм халыкчанлык мәктәбе булды. Революциягә кадәр рус һәм татар театрлары арасындагы бәйләнешләрнең төп формасы рус режиссерлары һәм актерларының татар театры эшлеклеләре белән шәхси элемтәләре рәвешендә күзаллана. Китапта бу элемтәләр архив документлары, истәлекләр аша күздән кичерелә.

Рус театрының тәҗрибәсен үзләштерү белән бергә, татар театры Идел буендагы, Урта Азиядәге төрки халыклар сәнгате белән иҗади элемтәгә керә. Төрки телле халыклар яшәгән якларда Европа тибындагы театр барлыкка килү әлеге халыклар культурасында милләтара бәйләнешләрнең ачык гәүдәләнеше булды.

Китапның күп кенә битләре үзара тәэсир итешүнең конкрет юлларын өйрәнүгә багышланган. Бу — үзбәк драматургиясен башлап

[1] Илялова И. Межнациональные связи татарского театра. Казань, Татарское книжное издательство, 1985.

җибәрүче Х. Ниязиның татар мәгърифәтчеләре белән аралашуы да, үзбәк театр эшлекләренең Г. Камал драматургиясе белән танышуы да, татар актерларының үзбәк һәм казах театр труппаларында чыгыш ясаулары да. Башка милли театрларда эшләүче татар артистларына да китапта тәэсирләндергеч юллар багышланган.

Сәнгатебезнең иң демократик төрләреннән берсе булып туган совет театры, дөньяны социалистик үзгәртеп кору идеяләрен кабул итеп, массаларга актив йогынты ясау, аларның революцион аңын формалаштыру чарасына әверелә. Әлеге күренеш китапта эзлекле яктыртыла. Совет властеның беренче елларында, гражданнар сугышы чорында театрның агитация-пропаганда роленә багышланган бүлекләр милли театрның һәм халыкның азатлык өчен, социализм җиңүе өчен көрәшенең аерылгысыз бердәмлеге идеясе белән сугарылган. Сәхнә сәнгате тарихында элек билгеле булмаган фронт театры совет сәнгатенең феномены буларак кабул ителә. Ул Кызыл Армия белән бергә героик юллар үтә. Бу юлларда күп кенә фронт театрларында уйнаган татар артистлары дан казана.

Октябрьдән соңгы чорда совет культурасының интернациональ асылы һаман ачыграк чагылу татар театры үсешендә, аның башка халык театрлары белән элемтәләре ныгуда төп тенденция була. Милли театрлар рус совет драматургиясе әсәрләренә мөрәҗәгать итәләр. Сәхнәгә революцион героика, иҗади хезмәт темасы килә. Станиславский системасының киң җәелүе белән реалистик сәнгать тагын да баеый.

Сугышка кадәрге татар театрының милләтара элемтәләре спецификасын И. Илялова социаль мотивларның тирәнәюендә, дөньяга караш позицияләренең ачыграк булуында күрә. Бөек Ватан сугышын совет театры социалистик реализм методы белән коралланган хәлдә, идея-политик бердәмлек, оешу ягыннан җитлеккәнлек чорында каршылады. Кырыс сынау көннәрендә ул, бөтен совет сәнгате кебек үк, «халык күңеленең героик авазы» (А. Толстой) булып әверелде. Сугыш елларында актерлык һәм режиссерлык осталыгында, бигрәк тә репертуар формалаштыруда милли сәхнә культураларының типологик охшашлыгы тагын да ачыграк күренә. Татар театры, илебезнең барлык театрлары кебек үк, совет халкы батырлыгының бөтен тирәнлегенә төшенергә омтыла. Әмма театрның сугыш елларындагы эшчәнлегенә китапта бик аз урын бирелүен әйтмичә булмый (бу чорга нибары 6 бит кенә багышланган). Безнең уебызча, хезмәтне алга таба үстергәндә бу бүлекне киңәйтә төшү яхшы булыр иде, чөнки бу чорда илебезнең эчкәрге районнарына эвакуацияләнгән театр коллективларының һәм башка сәнгать эшлеклеләренең тыгыз иҗади контактлары нәтиҗәсендә милләтара бәйләнешләрнең спецификасы тагын да ачыграк күзаллана.

Сугыштан соңгы һәм хәзерге чорга мөрәҗәгать иткәндә, И. Илялова татар театрының милләтара бәйләнешләрендәге гомуми һәм үзенчәлекле якларга игътибарын туплый. Милләтара элемтәләр чагылышының хәзерге этабында гомуми һәм үзенчәлекле якларны тикшерү предметы итеп аерып карау шуның белән аклана: бердәм социалистик, гомумхалык культурасы формалашу процессында аларның диалектикасы интернациональ һәм милли яклар диалектикасының бер формасы буларак чагылыш таба. Театр сәнгатенең формалашу һәм үсүе процессында үзара бәйләнешләр формасы да үзгәрә. Башлангыч этапта алар шәхси контактлар дәрәҗәсендә һәм очраклырак булган булса, совет театры туганнан соң рухи культура өлкәсендәге милләтара бәйләнешләр планлы, аңлы характер ала. Сугыштан соңгы елларда һәм бигрәк тә хәзер милләтара элемтәләр үзара тәэсир итешү, берсен-берсе баетышу ягыннан тагын да камилләшә бара. Китапта татар театрының хәзерге шартлардагы эшчәнлеге, совет сәхнә сәнгате системасындагы урыны әнә шул күзлектән карала да.

Күпмилләтле совет театрының идея-политик бердәмлеген күрсәтеп, автор иң элек төрле театр коллективлары куйган спектакльләрнең тематика уртаклыгына игътибар итә. Мондый уртаклык беренче чиратта кеше турында, яңа социалистик чынбарлык тудырган характерлар турында, яшәү мәгънәсе турында тирәнтен, кызыксынып сөйли торган әсәрләрдә күренә. Тормыш үзе җәмгыятебезнең алга таба хәрәкәт итүендә кеше факторы проблемасын төп, хәлиткеч проблема итеп куйды. һәм бу партиянең соңгы вакыттагы күп кенә документларында ачык күренә. Табигый ки, тормыш логикасына ияреп, күп кенә очракларда аннан алгарак та китеп, сәнгать кешене төрле чаҺылышларда, тормыш ситуацияләрендә өйрәнә. Татар театры, китапта күрсәтелгәнчә, вакытында һәм тәэсирле итеп, төрле художество чараларын (трагедия дә, мелодрама да, комедия дә) кулланып, Кеше турында зур сөйләшү алып бара. Татар театры сәхнәсендәге Кеше социаль хәле ягыннан да, яше, идеаллары ягыннан да төрле. Кеше характерлары һәм гамәлләр төрлелегендә татар театрының гомуми һәм даими кредосы — чорыбыз героеның югары рухлылык һәм социаль активлык идеалын раславы ачык күренә. Театр эшчәнлегенең гомумкешелек, интернациональ мәгънәсе, гражданлык җитлеккәнлеге дә шушы идеалда чагыла. Театр спектакльләре белән төрле милләт тамашачыларының кызыксынуы юкка гына түгел. Мәскәүдә һәм илнең башка шәһәрләрендә үткәрелгән гастрольләр, үзәк телевидение аша чыгыш ясау, татар драматурглары пьесаларының рус һәм башка милләт сәхнәләрендә куелуы интернациональлек колачының киңәюе турында сөйли. Үз чиратында татар театры да совет драматургиясенең үз рухына җавап бирүче, бүгенге актуаль проблемаларны үзәккә алучы әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Театр сәхнәсендә бүгенге производство һәм төзелеш проблемалары (И. Дворецкий, «Чит кеше»), (Д. Вәлиев, «Тормыш бүләк итәм»), колхоз авылының катлаулы мәсьәләләре (А. Абдуллин, «Уночынче председатель»), кешенең мәңгелек яну пафосы (М. Кәрим, «Ташлама утны, Прометей») калку гәүдәләнеш тапты. Театрның лениниана багышланган эшләре (Н. Погодин, «Мылтыклы кеше» һәм «Кремль курантлары»), Бөек Ватан сугышы турындагы спектакльләре (Б. Горбатов, «Бер төн»; Л. Леонов, «Ябырылу»; Т. Миңнуллин, «Моңлы бер җыр») үсеш юлындагы әһәмиятле адымнар булды.

Л. Леоновның «Ябырылу» пьесасы буенча Мәскәү гастроле вакытында күрсәтелгән спектакльгә (режиссеры М. Сәлимҗанов) матбугат та, әсәр авторы да уңай бәя бирделәр. Спектакльнең концепциясе китапта җентекләп анализлана, пьеса образларының традицион юл белән хәл ителмәве, режиссер һәм актерларның, бигрәк тә Ш. Биктимеров белән Р. Шәрәфиевнең үзенчәлекле иҗади эше билгеләп үтелә. Пьесаның хәзерге куелышын сугыш вакытындагы спектакль белән чагыштырып карау театрның идея-художество дәрәҗәсе үсү турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Кызганычка каршы, театр үсешендә аерым этап булган «Моңлы бер җыр» спектакленә китапта җентекле характеристика бирелмәгән. М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлык чыганаклары турындагы спектакльгә шулай аз игътибар бирелү үкенечле, чөнки автор үзе үк, сугыш темасы өстендә «татар драматурглары аз эшләде», дигән фикер әйтә.

Татар театрының милләтара элемтәләрен өйрәнгәндә, И. Илялова нәтиҗәле алым кулланa — бер үк әсәрләрне сәхнәгә куйган төрле театрларның спектакльләренә чагыштырмалы характеристика бирә. Мәсәлән, И. Дворецкийның «Чит кеше» пьесасы буенча Мәскәү (Малая Бронная урамындагы) һәм Казан (академия) театрларында, Ч. Айтматовның «Анам кыры» повесте буенча Мәскәүнең К. Станиславский исемендәге рус театрында, Казахстан театрында (Алма-Ата) һәм Әлмәт театрында куелган спектакльләр чагыштырып карала. Татар драматургларының пьесалары буенча төрле театр сәхнәләрендә, аерым алганда, Казандагы В. Качалов исемендәге рус театрында, Мәскәү, Ташкент, Алма-Ата, Караганда, Харьков, Воронеж, Краснодар, Чабаксар һәм башка шәһәрләр театрларында куелган спектакльләр дә җентекләп анализлана. Художество кыйммәтләрен шулай киң алмашу татар театрының милләтара элемтәләре һаман интенсивлаша бару һәм аларның сыйфаты да үзгәрү турында сөйли. Рус классик драматургиясе пьесаларының хәзерге этапта татар сәхнәсендә куелышларын җентекләп күздән кичерү дә шул юнәлештә бара. Театр А. Островский һәм М. Горький әсәрләренә дә әйләнеп кайта. Ләкин бу кайту, китапта күрсәтелгәнчә, диалектик үсеш эчендә карала. Татар театрының сугыштан соңгы буыны турында сөйләшү, бер яктан, рус совет театры казанышлары белән органик бәйләнеш җирлегендә аларның иҗади осталык чыганакларын ачарга, икенче яктан, театр сәнгатенең иҗат лабораториясенә үтеп керергә мөмкинлек бирә. Автор китапның бу өлешендә читтән күзәтүче булып түгел, театраль процессның тулы хокуклы катнашучысы һәм шаһиты буларак чыгыш ясый. Театр тәнкыйтьчесе буларак, И. Илялованың эшчәнлеге татар сәхнә сәнгате белән аерылгысыз бәйләнгән. Бу аңа спектакльләрнең кабатланмас атмосферасын ышандырырлык итеп күз алдына бастырырга мөмкинлек бирә. Автор хәзерге татар театрының күп кенә күренекле эшлеклеләре — режиссерлар Ш. Сарымсаков, М. Сәлимҗанов, актерлар Ш. Биктимеров, Р. Таҗетдинов, Ф. Ильская, Г. Булатова һәм башкалар турында тәэсирле һәм образлы итеп, күңел җылысы һәм ихтирам белән сөйли. Сәнгатьне шәхесләр тудыра. Шуны истә тотып, И. Илялова талантлы һәм илһамы, идея инанулары һәм эстетик идеалы белән милләтара элемтәләрне гомуми закончалыклардан чын, зур сәхнә сәнгате реальлегенә әверелдерүчеләргә даими мөрәҗәгать итә.

Сәхнә — тормышка, социалистик җәмгыятьне камилләштерү практикасына актив үтеп керергә чакыручы гражданлык идеяләре, интернациональ идеяләр трибунасы. И. Илялова китабы социализмның рухи культурасындагы шушы шифалы яңару процессын данлаучы җитди хезмәт буларак кабул ителә.

**Вера БАЖАНОВА,**
философия фәннәре кандидаты.

**Вадим Дементьев**

# ХӘСӘН ТУФАН ГӨЛЛӘРЕ

*Каядыр дәшәләр,*
*Нәрсәдер әйтәләр...*
*Мөгаен, матдәнең*
*Җырыдыр чәчәкләр.*

Хәсән Туфан.

Бала чагыннан ук ул чәчәкләр ярата, аларның бөтәннәр күрепаңлап җиткерә алмаган ямен күңел күзе белән тоя. Аккош күле буендагы дачасында да балачак хыяллары кебек нәфис-садә гөлләр үстерә. Аның бакчасы иртә яздан алып беренче кар ятканчыга чаклы шау чәчәктә утыра. Гүзәллек эстафетасы, әдәбият бакчасындагы буыннар эстафетасын хәтерләтеп, бер чәчкәдән икенчесенә тапшырыла бара: бер иш гөлләр сула-сүрелә башлауга, яңа балкыш булып чираттагылары ачыла. Шагыйрь-бакчачы аларны юри шулай, бер-берсенең дәвамы булып янарлык итеп утырткан!

Хәсән ага үзеннән соң да чәчәкләрен корытмаска, таптамаска, төсе итеп сакларга васыять итеп калдырды...

Кырыс сынаулар кичкән кешенең күңелендә гөл-чәчәкләр үстерерлек наз-җылы саклап кала алуы чын мәгънәсендә сокланырлык бит! Без әле яңадан-яңа буыннарга кешелеклелек, түземлелек сабагы бирәчәк бу язмышка кабат-кабат әйләнеп кайтырбыз. Һәммәбезгә дә гыйбрәт-үрнәк булырлык бу шәхесне юксынырбыз.

*Кайсы коштыр, исемең белән*
*Сиңа кычкыра кебек;*
*Урмандагы һәрбер чәчәк*
*Сине юксына кебек...*

Хәсән Туфанны табигатьтән, дөнья-көн агышыннан, халык язмышыннан аерып карау мөмкин түгел. Татар халкының иң күркәм, иң асыл сыйфатлары безнең хәтердә нәкъ менә аның сурәтендә теркәлеп калгандыр шикелле. Шагыйрьнең тышкы йөз-кыяфәте аша, җаны-рухы, әйләнә-тирә мохитка, кешеләргә мөнәсәбәте аша.

«Туфан — авыр, катлаулы юл үткән, татар поэзиясенең зурлыгын гел сиздереп торган, Такташлар чорын бүгенге белән нык тоташтырган бердәнбер олы фигура. Татар поэзиясендә Туфан бер генә, башка Туфан юк!» — Каләмдәш дусты Сибгат Хәкимнең бу саллы сүзләре әле һаман күңелдә яңгырап тора, еллар үткән саен аларның чынлыгы, зур мәгънәсе раслана бара.

Хәсән Туфан — татар шигърияте багына да шифалы назын юмарт сарыф

иткән, аның чәчәк атуына, яңа исемнәр һәм яңа тәсмерләр белән баюына актив булышкан әдип. Аның иҗат яктысы яшь буын шагыйрьләр иҗатына да бәрәкәтле йогынты ясый, татар совет поэзиясен яңа эзләнүләргә рухландыручы көч булуын дәвам итә. Туфанның шигъри гөлләре сулмый, табигать фасылларына, вакытның тыелгысыз агышына буйсынмыйча, яңа буыннарны сокландырып, аларның рухын баетып яши.

Мәскәүнең «Современник» нәшриятында дөнья күргән, рус телендә Хәсән Туфанның әлегә иң тулы басмасы булган җыентыкка да (төзүчесе — Гәрәй Рәхим) «Миләүшә» («Фиалка») дигән бик гади һәм бер үк вакытта ифрат шигъри исем тикмәгә генә кушылмагандыр. «Юл читенә басып, уйга талып, карап тора гүзәл миләүшә...» Җәйге урман-болыннарның күз явын алырлык мең төрдәге, мең төстәге гөл-ганҗәләре арасында ерактан ук күзгә ташланып тормаса да, нәфис хуш исе белән безне әсир итүче бу табигать иркәсе... Хәтта ул да игътибарга лаек, соклануга лаек, ди сыман шагыйрь; чөнки дөнья бербөтен, без барыбыз да күзгә күренми торган җепләр белән, тамырлар белән бер-беребезгә бәйләнгәнбез:

*Мин — бу кырлар, сулар, җилләрдәге*
*Атомнарның иске туганы:*
*Материя мин, җаным,*
*Аның бары*
*Сөйли, җырлый, сагына торганы...*

Шушы еллар миңа мәңге булгандыр кебек тоела. Алар табигатьнең үзендәге һәр җисем, үсемлек, җан иясе кебек, ифрат табигый, ятышлы, гади һәм... шул ук вакытта биредә искиткеч катлаулы тойгы, катлаулы образ, катлаулы структура.

Туфан китабын кулыма алган саен, иң әүвәл шушы шигырьне эзләп табам. Ничәнче кат укыймдыр инде (русчага аны Рувим Моран тәрҗемә иткән),— һәрьюлы беренче мәртәбә укыганда туган кичерешләр яңара. Кырыс гыйбрәтле чынбарлык аша тормышның гармониясен, диалектик бөтенлеген тою, дөньяның аклыгына ышану тәшкил итә бу шигырьнең нигезен: «Ничә миллион гасыр үтте инде безнең шушы җиргә килгәнгә...»

«Сөйли торган материя» — шагыйрь тормышының авыр сынауларга дучар ителгән бер чорында язылган әсәр. Әмма анда сыктау-сызлану, кызгандырырга тырышу, янсә дөньяга, кешеләргә үпкә-үчләшү кебек нәрсәләрнең эзе дә юк. Киресенчә, сабыр сагыш, якты моң саркып торган нык юллар безне тормыш ямен, рухи яшәү мәңгелеген раслаучы фәлсәфи сөземтәгә алып килә. Җан олылыгын сыйфатлаучы гүзәл бер мисал, яңа буыннарга гыйбрәт булырдай рухи ныклык гәүдәләнеше түгелмени бу?!

Хәсән Туфан гаҗәп дәрәҗәдә оптимист һәм мавыгучан кеше, һич «дентә кермәс» бер хыялый иде.

Ун яшьлек үсмер чагында ул күктә атаклы койрыклы йолдыз — Галлей кометасы пәйда булганны күреп хәйран кала. Җитмеш алты елдан соң, галәмнең чиксез киңлекләрен урап, сәйях Галлей быел яңадан җир белән күрешергә әйләнеп кайтты. Хәсән ага шушы көнгә кадәр яшәргә, кайчандыр үзенең яшьлегеннән сәлам алып киткән «Койрыклы йолдыз»ны төнге күк йөзендә кабат күрергә хыяллана иде...

Туфанның үз тормышына да мондый илгизәрлек хас, анда да ерак сәфәрләр, аерылышулар, еллар үткәч очрашулар чиратлашып, тезелешеп тора.

«Язуын язам, ләкин нәрсәдер җитми, һаман нәрсәдер эзләнәм. Шул эзләнүләр мине 1928 елның язында тормыш эченә сәяхәткә алып китте... Кояшка да якынрак якларда, Кавказ һәм Урта Азия республикаларында

халыкларның яңа тормышлары эчендә ике ел буе җәяүләп йөрдем... Сәяхәттә йөргәндә төрле төрки халыкларның гади вәкилләре белән очрашып, язылмаган фольклорларын өйрәндем...» Хәзер инде бик күпләргә билгеле, әмма кызыклы, гаҗәп факт: Урта Азиядә ул... үзенең беренче китабы белән очраша. Көтмәгәндә, бик очраклы рәвештә. Бу җыентыкны шагыйрь сәяхәттә йөргән арада, аның Казанда калган дуслары туплап чыгарган була. Шунысы да бар, Хәсән Туфан үзе бу китапны күреп әллә ни сөенми. Юк, анда кайбер йомшак шигырьләр дә үтеп кергәнгә генә түгел. Сәбәп зуррак, җитдирәк. «Язуын язам, ләкин нәрсәдер җитми...» дип, «тормыш эченә» шушы сәфәр барышында шагыйрь нык уйлана, нык эзләнә. Аның шигърияткә карашы принципиаль рәвештә үзгәрә. Бу үзгәрешне Хәсән Туфан үзе болай аңлата:

*Без: «Җыр бу»,— дип*
*Тезмә тоттырдык,*
*Тезмә — башка, җыр башка.*
*Тезмәләрдән битәр тере шигырь —*
*Җыр сорыйлар бездән чордашлар.*

Ә бит бу вакыйгалар инде танылган шагыйрьләр сафына баскач, чорының иң таләпчән тәнкыйтьчеләре дә аны «татар совет әдәбияты күгендәге иң якты йолдызларның берсе» дип атаганнан соң бара! Әйе, үз-үзеңә югары таләпчәнлек, тыйнаклык, заман һәм укучы алдында искиткеч җаваплылык тою — әлеге сыйфатлар һәрвакыт чын мәгънәсендә зур шагыйрьләрнең юлдашы булып кала.

Хәсән Туфан шигырендәге яңарыш ничек чагыла, нинди конкрет билгеләре белән күзгә ташлана соң? Иң беренче нәүбәттә, күрәсең, төгәл ритмика, төгәл рифмалар ярдәмендә музыкаль яңгырашка ирешүдә, халык иҗатына хас тел бизәкләренә, сурәт чараларына байый төшүдәдер. Ләкин иң мөһиме — шагыйрь «тере шигырь», эчендә кеше җаны талпынып торган лириканы беренче планга куя, поэзиясендә яңа сыйфатка — чынбарлыкны күңел күзе белән сурәтләүгә омтыла. Туфан иҗатында лирик агымның бу көчәюен әдәбият белгечләре дә хаклы рәвештә төп игътибарны кешенең рухи дөньясын тикшерүгә, аның катлаулы кичерешләрен ачуга юнәлтү, халыкның лирик җыр традицияләренә йөз бирә башлау дип билгелиләр.

Халык җыры... Аның тирән агымында, тыенкы гына торган саллы борылмаларында бөтереп алып киткән җегәрен ахыргача тоеп-аңлап бетереп була микән... Хәсән ага белән минем танышлыгым да халык җырыннан башланган иде. Инде ничә еллар узды, ә шул «Шахта» көенең йомшак моңы күңелемдә әле дә булса яңгырап тора... Март аеның бер кичендә очрашуга җыелган татар язучылары бер тын белән, ниндидер рухи күтәренкелек белән җырлаганнар иде аны. Йөзләр, күзләр чал чәчле, җиңел гәүдәле Хәсән Туфан белән нык бәдәнле, терекөмеш кебек тере Сибгат Хәкимгә таба борылган. Халыкның ике улына, ике зур шагыйренә.

Әлеге җырның «Шахта» дип аталуы мине гаҗәпләндергән иде. Янәшәдә утырган татар дусларымнан шуның хикмәтен сорадым. Асыл егетләрен ерак күмер шахталарына әледән-әле озатып торган халык әнә шундый җыр чыгарган икән. Минем өчен татар халкы тормышындагы зур бер сәхифә ачылып киткән кебек булды.

Соңрак мин Хәсән Туфан якташларының да бәхет эзләп Себер якларындагы шахталарга, Урал заводларына чыгып китүләре турында укыдым, 13—14 яшьлек чагында ук аның үзенең дә шахтер абыйлары янына китеп, җир астыннан бакыр колчеданы чыгару эшендә катнашуын белдем.

*Кочаклыйсы килә шул Уралның*
*Яшьлек эзем калган һәр төшен...—*

дип сагынып язган юлларын бөтен тирәнлеге белән аңладым.

«Урал эскизлары»ннан башланган кабатланмас колоритлы, эпик колачлы, иркен сулышлы поэмаларының нигезе әнә шунда икән. «Пролетариатның шөһрәтле бер үзәге булган данлы Уралны, аның эшчәнлеген Туфанга кадәр бераү дә бу кадәр җанлы һәм мәһабәт итеп күз алдына китереп бастырганы юк иде»,— дип яза татар әдәбиятының олы затларыннан Гомәр Бәширов.

«Узган юлында гөлләр утыртып калдыргандай, шагыйрь иҗат гомере буе шулай, еллар күкрәгенә онытылмастай нәфис бизәкләр чигә-чигә, шигъри камиллекнең торган саен югарырак баскычларына менә барды»,— дип дәвам итә Гомәр ага. Илдәге зур үзгәрешләргә багышланган, сугыш һәм тынычлык темасын күтәргән шигырьләре дә, мәхәббәт һәм олы әрнү белән тулы әсәрләре дә шул фикерне раслый.

*Белми калдым, күрми калдым:*
*Киттең... хушлашмадың да.*
*Эзең генә калды миңа*
*Йөргән сукмакларыңда.*

Менә шундый гади генә сүзләр белән, ихлас интонация белән шагыйрь безне тирән кичерешләр дөньясына алып кереп китә. Күңелдәге иң нечкә тойгыларга әйләнә-тирәбездәге табигатьтән аваздашлык эзләп, ул әлеге хискичерешләрнең чынлыгын көчәйтә:

*... Урмандагы һәрбер чәчәк*
*Сине юксына кебек...*

Хәсән Туфан шигырьләрен укыганда бер кызыклы үзенчәлеккә игътибар итәсең: табигатькә — үзенә иң якын торган һәм камиллек мисалы булган дөньяга — адәм баласы каушап, кайгыга батып калган чакларында, кичерешләрен уртаклашырлык, хәленә кирәрлек иш тапмаганда гына мөрәҗәгать итә. Дулкынланып серен уртаклаша, киңәш сорый, аңа килеп сыена. Табигать күренешләре лирик геройның халәтенә битараф кала алмый. Шагыйрь өчен менә шушы мөнәсәбәт, җавап бик мөһим:

*Нигә дәшми?*
*Ник эндәшми?*
*Ник сөйләшми бу тургай?!*
*«Әйтермен дә йөрәге ярылыр,*
*Егылып китәр...» ди бугай...*

Табигать күренешләренә без поэзиянең даими атрибуты дип карарга күнеккәнбез, кайчакта рифмалы юллар гына тезә белүче кәсепчеләрнең ясалма, кыланчык чагыштырулар белән шыплап тутырылган «шигырь»ләреннән дә образлылык билгеләрен, яисә, һич булмаса, табигатьне саклау мотивларын эзлибез. Ләкин ул тезмәләргә көчләп, юри кертелгән «табигать», өзеп-йолкып алынган чәчәк төсле, бик тиз төсен югалта, шиңә, үлә...

Хәсән Туфан гөлләре табигый туфрагында тамырлана, үсә һәм чәчәк ата. Бу поэзияне бервакыт Мостай Кәримнең менә-менә ачылырга торган чәчәккә охшатуы бик урынлы иде. Кулга алырга өлгергәнче таҗлары коелып төшкән чәчәк шикелле үк, бөтен хикмәте ачылып беткән шигырьнең ни кызыгы да ни шатлыгы бар?

Хәсән Туфан — хикмәтле шагыйрь.

«Миләүшә» җыентыгына кыска, әмма бик дулкынланулы, тыгыз фикерле кереш сүз язган шагыйрь Ренат Харис поэзия аксакалының гүзәл гамь белән иҗади накалда яшәү үзенчәлеген аның кабатланмас шәхесе аша ача.

Әйтик, шагыйрь туктап калган сәгатькә тыныч карый алмый: «Вакыт никадәр генә кадерле булмасын, аны туктатып торырга ярамый»,— дип, шунда ук аны төзәтергә керешә. Туфан — һәрвакыт киләчәккә ашкынып яшәгән, вакыт агышын туктатырга яисә кирегә борырга маташучылар белән көрәшеп яшәгән шагыйрь. Ул төзәткән сәгатьләр бүген дә ил-көн адымыннан калышмый.

«Яраткан мавыгуыгыз ни?» дигән сорауга шагыйрь үзе дә: «Сәгать төзәтү, чәчәкләр үстерү».— дип җавап биргән иде.

Аның Аккош күлендәге бакчасы инде язга кадәр кар катламы астында калырга әзерләнә... Анда, күзге контрастлар арасында, салкын сулышын өреп килүче кышны үчекләгәндәй, әле дә сап-сары чәчәк башлары күренә.

Хәсән Туфанның бөтен гомере чәчәкләрдән аерылгысыз. Ул аларны бер ялгызы дала уртасында калганда да, Казанда, бөек Тукай һәйкәле каршында горур басып шигъри ант сүзләрен кабатлаганда да күрә.

*Елларым да, гомер юлларым да*
*Шундый җылы, җиләс көннәрдә*
*Күзге җилләр кагыла аламыни*
*Йөрәктәге шигъри гөлләргә?!*

Аның күзләренә малай чакның Кармәт болыннарындагы беренче чәчәкләр яктысы күчкән. Җәйге болыннар киңлегендә ул дөньяның төрле төсләргә, төрле кичерешләргә байлыгын күргән. Ниһаять, үзенең күңел хәзинәсен башкаларга ачкан, шигъри гөлләрен юмарт өләшкән.

Сибгат ага Хәкимнең Туфан турындагы иң соңгы истәлекләреннән берсе — «Аккош күлендә сагыш, моң...» дигән эссесы искә төшә...

«Туфанның гомерендә бер тапкыр тукталып ял иткән урыны — Аккош күле. Ерак юл, ерак сәфәрләрдән соң арып килеп егылган урыны — шул урын. Дачасы, бакчасы. Урманнан җыеп, кешеләрдән җыеп чәчәк үстерде. Тургай чәчәгеннән башлап, бөтен чәчәкләр дә бар аның кечкенә бакчасында. Көз җиткәч, ул аларны берәм-берәм өзеп, букет ясап, иртән Тукай һәйкәленә илтә. Балалар — мәктәпкә. Туфан — Тукайга. Һәр елны шулай. Һәр елны бер вакытта. Бер үзе. Ялгыз. Уйлары да үзе. Изгеләрчә. Авыл карты кичтән әзерләнеп, иртән изгеләр каберенә барган күк бара. Бара, басып тора, икәүдән-икәү. Шунда рухы аның Тукай рухы белән тәмам кушыла сыман. Хәзер ул тыныч. Үз бурычын үтәде. Менә бит Туфан чәчәкләре каян үсеп чыга. Тукай — Туфан туфрагыннан. Җирлеге бай...»

Татар совет әдәбияты бакчасындагы Туфан гөлләре фасылларга буйсынмый, кырыс җилләргә бирешми, шау чәчәктә утыра.

*Чәчәкләрдә*
*Төсе калды,*
*Җирдә җылы эзе калды.*

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

*Ап-ак, ап-ак чәчкә төсле*
*Балкып тора җанда төсе...*

Мәскәү.

Баян Гыйззәт

# НИГЕЗ ТАШЛАРЫН САЛГАНДА

## ТАТАР ТЕАТРЫНА 80 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА

Татар иҗтимагый фикеренең һәм культурасының яңа чоры мәгърифәтчелек хәрәкәте белән бәйләнгән. XIX йөзнең соңгы яртысында аеруча көчәеп киткән бу хәрәкәт, татар тормышының бөтен өлкәләренә үтеп кереп, халык тарихында чын-чынлап уяну, яңару чорын ачты.

Мәгърифәтчеләр дөньяны яңарту өчен көрәштә әдәбият һәм сәнгатькә зур урын бирделәр. Ш. Мәрҗани шулай ди: «Мөхәммәт пигамбәр тере әйберләрнең сурәтен ясаудан тыйган, чөнки ул чакта кешеләр сурәткә табынучы булганнар. Ә хәзер андый куркыныч юк. Шулай булгач, сурәт ясау, рәсемгә төшерү дә тыелмаска тиеш... Музыкадан төп максат — төрле тавыш һәм көйләрне бер-берсенә яраштырып, күркәм һәм матур итеп төзү аркылы җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлык дөньясына әтәрү»[1].

К. Насыйри исә үзенең «Фәвакиһелҗөләсә» (1884) әсәренең аерым бүлеген музыка һәм җыр мәсьәләсенә багышлый, җыр сәнгатенең, динчеләр әйтүенчә, гөнаһ эш булмыйча, кешенең рухи тормышында әһәмиятле роль уйнаганын күрсәтә. Шуның өчен, ди К. Насыйри, музыка белемен мәдрәсәдә фәннәр һәм һөнәрләр белән бергәттән өйрәнергә кирәк.

Әлбәттә, К. Насыйри һәм Ш. Мәрҗанинең югарыда китерелгән фикерләре мәгърифәтчеләрнең сәнгатькә булган уртак карашын чагылдыра иде. Шул ук вакытта алар халык иҗаты белән генә чикләнмичә, сәнгатьнең яңа, югары төрләрен булдыру бурычын алга куйлар, ә инде Г. Ильяси, Ф. Халиди кебекләр турыдан-туры практик эшкә дә тотыналар. Моны җәмгыятьнең, халыкның үзаңы, үсеш дәрәҗәсе таләп итә. Мәсәлән, Казанда рус телендә спектакльләр куела башлагач, динчеләрнең катгый тыюларына да буйсынмыйча, татар яшьләре әлеге театрның актив тамашачысына әйләнәләр. Ул гына да түгел, араларында бу сәнгать турында шактый төпле фикер йөртүчеләре дә барлыкка килә. Димәк, татар мәгърифәтчеләренең театр эшен оештыруга омтылышы тормыш соравына җавап булып тора иде.

Ә тарихта бу уңайдан шактый гыйбрәтле вакыйгалар булып узган. һәм алар үз заманында чыккан китапларда да язылып калган. Мәсәлән, тарихчы М. Рыбушкин «Краткая история города Казани» китабында (1834) шулай яза: «Бераздан соң татарлар бик дәртле театр яратучылар булып киттеләр... Татарлар хәзер театрга гына түгел, төрле күңел ачу урыннарына да бик яратып йөриләр. Хәтта заманча укыган кешеләр дәрәҗәсеннән торып бу тема турында фикер дә йөртәләр». Тарихчы Н. Баженов «Казанская история» китабында (1847), бу фактларны раслап, болай ди: «Татарлар да театрны яраталар, һәр спектакльдә, бәяләренә карамыйча, барлык урыннарга билет алалар». 1852 елда Казанда бер күчмә труппа, уйнар урын тапмаганнан, концерт кую белән чикләнергә тиеш була. Шунда килә алмаган кешеләрне тынычландырырга теләп, «Казанские губернские ведомости» газетасы (1852, 4 сан) хәбәрчесе эре генә болай яза: «Килә алмагансыз икән, борчылмагыз: театр татар балалары белән тулган иде».

Бу фактлар В. Г. Белинскийның да игътибарын җәлеп иткән, һәм ул татарлар арасында культура хәрәкәтенең көчәюенә, үсүенә чын күңелдән шатланып, матбугатта язып чыккан. Бу мөнәсәбәт аның материалны ничек җыюыннан да һәм аерым күренешләргә биргән бәясеннән дә ачык күренеп тора. М. Рыбушкинның мәгълүм китабын укыганда ул берничә мәсьәләгә тукталган. Шулар арасында татар халкының тормышына караган

[1] Хисмәтуллин Х. Шиһаб Мәрҗанинең тел, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә карашы.— «Совет әдәбияты», 1964, 4 сан, 130 б.

сәхифәләрне аерым алган, татарлар турында төрле урыннарга сибелгән мәгълүматларны бер урынга җыеп һәм алар турындагы уңай күренешләрне сайлап алып, рус укучысына тәкъдим иткән. «Рыбушкин әфәнде китабыннан,— дип яза ул,— аеруча зур канәгатьләнү белән шундый фактлар белән танышабыз: казан татарлары күпмедер дәрәҗәдә цивилизацияле булулары, хәтта укымышлылык белән аерылып торалар икән. Алар — әдәпле һәм түбәнчелекле кешеләр. Әгәр үзләренең милләттәшләренең нәфрәтенә дучар булырга теләмәсәләр, аларның һәрберсе укый-яза белергә тиеш. Аларда биш елга якын дәвам итә торган махсус уку тәртибе кертелгән» (В. Г. Белинский. Әсәрләренең тулы җыентыгы, 1 том, М., 1953, 214 б.). «Татарлар бик теләп театрга йөриләр һәм аны бик яраталар икән»,— дип дәвам итә ул. Патша ялчылары изелгән милләтләрнең культурасын үстермәс өчен бөтен көчен куеп көрәшкәндә, мәктәп-мәдрәсәләрне ябып, газета-журнал, китап чыгаруларны тыеп, һәр яңалыкка каршы килеп торганда, бөек демократ милләтебезнең культурасы үсүен чын күңелдән яклап чыга, шул өлкәдә ясалган һәр адымны «аеруча зур канәгатьләнү белән» каршылый һәм бу фактларны башкаларга белдерергә ашыга. Бу — татар халкы турында, В. Белинский журналы аша, бөтен илгә, бәлки Европага да беренче дөрес хәбәрләр җиткерү булгандыр.

Тагын бер кызыклы фактка тукталып үтәргә кирәк. 1876 елда Казанда рус телендә «Первый шаг» исемле альманах басылып чыга. Анда әдәби әсәрләр белән бергә, юльязмалар, истәлекләр, иҗтимагый һәм культура мәсьәләләренә, шул исәптән татар халкы тормышына караган материаллар урын алган. Альманахта Г. Потанинның «От Новочеркасска до Казани» дигән мәкаләсе аеруча кызыклы. Ул Казан театры тамашачылары арасында татарларның зур урын алып торганын әйтә. Шуннан соң автор, театрның репертуарына күчеп, аның берьяклы булуын тәнкыйтьли, бу төбәкнең төп халкы булган татарлар тормышына кагылган әсәрләрнең булмавы репертуарның зур кимчелеге, дип белдерә, һәм эшләр киләчәктә дә болай бара торган булса, татарлар театрга йөрми башлар, дип кисәтә. Мәкалә авторы чоры өчен шактый кыю булган тәкъдимнәр дә кертә: «85 ел яшәү дәверендә Казан театры җирле халык интереслары белән ни дәрәҗәдә бәйләнгән булды икән... Бу театр ике халыкка да — русларны һәм татарларны бергә кушкан Казан халкына ни дәрәҗәдә аңлашыла икән?.. Әлбәттә, әгәр театр аларның (татарларның) ихтыяҗларын искә алып, үзенчәлекле тормышларына якынайса һәм шулай итеп аларга аңлаешлы булып әверелсә, һичшиксез, алар спектакльләргә ешрак йөрерләр иде... Аннан соң биредә языла торган драмаларга урындагы татар тормышы күренешләрен һәм типларын кертү турында кайгыртырга кирәк...»

Татар театрының оешу тарихын өйрәнгәндә, бу материалларның әһәмияте бик зур. Беренчедән, әлеге язмалардагы фикерләр татар тамашачысын күздә тотып, татар тормышына бәйләп әйтелә. Икенчедән, бу чыгышлар, алдарак әйтелгәнчә, милли изүләр һәрьяклап көчәйгән чорда, патша хөкүмәте татар мәктәп-мәдрәсәләрен ябып, мәчетләрен җимереп, көчләп чукындыру кампаниясенең кызган чагында ясала. Менә шул чакта В. Г. Белинский кебек эшлеклеләрнең әйткән җылы сүзләре татар җәмәгатьчелеге тарафыннан ничек кабул ителгәнлеген күз алдына китерү авыр булмаса кирәк. Әлбәттә, алар татар мәгърифәтчеләре күңелендә рәхмәт хисләре уятып кына калмаган, шул юлда тырышлыкны арттырып эшләргә илһам да биргән.

Шушы катлаулы иҗтимагый-политик шартларда татар мәгърифәтчеләре башка бик күп мөһим практик чаралар белән (яңача укыта торган мәдрәсәләр ачу, газета-журналлар чыгару өчен көрәш, культура оешмалары төзү, китап бастыру h. б.) беррәттән, татарча театр оештыру максатын да алга куялар. Бу эш театр сәнгатенең идея-эстетик нигезе булган драма әсәрләре язудан һәм тәрҗемә итүдән башлана, аларны сәхнәгә кую тәҗрибәләре ясала. Шулай итеп, ун ел чамасы вакыт эчендә (1887—1898) Г. Ильяси, Ф. Халиди, М. Казани, Г. Камал пьесалары языла, «Хасәт баба», «Комедия Чистайда» комедияләре басылып чыга, театр булдыру кирәклеге, аның беренче адымнары турында «Тәрҗеман» газетасында һәм Казанда русча чыга торган газеталарда хәбәрләр басыла башлый.

Татар телендә беренче сәхнә әсәре булган «Бичара кыз» драмасы (1887) мәгърифәтчелек хәрәкәтендә актив катнашучылардан Габдрахман Ильяси, икенчесе — «Рәдде бичара кыз» (1888) Фатих Халиди тарафыннан языла. Г. Ильяси татар драматургиясенә нигез салучы булу белән бергә, татарча беренче спектакль куючы да, беренче режиссер һәм артист та. Л. Җәләйнең язуына караганда, «Бичара кыз» әсәре язылган чорда сәхнәгә дә куелган. Биографиясеннән шул күренә ки, Г. Ильяси беренче башлап Казанда «Чыбылдык театры» (өй театры) оештыра. «Бичара кыз» әсәре әнә шул сәхнәдә һәвәскәрләр көче белән уйнала. Л. Җәләй әлеге мәкаләсендә Г. Ильясиның кызы Зәйнәп Ильясиның сүзләрен дә китерә: «Әни әйтә торган иде, әтиең өйдә театр корып йөри торган иде» [2]. Бу факт Г. Камал истәлекләре белән дә раслана. Татар дөньясындагы шушы беренче драманың беренче артисты да Габдрахман Ильяси үзе булган булса кирәк. Габдрәшид Ибраһи-

---

[2] Л. Җәләй. Татар драматургиясенә 60 ел тулу уңае белән. «Совет әдәбияты», 1947, 11 сан, 110 б.

мовның «Миръат»ындагы мәгълүматка караганда, 1900 елларга кадәр үк Касыйм шәһәрендә рәсми театр уйналган була. Әнә шунда куелган әсәрләрнең берсе шушы «Бичара кыз» булуы бик ихтимал. Әлеге пьеса басылып чыкканчы ук сәхнәдә уйналган диган хәбәрләр дә бар: «Бу әсәрне китап булып басылганга хәтле үк йортта-гаиләдә (домашний спектакль рәвешендә) уйналган дип сөйлиләр, бу хәбәргә караганда, бездәге йорт-гаилә спектакльләре 1885—1886 елларда ук булган була»[3].

Дөрес, бу чорда куелган спектакльләр турында хәбәр иткәндә, күпчелек очракларда нинди әсәр уйналганы әйтелми. Шулай да моңа кадәр татар телендә басылып чыккан пьесаларның исемнәре билгеле булганлыктан, сәхнәгә, әлбәттә, шулар куелган дияргә була. Димәк, аларны драма әсәре буларак кына түгел, театрга бәйләп тә, шул чор сәхнәсенең репертуары буларак та тикшерергә нигез бар.

Иҗат методы ноктасыннан караганда, мәгърифәтчелек театры репертуары — шактый катлаулы һәм үзенчәлекле күренеш. Мондый әсәрләрдә шул чорның реаль тормышы күз алдына килеп баса, андагы фикер көрәшләре, төрле көчләрнең бәрелеше-конфликтлары шактый тулы гәүдәләнә. Аеруча тормышның тискәре яклары реалистик күренешләрдә ачыла. Әмма уңай идеалның ничек сурәтләнүенә килгәндә, мәгърифәтче язучы, реалистик типизация юлыннан чыгып, хыял дөньясына кереп китә. Мәсәлән, «Хисаметдин менла»дагы Хәнифә, «Бичара кыз»дагы Маһитап, «Морад Сәлимов»тагы Морад, «Комедия Чистайда»гы асрау Хесни образлары әнә шундый алым белән иҗат ителгән. Җәмгыятьтә изүче һәм изелүчеләрне күреп тә, изелүчеләр өчен чын күңелдән борчылып та, шуларны әдәби әсәргә күчергәндә яхшылык һәм начарлык категорияләреннән чыгып кына, димәк, социаль анализ кулланмыйча, мораль яктан гына гәүдәләндергәнлектән, әлеге әсәрләр тормыш турында тулы мәгълүмат бирә алмыйлар иде. Шушы сыйфатлар мәгърифәтчелек реализмының шактый чикләнгән булуын күрсәтә. Әмма шул чорга тәэсирләре ягыннан бу үрнәкләрнең дә уңай роль уйнаганлыгын һич тә шик астына алып булмый. Алар хәтта үзләреннән соң килгән язучыларны да рухландырганнар. Г. Тукайның «Рәдде бичара кыз»дан аерым монологлар сөйләп йөргәне, ә Г. Камалның аны хәтта яттан белгәнлеге мәгълүм. Димәк, шул чорда сәхнәгә куелган беренче татар пьесалары үз чорының әһәмиятле актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыгып, аларны җәмәгатьчелек алдына куялар. Шунысын әйтергә кирәк: мондый иҗат методында реализм элементлары уңай геройларны яки киләчәкне сурәтләгәндә, нәтиҗәләр ясаганда түгел, ә чынбарлыкта яшәп килгән һәртөрле гаделсезлекләрне, иске тәртипләрне тәнкыйтьләү дәрәҗәсенә күтәрелгән әсәрләрдә алга чыга, шуларда тормыш дөреслеге тирәнрәк чагыла. Менә шушы сыйфат — аның көчле ягы. Бу сыйфатлар аеруча комедия-сатира жанрында язылган әсәрләргә хас. Аларда әлеге реалистик элементлар күбрәк урын алып тора. Әлеге сыйфат билгеле күләмдә критик реализмга да күчә, һәм бу фактта без мәгърифәтчелек реализмындагы кайбер тенденцияләрнең дәвамын күрәбез. Әмма соңга таба, уңай геройлар демократик катлаулардан алына башлагач, критик реализм бу берьяклылыктан торган саен кыюрак котыла бара. Төрле урыннарда, күбесенчә «өй театры» шартларында башлаган спектакльләрнең эчтәлеге шулай камилләшә, булачак театрның идея-эстетик нигезе шулай формалаша.

Бу әсәрләр булачак театр алдында нинди бурычлар куелуын һәм ничек хәл ителүен өйрәнү өчен дә әһәмиятле документ булып хезмәт итәләр. Аларның кайберләренә үз вакытында үзенчәлекле бәя дә бирелә, анализ ясала. Күләме һәм формасы ягыннан бик чикләнгән мондый бәяләрдә шул чорның, башлангыч дәрәҗәдәге булса да, әдәби-эстетик карашларын күрергә мөмкин. Бу тәҗрибә башта әдәби әсәрдә — Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» драмасында ясала, сәхнә әсәре тормыш белән чагыштырып карала. Әнә шулай беренче тапкыр театр тәнкыйте элементлары сизелеп кала. Исеменнән үк аңлашылганча (рәдде — кабул итмәү), әсәрдә полемика бар. Аның геройлары Г. Ильяси пьесасындагы вакыйгаларга, персонажларның эш-гамәлләренә бәя бирәләр, бәхәсләшәләр, хөкем чыгаралар. Вакытлы матбугат булмаганлыктан, Ф. Халиди бу өлкәдә барган бәхәсләрнең асылын әдәби әсәр ярдәмендә ачып бирү юлын таба. Гомумән, аның «Рәдде бичара кыз» драмасы — фикердәше Г. Ильясига каршы чыгучыларга җавап рәвешендә язылган әсәр. Милли газета-журналлар булмаган вакытта бер әдәби әсәргә икенче әсәрдә бәя бирү, аның турында фикер йөртү гадәткә кергән була. Мәсәлән, З. Һадиның «Мәгъсүм» хикәясендә Ислам хәлфә М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы турында фикер әйтә: «Бу хикәят гыйшык-мәхәббәт хакында язылган кеби күренсә дә, милләт хакында булган нәрсәләр күп икән». Г. Камал исә «Бәхетсез егет» драмасында үзенең геройларыннан театрның әһәмияте, кирәклеге турында сөйләтә. «Хуҗа һәм приказчик» комедиясендә шундый ук фикерләр бар.

Милли драматургия өлкәсендә барлыкка килгән яңалыклар белән бергә, турыдантуры театр тамашалары оештыру эше дә башланып китә. Габдрахман Ильяси тарафыннан куелган беренче спектакль турындагы хәбәр халык арасында тиз тарала. Моның шаһиты булган Г. Камал соңыннан үзенең истәлекләрендә бу турыда язып та чыга.

[3] М. Парсин. 20 ел эчендә татар театры. «Татар театры. 1906—1926» җыентыгы. Казан, 1926, 71 б.

Бу вакыйгалардан соң төрле урыннарда театр эшенә хәзерлек чаралары — пьесалар язу, тәрҗемә итү һ. б. турында хәбәрләр ешая бара. Алар «Тәрҗеман» газетасында шактый басыла. Гомумән, бу газета татар культурасындагы яңалыклар турында вакытында хәбәр итеп бара, театр тирәсендәге беренче бәхәсләр, фикер алышулар да шушы газета битләрендә сакланып калган. Мәсәлән, 1892 елның 10 декабрендә чыккан санда драматург Д. Фонвизин турында мәкалә урнаштырыла, аның иҗат алымы безнең җәмгыять өчен дә бик файдалы дип, комедия язучыларга үзенә күрә бер күрсәтмә бирелә. Аның көлүе, күңелле итеп һәм шул ук вакытта ачы телле көлүенең зур тәрбияви әһәмияте бар иде, диелә газетада. «Безнең җәмгыять өчен нәкъ менә Фонвизинча көлү урынлы һәм вакытлы». Күрәсең, бу чакырулар эзсез калмаганга охшый. «Хәсәт баба» (1893), «Комедия Чистайда» (1895) кебек әсәрләр басыла башлау шул турыда сөйли. Ф. Халидинең «Надан, саран Теллә бай» комедиясенең шулар тәэсирендә язылган булуы мөмкин.

Шул ук «Тәрҗеман» газетасында (1893 ел, 10 сентябрь) басылган хәбәргә караганда, Сембер губернасында яшәүче Мөхәммәт Акчурин дигән берәү Н. Гогольнең «Өйләнү» комедиясен тәрҗемә иткән. Димәк, театр репертуары турында сүз барганда, жанр мәсьәләсенә дә игътибар ителә башлый, репертуарның идея юнәлешен билгеләү омтылышлары ясала. Алдынгы җәмәгатьчелек репертуарның эчтәлеге мәсьәләсенә игътибар итү белән бергә, турыдан-туры даими театр булдыру, спектакль уйнау эшенә керешергә кирәклеген дә көн тәртибенә куя. «Тәрҗеман» газетасы 1895 елның көзендә казанлыларның бу юлда шактый әкрен кузгалуларына борчылып язган хат бастырып чыгара. Бу хатта татарлар арасында театрга йөрүчеләрнең күплеге, аларның театрны яратулары, димәк, хәзер милли театр кирәклегенең өлгергән мәсьәлә булуы басым ясап әйтелә. Аннан соң бу эштә үрнәк итеп алырлык мисаллар китерелә, мөселман динендәге кайбер халыкларның инде театр уенын башлаганлыгы искәртелә. Әлеге хатта түбәндәге юллар бар: «Казанда театр тамашасы аз түгелдер. Ахшамнарда театрда энҗеле, фәсле ханымнар да буладыр. Ләкин милли театр улдыгыннан хәбәре бу чакта бик аздыр. Бу хосуста Кавказия мөселманнары алда бара. Араларында зыялы вә мәгълүматле адәмнәр булдыгыннан аратирә Тифлиста, Бакуда милли театр тамашалары тәртип итәрләр».

Мондый хәбәрләр, аерым алганда, театрның әһәмиятен аңлатып язган кыска-кыска мәкаләләр Казанда чыгып килгән рус матбугатында да басыла башлый: «Мөселман халыкларында, алдынгы әдәбиятның үсә баруы белән бәйләнештә, халык театры булдыру мәсьәләсе дә көн тәртибенә куелды. Алдынгы әдәбиятның үсеше кешеләрнең рухи ихтыяҗларын уятты, бу нәрсә мөселманнарны да театрны «җен шаукымы» дип түгел, ә башка күзлектән карауга этәрде»[4].

1898 елның көзендә «Казанский телеграф» газетасы бу эшне оештыручылар да бар икән, дип белдерә: «Татар телендә спектакль булдыру — Казан мөселман җәмәгатьчелеге алдынгыларының күптәнге хыялы. Изге хыял, әмма ул тиз генә тормышка ашармы? Соңгы вакытта татар телендә спектакльләр кую мәсьәләсе үзенең үсешендә яңа дәвергә керде. Интеллигент татар мөселманнарыннан берәү Казанда татар театры мәсьәләсен хәл итү эшенә җитди рәвештә алынырга булды»[5]. Бу оештыручының исеме дә билгеле: ул — Заһит Шамил. «Кем белә,— дип яза газета,— бәлкем, Шамил әфәндenең җиңел кулы белән мөселман җәмгыяте файдасына беренче булып оештырылган Казан театры Болак артындагы Яңа тамашачыларның да мәхәббәтен җәлеп итәр»[6].

Шул ук вакытта булачак театрның репертуары мәсьәләсе дә күтәрелә. Югарыда әйтелгән газетада бу турыда бәхәс тә булып ала. Татар телендә сәхнә әсәре һәм театр уеннары булуы мөмкинме-түгелме дигән сорау да куела.

Бу бәхәсләр, театр турындагы хәбәрләр әлеге газеталар битләрендә берәзга сирәгәеп кала. Моның сәбәпләрен аңлау, әлбәттә, авыр түгел. Царизмның аяусыз колониаль политикасын тормышка үткәрүче патша ялчылары, изелгән милләтнең алдынгы көчләре башлаган бу яңалыкны бик тиз күреп алып, гадәттәге алымны кулланалар: моңарчы татарча газеталар чыгаручыга ничек аяк чалып килгән булсалар, бу эшкә дә юл куймаска тырышалар. Димәк, театрга да патша самодержавиесенең милли культураны үстермәүгә юнәлтелгән реакцион политикасы каршы төшә. Әлбәттә, бу турыда сүз йөртә башлаган газеталарга да тиешле «күрсәтмә» бирелгән булырга тиеш. Моның шулай булуы шушы чорда Татар укытучылар мәктәбендә булып узган кайбер вакыйгалардан да күренә.

Театр эшен практик юлга салу омтылышы шушы Укытучылар мәктәбе укучылары арасында да башлана. Бу турыда шул чор рус матбугаты да яза, моны архив документлары һәм истәлекләр дә раслый. Күренекле театр тәнкыйтьчесе һәм татар театрының беренче адымнарыннан ук бу өлкәдә актив эшләп килгән Г. Кәрам болай дип искә ала: «Учительская школада тәҗрибә өчен рус телендә вак-вак рус пьесалары куела. Менә шул школа

---

4 «Волжский вестник», 1898, 23 июнь.

5 «Казанский телеграф», 1898, 6 октябрь.

6 Шунда ук.

сәхнәсе театр русларга гына махсус бер нәрсә дип йөргән шәкертләргә бик зур тәэсир иткән булса кирәк. Бу яшьләр, үзләре уйнау белән генә канәгатьләнмичә, аның татарча уйналуын таләп итә башладылар. Моңа, әлбәттә, школа идарәсенең, бигрәк мәхәлли хөкүмәтнең (урындагы властьларның — Б. Г.) рөхсәт бирү ихтималы юк иде. Алар бу таләпләренә ирешә алмадылар. Ләкин алар моның белән генә калмадылар. Шуннан 5-6 елдан соң бәгъзе бер өйләрдә шул ук школа шәкертләре русчадан тәрҗемә ителгән кечкенә әсәрләрне ара-тирә уйный башладылар»[7].

Татар театрының 20 еллыгына карата тезислар рәвешендә басылган материалда моңа түбәндәге фактлар өстәлгән: «1898 елда Казанская учительская школада укучы татар яшьләре татарча спектакль куярга рөхсәт сораганнар. Рөхсәт бирелмәгәч, рус әдәбияты белән файдаланып, спектакльне русча куйганнар»[8].

Г. Кәрам китергән фактлар башка документлар белән дә раслана. Татарстан Үзәк дәүләт архивында Татар укытучылар мәктәбендә оештырылган спектакльләр турында мәгълүматлар саклана. 1897 елның январенда мәктәпнең инспекторы Ш. Әхмеров Казан уку-укыту округының попечителеннән кышкы каникуллар вакытында бу мәктәптә укучыларга Н. Гогольнең «Өйләнү» һәм «Ревизор» (2 акт) пьесаларын куярга рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән. Үтенеч язуы өстенә 1897 елның 24 декабрендә (иске стиль белән) округ попечителенең «рөхсәт итәм» дигән резолюциясе салынган[9]. Моннан соң да бу мәктәптә татар укучылары русча спектакльләр кую эшен дәвам итәләр. Шул ук вакытта татар телендә әдәби музыкаль кичәләр үткәрү үтенече мәктәпнең педсоветы тарафыннан кире кагыла[10]. Бу вакыйгаларда катнашкан Г. Кәрам әлеге мәктәптә татарча спектакльләр кую да тыелганлыгын әйтә. «Татар театры (1906—1926)» җыентыгында шул факт раслана.

Укытучылар мәктәбендә башланган тыюлар шәһәр күләмендә оешып килгән труппа язмышына да кагыла. Газеталардан күренгәнчә, шәһәр яшьләре Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» драмасын сәхнәгә куярга хәзерләгән булганнар һәм спектакльне күрсәтергә рөхсәт сорап үтенеч җибәргәннәр. «Волжский вестник» газетасы шул уңай белән кызыклы фактлар китерә: «Шәһәрнең татарлар яши торган өлешендә озын колаклардан татарча спектакль куелачагы турында хәбәр таралды. Бу хәбәр бераздан «Казанский телеграф» газетасында да басылган иде. Ул хәзер дөрескә чыга башлады. Безгә хәбәр итүләренә караганда, инде тиешле үтенеч тә җибәрелгән һәм, әгәр дә рөхсәт ителсә, татарча спектакль һөнәрчеләр клубында, ярлыларга ярдәм максаты белән, мөселман бәйрәме... көнендә куелачак икән. Ирләр ролен дә, хатын-кызлар ролен дә ирләр башкарачак. Катнашучылардан безгә шушы кешеләрне атадылар: З. Шамил (бу эшне башлап йөрүче), З. Димов, бертуган Айтугановлар. Киләчәк күрсәтер. Хәзергә яшь мөселманнарга Казанда моңарчы күрелмәгән башлангычларында зур уңыш телик. Куелачак әсәр — «Рәдде бичара кыз» пьесасы икән («Бичара кыз»га тәнкыйть»). Казанлылар тәрәккый итә»[11].

Әмма күп еллар буе хәзерләнеп килгән, зур өметләр багланган бу вакыйга булмый кала — патша властьлары аны тыя. Бу турыда газеталарда хәбәрләр бастыру да шуннан соң сирәгәя.

Шулай да башланган эшне бөтенләйгә тыю инде мөмкин булмый. Мәсәлән, шул ук елларда театрның әһәмиятен аңлаткан, аны булдыру кирәклеге турында чыгышлар татар телендә дә күренә башлый. Бу хакта беренче башлап Г. Камал язып чыга, һәм яшь драматург бу мәсьәләдә үзенең шактый хәзерлекле булуын күрсәтә. Аның бу чыгышы татар театр сәнгатенең башлангыч чорына карата үзенә күрә бер программа булып саналырга хаклы. Моның өчен ул үзенең беренче әсәре булган «Бәхетсез егет» (1898) драмасын файдалана, театрга караган фикерләрен әсәрдәге яңача укыган яшь геройдан әйттерә: «Минем театрга бару дигән сүзем дә гаеп түгел, анда никадәр гыйбрәтләр бар: начар юлда йөргән кешеләр нинди эшләргә очраганын һәм дөньяда нинди хурлыкларга төшкәннәрен күз алдында күрсәтәләр». Пьесада бер биткә якын урын алган монологта шул чорда театр турында барган бәхәсләр дә чагылып үтә, сәхнә сәнгатенә тискәре карашлар белдергән, аны уен-көлке дип кимсетүчеләргә җавап та бирелә. Театр тамашасының башка әһәмиятле яклары да онытылмый: «Анда биргән акчаларыбыз да җилгә китми, анда җыелган акча белән фәкыйрьләрне, мәктәп вә мәдрәсәләрне тәрбия кылалар».

Шушы карашлар нигезендә Г. Камалның үз иҗаты да башланып китә. һәм ул бер-бер артлы «Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет» исемле пьеса яза, «Кызганыч бала» драмасын тәрҗемә итә. Шунысы игътибарга лаек: 19 яшьлек Камал, әле иҗат тәҗрибәсе булмавы нык сизелүгә дә карамастан, күп кенә мәсьәләләрдә, мәсәлән, алган вакыйгалар, аларны ничек күрсәтү, конфликтларны хәл итү өлкәсендә яңа юлга баса. Биредә гел бәхетле тәмамлана торган финаллар да юк, тискәре типларның кәтмәгәндә уңайга үзгәреп китүләре

---

[7] Кәрам Г. Татар театры тарихы. «Кызыл шәрык яшьләре», 1922, 11-12 сан, 20 б.

[8] Парсин М., Мутин М. Татар театрының 20 еллык бәйрәменә. «Кызыл Татарстан», 1926, 3 январь.

[9] Таһиров З. Беренче спектакльләр. «Социалистик Татарстан», 1968, 21 январь.

[10] Шунда ук.

[11] «Волжский вестник». 1899. 16 январь.

дә күренми. Әсәрләрдә тормышның катлаулылыгы, драматизмы чагыла. Уңай геройларның характеры да башка...

Әйткәнебезчә, патша самодержавиесенең колониаль политикасын тормышка ашыручылар казан татарлары арасында барган вакыйгаларны, һәртөрле яңалыкларны каты күзәтү астында тоталар һәм прогрессив башлангычларны даими рәвештә тыеп киләләр. Менә шушы кысулардан соң, күп кенә әһәмиятле эшләр чит төбәкләрдә оештырыла башлый. Мәсәлән, шул ук театр уены Казанда әзерләнеп тыелгач, аны моннан ерак булган шәһәрләрдә оештырырга мәҗбүр булалар. Күрәсең, урындагы властьлар моңа артык зур игътибар итмичә генә рөхсәт бирәләр. Әнә шулай итеп, Казанда «Рәдде бичара кыз» спектакле тыелган вакытта, Касыйм шәһәрендә ике көн рәттән ачык спектакль куюга ирешәләр. Ә бераздан Ташкент шәһәрендә уйнала, Оренбургта хәрәкәт башлана.

Патша властьлары, газета-журнал чыгаруны гасырлар буена тыеп килгән кебек, театр булдырмау өчен башлаган көрәшне дә мәкерле рәвештә дәвам иттерделәр. Әмма моның да чиге якынлаша бара иде. 1905 елның көзендә Оренбург театр сөючеләренең спектакльләрен тыюлары властьларның соңгы хурлыклы «җиңүе» була. Казан Укытучылар мәктәбендә укыганда, Ф. Әмирханнар белән аралашып, театрга гашыйк булган И. Кудашев (Ашказарский) Оренбургка эшкә килгәч, үз тирәсенә һәвәскәрләр җыеп, спектакль куярга алына һәм, А. Островскийның «В чужом пиру похмелье» пьесасын татарчага күчереп, спектакль хәзерли, афишалар тарата. Менә шунда кара көчләр тагы хәрәкәткә килә, һәм губернатор тамашаны тыя. Әмма бу реакциянең соңгы тантанасы була. Беренче рус революциясе ташкыннары самодержавиене бик нык какшата, куркуга сала. Нәтиҗәдә аның газета-журнал чыгаруга, театрлар булдыруга, төрле культура оешмалары төзүгә каршы килә алырлык көче калмый. Менә шундый шартларда Казанда һәвәскәрләр труппасы 1906 елның 22 декабрендә «Кызганыч бала» белән «Гыйшык бәласе» спектакльләрен рәсми рәвештә тамашачыга күрсәтә. Бу спектакльләрдә катнашалар: Зәйнәп Габитова-Терегулова (сәхнәдә Хаҗаева һәм Солтанова), Суфия Коләхметова (Морадова), Әминә Терегулова (Гәрәева), Рабига Габитова, Әбүбәкер Терегулов (Юнысов), Шакир Мөхәммәтъяров, Газиз Сәйфелмөлеков, Шәриф Сүнчәләй, Гариф Габитов, Габдрахман Мостафин, суфлер Гыймад Нугайбәк. Моннан соң куелган спектакльләрдә Шәмсекамәр Коләхметова, Гайшә Богданова, Гафур Коләхметов (сәхнәдә Ширалеев), С. Газизов, С. Рәмиев, А. Кайбышев һ. б. катнаша. Бу труппа «Яшьләр» дип атала башлый. Беренче ачык спектакльләргә рөхсәт сорап язылган прошение Ибраһим Терегулов исеменнән бирелгән. Бу труппаны оештырып җибәрүчеләр арасында Ф. Әмирхан, Г. Колахмәтов, М. Вахитов, Г. Мостафин, Ç. Рәмиев, И. Кули һ. б. була. Бу тарихи вакыйганы ул чорда инде барлыкка килгән вакытлы милли матбугат күтәреп ала, һәм 1906 елның 22 декабре татар театрының туган көне булып тарихка керә. Г. Ибраһимов татар театрының нинди шартларда тууын тикшергәннән соң, аның кара көчләргә каршы көрәштә үсә, көчәя барганын күрсәтеп болай дип язды: «... ике кара көчне: 1) татар феодаль кара динчелеге белән, 2) рус алпавыт самодержавиесен җиңеп, иркен дөньяга чыга алуы — тик 1905 нче ел революциясе аркасында гына мөмкин булды. Бу революция татар театры өчен җиңел туруга ярдәмчелек ролен уйнады... Татар театрының ул беренче башлангыч еллары 1905 ел революциясенең каты көрәшләре астында булганга, байтак революциячелек рухы бар иде[12].

•••••••••••••••••

---

[12] Ибраһимов Г. 20 еллык көрәш бәйрәме. Китапта: «Татар театры 1906—1926», Казан, 1926, 6 б.

**Гомәр Бәширов**

# АНЫҢ ТЫЛСЫМЛЫ КӨЧЕ



Сара ханым Садыйкова Татарстан иҗат интеллигенциясенең иң популяр бер вәкиле булып, талантлы композиторларыбызның берсе булып көнелләргә кереп калды. Ничә дистә еллар буена ул безнең белән янәшә яшәде, үзенә шөһрәт алып килгән популяр җырларын безнең күз алдыбызда диярлек язды. Без, шагыйрьләр һәм әдипләр, авылларда һәм шәһәрләрдә, төрле тамаша залларында аның белән бергәләп әдәби-музыкаль кичәләр, очрашулар уздырдык, шау-шулы җыелышларда бергә булдык. Аның нечкә зәвык белән җиһазландырылган курчак өедәй җыйнак фатирында кайчакларны музыка хакында, теге көй, бу көй турында кайнар бәхәсләр дә кузгалгалый иде. Без аны гомеренең аерылмас юлдашы булган пианиносы янында да еш күрдек. Концертларда, көн саен диярлек радиода аның җырларын ишетеп, күңелебез хушлана, ул безнең көндәлек гадәтебезгә әверелгән, гомер буена шулай дәвам итәр кебек тоела иде. Сара ханым арабыздан китү белән, тормышыбызның кай төшедер кинәт бушап калгандай булды, нәрсәдер, җанга бик якын бер «нидер» юксындыра, сагындыра башлады. Соңыннан гына бөтен тирәнлеге белән аңладык: Сара ханым, танылган композитор булудан тыш, әле бик күбебезнең якын дусты, ышанычлы сердәше, фикердәше дә, сәнгать юлына яңа гына аяк баскан яшь шагыйрь һәм җырчыларның тәҗрибәле остазы, киңәшчесе дә, иҗат юлында-таләпчән ярдәмчесе дә иде бит. Үзенең шушы асыл кешелек сыйфатлары белән ул әдәбият һәм сәнгать даирәсен ничә еллар буена тулыландырып, баетып яшәде. Аның беркайчан да күңел төшенкелегенә бирелми торган күркәм холкы мине һәрвакыт сокландыра иде. Сара ханымның көләч йөзе әле дә күз алдымда, шат тавышы әле дә колак төбемдә.

Кыскасы, соңгы ун-унбиш ел эчендә Сара ханымның тормышы безнең күз алдыбызда үтте диярлек. Шулай да ул минем өчен һаман да укыла гына башлаган мавыктыргыч серле китап булып калды. Анда чит күзгә ансат кына ачылмый, әмма һәрдаим үзенә җәлеп итеп, сокландыра, үзен-үзе сөйдерә һәм шул ук вакытта гаҗәпләндерә торган ниндидер бетмәс-төкәнмәс, армас-талмас тылсымлы көч бар иде ахрысы. Менә мин шул гаҗәеп көчнең серен ачасым килеп, бик ерагта ук калган озын-озак гомернең аргы якларын исемә төшереп утырам.

Музыка дөньясында Салих Сәйдәшевнең зур таланты гөрләп чәчәк аткан, Татар академия театрында Кәрим Тинчурин, Мохтар Мутин, Гөлсем Болгарская, Фатыйма Ильская, Хәлил Әбҗәлилов, Зәйни Солтанов кебек сәхнә корифейларының мәйдан тоткан истәлекле еллары иде бу. Шушы зур талант ияләре арасына егерменче еллар башында дәртләре ташып торган сәләтле яшь көчләр — Галия Кайбицкая, Сара Садыйкова килеп керәләр. Мәгълүм ки, безнең Академия театры, «Сәйяр» труппасыннан ук калган элекке гадәт буенча, сәхнәгә куелган байтак драма һәм комедия әсәрләрен музыка һәм җыр белән баетып бирергә ярата. Әлеге яшь җырчылар башта әнә шул

спектакльләрдә, төрле концертларда катнашып таныла башлыйлар. Сара Садыйкованың иҗат юлы әнә шуннан башланган.

Үзенең ничек җырчы булып китүе турында Сара ханым болай сөйли торган иде:

— Безнең гаиләдә җырны, музыканы бик яраталар иде. Әле дә хәтерлим: әнкәм үздереп-үздереп гармун уйный, мин, сабый, шуңа хәйран калып, сокланып утырам. Миндә дә шундый дәрт кузгалды: алты яшемнән үзем дә гармун уйный башладым. Аннары пианинода. Яшьтән үк концертларда катнаштым. Менә Академия театрында «Бүз егет» пьесасын куйдылар. Анда мин хан кызы ролен уйнадым. Шуннан соң, 1922 елда Татарстан хөкүмәте мине Мәскәү консерваториясенә укырга җибәрде...

Менә афишаларда берзаман «музыкаль комедия», «милли опера» дигән яңа сүзләр пәйда була. Билгеле, классик операларны Мәскәүнең үзендә яисә Ленинградта карап гадәтләнгән зыялылар бу спектакльләргә берникадәр икеләнебрәк, хәтта шигәебрәк баралар. Опера бит бай сәхнә тәҗрибәсе, зур талант, нечкә зәвык таләп итә. Безнең яшь артистлар андый спектакльләрне күңелләргә үткәреп, эстетик ләззәт бирердәй итеп башкара алырлармы?

Баштарак шундый шөбһәнең булуы табигый иде. Әмма кыбәләктәй җиңел гәүдәле, яшьлек матурлыгы белән үк үзенә җәлеп итүче Сара туташ сәхнәгә берьюлы мөлаемлык та, нәзакәт тә, ялкынлы дәрт тә алып чыга. Чөнки сәхнә өчен яралган була бу зат. Тамашачыга аның колоратуралы сопраносы гына, тавышының кабатланмас үзенчәлекле тембры гына түгел, бәлки бөтен җаны-тәне белән бирелеп уйнавы, табигый сөйкемлелеге дә тәэсир итә. Яшь артистканың музыкадан, сәхнә уеныннан алган эмоциональ ләззәте, хуш авазлар дулкыны булып, тамашачыга да барып җитә, аның да күңелен кузгата иде. Шунда инде театрга шигәебрәк аяк басучылар да чын күңелдән кул чабарга тотыналар иде.

Менә шулай. Хәзерге заман кешесенә үзен талантлы композитор итеп таныткан Сара ханым элегрәк елларда профессиональ осталыкка ирешкән талантлы опера артисткасы иде әле. Күрәсең, аның җырга булган чиксез мәхәббәте дә яшь чакларында ук бөреләнеп, соңгарак кына чәчәк аткандыр. Өлкәнрәк буын кешеләре, ул елларның музыкаль комедия һәм опера сөючеләре Сара ханымны «Эшче» операсында — Сәлимә, «Сания» операсында Сания итеп күрделәр. Ул «Башмагым» музыкаль комедиясендә Сәрвәр, «Наемщик» музыкаль драмасында Зөбәрҗәт, «Аршин мал алан» опереттасында Асия булып та уйнады. Татар опера театрының беренчеләрдән булып пәрдәсен күтәргән артистка булуы, милли опера сәнгатен тудыруга зур көч салуы өчен Сара ханым шул елларда ук «Татарстанның халык артисткасы» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Татар совет музыкасы тарихына күренекле затлардан берсе булып кереп калу өчен шул мактаулы хезмәт үзе генә дә бик җиткән булыр иде. Ләкин, бәхеткә каршы, Сара ханымга сәнгать дөньясында тагын бер балкып алырга, тагын бер бәхетле иҗат гомере кичерергә насыйп булды. Чөнки табигать аңа башта ук талантның төрлесеннән мул өлеш чыгарган, сирәк очрый торган композиторлык талантын да бүләк иткән, тормыш аны музыка сәнгатенең тагын да югарырак, хөрмәтлерәк баскычына күтәргән.

Бу хәл заманында күпләрне гаҗәпкә калдырды.

— Ничек шулай һич көтмәгәндә җырчы... композитор булып китте соң әле? — диештеләр.

Көтелмәгәнме икән? Сәхнәне яшьләргә калдырып, театрдан берникадәр читкәрәк китсә дә, артистканың музыкадан беркайчан да аерылганы булмаган. Күңел җырын ул өзлексез дәвам иткән — уйланган, моңланган. Иң зур шатлыгын да, иң ачы хәсрәтен дә, иң нечкә күңел тибрәнүләрен дә Сара ханым пианино янына утырып, иң якын дусты, сердәше, юанычы һәм куанычы булган музыка белән уртаклашкан. Аның нотага салган беренче көе дә иң кыен сугыш елларында мөлдерәп торган ил хәсрәтенең бер тамчысы булып барлыкка килгән.

Уйлап карасаң, табигатьнең адәм баласы аша гамәлгә ашырган бихисап могҗизалары, яшәешнең кеше күңеленә иңдергән биниһая серләре хәйран калдыра. Ничек әле ул бер кешенең күңеле түрендәге шәхси кайгы-хәсрәте, юксынуы, өзелеп сагыну хисе миллионнарның йөрәгенә шифа булып тәэсир итәрдәй якты моңга, хушавазлар хикәясенә әверелә? Сара ханым гомеренең уртасында әнә шул кадерле моңнарны, адәм баласының күңел серләрен башкалар да аңларлык итеп әйтеп бирүче «көйләр остасы» булып китә.

Сара ханым беренче җырының көе һич кѳтелмәгән урында — трамвай тукталышында күңеленә килүе хакында сөйли торган иде:

— Каһәр төшкән сугыш газраиле мине иң, иң газиз кешемнән аерды. Мин аны оныта алмадым, бик сагындым, һаман юксындым. Әнә шул сагынуларым-юксыну моңнарым, йөри торгач, күкрәгемә сыя алмыйча, бер көнне шушы көй булып тышка бәреп чыкты...

Без ул җырны сирәк кенә булса да радиода әле хәзер дә ишеткәлибез:

Син кайларда йөрисең икән,
Алтыным, күләч йөзле иркәм.
Кайтырсың дип мин өмет итәм,
Мин сине һаман көтәм, көтәм...

Беренче мәртәбә ишеткәндә бу җырның үзенә ничек көчле тәэсир итүен композитор Әнвәр Бакиров әле хәзер дә дулкынланып сөйли:

— Фронтка узышлый беразга гына Казанга тукталганда, радиода яңа бер җыр ишеттем. Бу җырның музыкасы әчке моңы, формасының камиллеге белән миңа бик ошады. Һәркемгә мәгълүм, бик хәвефле еллар иде. Өйдән чыгып киткәндә, телдән әйтмәсәң дә, күңелдән:

Я кайтырбыз, я кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар...—

дип, хушлашып киткән чаклар иде бу. Композиторларның күбесе фронтта иде. Шундый дәһшәтле вакытта да музыка дөньясының тынсыз ятмавы, яшь талантлар пәйда булуы мине канатландырып җибәрде. Фронттан кайткач кына белдем: бу Сара апа җыры булган икән.

Шул еллардан башлап гомеренең соңгы көннәренә кадәр Сара ханым татар музыкасын өч йөздән артык яңа җырга баетты, ике комедиягә музыка язды, романслар, вальслар иҗат итте.

Һәркемгә мәгълүм: татар музыка сәнгатендә җыр жанры әлек-әлектән иң күренекле урыннарның берсен алып килә. Опера, симфония кебек катлаулы жанрларны һәркем дә аңлап житкермәскә мөмкин. Җыр исә, музыканың иң популяр, иң аңлаешлы жанры буларак, бик борынгы заманнардан бирле үк халыкның тормышын бизәп, башка берни белән дә чагыштырып булмый торган, һәрвакыт тансык һәм кадерле күңел ачу чарасы, эстетик, әхлакый тәрбия чарасы булып килә. Бу чиксез бай рухи хәзинәне С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Р. Яхин кебек зур талантларның өзлексез баетып, яңартып торуларын да истән чыгармыйк. Сара ханымның хәтта менә шундый бай хәзинәгә дә ифрат үзенчәлекле һәм күп санлы иҗат җимешләре өстәргә көче җитте.

Шуның өстенә, бу талпанчан художник музыкаль әсәрләрне никадәр генә күп иҗат итмәсен, үзен дә, башкаларны да кабатламады. Аның музыкаль палитрасы ифрат бай иде. Һәр җырының үзенә генә хас оригиналь аһәңе була, ул милли бизәкләрне нәкъ үз урынында, фәкать кирәгенчә генә куллана, һәр әсәре кеше рухының нинди дә булса бер нечкә кылын чиертеп ала, уй-хисләрен кузгата иде. Ул язган көйләрдә без күкләргә ашыра торган патетик аһәңнәр дә, борчу-кайгы белмәс шат күңелле яшьлек, батырлык ашкынуларын да, лирик җырларында, табигый буларак, тирән кичереш, юксыну, сагыну моңнарын да ишетәбез. Аның җырлары якты моңга, музыкаль гүзәллеккә бай, алар тыңлаучының күңелен күтәрәләр, анда тормышның ямен, кадерен белү тойгысы уяталар. Шул сәбәпле, Сара Садыйкова җырларын тыңлаганда, рәхмәт хисләре белән аның үзен дә искә алалар.

Сара ханым үзенең иҗатына ифрат талпанчан булды, һәрбер әсәрен тәмам камиллеккә ирешкәнче эшләде. Ул үзенең иҗатына ике нәрсәне якын да китермәде: битарафлыкны, төшенкелекне. Язган көйләре, аның үзе шикелле үк, күбесенчә күләч йөзле, шат күңелле булып туалар иде. Никадәр әсәрен ишетеп тә, мин аның эленке-салынкы, пассив интонациядә язган бер җырын да хәтерләмим.

Бу уникаль шәхеснең музыкабыз фондына нинди мирас калдыруы, халык арасында нинди популярлык казануы хакында тәфсилләп язып торуның бәлки кирәге дә юктыр? Үзебезнең Идел буенда аның ни дәрәҗәдә танылган кеше булуы бик мәгълүм нәрсә. Сара ханымның җырларын Уралның бирге һәм аргы ягында, Казахстан далаларында, Урта Азиядә, Мәскәү һәм Ленинград якларында да бик яратып җырлыйлар. Ул әнә шул төрле тарафларда яшәүче төрле халыкларның музыкаль зәвыкларын канәгатьләндерерлек киң сулышлы, озын гомерле җырлар язып калдырды.

Шулай да композиторның халык аеруча хуплап каршы алган кайбер көйләрен тирән ихтирам белән телгә алып узасым килә. Менә алар: «Казан кичләре», «Дөнья матур, дөнья киң», «Минем республикам», «Өченче көн тоташ кар ява», «Җидегән чишмә», «Тын сукмакта тал тирбәлә», «И, язмыш, язмыш...», «Үз илемдә», «Уфа ни өчен матур» һәм тагын байтак җырлары. Болар, минемчә, теләсә кайсы композиторның визит карточкасы булып хезмәт итә алырлар иде.

Бу композитор иҗатында минем игътибарымны җәлеп иткән тагын бер «сер» — әсәрнең эчтәлеген музыка теле белән дә әйтеп бирә алу осталыгы. Сүз белән язылган мәгънәне аның музыкасы шулкадәр күңелгә үткәзә, син инде бу эчтәлекне нәкъ шушы көй генә әйтеп бирә алганын, моңа башка музыка язу мөмкин түгеллеген тоясың. Һәрхәлдә, тыңлаучыда шундый тәэсир туа. Бу хакта минем композиторның үзе белән дә сөйләшкәнем бар.

— Белмим, алай ук чагыштыру урынлымы икән? Болар бит сәнгатьнең ике төре,— диде ул.

Җырлар хакында сүз чыкканда, ул пианиносы янында утырып сөйләшергә ярата иде. Нинди дер катлаулы уйларына җавап эзләгәндәй, ул сүз арасында пианино телләренә тиеп алгалый. Күрәсең, авазлар аның уйларына үз телләрендә җавап бирәләрдер, бу аның сүзләренә куәт була торгандыр.

— Бәлки монда Пушкин фикерен искә төшерү урынлы булыр? Ул, сүзнең көче җитми башлаган урында музыка телгә килә, дигән түгелме?

— Менә, менә, нәкъ үзе! Әгәр дә тексттагы эчтәлекне музыка белән тагын да тирәнрәк, тагын да тәэсирлерәк итеп әйтеп бирәсең икән, бу инде шатлык, бу инде бәйрәм!

Сара ханым кинәт кенә пианиносына борылды да дәртле авазлар дөньясына күчте. Язгы ташкынның тыелгысыз сикерә-сикерә шаулап агуын хәтерләтеп, ниндидер бер ярсулы көй уйнарга тотынды. Уйнаганда ул бөтенләй үзгәреп, тагын да җанланып китте. Аның бармакларына күз иярми, ул әле кашларын җыера, әле ниндидер тирән шатлык кичергәндәй елмаеп ала, кинәт чырае яктырып китә. Мондый минутларда ул яше сиксәнгә якынлашып килүен дә, бик үк сәламәт булмавын да онытып җибәрә, үзен чын-чыннан бәхетле хис итә иде. Шунда мин Сара ханымны, төрле чәчәкләрдән тәкыя үргән шикелле, нәфис авазлардан музыка нәкышләре үрә белүче тылсымчы, могҗизачы итеп күрә башладым.

Сара ханым үзенә дә, башкаларга да ифрат таләпчән музыкант иде. Чөнки ул композиторның музыка дөньясында нинди җаваплы һәм хөрмәтле урын тотуын бик яхшы белеп яшәде.

«Җидегән чишмә» җырының музыкасын язарга алынганнан соң берәр атнадан Сара ханым аңа көй язуы хакында әйтте.

— Язуын яздым да, үземне бик үк канәгатьләндерми әле,— диде.

Икенче атнада җыелышта очратып, яңадан шул хакта сүз кузгатты.

— Синеңчә, ул җырның көе ниндирәк булырга тиеш? — диде.

— Аның музыкасында халыкның табигатькә мәхәббәте сизелсен иде. Аннары килеп, халыкчан булуын теләр идем. Аны бит халык җырлый. Текстында халыкның гореф-гадәтенә дә басым ясала: чишмә — кыз белән егетнең вәгъдәләшү урыны, йөзек, җидегән йолдыз, хушлашу...

Сара ханым тыныч сукмакларны бик үк өнәп бетерми, аның үз фикерен ап-ачык итеп, турыдан бәреп әйтү гадәте бар иде.

— Ә «халыкчан» дигәнне син ничек аңлыйсың? Халык җырларына охшатып язу дип түгелме? — диде ул.

— Һич алай түгел,— дидем мин.

Композитор «халыкчан»лыкның нинди мәгънәдә йөрүен үзе дә яхшы белә иде, билгеле. Күрәсең, аңа бу төшенчәне киңәйтебрәк аңларга кирәк булгандыр.

— Сез халык җырларын турыдан-туры үз әсәрләрегезгә күчермисез бит, шулаймы?

— Шулай. Мин халыкчанлыкны Сәйдәшчә аңларга тырышам. Тик халыкчан дигәннән... халык та мәңгегә бер төрле генә булып калмый бит, ул да үзгәрә.

— Берәр мисал да китерсәгез! — дидем мин.

— Мисалы шул — «Карурман» җыры чыккан заманнарда халыкның тормышы да башкарак, җырлары да сагышлырак булган. Әйеме? Ә хәзерге заман яшьләре сузынкы көйне түгел, җанлы ритмны, җитез хәрәкәтне ошатарак төшәләр.

— Димәк, нишлибез соң инде?

Сара ханым, гадәтенчә, рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Димәк, шундый көй язарга туры килә инде: үзе халыкчан да булсын, әмма анда хәзерге заман сулышы да сизелеп торсын! — Ул кинәт җитдиләнеп китте, сер сөйләгәндәй тавышы да акрынайды.— Беләсеңме, ул көй миңа унбиш көннән бирле тынгылык бирми инде, мин аны ике атна буена эзлим. Күңелемнән чишмә тавышларын да, кошлар сайраганны да тыңладым, романыңны да укыдым, ямь-яшел болын буйларында да йөрдем. Кайчакларны күңелгә ятышлы кирәк авазлар да ишетелгәли, менә-менә көй башланып та китәр шикелле. Табам мин ул көйне, табам!..

Сүзендә торды композитор, «тапты» ул көйне. Аның көчле таланты җырны иң популяр әсәрләрнең берсе дәрәҗәсенә күтәрде.

Миңа Түбән Камада, аның авылларында, Казанның үзендә Сара ханым белән берничә әдәби-музыкаль кичәдә, төрле очрашуларда катнашырга туры килде. Шул кичәләрдә минем өчен аның тагын бер күркәм сыйфаты, популярлыгының тагын бер «сере» ачылды. Бу — Сара ханымның халыкка булган зур ихтирамы, тирән мәхәббәте.

Менә сәхнәгә җыйнак гәүдәсе белән яшьләрчә җиңел генә атлап, Сара ханым килеп чыга. Аның күзләре нур чәчә, йөзе тулган ай төсле. Ул сәхнә кырыена ук килеп баса да, кулларын күкрәгенә кушырып, ягымлы, йомшак тавышы белән:

— Дусларым, туганнарым! Мин сезне бик-бик яратып, якын итеп килдем! — ди. Шулкадәр ихлас күңелдән, җаннарны эретердәй итеп, күңелләрне тетрәтеп әйтә, бу сүзләр залда да шундый ук дуслык, туганлык тойгысы кабызып җибәрә һәм тамашачы дәррәү килеп кул чабарга тотына. Һәм шул сулыштан Сара ханым тамаша залын бөтенләе белән үз кулына алып, аның белән үзе идарә итә башлый. Ул, көлдерә-көлдерә, үзенең ничек артистка булып китүен сөйли, пианинода әле кичә генә язган яңа көен уйнап күрсәтә, әгәр кирәк икән, үзе уйнап, үзе үк җырлап та җибәрә. Ничә тапкырлар сокланып утырганым бар — сәхнә Сара ханымның стихиясе, тормышының иң җанлы, күңелендә канәгатьлек тудыра торган иң нәтиҗәле бер өлеше иде. Шактый өлкән яшьтәге бу ханым сәхнәгә килеп чыгуы белән кинәт яшәреп, матурланып китә, тавышы да көрәя, батырая бара, ул халыкка җан азыгы бирә алуы, аны рухландыруы белән, үзенең аңа кирәклеге белән илһамланып, шуннан җан рәхәте табып сөйли иде. Сара ханым сәхнәдә чагында тамаша залында бер генә дә битараф, ваемсыз чырайны күрми идең.

Минем бу хакта уйланганым бар. Сара ханымның әнә шулай килеп чыгуы белән бөтен тамаша залын «яулап алуында», һичшиксез, аның артистлык талантының да зур өлеше бар иде. Ләкин ул гына да түгел. Моны Сара ханымның халыкка булган тирән ихтирамының сәхнәдә гәүдәләнеше дип карарга кирәктер. Шәһәрдә булсын, авылда булсын, композитор үз чыгышларының һәркайсына, авыр фәннән имтихан бирергә җыенгандай, бөтен дөньясын онытып, барлык тырышлыгын куеп әзерләнә торган иде. Әйтерсең, ул әдәбият һәм музыка сөюче гади кешеләр каршысына түгел, бәлки миллионлаган шәхесләрне берләштерүче халык дигән бөек бер көч каршысына килеп чыга. Сара ханым гомере буена әнә шул бөек көчнең шатлыгына куанып, кайгысына кайгырып, үзенең зур таланты һәм тырышлыгы белән аның таләпләренә җавап бирергә, Салих Сәйдәшев мәктәбен дәвам иттерергә, аны тагын да баетырга омтылып яшәде.

Сара ханым Садыйкова, үзенең замандашлары белән якыннан аралашып, алар белән кулга-кул тотынып, озын-озак һәм бәхетле иҗат юлы узды. Ул киң күңелле, күркәм холыклы кеше, сәнгать әһелләренең, бик күп әдип һәм шагыйрьләрнең, атап әйткәндә, Хәсән Туфанның, Сибгат Хәкимнең якын дусты иде. Бик күп җыр текстлары авторы Гөлшат Зәйнашева белән дә аны якын дуслык җепләре бәйли иде. Культурабызга бай мирас калдырган композиторның бик күп әсәрләре татар музыкасының беркайчан да искерми, кадерен югалтмый торган алтын фондына керде.

Безнең халыкның әдәбиятта югалмаслык эз калдырган мәшһүр шагыйрәләре, сугышларда дан казанган Мәгубә Сыртланова кебек батыр кызлары бар. Җырчы һәм композитор Сара Садыйкованың якты истәлеген дә халык әнә шул кызларының истәлеге белән бергә киләчәккә алып барачак.

**Нури Арсланов**

# ЯКЫН ДУСЛАР ИДЕК

Замандашым Байназар турында сөйләгәндә аның мөлаем сурәте күз алдына баса. Куе кара кашлары астыннан сөйкемле елмаеп торучы коңгырт күзләрен әз генә кыса төшеп каравы, иреннәренең, әле берни дә әйтмичә, нидер әйтергә җыенгандай, сизелер-сизелмәс дерелдәве, көр тавыш белән көлеп исәнләшүе, бүгенгедәй күзгә күренеп, колакка ишетелеп, Байназарны исәннәр арасында исән иттереп гәүдәләндерә.

Байназар Әлминов татар сәнгате үзәге Казанга Бөек Ватан сугышына кадәр үк килде. Ул вакытларда мин дә графика белән беркадәр шөгыльләнә идем. Ләкин Байназарның рәсемдәге нык кулын, маһирлыгын күреп бик сокландым, безнең кебек бизәүчеләрдән күп өстен булуын аңлап, иҗади көнләштем һәм аны чын күңелдән хөрмәт итә башладым.

Замандаш рәссамнардан П. Григорьев миңа: «Син татар художнигы, Тукай шигъриятен яхшы беләсең, рус сынлы сәнгатендә Врубель тудырган Пан сурәте шикелле, нигә үз милли сәнгатеңдә Шүрәле сурәтен җанландыру турында уйламыйсың?» — дип, ярым шелтәләп, бик кызыклы фикер әйткәне әле дә исемдә. Ул сурәтне иҗат итүдә безнең танылган рәссамнарыбыз күп көч куйдылар, эзләнделәр, һәм, бәхеткә каршы, Шүрәле сурәте төрле вариантларда гәүдәләнде. Аны тудыруда рәссам Байназар Әлминов җиң сызганып эшләүче һәм уңышка ирешүче беренчеләрдән берсе булды. Аның рәссам буларак Г. Тукай иҗатына карата тирән һәм җитди игътибары — шагыйрь әсәрләрен бизәү-сурәтләү тәҗрибәсенә чынлап тотынуы да шул вакытлардан башланып китте дисәк, ялгышмабыз кебек.

Әдәбиятыбызны белү ягыннан, элекке һәм хәзерге шигъριяттән хәбәрдар булу ягыннан Байназар рәссамнар арасында үзенә аерым бер урын тота иде. Мин сынлы сәнгать осталары белән аралашып яшәгәнгә, аларның нинди зәвыкка ия булуларын, нәрсә белән кызыксынуларын, әдәбият мәсьәләләрендә ни дәрәҗәдә хәбәрдар икәнлекләрен белеп, сизеп йөри идем. Ләкин Байназар кебек рәссамны — әдәбиятны һәрьяклап, бөтен нечкәлекләре белән белгән кешене очратуы җиңел түгел. Байназар Шәрык шигърияте вәкилләре Низами, Ширази, Фирдәүсиләр белән кызыксынган кебек, безнең Кол Гали, Сараи, Кандалый, Акмуллаларыбызны да, Тукай, Дәрдмәнд, Рәмиев, Такташ, Туфан, Җәлилләребезне дә яхшы белә, алар шигъриятенә мөкиббән кеше иде.

Сугыш вакытында мин яраланып, госпитальдә ятып чыккач, Байназар мине үзенә чакырып алды. Минем «Зоя» («Рус кызы») дигән поэмам әле генә китап булып чыккан чак иде. Ул минем беренче китабым иде. Шактый әңгәмәләшкәннән соң мин поэманы Байназарга укып чыктым. Ул миңа: «Дөресен әйткәндә, Нури, мин бу поэманы нәшриятта укыган идем инде. Художник та шигъри әсәр язарлык бай телле була ала икән дип, исем киткән иде»,— диде.

Ул вакытларда Байназар худфондта эшли торган булып чыкты. Беркөнне ул миңа буяулар, киндерләр һәм рәсем өчен башка кирәк-яраклар бирде: «Син фронтның үзендә булган кеше, бәлки, сугыш дәһшәтләрен полотнода чагылдырырсың?!» Ләкин соңыннан шаярып: «Ул вакытта мин синең «акварельче» икәнлегеңне онытып җибәргәнмен, сиңа майлы буяулар белән киндерләр түгел, карандаш, кәгазьләр бирәсе калган, сугыш дәһшәтләрен син төшермисең, ә язасың»,— диде.

Байназар, гаиләдә булсын, дуслар белән булсын, үзен гади тотты, һаваланмады, шуңа күрә, аның белән бергә булу, сөйләшү, очрашулар һәркемнең дә күңелендә ягымлы тәэсир калдыра, җанга җылы бирә иде. Базарга барып, итнең сум җирен яки яхшы каз сайлап алу аның яраткан вазифасы булып, бу яктан ул мәрхүм Кави Нәҗмигә бик охшаш иде. Нәшрият коридорын тутырып килгән чакларында һәрвакыт анда бер яңа анекдот булыр, һәм ул аны ашыкмый, түкми-чәчми, ыспайлап «тәштит»ләрен җиренә җиткереп сөйләп бирер иде.

Байназар белән очрашкан чакларда безнең гәпләшү темаларыбыз сынлы сәнгать һәм әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы була торган иде. Ул сынлы сәнгать классикасын,

минем шикелле үк, бик ярата һәм аны сәнгатьтә барлык нигезләр нигезе итеп саный. Италия рәссамнарыннан Рафаэль, Леонардо да Винчи, Микельанджелоларга сокланып, Франциянең Давид, Делакруа кебек бөек күтәрелешләр дәвере осталарын, Гоген кебек лирик «сәйяхлар»ын, соңгарак — Пикассоларны, сәнгатьтә гаҗәп каршылыклы агымнарны, Испаниянең Веласкес, Гойяларын һәм башка бик күпләрне искә алырга яратадыр иде. Дустым Байназарның тарихка мондый мөнәсәбәте дә безне рухи яктан үзара якынаюга илткәндер. Ул һәрвакыт: «Художникның кулыннан һәрни килгән кебек, ул һәрбер әйберне белергә дә тиеш!» — дия торган иде. Әнә шул девизы инде аны күп әйбер белән кызыксынырга, күп белергә өндәгән дә булса кирәк.

Байназар Әлминовның Казан шәһәренә килгәндә үк инде нык куллы, үткен һәм дөрес күрүчән рәсем остасы булуы турында мин башта бер ымлап үткән идем. Ләкин ул графикада гына түгел, җанлы язуда да, аның да иң җитди һәм катлаулы өлкәсе — портрет жанрында да эзләнде. Мин аның Бөек Ватан сугышы елларында язган Гадел Кутуй портретын хәтерлим. Зәңгәрсу-яшел гаммаларда майлы буяулар белән язылган бу портрет миндә, беренче карауга, яз исен, яз җылысын һәм шул фонда оптимист шагыйрьнең җан җылысын бергә үрелдереп, аның елмаерга әзер торган авызыннан шигырь яңгырап чыгар төсле тойгы уяткан иде. Кутуйны бик якыннан белгәнгәдер ахры, рәсеменә карау белән, аның трибунлык сыйфаты да, гади, тайнак кешелеге дә, менә-менә елмаеп көлеп җибәрергә торган матур иреннәре дә җанланып күз алдыма килде. Рәссамның бу рәсеме нишләптер аның күргәзмәсендә күрсәтелмәде. Бәлки ул портрет техник яктан һәм хәзерге таләпләр ягыннан кимчелекле дип табылгандыр. Шулай да, эзләнү процессында бер кыю адым буларак кына булса да, авторның андый хезмәтләренә игътибарсыз калырга ярамас иде дип уйлыйм.

Әйе, рәссам эзләнде. Ниһаять, байтак елларга сузылган эзләнү аны иң дөрес, иң кирәкле юлына — график сәнгать юлына алып чыкты. Бу сәнгатькә ул үзе дә эзләнү елларында күп вакыт һәм зур игътибар бирде. Уннарча еллар буена, мәсәлән, Г. Тукай әсәрләрен бизәү, аның каһарманнары образларын рәсемдә җанландыру эшендә күп көч куйды. Тукай-Кырлайдагы музей-йортта зур урынны Әлминов рәсемнәре экспозициясе алып тору — шул тырыш һәм талантлы хезмәтнең күзгә күренеп торган нәтиҗәсе.

Байназар белән икебезнең арада да иҗади хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнерлек рәсемнәр барлыкка килде. Иң беренче булып ул минем «Рус кызы» поэмасына иллюстрацияләр ясады. Китап аерым басмада дөнья күргән иде. Тышлыгы да, эчке рәсемнәре дә бербөтен итеп ясалып, ул вакыттагы басмалар арасында китап бик матур булып чыкты. Соңгарак минем кайбер китапларыма да тышлыклар аның тарафыннан эшләнде. Ә Байназар дусның үземә багышлап эшләгән иң соңгы һәм иң зур эше минем портретым булды. Ул портретны автор миңа 60 еллык кичәмдә бүләк иткән иде. Якын дустымнан калган бу бүләкне мин бик кадерләп саклыйм. Рәсемгә караган саен үзен искә алам.

Байназар Әлминов татар совет художниклары арасында үзенә аерым бер күренекле урын алып тора. Ул — безнең график сәнгатьне башлап җибәрүчеләрдән, бүгенге хәленә җиткереп үстерүчеләрдән берсе. Беренчеләрдән берсе! Аның исеме — бу яктан караганда да, күп кенә яшьләргә остаз булуы ягыннан да телдән төшмичә озак еллар яшәргә, хөрмәт белән искә алынырга лаек, кадерле исем.

**Рафис Әхмәтов**

# ШӘМДӘЛЛӘРДӘ — ЯКТЫ УТЛАР...

*Татар әдәбиятының... беренче кадим дәверендә... Гали Чокрый кебек талантлы шагыйрьләр күрәчәкмез. Болар һәммәсе үз заманнарының балалары иде; ...шул дәвернең икътисади-мәдәни туфрагында үскән гөлләр уларак җитештеләр.*

Галимҗан Ибраһимов

Урта гасыр татар әдәбияты мәшһүр шагыйрьләргә, гали затларга гаҗәеп бай: Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Габдерәхим Утыз-Имәни, әл-Болгари, Әбелмәних Каргалый, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Каргалый, Габделҗәббар Кандалый, әл-Болгари һәм, ниһаять, Гали Чокрый әл-Болгари...

Күпгасырлы бай традициясе булган урта гасыр татар поэзиясе менә шулай мәшһүр Кол Галидән башланып, Гали Чокрый әл-Болгари исеме белән тәмамлана... Алга таба инде Акмулла, Акъегетләр яңа дәвер әдәбияты капкасын киң ачып, түргә узалар!

Талантларга бай XIX йөз татар поэзиясе күгендә Гали Чокрыйның да үз урыны, үз яктысы бар. Үткәннәргә йомгак ясаучы гына түгел, яңа дәвер шигърият диңгезенә коячак яңа ерганаклар ярып калдырган, иске-лек белән яңалык арасында барган кискен көрәшне сизгер шигъри җаны аша үткәргән, күпчелек башлангычларында фикер, рух кыйбласын Казаннан, Мәрҗаниләр, Насыйрилар мохитеннән эзләгән, үтә каршылыклы, әмма бик үзенчәлекле һәм кызыклы шагыйрь һәм шәхес булган ул.

Мөхәммәтгали бине Габдессалих бине Габдел бине Шәриф бине Киек бине Күчкән әл-Чокрый әл-Гари әл-Вади әл-Ирәктәви әл-Бөри әл-Киеки әл-Болгари (1826—1889)[1] — XIX гасыр татар поэзиясенең күренекле вәкиле генә түгел, бәлки оста прозаик, танылган мәгърифәт эшлеклесе дә. Г. Рәхим, Г. Газиз әйтүенчә, ул йөздән артык әдәби-гыйльми әсәр иҗат итеп калдырган. Кызганычка каршы, бу бай мирас әлегә хәтле тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән хәлдә Казан, Ленинград, Уфа китапханәләрендә һәм аерым кешеләр кулында саклана. Г. Ибраһимов 1923 елда ук «Татар әдәбияты тарихына материаллар» исемле рецензиясендә: «Хәлбуки, бездә эзләнгән вакытта, беренче кул материалларның ерак түгеллеге мәгълүм... Борынгы шагыйрьләрнең бере булган Гали Чокрый хакында тагы да ачыграк сөйләделәр. Яшь шагыйрь Кәрим Әмири әйтүенчә, шагыйрьнең туган иле Чокыр авылында бу хакта мәгълүмат табарга мөмкин»,— дип язган булган[2]. «Яшь шагыйрь» Кәрим Әмиринең арабыздан киткәненә дә инде байтак

---

[1] Боларның һәркайсы — шагыйрьнең төрле әсәрләрендә кулланган псевдонимнары: әл-Гари — гарәпчәдән, Чокыр — авыл исеме; әл-Ирәктави — ыруг атамасы, әл-Киеки — өченче өлкән бабасы исеме, әл-Бөри — өлә исеме.

[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда, т. 5. Казан, 1978, 369 б.

гомер узды, тик менә Гали Чокрый яшәгән, йөргән юллар буйлап махсус археографик эзләнүләр һаман да, төрле сәбәпләр аркасында, тоткарланып, кичектерелеп килена. Ә бит Г. Ибраһимов 1923 елда ук «борынгы шагыйрьләребезнең берсе» дип атаган Г. Чокрыйның вафатына да инде тиздән (1989) 100 ел тулачак. Димәк, Г. Ибраһимовның сүзләре бүгенге көндә икеләтә актуаль һәм вакытлы яңгырый.

Дөрес, XIX йөзнең башка каләм ияләре белән чагыштырганда, Г. Чокрыйны шактый өйрәнелгән һәм бәхетле язмышлы автор дип санарга мөмкин. Ә. Каргалый, Ш. Зәки, Г. Кандалый, мәсәлән, үз әсәрләрен басма китап рәвешендә күрмичә вафат булганнар. Мәгърифәтчелек хәрәкәте җырчысы Мифтахетдин Акмулла да исән чагында фәкать бер әсәре («Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе», Казан, 1892) басылып чыгуына шаһит булган. Г. Чокрый исә, татар мәдәнияте һәм әдәбияты чәчәк аткан мәгълүм төбәклрдән шактый читтә яшәп иҗат итүенә карамастан, уннан артык китабын Петербург һәм Казан басмаханәләрендә чыгаруга ирешә. Алай гына да түгел, шагыйрьнең вафатыннан соң да бу эшне улы Гарифулла Киеков һәм башка туганнары дәвам итә. Шуның аркасында Г. Чокрыйның әсәрләре белән гасыр башында ук Г. Тукайлар, Ф. Әмирханнар, Г. Ибраһимовлар таныша алганнар. Г. Чокрыйның тормышы һәм иҗат юлы хакында Р. Фәхретдинев «Асарь»да (11 җөзьә, 189—191 б.), М. Рәмзи «Тәлфик...» тә (11, 451 б.) язып чыгалар. Бөек Октябрьдән соң бу башлангычны Г. Газиз, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, Б. Яфаров, М. Гайнуллин кебек галимнәр дәвам итә. Ниһаять, А. Фәтхи шагыйрьнең Казан дәүләт университеты китапханәсендә саклана торган күпсанлы кулъязмаларына тәфсилле тасвирлама бирә, ә яңа гына дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче томында бу шагыйрьнең тормышы һәм иҗат юлына шактый тулы һәм яңача күзәтү ясала.

Шунысы куанычлы һәм игътибарга лаек: Г. Чокрый иҗатын бөек замандашлары — татар мәгърифәтчеләре Каюм Насыйри (1825—1902) һәм Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889) яхшы белгәннәр һәм югары бәяләгәннәр.

Г. Чокрый хаҗ сәфәрен башлар алдыннан еш кына Казанда була, берничә мәртәбә Каюм Насыйри белән күрешеп, озаклап сөйләшеп утыра. Улы Гарифулла истәлекләренә караганда, алар бик тиз уртак тел табып, тарих, әдәбият, тел турында фикер алышканнар. Г. Чокрый Каюм Насыйриның эшчәнлеген, бигрәк тә ел саен халыкка бик кирәкле календарь чыгаруын хуплый, үзенең дә шуның тәэсиренә бирелеп, календарь төзегәнлеген әйтә. «Минем һәм «Гөррәи галийә вә мирьател әһиллә»[3] исемле гөррәллекләрем бар иде, шуларны бастырыр өчен Бөре өязе Кучмаш имамы Гайнулла мулла дигән кемсә Казанга алып килеп югалтты»,— дип, ачынып сөйли. К. Насыйри аңа: «Беләм, күргәнем дә бар, Сезнең ул иҗтиһадыңызга бик тәхсин иттем (хуплау, югары бәяләү — Р. Э.),— дип җавап кайтара һәм: — Сезнең шигырьләреңез вә тәхрирләреңез (әсәрләр, язмалар — Р. Э.) бик матур, мәгәр бастырырга кирәк иде»,— дигән киңәш бирә («Шура», 1913, 5 сан, 141 б.)

Билгеле булганча, 1870 елда Ш. Мәрҗанинең «Назурәтел-хак» («Хакыйкатьне күзәтү») исемле китабы дөнья күрә. Реакцион руханилар, бу китапка ябырылып, «Назурә...»гә каршы үзләре бер китап язып бастыралар. Китап тирәсендәге бәхәс кызганнан-кыза бара. Көндәлек матбугат булмаганлыктан, Ш. Мәрҗанине яклаучылар үз карашларын шигъри формага салып, бөек остазларына ирештерәләр. Ш. Мәрҗани аларның кайберләрен (Ихсан бине Гомәр Мәмсәви, Габдрахман Даут улы Чутаи, Фәхретдин бине Арслан Букали, Габдулла Бәләбәи-Раи, Габделкаюм бине Морад әл-Бәдәхши) «Мөстәфадел-әхбар...»ның 1 томына кушымта итеп урнаштыра. Арада Гали Чокрыйның да «Манзумате Гали бине Салих әл-Чокрый әл-хаҗ фи мәдхе китабе «Назурәтел-хак» исемле 86 бәетле әсәре дә урын алган (249—256 б.).

Ш. Мәрҗани һәм аның эшчәнлеген, язган хезмәтләрен бәяләүдә Г. Чокрый, М. Акмулла, Мостафа Чутаи кебек алдынгы карашлы шагыйрьләр рәтендә тора. Алай гына да түгел, Гали Чокрый, бөек остазына ияреп, 1885—1889 елларда татар халкының тарихына багышланган «Тәварихе Болгария яки тәкърибе Гари» («Болгар тарихы, яки Гаринең аны якынча сөйләп бирүе») исемле күләмле хезмәтен яза, азагына татар тарихының

---

[3] «Бөек календарь һәм халыкның көзгесе»

яңа чорларына караган бүлекләр дә өсти. Кызганычка каршы, бу тарихи китабын ул үзе йомгакларга өлгерми; бу эшне улы Гарифулла тәгәлли»[4]

1889 елда Ш. Мәрҗани вафат була. Үзе дә үлем түшәгендә яткан шагыйрь бу олы хәсрәтне бик авыр кичерә. Бу хакта аның Ш. Мәрҗани үлеменә багышланган 64 юллык мәрсиясе сөйли. Автор Ш. Мәрҗани үлемен тирән кайгы белән уртаклаша, фикер иясе һәм галим булганлыгын тагын бер кат ассызыклый.

Г. Чокрый — искиткеч тырыш, максатчан кеше булган. Табигый сәләткә бу мөһим сыйфатлар да өстәлгәч, мондый иҗади шәхеснең тарихка кереп, тиешле урын алуы бик табигый. Моңа төшенү өчен, Галинең тормыш юлындагы кирталәрне ничек җиңүенә күз ташлау да җитә.

Уфа губернасы Бөре өязе Тәтешле волосте Иске Чокыр авылы имамы Габдессалих хәзрәтнең ишле гаиләсендә дөньяга килгән Гали өч-дүрт яшендә үк укырга, язарга өйрәнә. Малай яшьтән үк зиһенле, тапкыр сүзле, әмма бәйсез характерлы һәм шук булып үсә. Әтисе кулында ук малай Коръәнне яттан өйрәнә, булган китапларның барысын укып чыгарга өлгерә. Шуның өстенә, ул бик матур һәм пөхтә яза белә. Мәсәлән, Гайнә волосте Танып авылында Хәйзерахман Габди угылы мәдрәсәсендә укыганда ук «Тәһзибе мантыйкый» («Логика укыту китабы») кебек калын китапны күчереп яза.

Г. Чокрыйның иҗаты да шул Танып мәдрәсәсендә укыганда башланып китә. Остазының вафатына ул мәрсия яза (1843 ел), әнисе Гөлбәһәрнең якты истәлегенә багышлап, шулай ук мәрсия иҗат итә.

1849 елда Г. Чокрый үткән гасырда дан тоткан Эстәрлебаш мәдрәсәсенә килә, Шәмсетдин Зәки кебек мәшһүр татар шагыйре һәм мөгаллиме белән шәкертләр укыта. Бу танышлык яшь шагыйрь иҗатына көчле йогынты ясый. Ул тома сукыр Шәмсетдиннең бәйсез характеры, фикер мөстәкыйльлегенә соклана:

Үзе әгъма заһит күзгә,
Басирдыр фәһмә һәр йөзгә,
Хәкимдер һәм фәсыйх сүздә...
(Үзе дөм сукыр күзгә,
(Әмма) күңел күзе барча йөзне күрә,
Галимдер һәм сүзгә бик оста...)

Күпне белергә, күрергә ашкынып торган егетне ерак Бохара үзенә тарта:

Китәр булдым чыгып илдән укырга,
Гыйлем эстәп кайтыем дип Чокырга.

Әмма юлда әтисенең үлгән хәбәрен ишетеп, кире борыла. Габдессалих хәзрәтнең өлкән варислары ул кайтканчы ата малын бүлеп бетергән булалар.

Атам бик бай иде, шиксез,
Малы күп ирде һәм чутсыз,
Соңында калды угыл-кыз,
Алар малга козан улды.
Насыйбымны алалмадым,
Җилгә китде хәләл малым,—

дип үкенеп яза шагыйрь бу хакта. Галигә нибары иске йорт, иске келәт һәм урман арасындагы уңдырышсыз, ташлы җир тия. Әмма ул аптырап калмый. «Игенче улы — игенче, крестьян улы — крестьян. Күбрәк эшебездә бар тапкан вакытымны, хәл вә форсатымны күбрәк шул эшкә бирдем»,— дип искә ала ул «Манзумате Галийә» исемле кулъязмасында. Галидә башка туганнарында булмаган иң кыйммәтле хәзинә — тирән белем була: «Юк хәл белән указ алып вә йорт салып, тормыш кирәк-ярakларын барысын сатып алып, ярлы кеше баласы кебек, бик күп бурычка баттым. Шул арада юк мәдрәсәне бар итеп, мәдрәсә ямаштырырга бер үзем тырыштым, күп михнәтләр арасында өемдә авыл балаларын, ә мәдрәсәмдә кабилә балаларын укытып вә шул арада духовный хезмәтләр артыннан да йөреп, Ирәкленең иң зур михнәтле бәндәсе булып торамын».

Указ алган ярлы, әмма горур һәм бәйсез Галине туганнары көнли башлый. Аның хакында төрле гайбәт таратыла. Мондый атмосферада аңа мәд-

---

[4] Бу хезмәт Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге китапханәсендә саклана. В-2662

рәсә тотып, балалар укыту да бик кыен була. Җимерек мәдрәсә бинасын үзе рәтләп, мич чыгарып, пыяла куеп җылытуга, дошманнары аларны ватып-кырып чыгалар. Салкын мәдрәсәгә шәкертләр йөрми башлый. Котыкыга бирелгән авылдашлары балаларын күрше авыл мәдрәсәсенә куалар, килгән шәкертләргә дә кунарга почмак бирмичә йөдәтәләр. Гали, кәләше Мәрфуга белән өйдән өйгә йөреп, балаларны кире җыя. Абыстай шәкертләрнең киемен үзе юа, үз мунчаларына йөртә, ипиләренә чаклы үзе салып пешерә. Менә ни өчен тормыш иптәшен шагыйрь «гөлем, былбылым» дип атый, каенатасы Җәләлетдингә багышланган мәдхиясендә бу «гөл»не үзенә «өзеп күндергәне» өчен рәхмәт укый:

«Голуг итде өемгә дәүләт ае,
Ул ай берлә дәхи дәүләт һомае».

(Һома — бәхет кошы)

Әммә Галинең дошманнары кара эшләрен ташламый: еш кына инде сарыф-нәхү укырга өйрәнгән шәкертләр аның мәдрәсәсен ташлап, элекке остазлары адресына таш ыргыта башлыйлар. Ниһаять, Галинең көндәшләре — 32 мулла Диния назаратенә аның өстеннән шикаять язалар, аны наданлыкта, укыта белмәүдә, сихерчелек белән шөгыльләнүдә һ. б. әллә нинди эшләрдә гаепլиләр. Бермәлгә Г. Чокрый хәтта мәхәлләсеннән дә куыла. Дошманнары аны мәчеттән куганда төрлечә мәсхәрәләп, кыйнап чыгаралар... Әммә Гали бирешми, башлаган эшен дәвам итә. Тирә-яктагы бу дошманлыкны шагыйрь гади көнчелек, хөсетлек белән аңлатмакчы була, әмма төп сәбәп, әлбәттә, тирәндәрәк ята. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, димәк, яңалык тарафдары буларак, ул, әлбәттә, искелек ялчыларын чыгырыннан чыгара, ярсыта. Заманында Г. Курсавины, Г. Утыз-Имәнине, Г. Кандалыйны да тирә-яктагы надан руханилар эзәрлекләгән бит, Г. Чокрый да шундый шартларда яшәп, иҗат итә.

Әнә шулай, бертуктаусыз көрәшеп, ызгышып, Гали 22 ел буе балалар укыта. Ниһаять, 1872 елда мәдрәсәсен улларының берсенә тапшырып, күптәнге хыялын тормышка ашыра — хаҗ сәфәре кылып кайта. 1879, 1880, 1886 елларда ул бу сәяхәтен янә кабатлый. Нәтиҗәдә, гаять кызыклы, бай мәгълүматлы «Хаҗнамә» әсәре туа[5].

XIX йөз татар әдәбияты тарихында бу жанрда язылган әсәрләр рәтенә Ш. Мәрҗани сәяхәтнамәсен һәм З. Бигиевнең 1893 ел җәендә Урта Азиягә ясаган сәяхәте нәтиҗәсендә туган «Мавәраннәһердә сәяхәт»е кертелә. Саф татар телендә язылган, кызыклы күзәтүләргә бай «Хаҗнамә»дә эчтәлеге белән дә, мәгърифәтне, прогрессны яклап чыгуы белән дә XIX йөз прозасының гүзәл үрнәге булып саналырга хаклы. Кызганычка каршы, бу әсәр кульязма хәлендә калган, шуның аркасында тикшеренүчеләр күзеннән читтә кала бирә. Бу сәяхәтнамәдә татар имамы һәм мөдәррисе Гали Чокрый мөселман Төркиясеннән Европаны, Россияне өстен куя, үзен Россиянең җитлеккән гражданины, патриоты итеп таныта. Истәлекләрдән Гали Чокрыйның, нык ихтыярлы, хәтта гипнозга да сәләтле шәхес булуына карамастан, көндәлек тормышта тотышы, рәвеш-килбәте белән гади, суфи-дәрвиш табигатьле кеше булганлыгы ачыклана. Ашау-эчүгә талымсыз, ул үзен кунак итүчегә: «Миңа арыш икмәге белән чәй булса җитә, коймак пешереп, бавырсак хәзерләп миннән артык фатыйха ала алмассыз, минем догам тәкәллефсез кешеләргә күбрәк»,— ди торган була. Малга да бик исе китми, кешеләрдән кергән сәдаканы ул еш кына өләшеп бетерә: «Биш таңкә акча белән ике кич йоклый алмыйм: ун төрле аласы нәрсә булып, берсенә дә җитмәгәч, мохтаҗларга бирәм»,— ди ул.

Кыскасы, шәхес буларак та Гали Чокрый истә калырлык, күркәм холыклы кеше булган. Аның әдәби-гыйльми мирасын шартлы рәвештә ике олы төркемгә бүлеп карарга була: 1) дөньяви, ярым дөньяви; үзе, заман һәм замандашлары, табигать, тирә-як турында язылган оригиналь әсәрләр, 2) дини эчтәлекле оригиналь әсәрләр, Көнчыгыш әсәрләренә шәрех һәм өстәмәләр.

Бу шагыйрьнең татар поэзиясенә алып килгән яңалыгы нидән гыйбарәт соң? Иң элек, бөтен иҗатын башыннан ахырынача сугарган лирик башлангыч, автобиографизм. Шагыйрь үзен шул чорның, үз халкының

---

5 Кульязма КДУ китапханәсендә саклана. № 627. т. Э-3779.

тулы канлы, ачык карашлы, димәк, хакыйкать сүзе әйтергә сәләтле зирәк вәкиле саный. Шул позициядән торып, үзенең дошманнарын камчылый, фикердәшләрен, көрәштәшләрен олылый, зурлый. Мәдхия, мәрсия жанры Г. Чокрыйга чаклы да киң таралган иде. Әмма шагыйрь бу жанрны тагын да камилләштерә, кирәкле өстәмәләр кертә, нәтиҗәдә, ул язган мәрсия мәет өстендә яшь кою, сыктаудан бигрәк, игелекле эшләр, халыкка файдалы хезмәт кылып киткән күркәм шәхесләрне олылый, ягъни мәрсия белән мәдхиянең үзенчәлекле синтезы хасил була. Бу башлангыч Мифтахетдин Акмулла иҗатында тагын да үстерелеп, татар әдәбияты тарихында күренекле әсәр тууга («Дамелла Шиһабетдин хәзрәт мәрсиясе») китерә.

Татар халкының милләт булып формалашкан чорында яшәп иҗат иткән шагыйрь үз халкының катлаулы тарихын яхшы белә һәм өйрәнә. Нәтиҗәдә, татар поэзиясендә борынгы Болгарны һәм Казан каласын зурлаган мәшһүр поэмалар туа. Казан аны иң элек «ләбибләр күплеге берлә, әдипләр күплеге берлә, табибләр күплеге берлә» җәлеп итә, ул Казанның «саф йортлары», «саф ирләре», «саф җырлары»на соклана.

Татар поэзиясендә ел фасыллары турында шигырь язу Г. Чокрыйга кадәр дә очрый (Ә. Каргалый, Г. Кандалый һ. б.), әмма Г. Чокрый — елның дүрт фасылы турында күләмле шигъри цикл иҗат иткән автор. «Фосуле әрбага» («Елның дүрт фасылы») китабында «Яз» шигыре аеруча күтәренке рух, романтик пафос белән язылган.

Табигать турындагы шигырьләрендә дә Г. Чокрый еш кына традицион поэтика кысаларын киңәйтеп җибәрә, поэзиягә тормышның үзеннән алган яңа табигый образлар, темалар алып килә.

Әлбәттә, алда без Гали Чокрый иҗатының көчле, уңай якларына тукталдык, чөнки теге яки бу иҗат кешесенең мирасы халкының рухи хәзинәсенә иң элек нәрсә бирә алуы белән билгеләнә. Шул ук вакытта бу шагыйрьнең үз чорының типик улы булмаганлыгын, димәк, табигый рәвештә, ялгышуын, әмма караңгылыкта да яңалыкка, прогресска юл ярырга тырышканлыгын онытырга тиеш түгелбез. Бер яктан, танылган ишан-мөдәррис, дин хезмәтчесе, дүрт мәртәбә хаҗ сәфәре кылган абруйлы хаҗи, икенче яктан балаларны укырга-язарга өйрәткән, гади крестьян кебек, игенчелек, умартачылык белән шөгыльләнгән, халыкны мәгърифәткә, һөнәрчелеккә өндәгән, йөзләгән әдәби-гыйльми хезмәт калдырган, заманы өчен аек, кыю карашлы фикер иясе ул. Ничек кенә булмасын, халык аны үз күргән, хөрмәт иткән, олылаган.

Шагыйрьнең вафатына ачынып, аның күпсанлы шәкертләре мәрсияләр иҗат иткән. Шагыйрь үзе дә иҗатының асыл мәгънәсе, әһәмияте турында уйлаган. Үләр алдыннан язган түбәндәге юллар шул хакта сөйли:

Рухым илә тәрбия кылган гавам
Йөз-мең ирдән артык була вәссалам.
...Йөз-мең улса Урта Иркәтә мәгәр,
Бергенәсе купмаган бойлә әсәр!

Гали Чокрыйның иң күләмле әсәре «Шәмгыз-зыя», ягъни «Шәм нуры» дип атала. Ул аны болгар-татар илендә яшәгән гыйлем, мәгариф ияләрен олылауга багышлаган. Шагыйрь бу әсәрендә мактап телгә алынган затларны «мәзкүр кемсәләрнең» йолдызлар кеби әгъла мәкамдә (зур дәрәҗәдә) мәхсубләрдер (саналалардыр)», шуңа күрә алар «таләбе хикмәт (хикмәт таләп итү) юлында гизүчеләргә... йолдызлар кеби һадилардыр (юл күрсәтүчеләрдер)» дип атый. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы үзе дә бабаларыбызның хакыйкать һәм яктылык эзләү юлында нинди сират күперләрен кичә алуын яхшы исбатлый.

«Шәм нуры»... Әлбәттә, Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан кояшлары астында Гали Чокрыйның тыныч агымлы шигърияте гасыр карындыгы аша салмак нур сирпегән шәм яктысын хәтерләтәдер. Әмма Добролюбов әйтмешли, «караңгылык патшалыгында» сүнмичә яна, балкый алган шундый «нурның» тарихи кыйммәте бермә-бер арта төшә. Ә безнең үткән гасыр поэзиясендә, «шигъри шәмдәлләрдә» утлар якты яна!

# Гали Чокрый

## Мәдхе Болгар

Менә шәһре Казаннан күп
Мокатдәм шәһре Болгар_хуп
Дәрел ислам иде мәхбүб,
Мәгәр, тәкый, харап саздыр...

Ләтыйф җайда булып мәгъмүр
Ләтыйф хәлләр табыптыр ул,
Ки мәсҗедләр итеп мәхсул,
Мәгәр тәкый хараб саздыр...

Дәхи анда китап-коръән,
Уку-язу — бары булган,
Тәмам дин асаре тулган,
Дәрел ислам эшен саздыр...

Ләимнәрдән ләим тәкый,
Кем ул Аксак Тимер багый,
Мөселман һәдменә сәгый
Булып шәһри харап саздыр...

Мөбарәк шәһре Болгарга
Килеп җиткән, тулып нарга,
Кыйлып күп тәхкыйр анларга
Золымлыкны гаян саздыр...

Гадиләр һәр тарафдин күп
Кылыч, мылтык илә күп туп
Калага ягдырып атып —
Ватып шәһри тәләф саздыр...

Ләимнәрнең йөзе кара,
Ничек тупка кулы бара
Атарга шәһре Болгара,
Ничә әбрар мәкам саздыр?!

Янә Болгарда күп әхъяр
Карап торганда егълап зар,
Нә йөз берлә карап хунхар,
Нә кул берлә кыйвам саздыр?!

Чөн ул шәйтан эшен итмам
Итеп кыйлган сөрүрен там,
Ки куркып шәрридән һәр гам
Биначар ихтирам саздыр...

Карап яткан каршы җирдә,
Халыкны куймаган бер дә,
Сөреп куйган ерак җиргә,
Мәкаме чөн харам саздыр...

Риҗалене кырып салмыш,
Хатынларын әсир алмыш,
Тәмам Болгар янып калмыш,
Имам әһле фөган саздыр...

Шу дәм Болгар күреп хәсрәт,
Таралып һәм кыйлып һиҗрәт,
Нә михнәт күрде, нә гыйбрәт,
Иман әһле һаман саздыр...

Менә Казан шәһәреннән күп
Борынгырак гүзәл Болгар шәһәре.
Исламның яраткан йорты иде,
Әмма, тәкый, харап булды...

Матур урында салынган булып,
Гүзәл хәлләр кичерде ул,
Мәчетләр барлыкка китерде,
Әмма, тәкый, харап булды...

Һәм дә анда китап-коръән,
Уку-язу — бары булган,
Һәм диннән әсәрләр тулган,
Ислам-йортның эшен йөрткән...

Кабахәтләрнең кабахәте
Аксак Тимер атлы юлбасар
Мөселманнарның егылуына
сәбәпче булып,
Шәһәрне харап итте...

Күркәм Болгар шәһәре янына
Килеп җитеп, аны утка күмеп,
Аңа күп тентүләр ясап,
Күп золымлыклар кылган...

Дошманнар һәр тарафтан
Күп кылыч, мылтык белән
Калага күп туп яудырып, атып,
Шәһәрне җимереп харап иткән.

Кабахәтләрнең йөзе кара,
Ничек тупка кулы бара
Никадәр изгеләр торган
Болгар шәһәренә атарга?!

Янә Болгарда күп яхшы кешеләр
Карап торганда зар елап,
Ни йөз белән карап кан эчүче,
Нинди кул белән каршы күтәрелгән?
Чыннан да, ул, шайтан, эшен
тәмам иткән,
Тәмам шатланып-куанып,
Һәммә кеше аның явызлыгыннан куркып,
Аны хөрмәтләргә мәҗбүр булган.

Карап яткан якын җирдә,
Халыкны куймаган бер дә,
Сөреп куйган ерак җиргә,
Ул халыкларга Болгарда торуны
тыйган.

Ир-атларын кырып салган,
Хатыннарын әсир алган,
Тәмам Болгар янып калган,
Мөселманнар зар елаган.

Шулчак Болгар, күреп хәсрәт,
Таралып һәм кылып һиҗрәт,
Нә михнәт чиккән, нә гыйбрәт,—
Иман әһле зар әчендә.

## Мәдхе Казан

*(Өзек)*

Чыгар андин кием-салым,
Читек-башмак булып мәнзум,
Зифалык васфилә мәгълүм,
Җиһан халкы мәдех саздыр!

Дәхи анда хатын-кызлар
Чигү-чәнчү, нәкыщ дәяр,
Җиһан халкы санынча бар
Сияп-сәрпүш гаян саздыр...

Иң әүвәл йортлары бик саф,
Икенче — ирләре бик саф,
Өченче — җырлары бик саф,
Әмерләре нәзар саздыр!

Ләбибләр күплеге берлә,
Әдипләр күплеге берлә,
Табибләр күплеге берлә
Тәмам илгә гаян саздыр...

Азанчылар, хатыйбчылар,
Карый-хафиз вәгазьчеләр,
Суфый-закир намазчылар
Тәмам, урман кеби, саздыр...

Ходүде шәһри Болгарда,
Ничә кальга, ничә карья,
Берәрсе киләме парга,
Кеми Казан мисал саздыр?!

Чыгар аннан кием-салым,
Читек-башмак тезелеп киткән,
Матурлыклары белән дан тоткан,
Дөнья халкы аны олылый.

Һәм дә анда хатын-кызлар
Чигү-чәнчү эшенә бик оста,
Анда эшләнгән киемнәр һәм
кәләпүшләр саны
Җиһан халкы санынча бар.

Иң әүвәл йортлары бик саф,
Икенче — ирләре бик саф,
Өченче — җырлары бик саф,
Эшләре — карап туйгысыз.

Галимнәр күплеге белән,
Әдипләр күплеге белән,
Табиплар күплеге белән
Тәмам бөтен илгә мәшһүр...

Азанчылар, ораторлар,
Карый-хафиз вәгазьчеләр,
Суфый-догачылар, намазчылар
Тәмам, урман кебек, күптер...

Шәһре Болгар җирләрендә
Ничә кала, ничә авыл,
Берсе дә аңа пар түгел,
Казанга тиңләшә алмый.

## Яз

*Өзек*

Хәмәл тугъды, бәһар улды,
Ләяли чөн нәһар улды,
Көнә-көн мәстанәр улды,
Һәммә экван әҗәр баздыр.

Бизәнде йир нияз илә,
Туналды төрле наз илә,
Куанды фаслы яз илә,
Нәбате берлә дәм саздыр.

Әгәр дарда йөресәң дә
Вә йә тагда йөресәң дә
Япанларда йөресәң дә,—
Хода зикрилә ауаздыр.

Бу дәмдә җәм каю җанвар
Җиргә дәүран идеб сайрар;
Буларда һәм дәлилләр вар:
Алар да гыйшкилә саздыр.

Күгәрчен, карлыгач комре
Сәна берлән үтәр гөмре.
Сабан тургай ничә төрле
Нәуалар берлә дәм саздыр.

Апрель туды, яз булды,
Төннәр көндездәй булды,
Көннән-көн матурланды,
Бар тереклек уянды.

Бизәнде җир кирәгенчә,
Тулды төрле наз белән,
Куанды килгән яз белән,
Яшеллектән ямьләнде.

Әгәр йортта йөресәң дә,
Яки тауда йөресәң дә,
Яланнарда йөресәң дә,—
Ходаны мактау авазы.

Бу мәлдә һәртөрле җанвар
Җиргә әйләнеп кайтып сайрар.
Боларда һәм дәлилләр бар:
Алар да гыйшык җырын суза.

Күгәрчен, карлыгач уйный,
Язны мактап үтәр гомре.
Сабан тургай ничә төрле
Моңы белән җырын суза.

Бүре, төлке, елан, куян,
Балыклар һәм каму хайван
Сәна итеб калыр әфган,—
Бары дәрд илә дәм саздыр.

Бакалар су якасында
Булып гаркаб гатасында,
Ертып дамен, якасын да
Садалар берлә дәм саздыр.

Кеме япраг илә әзһар,
Арасында укыр әшгар,
Кеме җәүве һавада зар,
Газәл хан, бала пәрваздыр.

Кеме җирдә, кеме суда,
Кеме көндез, кеме төнлә
Йөреп һәр ан, кеме көндә,
Кеме бер җирдә дәм саздыр,

Кеме җәһран, кеме хөфийә,
Кеме ялгыз, кеме җөмлә,
Кеме зикер идә бер диллә,
Кеме күб диллә дәм саздыр.

Кичәләр мөстәмигъ улсаң,
Тәфәккер әйләер булсаң,
Гаҗәпме дәрт илә тулсаң,—
Бары безгә кәрәм саздыр.

Килеп былбыл күрер бостан,
Нәмүнә, дир, гөле дустан,
Укыр гөлгә һәзар дастан,
Гөле гүштер вә һәмраздыр.

Киләлем карема бән уш,
Диялем ярыма бән хуш,
Булалым, кош кеби, яз-кыш:
Кем ул зикре һөнәр саздыр.

Бүре, төлке, елан, куян
Балыклар һәм төрле хайван
Мәдех кылып өзгәләнер,
Дәрт белән сайрар бар да.

Бакалар да су буенда,
Ары сикереп, бире сикереп,
Ертылырдай киерелеп,
Садалар әйтеп тавыш бирә.

Кайсысыдыр яфрак белән гөл
Арасында шигырьләр укыр,
Кайсы күккә күтәрелеп
Гыйшкын газәл итеп сузар.

Кеме җирдә, кеме суда,
Кеме көндез, кеме төнлә
Кеме һәр тарафта,
Кеме бер җирдә җырын көйли.

Кеме тавыш сала, кеме өнсез,
Кеме ялгыз, кеме бергә,
Кеме телгә ала бер телдә,
Кеме көйли күп телдә.

Кичәләрдә тыңлар булсаң,
Фикер йөртеп уйлар булсаң,
Гаҗәпме дәрт белән тулсаң,—
Бары безгә хөрмәт җырлый.

Килеп былбыл күрер бакча,
Сокландыргыч дип, гөлгә кунар,
Укыр гөлгә меңләп дастан,
Гөле тыңлар, серен белер.

Килим инде мин дә эшемә,
Хуш диим ярыма,
Булыйм яз-кыш та, кош кеби:
Аның кебек һөнәргә, эшкә
мактау җырлый торган.

# ҺАДИ АТЛАСИ ТУРЫНДА

### ҺАДИ АТЛАСИНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Мең тугыз йөз бишенче елгы буржуаз-демократик революция Россия империясендәге халыкларның барлык катламнарын да дулкынландырып, кузгатып җибәрде, аларның социаль һәм милли аңнары үсүгә гаять зур этәргеч булды. Шул зур хәрәкәт дулкынында татар җирлегендә дә җәмәгать эшлеклеләренең, әдипләрнең, галимнәрнең, халык мәгарифе һәм культурасы эшлеклеләренең яңа буыны мәйданга чыкты. Чорында матбугатта исеме киң мәгълүм булган Һади Атласи — Һади Мифтахетдин улы Атласов (1876—1938) — әнә шул буынның бер вәкиле иде.

Мәгълүм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы галим һәм халык мәгарифе хезмәткәре Һади Атласи 1876 елда Сембер губернасы Буа өязе Чәке авылында (Татарстанның хәзерге Чүпрәле районы) дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында әтисеннән алгач, Һади укуын, ул вакытларда шактый билгеле булган Буа мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Кадим мәдрәсәдә бирелгән гыйлемнәр белән канәгать булмаган егет үзлегеннән белемен үстерү чараларын күрә: төрле фән нигезләрен үзләштерә, бик тырышып, рус һәм немец телләрен өйрәнә. Культура һәм фән казанышларын үзләштерүдә аңа Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсендә (Каргалы авылы) укытучылар хәзерләү өчен оештырылган өчьеллык курсларда уку да мәгълүм күләмдә уңай йогынты ясый. Нәтиҗәдә Һ. Атласи татар укымышлылыларының үз заманы өчен шактый киң карашлы, белемле вәкиле булып җитлегә. Төрле фән нигезләрен үзләштерү белән бергә ул, туган теленнән тыш, рус, немец, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен дә яхшы белгән.

1898 елда Һади Атласи Буа мәдрәсәсенә мөгаллим-укытучы булып кайта һәм җиң сызганып уку-укыту эшләрен заман таләпләре югарылыгына күтәрү чараларына керешә. Моның белән ул уку-укытуның иске ысулларын яклаган хәлфәләрнең кискен ризасызлыгын тудыра. Озак та үтми, ул фән нигезләрен пропагандалау өлкәсендә дә беренче адымнарын ясый: «Гыйльме һәйәт» («Астрономия фәне») һәм «Тарихе табигый» («Табигать гыйлеме тарихы») кебек хезмәтләрен язып бастыра.

1903 елда Һ. Атласи Бөгелмә өязенең Әлмәт авылына имам һәм мөдәррис итеп чакырыла. Имамлык вазифасын үтәгән хәлдә ул иҗат һәм уку-укыту эшләре белән шөгыльләнүен, публицистик әсәрләр язуын ташламый. Озакламый аның «Ахыр заман ишаны», «Идел буе», «Мәктәп һәм мулла» кебек әсәрләре дөнья күрә. Мәдрәсәдә ир балалар укыту белән бергә ул кызлар өчен дә мәктәп ача.

Россиядә революцион хәрәкәтнең күтәрелеш елларында Һади Атласиның иҗтимагый-политик эшчәнлеге сизелерлек дәрәҗәдә активлаша. 1907 елда ул II Дәүләт думасына депутат булып сайлана һәм «Мөселман депутатларының зәхмәткәш фиркасе» — мөселман хезмәт фракциясе эшендә актив катнаша. Аның турыдан-туры катнашуында Питербургта татарча «Дума» исемле газета чыга башлый. Бу газета агымдагы политик хәлләрне трудовиклар позициясеннән торып яктырта. Барысы алты саны дөнья күргән газета хөкүмәт тарафыннан ябыла.

1905 елның маенда хөкүмәт тарафыннан Россиянең Көнчыгыш өлкәләрендә яшәүче рус булмаган халыкларда мәгариф эшләренең торышы мәсьәләләре буенча махсус киңәшмә җыела. Киңәшмә карарлары нигезендә, мәктәптә укыту процессында рус булмаган халыкларның милли үзаңы уянуны һәм үсүне булдырмау, тоткарлау максатыннан чыгып, кагыйдәләр төзелә. Кагыйдәләр 1906 елның 31 мартында Мәгариф министрлыгы тарафыннан раслана. Һ. Атласи 1908 елда шул кагыйдәләрне тәнкыйть иткән «Яңа низам вә голямаларымыз» исемле әсәрен дөньяга чыгара. Кискен политик рухта язылган бу китап царизм һәм кадимче-мөселман руханиларының халык мәгарифе өлкәсендәге политикасына каршы юнәлтелгән иде. Шушы китабы өчен Һ. Атласи

1909 елда политик җавапка тартыла, һәм өч айга төрмәгә хөкем ителә, шулай ук ул указлы мулла һәм башка рухани дәрәҗәләрдән мәхрүм ителә. Төрмәдән чыккач, полиция аны даими күзәтү астына ала. Аның тарафыннан оештырылган кызлар мәктәбе дә ябыла.

Нинди дә булса рәсми вазифалар башкару мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән Һади Атласи үзен гыйльми, әдәби-публицистик һәм мәдәни — агарту эшләренә багышлый: фәнни хезмәтләр яза, «Йолдыз», «Вакыт», «Шура» кебек газета-журнал битләрендә публицистик мәкаләләр бастыра. Бераздан ул Әлмәттә яңа мәктәп ачып, җәдитчә ягъни яңа ысул белән укыту эшләрен башлап җибәрә. 1921 елны Әлмәттәге совет власте вәкилләре тарафыннан бирелгән белешмәдә дөрес күрсәтелгәнчә, «Бу мәктәпне тәмамлаган укучыларның күпчелеге соңыннан совет мәктәбе хезмәткәрләре, партия эшлеклеләре булдылар. Мәктәп җитәкчесе буларак, Һади Атласи үзенең укучыларында халык... арасында... культура таратуга омтылыш тәрбияләде»[1].

Егерменче йөзнең уынчы елларында Һади Атласи үзен күренекле тарихчы итеп таныткан хезмәтләр яза. Мәсәлән, 1912 ел башында галимнең «Себер тарихы», ә 1913 елда Казанның соңгы ханбикәсе турында «Сөембикә. Тарихи хикәя» исемле очеркы басылып чыга. Гыйльми җәмәгатьчелек каршында үзен төпле, җитди тарихчы итеп таныта алган Һ. Атласи 1913 елда Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана. 1914 елда галимнең төп фәнни хезмәте булган «Казан ханлыгы» исемле зур китабы басылып чыга. Бу хезмәтнең фәнни әһәмияте хакында аның Совет чорында яңадан ике тапкыр (1920 һәм 1924 елларда) нәшер ителүе үк күпне сөйли булса кирәк. Һ. Атласиның тарихи хезмәтләре максат һәм концепция ягыннан оешкан, ә эчтәлек җәһәтеннән исә бай булулары белән аерылып торалар. Тарихи тикшеренүләрендә автор татар, рус, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә язылган беренче кул тарихи чыганаклардан җыелган фактик материалларга таянып гамәл кыла. Бу уңайдан аның В. Н. Татищев, С. М. Соловьев һ. б. рус тарихчылары хезмәтләрен һәм шулай ук рус елъязмаларын яхшы белгәнлеге ачык күренә. Асылда ул — татар тарихчылары арасындаXV-XVI йөз русча тарихи истәлекләрдән алынган күпсанлы материалларны беренчеләрдән булып фәнни хәрәкәткә кертеп җибәргән галим. Шуның белән беррәттән Һ. Атласи — аңа кадәр галимнәргә билгеле булмаган кыйммәтле татарча тарихи чыганакларны да фәнгә кертүдә зур тырышлык күрсәткән галим. Мисал рәвешендә, 1523 елны Сәхиб Гәрәй хан тарафыннан бирелгән тарханлык ярлыгын беренче тапкыр (1914 елда) матбугатта чыгару, Казан шәһәренең беренче рәсми исеме «Яңа Болгар» булуы хакында хәбәр итүче мөһим факт теркәлгән «татар елъязмасы»ның фарсы телендәге версиясен табу, тикшерү, шулай ук беренче булып «Ханәкә солтан» исемле тарихи бәетне бастырып чыгару һ. б. фактларны күрсәтергә мөмкин.

Тарихчының бу хезмәтләре үз вакытында ук көнчыгышны өйрәнүче рус галимнәренең дә игътибарын җәлеп иткән иде. Мәсәлән, күренекле ориенталист галим академик В. В. Бартольд Һади Атласиның «Себер тарихы» һәм «Казан ханлыгы» дигән китапларына язган рецензиясендә, әлеге китапларда очраган кайбер текстологик кимчелекләрне һәм ялгышларны күрсәтү белән бергә аларның бәхәссез уңай сыйфатларын да билгеләп уза[2]. Һ. Атласиның бу китапларны «татар патриоты» позициясеннән торып язуын әдәпле рәвештә махсус искәртеп узгач, гадел хөкем йөртүче В. В. Бартольд, рецензияләнә торган хезмәтләрнең авторы XV-XVI йөз рус дәүләт эшлеклеләрен дә тиешле дәрәҗәдә объектив бәяләгән дип күрсәтә.

Бер үк вакытта шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Һ. Атласи методологик яктан әле җитлекмәгән тикшеренүче буларак, татар ханлыкларының җимерелү сәбәпләрен социаль-экономик шартлардан түгел, бәлки аерым татар хөкемдарларының «ихтирамга лаек булмаслык» гамәлләрендә әзли һәм бөтен «бәла-казаларның» башын аларның алдан күрә алмаучанлыкларында, үзара ызгыш-талашларга батуларында һ. б. күрә. Әлбәттә, болары да булган һәм андый фактлар хакында рус һәм совет тарихчылары аз язмадылар инде. Ләкин болар асылда Казан ханлыгын җимерүче төп сәбәпләрнең үзләре булмыйча, дәүләтне шул һәлакәткә китергән социаль-экономик мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәләре генә иде. Нәкъ менә шушы үзенчәлекле социаль-экономик мөнәсәбәтләр өлкәсендәге буталчыклыкның, таркалышның нәтиҗәсе буларак әлеге үзара ызгыш-талашлар, гауга-тартышлар илдә тамыр җәйгән, киң таралган иде. Вак буржуаз тарихчы буларак, Һ. Атласи әнә шул тирәндә яткан беренчел процессларга игътибар итмәде диярлек. Дәүләтләр, илләр тарихын ул бары тик политик тарих — ханлыклар, династияләр яки аерым дәүләт башлыклары тарихи рәвешендә генә бәян итә. Шунысы белән ул үз чорының башка буржуаз тарихчылары дәрәҗәсендә иде.

---

[1] ТАССР ҮДА, 779 ф., 3 тасв., 33 эш, 65 бит. (Алга таба бу эшнең бит саннары текстта җәяләр эчендә күрсәтеләчәк)

[2] Записки Восточного отделения Русского археологического общества. т. XXIII, вып. III-IV, 1916, 421-422 бб.

Һ. Атласи иҗатының характерлы тагын бер үзенчәлеген билгеләп үтәргә кирәк: беренче әсәрләрен ул гади татар укучысына авыр аңлашыла торган һәм шул вакыттагы кайбер әдипләр, галимнәр карашында «могтәбәр» саналган корама телдә язган. Соңрак Һ. Атласи хезмәтләренең теле сөйләм теленә якыная төшә, ягъни күзгә күренеп халыкчалаша. Әгәр Атласига мондый характердагы җитешсезлекләрдән котылу чагыштырмача җиңел бирелгән булса, вак буржуаз авторларга хас кайбер идеологик буталчыклардан котылу аңар, кызганычка каршы, гомумән, насыйп булмый диярлек.

Һ. Атласи энергияле һәм нәтиҗәле иҗатчы булу белән бергә татарлардагы вак буржуаз тарихи фикернең идеологик җәһәттән эзлексез һәм каршылыклы вәкиле иде. Аның эзлексезлеге фәнни иҗатында да, публицистикасында да чагылыш тапкан. Тарихчының хезмәтләренә методологик җитлекмәгәнлек, тикшерелә торган күренешләрнең объектив нигезен ачып бирә белмәү хас. Аның дөньяга карашында методологик яктан идеалистик күрсәтмәләр өстенлек итә, ә бу исә, үз чиратында, тарихи вакыйгалар турында фикер йөртүдә субъективлыкка китерә. Автор үз хезмәтләрендә бик тәмләп, тәфсилләп дигәндәй интим характердагы фактлар турында сөйли, һәртөрле вак имеш-мимешләргә артык күп урын бирә. Тарихи чыганакчылык белеме күзлегеннән караганда, Һ. Атласи хезмәтләре өчен бер төр чыганакларның хәбәрләрен тәнкыйтьсез генә кабул итү, ә икенчеләренә исә, киресенчә, нигезсез рәвештә шикләнеп карау, ышанмау хас. Дөрес, бу өлкәдә ул бернинди дә үзгәреш, үсеш кичермәде дип әйтеп булмый. Соңрак язылган хезмәтләрендә Һ. Атласи, гомумән алганда, үз чорының буржуаз тарихи чыганакчылык белеме дәрәҗәсенә күтәрелә яза. Көндәлек матбугат битләрендә аның хезмәтләренә карата бирелгән бәяләр нәкъ менә шул хакта сөйлиләр. Үз чоры өчен традицион, мәгълүм истәлекләрдән тыш, күптөрле яңа чыганакларны (хан ярлыкларын, тарихи риваятьләрне һ. б.) фәнни хәрәкәткә кертеп җибәрүдә галим биргән яңалыклар турында сөйләгәндә шуны да истә тотарга кирәк: Һади Атласи хезмәтләрен тарихи чыганакчылык күзлегеннән карап бәяләү — ул әле киләчәктә махсус тикшеренүне сорый торган мөстәкыйль мәсьәлә.

Һади Атласиның политик эшчәнлеге дә махсус тикшерүгә, бәяләүгә лаек. Аның политик эшчәнлеге һәм фәнни иҗаты арасында үзара бәйләнеш һәм тәэсир итешүне инкарь итмәгән очракта да, аларның бер-берсенә тәңгәл килеп бетмәүләрен дә истә тотарга кирәк. Һ. Атласи вак буржуаз политик эшлекле һәм вак буржуаз тарихчы иде. Тарихчы буларак ул эре буржуазия позициясенә якынрак торса, җәмәгать эшлеклесе хәлендә халык массаларына тартымрак иде. Мәсәлән, Һ. Атласи, җәмәгать эшлеклесе сыйфатында кыска вакыт эчендә суллаша барган булса, тарихчы Атласи исә ике арада, урталыкта кала бирде дип әйтерлек.

Һ. Атласиның вак буржуаз эшлеклеләргә хас эзлексезлеге һәм каршылыклы шәхес булуы аның иҗтимагый-политик эшчәнлегендә аеруча ачык чагыла. Иҗтимагый-политик көрәш мәйданында ул крестьяннар мәнфәгатен чагылдыручы көрәшче буларак чыгыш ясый, әмма крестьян массаларының сыйнфый бүленешен исәпкә алмыйча, «гомум крестьяннар» мәнфәгатеннән чыгып эш итәргә тырыша. II Дәүләт думасына ул крестьяннар куриясе буенча сайланган иде. Дәүләт думасында ул, трудовиклар рухында чыгыш ясап, үзен татар халкының вак буржуаз катламнары мәнфәгатьләрен яклаучы итеп танытты. Һ. Атласи патша хөкүмәте политикасын мөселман хезмәт ияләре исеменнән тәнкыйтьләде һәм бу мәсьәләдә трудовикларга теләктәшлек күрсәтте. Ул монархия һәм полиция режимының килешмәс дошманы булды. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач ул, аңа каршы чыгып, сугышны хезмәт халкы өчен бәла-каза дип бәяләде. Шул ук вакытта Һ. Атласи бу тенденцияне эзлекле рәвештә үстереп, аны буржуазия һәм алпавытлар строена каршы юнәлгән революцион көрәшне тану югарылыгына җиткерә алмады.

Һади Атласи социалист-революционерлар партиясе члены иде. Дөрес, «сугыш һәм революция һәм буржуазия белән килешү» мәсьәләләрендә эсерлар политикасы белән килешмичә, ул соңыннан бу партиядән аерылды. Бер үк вакытта Һ. Атласи «РКП(б) программасының кайбер пунктларына» теләктәшлек белдерде. Шулай да ул тулысынча пролетариат партиялелеге позициясенә дә күчә алмады. Үзенең әйтүе буенча, ул эсерлар һәм большевиклар арасында бәргәләнде. Бер яктан ул «большевикларны, ә икенче яктан эсерларны яклый, ягъни һәр ике партия программаларының кайбер пунктлары белән килешсә дә, кайберләрен кире кага, икенче төрле әйткәндә, бу партияләр арасында урта линияне тотарга тырыша» (80 б., 131 битләр).

Һади Атласиның бу вак буржуаз эзлексезлеге, принципиаль линияне сайлый белмәве, буржуазия һәм алпавытлар строе белән хәлиткеч көрәш чорында — Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында үзен бигрәк тә ачык сиздерде. Бу вакытта ул тотрыксыз культура эшлеклеләренә хас позициядә торды. Февраль революциясеннән соң Һ. Атласи Бөгелмә өязенең Земство идарәсе һәм мөселман оешмалары составына керде, «анда хезмәт ияләре ягында торып ачыктан-ачык буржуаз элемент-

ларга каршы чыгыш ясады» (29 б.). Ул Земство идарәсенең халык мәгарифе бүлегенә житәкчелек итте. Октябрь революциясе җиңгәч һәм совет власте урнашкач, Һ. Атласи Бөгелмә өяз советы составына кереп, аның башкарма комитеты члены булып сайланды, совет мәктәпләре өчен кадрлар хәзерләүне юлга салуда актив катнашып, яңа оештырылган дүртьеллык укытучылар семинариясендә укытты. Ләкин озак та үтми, контрреволюция баш калкыта, чехословаклар корпусы фетнә күтәрә. Совет органнары һәм хезмәткәрләре Бөгелмәне ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Ләкин Һ. Атласи алар белән бергә китми, фетнәчеләр власте урнашкач, яңадан эшли башлаган Земство идарәсенә эшкә урнаша. Чехословаклар шәһәрдән киткәндә дә ул Земство идарәсенең башка членнары кебек Бөгелмәне ташлап чыкмый, бәлки шәһәргә кергән Кызыл Армия частьләрен каршылый һәм яңадан совет мәктәпләрен оештыру эшендә катнаша, укытучылар семинариясендәге эшен дәвам иттерә. Озак та үтми Бөгелмә өстендә яңадан болытлар куера, шәһәргә Колчак армияләре якынлаша. Кызыл Армия частьләре һәм совет хезмәткәрләре шәһәрне калдырып чыгалар. Ләкин, бу юлы да Һ. Атласи алар белән китми, бәлки Колчакны «иң рәхимсез рәвештә халык восстаниесен бастырган иң зарарлы элемент» дип санаса да, шәһәрдә кала бирә. Аклар аңа Земство идарәсенең эшен яңадан торгызырга тәкъдим итәләр. Һ. Атласи тәкъдимнән баш тарта. Әмма соңыннан, хәрби комендатура һәм гарнизон начальнигы басымы астында, ул Земство идарәсе урынбасары булып эшләргә ризалык бирә, хәтта Россиянең «Гали идарәчесе»нә котлау телеграммасы да җибәрә, аклар шәһәрдән чигенгәндә ул да, алар белән китә. Ләкин беренче мөмкинлек тууга, ул ак армия обозын ташлап кача. Чиләбедә аңа аклар армиясе контрразведкасында үзенең большевистик характердагы эшчәнлеге хакында материаллар туплануы турында хәбәрләр ишетелә. Шуннан соң Һ. Атласи ашыгыч рәвештә хәрәкәт маршрутын көнчыгыштан көнбатышка таба үзгәртә һәм Троицк аркылы Бакуга килә, Баку советы Мәгариф комиссариаты нәшриятының төрки бүлегендә эшли башлый (81, 89 бб.). Һ. Атласиның бу аумакайлыгы, кыска гына, ләкин бик давыллы чордагы эшчәнлегенең зигзаглары аның вак буржуаз интеллигенция вәкиленә хас эзлексез һәм тотрыксыз позициясенең ачык үрнәге булып тора.

Әлбәттә, Һ. Атласиның ул вакытларда үз-үзен тотышын берьяклы гына бәяләп булмый, һәм бу хәзер зарури да түгел. Андый позиция революциядә «өченче юл» эзләүче күпләгән вак буржуаз демократлар өчен типик күренеш иде. Мондый омтылышларның хыялый һәм политик яктан зарарлы булуын тарих үзе исбат итте. «Кем белән барырга?» дигән сорауга өздереп җавап бирергә кирәк булганда бик күп вак буржуаз эшлеклеләр, бигрәк тә аларның сул өлеше, һаман да әле революция һәм контрреволюция арасында бәргәләнүен дәвам итте. Әмма, аларның күпчелеге ахыр чиктә дөрес позицияне сайлый алдылар. Һ. Атласи да шулай ук төрле хаталар һәм икеләнүләр аша революциягә таба якынлашты, әмма, кызганычка каршы, ахырына кадәр аны дөрес аңлау дәрәҗәсенә барып җитә алмады.

Соңгы елларда дөнья күргән кайбер хезмәтләрдә Һ. Атласига Бөгелмә өязе Колчак гаскәрләре кулында калган чорда совет хезмәткәрләрен һәм укытучыларын эзәрлекләүдә катнашу кебек гаепләр тагылды. Әмма бу гаепләүләр нигезсез, чөнки алар тарихи документлар белән расланмыйлар. Киресенчә, архив документлары Һ. Атласиның ак чехлар фетнәсе һәм Бөгелмәдә Колчак гаскәрләре хуҗа булган вакытта, үзенең эш урыныннан файдаланып, мөмкин булган кадәре совет хезмәткәрләрен контрреволюция тырнагыннан саклап калу өчен тырышуы хакында сөйлиләр. Мәсәлән, Һ. Атласи үлем вагонына ябылган РКП(б) члены, Бөгелмә өязе башкарма комитеты председателе Закир Исхаковны акларның контрразведкасы кулыннан коткарып кала һәм качарга булыша (39, 81, 82, 86 бб.). Өяз комитетының агитация-пропаганда бүлеге мөдире, РКП(б) члены С. Рахманкулов, халык мәгарифе бүлеге инспекторы С. Уразмановлар да аклар контрразведкасы тырнагыннан шул ук Һ. Атласи ярдәмендә коткарылалар (23, 37, 40, 82, 86, бб.). Бөгелмә шәһәренең ятимнәрне тәрбияләү эшләре комиссары, өяздә беренче совет газетасы булган «Бөгелмә мөхбире»н оештыручыларның берсе, РКП(б) члены З. Гыймазетдинов аклар контрразведкасыннан Һ. Атласи өендә яшеренеп ята (43, 44, 81, 82 бб.). Һ. Атласи татарлар арасындагы контрреволюцион хәрәкәтнең идеологы, хәтта аның җитәкчеләренең берсе булган дигән кайбер раслауларның да нигезсез икәнлеген архив материаллары ачык дәлилләр.

20-30 елларда Һади Атласи актив рәвештә совет мәктәпләрендә укытучылык эше белән шөгыльләнде. 1921 елдан 1929 елга кадәр Бөгелмә шәһәрендәге икенче баскыч мәктәбендә тарих һәм немец теле, ә утызынчы елларда исә Казанда немец теле укытты. Замандашлары аның татар мәктәпләре өчен педагогик кадрлар хәзерләүгә керткән өлешен тәкъдир итәләр һәм бу өлкәдәге эшчәнлеген югары бәялиләр.

Күп еллар буе Һ. Атласи көнчыгыш халыклары һәм төрле илләр тарихы буенча төрле телләрдә язылган өч меңнән артык китапны, шул исәптән рус, татар, фарсы һәм гарәп әдәбиятлары классикларының әсәрләрен үз эченә алган уникаль китапханә туп-

лый. 1925—1928 елларда Һ. Атласи фарсы әдәбияты җәүһәре — Сәгъдинең «Гөлстан»ын татарчага тәрҗемә итә.

Бу әйтелгәннәрдән без Һ. Атласиның актив иҗат иткән бай мирасы һәм бер үк вакытта татар вак буржуаз интеллигенциясенең үтә каршылыклы, эзлексез бер вәкиле булганлыгын ачык күрәбез. Әлбәттә, ул буржуаз милләтчелек идеологиясе йогынтысыннан да азат түгел иде. Шул ук вакытта аны, кайвакытлардагы кебек, контрреволюцион хәрәкәтнең әйдәп баручы идеологы яки җитәкчесе итеп күрсәтүнең дә кирәге юк. Киресенчә, фактлар мондый раслауны кире кагалар. Безнең каршыга ул үзенчә намуслы һәм үзенчә халыкка тугрылыклы интеллигент буларак килеп баса. Һ. Атласи — халык мәгарифен һәм татар тарихи фикерен үстерүгә үзеннән билгеле күләмдә өлеш керткән галим һәм җәмәгать эшлеклесе. Шул ук вакытта аны тәмам калыплашып җиткән мәгърифәтче итеп сурәтләргә дә җитәрлек нигез юк. Һ. Атласи — Россия чынбарлыгының катлаулы революция алды һәм революция чорының татар җирлегенә хас вак буржуаз мохиты вәкиле булды һәм ахырга кадәр шулай булып калды да. Ул күп тапкырлар ялгышты, адашты, икеләнде, кискен тайпылышлар ясады, әмма ахыр чиктә, совет чынбарлыгына килде һәм калган көчен, сәләт-тәҗрибәсен совет мәктәбен үстерүгә, яңа культура төзелешенә бирде.

**Яхъя АБДУЛЛИН,**
философия фәннәре докторы, профессор,
**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
тарих фәннәре докторы, профессор,
**Индус ТАҺИРОВ,**
тарих фәннәре докторы, профессор.

# ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЛАРЫНДА РУН ЯЗУЫ

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы һәм Казан дәүләт университетының археологик экспедициясе 1983 елның җәендә Биләр шәһәрлегендә казу эшләре алып барды. Эчке шәһәрнең үзәк өлешен казып тикшеренүләр кызыклы табылдыклар вәгъдә итә иде. Гасырлар буе җир куенында яткан меңнәрчә балчык һәм пыяла савыт-саба китекләре, бик күп тимер әйберләр, шулай ук бронзадан ясалган бизәнү әйберләре калдыклары археолог-тарихчылар кулына күчте. Бу табылдыклар барысы да урта гасырның эре шәһәр тормышына хас булган гадәти көнкүреш һәм җитештерү әйберләре. Археолог тора-бара моның ише табылдыкларның күплегенә һәм төрлелегенә акрынлап күнегә. Әмма июль аеның эссе бер иртәсендә ниндидер ватык савыт toткасы казу эшләре белән мәшгуль барча кешенең игътибарын үзенә җәлеп итте. Беренче карашка тотка үз ишләреннән формасы белән генә аерылып тора сыман: ул ниндидер бер җан иясенең башын хәтерләтә иде. Иң кызыгы — тоткадагы рун алфавиты билгеләре төшерелгән язу булды. Бу язулы тотканың табылуы Биләрдән чыккан археологик табылдыкларны гына түгел, ә бәлки бөтен Идел буе Болгар иленең кайбер ядкарьләрен яңа бер күздән кичерүне сорый.

Ислам дине кабул ителгәнгә кадәр казан татарларының борынгы бабалары булган болгарларда нинди язу кулланылуы турында без әлегә кадәр бик аз мәгълүматлар белән канәгатьләнәбез. Ул чорларның язма ядкарьләре безнең көннәргә килеп җитмәгән. Әлегә кадәр мәгълүм булган эпиграфик истәлекләр барысы да соңгырак дәвергә — Алтын Урда чорына карыйлар. Андагы язулар да гарәп яки кайберләре — уйгур хәрефләре белән язылган. Ул ядкарьләрнең телен һәм стилен, шулай ук урта гасыр чит ил авторлары мәгълүматларын өйрәнү нәтиҗәсендә галимнәрдә монголларга кадәрге чорда ук Идел буе болгарлары югары үсешкә ирешкән язу культурасына ия булганнар дигән фикер урнашты. Бу нәтиҗә болгар шәһәрләрен казу вакытында табылган аерым археологик ядкарьләр белән дә раслана иде. Гарәп хәрефле язулар еш кына балчык сфероконусларда һәм бронзадан ясалган әйберләрдә дә очрый.

Мәгълүм булганча, болгарларда гарәп язуының таралуы аларның Урта Азия белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләрендә булулары һәм ислам динен кабул итүләре белән тыгыз бәйләнгән. Ә аңа кадәр болгарларда нинди язу кулланылышта йөргән? Галимнәрдә бу сорау һәрвакытта зур кызыксыну уята. Совет чорында бу мөһим мәсьәлә белән аеруча күп шөгыльләнгән галим Х. Г. Курбатов 50 елларда ук, болгар шәһәрләрендә табылган ядкарьләрдәге билге һәм язуларны, Саркелда, Маяцк шәһәрлегендә, Сент-Миклош хәзинәсендә табылган аз санлы төрки орхон-енисей язмалары белән чагыштырып, Идел-Чулман болгарлары да рун язуы белән таныш булганнар дигән фикергә килгән иде[1]. Соңыннан бу фикер Һ. В. Юсупов, А. Х. Халиков, Г. М. Дәүләтшин хезмәтләрендә яклау тапты һәм өстәмә дәлилләр белән куәтләнде. Мари АССРдагы Юрьино авылында рун язулы таш табылу күренекле совет галиме тюрколог Э. Р. Тенишев өчен Урта Идел регионын төрки рун язуының таралыш ареалына кертергә саллы нигез булды.



Биләрдә табылган рун язулы савыт тоткасы.

Соңгы елларда рун хәрефләренә охшаш билгеләр төшерелгән әйберләр Болгарда, Биләрдә, Хулашта, шулай ук элеккеге болгар авыллары урынында һәм Танкеевск каберлегендә табылды. Рун тамгаларының зур булмаган коллекциясен археолог Е. П. Казаков «Казан утлары» (1983, 6 сан) журналында да бастырып чыгарды. Кагыйдә буларак, алар киң куллану коралларына төшерелгән аерым тамгалардан яки берничә билгедән тора.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы һәм Казан дәүләт университетының профессор А. Х. Халиков җитәкчелегендәге археологик экспедициясе тарафыннан Татарстанның Алексеевск районында урнашкан Биләр шәһәрлегендә 1967 елдан бирле эзлекле рәвештә алып барылган казу эшләре галимнәрнең Идел буе болгарларының язу тарихы турындагы мәгълүматларын тагын да баетты.

Мондый характердагы материалларга, иң беренче чиратта, рун хәрефләренә охшаган билгеләр төшерелгән балчык чүлмәк китекләре керә. Безнең көннәргә кадәр алар савыт-саба төпләренә төшерелгән келәймә сыйфатында килеп җиткәннәр. Хәзер андый келәймәләр коллекциясе 800 гә якын керамик әйберне үз эченә ала[2]. Келәймәгә охшаган билгеләр кайвакытта сөяктән ясалган әйберләрдә һәм башка көнкүреш коралларында да очраштыргалый.

Биләр шәһәрлегендә табылган келәймәләрне системага салу рун хәрефләре белән бәйләргә мөмкин булган билгеләрне ачыкларга ярдәм итте. Ачыкланган барлык сурәтләрнең яртысын рун хәрефләренә охшаш билгеләр тәшкил итә. Аларның кайберләре конкрет рун хәрефләре кебек, кайберләрен исә рун хәрефләренең катлаулandырылган вариантлары дип карап була. Шуның сын да әйтеп үтәргә кирәк, келәймәләргә сурәтләрне төшерү принцибы да рун билгеләрен язу принцибына якын. Биләрдә табылган келәймәләрдә рун язуы билгеләренең барысы да очрый.

Рун билгеләрен башка максатларда файдалану — мәгълүм күренеш. Күпсанлы күзәтүләрдән күренгәнчә, кайбер халыклар, шул исәптән төркиләр дә, язу билгеләрен һәртөрле тамга нигезе итеп файдаланганнар. Мондый күренеш болгарларда, әлешчә әнә шул чүлмәк келәймәләрендә чагылыш тапкан дип әйтергә мөмкин. Көнкүреш әйберләреннән тыш рун язуы билгеләре төшерелгән ритуал әйберләре дә очрый.

Җыелган археологик материаллар Идел буе болгарлары рун алфавиты белән танышкына түгел, ә бәлки аны киң кулланганнар

---

[1] Курбатов Х. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан, 1960.

[2] Кочкина А. Ф. Гончарные клейма Билярского городища.— К-та: Средневековые археологические памятники Татарии. Казань, 1983.

да дигән фикергә ышанычлы дәлил булып тора.

Болгарларда рун язуының киң таралган булуы уникаль табылдык — Биләрдә табылган савыт тоткасындагы язу белән дә раслана. Бу табылдык Биләр шәһәрлегендә генә түгел, ә бөтен Идел буе Болгар дәүләте археологик ядкарьләрендә очраган бу типтагы беренче табылдык. Безнең уебызча, рун язулы бу тотка X—XI гасырларга карый. Мондый тоткалар, элеккеге болгар шәһәрлекләре өчен массовый табылдыклар рәтенә кермәсәләр дә, очрап торалар. Алар төрле җанвар башына, еш кына тәкә, пошн яки берәр кош башына охшатып ясалган булалар. Кайвакытта мондый тоткалар шулкадәр стильләштереләләр ки, хәтта прототипларын да ачыклап булмый. Кагыйдә буларак, мондый тоткалар савытларыннан башка табылалар, шуңа күрә аларның савытларның төгәл бер формасы белән үзара бәйләнешен билгеләве дә кыен. Биләрдә табылган савыт бу уңайдан кайбер нәрсәләрне күзалларга мөмкинлек бирә. Бу — өч кыска аякта торган оригиналь савыт — трипод — формасы белән чүлмәккә охшаган, әмма аннан тәбәнәгрәк, базыграк. Савытның җентекле пөхтә эшләнеше һәм купшы бизәлеше аны тантаналы мәҗлесләр өчен махсус эшләгәннәр дип фикер йөртергә нигез бирә. Тотка үзе әтәч башын хәтерләтә: кыска гына очлы томшык, сакалчык һәм кабарынкы кикрик. Язу савыт тоткасына әле аны яндырып чыныктырганчы ук очлы корал белән төшерелгән. Язуның ышанычлы төстә язылган булуы рун язуы белән таныш борынгы остаңың маһир куллы икәнлеген искәртеп тора. Барлык билгеләр дә пөхтә, ачык итеп төшерелгән, бары тик дүртенче билгене язганда гына тигезлек югалган, шуңа күрә дуга сыман сызык урынына сынык сызык хасил булган.

Юлның биеклеге 1—1,5 см. Язу барысы биш билгедән һәм сүз аергычтан тора. Соңгысына караганда, язу уңнан сулга таба укылырга тиеш. Биләрдә табылган язманың палеографик үзенчәлекләрен тикшерү һәм аны башка тарихи истәлекләрдә сакланып калган рун язуы үрнәкләре белән чагыштыру, тикшерелә торган язманың Төньяк Кавказ һәм Идел-Дон төбәкләрендә (Саркел, Хумарин һәм Маяцк шәһәрлекләрендә) табылган рун язмаларына якынлыгы турында фараз итәргә мөмкинлек бирә. Моңа югарыда күрсәтелгән төбәкләрдә яшәүче кайбер халыкларның кардәшлеге дә каршы килми. Әгәр дә бер төркем тюркологлар тарафыннан ул төбәкләрдә табылган язуларның протоболгар теленә нисбәт ителүен дә искә алсак, бу инде безнең фикерне тагын да ныгыта төшә. Биләрдә табылган рун язуын уку һәм тәрҗемә итүдә соңгы сүзне белгечләр хөкеменә тапшырып бу уңайдан үзебезнең кайбер фикерләр белән уртаклашасы килә. Биләр язмасын укуда рун язуының Төньяк Кавказ варианты үзенчәлекләрен искә алганда, язмадагы хәрефбилгеләрне түбәндәге тәртиптә укырга мөмкин булыр иде: уңнан сулга беренчесе «а» яки «ә», икенчесе «ш» яки «ч», өченчесе «т», дүртенчесе «ай», бишенчесе «н». Килеп чыккан сүзтезмәгә — «аштайн» яки «әчтәйн» — борынгы төрки теле сүзлегендә тәңгәл килә торган гыйбарәләр юк. Әмма аңа охшаш сүзләрне бу сүзлектән табарга була һәм алар мәгънә ягыннан да бер-берсенә якын киләләр: «аш» — ашамлык, «аш тат» — ризыкны татып карау, «тай на» — әчегән сөт. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып савыт тоткасындагы язуны ризык кабул иткәндә әйтелә торган тәбрик-теләк яки савытның нинди ашамлык өчен кулланылганын белдерүче язу дип уйларга мөмкин. Сөт ризыкларының борынгы заманнардан бирле төрки халыкларының яраткан ашы булуы киң мәгълүм. Мәсәлән, борынгы кыргыз халык эпосы «Манас»та әчегән сөттән ясалган «эжигей» исемле әчемлекнең тәмлелеге һәм, шулай ук, дәвалау үзенчәлекләре турында да сөйләнелә. (Кара: «Социалистик Татарстан», 1985, 24 февраль). Биләрдә табылган язуны укуда без тәкъдим иткән версия Э. Р. Тенишев тарафыннан да хупланды.

Тоткадагы язу нәрсәне булса да аңлатканны исәпкә алмаган очракта да бу табылдык фәндә моңа кадәр яшәп килгән һәм Идел буе болгарлары рун язуы белән таныш булганнар дигән фикерне генә түгел, ә бәлки рун язуының аларда озак вакыт кулланылышта булуын да исбатлый. Бу уникаль табылдык Болгар илен ышанычлы рәвештә борынгы төрки рун язмасы таралган ареалга кертергә мөмкинлек бирә. Рун язуы Урта Иделгә Салтово-Маяцк культурасы белән турыдан-туры бәйләнештә булган һәм Идел буе Болгар дәүләтенең культурасын һәм халкын формалаштыруда актив катнашкан кабиләләр тарафыннан китерелгән булырга тиеш.

Идел болгарларында рун язуы традицияләре төрле келәймәләрдә сакланган тамга яки шәхси милек билгеләре нигезен формалаштыруда да чагылыш тапкан. Урта Иделдә рун язмалары әлегә кадәр сирәк табылса да, казан татарларының борынгы бабалары булган болгарларның бер өлешендә рун язуы гарәп алфавиты белән бергәттән кулланылган дип әйтергә нигез бар. Шуңа күрә археологик тикшеренүләрдән Идел буе болгарлары язма культурасының әлегә кадәр билгеле булмаган сәхифәләрен ямтыртырлык яңа кызыклы табылдыклар өмет итәргә була.

**Анна КОЧКИНА.**
*Куйбышев шәһәре.*

# Археолог А. Кочкинаның «Идел буе болгарларында рун язуы» исемле мәкаләсенә карата

Үз чорының белемле кешесе төшергән бу рун язуын. Сүз азагы билгесен — ике нокта куярга да онытмаган. Әмма бу бер генә сүздән торган язманың дөрес әйтелеше ничек — хәзергә ул ачык кала. Әгәр язма берничә сүздән, бигрәк тә берничә җөмләдән торса, хәрефләрне һәм аларның нинди авазларны белдергәнен чагыштыра-чагыштыра, анык укылышка ирешеп булыр иде.

Рун язуы (борынгы скандинавлылар телендәге run «сер» дигән сүздән) үзенең килеп чыгышы буенча арами алфавитына барып тоташа. Гуннар, болгарлар һәм башка борынгы төрки халыклар аны, согдиларның курсив язуы билгеләреннән файдаланып, үз телләренә җайлаштырганнар. Төрки халыклар урнашкан төрле төбәкләрдә ул төрлечәрәк булган. Һәм барыннан да бигрәк, бу язу өчен шул үзенчәлекле: анда сүзнең калынлыгы-нечкәлеге — сузыклар гармониясе (өлешчә иренләшү гармониясе дә) кагыйдәгә нигез итеп алына (морфонологик принцип). Бер үк тартык аваз өчен калын сүздә — бер төрле, икенче сүздә икенче төрле билге кулланыла. Сузык аваз күп очракта күрсәтелми (җитмәсә, бер үк хәреф калын сузыкка да, нечкәсенә дә йөри) — аның нинди булуы янәшә тартык аша аңлашыла. Язылышы — уңнан сулга.

Яшь археолог, керамика технологиясе белгече Анна Федоровна Кочкина тапкан савыт тоткасындагы язманы, мәкаләдә тәкъдим ителгәндәгедән аермалы буларак, «ачыткан» дип укырга була. Ягъни уңнан сулга беренче хәреф «а», икенчесе «чы», өченчесе «т», дүртенчесе «ка», бишенчесе «н» авазларын белдерә. Нәкъ шундый авазларга туры килгән хәрефләр рун алфавитының җыелма таблицаларында бар.

Эчендә нәрсә икәнлеге күренеп тормаган савытка аның ни өчен икәнен язып кую гаҗәп түгел. Казан шәһәр музеенда сакланган шундый балчык чүлмәкләрнең берсен — өстенә рун хәрефләре белән «ичиг су» дип язылганын — Э. Ленц үзенең бер хезмәтендә искә алып үтә[1].

Әлеге язманың дүртенче хәрефе «й» авазын белдергән билгегә дә берникадәр ошаган — ул вакытта «Ачытйан» яки «Ачыйтйан» укылышы килеп чыга. Савытны ясаучының исememe бу? Ләкин оста үзенең исемен тулысынча язып торырмы — алар, гадәттә, кыска итеп, үз тамгаларын гына сугалар. Әллә ул сүз шушы савыт иясенең исемеме? Һәм гомумән, андый ялгызлык исем булырмы? Төрки телләр фонетикасы өчен «к» — «г» — «й» тәңгәллеге хас. Әллә шул дүртенче хәреф «ачыткан» сүзенең төрле төрки төбәктә төрлечә яңгырашымы: «ачыткан» — кыпчак төркемендә, «ачыйтйан» («ачытган») — угызларда.

Һәрхәлдә, бу язманы «ачыткан» дип уку дөреслеккә якынрак булыр.

**Хәлиф КУРБАТОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

---

[1] Ленц Э. О глиняных сосудах с коническим дном, находимых в пределах мусульманского Востока.— «Записки Вост. отд. Имп. археол. общ-ва». Том XV, вып. IV, 1904, 0101—0112 бб. (фотоpесемнәре — 0112 биттә).

# МОҢЛЫ ГОМЕР

Татар музыкасы тарихында утызынчы еллар аерым урын алып тора. Бу республикада социалистик музыкаль культураны актив тəзү, профессиональ музыка иҗатын зур тизлек белəн үстерү еллары иде. Шул чорда Мəскəү, Ленинград шəһəрлəренең музыкаль уку йортларында милли кадрлар əзерлəнде. Алар арасыннан Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев, Нəҗип Җиһанов, Фəрит Яруллин, Җəүдəт Фəйзи, Заһит Хəбибуллин кебек композиторлар, Сара Садыйкова, Фəхри Насретдинов, Мөнирə Булатова кебек башкаручылар үсеп чыкты. Шушы буын вəкиле булган талантлы скрипкачы, югары профессиональ музыкант, фольклорчы галим Хəсəн Гобəйдуллин — татар совет музыкаль культурасы үсешенə зур хезмəт күрсəткəн кеше дəрəҗəсенə күтəрелде. Хəлбуки, аның эшчəнлеге бүгенгə кадəр тиешенчə яктыртылганы юк əле.

Замандашлары сөйлəвенчə, Хəсəн Гобəйдуллин композиторлар һəм музыкантлар белəн зур иҗади дуслыкта яши. 1934 елгы бер фоторəсемдə ул Муса Җəлил, Александр Ключарев һəм Җəүдəт Фəйзи белəн төшкəн. (Бу рəсем беренче тапкыр «Музыкаль Татарстан» дигəн китапта урнаштырыла). «Композиторлар эшкəртүендə татар халык көйлəре» дигəн китабында (1964) Мəхмүт Нигъмəтҗанов 1935 елда Хəсəн Гобəйдуллин җыеп, язып алган Касыйм татарлары җырларын бу төбəк музыкаль фольклорының бердəнбер документы итеп атый. Р. Исхакова — Вамба төзегəн «Татар халык җырлары» китабына (1981) Х. Гобəйдуллин язып алган һəм эшкəрткəн 11 көй кертелгəн.

Хəсəн Миңлевəли улы Гобəйдуллин 1904 елда Петропавловск шəһəрендə тимер юлчы гаилəсендə туган. Башлангыч музыкаль белемне ул Омск музыка училищесы каршындагы музыка мəктəбендə ала. 1926—1928 елларда Казан шəрык музыка техникумында А. Литвинов җитəклəгəн скрипка классында, аннары бер ел Уфадагы музыка техникумында укый. Аны тəмамлаганнан соң Ленинград консерваториясенең радио бүлегенə укырга керə һəм 1933 елда югары квалификацияле музыкаль тапшырулар редакторы таныклыгы белəн Казанга кайта. Монда ул шул заманның кайнап торган иҗтимагый-музыкаль тормышына чума.

Социалистик музыкаль культура тудыру гаять катлаулы бурыч иде. Композиторлык иҗатын уңышлы үстерү өчен, бер яктан, музыка сəнгатен үстерүдə фидакарьлек күрсəтердəй белемле башкаручы кадрлар зарур булса, икенче яктан, яңа сəнгатьне аңларга əзерлеге җитəрдəй тыңлаучысы булуы да шарт иде. Мəгълүм ки, башкаручысы белəн тыңлаучысы булмаганда, телəсə нинди, хəтта иң гүзəл əсəр дə җансыз килеш ята бирə. Х. Гобəйдуллин шушы өчлек — композитор, башкаручы, тыңлаучы арасында элемтə урнаштыруда күп көч куя, яңа культура казанышларын пропагандалый, яңа совет тыңлаучысын тəрбиялəүне үз бурычы итеп саный. Тыңлаучыларны оста һəм рухланып уйнавы белəн сокландырып, ул бик еш концертлар бирə. Композитор Заһит Хəбибуллин менə болай искə ала: «Хəсəн Миңлевəлиевичны мин бигрəк тə скрипкачы буларак оныта алмыйм. Ул чын артист иде. Аның уң кулы гаҗəп гүзəл иде. Ə сул кул бармакларының җитезлеге «күзлəрне камаштырырлык» иде. Ул матур һəм тигез «аваз» белəн, халык иҗатының бөтен нечкəлеклəрен белеп, татар һəм башкорт көйлəрен башкара. Репертуарында шулай ук Европа һəм рус классикасының скрипка өчен язылган иң яхшы əсəрлəре дə бар иде. Нəфис зəвыклы музыкант иде Хəсəн, коллегалары аны хөрмəт итə, ярата иде. Аның һəр чыгышы хуплап каршы алынды, вакытлы матбугат исə талантлы скрипкачы турында күп тапкырлар язып чыкты...»

Радиода музыкаль тапшырулар редакторы буларак, Х. Гобəйдуллин бу вазифаның никадəр җаваплы эш икəнлеген аңлап эшли. Ул елларда радио халыкны музыкаль эстетик яктан тəрбиялəүдə һəм музыка сəнгатен пропагандалауда бик əһəмиятле чараларның берсе иде. Редактор эшкə дəртлəнеп торуы белəн башкаларны да рухландыра. Шушы елларда аның белəн бергə эшлəгəн Зəйнəп Хəйруллина болай искə ала: «Яшь белгеч эшкə бөтен барлыгы белəн тотынды. Ул килгəч, музыкаль тапшырулар һəм эчтəлек, һəм форма ягыннан шактый баедылар».

Хəсəн Гобəйдуллин башкару һəм редакторлык эше белəн генə чиклəнеп калмый. Аның фольклорчы буларак эшчəнлеге аерым əһəмияткə ия. Халык музыкасына ул балачактан гашыйк була.

1934 елда Татарстан Мəгариф Халык Комиссариаты Хəсəн Гобəйдуллинны СССР Фəннəр академиясенең Ленинград антропология һəм этнография институты аспирантурасына укырга җибəрə. Утызынчы елларда монда, СССР халыклары музыкасын җыю һəм өйрəнү эше бер үзəккə тупланып, социалистик төзелеш бурычлары белəн тыгыз

бәйләнгән идеология фәне буларак, совет фольклористикасының төп принциплары формалаша.

Совет властеның милли политикасы яктылыгында милли культураларны үстерү бурычы беренче планга куелды. Монда инде фольклористика проблемалары белән практик музыкаль иҗат проблемаларының тыгыз бәйләнештә икәнлеге ачыкланды. Бу хәл, экспедицияләр оештырып, халык авыз иҗатын фән нигезендә җыя башлауга китерде. Институтның фонограммалар архивына гаять бай материал туплана. Шул фондларда аспирант Х. Гобәйдуллинның 1934 елда Мари автономияле республикасына барып язган фонографик язмалары да бар. Анда авыл җырлары һәм төрле уен коралларында башкарылган көйләр язылган. Ә шул ук елның сентябрендә Татарстанның Беренче Май һәм Шөгер районнарында булганда ул татар көйләрен яздырып ала. 1935 елда композитор Н. Чаплыгин һәм шагыйрь Ә. Еникәй белән бергә Хәсән Гобәйдуллин Касыйм районына музыкаль фольклор җыярга бара. Монда рус һәм татар авыл җырлары языла. Җырларны кәгазьгә күчерү Е. Гиппиус җитәкчелегендә зур тәгәллек белән эшләнә. Соңрак бу таләпләр Е. Гиппиусның «аналитик нотация» принциплары нигезенә ята.

Аспирантурада укыганда Х. Гобәйдуллин совет фольклористикасының методологик принципларын өйрәнә, җыю эшенең техникасын һәм методикасын үзләштерә.

Архив документлары арасында мари авылларында эшләгән экспедиция турында отчет саклаган. Аннан без Х. Гобәйдуллинның фольклорчылык эше турында фикер йөртә алабыз. Экспедиция СССР Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы тел һәм язмачылык комитеты тарафыннан, фәнни-тикшеренү институты белән берлектә, мари теленең үзенчәлекләрен өйрәнү, шулай ук халыкның поэтик һәм музыкаль авыз иҗаты әсәрләрен язып алу өчен оештырыла. Х. Гобәйдуллин эшләгән отряд Таулы Мари районында тикшеренү эшләре алып бара (унбишләп авыл). Отчетта тау ягы марилары белән болын ягы марилары культурасындагы мәгълүм аерымлыклар географик үзенчәлекләр белән бәйләп аңлатыла. Отчетта бер үзенчәлек күрсәтеп үтелә: һәр авылның үз җырлары бар, һәм башка авыллар җырларын бу авылда белмиләр дә, белергә дә теләмиләр. Чит җырлар җырлау бу якта үзеңне үзең санламауга исәпләнә икән.

Тупланган материал нигезендә Х. Гобәйдуллин мари җырларына хас үзенчәлекләрне күрсәтә:

1. Мари музыкасы бер тавышлы. Ансамбль һәм хор белән җырлаганда униссонга җырлана.
2. Авазлар пентатоникага корылган. Моннан тайпылу бик сирәк очрый.
3. Мари җырлары ике кисәктән тора, икенче кисәк беренчесен тулысы белән кабатлый диярлек, ләкин бер квинтага түбәнрәк була.
4. Җырның үлчәме бик симметрияле, речитативлык юк.
5. Бизәкләр юк.
6. Иҗекләрне сузу юк.
7. Киң интерваллар бар.
8. һәр җырның үз сүзләре бар.

Инструменталь музыкага тукталып, Х. Гобәйдуллин түбәндәге уен коралларын күрсәтә:

1. Төрле гармуннар. Алар асылда көй уйнау өчен кулланылалар.
2. Гөслә-кусле. Тау ягында гөсләдә хатын-кызлар уйный, болын ягында — ирләр генә диярлек.
3. Тынлы уен кораллары төркеме: озынча флейта, аркылы флейта һәм һәрчак кул астында булуы белән уңайлы агач яфрагы. Кайберәүләр яфрак белән гаҗәп матур көй чыгара беләләр.

Моннан тыш, Х. Гобәйдуллин шөбер дигән уен коралын атый. Ул мөгез һәм куыктан гыйбарәт. Аның үзенә генә хас — туйда уйный торган репертуары бар. Ул — туйны башлау җыры, туй биюе, озак җырланучы туй җыры, карак җыры. Шөбергә еш кына дөмбер-кечерәк кенә барабан да кушыла.

Бу экспедиция мари җырларын фонографка беренче булып язып ала. Шуңа күрә Х. Гобәйдуллин мари халкының җыр иҗаты хакында кистереп йомгак ясамый тора. «Мари халык авыз иҗатының аз өйрәнелгән булуы,— дип яза ул,— экспедиция эшен дәвам иттерүне һәм тагын ике районда фольклор җыюны таләп итә. Шулай иткәндә генә проблемаларны хәл итүгә якын килергә мөмкин...»

Диссертация өстендә эшләү барышында татар халык музыкасын язып алу һәм өйрәнү өчен экспедициягә чыгуны да күздә тота. Шул максат белән ул Беренче Май һәм Шөгер районнарына бара. Анда җырлар язып алу белән бергә, үзе дә концертлар оештырып, скрипкада уйный, музыка турында әңгәмәләр үткәрә, рәсемнәр ясый (аның андый сәләте дә була). Бу экспедициядә язып алынган «һавааларда йолдыз» җыры Р. Исхакова-Вамба җыентыгына да кертелгән. 1935 елда Рязань өлкәсенең Касыйм районына оештырылган экспедиция дә үз алдына татар совет фольклорын өйрәнү бурычын куя.

Экспедиция материалларына нигезләнеп, Х. Гобәйдуллин «Касыйм татарлары җырлары» дигән мәкаләсен яза. Анда автор, Касыйм татарлары фольклорының музыкаль стилистикасы турында актык фикерне әйтү иртәрәк булыр иде, ди. Мәсьәлә киңрәк куелырга тиеш — Идел һәм Касыйм татарлары авыз иҗаты турында заман таләпләренә җавап бирә алырлык фәнни тикшеренүләр бастырып чыгарырга кирәк, ди ул. М. Нигъмәтҗановның «Идел татарлары халык җырлары» китабында (1982) Х. Гобәйдуллин тикшеренүләренә «Касыйм татарлары музыкасы буенча галимнәре киләчәк өчен бик кыйммәтле бердәнбер хезмәт», дип, югары бәя бирелә.

Х. Гобәйдуллин язмаларындагы әсәрләрне совет чорында гына туган әсәрләр дип әйтеп булмый. Аларның һәркайсының диярлек революциягә кадәр үк элгәрләре булган. Аларны я тематикасы, я башкару рәвешләре заманча итә. «Кызыл эскадрон» җырын алып карыйк. Ул Р. Исхакова-Вамба җыентыгында өченче җыр итеп урнаштырылган. Ачык ритм. Темасы — гражданнар сугышы. Сафта барганда җырлана торган типик җыр. А. Ключаревның 1941 елда чыккан җыентыгында шул ук җыр «Күгәрчен» исеме белән яңа сүзләргә җырлана торган, Октябрьгә хәтле туган җырлар бүлегендә бирелә. Аңлатмада аның гасыр башында лирик сүзләр белән җырлануы, ә гражданнар сугышы вакытында бигрәк тә киң таралып китүе әйтелә. Музыкаль стилистикасы ягыннан ул типик кыска көй. Тематикасы — гражданнар сугышыннан соң яңа тормыш төзү. Бу җыр да утызынчы еллар тирәсендә язып алынган. М. Нигъмәтҗанов җыентыгында аның Казанда Х. Алмаевадан язып алынган «Күгәрчен гөрлидер» дигән варианты бирелә. Ул А. Ключарев җыентыгындагы җыр белән бик охшаш. Автор бу көйнең егерменче елларда Оренбург өлкәсендә яшәүче татарлар арасында бик популяр булганлыгын күрсәтеп уза.

Х. Гобәйдуллин язмаларына кире кайтып, Р. Исхакова-Вамба китабында 106 нчы номер белән урнаштырылган «Оренбург кала» җырына игътибар итик. Монда бөтенләй башка җыр булган «Кызыл эскадрон» белән ап-ачык бәйләнеш сизелә. Ә җавапны аңлатмадан табып була — ике җыр да бер үк башкаручыдан язып алынган икән. Җәүдәт Фәйзи җыентыгында «Оренбург кала» җырының бер варианты «Сандугач-күгәрчен» исеме белән урнаштырыла. Бу очракта инде җырның ритмы һәм характеры бөтенләй үзгәрә, ә аның структурасы һәм интонацион әйләнмәләре ныклырак элемент булып калалар.

Күргәнебезчә, Х. Гобәйдуллин язмалары утызынчы еллар музыкаль фольклорының фәнни нигезләнгән, «тавышлы документ»лары булып торалар. Аларны түкми-чәчми кәгазьгә күчерәсе һәм фәнни хәрәкәткә кертәсе бар.

1940 елның 30 июнендә РСФСР составындагы автономияле республикалар композиторларының иҗади конференциясендә Х. Гобәйдуллин ясаган чыгыш зур әһәмияткә ия. Анда аның халык сәнгатенең мөстәкыйль кыйммәткә ия булуына инанганлыгы, фольклорның читтән тәэсирләрне кабул итә-итә үсә торган аерым бер сәнгать дөньясы икәнлеген тирәнтен аңлавы чагылыш таба. Х. Гобәйдуллин фольклорны өйрәнгәндә бар мәсьәләне музыкаль ладка гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде ди, чөнки халыкның музыкаль теле бик күп элементлардан тора. Кызганычка каршы, аларның күбесе темпка корылган уен коралларында башкарылганда тонықланалар, юкка чыгалар. Аннары ул татар җырының гаять үзенчәлекле хасиятенә — аның бизәк чараларына туктала. Бизәк чараларының күп булуын музыкант күптавышлылыкның булмавы нәтиҗәсе дип исәпли. Төп көйне бизәкләп җырлый-җырлый, башкаручы ладның ныклыгына ирешә.

Х. Гобәйдуллин куйган мәсьәләләр бүгенге көндә дә яшәүчән һәм бик актуаль яңгырыйлар: халык авыз иҗатын тирәнтен өйрәнү профессиональ музыка үсешенең иң кирәкле шарты булып тора.

Кызганычка каршы, Х. Гобәйдуллин үз алдына куйган максатларының барысын да үтәп чыга алмый калды. Ул 1941 елда 36 яшендә Бөек Ватан сугышы башланырга ике көн кала вафат булды. Матбугат өчен әзерләнгән «Касыйм татарлары җырлары» дөнья күрми калды, диссертациясе өзелгән җирендә тукталды. Сугыштан соң күп нәрсә югалган, онытылган булып чыкты. Яңа проблемалар барлыкка килде. Әмма без музыкаль культурабыз үсешенә, татар совет музыкаль фольклористикасына бөтен көчен биргән һәм шул вакытта ук инде аның интернациональ нигезен аңлаган кеше алдында бурычлы булып калырга тиеш түгелбез. Хәсән Гобәйдуллин чын югары профессиональ дәрәҗәгә ирешкән музыкант-галимебез иде. Аның мирасы әле җитди өйрәнүне көтеп ята. Уңышлы төстә алга бару өчен бездән үткән буын тикшеренүчеләр яулаган белемнәрне җентекләп өйрәнү таләп итела.

**Халидә ФӘРХЕТДИНОВА,**
Казан шәһәренең П. И. Чайковский исемендәге
1 нче музыка мәктәбе укытучысы.

# ИБНЕ ФАЗЛАН СӘЯХӘТНАМӘСЕ ҺӘМ «КӘЛИЛӘ ВӘ ДИМНӘ» ТУРЫНДА

Борыңгы Болгар дәүләтенә чордаш истәлекләр арасында Ибне Фазланның сәяхәтнамәсе аерым урын алып тора. Сәяхәтнамәне рус теленә тәрҗемә итүче һәм аны тәфсилләп өйрәнүче А. П. Ковалевскийның сүзләре белән әйткәндә, «Ибне Фазланның китабы СССР халыклары тарихына караган чыганакларның алтын фондын тәшкил итә»[1].

Галимнәр Ибне Фазлан сәяхәтнамәсенә әледән-әле мөрәҗәгать итәләр, аны кайта-кайта тикшерәләр, яңа ачышлар ясыйлар. Безнең илебездә генә дә бу мәшһүр сәяхәтнамә ике тапкыр нәшер ителде: беренче тапкыр 1939 елда, икенчесе 1956 елда Харьковта басылып чыкты.

Сүрия гарәп республикасы галимнәре Ибне Фазланның Болгарга сәяхәтен өйрәнүгә күп тырышлык куялар. Башка гарәп илләрендә дә галимнәр әледән-әле мәкаләләр язалар, китаптан өзекләр алып, аларны анализлап, фәнни бәхәсле мәсьәләләрне газета-журнал битләрендә бастыргалыйлар. Ләкин Сүрия галимнәре, алардан аермалы буларак, шактый җитди юнәлештә эшлиләр. Мәсәлән, соңгы елларда гына гарәп халкының борынгы мирасын өйрәнү, яңадан торгызу Департаменты тарафыннан бу сәяхәтнамә ике тапкыр нәшер ителде. Күләме ягыннан зур булмаган бу китап (ул 195 биттән тора) «Рисаләтүн Ибне Фазлан» (ягъни «Ибне Фазлан илчелеге») дип атала[2]. Аны басмага әзерләүче галим филология фәннәре докторы Мөхәммәд Самий әд-Дәһһан. Аның бу хезмәте һичшиксез олы мактауга лаек.

Шунысын да искәртеп китү урынлы булыр: авторның, һәм башка күп кенә гарәп галимнәренең әйтүенә караганда, Ибне Фазланның төрки халыклар, җөмләдән болгарлар, хәзерләр арасына, шулай ук руслар яшәгән якларга сәяхәте турындагы тарихи язма һәм башка гарәп сәяхәтнамәләре арасында иң әһәмиятлесе булып санала икән[3]. «Гарәп ватаныбызның төрле почмакларында яшәүче, аның борынгы мирасы, тарихы белән кызыксынган күпсанлы укучыларыбызның теләкләрен канәгатьләндерү ниятеннән чыгып, Сүрия хөкүмәтебез культура министрлыгы Ибне Фазланның бу мәшһүр сәяхәтнамәсен икенче тапкыр нәшер итүне кирәк тапты»,— диелә кереш мәкаләдә. Шуны да өстәп китәргә кирәк, әлегә кадәр гарәп илләрендә Ибне Фазланның Болгарга сәяхәтенең тексты мондый күләмдә, ягъни тулы килеш нәшер ителгәне юк иде.

Мөхәммәт Самий әд-Дәһһан китапны әзерләү процессында иң элек Ибне Фазлан әсәренең Иранда Мәшһәд шәһәре китапханәсе фондында табылган уникаль кульъязмасын нигез итеп алган, әлбәттә. Моңардан тыш ул гарәп, фарсы, инглиз, немец, рус, чех, венгр телләрендә чыккан, Ибне Фазлан сәяхәтенә кагылышлы булган фәнни хезмәтләрне дә актив җәлеп иткән. Шулай ук дөньяның төрле илләрендәге Көнчыгышны өйрәнүче мәшһүр галимнәр белән дә очрашкан, аларның фикерләрен өйрәнгән. Шуңа күрә китапны укып чыгуга, Самий әд-Дәһһанның ифрат дәрәҗәдә зур эш башкарганлыгын күреп таң калмыйча булдыра алмыйсың.

Кереш мәкаләдән соң килгән өлештә истәлеккә фәнни анализ ясауга шактый зур урын бирелгән. Тәфсилле анализ белән бергә шул чордагы халыкара мөнәсәбәтләр, сәяси хәлләр турында, ерак илләргә оештырылган төрле сәяхәтләрнең максатлары, шулай ук Ибне Хордәдбәһ, Кодәмә Ибне Җәгъфәр, әл-Ягъкуби, Ибне Фәкыйһ, әл-Хәмадани, Ибне Рөстә, Ибне Хәукаль, әл-Истәхри һәм башка гарәп авторлары турында да бай мәгълүмат бирелгән. Шулай ук гарәпләрнең әл-Әндалустан (Испаниядәге бер өлкәдән) алып Кытайга кадәрге булган җирләрдә яшәгән халыкларның гореф-гадәтләрен, дәүләт төзелешләрен, әйләнә-тирә мохитларын өйрәнгәннекләре һәм зур күләмле хезмәтләр язып калдырулары турында киңәннән бәян ителә. Әлбәттә, дип дәвам итә Самий әд-Дәһһан, ул хезмәтләрнең барысын да бүгенге җитди таләпләргә җавап бирерлек югарылыкта язылган дип уйларга ярамый, ләкин аларның күпчелеге тарих, география, тел һәм башка өлкәләрдә эшләүче галимнәр өчен зур игътибарга лаеклар, чөнки алар кыйммәтле чыганаклар булып кала бирәләр.

Эчтәлекле фәнни анализдан соң өч биттә Мәшһәд кульъязмасының фотокүчермәсе бирелгән. Алар 1956 елда Харьковта басылып чыккан А. П. Ковалевский китабыннан алынганнар. Шунда ук фарсы телендә басылып чыккан хезмәттән алынган Ибне Фазлан сәяхәтенең маршрутын чагылдыручы ике махсус карта да урнаштырылган.

Димәшкъта нәшер ителгән китап бүгенге көндә билгеле булган Ибне Фазлан турындагы башка хезмәтләрдән шул ягы белән аерылып тора: биредә хикәяләр бер-берсеннән аерым рәвештә, билгеле бер сан астында бирелә. Шул рәвешчә, Ибне Фазланның сәяхәтнамәсе егерме дүрт бабка, ягъни бүлеккә

---

[1] Ковалевский А. П. Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921—922 гг. Харьков, 1956, 7 б.

[2] Рисаләтүн Ибне Фазлан. Икенче басма. Димәшкъ. 1977.

[3] Шунда ук. 5 б.

бүленгән. һәр баб бер, ике, яисә өч кыска хикәятләрдән тора. Мәсәлән, төркиләр, фарсылар, Бохара, Харәзм, Җөрҗания, Газзия, бәҗәнәкләр, болгарлар, руслар, хәзәрләр турында аерым бабларда сөйләнә. Мондый ысулны куллану китаптан файдалануны тагын да уңышлырак итә.




Сүриядә басылган «Ибне Фазлан илчелеге» китабының тышлык бите

Текстларда очрый торган кабилә, кеше исемнәре, географик һәм башка атамалар да хәрәкәләр (дөрес уку өчен кулланыла торган гарәп язуындагы ас-өс билгеләре) белән язылган. Шуңа күрә кыен укылышлы сүзләрне, исемнәрне, атамаларны бозмыйча укырга мөмкин. Мәсәлән, Итил, Суар һәм башка исемнәр.

Итил (елга) исемен кайбер галимнәр Атыл, Атал дип тә укыйлар. Ибне Фазлан китабының оригиналында бу исем гарәп алфавитының «әлиф» һәм «тә» (ба хәрефләреннән соң килә торган тел алды авазын белдерүче ике нокталы билге) хәрефе белән язылган, әмма эмфатик «та» хәрефе белән түгел. Димәк, ул шулай «Итил» дип укылырга тиеш, ә Атал яисә Атыл түгел.

Сәяхәтнамәдә эмфатик «та» хәрефе белән язылган сүзләр дә аз очрамый, әмма кучереп язучы беркайда да «тә» хәрефен эмфатик «та» белән бутамаган. Гарәп географы әл-Идриси төзеп калдырган картада да Итил елгасы дип язылган[4]. Егерме биш ел буена сәяхәттә булып, күп илләрне гизгән, чыгышы белән сахрада тормыш итүче бәдәви гарәпләреннән булган тарихчы Ибне Баттутә (тулы исеме Әбу Габдулла Мөхәммәд Ибне Габдулла Ибне Мөхәммәд Ибне Ибраһим әт-Танҗий) төзегән картада да шулай ук Итил дип язылган[5]. Бу ике галим төзеп калдырган карталарның нөсхәләрен Багдад шәһәренең «Бәйтел-хикмә» музеенда әле бүген дә күрергә мөмкин.

Китапны төзүче автор гарәпләрнең җәһилийә чорында ук (ислам диненә кадәр булган чорны гарәп әдәбиятында шулай атыйлар) сәяхәтләргә бик маһир булуларын, теләп илләр гизүләрен күрсәтеп үтә. Мисал итеп Имрулькайс исемле шагыйрьнең Константинополь (хәзерге Истанбул) шәһәренә сәяхәт иткәнлеген һәм «Әнкарә»гә диган шигырь язганлыгын да әйтеп үтә. (19 б.)

«Ибне Фазлан илчелеге» китабын укып чыккач габбасилар чоры әдибе Ибне әл-Мокаффәгъның «Кәлилә вә Димнә» исемле әсәре искә төшә. Ибне Фазланның язу стиле, хикәятләрнең бәян ителүе барыбызга да балачактан мәгълүм булган «Мең дә бер кичә», ә кайберләре «Кәлилә вә Димнә» хикәятләрен хәтерләтә. «Кәлилә вә Димнә» әсәре, әлбәттә, сәяхәтнамәдән аермалы буларак икенче максатны күздә тотып язылган, ләкин аларның икесе өчен дә уртак мотивларның барлыгын инкарь итү хата булыр иде. Мәсәлән, әхлаксызлык, караклык, зина кылучыларга җәза бирү һәм башка күренешләр Ибне әл-Мокаффәгъның «Кәлилә вә Димнә»сендә, Ибне Фазланның сәяхәтнамәсендә дә күзгә бәрелеп тора.

Әйтеп үтүебезчә, бу әсәрнең икесе ике төрле стильдә башкарылган. Берсе олы затлар, хөкемдарлар өчен үгет-нәсихәт рухы белән сугарылып язылган булса, икенчесе халыклар, илләр, диннәр хәбәр итү максатыннан чыгып язылган. Шулай да Ибне Фазлан сәяхәтнамәсен А. П. Ковалевский һәм башка Европа галимнәренең «Мең дә бер кичә» белән чагыштырып караулары бер дә гаҗәпкә калдырмый.

«Кәлилә вә Димнә»не Ибне әл-Мокаффәгъ якынча безнең эраның 750 елларында тәрҗемә иткән. Ибне Фазланның Болгарга сәяхәте исә ике гасырга якын соңрак булган. Бу вакытта «Кәлилә вә Димнә»нең дисталәгән гарәпчә версияләре таралган була. Хәтта аны яңадан тәрҗемә итеп тә караганнар, шул рәвешчә икенче төрлерәк, ягъни «дине исламиягә» муафыйграк итеп эшләнгән иреклә тәрҗемәләрен дә тудырганнар. Моны исбатлар өчен бүгенге көндә Багдадтагы милли китапханәдә саклана торган «Кәлилә вә Димнә»нең шул чорда язылган кульязмалары барлыгын искә алу да җитә. Багдад шәһәрендәге «Бәйтел-хикмә»дә йөзләгән грек, һинд, фарсы, ассирия һәм күп кенә башка телләрдә язылган фәнни китаплар саклангән, аларны гарәп теленә тәрҗемә итү белән зур осталар шөгыльләнгәннәр. Болар барысы да Ибне

4 «Нейшенал Жеографик» журналы, июль, 1972. Вашингтон, 11 б.

5 «Әл-Гарәби» журналы, Кувейт, 1976. 213 сан. 29 б.

Фазланның «Кәлилә вә Димнә» белән яхшы таныш булуын таныргa мәҗбүр итә. Аның мәдәниятле, олы әхлаклы, укымышлы, диндар, сүзгә маһир, беркайчан да югалып калмый торган, малның кадерен белүче бер зат булганлыгына ышанмау мөмкин түгел дип яза Самий әд-Дәһһан (18 бит).

Ибне Фазлан нисбәсе фарсылар арасында юк түгел. Фазыл — гарәп сүзе, ә «ан» кушымчасы фарсы телендә күплек санын белдерә. Шулай итеп, Фазлан, Фазыйлан нисбәсен зыялылар, укымышлылар дип тәрҗемә итәргә дә мөмкин икән.

Гыйрак гарәпләре арасында да Фазлан нисбәбе сирәк кенә булса да очрый. Ислам дөньясында мәгълүм хәдисче Шәфигый мәзһәбеннән булган Әбу-л-Касим Җәмаледдин дә Фазлан нисбәсен йөрткән[6].

Ибне Фазлан үз хикәятләренең берсендә угызлар минем Коръән укыганымны яратып тыңладылар дип яза (124 б.). Димәк, бүләкләр арасында китаплар да булган. Коръән белән бергә дидактик эчтәлекле китапларның, мәсәлән, «Кәлилә вә Димнә»нең дә булуы ихтимал. Чөнки «Кәлилә вә Димнә» эчтәлеге белән заманына хас тәрбияви максатларга тулысынча җавап бирә алырлык, патшаларның зәвыгына муафыйк әсәр. «Кәлилә вә Димнә»дә пәйгамбәрләр тарафыннан әйтелгән хикмәтле сүзләр, мәсәлләр дә аз түгел[7].

Менә шуннан чыгып, «Кәлилә вә Димнә» әсәренең Болгар иленә Ибне Фазлан илчелеге белән, бая аталган Коръән белән бергә китерелгән булуы да бик ихтимал диган нәтиҗәгә килә алабыз. Ул исәлектәге аерым сюжетларның безнең әдәбиятыбызга тирән үтеп керүе шул фаразның файдасына сөйләсә кирәк. Әлбәттә, бу гарәпләрнең болгарларны белемле, мәдәниятле итү теләгеннән түгел, ә бәлки сәяси максатларыннан эшләнгән, ягъни аларны ислам диненә күндерү, шуның аркылы сәүдә, алыш-биреш мөнәсәбәтләрен киңәйтү өчен кирәк булган.

Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә: Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе язылганга мең елдан артык вакыт үтте, ләкин аның теле шулкадәр аңлаешлы һәм җиңел укыла ки, әйтерсең лә аны бүгенге гарәп язучысы язган.

Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе әле бүген дә СССРда яшәүче кардәш халыкларның үткәнен өйрәнүдә һичшиксез кыйммәтле ядкарь булыр тора. Тарихчы галим А. Ю. Якубовский Ибне Фазлан сәяхәтнамәсен X гасырның иң ышанычлы чыганагы дип бәяли.

Бу мәшһүр тарихи сәяхәтнамәнең Димәшкъта икенче тапкыр басылып чыгуы ул Сүрия һәм СССР халыклары арасындагы мәдәни, дуслык бәйләнешләренең үсә, ныгый баруын күрсәтүче тагын бер җитди дәлил булып тора.

•

**Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН.**

---

[6] «Әл-Мөнҗид» (Гарәп теленең аңлатмалы сүзлеге). Бәйрут, 1969, 395 б.

[7] «Кәлилә вә Димнә». Бәйрут, 1983, 48 б.

# КӨНДЕЗГЕ ЯКТЫЛЫК

Муенында — әлмәкне хәтерләткән, үлем җәзасына хөкем ителү турында немецча язылган калай жетон. Кулларында — тимер богау. Өстеннән арестантлар халатын салган килеш, ярым шәрә хәлдә горур басып тора. Карашлары җитди, шикләнүләр-үкенүләрнең әсәре дә сизелми. Тагын өч минуттан соң аның башы гильотина пычагы астына куелачак. Ә иреннәре әйтерсең лә шигъри юлларны әйтеп тибрәнә:

Тиздән сүнәр, сүнгән йолдыз кебек,
Соңгы яшәү көчем.
Үләм, ләкин бөек халкым өчен,
Илем, халкым өчен!

Мин рәссам Фәрит Якупов картинасына карап уйланам...

Төрмәдәге гильотина пычагы — фашистларның «акыл хезмәте» җимеше. Шактый камил итеп эшләнгән. Ярым чуен, ярым титан.

Тәкәббер палачның куллары гильотина пычакларын төшерергә әзер. Җиңнәре сызганылган. Палачка каршы урында, гильотинаның икенче ягында, чал сакаллы, йөзенә канәгатьсезлек билгеләре чыккан, ачулырак карашлы мулла басып тора. Башында — чалма, кулында — бөҗралы, шомарып беткән озын таяк. «Шәфкатьле» мулла хезмәтеннән шагыйрь баш тарткан, «ахирәт газапларыннан» котылырга теләми, кылган «гөнаһларыннан» тәүбә итми. Инде шулай икән, Мостафа углы Мусаны «теге дөньяда» тәмуг җәзасы көтә. Бер генә дә түгел, ике җәза: берсе тәннеке, берсе рухныкы!.. Юк, шагыйрьнең рухы тәненә таңгәл. Ул Туган иле, туган халкы белән бер тән, бер җан булып яшәде, эшләде, иҗат итте, көрәште. Моңа аның бөтен гомере, тормыш һәм көрәш юлы шаһит. Авыр, котылгысыз, газаплы фаҗигалар аны үлемсезлеккә, гильотина пычагына китерде. Моның өчен аңа 791 көн үтәргә туры килде... Гильотинага свастикалы һәм кара кошлы фашистлар гербы чокылган. Әҗәл кошы Җәлил йөрәген чукырдай, канын эчәрдәй тора. Шагыйрь күкрәгенә мылтыклар төбәлгән. Алга атларга да, артка басарга да урын юк: аны бары тик үлем көтә. Җәлил тәненең яртысы кояшлы, якты, ә яртысы күләгәле, караңгылык каплап алган.

Тоткыннар артында ике олы тәрәзә. Тимер рәшәткәләр аша төрмәгә яктылык сирпелә. Рәссам Ф. Якупов сурәтләгән яктылык — җиһан-тереклек, тормыш-яшәү, хакыйкатьинану билгесе. Әйтерсең лә ул шагыйрь күңеле яктылыгы. Җәлил тарафыннан таш капчыкта язылган өч мең шигырь юлы көрәш, ирек яктылыгы бирә кебек. Әлеге яктылыкның кояш нурлары белән тоташканлыгын Җәлил һәм аның көрәштәшләре аңлый да, тоя да. Алар шул яктылык өчен якты дөнья белән саубуллашалар.

Бөтенроссия күргәзмәсенә куелган «Шагыйрь һәм палач» («Муса Җәлил») исемле картина, фронтовик-шагыйрь буларак, миндә әнә шундый уй-фикерләр уятты. Бөек Ватан сугышының кырык еллыгына багышланган әлеге зур күргәзмәдә меңнән артык рәссам катнашты. Алар арасында, илкүләм танылган сынлы сәнгать осталары белән бергә, яшь рәссам Фәрит Якуповның да әсәре бар иде. Әлеге картина күргәзмә девизына бик авазваш иде: «Тынычлыкны саклаклык һәм саклярбыз».

Сугыштан соң дөньяга килгән яшь рәссамның М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгына мәдхия укуы бик сөендерә. «Шагыйрь һәм палач» картинасы — авторның озак эзләнүләр нәтиҗәсе, иҗади уйланулар җимеше. Батыр йөрәкле шагыйрь образын калку итеп гәүдәләндергән әсәрләрдән, аерым алганда, Х. Якуповның «Хөкем алдыннан», И. Рафиковның «Җәлилчеләр» картиналарыннан соң, Б. Урманченың мәрмәрдән, В. Маликовның чүкелүле тимердән эшләнгән портрет-бюстларыннан соң, каһарман Җәлил турында яңа әсәр тудыру җиңел эш түгел, әлбәттә.

Яшь рәссам Ф. Якупов өчен батырлык темасы очраклы түгел. Ул аңа СССРның халык художнигы, Ленин премиясе лауреаты, профессор А. Мыльников һәм СССРның халык художнигы, Художество академиясенең член-корреспонденты, Дәүләт премиясе лауреаты Х. Якупов кебек күренекле остазлары йогынтысында килде. Яшь рәссам үзен чын мәгънәсендә бу ике олы рәссамның шәкерте дип әйтә ала. Колачлылыкка һәм масштаблылыкка турыдан-туры ул алардан өйрәнде. Ф. Якупов, Ленинградның И. Репин исемендәге сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтында укып, монументаль сынлы сәнгатьче дигән белгеч һөнәрен үзләштерде һәм

диплом эшен А. Мыльников җитәкчелегендә яклады: Кырлайдагы Тукай музее өчен буяулы бизәкләр төшерүне башкарды.

Яшь рәссам үзе Казанда туып үссә дә, аны табигать, авыл темасы җәлеп итте. Аның моннан сигез ел элек ясалган беренче картинасы «Җылы җил» дип атала. Бу рәсемдә тормыш шатлыгы тирә-якка бөркеп тора. Картинада ата, ана һәм малай тарафыннан әйтелмәгән шатлык-сөенечләрне, телгә килеп, төрле төсләрдәге салават күпере сөйләп бирә кебек. Геройлар табигать балалары рәвешендә сурәтләнә. Шатлык-сөенеч авазлары тугайболыннарда, басу-кырларда канатлы кошлардай яктан-якка очып йөри сыман. Ә җылы җил кешене табигать белән үзара бәйли шикелле. Әйтерсең, табигать баласы булган кешенең кайнар хисләре шул тере, җылы җанлы җилләргә әверелгән. Җылы җил белән кешенең шатлыгы-сөенече таңгал килә, һәм алар бер кошның ике канаты төсендә кабул ителә. Биеклектәге малай кулларын канат шикелле җәйгән, ул, әтисе һәм әнисе белән бергә, тормыш-яшәү өчен кинәнә, тантана итә, җил аңа салават күпередәй төсле-бизәкле булып тоела. Яшь рәссамның «Җылы җил» исемле беренче картинасы Художество академиясенең күргәзмәсен ачып җибәргән иде. Белгечләр аны Татарстанның бай табигатен тасвирлаган «синтез-образ» дип бәяләделәр. Картина-репродукция, яшь рәссамнарның эшләре белән бергә, төсле альбомда басылды, хатын-кызлар өчен чыгарылган календарьда да урын тапты.

«Җылы җил» картинасы сынлы сәнгатька үзенчәлекле саф җил килүен белгертте. «Җылы җил» яшь рәссамның иҗат күгендә беренче карлыгач иде. Фәрит очырган карлыгач очышын дәвам иттерде, әйтерсең лә, ул эзәргә чишмә эзләде һәм тапты. Ул онытылган чишмә иде. Бәлки шуңадыр, Ф. Якуповның икенче картинасы «Онытылган чишмә» дип аталды. Кайчандыр яшьлекләрен, пакь судай саф мәхәббәтләрен табигать кочагында уздырган карт белән карчык чишмә янында уйга талып утыралар: яшь чак, матур чак үткән дә киткән, белми дә калынган. Кеше гомере бер генә мизгел микәнни? Ул мизгелне туктатасы иде генә дә бит!.. Юк, дөрес уй түгелдер бу. Болай булса, тормыш үзе, хәрәкәт тоткарланачак... Онытылган чишмә генә тасвирланмый бу картинада, тереклек чишмәсе турында сүз бара. Онытылган чишмә — тереклек чишмәсенең яшерен, серле «су асты» агымы гына. Бабай белән әби янындагы бала — чал табигатьнең тере, җанлы җимеше. Онытылган чишмәнең башы — тереклек чишмәсендә. Яшь рәссам сәнгать теле белән әнә шул хакта әйтә һәм шуны картина итеп сурәтли.

Мәскәүнең «Советский художник» нәшриятында басылып чыккан «Совет Татарстанында сынлы сәнгать» исемле альбомда «Онытылган чишмә» лаеклы урын алды.

«Кызыл туй» әсәре яңа гына никахлашкан яшь кияү белән кәләш турында. Кәрзин тулы җиләк-җимешләр. Иң татлылары. Канатлары ныгыган казлар каңгылдаша. Әйтерсең лә алар яшьләрнең кавышу шатлыгыннан очынып, кешеләрдәге сөенеч-куанычны җиһанга таратырга телиләр. Яшьләр каршысында — тормышның ямен-тәмен белгән, ачысынтөчесен татыган өлкәннәр. Алар янында сөенече эченә сыймаган бер малай тора. Ул бөтен авыл халкын кызыл туй мәҗлесенә чакырырга әзер. Авызы ерылган, йөзе көләч. Өйләнешүчеләрне яше-карты урап алган. Өй капкасы төбендә кешеләр күренә. Туй зур булыр. Яшьләрне котларга килүчеләр өйгә сыймас. Хәер, йорт артында гына болын: ул киң, иркен. Ә богыл-кибән бер бөтен каравай-икмәкне хәтерләтә. Картина күе сары, кызыл буяулар белән эшләнгән. Ул буяулар, кояш нурларыдай, күңелгә җылылык бирә. «Кызыл туй» картинасы 1980 елда Казанда оештырылган «Зур Идел» зона күргәзмәсендә сынлы сәнгать сөючеләр тарафыннан яратып кабул ителде. Ә инде рәссамның «Әхмәт бабай һәм аның авылы» дигән әсәре, Бөтенсоюз күргәзмәсендә булганнан соң, Татарстан сынлы сәнгать музеенда үз урынын тапты.

Менә рәссамның «Әни җәе» исемле тагын бер шигъри картинасы. Табигатькә, болынга сокланып, алай гына да түгел, хуҗа булып ана утыра. Янында — балалар. Менә кемнәр — булачак хуҗалар! Бөтен табигатьне, болыннары-тугайлары, чишмәләре-сулары белән алар кабул итәчәк.

«Җиңүче» дигән әсәр сабан туе турында. Атка атланган егет. Кулында — радиоалгыч. Чабышта ул беренчелекне алган, җиңүче булып чыккан. Аңа карап торучы малайларның да җиңүче буласылары килә. Җиңүче егет хәтта карчыкларны да канатландырган, күңелләрендә горурлык хисләре уяткан.

Сагыш-гамь-уй-моң уяткан «Шәһәр кешесе һәм ат» картинасы берәүне дә битараф калдырмастыр. Бер агай шәһәр урамында ат белән очрашкан, һәм ул, үзенә дигән икмәк телемен кесәсеннән алып, гәпләшә-гәпләшә аны яраткан хайванына ашата. Ага кеше аңа узган яшьлеген, гомер юлын сөйли төсле. Аңлыйлар алар бер-берсен...

«Кич» картинасында кечке бистә күренеше сурәтләнә. Капка төбендә утыручы ана бишектә бала тирбәтә. Тирәсендә — балалар. Агай курайда уйный. Тылсымлы моңнар, бишектәге сабыйны йоклатып, еракларга китә дә кичке шәфәкъ белән аралаша, тирә-як төсле моң бизәкләренә күмелә...

«Риваятьләр илендә» исемле әсәр чал тарихны чагылдыра. Әлеге картинаны «Болгар бабайлар илендә» дип тә атап булыр иде. Археолог кулындагы табылдык чүлмәк игътибарны шундук үзенә җәлеп итә. Кемнәрдер өчен ул гади чүлмәк кенәдер. Ә гомерен тарихка багышлаган белгеч өчен — халыкның

зур хәзинәсе, гыйбрәтле вакыйгалар шаһиты. Шуңа да археолог йөзендә нур балкый. Җир казучы агайның да бу табышта өлеше бар. Мускул көче белән генә түгел, күңел күзләре белән тапкан ул әлеге кадерле хәзинәне.

«Риваятьләр илендә» картинасы белән Ф. Якупов Чувашстан башкаласы Чабаксарда оештырылган «Зур Идел» зона күргәзмәсендә катнашты.

Рәссам күптән түгел тынычлык һәм авыл темасын берләштергән күләмле әсәрен төгәлләде. «Бүген дөньяда» дип исемләнгән әлеге картинада заман киеренкелеге тасвирлана. Алгы планда — кулына әфлисун тоткан ир бала һәм кулларын сузган ата. Атаның йөзләре хафалы, күзләре уйчан. Сугыш җилләрен тидертәсе килми аның бәгырь җимешенә. Бала атаның тәнен-җанын җылыта, ул аңардан яшәр өчен күңел җылысы ала. Әлеге җылылык бөтен өйгә тарала, идәнгә сузылып яткан мәче дә моны тоя шикелле. Кышкы урамнан әле генә уйнап кергән малай гына аркасы белән җылы мичкә сөялгән. Ул әле күңел җылысын әтиседәй аңларлык дәрәҗәдә түгел...

Картлар — бабай белән әби «Бүген дөньяда» тапшыруын карап утыралар. Аларны дөнья, заман хәлләре борчый. Кечкенә генә өй — әйтерсең, бүгенге киеренке дөнья күзгесе. Алты кашыктан торган гаилә кешелек дөньясы белән бер камертонда яши. Чаршау артында яшь хатын күренә. Мөгаен, ул тагын бер бала анасы булачактыр. Дөнья нинди генә киеренке һәм катлаулы булмасын, яшәү дәвам итә.

Фәрит Якупов — тирән фикерле, кайнар хисле, төсләрне нечкәләп тоя белүче, лирикфәлсәфи юнәлештә иҗат итүче, туктаусыз эзләнүчән рәссам. Милли сынлы сәнгатьнең ул сыналган юлыннан бара. Яшь рәссам бу юлда әтисе белән әнисе җилкәләрен дә тоя. Әтисе Х. Якупов — «В. И. Ленинның Татарстан АССРны оештыру турындагы декретка кул куюы» (Л. Фәттахов соавторлыгында), «Пролог», «В. И. Ленин 1887 елда Казан университеты студентлары сходкасында», «Хөкем алдыннан», «Чаллы чибәрләре», «Көчле кешеләр» кебек күпләргә билгеле булган, танылган картиналарның авторы. Әнисе Рушан ханым Мостафовна да үзенчәлекле рәссамнардан санала. Ул үзенең натюрмортлары, табигать күренешләрен тасвирлаган әсәрләре белән күп кенә күргәзмәләрдә катнашты. Хәзер дә яңа әсәрләр өстендә эшли. Фәритнең энесе Әнвәр Якупов та — рәссам. Югары промышленность художество училищесын тәмамлап, ул рәссам-дизайнер булып эшли башлады. Брежнев шәһәрен төзү проектын булдыруда, Казан каласын һәм андагы музейларны реставрацияләүдә катнашты. Бер төркем дизайнерлар белән бергә, аның хезмәтләре күргәзмәләрдә лаеклы урын тапты.

Икенче энесе Айдар гына үзе өчен башкачарак һөнәр сайлап алды: Казан дәүләт университетының физика факультетында укып, ЭВМ белән эш итүгә кереште. Хәер, ул да балачакта рәсемнәр белән мавыга иде. Шуңар булса кирәк, Айдарның ике баласы — Тимур белән Линаның кулларыннан төсле карандашлар төшми. Фәрит кызы Алсу белән бергәләп, бабалары, әбиләре, әтиләре янында ярыша-ярыша матур-матур рәсемнәр ясыйлар. Фәрит тә аларның эшләрен даими күзәтеп бара, чөнки ул яшь рәссамнар өчен үзе остаз, биш ел инде художество училищесында укыта. Беренче шәкертләре яхшы һәм бик яхшы билгеләренә генә укыдылар. Ә хәзер икенче чыгарылыш әзерли.

Ял көннәрендә Харис Габдрахманович Якуповның иҗат мастерскоена кадерле яшь кунаклар җыела. Алар арасында аның оныклары да була. Харис Габдрахманович, хатыны Рушан Мостафовна белән бергә, кулларына беренче мәртәбә пумала алучыларга сабаклар бирә, төсле рәсемнәр ясарга өйрәтә. Бу игелекле эштә аның беренче ярдәмчесе — художество училищесы укытучысы, СССР Художниклар союзы әгъзасы рәссам Фәрит Якупов. Фәрит, нәни шәкертләргә карап, үзенең балачагын искә төшерә. Ул да шулай, бәләкәй чакта, әтисе белән әнисе янында бөтерелде. Сынлы сәнгатькә аның сүнмәс мәхәббәте шуннан башланды. Ләкин төсләр дә һәм моңнар да яратканга, ике төрле хистойгы кичерде: рәссам да, музыкант та булырга хыялланды. Балачакта художество мәктәбендә дә, музыка мәктәбендә дә укыды. Гобой, саксофон, труба кебек музыка коралларында менә дигән итеп уйнарга өйрәнде. Ләкин тавыш-аһәңнән битәр, төсле моң өстенлек алды, әтисе белән әнисе йогынтысында, сынлы сәнгать юлыннан китте, художество училищесын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлады. Икеләнүләр-шикләнүләр шулай арттa калды. Ә бит художество училищесына укырга кергәндә, ике сәгать буена бина янында уйланып басып торган иде: «Барып чыгар микән?.. Биредә әзерлекле, исемнәре билгеле булган рәссамнар укыйлар түгелме?.. Хәер, әтисе тудырган сынлы сәнгать мәктәбен күпмедер үзләштерде инде ул. Бу гына җитәрме?.. Кире борып җибәрмәсләрме?..

Мәһабәт бер бинаның иң соңгы катында урнашкан иҗат мастерскоенда Фәрит Якупов көндезге яктылыкта эшләргә ярата. Ә бу рәссамнар өчен уңыш башы икән. Мәскәүнең М. Горький исемендәге әдәбият институтында сынлы сәнгать нигезләрен укытучы профессор авызыннан минем үземә дә шул хакта ишетергә туры килде. Фәрит Якупов көндезге яктылыкны тормыш-чынбарлыкның үзеннән ала. Озынрак, күбрәк булсын иде көндезге яктылык мизгелләрең, яшь рәссам!..

**Кави ЛАТЫЙПОВ.**

# ДЕМЬЯН ФӘТХИ

**(1906—1943)**

Шигырь стиленең яңалыгы, фикерләренең үткенлеге, тасвирлауларының матурлыгы белән татар поэзиясендә үзенчәлекле урын алып торган шагыйрьләрнең берсе Демьян Фәтхи иде. Ул 1926-27 елларда беренче шигырьләре белән газета-журнал битләрендә күренә башлый. Шагыйрь үз әсәрләрендә көннең кадагына суга торган темаларны — завод-фабрикалардагы тырыш хезмәтне, наданлыкны бетерү өчен көрәшне, авылның яңалыкка омтылуын, кулакларга каршы кискен отпор бирүне һ. б. яктыртты.

Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдинов) 1906 елның 10 октябрендә Ульяновск өлкәсе Чардаклы районы Татар Колмаеры авылында ярлы крестьян семьясында туа. Башта үз авылларында укый, аннан соң Самарадагы Татар-башкорт педагогия техникумына укырга керә. Техникумда укыган елларында шигырьләр яза башлый. 1926 елны Демьян Фәтхи Казанга килә һәм Татрабфакта укый. Уку белән бергә ул газета редакцияләрендә дә эшли.

1929 елны шагыйрьнең беренче шигырьләр бәйләме — «Тальян» җыентыгы дөньяга чыга. Озак та үтми, «Металл тавышлары» исемле икенче китабы Мәскәүдә басыла. Демьян Фәтхи барлыгы 6 китап чыгара. Шулар арасында «Бояр урманында» дигәне, берничә тапкыр басылып, укучыларның мәхәббәтен казана.

Шигырь язудагы кайбер алымнары, рифмаларның сакланмавы Демьян Фәтхинең яңа формалар эзләү белән мәшгуль булуын күрсәтә. Вакыты белән ул Такташка иярергә, аннан өйрәнергә тырыша. Шагыйрь шулай ук Европа классикларын һәм рус язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итә.

Демьян Фәтхи озак еллар Ерак Көнчыгышта яши һәм анда гади эшче булып төрле эшләрдә эшли, рудниклар, шахтерлар тормышын өйрәнә, Себер һәм Ерак Көнчыгыш турында күп кенә әсәрләр иҗат итә. Революциягә кадәрге алтын табучы шахтерларның газаплы хезмәтен, коточкыч авыр шартларда яшәүләрен сурәтләгән «Алтын тайга трагедиясеннән» дигән әсәре әнә шул елларда язылган.

Бу авырлыкларга түзә алмыйча, эшчеләр 1912 елны баш күтәрәләр. Ләкин аларны «кургаш белән сыйлап каршы алалар, салкын тайга кары кан белән кызара».

Демьян Фәтхи, Бөек Ватан сугышы башлану белән, кулына корал алып фронтка китә. Ул алгы сызыкта да дошманнарга каршы көчле нәфрәт белдереп шигырьләр яза һәм фронт газеталарында бастыра.

Демьян Фәтхи 1942 елгы атаклы Сталинград сугышларында катнаша һәм яралана. Яралары төзәлгәч, ул яңадан алгы сафка баса, Сталинград каһарманнары турында поэма яза башлый. Ләкин шагыйрь бу поэмасын төгәлли алмый.

Шагыйрь үзенең фронттан җибәргән хатларында коточкыч авыр сугышларда, гигант бәрелешләрдә катнашуын яза. 1943 елгы хатында болай ди: «Сталинград янында немец-фашист гаскәрләрен чолгап алып, аларны тар-мар итү, кыру, җир йөзеннән юк итү сугышлары барды. Бу — гигант сугышлар барган, ут-ялкын чорнап алган урыннар. Алар тетрәгән тарихи көннәр һич тә истән чыкмаслар!»

Сталинград өчен барган сугышларда Демьян Фәтхи авыр яралана. Өенә — туганнарына язган хатында бу турыда әйтеп үтә: «Туганнарым, үземнең исән икәнлегемне, ягъни өченче тапкыр авыр яраланганнан соң, терелеп җиткәнлегемне хәбәр итәм. Яңадан фронтка — алгы сызыкка китәм...»

Яралары төзәлеп җитү белән, шагыйрь яңадан алгы сызыкка килеп баса һәм баһадирларча көрәшә. Явыз немец-фашист илбасарларына каршы автомат тотып атакага күтәрелүче батыр солдатлар һәм офицерлар арасында шагыйрь-солдат Демьян Фәтхи дә була.

Тормышны тирән сөюче, бай хыяллар белән яшәүче талантлы шагыйрь-солдат 1943 елны Кантемирово янында барган сугышта каты яраланып һәлак була.

**Самат ШАКИР.**

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

17 сентябрьдә Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышы булды. «КПСС Үзәк Комитетының апрель (1985 ел) Пленумы карарлары яктылыгында Язучылар союзы идарәсенең оештыру эшләрен яхшырту чаралары турында» доклад белән идарә секретаре М. Хәбибуллин чыкты. Фикер алышуда Г. Бәширов, А. Расих, Ш. Галиев, Җ. Тәрҗеманов, Н. Дәүли, К. Латыйпов һәм башкалар катнашты. Алар Язучылар союзы идарәсе алдында торган проблемалар турында сөйләделәр, иҗат итү өчен шартларны яхшырту һәм башка мәсьәләләргә тукталдылар.

## КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ ХӨРМӘТЕНӘ

1 сентябрьдә Оренбургта күренекле татар галиме, тарихчы, язучы, журналист һәм педагог Риза Фәхретдинев истәлегенә мемориаль такта ачу тантанасы булды.

Галимнең тормышы һәм иҗаты Оренбург белән тыгыз бәйләнгән. Ул биредә чыга торган «Шура» журналы редакторы була, «Хөсәения» мәдрәсәсендә эшли. Иҗатының Оренбург чорында ул 90 лап китап бастырып чыгарган.

«Правда» урамындагы йортта мемориаль такта ачылу тантанасына Казан һәм Уфа галимнәре, язучылар, Р. Фәхретдиневнең кызы Әсма Шәрәф, оныклары А. Шәрәф һәм Л. Еникеевалар килгән иде. Р. Фәхретдиневнең истәлеген мәңгеләштерүдә Оренбургның Ленин район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары А. Фролов, хезмәт ветераны М. Рәхимкулова, Х. Ямашев исемендәге китапханә каршында эшләүче әдәби түгәрәк җитәкчесе З. Шакиров, Бөтенсоюз тарих һәм культура истәлекләрен саклау җәмгыяте членнары зур көч куйган.

Митингта чыгыш ясаучылар галимнең күпкырлы эшчәнлеге турында сөйләделәр. Тантанада Ленинградтан академик А. Н. Кононовтан килгән тәбрик телеграммасы игълан ителде.

Мәрмәр тактага алтын хәрефләр белән мондый сүзләр язылган:

«Здесь стоял дом, в котором с 1906 по 1918 год жил ученый-мыслитель, педагог, создатель татарской историко-биографической энциклопедии, редактор журнала «Шура» в г. Оренбурге Ризаэтдин ибн Фахретдин. (1859—1936)».

Шул ук көнне Х. Ямашев исемендәге шәһәр китапханәсендә Р. Фәхретдиневнең тормышы һәм иҗатына багышланган фәнни конференция үткәрелде.

Конференция эшендә Казаннан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Ә. Хәйруллин катнашты.

## ТЕАТРГА ИКЕНЧЕ УРЫН

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры быел җәй илебез башкаласы Мәскәүдә гастрольләрдә булган иде. Татарстан сәнгать осталарының чыгышын башкала тамашачылары яратып кабул итте.

Сентябрь аенда бу иҗади коллективка тагын бер шатлыклы хәбәр килде. СССР Культура министрлыгы һәм культура работниклары профсоюзы Үзәк комитеты җитәкчеләре кул куйган телеграммада театрның быелгы беренче ярты еллыкта театр-тамаша оешмалары арасында барган Бөтенсоюз социалистик ярышында икенче урынны алуы турында хәбәр ителә.

## ЯҢА КОНЦЕРТ СЕЗОНЫ

Сентябрьдә Татарстан дәүләт симфоник оркестры яңа концерт сезонын башлап җибәрде. Концертта СССРның халык артисты Нәҗип Җиһановның симфоник сюитасы беренче тапкыр яңгырады. Казахстанның һәм Татарстанның халык артисты, профессор Ф. Мансуров җитәкчелегендә симфоник оркестр сюитаны зур рухи күтәренкелек белән башкарды.

Бу концертта шулай ук П. Чайковскийның фортепьяно һәм симфоник оркестр өчен язган Беренче концерты, Д. Шостаковичның Беренче симфониясе башкарылды.

## КЫРГЫЗСТАН РӘССАМНАРЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

Сентябрьдә Казанда Кыргызстан рәссамнары әсәрләреннән төзелгән күргәзмә ачылды. Татарстан Художниклар союзының күргәзмәләр залында соңгы биш елда иҗат ителгән йөз илледән әсәр куелды. Аларның авторлары — тугандаш республиканың танылган осталары А. Даиров, Д. Оморкулов, Н. Евдокимов, А. Осмонов, М. Әхматов, Д. Жолчуев.

Күргәзмәдәге әсәрләрдә бүгенге социалистик Кыргызстанның чынбарлыгы ачык

чагыла. Байтак рәсемнәр туган якның бай табигатен тасвирлый.

Яңа экспозицияне татар сәнгате аксакалы Б. Урманче һәм Кыргызстанның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Оморкулов ачты.

## МӘСКӘҮЛЕЛӘР ГАСТРОЛЕ

Моннан берничә еллар элек Москонцерт каршында «Хыял» исемле татар эстрада ансамбле оештырылган иде. Үткән чорда ул Урта Азия һәм Казахстанда, Идел буе һәм Уралдагы автономияле республикаларда, төрле өлкәләрдә гастрольләрдә булды. Сентябрьдә Мәскәү артистларының чыгышлары белән Татарстан тамашачылары танышты.

Композитор Сәйяр Хәбибуллин җитәкчелегендәге бу коллектив халык иҗаты һәм хәзерге заман эстрадасына нигезләп театрлаштырылган тамаша жанрында чыгыш ясый. Җырчылар Гүзәл Басыйрова, Роза Хәбибуллина, Илдар Шиһаповның башкару осталыгын тамашачылар чын күңелдән яратып алкышладылар.

## ЯҢА ПЛАСТИНКАЛАР

Бөтенсоюз «Мелодия» фирмасында Татарстан сәнгать осталарының яңа язмалары дөнья күрде. Илһам Шакиров иҗаты «Туган моңнар» дигән исем астында туплап чыгарылды. Анда халык җырлары һәм композиторлар әсәрләре кертелгән.

Римма Ибраһимова пластинкасы «Уйлану», Зөһрә Сәхәбиева белән Хәйдәр Бигичев җырларын туплаган диск «Рәхмәт сиңа» дип атала.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм тууына 70 яшь тулу уңаеннан күренекле язучы Атилла Расих, СССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 15 сентябрь Указы нигезендә, Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

Совет культурасы, әдәбияты һәм сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә актив катнашкан һәм унберенче бишьеллык заданиеләрен уңышлы үтәгән өчен СССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 22 август Указы нигезендә республикабыздан бер төркем әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре илебез орденнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр.

Композитор Хөснул Вәлиуллин, В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры артисты Юрий Федотов — Хезмәт Кызыл Байрагы орденына;

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе солисты Илһам Шакиров, СССРның халык художнигы Харис Якупов — Халыклар дуслыгы орденына;

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Ирек Баһманов, язучы Илдар Юзеев — «Почет билгесе» орденына;

Әлмәт татар дәүләт драма театры артисты Зәкәрия Гыйлемов, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Владимир Яковлев — «Аеруча хезмәтләр күрсәткән өчен» медаленә лаек булдылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Хәйдәр Бигичевка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 25 август Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## СИБГАТ ХӘКИМ МИРАСЫН ТУПЛАУ

РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең әдәби мирасын җыйнау максатыннан Татарстан Язучылар союзы каршында мирас комиссиясе төзелде. Аның председателе итеп Р. Мостафин, секретарь итеп Р. Хәкимов, членнары итеп Г. Рәхим, Н. Юзиев, И. Юзеев, Ф. Миңнуллин, Г. Шәрәфетдинов һәм Р. Миңнуллин иптәшләр сайланды.

Мирас комиссиясе шагыйрь С. Хәкимгә кагылышлы барлык истәлек-хатирәләрне, фоторәсемнәрне, башка документларны түбәндәге адрес белән җибәрүегезне үтенә: 420012, Казан шәһәре, Комлев урамы, 14, Татарстан Язучылар союзы идарәсе.

# ҖИР ХУҖАЛАРЫ

Сугыштан соңгы татар сынлы сәнгатендә тарихи-революцион тематик картина жанры мөһим урын алып тора. Мондый төрдәге әсәрләр Татарстан рәссамнары иҗатында күзгә күренерлек үсеш кичерде. Кырыгынчы-илленче елларга хас иллюстратив тенденцияне калку чагылышлы героик концепция, бүгенге заманның көн-үзәк вакыйгаларын философик гомумиләштерү кысрыклап чыгарды.

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Исмәгыйль Хәлиуллов татар сынлы сәнгатенең тарихи-революцион картина жанрын үстерүчеләр рәтенә керә. «В. И. Ленинның беренче мәртәбә кулга алынуы», «Крестьяннар авыру Тукай янында», «Беренчесе», «Отряд китте»... Сәнгать сөючеләргә яхшы таныш булган әлеге полотноларында автор тарихи-революцион теманы төрле яклап колачларга омтыла. Сурәтләнә торган вакыйгаларда үзенне катнашучы итеп тою әсәрләрнең ышандыру көчен арттыра. Рәссам моны яхшы аңлый. Алтмышынчы еллар сынлы сәнгатенең күркәм казанышы булып саналучы «Җир хуҗалары» картинасында И. Хәлиуллловның үткән тормыш вакыйгаларына нәкъ менә шәхси кичерешләре аша карарга омтылуы сизелә.

...Көзнең сүрән көне. Яшеллеген җуймаган иген басуына болытлар күләгәсе төшкән шикелле. Мәчетле авыл күренеп тора... Яшькелт-соры, зәңгәр һәм аксыл шәмәхә төсләрдә сурәтләнгән менә шундый пейзаж геройларны «әре планда» бирү өчен уңайлы җирлек булып хезмәт итә. Монументальлеккә якынайтылган фигуралар... Бу җирдә күп мәртәбә чәчкән-урган могтәбәр ил карты, гражданнар сугышыннан туган туфрагына әйләнеп кайткан солдат, буыннан-буынга мирас булып күчә баручы игенчелек хезмәтен кабул итәргә әзер яшүсмер... Карап торышка тыныч булып тоелучы әлеге геройлардан «җир җимертеп» эшләрлек әчке куәт ташып тора. Табигать манзарасы да тыныч итеп сурәтләнгән. Әмма геройлар үткән һәм үтәчәк юллар алай ук идиллик булып сизелми. Картинаның «тыныч» композициясенә эчке динамизм яшерелгән. Алгы пландагы суканың кызыл төстә булуы авылдагы бөек үзгәрешләр символы буларак кабул ителә. Картина геройлары йөзендә без героик чорның өч буынын күрәбез. Октябрь революциясеннән соң менә шундый хезмәт кешеләре җирнең чын хуҗаларына әверелделәр. Халыкның кан-яшен сеңдергән шушы җирдә алар хуҗаларча басып торалар һәм ышанычлы рәвештә матур киләчәккә карыйлар.

**Юрий ГОРШУНОВ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
өлкән фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелган «Башмагым» музыкаль комедиясеннән (Җәүдәт Фәйзи) күренеш.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)